**Вәлиев, Р. И.**

**Дөнья гаме**
публицистик язмалар, әңгәмәләр

Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.

ISBN 978-5-298-02143-2

Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиевнең бу китабына төрле елларда язылган публицистик әсәрләре, әңгәмәләре һәм депутатлык эшчәнлеге белән бәйле чыгышлары тупланды. Татар халкы һәм Татарстан язмышы, ил-көн гаме, туган тел, милли мәгариф һәм мәдәният-сәнгать хакындагы җитди уйланулардан торган бу җыентык укучылар күңеленә юл табар дип ышанабыз.

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Вәлиев Р. И., 2011
© Заһидуллина Р. Ә., төзү, 2011

# ДӨНЬЯ ГАМЕ

***Нәрсә ул иҗат?*** *Нәрсә ул* ***шигърият****? Мин гомерем буе шушы сорауларга җавап эзлим.*
***Иҗат ул****, бәлки, Ходай Тәгаләнең кешеләрдән яшергән иң олы серен – галәми чиксезлекнең ничек яралуын белергә, аңларга тырышудыр?*
***Иҗат ул****, бәлки, яхшыны яманнан, мәрхәмәтне золымнан аерырга өндәүче ихласи талпынудыр?*
***Иҗат ул****, бәлки, оҗмахтан сөрелгән гөнаһлы адәм балаларын фани дөнья утларына салып чыныктырудыр, яшәү мәгънәсен аңларга омтылудыр?*
***Иҗат ул****, бәлки, гаделсез җәмгыятьтә Гаделлек эзләп бәргәләнүдер?*
***Иҗат ул****, бәлки, хокуксыз халыклар хокукын даулап, бар дөньяга аваз салудыр?*
***Иҗат ул****, бәлки, Мәхәббәткә илаһи һәйкәл куюдыр?*
***Иҗат ул,*** *бәлки, таш бәгырьле бәндәләрнең күңелен эретергә тырышудыр?*
***Иҗат ул****, бәлки, кеше күңеленә үзең генә белгән сукмак салудыр, кеше җаны белән сөйләшүдер, җансыз матдәләрне дә җанлы итеп күрә белүдер?*
***Иҗат ул****, бәлки, дөньяның бүгенгесеннән канәгать булмыйча, аны яхшырак, матуррак, гаделрәк, камилрәк итеп күрергә теләү, шуның өчен көрәшүдер?*

*Әгәр дә шулай икән, димәк, шигырь, хикәя, повесть-роман язу гына түгел, безнең һәр кылган игелекле гамәлебез иҗат дип аталырга хаклы.*
*Бу китапка тупланган язмаларым шигырь яисә хикәя теле, әдәби әсәр калыбы белән иҗат ителмәгән. Әмма мин аларны үземнең шагыйранә иҗатымнан, роман-повестьларымнан аерып, бер читкә этәреп куя алмыйм. Чөнки миндә «ике мин» юк, мин бербөтен, минем иманым да, кыйблам да, язмышым да бер генә.*
*Мин үземнең һәр кылган гамәлемне иҗат диеп саныйм. Шигырь язаммы яисә композитор белән бергәләп җыр иҗат итәмме, газетага мәкалә әзерлимме яисә радио-телевидениедән чыгыш ясыйммы, авыл агайлары белән әңгәмә кораммы яисә парламент мөнбәреннән чыгыш ясыйммы, – болар барысы да минем өчен иҗат. Һәр кылган эшемдә мин ихласлыкка омтылам, гаделлек таләп итәм, кешеләрне битараф булмаска өндим. Чөнки битарафлык булмаган, көрәш дәрте кайнаган җирдә генә иҗатка урын бар, ихлас гамәлләр генә җәмгыятьне яхшы якка юнәлтә ала.*
*Адәм баласы халыкка, милләтенә, җәмгыятькә кайда күбрәк файда китерә, шунда эшләргә һәм иҗат итәргә, яшәргә, үз күңеле тарткан, кыйбласы күрсәткән юлдан барып, игелекле гамәлләр кылырга тиеш. Әгәр бүген, шигырь-җыр иҗат итеп, халкым рухына аз гына булса да куәт өсти алам икән, димәк, миңа шул илаһи эш белән мәшгуль булу фарыз. Әгәр дә бүген парламент мөнбәренә басып яисә халыкара мәйданга чыгып, милләтем һәм дәүләтем хакларын хаклый*

*алсам, моны вазыйфаи эшем генә түгел, ә рухи талпынышым, иҗади көрәшем дип атау да дөрестер.*

*Туа-тумыштан күңеленә шагыйрьлек уты салынган кеше башкача яши алмый, ул гомере буена шагыйрь булып кала. Аның һәр хәрәкәтендә, һәр кылган гамәлендә шагыйранә рух, шагыйранә дәрт һәм омтылыш чагыла. Бу китапка кергән язмаларда әле санап үткән сыйфатларны, дөнья гаме белән сугарылган уй-фикерләремне күрәсез икән, димәк, мин үз-үземә, шагыйрьлек асылыма һәм намусыма, иҗади язмышыма хыянәт итмәгәнмен дигән сүз.*

# БАЛАЧАК КАЙТАВАЗЫ

## Манарадан Ходай якынрак

Башлангыч мәктәптә без үзебезнең авылда элеккеге мәчет бинасында укыдык. Бу агач мәчет 1921 елда ук салынган булса да, бер якка да кыйшаймаган, таушалмаган, бары тик манарасы гына җил-давыл искән көннәрне, үз язмышыннан сыкранган сыман, ыңгырашып-ыңгырашып куя. Казан өчен, Татарстан, бөтен татар халкы өчен Сөембикә манарасы нинди мәгънәгә ия булса, безнең манаралы мәчет бинасы авылыбыз халкы өчен шул дәрәҗәдә кадерле, изге иде. Егерме беренче ачлык елында авылдашларыбыз аны ничек торгыза алганнардыр, бу могҗиза миңа бүгенге көнгә кадәр ачылмаган сер булып кала бирә. Ә инде аның ыспайлыгына, төзелеш мөкәммәллегенә, архитектура камиллегенә сокланмаган кеше булмагандыр. Каян килгән гап-гади авыл агайларына, мәдрәсә белемле балта осталарына андый маһирлык! Хәзер дә авыл саен мәчет салалар. Татарстанда аларның саны бер мең өч йөздән артып китте бугай инде. Әмма аларның күбесе, Аллаһ йортыннан битәр, түбәсенә манара торгызган гап-гади йорттан әллә ни аерылып тормый. Манаралары да бинасына ятышсыз, йә ул иләмсез юан һәм тәбәнәк-тупыйк була, йә завод торбасы сыман чамасыз биек һәм нәзек итеп эшләнә. Төзүчеләргә архитектураның асыл кагыйдәсе – пропорция саклый белү сәләте, гармония камиллеге җитмәү аркасында, халыктан тиенләп җыелган акчалар шундый зәвыксыз мәчетләр төзүгә сарыф ителә. Әйткәнемчә, безнең авыл мәчете агач архитектурасының гүзәл үрнәкләреннән саналып, дәүләт тарафыннан саклана торган тарихи һәйкәлләр исемлегенә кертелгән иде.

Мәктәптә укыганда минем иң зур хыялларымның берсе мәчет манарасының иң очына менеп, тирә-юньне күзәтү иде. Манара ике балконлы булып, өстәге балконга кадәр бормалы баскычтан менеп була. Әмма бу әле манараның өчтән ике өлеше генә, очлаеп килеп, түбәсенә көмеш төстәге ай кунаклаган конуссыман өлешендә баскыч-мазар юк, анда күгәрченнәр патшалык итә. Күгәрченнәргә кереп-чыгып йөрү өчен иң югарыда кеше башы сыярлык кына тәрәзә дә бар. Минем хыял ничек тә шул ай янына кадәр менеп, әлеге тәрәзәдән дөньяга күз салу иде. Аның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Берчакны мин әнкәйдән: «Мәчеткә манара нигә кирәк?» – дип сораган идем. Ул миңа: «Манарага менеп мәзин азан әйтсен өченгә, улым. Аннары... манарага менгәч, бөтен авыл күренә, тавыш та ераккарак ишетелә. Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная»,– дип җавап бирде. Бу сүзләр минем күңелемә гомерлеккә уелып калды. Манарага менеп әлеге күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карасам, миңа күрше авыллар гына түгел, Казан һәм Мәскәү калалары, бөтен дөнья, хәтта Ходай Тәгалә үзе дә күренер сыман иде.

Дүртенчедә укыганда, барыбер мендем мин ул манара очына. Калай астындагы черек такталарны сындыра-сындыра, кул-аякларны каната-каната булса да, иң өскә үрмәләдем. Күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карагач, әллә инде алдымда беренче мәртәбә шундый иркен манзара ачылудан, әллә инде манара чайкалудан күз алларым томаланып, башым әйләнеп китте, күңелгә шом керде. Әйтерсең Ходай Тәгалә рөхсәтсез-нисез үз биләмәләренә кергән өчен шулай акылымны томалый иде. Билгеле инде, мондый нәтиҗәләрне мин соңрак, бераз үскәчрәк ясадым, ә ул чакта кабалана-кабалана манарадан төшкәнем генә истә калган.

Үзебезнең авылда – башлангыч, күрше Шәңгәлчедә – сигезьеллык, Түбән Камада урта мәктәп тәмамлаганнан соң, мин башта – Казанга, аннары Мәскәүгә укырга китеп бардым. Авылга кайткан саен, әллә каян ук иң беренче булып мине мәчет манарасы каршылый торган иде. Әмма ул елдан-ел таушалып, әкренләп бер якка янтаеп бара. Бер кайтуымда аның инде калайларын җил каерып аткан, ае да менә-менә егылып төшәм дип кыйшайган иде. Минем яңа китабым чыгып, ярыйсы гына гонорар алган чак, Казаннан реставратор егетләр алып кайтып, 1979 елның көзендә мәчет манарасын сипләргә тотындык. Ул вакытта район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән яшьлек дустым Рифкать Муллин да ярдәм кулы сузды, авылдашлар да хәлдән килгәнчә булыштылар. Шулай итеп бергәләп манараны торгызып та куйдык. Ай күтәргән көнне бөтен тирә-юнь авыллар җыелышып көч-куәт биреп торганны күрү минем өчен әйтеп бетерә алмаслык

рәхәтлек иде. Дөрес, Казанга кайтуга башта ВЛКСМ өлкә комитетына, аннары партия өлкә комитетына чакырып, утлы табада кыздырдылар, идеологик яктан өлгермәгән кеше икәнлегемне, балаларны коммунистик рухта тәрбияләргә тиешле «Ялкын» журналында эшләргә әзер булмавымны искәрттеләр.
Мәчетебез никадәр матур булса да, рәхимсез еллар барыбер үзенекен итте, агач бина әкренләп тузып, берзаман ярым җимерек хәлгә килде. Аны сүтүдән башка чара калмаган иде. Әмма сүткәнче, авыл осталары, аның барлык үлчәмнәрен алып, бизәкләрен фотога төшереп, нәкъ шундый ук кыяфәттәге таш мәчет салырга вәгъдә бирделәр. Озак еллар төзелештә прораб булып эшләгән энекәшем бу эштә башлап йөрүче булды, финанс мәсьәләләре күбрәк минем өскә төште, авылыбыз эшмәкәрләре дә кулдан килгән ярдәмне күрсәтте.
Бүгенге көндә авылыбыз мәчете, элеккесеннән дә матуррак, мәһабәтрәк булып, дистәләгән чакрымнан балкып тора. Балчыклы урманын чыгуга, минем күз карашым иң беренче булып шул мәчет манарасын эзли башлый. Әгәр манара булмаса, авылымның бөтен яме китәр, хәтта авыл үзе дә бетәр, юкка чыгар кебек тоела миңа. Гомумән, мәчетсез, манарасыз мөселман авылын, татар авылын камил авылга санамыйм мин.
Шушы мәчет манарасы аша иң беренче мәртәбә дөньяның зурлыгын, матурлыгын күрүем, тәүге тапкыр хыялый күккә ашуым бүгенгедәй хәтеремдә, күз алдымда. Ул чакта мин күккә генә ашып калмадым, тәүге кат Аллаһы Тәгаләнең үзе белән очрашкандай булдым. Әле бүген дә колагымда әнкәемнең: «Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная», – дигән сүзләре яңгырап тора сыман.

## Минем беренче эшмәкәрлегем

Безнең әткәй озак еллар агроном һәм колхоз рәисе булып эшләде. «Уңыш» колхозының уңышы мул булганга, эшләре яхшы баргангадыр инде, көннәрдән бер көнне аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләделәр. Билгеле, безнең гаилә, безнең авыл өчен генә түгел, бөтен район өчен дә заманында зур вакыйга иде бу. Миңа ул чакта нибары җиде-сигез яшь кенә булгангадыр инде, әлеге орденның кыйммәтен аңлап бетермәгәнмендер, аны октябрят, пионер значогы кебегрәк бер нәрсә дип уйладым. Әткәйнең дә күкрәгенә орден тагып, кукраеп йөргәнен хәтерләмим. Өйдә апалар, сеңелләр белән без аны уенчык итеп уйный идек. Шулай сигез бала чиратлап уйный торгач, ул каядыр юкка чыкты, күпме эзләп, әлегә кадәр таба алганыбыз юк. Документы калды калуын, шуны күрсәтеп, киләчәктә, бәлки, дубликатын алырбыз, дип уйлыйм. Еллар үткән саен, әткәй-әнкәй белән бәйле һәрнәрсәнең кыйммәте арта бара икән...
Ул елларда орденга ияртеп бүләк бирү гадәте дә булган, ахрысы. Көннәрдән бер көнне безнең ишегалдында ялык-йолык килеп торган чып-чын велосипед пәйда булды. Билгеле, минем сөенечнең чиге-чамасы юк, бүген «Мерседес» бүләк итсәләр дә, ул кадәр үк шатлана алмас идем кебек. Авылыбызда моңа кадәр бер-ике генә велосипед булганга күрә, әлеге бүләкне берничек тә бәяләп бетерерлек түгел иде. Шуңа күрә минем үземә бу велосипедны орден өчен түгел, ә орденны велосипедка ияртеп биргәннәрдер кебек тоелды.
Велосипед утыргычына буй җитмәгәнгә күрә, борын каната-каната ике-өч көндә рам астыннан йөрергә өйрәндем. Җыен бәйрәме көннәрендә бөтен авылны шаккатырып авыл башындагы мәйданга велосипедта барырга иде исәп. Бәйрәм җитәргә берничә көн кала, күрше Мәликә апаларга Пермь шәһәреннән кунаклар кайтып төште. Араларында миннән ике-өч яшькә генә өлкәнрәк бер малай да бар иде. Аның белән тиз арада танышып, дуслашып та киттек. Миннән өлкәнрәк булгач, билгеле инде, аның аяклары педальгә җитә, рәхәтләнеп утыргычка утырып йөри ала. Әмма әнкәй: «Велосипедны беркемгә дә бирмә», – дип, колакка киртләп куйган иде. Әнкәй дигәннән, әткәй колхоз рәисе, коеп куйган коммунист булса да, әнкәй авылның заманында «кулак» дип аталган хәлле кешеләр нәселеннән иде. Шушы нәсел каны уйнагандырмы, белмим, кинәт кенә миндә алыш-биреш итү теләге уянгандай булды. Ә моның өчен бик кулай сәбәбе дә бар иде. Кайткан көнне үк теге малай (исемен оныткан мын инде) кесәсеннән пистолетка охшатып ясалган зажигалка чыгарып күрсәтте. Пистолетын безгә төбәп «черт» итүгә, көпшәсендә ут

кабынды. Велосипед шәп нәрсә булса да, мондый хикмәтне исә без – авыл малайларының моңа кадәр төшендә дә күргәне булмагандыр әле. Малай пистолетын чертләткән саен, минем күңелдә дә ут кабына, ул ялкын, көннән-көн көчәеп, бөтен тәнемә йөгерә иде. Рам астыннан йөрү шактый җайсыз булгангамы, мин инде бераз ялыктыра башлаган велосипедны әлеге пистолет-зажигалкага алыштырырга ният иттем. Ниятемне кунак малайга әйткәч, ул артык сатулашып тормады, зажигалкасын кулыма тоттырды да үзе велосипедка атланып урам буйлап китеп барды.
Билгеле, бу «бик тә отышлы» алыш-биреш хакында мин өйдәгеләргә әйтмәдем. Велосипедны әткәй миңа бирде бит, димәк, мин аның белән теләсә нәрсә эшли алам дип уйладым. Пистолетны чертләтеп, малайларны да куркыткан булдым, чыпчыкларга да төбәп атып карадым. Шулай көне буе туйганчы уйнадым мин аның белән, кич арып-талып пистолетны кочаклап йокыга талдым.
Иртә таңнан торган әнкәй, минем кочактагы пистолетны күргәч, башта куркып калган. Әткәйне чакырып күрсәткәч кенә аның чын пистолет булмаганын аңлаганнар. Билгеле инде, моның өчен миңа әткәйдән шактый ук эләкте. Зажигалканы кире биреп, велосипедны үзебезгә алып кайтырга туры килде. Шулай итеп, минем тәүге эшмәкәрлегем, алыш-бирешем уңышсыз тәмамланды. Әмма моңа һич кенә дә үкенмим, әгәр әткәй-әнкәй ул чакта мине хуплаган булса, бәлки, кемнәрдер кебек гомер буе шулай алтыга алып, бишкә сатып, сәүдә кылып йөрер идем әле.

**Туктатыгыз мине!**

Авылда велосипедта йөрмәгән малай булмый торгандыр. Берничә ел велосипед тәгәрмәче тәгәрәткәч, инде мотоциклга атланасым килә башлады. Мин алтынчы сыйныфта укыган чакта, әнкәйнең олы энесе Раиф абый кайдандыр мотоцикл сатып алып кайтты. Бер генә урынлы, артында тимер утыргычлы бу матайга авыл халкы нигәдер «Кәҗә тәкәсе» дигән исем кушты. Элекке хуҗасы шактый туздырып өлгергәндерме, матайның башы ремонттан чыкмый иде. Ярый әле Раиф абый алтын куллы кеше, сәгать тә төзәтә, чана да ясый, тәгәрмәч тә бөгә, пыяла да кисә, йорт та сала, тимерчелектә дә эшли, хәтта гармун да ясый, – кыскасы, белмәгән һөнәре юк. Мин күбрәк аның тирәсендә кайнашырга тырышам, мотоцикл төзәткәндә ачкыч-мазар биреп торам. Моның өчен ул мине соңыннан арттагы тимер утыргычка яисә бак өстенә утыртып урам әйләнә. Ә минем хыял тагын да зурракта: Раиф абыйдан рөхсәт алып, үземә рульгә утыруда. Ә андый рөхсәт һаман юк та юк. Велосипедта җил кебек очып йөргән малайга мотоцикл йөртү ни тора инде югыйсә!
Көннәрдән бер көнне Раиф абый матаен ишегалдында калдырып, күрше авылга шабашкага – йорт салырга китте. Бер киләм бабайларга, ике киләм, ә мотоцикл мине кызыктырып, ымсындырып, үзенә чакырып һаман шул килеш ишегалдында тора. Шулай кызыгып йөри торгач, түземем чиктән чыгып, матайга утырып карарга булдым. Аяк белән әллә ничә тибеп тә кабынмагач, бакча артындагы юлга чыгып этә башладым. Бер-ике төчкергәннән соң кабынып киткәч, сикереп менеп атландым да тузан туздырып урманга таба юл тоттым. Басу юлларын урап туйгач, матай белән авыл урамына керергә булдым. Күрсеннәр әле авылның кызлары-малайлары минем кем икәнлегемне, имеш. Авыл уртасындагы буа аша салынган тар гына агач күпергә җитәрәк, каршыма килүче атлы арбаны күреп югалып калдым. Инде нишләргә? Каушаудан тормозга басарга онытып, пырылдап күпер башына килеп җиттем дә, атка бәрелүдән куркып, рульне уңга бордым һәм матаем-ниem белән буага очып төштем.
Авыл халкы, җыелышып, мотоциклны багорлар белән буадан күтәреп алдылар.
Шул вакыйгадан соң Раиф абый берничә ел буе мине матае янына якын китермәде. Ә унынчыны бетергән елны (ул чакта без унбер ел укый идек) Раиф абый белән бергә шабашкада йорт салып йөреп, кеше кулыннан үземә тотылган «Иж-Планета» мотоциклы сатып алдым. Анысы да шактый хикмәтле матай булды аның.
Матай һәрчак ишегалдында яисә лапаста тора, миннән башка аңа утыручы юк. Әткәйнең матайга исе китми, ул ат җигеп йөри, энекәшем Рәмзил әле бәләкәй, матайда йөрерлек түгел, аңа әле ун яшь чамасы гына. Әмма, гөнаһ шомлыгына каршы, ул да миңа охшаган булып чыкты. Шулай беркөнне Рәмзил иптәш малайлары белән матайны урамга тәгәрәтеп чыккан да рульгә утырган.

Малайлар арттан бераз этеп баруга, минем «Иж-Планета» ярсып алга ыргылган. Велосипед йөртә белгән Рәмзил югалып калмаган, рульне туры тотып, авыл башына таба киткән. Басуны урап, яңадан авыл урамына килеп кергән бу. Безнең өй янына җитүгә, матайны туктатырга маташа, әмма газга басудан, рульне борудан башка моның җаен, рәтен белми. Шулай итеп, авыл урамнарын бер урый, ике урый, өч урый бу, әмма һаман туктый алмый. Урамдагы шау-шуны ишетеп, мин өйдән чыгып килгәндә, ул, артыннан куе төтен чыгарып, җан-фәрманга матайда килә, үзе бертуктаусыз: «Туктый алмыйм! Туктатыгыз мине!» – дип кычкыра иде. Без барыбыз да аптырашта, нишләргә белмичә, авыз ачып тик торабыз. Әгәр шунда бензины бетеп матай үзе туктамаган булса, бу хәл ничек тәмамланган булыр иде, белмим. Балачакта үземнең дә шундыйрак маҗарага юлыкканым булганга күрә, моның өчен энекәшкә артык каты кагылмадым. Бераз үсә төшкәч, ул мотоциклда миннән дә шәбрәк йөрергә өйрәнде, эшли башлагач, иң беренче итеп үзенә матай сатып алды.

**Мин ничек аучы булдым?**

Әткәй ягыннан безнең бабайларны элек заманда аучы булган дип сөйлиләр иде. Шуны ишетеп, берзаманны мин дә ауга чыгарга хыялланып йөри башладым. Ләкин иң беренче чиратта аучыга мылтык яисә тозак ише кораллар кирәк бит. Аларны каян табарга? Тозакка әллә ни исем китмәде, булгач-булгач, мылтык булсын дип, шуны табу чарасын эзли башладым. Кибеттән сатып алу хакында уйларга да мөмкин түгел, моның өчен, беренчедән, акча юк, икенчедән, рөхсәтсез сиңа аны кем сатсын ди әле. «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, көннәрдән бер көнне бабайларның мунча түбәсендә актарынып маташканда, иске-москы арасыннан күгәреп беткән бер мылтык килеп чыкты. «Ватык берданка ул, бернигә дә яраклы түгел», – дип, бабай аңа кул гына селтәде. Ә мин үҗәтләнеп эшкә тотындым. Башта мылтыкны сүттем дә, озынча ләгәндә керосинга батырып, берничә көн тоттым. Аннары, ком белән ышкып, күгәреген чистарттым. Сынган пружина урынына яңасын табып куйдым. Шулай маташа торгач, күгәргән берданка, ниһаять, мылтык төсенә керде. Яхшымы-яманмы, инде мылтыгым бар, ә патронын каян табарга? Бабайның эш кораллары әрҗәсеннән буш патрон табып, аңа шырпы күкерте төеп тутырдым, ядрә урынына вак кадак кискәләп салдым. Әмма күпме генә тырышсам да, мылтыгым барыбер атмады. Әмма шушы хәлләрдән соң әче телле авыл малайлары миңа «Аучы Разил» дигән кушамат тактылар. Гомеремдә бер чыпчык та атып карамаганга күрәдерме, бу кушамат мине бик тә гарьләндерә, шул мыскыллы сүзне ишетмәс өчен, җир тишегенә керердәй була идем. Тора-бара бу кушамат бердәнбер исемемә әверелде, аннан «Разил» сүзен төшереп калдырып, берзаман авылда мине «Аучы» дип кенә йөртә башладылар. Бу кушаматтан котылу чарасын уйлап, төннәр буе йоклый алмый ята башладым.
Әткәй айга берничә мәртәбә ул вакыттагы район үзәге Ширәмәткә райком җыелышларына бара торган иде. Бер баруында ул Ширәмәт базарыннан алагаем зур йорт куяны алып кайтты. Без ул куянга лапас эчендә тактадан бәләкәй генә өй сымак нәрсә әтмәлләп куйдык. Иртән-кичен-көндезен алдына ризык куеп, сабый бала караган сыман карасак та, ул яңа җиргә, яңа хуҗаларга иялəшә алмадымы, әллә берәр чире булдымы, көннән-көн боега барды, тора-бара бөтенләй тамактан калды. Ә көннәрдән бер көнне иртән хәлен белергә дип чыксам, ул, кышкы суыктан тораташ булып, хәрәкәтсез ята иде.
Инде нишләргә? «Куянны авыл зиратына кешечә җирләп булмый бит инде, һичьюгы, басуга яисә урман читенә илтеп күмәргә кирәк», – диде әнкәй. Көн буранлап торса да, җан иясен көнендә җирләргә кирәк дигәнне истә тотып, куянны җилкәгә астым да авыл читендәге урман ягына таба атладым. Ни әйтсәң дә, унике яшьлек малайны урман ягы шомландыра. Куркуны басар өчен, атмый торган мылтыкны да җилкәгә асып куйган булдым. Ул елларны урманда бүреләр шактый күп очрый торган иде. «Ахмак бүре атмаган мылтыктан да курка», – диләр бит безнең авылда. Басу капкасын чыгып бераз баргач, каршыма күрше Галиулла абый очрады. Урманнан утын әзерләп кайтуы икән. Минем җилкәдә мылтык белән куянны күргәч, ул: «Ай-һай, зурысын чәкегәнсең, юкка гына «Аучы» дип йөрмиләр икән үзеңне!» – дип тел шартлатты. Мин, нәрсә

әйтергә дә белмичә, моңсу гына елмаеп куйдым. Урманга җитәрәк, чанасына коры чыбык-чабык төягән тагын бер кеше күренде. Аръякның күкәй җыючы, әнкәй әйтмешли, теленә шайтан төкергән Ялтер Хәсәне икән монысы. Ул да алагаем зур куян түшкәсен күреп аһ-уһ итте.
Икенче көнне иртән мин авылның чып-чын аучысына әверелеп уянган идем инде. Минем куян атып кайтуым хакындагы хәбәр көне-сәгате белән бөтен авылга таралган, очрашканда инде хәзер миңа мыскыллап түгел, ә ниндидер бер хөрмәт белән «Аучы Разил» дип әйтә башладылар. Тора-бара мин бу куян маҗарасын бөтенләй оныттым, бабайның иске мылтыгын да яңадан мунча түбәсенә менгереп ыргыттым, аучы булу хыялы да әкренләп каядыр юкка чыкты. Мыскыллы сүз дип кабул итмәгәнгә, бөтенләй исем китмәгәнгәме, озакламый авыл халкы да «Аучы» сүзен онытып, мине яңадан мулла кушкан исемем белән Разил дип кенә йөртә башлады.

**Ат урлау**

Чит кеше белән очрашырга-танышырга туры килгәндә, мин, гадәттә, үземнең кемлегем хакында сөйләп тормыйм, «Алмаз Хәмзин белән бер авылдан», – дип кенә җибәрәм. Алмаз гаҗәеп талантлы һәм йөремсәк кеше. Үзе музыкант, җырчы, шагыйрь, сүз остасы, – кыскасы, татарда аны белмәгән кеше бик сирәк. Аннары унбер ел буена аның белән бер партада утыруыбыз, бергәләп җырлап, концертлар куеп йөрүебез, ярыша-ярыша шигырьләр язуыбыз хакында сөйлим. Шушындый кешенең дусты һәм авылдашы булгач, мине дә бөтенләй үк төшеп калган кеше түгелдер диюләренә өметләнәм.
Алмаз белән безнең михнәтле һәм маҗаралы балачагыбыз, яшьлек елларыбыз турында бик тә кызыклы һәм гыйбрәтле кыйсса язып булыр иде. Анысын киләчәккә калдырып, бу юлы үсмер чак елларының бер вакыйгасын гына бәян итәргә уйлыйм...
Минем әткәй, инде әйткәнемчә, колхоз рәисе, Алмазныкы – партком секретаре, алар гомер буе шулай бер-берсенә терәк булып, аралашып яшәделәр. Алмазның әтисе Наил абый сугышта аягын калдырып кайткан, урам буйлап килгәндә, әллә каян ук аның протезы шыгырдаган тавыш ишетелә иде. Мин, гомумән, сугыштан кайткан кешеләрдән, бигрәк тә аяксыз яисә кулсыз фронтовиклардан бераз шөлли идем. Бәлки, бу курку түгел, ә үземчә хөрмәт итү хисе булгандыр. Аннары нишләптер миңа сугыштан кайткан һәр кешенең өендә автоматы яисә пистолеты бардыр кебек тоела иде.
Мин әле бүген дә үземне Наил абыйга бурычлы кеше дип саныйм, аңа рәхмәтләр әйтеп яшим. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, без, укуны Зәй елгасы аръягындагы Кызыл Чапчак урта мәктәбендә дәвам итәргә ниятләп, документларыбызны шунда илтеп тапшырган идек. Әле яңа төзелә башлаган Түбән Кама шәһәрендә 1 нче урта мәктәп ачыласын ишетеп, Наил абый безнең документларны аннан кире алып, шул яңа мәктәпкә илтеп биргән. Ә Түбән Каманың 1 нче мәктәбе Алмаз белән безнең язмышта хәлиткеч роль уйнады дисәм, арттыру булмастыр кебек.
Туктале, ниятем бер вакыйга хакында сөйләү иде бит әле... Шулай без Алмаз белән Түбән Камада укып йөрибез, шәһәргә терәлеп торган Актүбә авылында интернатта яшибез, һәр шимбә авылга кайтып, дүшәмбе иртән китәбез. Безнең егет булып килгән, борынга ис керә башлаган чак. «Күрше тавыгы күркә булып күренә» дигәндәй, авыл кызларына күз салу юк, җай чыккан саен, күрше авылга йөрергә тырышабыз. Безнең авылга бер иңсәсе белән терәлеп торган Шәңгәлчене күрше авылга санау юк, якшәмбе җитте исә, урман артындагы Иштерәккә юл тотабыз. Җитмәсә, якын дустыбыз Рифкать тә, Алмазның әнисе – безнең беренче укытучыбыз Разия апа да – тумышы белән шул авылдан. Ә кызларының чибәрлеге турында әйтәсе дә юк инде! Шулаен шулай, әмма Иштерәккә карурман аша сигез чакрым барасы, аннары төн уртасында сигез чакрым кире кайтасы. Бу араны берничә мәртәбә тәпи-тәпи узгач, моның никадәр михнәтле сәяхәт икәнен чынлап аңладык. Аңлавын аңладык, ә күңел һаман шул авылга тарта бит, каһәр! Чираттагы якшәмбегә авылга кайткач, без, ниһаять, моның чарасын таптык. Әткәй иртә таңнан «Җүләр» исемле үзен-үзе белештерми чаба торган юртак айгырны җигеп эшкә китә, кич арып-талып өйгә кайта. Гадәттә, кичләрен мин Җүләрне аръяктагы ат абзарына илтеп, тугарып кайта идем. Бу юлы да әткәй кашовкадан төшүгә, аның урынына менеп утырдым да... Түбән очка, Алмазларга таба элдердем. Ул мине,

сөйләшенгәнчә, баянын күтәреп, капка төбендә көтеп тора иде. Кичке эңгер-меңгердә безне абайлаучы булмады, Җүләр, бер чөңгерүгә үк канатлы атка әверелеп, безне хыялдагы Иштерәк авылына таба очыртып алып китте. Шулай һәрчак җан ярсуы белән ак күбеккә батканчы чапканга, «Җүләр» исеме кушканнардыр инде аңа.

Иштерәктә Алмазларның туганнарында атыбызны тугарып калдырдык та үзебез клубка юл тоттык. Барышлый Рифкатьләргә дә кереп чыктык, клубта халык таралганчы, хәлдән тайганчы биедек, җырладык. Аннары, кызлар озаткан булып, кышкы авыл урамын кат-кат урадык. Эчләргә суык төшеп, аяклар бозлана башласа да, сер бирү юк. Чөнки без бит андый-мондый малай-шалай түгел, ә колхозның иң атаклы айгырын җигеп, затлы кашовкада утырып килгән Ташлык егетләре! Билгеле, ул атны әтиләргә әйтмичә урлап китү хакында кешегә сиздерү юк инде...

Төн уртасы җиткәч, безнең күңелләргә дә шом керә башлады. Әле урман аша кайтып, атны тугарасы бар бит. Әткәй сәгать биштә аны җигеп эшкә китәчәк. Аңа кадәр Җүләргә бераз хәл алып, тамак ялгап, тирен киптереп өлгерергә кирәк. Шундый уйлар белән ишегалдына керсәк, Җүләребездән җилләр искән. Кашовкасы урынында, ә атыбыз юк. Шунда гына без аның, баганага бәйләгән йөгәнне өзеп, ачык капкадан чыгып качканын аңлап алдык. Инде нишләргә? Төн уртасында җәяүләп өйгә кайтсаң, кара тавыш чыгасы көн кебек ачык. Атны сорамыйча алып китү, дөресрәге, урлау үзе бер җинаять булса, югалган ат өчен җавап бирүне күз алдына да китерерлек түгел. Мондый чакта авылга әти-әни янына кайту безнең өчен тәмугка барып керү белән бер иде. Кара кайгыга батып, Иштерәк урамын әллә ничә кат урасак та, атыбыз табылмады. Алмаз белән бүрекләрне батырып кидек тә төн уртасында урман аша уникe чакрым ераклыктагы Түбән Камага таба җәяүләп юл тоттык. Мең төрле уйлар уйлап, юл буе сөйләшми бардык. Урман читендәге төрмә биналары янына җиткәч, Алмаз ишетелер-ишетелмәс кенә: «Җүләр югалса, безне судка бирерләр микән?» – дип куйды. Мин җавап кайтармадым.

Шушы хәлдән соң без алдагы якшәмбедә авылга кайтмадык. Әти-әни шелтәсеннән, кеше күзенә күренүдән шулай нык курыкканбыздыр инде. Тагын бер атнадан Наил абый интернаттан безне үзе килеп алды. Аннары ниләр булганын сөйләп тормыйм, анысы болай да аңлашыла торгандыр. Ә Җүләргә бернәрсә дә булмаган, Иштерәккә беренче тапкыр гына килүе булса да, ул, адашмыйча, үз аягы белән Ташлыкка кайтып җиткән. Безнең моңа кадәр Иштерәккә йөрүебезне шәйләгән Наил абый икенче көнне үк ат караучы Газиз абыйны кашовка алырга җибәргән.

Шул вакыйгадан соң Җүләргә хөрмәтем бермә-бер артты, тора-бара ул минем якын дустыма әверелде. Бары тик еллар узгач кына мин аның гаҗәеп тә акыллы икәнен, ә үзебезнең ул вакытта никадәр башсыз, дөресрәге, «җүләр» булуыбызны аңладым.

*2010*

# СИНЕ, ӘНКӘЙ, СИНЕ САГЫНАМ...

Үз-үземне белә башлап, зиһенем яктырып, күзләрем чын-чынлап ачылган чорда иң беренче күргән, аңлаган, якын иткән кешем, һичшиксез, әнкәй булды. Бала чакта да, яшүсмер елларда да мин гел әнкәй янәшәсендә идем. Чөнки әткәй таңнан эшкә чыгып китә, кичен соң гына арып-талып кайтып керә. Ә мин көне буе өйдә әнкәй янында. Гаиләдәге сигез баланың алтысы кыз-кыркын, ә малайлардан өлкәне мин булганга күрә, йорт тирәсендәге ир-ат эше дә күбрәк минем җилкәгә төшә иде.

Әткәй колхоз рәисе булса да, әнкәй колхоздагы бер эштән дә калмаска тырыша. Шуның өстенә безне карау, безне киендерү, безне ашату-эчертү дә, абзар-курадагы эшләр дә аның өстендә. Дөрес, без – балалар – аңа ярдәм итәбез, әмма әлеге эшләрнең күбесен бары тик ул гына булдыра, ул гына башкара ала иде. Ничек барысына да өлгерә алгандыр, ничек барыбызның да көен көйләп бетергәндер, белмим, әмма ишле гаиләдәге очсыз-кырыйсыз мәшәкатьләрне салмак кына, кабаланмый гына, сукранмый гына ерып бара иде ул...

Мин бәләкәйдән үк бик иртә, сәгать дүртләрдә үк, йокыдан тора идем. Тора-торуга мичне ягып җибәрәм дә, җәй булса, ишегалдын себереп керәм, кыш булса, кар көрим. Аннары мич алдында кичтән калган ашны җылытып ашыйм. Әнкәй исә кич куйган камырын, күәстән алып, әвәли-әвәли ипи салырга әзерләнә. Гаилә ишле булганга, ипине ул көнаралаш сала иде. Ипи пешермәгән көнне мич түренә чуен белән елкы ите пешерергә куя. Көне буе мич җылысында изрәп утырган ат ите авызга алуга ук эреп киткәндәй була. Шушы яшькә җитеп, кайсы илләрдә нинди генә ашлар авыз итсәм дә, минем өчен мич түрендә чуенда изрәгән елкы ите белән әнкәй пешергән кара ипидән дә тәмлерәк ризык юк сыман.

Яшьлек елларымны, бала чагымны искә төшергәндә, иң элек күз алдыма алты почмаклы җыйнак кына йортыбыз килеп баса. Ишектән керүгә, сул яктагы элгечтә, әткәйнең туны эленеп тора. Ул йорт миңа нишләптер гел кышкы буран эчендә булып күренә. Чөнки җәен без өйгә кайтып та кермибез: йә бакча утыйбыз, урманда җиләк җыябыз, болында печән әзерлибез, йә Зәй суында балык тотабыз, су коенабыз... Ә кышын вакыт күбрәк өйдә үтә. Дөрес, якты вакытта чаңгы-чана шуулар, бозда кәшәкә уйнаулар да бездән читтә калмый иде. Ә караңгы төшеп өйгә кайтуга, мин, туңган аяк-кулларны җылытырга дип, мич башына менеп утырам. Аның төп сәбәбе, бәлки, җылынуда булмагандыр да... Минем мич каршындагы әнкәйгә якынрак буласым килә, чөнки минем аңа кичә укый башлаган китапны укып бетерәсем бар. Бераз укыгач, әнкәй мине туктатып нидер сорап куя. Без аның белән бергәләп китаптагы вакыйгаларга кереп чумабыз, андагы геройлар белән бергә яши башлыйбыз... Минем әдәбият белән, әдәби әсәрләр белән чын-чынлап кызыксына башлавым менә шундый озын кышкы кичләрдә керосин лампасы яктысында әнкәйгә кычкырып романнар, әкиятләр, повестьлар укыган чакларда башлангандыр инде...

Кайчакта мин китап укый-укый үзем дә сизмәстән йоклап китәм. Район үзәге Ширәмәткә ниндидер җыелышка киткән әткәйнең кайтканын да күрми калам. Иртән уянып тышка чыкканда, элгечтә әткәйнең кар исе, басу исе, ат исе сеңгән тун кесәсенә кулымны тыгам. Чөнки беләм, Ширәмәттән ул беркайчан да буш кул белән кайтмый, тун кесәсендә һәрчак безгә дигән тәмле перәнник була.

Әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк булып шигырьләр яза башлавыма, гармун уйнарга өйрәнүемә дә әнкәй сәбәпче булгандыр. Чөнки ул үзе дә такмаклар, бәетләр чыгара, хатлар язганда да арага шигырьләр кыстырырга ярата иде. Әнкәйнең әнисе Хәбибә әби хыялга гаҗәеп тә бай, телгә оста карчык иде. (Драматург, җырчы Зөлфәт Хәкимнең бабасы Хәкимҗан бабай белән бертуган алар.) Әнкәйнең ике энесе – бик шәп гармунчылар, телгә дә, эшкә дә оста кешеләр. Әгәр мөмкинлек булып, сәнгать юлыннан китсәләр, алардан менә дигән музыкант яисә башка төрле иҗат әһелләре чыккан булыр иде. Шуңа күрә язучылык оеткысы, иҗат хирыслыгы миңа әнием ягыннан күчкәндер дип уйлыйм.

Әткәй колхоз рәисе булса да, без һич тә мул тормышта яшәмәдек. Беренчедән, гаиләбез бик ишле, икенчедән, колхоз ул чакларда беркемгә дә акчалата хезмәт хакы түләми. Ә әткәй алдашуны, урлашуны белми торган «үтә кызыл» коммунист, гаҗәеп гадел кеше иде. Дөрес, без ач яшәмәдек, колхоз ел саен хезмәт көненә азмы-күпме икмәк өләшә, үзебез дә мал-туар асрыйбыз. Әмма киемсалым мәсьәләсендә кытлык шактый зур булды. Тик әнкәй безне беркайчан да кеше алдында кимхур итмәде, кигән киемнәребез гади булса да, һәрчак пөхтә, ыспай иде. Боларның һәммәсе өчен дә әнкәйгә һәм үзебезнең бәрәңге бакчасына рәхмәт әйтергә кирәк. Бәрәңге буразналары арасына утыртылган көнбагышны көзен җыеп, әйбәтләп мичтә киптергәннән соң, әнкәйләр, капчыкка тутырып, Алабуга базарына сатарга китәләр иде. Көнбагышны стаканлап сатып бетергәч, бар акчасына ситсы алып кайта да әнкәй, тегү машинасы янына утырып, безнең өчен җөй тегә башлый. Аның теккән киемнәре һич кенә дә кибетнекеннән ким булмый торган иде. Энесе Фаиз сугыштан алып кайткан трофей «Зингер» тегү машинасы бер безне генә түгел, ярты авылны өслебашлы иткәндер ул елларны.
Мин бәләкәй чакта безнең өйдәге бөтен җиһаз, мебель ише нәрсә әнкәйнең әтисе Нуретдин бабай кулы белән ясалган иде. Без сигез бала һәммәбез дә бабай ясаган бишектә тирбәлеп үстек, әнкәй, безне бабай ясаган бала арбасына утыртып, басуга урак урырга йөрде. Шул бала арбасы хәтта миңа университетка керергә дә булышты әле... Түбән Камада урта мәктәпне тәмамлагач, мин Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә керергә ният иттем. Ул чакта инде язган шигырьләрем, хикәя-парчаларым район газетасында да, хәтта республика матбугатында да басылгалый иде. Ниятемне әткәй дә, әнкәй дә хупладылар, мине юлга әзерли башладылар. Әмма әлеге дә баягы бәла: өйдә бер тиен дә акча юк. Мин моны кичләрен әткәй белән әнкәйнең чышпыш сөйләшкән чакларында ишетеп калдым. Әмма, каян алганнардыр, мин китәсе көнне әнкәй кулъяулыкка төреп кулыма унике сум акча тоттырды. Пароходта дүртенче класста бару – ике сум чамасы, кайту – ике сум, ә калганы имтиханнар тапшырганда яшәп тору өчен. Аның янына биштәремдә әнкәй пешергән ризыклар да бар. Әткәй мине ат белән егерме чакрымдагы Чургат (Красный Ключ) пристанена кадәр озата барды. Мин, шулай итеп, кесәдәге унике тәңкә акча белән, Казанны яуларга дип, авылдан чыгып киттем. Шактый еллар узгач кына белдем: әнкәй, бабай ясаган бала арбасын сатып, минем өчен әлеге унике сум акчаны юнәткән икән. Тәпи басканчы тирбәтеп йөрткән бала арбасының үсеп җиткәч тә кирәге чыкты, шул бала арбасы аркасында мин Казанга барып укырга кердем, югары белем алдым, тормышта үз урынымны табып, аякка бастым...
Дүртенче сыйныфны бетергән елны көннәрдән бер көнне Нуретдин бабай миңа кечкенә генә чалгы ясап бирде дә үзе белән печән чабарга алып китте. Бер ай буе бабайга ияреп йөри торгач, мин, шактый гына кул арасына кереп, чалгы селтәргә, печән чабарга өйрәнеп җиттем. Ә инде үзем чапкан бер йөк печәнне ишегалдына кайтарып аударгач, әткәй белән әнкәйнең башлары күккә тигәндәй булды. Шул елдан башлап мин һәр елны, башта – бабайга, аннары әнкәйгә ияреп, печән әзерләргә йөри башладым. Әнкәй әрәмә уентыкларындагы печәнне урак белән ура, ә мин болын читендә уйдык-уйдык калган урыннарны чалгы белән чабам. Хәтеремдә, печән чабудан бигрәк, ял иткәндә Зәй елгасында яисә Түгәрәк күлдә су коенулар, әрәмә арасында карлыган җыюлар, әнкәй сөйләгәнне тыңлап, хуш исле печән өстендә күккә карап ятулар калган. Әнкәй миңа Олы байның, Мулла баеның, Миткә чокырының, Куян атавының, Мукшы елгасының исемнәренең килеп чыгышын аңлата, болындагы һәр чәчәкнең, һәр үләннең, һәр куакның, һәр кошның исемен өйрәтә, үз авылыбызның, күрше авылларның тарихын сөйли...
Әле хәзер дә авылда печән өсте җитә башлаганда, минем күңелдә тынычлык югала, Казан кибетләрендә йөргәндә, күзләрем күбрәк чалгыларга төшә башлый, күңел Зәй буе болыннарына ашкына, һәр җәйне җай табып печән өстендә авылга кайтмыйча калсам, мин нәрсәнедер югалткан, ниндидер гөнаһ кылган кебек булам. Юк, эш монда мал-туар өчен печән әзерләүдә генә түгел, мәгънәсе тирәндәрәк бугай аның. Югыйсә энекәшем Рәмзил ул печәнне миннән башка да әзерли ала. Зәй буе болыннарында йөргәндә, каерып-каерып печән чапканда, мин гүя үземнең яшьлегем белән очрашам, гүя, чәчәкле печән өстенә сузылып ятып, әниемнең яшьлек хатирәләрен тыңлыйм. Кайтмый калсам, миңа яшьлегем үпкәләр, әнкәй рәнҗер кебек. Ә еллар узып, мәңгелек

чигенә якыная барган саен, минем һич кенә дә яшьлегемне үпкәләтәсем, әниемне рәнҗетәсем килми...

Яшьрәк чакта әнкәйнең хәтерен калдырган, үпкәләткән чакларыбыз да җитәрлек булгандыр инде. Шуларның берсе бигрәк тә хәтердә уелып калган... Мәскәүдәге Әдәбият институтында укый башлагач, мин беренче курста өйләнеп, тормыш корып җибәрдем. Хатыным Алия белән икебезгә дә егерме бер яшь тулганда, кызыбыз Сөембикә дөньяга килде. Торырга урын юк, тулай торакта бала белән яшәргә ярамый, дип, урамга ук куып чыгардылар. Мәскәү янындагы бер иске дачаның хуҗасы белән килешеп, шунда тора башладык. Аңа түләү, гаилә асрау өчен, заводка эшкә кердем. Көндез – лекциядә, төнлә – заводта... Шуның өстенә әле шигырьләр, проза әсәрләре язып маташам, китап чыгарырга җыенам. Дөнья куа-куа бәргәләнеп, суккаланып йөри торгач, ике ел вакыт үтеп тә киткән. Ә минем һаман яшь киленне әнкәй, әткәй янына алып кайтып күрсәткәнем юк. Кайтыр идем, юлга да, күчтәнәч-бүләк алырга да рәт юк. Көннәрдән бер көнне әнкәйдән хат килеп төште. Хатның башында авылдагы, өйдәге хәлләрне язган, ә азагын шигырь юллары белән тәмамлаган:

Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен...
Өйләндең дә, көйләндең дә, ахры,
Бер усалга каптың, күрәсең.

Бу юлларны укыгач, йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды. Әйе, чынлап та, кайтмавыма үпкәләгән, бик нык рәнҗегән иде ул. Мин утырып шунда ук шигырь белән аңа җавап хаты яздым...

Ниләр языйм, әнкәй, ниләр салыйм? –
Бар байлыгым – кәгазь һәм каләм...
Җитмеш тиен юлы шигыремнең,
Шигырьләтә генә җибәрәм.

Әнкәйгә исә күчтәнәчләрем дә, хәтта шигырем дә түгел, ә үзем кирәк икәнне мин шактый соңрак, яши-яши генә аңлый башладым.

Әнкәйгә багышлап мин аннан соң да шактый шигырьләр, җырлар яздым. Әмма инде хәзер мин әнкәйгә сүземнең генә түгел, ә үземнең дә кирәк икәнлегемне бик яхшы белә идем. Шуңа күрә, җай чыккан саен, әнкәй янына кайтуны мин үземнең гап-гади бурычым дип кенә санамыйм. Әнкәйне күрү, әнкәй белән сөйләшү минем үземә дә җан тынычлыгы бирә, минем иманымны бөтәйтә, кылган һәм кылырга җыенган гамәлләремә мәгънә өсти. Чөнки әнкәйнең хәер-фатихасы белән эшләнгән эш һәрчак игелекле була, әгәр яшәү рәвешемнән, тормыш итүемнән әнкәй канәгать, хәерхаһ икән, димәк, мин дөрес юлда.

Ә әнкәйне бик сагынган чакларда, мин аңа багышлап язган җырымны эчтән генә көйләп йөри башлыйм:

Инде менә ничә еллар буе
Сине уйлыйм, сиңа табынам...
Бөтенләйгә кайтып җитәрмен күк, –
Сине, әнкәй, сине сагынам.

*2003*

# ЯШЬЛЕГЕМ-ҖҮЛӘРЛЕГЕМ

## Затлы баян

Алмаз белән без һәр елны үзебезнең авыл Сабан туена кайтырга тырышабыз. Кайткач, ел буе күрешмәгән яшьтәшләр белән очрашырга-аралашырга да җай чыга, өйдән өйгә йөреп бәйрәм итәргә дә туры килә. Сабантуйда (элегрәк безнең якта аны «Җыен» дип йөртәләр иде) Алмаз бигрәк тә көтеп алынган кунак. Чөнки ул җырчы, баянчы, сүз остасы, аннан башка бер бәйрәмне дә күз алдына да китереп булмастыр кебек.
Бер елны чираттагы Сабантуйга кайтуына, әтисе Наил абый Алмазга бик шәп баян алып куйган иде. Германиядә эшләнгән бу затлы баянның бәясе дә машина хакы тора дип сөйләделәр. Бүләкне биргәндә, Наил абый Алмазның колагына киртләп куйды: «Бу баянда өйдә һәм клубта гына уйныйсың! Сабан туенда яисә урамда шыңгырдатырга иске баяның да бик яраган. Алай-болай ялгыш яңгыр тамчысы төшсә дә, яңа баянның күреге җебеп, рәттән чыгарга мөмкин».
Шулай да үзләренең капка төбендәге утыргычта уйнарга каршы килмәде Наил абый.
Сабантуй көнне иртәнге якта шулай капка төбендә яңа баянын сайратып утырганда, без өчәүләп: мин, энекәш Рәмзил һәм Рифкать дустыбыз машина белән Алмаз янына килеп туктадык. Тавышыбызны ишетеп, әтисе дә урамга чыкты. Яңа баянны, баянга кушып үзен дә мактый торгач, Наил абыйның күңеле йомшарды бугай, баянны Сабантуйга алып чыгарга рөхсәт бирде. Җитмәсә, Рифкать: «Сабантуйда да уйнарга ярамагач, нинди баян инде ул», – диюгә, бөтенләй таралып китте. Без дүртәүләшеп машинага төялдек тә, баян уйный-уйный, Югары очка, Җыен мәйданына менеп киттек.
Алмаз һәрвакыттагыча көне буе мәйдан уртасында, игътибар үзәгендә булды. Ул көнне, әллә кулында өр-яңа немец баяны булганга инде, бигрәк тә илһамланып уйнады, дәртләнеп җырлады, ак күлмәге манма су булганчы биеде ул. Соңыннан агач күләгәсендә авыл җитәкчеләре корган палаткада тамак ялгап, тамак чылатып чыккач, ул тагын баянын кулына алды. Аннары кайсы кайдагы агач төбенә табын корган яшьтәшләр, классташлар, авылдашлар безне берәм-берәм үзләре янына чакыра башлады. Һәммәсенең дә күзенә иң элек затлы баян ташлана, Алмазны тагын уйнарга, җырларга кыстыйлар. Шулай бер-бер артлы дус-ишләрне барлап йөри торгач, йөрәк хисләребез читлектән чыгып, безгә яшь арыслан холкы керә башлаган иде инде. Ә Алмаз ялындырып тормый, яңа баянны бертуктаусыз тарта да тарта. Малай чакларны искә төшерә-төшерә, кочаклашып җырлый-җырлый безнең йорт турына килеп җиткәч, минем энекәш, Алмазның ай-ваена карамыйча, ишегалдына култыклап алып кереп китте. Башта өйгә кереп, әнкәйнең тел йотардай бәлешен мактый-мактый баянда уйнады Алмаз. Аннары мәҗлес әкренләп мунчаның ял бүлмәсенә күчте. Мин мунча түбәсеннән туйра себеркесе алып төшеп, ташка пар җибәргәндә, Алмаз ләүкәдә затлы баян тартып утыра иде инде. Рәмзил белән Рифкать, ләүкәне сәхнәгә әйләндереп, бөтен дөньяларын онытып, «Ай гармун, гармун» җырын суза... Татар мунчасындагы эсселеккә чыдый алмаган өр-яңа немец баянының күреге, бер яктан кубып, үлем авазы чыгаргандай уфылдый, аһылдый иде.
Өйгә кайткач, Алмаз әтисеннән нинди сүзләр ишеткәндер, белмим, әмма бу баянны безнең беренче һәм соңгы күрүебез булды. Наил абый, бәлки, аны ремонтлап саткандыр, йә берәр нәрсәгә алышкандыр, анысы безгә мәгълүм түгел. Үзен бүтән күрмәсәк тә, безнең күңелләрдә ул «немец баяны», «мунча баяны», «затлы баян» булып, кызыклы хатирә булып уелып калды.

## Учитель Сәхби

Безнең авылда берничә атаклы кеше бар иде. Шуларның берсе «Учитель Сәхби» исеме белән даны таралган Сәхбетдин абый. (Бу затлы кушамат аңа утызынчы елларда мәктәптә укытканда ябышып калган булган.) Ул – авылның атаклы балта остасы, әмма бүрәнә күтәреп кара эш эшләп

йөри торган «оста» түгел, йорт-җирнең бизәкләрен ясаучы сәнгать дәрәҗәсендәге чын оста иде. Тирә-юнь авыллардагы иң матур тәрәзә кашагаларын агачтан уеп ул ясаган, иң мәһабәт урыс капкалар да аның эше, мәчет манарасын торгызганда да Сәхбетдин абыйга ярдәм сорап барырга туры килде. Җитмәсә, әле ул иң нәзберек уен коралы – скрипканы да үзе ясый һәм һәр елны Җыен башланган көнне, халыкны үзе артыннан ияртеп, скрипка уйнап, урам буйлап уза.

Кызык та, сәер дә кеше иде «Учитель Сәхби». Сугыш вакытында әсирлектә булганга күрә, ул авыл-колхоз тормышына артык катнашмыйча (дөресрәге, аны катнаштырмадылар), ялгыз гына яши, үз гомерен күбрәк үзе белән генә узгара иде. Хәләл җефете белән нигәдер сүзгә килешкәннән соң, ул, өеннән чыгып китеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр озак еллар берьялгызы үз ишегалдындагы остаханәсендә яшәде. Бу остаханә утын яга торган акшарланган мичтән, кечкенә сәке, аш өстәле һәм төп эш урыны – агач верстактан гыйбарәт иде. Хатыны белән бергә тормаса да, аңа авыз ачып сүз катмаса да, киемнәре каралгач, ул аларны ишегалдындагы ләгәнгә чыгарып сала, ә тегесе керләрне юып, үтүкләп болдырга өеп куя торган иде. Нигә ачуланышканнардыр, белмим, әмма үпкәләре никадәр зур булса да, алар чынлап аерылышмадылар. Сәхбетдин абый туксан дүрт яшенә кадәр үзе лапас ышыгында яшәсә дә, йорт-җирен, каралты-курасын һәрчак карап, йортына күз-колак булып торды.

Әнкәйнең энесе Раиф абый да немецларда әсирлектә иза чиккәнгә күрәдерме, әллә инде икесе дә балта остасы булгангамы, алар бик еш очрашалар, очрашканда сөйләшеп сүзләре бетми торган иде. Әгәр бераз төшереп тә алсалар, әңгәмә башта татарчадан русчага, аннары әкренләп немецчага күчә. Күрәсең, алар үзләре генә белгән серләрне кеше аңламасын дип шулай сөйләшә торган булганнардыр.

Авылга кайткан чакта мин, гадәттә, Яңа урамда юл өстендә яшәгән Сәхбетдин бабай янына сугылып чыгарга тырыша идем. Чөнки аның белән сөйләшүе кызык: ул күпне күргән, күпне белә, аның һәрнәрсәгә үз карашы, дөньяга үз мөнәсәбәте бар. Мин алып кайткан кала күчтәнәчләре белән чәй эчәбез, кайчакта ул дару өчен генә бераз мәен дә йотып куя. Яше туксанны узса да, җөмләсе төзек, фикере төгәл һәм ачык. Аның остаханә-сараенда түр стенага татар кыяфәтле Ленин портреты элеп куелган. Еллар тузаны һәм кояш нуры сеңеп, ул инде шактый саргайган, төсе китә башлаган. Бер кайтуымда мин аннан: «Сәхбетдин абый, без бит инде башка заманда яшибез. Ленин модадан чыкты, мәктәп балалары хәзер аның кем икәнен дә белми. Нигә бу иске портретны алыштырмыйсың?» – дип, ярым җитди, ярым шаяртып сорап куйдым. Ул, миңа бераз сынап карап торды да, авыз чите белән генә елмайды һәм: «Әлегә бу стенага эләрлек кешегез юк бит. Булгач, эләрмен», – диде.

Саубуллашып китәр алдыннан мин аннан берәр көй уйнавын сорадым. Ул ашыкмый гына үзе ясаган скрипканы кулларына алды да иң яраткан көен – Сәйдәшнең «Хуш, авылым»ын сузып җибәрде. Гүяки бу мизгелдә ул безнең белән түгел, ә үзенең туган авылы, узган михнәтле гомере белән саубуллаша иде.

Икенче кайтуымда, Сәхбетдин абый инде мине, кабер ташы кыяфәтенә кереп, авыл башындагы зиратта көтеп тора иде.

### Күктән төшкән бәхет

Бу хәлләр бераз үсә төшкәч, Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укыган чорда булды. Яшь артса да, бездән балачак беркатлылыгы чыгып бетмәгән иде әле.

Институтта ул вакыттагы Советлар берлегенең бөтен төбәкләреннән килеп, төрле милләт балалары белем ала. Мин күбрәк үзебезнең төрки кавемнәре, Кавказ, Балтыйк буе вәкилләре, рус егетләре белән аралашырга тырышам. Бурят шагыйре Нажмил Нимбуев, Таулы Алтайдан Бронтой Бедюров, руслардан Юрий Кузнецов, Александр Гаврилов, балкарлардан Мөхәммәт Геккиев, Али Байзуллаев белән көне-төне диярлек бергә йөрибез. «Бары – бергә, югы – уртак» дигәндәй, һәммә нәрсәбезне бүлешеп яшибез. Яшь чагында кешегә күп нәрсә җитмәсә дә, безгә иң җитмәгәне акча иде. Стипендия нибары 28 сум, аның да бер өлешен тулай торак өчен тотып калалар. Бу акчаны без тартып-сузып ике-өч атнага җиткерәбез дә соңгы атнада ачлы-туклы көн

күрәбез. Ә инде кемгәдер нәшрияттан яисә газета-журналдан гонорар килсә, ул көн барыбыз өчен дә бәйрәмгә әверелә иде.
Әлеге дә баягы акча бөтенләй бетеп, һәммәбез өчен дә кара көннәр башланган вакыт иде. «Казан утлары» журналының соңгы санында минем бер туплам шигырьләрем басылды, бөтен өмет шуның гонорарында. Вахта янындагы почта тартмасын көненә берничә тапкыр төшеп карасам да, гонорар һаман килми дә килми. Шулай пошаманга калып утырганда, минем бүлмәгә балкар егете шагыйрь Мөхәммәт Геккиев килеп керде. Үзенең авызы ерык, кулына ниндидер кәгазь тоткан. «Менә, сиңа күптән көткән гонорарың килде, йөз егерме сум!» – дип, керә-керешкә миннән сөенеч алырга тырышты бу. Билгеле инде, минем баш күккә тиде. Ләкин бүген якшәмбе, почта эшләми, тешне кысып булса да, тагын бер көн ураза тотарга туры киләчәк. Мөхәммәтнең моңа да җавабы әзер икән. «Берәрсеннән бурычка алып тор, бу кәгазьне күрсәтсәң, теләсә кайсы бирә инде сиңа». Мөхәммәтнең тапкырлыгына куанып, тиз генә тугызынчы катта яшәүче башкорт шагыйре Габделхак Игебаев янына чаптым. Ул Югары Әдәби курсларда аена йөз илле сум стипендия алып укый, җитмәсә, киң күңелле, шактый ук юмарт кеше. Кыскасы, берничә минуттан шәмәхә егерме бишлекне тирләгән учка йомарлап, мин каршы йорттагы гастрономда чиратта тора идем инде.
Ул көнне барча дус-иш җыелып, тулай торак бүлмәсендә төне буе бәйрәм иттек. Дүшәмбе иртән ишек шакуга уянып китсәм, каршымда бик моңсу кыяфәтле Мөхәммәт басып тора. «Разил дус, зинһар өчен, ачуланма. Кичә мин бераз шаярттым бит. Ул акча бланкысын мин шимбә көнне почтадан алып, үз кулым белән генә тутырган идем. Ә син, беркатлы шагыйрь, шуңа ышандың, пичәте булмаганына да игътибар итмәдең. Борчылма, барыбер киләчәк бит ул гонорар. Мин аны бераз ашыктырдым гына...»
Мин, ни әйтергә белми, телсез калдым. Шулчак Мөхәммәт: «Ә кичәге бәйрәм шәп булды бит! Мәңге онытылмаслык!» – диде дә мине кочаклап алды. Без икебез бергә шаркылдап көлеп җибәрдек. Чыннан да, әгәр Мөхәммәтнең шундый шуклыгы булмаса, мин ул гонорарны ничек алганымны, нәрсәгә тотканымны да белмәс һәм андый мәңгегә онытылмаслык бәйрәм дә оештыра алмас идем.

**«Наполеон» коньягы**

Мәскәүдә Әдәбият институтында укыганда, безнең иҗат семинары җитәкчесе мәшһүр шагыйрь, йөзләгән популяр җырлар авторы Лев Ошанин булды. Сугыш елларында Казан һәм Чистай калалары гаиләсен сыендыргангамы, үзе дә беркавым шунда яшәп алгангамы, әллә башка берәр сәбәбе булгандырмы, ул һәрвакыт миңа карата аталарча җылы мөнәсәбәттә булды. Студент чакта ук үзенең өенә һәм дачасына кунакка чакырып, ач вакытта тамагымны туйдырып, юлга акчалар биреп озатып кала иде. Мин институт тәмамлап Казанга кайткач та, Чаллыга күченгәч тә, араларыбыз өзелмәде, ул – минем янга, мин аңа барып, һәрдаим аралашып яшәдек. Шуңа күрә мин аны һәрвакыт сагынып искә алам, шуңа күрә дә мин аңа гомерем буена рәхмәтле.
1982 елны Лев Иванович мине хатыным Алия белән үзенең 70 яшьлек юбилей бәйрәменә чакырды. Тантананың беренче иҗат өлеше Мәскәүнең атаклы Әдипләр йортында (ЦДЛда), зур залда узды, анда юбилярның шәкертләре исеменнән сөйләү өчен миңа да сүз бирделәр. Бәйрәмнең мәҗлес өлеше шул ук бинада урнашкан ресторанның Имән залында оештырылган иде. Юбилейга Мәскәүнең затлы-зыялы кешеләре чакырылган, төрле республикалардан, хәтта чит илләрдән дә кунаклар бар иде. Кунаклар күплегенә карамастан, Лев Иванович беркемне дә игътибарсыз калдырмый, һәркемгә җылы сүз таба, килүчеләрне елмаеп каршы ала, китүчеләрнең һәммәсен кочаклап-үбеп озата. Саубуллашканда, ул минем кулга гаҗәеп затлы, безнең ишеләрнең моңа кадәр төшенә дә кермәгән «Наполеон» коньягы тоттырды. Һәм, ике кулын иң өстемә куеп: «Угостишь от моего имени своих близких друзей, если это возможно, пригласишь и моего друга Раиса Беляева», – диде.
Чаллыга кайткач, мин бу «Наполеон»ны кеше күзе төшми торган җиргә, диван башындагы тумбочкага яшереп куйдым. Исәбем, ничек кенә булса да, Лев Ивановичның аманәтен үтәү – Рәис

Кыямовичны кунакка дәшү иде. Ләкин бу бик ансат эш түгел, ул кем дә мин кем дигәндәй, ничек итеп инде тик торганда шәһәр башлыгын юньле мебеле дә булмаган шып-шыр фатирыңа чакырасың?! Әмма барыбер җае чыкты бит моның. Рәис Кыямович көннәрдән бер көнне Чаллының мин җитәкләгән язучылар җыелышына киләсе итте. Җыелыштан соң минем кабинетка кергәч, ниһаять, бөтен кыюлыгымны җыеп, Лев Ошанин юбилее турында сөйләп киттем, аннан сәламнәр дә тапшырдым. «Рәис Кыямович, мин монда янәшәдә генә яшим. Вакытыгыз булса, бәлки, бер татар шагыйренең сез биргән фатирда ничек яшәп ятканын күреп чыгарсыз? Лев Ивановичның сезгә дигән күчтәнәче дә бар анда». Ни могҗиза булгандыр, Рәис Кыямович ялт итеп сәгатенә карап алды да: «Киттек!» – дип кул селтәде.

Фатирга килеп керүгә, мин иң элек «Наполеон» янына ташландым. Ә ул юк, коньяктан җилләр искән. Инде нишләргә? Рәис Кыямович алдында адәм хурлыгына калам бит. Аптыраудан кызарып-бүртенеп аның янына чыктым да фатирым бүлмәләрен күрсәтә башладым. Рәис Кыямович, минем кабинеттагы китап шкафы янына җиткәч, капыл туктап калды, киштәдәге китапларны алып карый-карый, таныш авторлары хакында үз фикерләрен әйтә башлады. Безнең белән бергә килгән язучы Газиз Кашапов та сүзгә кушылды. Болар китаплар белән әвәрә килгән арада, мин сиздермичә генә күрше бүлмәгә чыктым да телефоннан янәшәдәге гастроном директорына – авылдашым Рафаэль Сәхәбинең ГПТУдагы сабакташы, дустыбыз Илһамга шылтыраттым. «Синдә «Наполеон» коньягы бармы? Юк, дисеңме? Алайса, үзеңдә булган иң яхшы коньякны алып, өч минутта минем фатирга килеп җит! Калганын килгәч аңлатырмын».

Китап киштәсе белән танышып, миннән яңа гына язган берничә шигыремне укытканчы, Илһам килеп җиткән, кухняга өстәл әзерләп куйган иде. Коньякның исеме «Москва» булгангамы, Рәис Кыямовичның күңелендә шик уянмады, ул, Лев Ошанинга рәхмәт әйтә-әйтә, рюмкага авыз тидерде дә саубуллашып чыгып китте.

Ә «Наполеон» коньягы югалуның хикмәте бик гади булган. Энекәшем Рәмзилгә мин фатирымның ачкычын биргән идем. Чаллыга килгәндә, ул, мин өйдә булмасам да, безгә кереп, бераз ял итеп, чәй эчеп чыга иде. Бу юлы дуслары белән килгәнгә, болар чәй белән генә канәгатьләнмәгәннәр, мәй эзли башлаганнар. «Минем абый запассыз тормый ул!» – дип, дуслары янында мактанып та җибәргән энекәш. Эзли торгач, яшерен урыннан табып, мактый-мактый коньякның башына да җиткәннәр. Мин ачулана башлагач, ул, гөнаһсыз күзләрен сабыйларча челт-челт йома-йома: «Наполеон заманында безнең илгә һөҗүм иткән кеше бит. Шуңа күрә рәхәтләнеп башына җиттек без аның, абый», – дип акланырга тотынды.

*2010*

# БЕЗНЕ БАЛЬЗАК КАВЫШТЫРДЫ...

Гаиләдәге хәлләр, ир-хатын мөнәсәбәте хакында бер чакта да язарга яратмадым мин. Дус-ишләрнең, күргән-белгәннең гаилә эшенә тыкшынуны, төпченүне дә хуп күрмәдем. Шулай ук минем өемдәге хәлләргә игътибар итәргә, «күп белергә» тырышучыларны да өнәмәдем. Чөнки гаилә – минем өчен ике кеше тарафыннан төзелгән кечкенә генә, әмма мөстәкыйль дәүләт. Ул дәүләтнең үз законнары, үз тәртипләре, үз дипломатиясе, «хәрби» серләре бар, һәм шуңа күрә аның эчке эшләренә тыкшыну бик зур әдәпсезлек, хәтта җинаять кебек тоела иде миңа...

Рәисә апа Юсупова кат-кат үгетли торгач, аңа хөрмәтем зур булганга гына, ниһаять, беренче мәртәбә сер капчыгымны бераз чишәргә риза булдым. Башта «Таһир-Зөһрә»дә чыккан бөтен мәхәббәт язмаларын укыдым, мин белгән бик тә могтәбәр кешеләрнең гаилә серләре аларга хөрмәтемне тагын да арттырды, хәтта кайберләренең «матур ялганы» да күңелемә хуш килде, һәм икеләнә-икеләнә кулга каләм алдым...

Нәрсә хакында язарга? Ничек язарга? Бар булганын тәфсилләп сөйләсәң, урамга шәп-шәрә килеш чыккандай булыр кебек, шагыйранә ялган белән тасвирласам, үземә үзем хыянәт итәрмен сыман. Әйдә, баштан кичкәннәрне чәчәкләп-чуклап бизәмичә, бернәрсәне дә арттырмый һәм киметми генә сөйләргә тырышып карыйм әле...

Казан дәүләт университетында ике ел укып йөргәннән соң, мин, 1967 елның августында Мәскәүгә барып, инде ничә еллар хыялланып йөргән атаклы уку йортының – М. Горький исемендәге Әдәбият институтының беренче курсына кердем. Мәскәү коточкыч зур, мин анда кечкенә йомычка кебек, халык ташкыны арасында бөтерелеп, агып йөрим, үземә үзем урын таба алмыйм. Күңелдәге моңсулык, ялгызлык хисе көннән-көн ныграк әчи, көчәя бара. Тулай торак тәрәзәсеннән күренеп торган Останкино манарасы әкренләп минем бердәнбер сердәшемә әверелде. Ялгызлыктан котылырга теләп, мин аның белән шигырь телендә сөйләшә башладым:

Мәскәү, Мәскәү...
Монда кем аңласын мине,
Кем соң минем көйне көйләсен?!
Кулларымны сузып, аста көтәм, –
Ыргыт миңа, ыргыт кочагыма
Останкино Сөембикәсен!

Шулай каңгырып йөри торгач, көннәрдән бер көнне, туганнарга, Казандагы дус-ишләргә хат салырга дип, Кремль янындагы Үзәк телеграфка кердем. Хат язып торганда, минем янәшәмә җитен чәчле бер кыз килеп басты. Нидер сизенеп, күтәрелеп карасам, Казан университетында минем белән бер группада укыган Гәүһәр Абдуллина! Ул, беренче курстан соң кияүгә чыгып, Мәскәүгә күчеп киткән иде. Сигез миллион кеше яшәгән шәһәрдә бердәнбер танышыңны очратудан да зуррак сөенеч булырга мөмкинме соң?! Гәүһәр мине Октябрь бәйрәменә кунакка чакырды, үзенең ире Әнвәр белән таныштырырга, ач студентны татар пәрәмәче белән сыйларга вәгъдә итте.

Аларның Мәскәү елгасы буенда урнашкан фатирлары бусагасын атлап кергән көн минем тормышның өр-яңа бусагасын атлау буласын, билгеле, мин ул чакта белми идем әле. Кыяр-кыймас кына өстәл янына барып утыргач, мине кунаклар белән таныштыра башладылар. Өй хуҗасы Әнвәр белән без, гомер буе таныш кешеләр кебек, бер-беребезне уздыра-уздыра, татар проблемасын хәл итәргә тотындык. Каршыда утырган шактый вәкарь кыяфәтле, әмма чын татарча мөлаем йөзле Мөгазимә апа Үзбәкстанның Маргилан шәһәреннән килгән, ул Гәүһәрнең әтисе Нияз абыйның олы туганы Мидхәтнең хатыны икән. Мөгазимә апа Мәскәүгә кызлары янына килгән, олы кызы аспирантурада, кечесе медицина институтында укый икән. Әнисе янәшәсендә елышып утырган, йөзеннән әле сабыйлык төсмерләре дә чыгып бетмәгән кече кызга Гәүһәр «Алла» дип эндәште. Аның үзен дә монда мәскәүчәләтеп Галя дип йөртәләр икән.

Танышкач, Алланың исеме Алия булып чыкты. Шулчак Муса Җәлилнең заманында Габдрахман Әпсәләмовка (ул чакта аны Абдрахман дип йөрткәннәр) әйткән сүзләре искә төште. Мәскәүдәге әдәбият түгәрәгендә танышкач, Муса аңа: «Казанга кайт, Абдрахман, Габдрахман булырсың», – дип әйткән, имеш.

Ашап-эчеп туйгач, мин кайтырга җыена башладым. Гәүһәрнең кысан фатирында Алиягә урын җитмәгәндер, ул да кайтырга ниятләде. «Кайсы якка кайтасыз?» – дип сорагач, «Добролюбов урамына», – диде. Ни гаҗәп, аларның тулай торагы минеке белән янәшә икән ләбаса. Сигез миллионлы шәһәрдә элекке курсташыңны очратуны, аларга кунакка килгән кызның минем белән күршедә яшәвен язмыш шаяртуы димичә нәрсә дисең инде?!

Ул арада минем Бальзак иҗаты белән җенләнеп йөргән көннәрем иде. Алия дә аның күп әсәрләрен укыган икән. Юл буе француз әдәбияты, Бальзак геройлары хакында сөйләшеп кайттык. Ә Бальзактан, Бальзак геройларыннан мәхәббәт маҗараларына бер адым гына кала инде... Икенче көнне безнең тулай торакта шагыйрь Евгений Евтушенко кичәсе булырга тиеш иде. Мин, Алияне шул кичәгә чакырып, тулай торак ишеге төбендә моңсу гына саубуллаштым. Ул кистереп вәгъдә бирмәде: «Җай чыкса, килермен», – диде. Аның әле ул чакта татарчасы бөтенләй диярлек юк, без икебез ике телдә сөйләшә идек. Шуңа күрә минем аңа беренче бүләк иткән китабым да «Татарча-русча сүзлек» булды.

Мин аны икеләнә-икеләнә тулай торагы ишеге төбендә урамда көттем. Үзбәкстанның эссе һавасында пешеп өлгергән «йөзем кызы»ның авылдан көчкә качып котылган «бәрәңге малае» белән аралашасы, якынаясы килүенә минем аз гына да өметем юк иде. Ә ул килде... Тулай торакта яңгыраган шигырьләрне нәкъ безнеңчә йотылып тыңлавы, аның бүгенге урыс шигъриятеннән шактый хәбәрдар булуы минем күңелне бөтенләй эретеп җибәрде. Кичә кич троллейбуста кайтканда башланган әңгәмә бүген безнең бүлмәдә дәвам итте. Шулай итеп, безнең танышып, якынаеп китүебезгә Бальзак белән Евтушенко сәбәпче булды. Шушы көннән, шушы мизгелдән соң, безнең язмыш елгалары кушылып бергә ага башлады.

Яхшыдырмы, ямандырмы ул, белмим, минем һәммә җирдә ашыга, кабалана торган гадәтем бар. Алия белән танышуга берничә атна үткәч, без инде, гаилә корып, бергә яши дә башладык. Мин бурят шагыйре Намжил Нимбуев костюмын киеп, Алия Римма апасыннан ике размерга зуррак яңа туфли алып, аның башына кәгазь дөңгечләп, загска киттек. Язылышып кайткач, тулай торакның бишенче катындагы минем бүлмәдә дүрт кеше «гөрләтеп» туй ясадык. Алия тәмле итеп аш пешерде, мин кибеттән шампан белән коньяк алып кердем. Туй мәҗлесендә Алиянең апасы Римма белән ул чакта Мәскәүдә укучы шагыйрь Рәдиф Гатауллин катнашты. Мин ул көнне әле бу гамәлемнең язмышымдагы иң зур вакыйга буласын белми дә, аңламый да идем. Без таң атканчы көлдек, шаярдык, җырладык, биедек, аннары мин, әле шактый вакыт мәхәббәт исереклегеннән айный алмыйча, әсәрләнеп йөрдем.

Ә инде гөнаһлы җиргә төшеп, тормыш мәшәкатьләре белән күзгә-күз очрашкач, дөнья үзе безнең белән уйный, безнең белән усал итеп шаяра башлады. Өйләнешеп бергә яши башлагач, мин, Алиягә багышлап, «Вәгъдә» исемле шигырь яздым:

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа,
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым – шигырьләрем
Һәм дә кара икмәгем.

Күкне бирә алмам сиңа...
Йолдызсыз да итмәмен.
Айны бөтен көе саклап,
Сине, ахры, көткәнмен.

Шатлыкларым тулы килеш,
Кайгымны да түкмәдем.
Йортым тәбәнәк булса да,
Биек әле күкләрем.

Бәлки, бәхетле булмассың...

Бәхетсез дә итмәмен.
Оҗмах бирәм димим сиңа,
Тәмугка да кертмәмен.

Егерме яшьлек чакта язган бу шигыремә мин гомер буе тугрылыклы булырга тырыштым, үземнән яхшырак булып күренәсем, шулай итеп аны да, башка кешеләрне дә алдыйсым, яшьлек вәгъдәмне рәнҗетәсем килмәде. Юк, мин һич кенә дә бөтен яктан камил холыклы, камил фигыльле идеаль кеше түгел, әмма барыбер үземне бар булганым белән, бөтен кимчелекләрем белән кабул итүләрен телим... Үзем телим, ә үзем янәшәмдәге кешеләрне һич кенә дә бөтен кимчелекләре белән кабул итеп бетерә алмыйм. Еш кына үземне шуның өчен әрлим, үзем белән бәхәсләшеп, дошманлашып бетәм... Гомумән, минем иң зур дошманым мин үземдер, шуңа күрә дә төннәр буе йоклый алмыйча, дөнья белән бәхәсләшеп ятканда, бөтен ялгышларым, хаталарым, уңышсызлыкларым өчен һич кенә дә башкаларны түгел, бары тик үземне генә гаепле саныйм, үземне генә битәрлим.
Мин һаман үзем турында сөйлим, ә сүз икебез хакында, гаилә тирәсендә барырга тиеш иде бит... Яши башладык шулай. Торыр урын – тулай торак бүлмәсе, бөтен байлык – стипендия акчасы. Алияне минем тулай торакка кертмиләр, шуңа күрә кача-поса бер-беребезгә кунакка гына йөрешәбез. Шул йөрешүләрнең нәтиҗәсе булып, икенче курста укыганда, кызыбыз дөньяга килде. Чәчәк күтәреп бала табу йортына бардым, ә үземнең көләсе дә, кычкырып елыйсы да килә. Чөнки бала белән Алияне алып кайтыр урын юк, тулай торак коменданты бүлмәгә кертмәсен әйтеп, кисәтеп куйды. Гариза язып, ректорга киттем, ярый әле ул, мәрхәмәтле җан иясе, бер ай яшәргә рөхсәт биреп чыгарды. Ай буе балага исем кушу артыннан йөрдем. Кызыбызга, чын татарча булсын дип, Сөембикә исеме кушарга ниятләгән идек. Мәскәү загсындагы исемнәр китабында андый исем юк икән. Казанга, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, татарда шундый исем барлыгын раслауларын сорап, хат яздым. Минем гозеремне бала-чага шаяруы дип аңладылармы, әллә башка сәбәп беләнме, нишләптер җавап бирүне кирәк санамадылар. Көтеп-көтеп тә Казаннан хәбәр килмәгәч, В. И. Ленин исемендәге иң зур китапханәгә барып, андагы егерме миллион китап арасыннан татар тарихына караганнарын эзләп таптым да, Сөембикә ханбикә исеме кергәннәрен сайлап, загска чаптым. Әмма бу юлы да мине бик төксе каршы алдылар. Чөнки китапларның берсендә ул исем «Сөембикә» дип язылса, икенчесендә «Сөенбикә», өченчесендә «Суюнбикэ» дип әллә ничә төрле бирелгән иде. Загс хезмәткәре китапларны миңа кире бирде дә, башын аска иеп, нидер язуын дәвам итте. Шулчак минем күңелем тулды, кочагымдагы китапларны ташлап, чыгып йөгерәсем килде. Бишектә яткан исемсез кызымнымы, әллә үземнеме, әллә инде кимсетелгән хокуксыз халкымнымы кызганып, күзләремнән кайнар яшьләр тәгәрәп төште. Минем тораташтай басып торуыма аптыраган ханым, башын күтәреп карады да, теш аралаш кына: «Упрямый татарин...» – дип куйды. Берничә минуттан инде мин, Мәскәүгә һәм бөтен дөньяга булган рәнҗүләремне онытып, Сөембикәле таныклык белән, тулай торакка очып кайта идем.
Әмма безнең маҗаралар моның белән генә тәмамланмаган икән әле. Бер ай эчендә фатир таба алмагач, комендант көн саен бүлмәгә кереп, вәгазь укый башлады, тиз арада чыгып китмәсәк, ректорга хәбәр итәсен әйтте. Аннан-моннан акча җыештырып, Алияне бала белән әти-әнисе янына Үзбәкстанга озатудан башка чара калмады.
Ул кайтып киткәч, мин көне-төне фатир эзләп чаба башладым. Эзли торгач, ниһаять, Мәскәүдән унбиш чакрым читтәге Перловская станциясенә барып юлыктым. Шундагы бер иске дачаның хуҗасы белән күрешеп, аена утыз тәңкәгә килешеп кайттым. 1968 елның ноябрендә, җиргә беренче кар төшкән чакта, Алия, Сөембикә һәм мин шул йортта яши башладык. Минем стипендиянең, димәк, бөтен гаилә бюджетының егерме алты сум илле тиен икәнлеген, Алиянең академик ял алуын әйтсәм, безнең хәлләрнең ничек икәнлеге аңлашыла төшәр. Җитмәсә, фатир эзләп йөргәндә калдырган лекцияләр өчен, мине өч айга стипендиядән дә мәхрүм итеп куйдылар. Инде нишләргә? Ярый әле Алиянең аш-суга осталыгы бар, юкны бар итеп, иң очсызлы балыклардан да әллә нинди ашлар пешерә, каткан ипиләрне сөттә җебетә дә маргаринда

кыздырып безне сыйлый. Шул чакларда бездә «кунак булган» Аяз абый Гыйләҗев әле дә Алиянең бу тәмле ризыкларын очрашкан саен сагынып искә ала.
Шушы иң ярлы һәм чарасыздан нишләргә белмичә тилмергән елларны кайчакларда мин әле дә сагынып куям. Егермешәр яшьлек ике бала-чаганың гаилә корып, чит шәһәрдә институтта укып, бала үстереп яши алуына һәм югалып-адашып калмавына бүген дә гаҗәпләнәм. Икебез ике якка китеп бару өчен ул вакытта безнең яшьлек кайнарлыгыбыз да, юләрлегебез дә җитәрлек иде югыйсә.
Бу тормыштан өмет өзеп, бөтен нәрсәгә кул селтәр чакларда мине янәшәмдәге яхшы кешеләр коткарып калды. Мәскәүдә укыганда, әткәйнең бәгырьләргә үтәрлек итеп үгет-нәсыйхәт биреп язган хатлары, әнкәйнең авылда калган тагын җиде бала авызыннан өзеп безгә җибәргән күчтәнәчләре, катлы-катлы мәгънә тулы шигырьләре һәр адымда сагалап торган хәвефләрдән, ялгышлардан сакларга булышканнар... Ә инде Әдәбият институты профессоры, иҗат семинарындагы җитәкчем, үзенең «Һәрвакыт булсын кояш» җыры белән бөтен дөньяга танылган шагыйрь Лев Ошанин Мәскәүдә минем җан сакчым да, тән сакчым да иде, дисәм, арттыру булмастыр кебек. Сөембикә туып берничә ай узгач, моңсуланып кына урамнан барганда, каршыма Лев Иванович очрады. «Хәлләрең ничек?» – ди ул, үзе һәрвакыттагыча бөтен йөзен балкытып елмая. «Әйбәт, Лев Иванович», – дигән булам мин. «Ничек әйбәт булсын? Үзеңнең кызың туган, ә үзеңнең торыр урының да юк. Җитмәсә, стипендиядән дә колак каккансың икән. Бар, кибеткә кереп, кызыңа һәм Алиягә бүләкләр ал», – диде дә ул, минем ай-ваема да карамыйча, кулыма ике йөз (!) сум акча тоттырды. «Ә бурычымны кайчан кайтарыйм соң?» – диеп ык-мык иттем мин. «Баегач бирерсең», – диде ул һәм елмаеп китеп тә барды. Ике елдан соң шигырь җыентыгым дөнья күреп, аның өчен гонорар алгач, беренче эш итеп Лев Иванович янына йөгердем. «Баегач китерерсең, дигән идегез, менә мин баедым, гонорар алдым», – дип акча сузгач, ул мине кочаклап алды да: «Син ялгыш ишеткәнсеңдер, мин ул чакны: «Миннән ныграк баегач» дип әйткәнмендер», – диде дә, акчаны алмыйча китеп барды.
Тормыш башлаган чакта торыр урын булмау, хәерчелек мине дә, Алияне дә упкын чигенә терәгән, чарасызлыктан бер-беребездән гаеп эзләп, нишләргә белми бәргәләнгән көннәребез күп булгандыр. Әмма бу гаҗәеп зур сынау, тормышның һәм үзебез теләп алган язмышның мәрхәмәтсез сынавы иде, һәм без шушы сынауны бергәләп җиңеп чыга алдык. Белмим, әгәр безнең ул чакта ук һәммә нәрсәбез булса, бәлки, бер-беребезне аңлый алмыйча, ничек табышкан булсак, шулай ук җиңел генә аерылышкан да булыр идек. Бергә кичкән катлаулы еллар, бергә җиңгән авырлыклар, бергә ирешкән уңышлар, уртак сөенечләр безгә тормыш мәгънәсен тирәнрәк аңларга һәм үзебез төзегән уртак йортның кадерен белергә өйрәткәндер дә.
Бер-береңне чын-чынлап аңлау, бер-береңнең кадерен белү өчен Аллаһы Тәгалә кешегә шундый сынаулар бирә торгандыр инде... 1987 елны мин каты гына авырып киттем. Республика хастаханәсендә биш сәгать буе операция ясап, эшләрен тәмамлый алмагач, табиблар кат-кат киңәшмә җыйдылар, нишләргә белмичә баш ваттылар. Дүрт ай буе палата түшәменә карап яткан чакта, күңелгә нинди генә шомлы уйлар килмәгәндер! Вакыт узган саен, дуслар сирәгәя, иптәшләр кими барды, минем өчен тормышның, яшәүнең мәгънәсе дә югала башлагандай булды. Шул чакта иң кирәкле даруларны табучы, мине юатып, сабый баланы карагандай карап торучы Алия булмаса, белмим, мин бу көннәргә килеп җитә алыр идем микән?
Казанда табиблар кат-кат киңәшеп тә, чарасын таба алмыйча, миңа кул селтәгәч, Алия Мәскәү хастаханәләре белән элемтәгә керде, Сәламәтлек саклау министрлыгына, хәтта обкомга кадәр барып җитте. Һәм мине ике табиб, култыклап, Мәскәүнең хирургия институтына илтеп яткырдылар. Мин инде, үземнең кырык яшьлек гомеремә йомгак ясап, Казан белән бөтенләйгә хушлашып киткән идем. Дөньяда могҗиза булуына беренче мәртәбә шул хастаханәдә ышандым. Академик дәрәҗәле табиблар тагын бер тапкыр операция ясагач, өч айдан соң тернәкләнеп, яңадан тугандай булып Казанга әйләнеп кайттым. Җиде ай рәттән хастаханәдә яткан чакта, мин тормышка, кешеләргә бөтенләй башкача карарга, яхшыны яманнан, дусны дошманнан аерырга өйрәндем. Хәлем авыр чакта янәшәмдә һәрчак Алия булды, шушы җиде ай вакыт эчендә мин аны

өр-яңадан ачтым, егерме ел яшәп тә моңа кадәр күрми йөргән яхшы якларын, яхшы сыйфатларын тоеп, үземнең бөтенләй үк ялгыз түгеллегемә куандым, аңа ышанычым артты.

Алия һәрвакыт йорт җанлы булды. Тулай торакта яшәгәндә дә, идәнгә очсызлы паласлар җәеп, стеналарны төрле картиналар белән бизәп, бүлмәне курчак йортына әверелдергән иде. Гомер буе ул өйдәге тәртип өчен, өйгә ямь кертү өчен җан атып яшәде, ә мин күбрәк дөнья мәшәкатьләре артыннан чаптым. Мәскәүдә укыганда, гаилә асрау өчен макарон фабрикасында төннәрен әрҗә ташырга да туры килде, АЗЛК заводының тимерчелек цехында да төнлә өченче сменада бер елга якын эшләп алдым. Андагы тавыштан колаклар тонып, лекциядә профессорның тавышын юньләп ишетми башлагач кына, заводтан китәргә туры килде. Макарон фабрикасында, фәкыйрь студентны кызганыптыр инде, һәр көнне миңа бер төргәк макарон биреп җибәрәләр иде. Ул макаронны үзебез генә ашап бетерә алмыйбыз, башкаларга да өләшәбез. Алия, шул бер уч макароннан дистәләгән төрле ризык әзерләп, бөтен кешене шаккатыра иде...

Алиядән мин бик күп нәрсәгә өйрәндем. Эш ягыннан, тормыш итү ягыннан мин инде шактый тәҗрибәле кеше идем. Балта эшен дә беләм, кирәк икән, үз кулым белән йорт та салам, башка эшләргә дә маһирлыгым бар. Әмма боларның һәммәсен дә бер тәртип белән, вакытында ипле-җайлы итеп эшләргә мин баштарак бабай белән әткәйдән өйрәнгән булсам, соңрак инде Алиянең үҗәтлеге, һәммә эшне ахырына кадәр җиткермичә туктамавы миңа да йога башлады. Ул – гаҗәеп эшчән, әгәр алдына бер максат куйса, таш яуса да, аңа ирешмичә калмас. Институтта педиатр һөнәре алып чыкса да, көннәрдән бер көнне ул авыруларны энә белән дәвалауга бирелеп китте. Үзлегеннән тау-тау китаплар укып, әллә нинди семинарларга, конференцияләргә, курсларга йөреп, бу һөнәрнең бөтен серләрен өйрәнде, хәтта Кытайга барып, андагы табиблардан өйрәнеп кайтты һәм, мине гаҗәпкә калдырып, шушы өлкәдә медицина фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә иреште.

Менә шулай һәрнәрсәнең асылына төшенергә, башлаган һәр эшнең ахырына җитмичә туктамаска омтылу сыйфаты безнең гаиләнең озын гомерле булуына сәбәпче булгандыр инде. Утыз биш елга якын бергә яшәгән чорда үпкәләшкән, сүзгә килгән чаклар да күп булгандыр, әмма артка борылып караганда, миңа күбрәк якты хатирәләр, уртак шатлыклар, уртак уңышлар һәм сөенечләр генә күренә.

Минем гомер күбрәк юлда, командировкаларда, эштә үткәнгә күрә, кызыбыз Сөембикәне тәрбияләү, нигездә, Алия җилкәсенә төште. Алия белән икебез дә яшь чакта телне бигүк камил белмәү аркасында (Алия – татарчаны, мин – русчаны) шактый кыенлыклар күргәнлектән, Сөембикәне бу кимчелектән азат итәргә тырыштык. Педагогика университетының чит телләр факультетын тәмамлагач, ул Америкада укып кайтты. Хәзер Татарстан Милли китапханәсенең чит телләрдәге әдәбият бүлеге мөдире булып эшли, татар, рус һәм инглиз телләрендә иркен сөйләшә. Олы кызы Камилә дә әнисе укыган инглиз мәктәбенең татар сыйныфында белем ала. Ә дүрт яшьлек Җәмиләсе бик тә рәхәтләнеп татар балалар бакчасына йөри, өйгә кайткач, авыз эченнән «Туган тел»не көйли. «Үскәч, кем буласың?» – дигәч, «Татар кызы булам», – дип җавап бирә. Мин моңа сөенәм, чөнки буыннар чылбыры, эти-әни белән балалар арасындагы бәйләнеш өзелмәс өчен аларның бер-берсен аңлавы мәгъкуль. Ә аңлашу өчен иң беренче чиратта бер телдә сөйләшә алу кирәк...

Мин мәхәббәт турында төчеләнеп сөйләргә яратмыйм. Үземнең яраткан кешемә дә хисләремне сүзләр белән әйтергә тартынам. Яратам яисә нәфрәтләнәм икән, мин инде ул хисләрне шигырь теле белән җиткерергә тырышам. Әгәр дә минем күңел түрендә нинди хисләр, нинди яшерен уйлар ятканын беләсегез килсә, аларны сез минем шигырьләремнән, җырларымнан таба аласыз.

Кайвакытта, бигрәк тә интервью алганда, миннән: «Син бәхетлеме?» – дип сорыйлар. Ә минем бәхет турында уйларым аларга бераз сәеррәк тоела. Чөнки мин кешене берчакта – менә бүген, менә шушы мәлдә, шушы вакытта бәхетледер дип санамыйм. Минемчә, бәхет һәрчак үткәндә яисә киләчәктә генә була ала. Бәхет ул – үткәндәге кадерле мизгелләрне сагынуда, бәхет ул – киләчәктә син ирешәсе уңышларда, син ачасы ачышларда, шуларны уйлап, шулар хакында хыялланып, татлы хисләргә чума алуда. Ә бүгенге бәхет ул бәхет түгел, ә ләззәтле минутлар, вакытлы рәхәтләр генә. Шуңа күрә менә хәзер бергә үткән утыз биш ел гомерне күздән кичерәм

дә, аның кадерле, иң татлы мизгелләрен хәтердә яңартып, бәхет диңгезендә йөзә башлыйм. Ә инде киләчәк турында уйлаганда, мин үземне карурман уртасындагы йорт кырыенда, күл буенда ак кәгазь өстенә иелеп, нидер язып утырган хәлдә күз алдына китерәм. Шулчак, мине чәй эчәргә чакырып, ягымлы тавыш ишетелсә, минем язганнарның мәгънәсен һәм кирәклеген аңлап, чәй янында чөкердәшеп утыручым булса, бәхет өчен миңа башка нәрсә кирәк булмас кебек тоела. Әгәр инде шул арада шау-гөр килеп бакча капкасыннан кызым Сөембикә, оныкларым Камилә белән Җәмилә, туганнарым, дус-ишләрем килеп керсә, бәхетем тагын да түгәрәкләнеп китәр... Чөнки бу дөньяда башкаларга файдалы булып, үзеңнең кирәкле зат, кадерле зат булып яшәвеңне тоюдан да зуррак бәхетнең булуы мөмкин түгел.
Гаилә бәхете ул – бер-береңә һәрчак кирәк булып, бер-береңә таяныч булып, бер түбә астында мөмкин кадәр озак килешеп яши алудыр. Ә без утыз биш ел бер һаваны сулап, бер хыяллар белән хыялланып яшәгәнбез икән, димәк, монда нидер бардыр инде...
Ә ул хисне, ул халәтне нинди исем белән атау – һәркемнең үз эше.

*2002*

# ГОМЕРЕМНЕҢ АЯЗ КӨННӘРЕ...

Аяз ага белән ныклап танышып, якынаеп китүем һич көтмәгәндә-уйламаганда булды. Минем Мәскәүдә – Әдәбият институтында укып йөргән чагым. Казанның рухи кысанлыгыннан соң Мәскәүнең чагыштырмача хөр фикерле мохитенә килеп эләккәч, башта бераз аптырап та калган идем. Әмма бу халәткә тиз ияләштем, бер ел эчендә бераз Мәскәүчә уйларга, Мәскәүчә яшәргә дә өйрәнә башладым кебек. Кем әйтмешли, кесәләр буш булса да, күңелләр хуш, йөрәкләр куш чак... Ул заманда безнең кулдан килмәгән бер эш тә юк сыман иде. Мәскәүдә беренче очраган татар кызына гашыйк булып, берничә айдан аңа өйләнеп тә җибәрдем, озакламый кызыбыз Сөембикә дә дөньяга килде. Бала белән тулай торакта яшәргә ярамый дип куып чыгаргач, Мәскәү читендәге бер иске дачага барып сыендык. Гаилә асрарга кирәк булгач, төннәрен заводта тимерчелек цехында эшли башладым.

Менә шулай шау-гөр килеп, очын очка ялгап яшәп ятканда, Казаннан мәшһүр язучыбыз Аяз Гыйләҗев килүе хакындагы хәбәр ишетелде. Җитмәсә, әле ул безнең тулай торакның кунакханә бүлмәсенә урнашкан икән. Аяз ага – минем өчен гыйбрәтле язмышы белән дә, олы иҗаты белән дә буй җитмәслек илаһи шәхес. Казанда дөнья күрә алмыйча Мәскәүдә басылып чыккан «Өч аршын җир» повестеның шаулаган еллары. «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, институтта лекциядән чыгып барганда, ишегалдында Аяз аганы күреп алдым. Югары әдәби курсларда укучы шагыйрь Рәдиф Гаташ белән кызып-кызып әңгәмә коралар иде болар. Кул бирешеп исәнләшкәндә, Аяз ага үткен күзләре белән мине аяк очларымнан баш түбәмә кадәр сөзеп чыкты да: «Шушы буламыни инде урыс капкаларын каерып ачучы егет?» – дип көлемсерәп куйды. Минем әле генә «Казан утлары» журналында чыккан шигырьләремнән хәбәрдар икәнен аңлагач, кинәт канатланып киткәндәй булдым, Аяз абый белән ике арадагы бушлык күз ачып йомганчы юкка чыкты. Тулай торакка кадәр таксида кайтканда да, Рәдиф бүлмәсендә озаклап чәй эчкәндә дә, мин Аяз ага сүзләренең сихеренә бирелеп, телсез калгандай, берни дәшмичә тыңлап тордым. Ул моңа кадәр мин ишетеп кенә белгән, әсәрләре «идән астыннан» гына таратылган Солженицын, Гумилёв, Пастернак кебек тыелган язучылар, үзебезнең Исхакый кебек мөһаҗир затларыбыз хакында шулкадәр тәфсилләп һәм тәмләп сөйли ки, мин, ирексездән, әле генә дөньяга килгән сабый бала кыяфәтендә, авыз ачып тыңлыйм да тыңлыйм.

Мәҗлес ахырында ул Рәдиф белән миннән яңа шигырьләребезне дә укытты. Бераз мактап, салпы якка салам кыстырып та алды. «Языгыз, көнне, төнне белмичә языгыз, сезнең әле шашып яза торган чагыгыз! Сезнең яшьтә мин дә шигырь яза идем, парин. Өч чемодан шигырем әле дә дачада ята», – дип һаваланып куйды ул. Монысы безне котырту өчен генә булгандыр инде, дип уйладык. Ул сүзен дәвам итте: «Әмма әйтәсе сүзне шигырьгә генә сыйдырып булмый. Әнә Пушкинны, Лермонтовны, Пастернакны алыгыз. Бөекләрнең пакусы киң була. Проза да язып карагыз сез... Рәдиф бөегебез коеп куйган шагыйрь инде ул, шуңа күрә проза белән вакланып, җиргә төшеп тормас, ә менә сиңа ныклап торып киңәш итәр идем...» Шулчак мин, хыялга бирелеп: «Минем язган повестем бар инде», – дип әйтеп ташлаганымны сизми дә калдым. Ә чынында бу – шагыйранә ялган, әлеге повесть кәгазьгә төшмәгән, ә бары тик минем күңел түрендә генә бөреләнгән иде. Аяз аганың: «Мин әле Мәскәүдә бер атна торам, эшләрем беткәч, китәр алдыннан дачаңа кунакка килермен, повестеңны әзерләп куй, бергәләп укырбыз», – дигән сүзләрен ишеткәч, бөтен тәнем кызыша башлады.

Инде нишләргә? Бер атнадан Аяз ага минем повестьны укырга киләчәк, ә аның әле бер бите дә язылмаган. Минем гомеремдә бер тапкыр да мондый ахмак хәлдә калганым юк иде. «Бу – һич тә алдашу түгел, чынлыкта повесть инде күңелемдә оешып җиткән, аны дөньяга китерәсе, кәгазьгә төшерәсе генә калган», – дип, үз-үземне юата-юата, «Перловка» станциясендәге иске дачага кайттым да өстәл янына кадакланып утырдым. Ярый әле институтта каникул вакыты – укырга йөрисе юк. Мин көнне дә, төнне дә онытып яздым да яздым. Хатыным Алия куйган чәйне эчәргә генә бүленәм дә тагын кәгазь өстенә капланам. Тәүлегенә егерме-егерме бишәр бит яза торгач,

Аяз ага киләсе көннең таңында мин «Эт кояшы» дигән повестемны тәмамладым. Атна эчендә җиңеләеп калган гәүдәмнең авырлыгын да тоймыйча, Аяз аганы алып киләчәк электричка янына очып, канатланып барам... Гомумән, кешеләргә, бигрәк тә яшь-җилкенчәк язучыларга иҗат дәрте өстәү, канат кую – Аяз аганың иң асыл сыйфатларының берсе булгандыр. Дөрес, вакыты-вакыты белән ул бик кырыс, таләпчән, хәтта усал да була белә иде. Әмма нигәдер хәтеремдә боларның берсе дә алай тирән уелып калмаган, ә инде заманында күңелемә ул салган иҗат кузлары әле хәзер дә, вакыт-вакыт кызыша башлап, йокыларны качыра, кулга каләм алырга мәҗбүр итә.
Ул безнең шактый таушалган кечкенә дача кисәген мактау өчен дә матур сүзләр тапты, ике каен арасына тартылган таганга утырып, көлә-көлә атынып та алды. Шушы «хан сарае» өчен аена күпме түләгәнебезне дә сорарга онытмады, өстәлемдә Рабит Батулладан калган вак шрифтлы борынгы язу машинкасын күргәч, «нәшриятлар мондый стандартны кабул итми» дип кисәтеп тә куйды. Ул һәрнәрсәне күрә, һәрнәрсәгә игътибар итә, аның һәрнәрсә хакында үз фикере, һәр кешегә, һәр вакыйгага үз мөнәсәбәте бар иде. Шулчак мин эчтән генә: «Чын язучы, чын прозаик шундый булырга тиештер инде», – дип уйлап куйдым. Алиянең аннан-моннан юнәтеп пешергән пылавын мактый-мактый ашаганнан соң, ул: «Әйдә, күрсәт инде шедевреңны!» – дип, йорт хуҗасыннан калган шыгырдавык диванга җайлап утырды. «Мин аны машинкада басарга өлгермәдем бит, кулъязма хәлендә генә ул», – дип, ык-мык килә-килә аклана башлаган идем, моңа да исе китмәде. (Югыйсә аннан: «Ярый алайса, Казанга машинкада бастырып алып кайтырсың, шунда укырмын», – дип әйтүен көткән идем.) «Прозаны кулдан язып торма син, турыдан-туры машинкада басарга өйрән. Шулай җайлырак ул, язганың күзгә ачык күренеп тора. Әйдә алайса, син кычкырып укы, мин тыңлармын», – диде.
Моңа кадәр инде күп мәртәбәләр имтихан биргәнем булса да, монысы минем тормышымда иң авыр, иң җаваплы сынау булгандыр. Әгәр повестьны укып бетергәннән соң Аяз ага миңа «икеле» куйса, бәлки, киләчәктә бөтенләй иҗат эшенә кул селтәгән, һичьюгында, үз-үземә ышанычым бик нык кимегән булыр иде... Мин өч сәгать буена берөзлексез укыдым да укыдым. Аяз агага күтәрелеп карарга да куркып укыдым. Әгәр шулчак ул туктатып, берәр авыр сүз әйтсә, минем бөтен хыялларым, бөтен өметләрем, бөтен дөньям бер мизгелдә чәлпәрәмә килер кебек иде. Повестьның соңгы җөмләсен тәмамлагач, мин, ниһаять, Аяз агайга күтәрелеп карадым. Аның йөзеннән хәйләкәр елмаю дулкыннары йөгереп үткән кебек булды. Шулчак ул торып басты да: «Булган бу, парин, – диде. – Әмма күңелеңә авыр алма, повестеңны Казанда басулары икеле, Казан – бик тар күңелле, тынчу һавалы шәһәр ул. Маяковский әйтмешли, тәрәзәсен ачып җиллләтәсе бар аның. Тик син язуыңны туктатма, бүген басмасалар, иртәгә басарлар, иртәгә басмасалар – берсекөнгә. Дөнья гел болай гына бара алмый ул, дустым».
Саубуллашканда, Аяз ага миңа язу машинкасы алырга акча биреп калдырды. «Пушкин урамында бик шәп «Эрика» машинкасы сата торган кибет бар. Немец машинкасы! Аны Мәскәү кешеләренә чиратка яздырып кына саталар. Икене алырсың, берсе үзеңә булыр. Югыйсә бу машинкаңда шедевр язсаң да, нәшриятлар кабул итмәячәк», – диде.
Аяз аганың юраганы юш килде. Минем «Эт кояшы» повесте хакында Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә фикер алышу оештырдылар. Бәхәс бик кызу булып, арада яхшы гына фикерләр әйтелсә дә, нәтиҗәне нәшриятның ул еллардагы баш мөхәррире ясады. «Мин бу әсәрнең уңай якларына туктап тормыйм, анысы хакында сөйләделәр инде. Без бүген сүз алып барган повесть совет чынбарлыгын бозып, каралтып күрсәтә. Шундый әсәрнең талантлы каләм белән язылуы аның зыянлы булуын икеләтә арттыра гына. Мин авторга тормышның якты якларына күбрәк игътибар итәргә, әдәбияттагы буржуаз агымнарга иярмәскә тәкъдим итәр идем». Баш мөхәррирнең тешләрен шыкылдата-шыкылдата сөйләвен тыңлаганда, миңа нигәдер кулымда зынҗыр чыңнары ишетелгәндәй булды, күз алдыма ап-ачык булып Аяз аганың язмыш шәүләсе килеп басты... Егерме яшьлек студент тарафыннан язылган «Эт кояшы» повесте ил өстендәге куе болытлар бераз тарала төшкәч, егерме ике елдан соң (1990) гына тулысынча басылып чыкты.
Ә язу машинкасын Аяз агайга барыбер алып кайттым мин. Һәм бу язмамны нәкъ менә шул Аяз ага белән бергә алган «Эрика» машинкасында басып утырам. Әмма ул машинкаларны алу җайлы гына булмады. Аяз аганың машинка алырга җыенуын ишетеп, Казаннан миңа тагын өстәмә

заказлар килә башлады. Берсеннән дә баш тартып булмый, чөнки һәммәсе дә мин белгән, хөрмәт иткән мөхтәрәм шагыйрьләр. Тик Мәскәү кибетендә башкала пропискасы булган бер кешегә бер машинка гына саталар. Ә миңа бишне алырга кирәк. Каян табарга тагын дүрт москвичны? Җитмәсә, моның өчен сәгать дүрттән барып, Пушкин урамындагы кибет янында чиратка басарга, анда көне буе торып, үз нәүбәтеңне көтәргә кирәк. Ниһаять, үзебез белән бер курста укыган бурят, монгол, калмык, балкар егетләрен ияртеп, чиратка язылдык. Атна саен барып, ел буена чиратыбызның кайсы тирәдә булуын белешеп тордык. Көне җитеп, биш машинканы кулга төшергәч, шул ук егетләр мине «Татарстан» поездына озатып та куйдылар. Вагонда ничек итеп мине «машинка сатучы спекулянт» дип атауларын, проводницага акча төртеп, көч-хәл белән бу бәладән котылуымны тәфсилләп сөйләп тормыйм. Казан вокзалында мине каршы алучы булмады. Инде нишләргә? Таксига акча юк, ике кулга биш машинканы да күтәреп булмый. Ни чарадан бичара дигәндәй, ике кулга икешәр машинканы бергә бәйләп тоттым, бишенчесен тоткасыннан авызга каптым да трамвайга кадәр көчкә барып җиттем. Трамвайдан төшкәч, колхоз базарыннан Матбугат йортына да шул рәвештә кайтырга туры килде. Җитмәсә, тирә-юньдәге халык бармак төртеп күрсәтә, арттан көлеп кала. Шулай көч-хәл белән Язучылар йортына кайтып егылдым. Юк, мин, боларны һич кенә дә күргән михнәтләремне тасвирлап, үземне кызгандыру өчен язмыйм. Боларны искә алуымның сәбәпчесе – әлеге дә баягы мөхтәрәм Аяз ага. Беренчедән, ул мине – әле яңа гына борын төртә башлаган әдәбият чебешен – якты дөньяга чыгару өчен куәт бирде, мә, эшлә, дип, кулыма корал тоттырды. Аяз абый аркасында мин шәп машинкалы булдым, ул машинка менә инде кырык елга якын минем иң мөкатдәс уйларымны кәгазьгә күчерә, хәзер дә ул мине һәр көнне ымсындырып үзе янына чакырып тора.

Мөхтәрәм шагыйрьләребез Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Нури Арслан һәм Әхсән Баянга Аяз ага фатихасы белән алып кайткан машинкаларның да әдәбиятыбыз өчен бәрәкәтле әсәрләр бүләк итүенә минем һич кенә дә шигем юк.

Язу машинкасы хакында шулай иркенләп сөйләвем юкка гына түгел. Иҗат кешесе өчен компьютер никадәр генә уңайлы булса да, минем әле һич кенә дә машинкадан аерыласым килми. Моның сәбәпләрен үзем дә аңлап бетермим бугай. Әмма бер сәбәбен беләм: ул – остазым Аяз ага ядкяре. Аяз ага машинкада гаҗәеп җитез һәм оста баса: Святослав Рихтер фортепьянода уйный диярсең. Вакыт-вакыт аның машинка тыкылдавы миңа йөгерек фикере артыннан калышмаска тырышып тупырдап чабучы ат тояклары тавышын да хәтерләтә. Ә кайчакта ул дошман явына каршы ялгыз калган пулемётчыга охшап ярсый-ярсый тыкылдата да тыкылдата кебек. Аның туктарга, бирешергә исәбе дә юк. Чөнки артта – аның газиз халкы, газиз Ватаны...

Халкы өчен һәрчак утка керергә әзер кеше булса да, Аяз ага беркайчан да ил, ватан, милләт турында купшы сүзләр сөйләп йөрмәде. «Үзеңнең зурлыгыңны, халыкның бөеклеген бары тик эш белән, акыл белән, мәдәният-сәнгать әсәрләре белән генә күрсәтеп була», – дип кабатларга ярата иде ул. Һәм бу сүзләрне үзенең гаҗәеп мул иҗаты, бөтен тормыш юлы, кылган гамәлләре белән раслады.

*2005*

# ХАЛЫК ХӘТЕРЕН ЯҢАРТУЧЫ

1986 елда мине Республика Фәнни китапханәсенең директоры итеп билгеләп куйдылар. Куюын куйдылар, ә ничек башлап китәргә, ничек эшне җайга салырга икәнен өйрәтүче, киңәш бирүче булмады. Йөздән артык китапханәченең яртысыннан күбрәге – фатирсыз, китапханә бинасының череп тишелгән батареяларыннан су ага, сугыштан соң кертелгән электр системасы бөтенләй сафтан чыккан, өстәл-урындыклар ватылып беткән, зур уку залының түшәме ишелеп төшкән, бөтен подваллар, баскыч аслары, чардаклар китап белән тулы, яңа килгән әдәбиятны куярга урын юк...

Башыма килгән иң беренче уй – китапханә һәм китап дөньясындагы иң мәшһүр кеше, галим Әбрар ага Кәримуллин белән күрешеп киңәшү булды. Телефоннан шылтыраткач, теләр-теләмәс кенә, очрашырга ризалык бирде. Икенче көнне иртән китапханә ишеген ачып керүгә, ул: «Совет агитпунктының мөдире булуың белән котлыйм! Белеп тор: бу – Татарстанның, татар халкының үзәк китапханәсе түгел, ә обкомның үзәк агитпункты!» – дип сүз башлады.

Билгеле, мондый сүзләрдән соң мин каушап, аптырап калдым, хәтта аны нигә чакыруыма да үкенә башладым. Ә ул һаман ярсый-ярсый сөйләвендә булды... Имеш, бу китапханәдә чын китапларның кадере юк, имеш, монда заманында гарәп язуындагы бөтен китапларны пыран-заран китереп, таратып, черетеп бетергәннәр, имеш, монда татар китабы турында уйлаучы, кайгыртучы гына түгел, хәтта татарча сөйләшүче кеше дә бик сирәк... Мин, гаепле кеше сыман, башны иеп, сабыр гына тыңлап тордым, аңа нәрсә дип әйтергә дә белмәдем. Саубуллашканда ул: «Бу эшкә килүең әйбәт булган анысы, ир кеше кулы, каты кул кирәк монда. Югыйсә китапханә, тол хатын йортына охшап, бөтенләй таралып, шыксызланып бетте. Әмма бинасын тәртипкә салсаң да, эчтәлеген үзгәртә алмассың, обком ирек бирмәс!» – диде. Ә мин, аңа җавап итеп: «Бергәләп тотынсак, бәлки, үзгәртә алырбыз, – дидем. – Каршы килмәсәгез, мин сезне китапханәгә эшкә чакырыр идем...»

Шулай итеп, академик Әбрар Кәримуллин безнең китапханәдә фәнни консультант булып эшли башлады.

Әбрар ага Кәримуллинның фәнни эшчәнлеге, татар матбагачылыгына, татар басма китабына һәм халкыбыз тарихына багышланган хезмәтләре хакында без инде шактый яхшы беләбез. Аның исеме республикабызда гына түгел, бөтен төрки дөньясында, башка чит ил галимнәре арасында да билгеле. Ул берүзе бөтен татар китап дәрьясын эзлекле рәвештә өйрәнеп, фәнни нигездә тасвирлап бирде, гыйльми хезмәтләрен рус һәм башка телләрдә бастырып, татар халкының бай рухи мирасын дөньяга танытты. *«Безнең халыкны һәрвакыт надан итеп, кыргый итеп күрсәтеп килделәр, тарих китапларында безне һәрчак хурлап, мыскыллап яздылар. Минем бөтен максатым – боларның чеп-чи ялган икәнен исбатлау, халкым турында дөрес мәгълүмат җиткерү!»* – дип әйтә иде Әбрар ага. Һәм ул үзенең бөтен иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге, бөтен тормышы белән шушы максатына тугрылыклы булды.

Әбрар Кәримуллинның китап дөньясына һәм халкыбыз тарихына багышланган фәнни иҗатын шактый яхшы белсәк тә, күпләребез әле аның күңел дөньясыннан, үз тарихыннан бик аз хәбәрдардыр. Моның сәбәпләре дә бар... Хрущёв хакимлек иткән совет чорында ул фәнни хезмәтләрендә И. Сталин исемен телгә алганы, милләтче вә эмигрант язучыларыбызны үз хезмәтләренә керткәне өчен җәбер-золым күргән, хәтта эшеннән куылган кеше. Билгеле инде, заманында андый шәхесләр хакында язу түгел, хәтта кычкырып сөйләшү дә куркыныч нәрсә иде. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен дә ул рәсми төстә раслатып түгел, ә эштән соң кача-поса яза, мең төрле киртәләрне үтеп, шактый олыгайгач кына яклый.

Әмма күпме генә михнәтләр күрсә дә, ул үз язмышыннан зарланмады. Аның бөтен зары, бөтен бәргәләнүләре бары тик халык язмышы белән бәйле булды.

Әбрар ага бик тә кызу холыклы, тиз ярсып китә торган кеше иде. Бәхәстә ул артка чигенүне белми, ахырга кадәр үз сүзен бирми, бигрәк тә милли мәсьәләләрдә үз фикерен үткәрмичә

туктамый иде. Андый бәхәсләрдә артык кызып китеп, хәтта кан басымы күтәрелә, аннары авырып түшәккә дә егылган чаклары була.
Дөрес, вафатына берничә ел кала, ул еш кына авыруыннан зарлана торган иде. Еллар узган саен, сугышта алган яралары сиздерә барып, аның аяклары шешә башлады. Андый чакта Әбрар ага, ике аягын да мамык шәл белән урап, өйдән чыга алмыйча, язу өстәле янында утыра. Үзе һаман, күңелен күтәрергә тырышып: «Аяк язарга комачау итми, үзең әйтмешли, аяк белән язмыйм бит мин, кул белән, баш белән язам», – дип шаярта. Тора-бара аның бу борчуына тагын бер көтелмәгән бәла килеп өстәлде. Хатыны Кинтә ханым белән икесенең дә авырулары гел сәбәпсез дә ешаеп китеп, айлар буе терелә алмыйча хасталанып ята торгач, Әбрар ага, махсус белгечләр чакыртып, фатирын тикшертте. Әллә нинди приборлар, дозиметрлар белән тикшерә торгач, аның өендә нindидер шикле матдәләр барлыгын ачыкладылар. Идән такталарын сүтеп карасалар, анда терекөмеш тапканнар, имеш. Әмма күпме генә тырышса да, нинди генә җитәкчеләргә язып караса да, аңа башка фатир бирмәделәр, без – депутатлар язган мөрәҗәгатьләргә дә шулай ук игътибар итүче булмады. Дөрес, идән астын чистартып, фатирга ремонт ясагач, ул бераз тынычлангандай булды. Әмма шиге бөтенләй бетеп җитмәде, соңгы көненә кадәр авыруы көчәюенең сәбәбен беренче каттагы суык идәнле фатирыннан һәм «терекөмеш казасыннан» күрде.
Әбрар ага Кәримуллинның фәнни хезмәтләре, иҗаты гына түгел, һәр кылган гамәле дә халык язмышы белән бәйләнгән иде. Шулай беркөнне китапханәдә борынгы татар китапларының кайсы илләрдә, кайсы китапханәләрдә саклануы хакында сүз чыккач, арадан беребез үзенең шиген белдереп куйды. «Элек булгандыр, ә хәзер кем сакласын да кем укысын аларны? Кемгә кирәк ул татар китабы?», имеш. Әбрар ага, гадәттәгечә, ярсып китте. «Ышанмасагыз, әйдәгез, Лейпцигка, Истанбулга, Хельсинкига яисә Киевка барып карыйбыз. Безнең үзебездә дә сакланмаган йөзләгән, меңләгән татар китаплары бар анда!» Чит илләргә үк барып булмаса да, без Әбрар ага белән Киевка юл тоттык, һәм мин шунда гомеремдә беренче мәртәбә татар китабының татар өчен генә түгел, ә башка халыкларга да кирәкле һәм кадерле икәнен күрдем. Соңрак миңа Америка, Финляндия, Кытай, Төркия, Англия китапханәләрендәге татар басмалары белән танышу насыйп булды, һәм без, Әбрар ага Кәримуллин җитәкчелегендә махсус төркем оештырып, борынгы татар китапларының җыелма каталогын төзергә тотындык.
Әбрар ага, инде әйткәнемчә, китап тарихын халык тарихы белән бергә үреп алып барган, янәшә куеп өйрәнгән сирәк галимнәребезнең берсе. Заманында татар тарихын бүгенге Татарстан җирләре һәм Болгар дәүләте белән генә чикләргә теләгән галимнәребезгә җавап итеп, ул, төрки-татар кавемнәренең җеп очларын эзли-эзли, Көньяк Америкага кадәр барып җитте. Аның ацтек һәм майя кабиләләре белән төрки халыкларның бәйләнешлары, уртак сүзләре хакындагы фәнни ачышлары бик күп илләрдә кызыксыну уятты.
1990 елда, ил чикләре бераз ачыла төшеп, демократия чалымнары күренә башлагач, Казанга Америкадан милләттәшебез профессор Рифат Таби килеп төште. Аның белән бергә Төркиядә яшәүче профессор Надир Дәүләт тә килгән иде. Боларны Казанга Әбрар ага чакырган икән. Чакыруын чакырган, ә кунакларны әйбәтләп кунак итәргә, аларга Казанны, Татарстанны да күрсәтергә кирәк бит әле. Ә кибетләрдә ул чакта ит тә, колбаса да талонга гына сатыла, лимон-әфлисунга Мәскәүгә барышлы, яхшы конфет һәм эчемлек-мазарны яхшы таныш аша гына табып була. Ә беркемгә баш бирмәс Әбрар агайның Америка һәм Төркия татарлары алдында мескен булып та, ярлы булып та күренәсе килми. Китапханәгә дус-ишләрне, хәлле таныш-белешләрне җыеп киңәштек тә ике атналык программа төзедек. Шушы ике атнада кунакларыбызның бер генә сәгать вакытлары да бушка узмагандыр: без аларны музейларга, мәчетләргә, китапханәләргә йөрттек, борынгы Болгарга, Алабугага, Чаллыга, Түбән Камага алып бардык, кат-кат мунчалар яктык, бәлешләр пешердек... Кыскасы, илебезнең ни хәлдә икәнен күрсәләр дә, алар безнең ярлылыгыбызны күрмичә, мескенлегебезне тоймыйча киттеләр бугай. Әбрар ага моның өчен бөтен көчен куйды, көнен-төнен белмичә чапты, малын да, җанын да кызганмады. Милләттәшләре, үз халкы өчен һәрчак шулай җанын фида кылырга әзер иде ул. Үзенең халкын аның һәрчак зур итеп күрәсе, зур итеп күрсәтәсе килә иде.

Фәннәр докторы, академик, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты исемнәре алган олпат галим булса да, Әбрар аганың күңелендә малайлык шуклыклары, егетлек чалымнары гомере буе сакланды. Сәламәтлеккә туймаса да, һәрчак аяклары авыртып торса да, ул теләсә кайсы вакытта җир читенә чыгып китәргә әзер торды, һәр барган җирендә ул иң элек татарлар хакында документлар, китаплар, фәнни хезмәтләр эзли, милләттәшләребезне табарга тырыша иде. 1991 елда Әбрар ага белән Канадага баруыбыз, хәтер тасмасына язылгандай, әле дә күз алдында тора. Безне анда Халыкара биографик үзәкнең генераль конференциясенә чакырганнар иде. Билгеле, бу безнең өчен генә түгел, хәтта республика өчен зур мәртәбә, әмма командировка чыгымнарын капларга риза булучы гына юк. Эзли торгач, мәрхәмәтле кешеләр табып, акча күчерттердек, билетлар алдык. Мәскәүдән самолёт белән Монреальгә килеп төштек. Икебезнең кулыбызда – китап белән шыгрым тулы ике чемодан. «Читтәге татарларга татар китабыннан да зуррак күчтәнәч булмас», – диде Әбрар ага. Инде килеп җиттек дисәк, безгә әле Торонтога кадәр тагын 600 чакрым автобуста барасы икән. Ә кесәдә бер тиен (бер цент!) дә акчабыз юк, чөнки Казанда барысы да түләнгән, акча күчерелгән дип әйткәннәр иде бит. Хет утыр да ела... Шулай аптырап торганда, каршыбызга кара мыеклы, мөлаем йөзле бер ир-егет килеп басты да чып-чын татар телендә: «Әбрар Кәримуллин белән Разил Вәлиев сез буласызмы?» – дип сүз катты. Без шаккатудан телсез калып тик торабыз... Юлга чыгар алдыннан берничә атна элек мин Америкадагы танышларыма Канадага барырга җыенуыбызны, хәтта Монреальгә кайсы рейс белән киләчәгебезне дә әйтеп хат язган идем. Ул танышларым бу хакта Монреальдәге татарларга хәбәр иткәннәр. Мондагы милли-мәдәни оешманың җитәкчесе Талип Күдәки шулай итеп аэропортта безне килеп тапкан. «Татар һәрчак татар кешесен таба ул. Кытайда, Төркиядә яшәгән чакта да бер-беребезне шулай табыша идек без», – дип, сүзен башлады Талип әфәнде. Әбрар ага хаклы булган, без алып килгән китапларны күргәч, аның сөенече эченә сыймады. Аннары ул безне, билетлар алып, Торонтога озатып җибәрде. Анда килеп җиткәч тә, хәерчегә җил каршы дигәндәй, тагын бер бәла көтеп тора икән. Безнең өчен күчерелгән акча кунакханәдә тору өчен генә булып, ашау якларын үзебез кайгыртырга тиеш булып чыктык. Инде нишләргә? Шулчак Әбрар ага чемоданыннан бер пакет сохари чыгарып өстәлгә куйды. Юлда кирәге чыгуы бар дип, Мәскәүдә алган булган икән. Минем чемоданнан чәй кайнаткыч белән бер кап чәй һәм шикәр дә килеп чыккач, башлар күккә тигәндәй булды. Көне буе халыкара конференциядә халкыбызның һәм илебезнең бөеклеге хакында сөйләп арыгач, ресторанга ашарга киткән башка делегатларга күренмәскә тырышып, кача-поса бүлмәбезгә кайтабыз да сохари кимерә башлыйбыз. Беркөнне шәһәр буйлап экскурсиягә чыгарга чакыргач та, түләүле икәнен белеп, бармыйча калдык. «Шәһәрне күрер өчен җәяү йөрергә кирәк», – дип, тәпи-тәпи атлап, урамнар буйлап киттек. Әбрар агайның атаклы Онтарио музеен күрәсе килә иде, шуны эзләп, ун чакрым чамасы юл үттек. Барыбер эзләп таптык үзен, Әбрар агай үзенең сугыш ветераны булуын әйтеп, Канаданың да безнекеләр белән бергә союзниклар ягында сугышуын аңлатып, мең хәйлә белән музейга бушлай кердек. Тагын ун чакрым юл узып, кунакханәгә кайтып егылганда, Әбрар аганың аяклары шешеп чыккан иде инде.

Конференция тәмамлангач, делегатлар Ниагара шарлавыгына барырга җыенды. Анда 160 чакрым автобуста бару өчен тагын түләргә кирәк икән. Канадага килеп Ниагара шарлавыгын күрмичә кайту мәчеткә кереп мулланы күрмәгәндәй була дип кайгырып утырганда, машинасында 600 чакрым юл үтеп, безнең янга Талип Күдәки килеп төште. Ул безгә, шофёр да, экскурсовод та булып, көне буе Ниагара шарлавыгын күрсәтеп йөрде.

Ике кило сохарины кимереп бетереп, инде кайтыр юлга чыгарга дип җыенганда, кунакханәдә безгә кап-кара чәчле, каратут йөзле бер чибәр егет сүз катты. Сүзләре төрекчәрәк булса да, аңладык. Баксаң, ул безнең татарча сөйләшкәнне ишетеп килгән, үзе дә Румыния татары икән. Монда ирле-хатынлы ике татар гаиләсе булып, кунакханә ресторанында эшлиләр икән. Алар безне мәҗлескә чакырдылар. Беренче генә күрешүебез булса да, сөйләшеп сүзләребез бетмәде, бергәләп төшкән фотоларыбыз әле дә минем альбомымда саклана. Юл буе Әбрар ага шул хакта сөйләшеп, уфтанып кайтты. «Без боларны беренче көнне үк тапкан булсак, балда-майда йөзә идек бит! Килү белән татар эзләргә кирәк, дип әйттем бит мин сиңа. Дөньяда татар булмаган җир юк

ул! Ә без, мокытлыгыбыз аркасында, атна буе сохари кимереп яттык. Әнә яһүд яһүдне әллә каян, исеннән үк сизә. Татар кайчан татарны сизәргә, татарны аңларга, татарны эзләргә, татарны табарга өйрәнер икән?!»

Торонтодагы конференциягә дөньяның йөзгә якын иленнән ике йөзләп делегат килгән иде. Араларында бик тә мәшһүр шәхесләр, атаклы галимнәр бар. Инглиз телен белмәвебез аркасында, бик теләсәк тә, алар белән якыннан таныша, иркенләп аралаша алмадык. Ярый әле безгә атаклы төрек шагыйре һәм галиме Осман Төркәй, атна буе ярдәм итеп, тәрҗемәче хезмәтен үтәп йөрде. Лондонда яшәүче бу төрек шагыйре белән шунда дуслашып киттек, аннары озак еллар буе хат-хәбәр алышып, төрле конференцияләрдә очрашып, аралашып яшәдек. Торонтода Әбрар ага, үзенең тел белмәвеннән гарьләнеп, Осман Төркәй белән икебезгә: «Киләсе конференциягә кадәр инглиз телен өйрәнәчәкмен!» – дип вәгъдә бирде. Казанга кайткач, ул, көн саен курсларга йөреп, инглиз телен өйрәнергә тотынды. Һәм бер елдан соң Англиянең атаклы Кембридж каласына барып, конференция делегатлары каршында инглиз телендә чыгыш ясады. Бу вакытта Әбрар агайга 70 яшь тулып килә иде инде.

Бу язмада мин Әбрар ага Кәримуллинның фәнни әсәрләре, китаплары, җәмәгать эшчәнлеге хакында махсус тәфсилләп сөйләмичә, аның белән бергә сәяхәт итүләребезне, көндәлек тормышта очраган вакыйгаларны искә төшерергә булдым. Чөнки галимнең әсәрләрен теләсә кем китапханәдән табып укый ала, ә бу истәлекле мизгелләрдә исә без аның үзе белән очрашкандай булабыз, аның холык-гадәтләрен, яшәү рәвешен искә төшерәбез, ә алары беркайда да теркәлеп калмаган.

Америкадагы Халыкара биографик үзәк вафатына берничә ел кала Әбрар ага Кәримуллинга «Егерменче гасыр кешесе» дигән мактаулы исем бирде. Әйе, ул үзенең гаҗәеп зур хезмәте һәм иҗаты, бөтен тормышы белән бу исемгә һичшиксез лаек шәхес. Әмма аның хезмәтләре, аның шәхесе бер гасырлык кына түгел, Әбрар ага әле татар халкы өчен егерме беренче, егерме икенче һәм тагын күп гасырлар кешесе булачак. Чөнки халыкның акыл сандыгын – китап дөньясын тәртипкә салган, милләтебезнең хәтерен яңарткан кеше үзе дә халык хәтерендә мәңге сакланырга тиеш.

*2005*

# МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ ҺӘМ ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

Миркасыйм ага турында көннәр буе, атналар, айлар буе да сөйләргә мөмкин. Аның турында сөйләр сүзләрем, фикерләрем күп. Мин аның белән инде дистә еллар буе аралашып яшим, фәнни хезмәтләрен өйрәнеп, укып барам, әдәби әсәрләрен, оештыру эшләрен дә күреп торам. Билгеле, иң беренче чиратта Миркасыйм ага барыбыз өчен дә галим һәм бик зур галим. Менә уйлап утырдым-утырдым да, мондыйрак фикергә килдем әле. Нинди кешене галим дип атап була икән? Мин, мәсәлән, үземнән күбрәк белмәгән кешене галим дип атый алмыйм. Әгәр дә ул кеше миннән акыллырак түгел, миннән күбрәк белми икән, әгәр дә мин ул кешедән күңел хәзинәмә нәрсәдер ала алмыйм, аннан нәрсәгәдер өйрәнә алмыйм икән, минем өчен ул кеше галим түгел. Минем өчен ул гап-гади бер кеше генә. Ә Миркасыйм аганы мин зур галимгә саныйм. Ул тарихи чыганаклар даирәсендә генә түгел, әдәбият-сәнгать өлкәсендә дә җентекле фәнни эзләнүләр алып барган, яңа ачышлар ясаган күпкырлы галим. Кайсы гына язучының, кайсы гына әдибебезнең әсәренә анализ ясарга тотынса да, ул аңа бик тә төпле итеп, асылына төшеп бәя бирә белә.

Әмма мин инде бу урында язмамның исеменнән артык читкә китәргә тиеш түгелмендер. Ә язмам, нигездә, Милли китапханә һәм Миркасыйм агай турында булыр.

Татарстан Милли китапханәсенең тарихы бик бай, ул 1865 елда ук ачылган, димәк, киләсе елның гыйнвар аенда аңа 140 ел тула. Ул башта Казан шәһәренең җәмәгать китапханәсе булып эшләп килгән, аннан соң төрле исемнәр белән аталган, узган гасырның 60 нчы елларында Татарстан АССРның В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе статусы алган. Академик Әбрар ага Кәримуллин безнең китапханәне, бераз шаяртып, «изба-читальня» дип тә, «идеологик оешма» дип тә, «клуб» дип тә атый иде. Чыннан да, ул елларда безнең китапханәнең исеме – җисеменә, җисеме исеменә туры килми иде. «Фәнни китапханә» дип аталса да, анда фән дигән нәрсә бик сирәк кунак була торган иде. Һәм менә без, 1990 еллар башында, бераз ирек бирелә башлагач, бу китапханәнең статусын күтәрү, үзгәртү эшенә алындык һәм, ниһаять, 1991 елның ноябрь аенда аңа Татарстан Милли китапханәсе исеме бирдек. Элмә тактага яңа исем язып кую әле ул бик зур эш түгел. Дөрес, исем үзгәрткәндә дә шактый кыенлыклар күрергә туры килде, чөнки аның өчен хөкүмәтнең карарын чыгарырга, программа төзергә, яңа устав кабул итәргә кирәк. Үзгәртүен үзгәрттек, ә ничек итеп аңа яңа эчтәлек – Милли китапханә эчтәлеге бирергә? Ничек итеп аны фәнни оешма итәргә? Ә республика Милли китапханәсе, һичшиксез, фәнни оешма булырга тиеш! 1980 еллар азагында, 1990 еллар башында безнең республика китапханәсендә фән белән шөгыльләнүче белгечләр дә, хәтта кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге дә юк иде. Заманында республика китапханәсенең иң кыйммәтле фондлары университет китапханәсенә тапшырылган һәм хәзерге көндә дә анда республика китапханәсе мөһере сугылган шактый китаплар саклана. Ул – безнең уртак байлыгыбыз, аңа бер сүзебез дә юк. Әгәр дә университет китапханәсенә күчерелмәгән булсалар, бәлки, ул китаплар Сталин чорында юк та ителгән булыр иде. Иң беренче эшебез итеп без Милли китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеген төзергә, бу бүлекнең китап фондын тупларга тотындык. Мин ул елларда китапханә директоры идем. Андый бүлек оештыруның китапханә хезмәткәрләре генә булдыра ала торган эш түгеллеген аңлап, без үзебезнең зур галимнәребездән Әбрар ага Кәримуллин белән Миркасыйм ага Госмановны киңәшкә, ярдәмгә чакырырга булдык.

Әбрар Кәримуллин борынгы басма китаплар өлешен үз өстенә алды, ә инде кулъязма китаплар буенча төп киңәшчебез, фәнни консультантыбыз булып Миркасыйм ага Госманов эшли башлады. Ул елларда гадәти республика китапханәсенә Милли китапханә эчтәлеге иңдерү өчен кылган гамәлләрнең барысын да саный башласам, бик озакка китәр. Хәзерге көндә безнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегебез шактый ук бай, ул көннән-көн байый һәм тулылана бара, һәм бу эштә без һәрдаим Миркасыйм аганың киңәшенә таянып хәрәкәт итәбез.

Милли китапханә нинди булырга тиеш? «Милли китапханә» башка илләрдә, нигездә, дәүләт китапханәсе дигәнне аңлата. Ул шушы җөмһүрияттә, шушы республикада яшәгән халыкның, андагы гыйльми оешмаларның, дәүләт органнарының рухи һәм мәгълүмати ихтыяҗларын кайгырта торган һәм аларга кирәкле мәгълүматны туплый, җиткерә торган фәнни-мәдәни үзәк булырга тиеш. Без моны үзебезгә өлге итеп алдык. Әмма безнең республикада Милли китапханәнең милли төсмере дә булырга тиеш дип санадык. Ул дәүләтнең төп китапханәсе булу белән бергә, шушы дәүләткә, республикага исем биргән милләтнең дә төп китапханәсе ролен үтәсен. Ә безнең халкыбыз Татарстанда гына түгел, бөтен дөньяда сибелеп яши... Димәк, безнең Милли китапханәбез республикадагы һәммә халыкның һәм бөтен татар халкының баш китапханәсе булырга тиеш. Миркасыйм ага бу эштә дә безнең төп киңәшчеләребезнең, ярдәмчеләребезнең берсе булды. Чөнки ул китапханә эше белән яхшы таныш, шуның өстенә төрле төбәкләрдә һәм чит илләрдә яшәп ятучы ватандашларыбызның тормыш хәлен, рухи ихтыяҗларын да яхшы белә. Иң элек без Россия төбәкләрендә татар халкына хезмәт күрсәтә торган китапханәчеләрне үзебезгә чакырып, алар өчен ел саен курслар оештыра башладык. Бу курсларда татар халкы тарихы, аның әдәбияты һәм сәнгате, йолалары, китапханә эше хакында лекцияләр укыдык, әдәби кичәләр, экскурсияләр оештырдык, һәр очрашу вакытында безнең төп консультантларыбыз, киңәшчеләребез Ә. Кәримуллин белән М. Госманов булдылар.

Аннары без Россиядәге, элеккеге СССРдагы татар халкына хезмәт күрсәтә торган китапханәләрне татар әдәбияты һәм татар халкы тормышына кагылышлы әдәбият белән тәэмин итү бурычын да үз өстебезгә алдык, моның өчен китапханәдә махсус бер бүлек тә ачтык. Әйткәнемчә, әлеге эшләрнең һәммәсенең үзәгендә Миркасыйм ага Госманов торды.

Аннан соң Милли китапханәнең Гыйльми шурасын оештыру эшенә тотындык. Миркасыйм ага монда да төп киңәшчеләребезнең берсе булды һәм безнең эшебезгә һәрчак юнәлеш биреп килде.

Менә инде дистә елдан артык Милли китапханә хезмәткәрләре археографик экспедицияләргә чыгалар, авылдан авылга йөреп, борынгы китаплар җыялар. Ул китапларны табып алып кайткач, фәнни яктан өйрәнергә, тасвирларга, сакларга, укучыга җиткерергә кирәк. Бу эшләрдә тәҗрибәле археограф Миркасыйм аганың ярдәме гаҗәеп зур булды. Милли китапханәдә хәзер өч миллион ярым китап бар. Аларның кайсылары сирәк китаплар һәм кульъязмалар исемлегенә керә ала? Без шушы 3,5 млн китапның һәммәсен өйрәнеп чыгып, аларның бер өлешенә «сирәк китап», «сирәк кульъязма» статусы бирергә, аерым исемлек төзергә тиешбез. Шушы исемлекне төзүдә дә Миркасыйм аганың ярдәме чиксез зур, бу эшне без аннан башка гамәлгә ашыра алмас идек.

Миркасыйм ага турында, әйткәнемчә, бик күп сөйләп булыр иде. Аның кешелек сыйфатлары турында аерым бер әңгәмә корырга мөмкин. Безнең галимнәребез шактый күп. Әмма Миркасыйм ага кебек милләт кайгысы белән кайгыручы, милләт борчуы белән борчылучы төпле шәкертләр үстергән, галимнәр әзерләгән остазларыбыз бик сирәк.

Миркасыйм агага берничә сүз белән генә характеристика бирергә кушсалар, мин: «Аның кулы каты, күңеле йомшак», – дияр идем. Бер карасаң, ул шактый усал кеше шикелле, әмма ныклап аралашкач, аның гаҗәеп нечкә, йомшак күңелле икәнен аңлый башлыйсың. Нечкә һәм нәзберек күңелен яралардан аралау өчен, ул аны каты сүзләрдән торган тышча белән каплаган, шулай итеп үз-үзен саклау чарасын тапкан кебек...

Һәммә галим кешенең дә язмышы китапханә белән бәйләнгән була. Чөнки китапханә фондларында казынмыйча, чыганакларны өйрәнмичә торып, гыйлем серләренә төшенү, яңа фәнни ачышлар ясау мөмкин эш түгел. Кыскасы, галим кеше китапханәдән башка яши алмый. Ә Миркасыйм ага Госманов белән Татарстан Милли китапханәсе арасындагы багланышлар тагын да ныграк, тагын да тирәнрәк. Галим Миркасыйм ага китапханәдән башка яши алмаган кебек, Татарстан Милли китапханәсе дә аннан башка, аның киңәшләре, тәкъдимнәре һәм ярдәменнән башка үзенең яшәешен күз алдына китерә алмый.

*2004*

# КУНАК БУЛЫП КИЛДЕ, ХУҖА БУЛЫП КИТТЕ...

Татарстан Милли китапханәсендә эшләгән елларымда, миңа Мөхәммәт ага Мәһдиев белән шактый еш аралашырга туры килде.

Ни гаҗәп, язучы, шагыйрь халкы китапханәгә сирәк йөри. Язучыларыбыз саны йөзәрләп исәпләнсә дә, аларның берничәсе генә китапханәгә кереп китап ала, ә инде уку залларында, сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә көннәр буе утыручылары икәү-өчәү генә була иде. Менә шулай, үз китапларын гына түгел, ә башкаларныкын да йотылып укыган, борынгы чыганакларны, кульъязмаларны җентекләп өйрәнгән сирәк әдипләрнең берсе Мөхәммәт ага Мәһдиев иде.

Әлеге очрашуларның берсендә ул миңа үзенең бер теләген әйтте... «Сезнең яклардан соңгы елларда әдәбиятка, сәнгатькә шактый кызыклы иҗат әһелләре килде. Сезнең яктан чыккан Рафаэль Сәхәбиев, Зөлфәт Хәким, Алмаз Хәмзиннәрне бик тә хөрмәт итәм. Заманында ул төбәктә Таҗетдин Ялчыгол яшәгән, балалар укыткан, иҗат иткән. Минем шул якларны барып күрәсем килә, җаен табып, бер туган авылыңа чакыр әле, – диде ул. Аннары, бераз уйланып торгач: – Минем китапларга, китапханәгә гашыйк кеше икәнемне күреп торасың, озакламый университеттан китәм, пенсиягә чыгам. Бераз ял иткәч, синең яныңа килермен әле. Каләм хакына гына яшәп булмас, аннары мин өйдә генә ята ала торган кеше түгел, кулайрак берәр эш тапсаң, китапханәгә урнашыр идем. Бәлки, файдам да тияр...» – дип өстәп куйды.

Мөхәммәт аганың беренче теләген үтәү насыйп булса да, икенчесен тормышка ашырырга өлгерми калдык. Әҗәл бездән җитезрәк, өлгеррәк булып чыкты...

Мөхәммәт абый белән безнең авылга кайту бик кызыклы да, мәгънәле дә булды. 1991 елның зәмһәрир суык февраль аенда без авылдашым Алмаз Хәмзин белән иҗат кичәсе, очрашу оештырырга дип авылга кайтканда, ул Түбән Кама читендәге карурман эчендә профилакторийда берьюлы дәваланып та, иҗат итеп тә ята иде. Афишада Мөхәммәт Мәһдиев исеме булмаса да, без, тәвәккәлләп, аны үзебезнең кичәгә чакыру өчен, энекәшем Рәмзил белән Кама буендагы профилакторийга төшеп киттек. Ул киреләнеп, ялындырып тормады: «Инде ике атнадан артык ак кәгазь каршында бөкрәеп утырам, бераз бил язып кайтырмын», – дип, бик җиңел ризалашты.

Бу кичә авылыбыздан чыккан ике иҗат кешесенең, ягъни мәсәлән, Алмаз Хәмзин белән Разил Вәлиевнең, халык каршында хисап тотуы кебегрәк булырга тиеш иде. Совхоз директоры Харис Гайнетдиновның безне күккә чөеп язган докладлы да әзер, мактау сүзләре әйтергә тиешле чыгыш ясаучылар да билгеләнгән, сәхнә артында район газетасы белән каплап куелган бүләкләр дә тора. Алмазның энесе авыл Советы рәисе Айдар белән минем энекәш Рәмзил кичәдә катнашучылар өчен совхоз ашханәсендә 10 – 15 кешелек өстәл дә әзерләп куйганнар. Ә халкыбызның күренекле язучысы Мөхәммәт Мәһдиев, нур өстенә нур булып, шушы кичәгә, шушы мәҗлескә ямь өстәргә, безнең дәрәҗәне тагын да күтәрергә тиеш иде. Кыскасы, Алмаз белән без бүген бу кичәнең генә түгел, бөтен авылның хуҗасы, каһарманнары кебек идек...

Кичә башланыр алдыннан, Мөхәммәт ага залга кереп, совхоз директоры Харис белән мәктәп директоры күрше керәшен авылы егете Аркадий Михайлович арасына утырды. Утыруга ук сүз башлап, боларга сорау артыннан сораулар яудырырга тотынды. Ул сорауларның иң кирәклесен, иң кәттәсен шундый да белеп китереп куя, авыл җитәкчеләре аның бар нәрсәдән хәбәрдар булуына шаккатып, авыз ачып карап торалар да, үзләре дә сизмәстән, әңгәмәгә кушылып китәләр. Берничә минуттан инде совхоз директоры Харис Ясәвиевич Мөхәммәт агайның иң якын дустына әверелгән, ул инде, сүз башлагандагы кебек, «әйе, әйе» дип, баш кагып кына утырмый, маңгаендагы тирләрен сөртә-сөртә бәхәсләшә үк башлаган иде.

Кичәне Алмаз җыр белән ачып җибәрде. Җыр тәмамлануга, сценарий буенча сәхнәгә совхоз директоры менәргә тиеш. Алып баручы аның исемен әйткәндә, ул әле Мөхәммәт агайга һаман нәрсәдер сөйли, исбатларга тырыша иде. Исемен ишеткәч, капыл гына сискәнеп куйды да, тунын урындыкка салып куеп, сәхнәгә күтәрелде. Микрофон янына килеп баскач, бераз тын торды да залга карап сүз башлады.

– Менә без язучы Мөхәммәт ага Мәһдиев белән авыл хәлләрен сөйләшеп утырдык әле, – дип алып китте ул. – Мөхәммәт абый дөрес әйтә: авыл ул – дуңгыз-сарык асрау, иген үстерү урыны гына түгел. Авыл ул – халкыбызның, милләтебезнең төп терәге. Татар авылы булмаса, татар милләтенең бөтен рухи байлыгы юкка чыга, чишмәсе корый. Әле кичә генә Мөхәммәт абыйның «Торналар төшкән җирдә» китабын укып яттым. Менә язып күрсәтә ул авыл турында! «Война и мир»ларың бер читтә торсын...

Шулай дип башлап китте дә ул кичә укыган китапның эчтәлеген сөйләргә тотынды. Шактый вакыт сөйләгәннән соң, сүзләренең хаклыгын расларга теләгәндәй, сәхнәгә Мөхәммәт аганы чакырып менгерде.

Ә инде Мөхәммәт ага Мәһдиев сөйли башлагач, моңа кадәр чыш-пыш килеп утырган кешеләр дә телсез калды. Ул әйтерсең үзенең туган авылына кайткан да, шушы залга иң якын дусларын, туганнарын чакырып, аларга үзенең еллар буена җыелып килгән серләрен сөйли, алар белән киңәшә, шатлык-кайгыларын уртаклаша иде.

– Кичә мин профилакторийда берничә агайдан сезнең авыл турында махсус сорашып утырдым, – дип дәвам итте ул сүзен. – Күпме иген чәчкәннәр, уңыш күпме чыккан? Мал-туар асрыйлармы, газ кергәнме, асфальт юллар салынганмы, мәктәбе, клубы, китапханәсе, мәчете, кибете бармы? Халкы нинди рәк? Шунысы сөенечле: сезнең авыл турында бары тик яхшы сүзләр генә сөйләделәр миңа. Уңган халык, горур халык, киң күңелле, җор телле халык яши Ташлыкта, диделәр. Шуңа күрә сезнең авылдан шагыйрьләр, җырчылар, композиторлар чыгуы бик табигый хәл...

Мөхәммәт ага бу кичәгә ни өчен килгәнен онытмаган, ул сүз уңаеннан Алмаз белән минем турыда матур фикерләр, мактау сүзләре әйтеп үтте. Әмма залдагы тамашачы безне түгел, Мөхәммәт агайны гына күрә, авыл халкы өчен без инде шагыйрь дә, җырчы да, артист та түгел, ә заманында ат көтеп, печән чабып, кәшәкә сугып йөргән гап-гади малайларга әверелеп калган идек. Залда, сәхнәдә бары тик бер генә язучы, бер генә шәхес – Мөхәммәт Мәһдиев кенә бар иде.

Авыл халкы Мөхәммәт агайга сорау артыннан сорау яудырды, җылы юморга төреп бирелгән тапкыр җаваплар ишеткәч, рәхәтләнеп, дөньясын онытып көлде, гыйбрәтле хәлләр хакында сөйләгәндә, хәтта кырыс йөзле агайларның да күзләренә яшь килде. Шулай сәгатьтән артык сәхнә тотып торгач, ул безгә күз ташлады да уңайсызланып кына, гафу үтенә-үтенә генә залга төшеп утырды. Сәхнәгә тагын Алмазны чакырдылар. Ул берничә җыр җырлап, мәзәк сөйләгәч, мин дә микрофон янына күтәрелдем. Үзем сөйлим, ә үзем Мөхәммәт агай турында уйлыйм. Күреп торам, бер мин генә түгел, бөтен зал, аның сүз тылсымына, аның җан җылысына оеп, гипнозда утыра. Шулчак, үзем дә сизмәстән, кылган гамәлләрем, иҗат иткән әсәрләрем турында сүз алып барасы, шигырьләр укыйсы урында, мин Мөхәммәт ага әсәрләре, аның китаплары, аның гыйльми хезмәтләре, мөгаллимлек осталыгы турында сөйли башладым. Шунда гына мин залдагы кешеләрнең күңелләренә ачкыч таптым, шунда гына кешеләр минем сүзләремә игътибар итә, вакыт-вакыт туктатып кул чаба башладылар. Миннән соң чыккан Алмаз да залның халәтен аңлаган иде. «Менә бу җыр – Мөхәммәт аганың яраткан җыры. Мин аны хәзер халкыбызның күренекле язучысы, авылыбыз кунагы Мөхәммәт ага Мәһдиевкә багышлап җырлыйм», – дип игълан итте.

Ул көнне мин Язучы белән Укучының күңелләре ничек итеп күренмәс җепләр белән тоташканын, йөрәкләре бергә кушылып типкәнен күрдем, халык белән аралашу сәнгатенең шаһиты булдым. Һәм Мөхәммәт ага Мәһдиевнең чын мәгънәсендә халык әдибе, халык язучысы булуына инандым.

Сүземне Милли китапханәдә Мөхәммәт ага белән булган әңгәмәбездән башлаган идем. Мин аның беренче теләген үтәдем, үзебезнең авылны күрсәттем. Ул бер кичкә кунакка кайтып та безнең авыл халкын мәңгелеккә үзенә гашыйк итте. Инде ничә еллар үтсә дә, әле һаман безнең авылда аны искә алып, сагынып сөйлиләр, аның китапларын өйдән өйгә йөртеп, чират торып укыйлар.

Кичәдән соң мин аны урмандагы йортына – профилакторийга кадәр озата бардым. Саубуллашканда: «Мөхәммәт ага, авылыбызга кунак булып килгән идең, хуҗа булып киттең», – дидем. Җавап итеп ул: «Авылыгыз да, авылыгызның кешеләре дә бик ошады. Чакырсаң, тагын бер килермен, Сабан туегызны да күреп китәрмен әле», – дигән иде.

Мөхәммәт ага безнең авылның Сабан туен күрергә дә, Милли китапханәгә килеп эшләргә дә өлгерми калды. Әйе, рәхимсез әҗәл бездән өлгеррәк булып чыкты. Әмма, иманым камил, гомере буе Галиҗәнап Китапка табынып яшәгән әдипнең икенче теләген дә үти алсак, ул тиз арада Милли китапханәнең рухи атасына, бу изге йортның хуҗасына әверелгән булыр иде.
Коръәндә язылганча, без – һәммәбез дә бу дөньяда кунак кына. Әмма җиргә кунак булып килеп тә хуҗа булып китә алганнар иң бәхетле затлардандыр. Мөхәммәт ага нәкъ менә шундый кеше иде...

*2004*

# ҮТКӘННӘРДӘН БАРЫ ШУЛ ҖЫР КАЛДЫ...

Аның иртәнге якта телефоннан шылтырата торган гадәте бар иде. Юк, кемнәрдер кебек таңнан торып, аһ-зарын сөйләү, үз борчуын синең күңелеңә күчерү яисә берәр йомышын җиткерү өчен шылтыратмый ул. Исәнләшә дә: «Якты көн белән котлыйм!» – дип, синең күңелеңә шатлык оеткысы сала. Яисә: «Тәрәзәңнән кара әле, урамда ап-ак кар яуган», – дия дә трубканы куя. Бер миңа гына түгел, тагын берничә кешегә көнаралаш шулай шылтырата иде ул. Әйтерсең шулай итеп гомеребезнең тагын бер көненә үзенең хәер-фатихасын бирә, үзенең исәнлеге хакында хәбәр сала, синең дә хәлеңне белешә. Шушы кыска гына сәламләшүдән, хәл-әхвәл белешүдән соң, беркавымга борчу-кайгыларың онытылып киткән кебек була, бу иксез-чиксез дөньяда үзеңнең ялгыз түгеллегеңне тоеп, эчтән генә куанып та куясың.
Менә инде ничә ел иртәнге якта минем телефоным эндәшми, якты көн белән котлап, Фасил абый шылтыратмый, хәл-әхвәлемне белешми...
Гомумән, Фасил Әхмәтнең сагынып сөйләрлек мондый сәер гадәтләре шактый күп иде. Гомере буе сәламәтлеккә туймаса да, хәтта рәхәтләнеп ике аягына басып йөри алмаса да, ул елап-сыкрап яшәмәде. Дөрес, аның да күңел төшенкелегенә бирелеп алган, йөрәге күкрәк читлегенә сыешмаган чаклары була иде. Әмма андый халәте гадәттә озакка бармый, берәр яңа әсәр язуга, ул, бөтен кайгы-хәсрәтен онытып, яңа туган сабый балага әйләнеп кала. Ә аның авызыннан чыккан тапкыр сүзләрне, аның белән бергә булган мәзәк хәлләрне без әле бүген дә сагынып искә төшерәбез...
Шулай бервакыт үзенең җырлар җыентыгы басылып чыккач, Фасил абый берничә дустын «Татар ашлары йорты»на алып китте. Ул елларда китап кадәр китап бастыру бигрәк тә композиторлар өчен зур вакыйга иде. Шуңа күрә мәҗлесе дә мулдан булды, ресторан ябылгач та, әле таралыша алмыйча, шактый вакыт бер-беребезне озатышып йөрдек.
Икенче көнне иртә таңнан мине телефон шылтыравы уятты. Гадәттәгечә, Фасил абый. «Хәлләр ничек, Фасил абый?» – диюгә, ул: «Булса соң», – дип, шаяртып әйтеп куйды. Аның бу сүзләрен «яхшы булса соң» дип тә, «начар булса соң» дип тә аңларга мөмкин, монысы инде синең эш... Билгеле, ул теләсә кем белән алай сөйләшми; бары тик якыннарына гына шулай сүз ката иде. Мин ни әйтергә белмичә аптырабрак торганда, ул сүзен болайрак дәвам итте: «Кесәдә яшереп йөрткән егерме бишлекне инде сәгать буе таба алмыйм. Әллә Йолдыз апаң чалбар үтүкләгәндә алып куйган инде...». «Фасил абый, син аңа иң соңыннан бер шампанский китерттең бит», – дигәч, аның рәхәтләнеп көлгәне ишетелде. «Ә мин монда, хатын алган дип уйлап, кара кайгыга баттым. Ярый, алайса, әйбәт булган, акча әрәмгә китмәгән икән», – диде дә ул саубуллашмый-нитми генә телефон трубкасын куйды.
Фасил абыйның фикер сөреше, сөйләшү тәртибе, хәтта кешеләрне сәламләве дә һәрчак үзенчә, оригиналь була торган иде. Әгәр дә аннан: «Хәл-әхвәлләр ничек, ниләр кырып ятасың?» – дип сорасаң, ул, башка кешеләрчә, «әйбәт» яисә «начар» дип әйтмәс, ә «суга барган чак була, судан кайткан чак була» дип кенә куяр. Монысы инде суга баргандагы кебек буш чиләкле чагым да, судан кайткандагы кебек тулы чиләкле чагым да була дигәнне аңлата. Аңлаган кеше аңлый, аңламаганы үзенчә баш вата инде. Һәр әйткән сүзен аңлап була торган булса, Фасил Әхмәт тә булмый бит инде ул...
Синең белән күрешеп, эч серләрен бүлешеп утырасы килгән чакларда да, ниндидер ярдәм яисә киңәш кирәк булганда да, ул аны турыдан-туры кистереп әйтми. «Эшең бик тыгыз түгелме? Кеше күрәсең килмәгән чагың түгелме? Минем шул якларга кагылып чыгасым бар иде... Хәзер теге калтырча «Запорожец»ны кабызып карыйм әле...

Сезнең дә бар мачыгыз,
Безнең да бар мачыбыз,
Безнең мачы сезгә килсә,

Зинһар, ишек ачыгыз», –

ди дә трубканы куя.

Бу кыска гына истәлек-язмамда мин композитор Фасил Әхмәтнең әсәрләренә тәфсилле анализ ясарга да, бәя бирергә дә җыенмыйм. Чөнки аның иҗатына бәяне инде халык үзе бирде. Әмма Фасил абый турында уйлаганда, мине һәрвакыт аңлатып булмый торган нindидер авыр сагыш баса. Элегрәк мин бу хисне Фасил абыйны сагынудан, юксынудан дип уйлый идем. Яши-яши моның серенә ныграк төшенә башладым – бу Фасил абыйның үзен, аның белән аралашу мизгелләрен генә түгел, ә беренче чиратта аның рухын, халкыбызның бөтен уй-фикерләрен, хәсрәт-кайгыларын сеңдергән күңел дөньясын, иҗатын сагыну икән. Татар халкының Габәшиләрдән, Сәйдәшләрдән башланган гаҗәеп бай милли музыка хәзинәсе бар. Мансур Мозаффаров, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарёв, Аллаһияр һәм Хөснул Вәлиуллиннар, Әнвәр Бакиров, Исмай Шәмсетдинов, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Мирсәет Яруллин, Ренат Еникеев... Бу исемнәрне санавым юкка гына түгел, чөнки соңгы елларда аларны бик сирәк искә алалар, концертларда, радио һәм телевидение тапшыруларында аларның әсәрләрен бик сирәк яңгыраталар. Татар дөньясын бүген «уйнаштан туган» милләтсез көйләр, компьютер-композиторлар язган бер көнлек җырлар басып китте. Ә милләтебезнең алтын хәзинәсе онытылып нота битләрендә ята, радио һәм телевидение архивларында юкка чыгып бара. Ә Фасил Әхмәт шушы корифейлар белән иңгә-иң торып иҗат иткән олы композитор, дөньяның теләсә кайсы залларында уйнарлык милли әсәрләр иҗат иткән кабатланмас талант иясе иде бит. Кайвакытта мин: «Әллә соң Фасил Әхмәт татарның чын мәгънәсендә милли әсәрләр иҗат иткән соңгы композиторы булдымы икән?» – дип, үз-үземә сорау да биреп куям. Һәм шул чакта бик тә куркыныч булып китә...

Дөньяда гади язмышлы иҗат кешесе булмый торгандыр. Чөнки иҗат һәрчак икеләнүләрдән, эзләнүләрдән, ялгышлардан, борчулардан тора. Ә Фасил абыйның язмышы аеруча катлаулы иде. Сиксәненче елларда иҗат әһелләренә дәүләт тарафыннан игътибар кимеп, инвалидлык пенсиясенә генә көн күрергә калгач, ул кешеләр арасына көннән-көн сирәгрәк чыга, концерт-спектакльләрдә әллә нигә бер генә күренә башлады. Мин үз-үземә моны башта аның сәламәтлеге белән, олыгая баруы белән аңлатырга тырыштым. Фасил абый элеккечә иртәләрен телефоннан шылтыратып үзенчә хәлне белешә, вакыт чыккан саен, очрашып-күрешеп тә торабыз. Ул һаман шаярырга, мәзәк сүзләр сөйләргә, үзенең дә, безнең дә күңелне күтәрергә тырыша... Әмма көннән-көн аның болай да моңсу күзләре сагышлырак була бара, вакыт-вакыт ул язмышка һәм тормышка үпкәсен дә белдереп куя иде.

Үз-үзенә урын таба алмыйча, шулай бәргәләнеп яши торгач, көннәрдән бер көнне ул Казаннан Әлмәткә күчеп китәргә дә ниятләде. Республика җитәкчелеге, Әлмәт хуҗалары белән сөйләшеп, аларның хәер-фатихаларын алса да, нишләптер бу теләген тормышка ашыра алмый калды.

1991 елда булса кирәк, хәзерге К.Тинчурин театры бинасында мәдәният хезмәткәрләренең республика корылтаен үткәрделәр. Корылтайга Фасил абый да чакырулы иде. Иртән мин юл уңайлый аның янына кердем, исәбем анда бергә бару иде. Ул мине, ниндидер ярамас эш эшләгән малай сыман, кыенсынып кына каршы алды. «Мин бара алмыйм инде. Бераз сырхаулап та торам, кәефем дә юк. Менә корылтайга бәләкәй генә хат яздым, шуны делегатларга кычкырып укырсың», – диде.

Нишлим, хатны кесәгә салдым да театрга киттем. Конвертны ачып, аның хатын укыгач, йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды... (Бу хатны корылтай документлары янына теркәргә кирәк дип, миннән алып калдылар, шуңа күрә сүзен-сүзгә хәтерләмим, әмма эчтәлеге менә болайрак иде...)

*«Хөрмәтле делегатлар!*

*Барчагызны да бүгенге бәйрәмегез, корылтайга җыелуыгыз белән котлыйм! Әмма ул бер-берегезне макташып яисә сүгешеп утыра торган гадәти җыелыш кына булмасын иде. Чөнки милли сәнгатебез бүген упкын читенә килеп җитте, иҗат оешмаларыбыз хәерчелек хәленә төште, иҗат әһелләребезнең кирәге, кадере бетте. Менә мин – Фасил Әхмәтов, Татарстанның һәм Россиянең иң югары Дәүләт бүләкләрен һәм исемнәрен алган композитор – бүген хәерче*

*хәлендә яшим. Көне-төне иҗат итсәм дә, минем әсәрләремне сатып алучы, аның өчен миңа гонорар түләргә җыенучы оешма юк. Димәк, бүген минем беркемгә дә кирәгем юк. Ә адәм баласы бит кадере булганда гына тулы көченә эшли, кирәге булганда гына милләткә хезмәт итә ала. Миңа нишләргә бүген? Бер миңа гына түгел, сезгә дә, безгә дә – барчабызга да нишләргә хәзер? Корылтайда шул турыда сүз алып барсагыз, шул сорауларга җавап эзләсәгез иде.*
*Сүземне тәмамлап, шуны гына әйтмәкче булам. Беребез дә мәңгелек түгел, мин дә кайчандыр якты дөньядан китәрмен. Әмма киткәндә үземнең оныкларыма: «Зинһар өчен, композитор яисә музыкант булмагыз!» – дип, васыятемне әйтеп калдырачакмын».*
Бу хатны укыргамы-укымаскамы дип икеләнеп, бер-ике агай белән фикерләшеп тә алдым. Җыелышны алып баручы җитәкчебез, кистереп, укымаска киңәш итте. Әмма Фасил абыйның әманәтен үтәмичә булдыра алмадым... Хатны укып бетергәч, зал тып-тын калды, җыелыш җитәкчесе, бу авыр хәлдән котылу өчен, тәнәфес игълан итәргә мәҗбүр булды.
Кайтышлый мин тагын Фасил абыйга сугыласы иттем. Ул кухня бүлмәсендә бер дусты белән чәйләп утыра иде. Бит очларына алсулык кунган, күзләрендә дә элекке очкыннар күренә башлаган, аларда иртәнге моңсулыкның эзе дә калмаган иде. Корылтайдагы хәлләрне, аның хатын укуымны сөйләгәч, ул шактый вакыт уйланып, сүзсез торды. Аннары кулымнан тотты да, зәгыйфь аякларын зәңгәр келәм өстеннән шудыра-шудыра, түр бүлмәгә алып кереп китте. Почмактагы кием шкафын ачты да костюмын алып идәнгә ыргытты. «Корылтайга бармавыма шушы костюм гаепле! Кия-кия, тышы каешланып, эче теткәләнеп беткән костюм! Ничек инде мин, татарның мәшһүр композиторы, Татарстанның һәм Россиянең Дәүләт премияләре лауреаты була торып, шундый костюм белән корылтайга барыйм ди?!» Шулчак аның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төште...
Мин аның костюмын шкафка элеп куйдым. «Мондый костюм белән өйләнеп тә була әле. Мин өйләнгәндә, костюмым да юк иде, күрше егет костюмын киеп өйләндем», – дип шаяртырга, аның күңелен күрергә тырыштым. Билгеле, эш монда костюмда гына түгел, ә зуррак, катлаулырак нәрсәләрдә иде. Әмма аның ул зуррак нәрсәләрне хәл итәргә көче-куәте дә, мөмкинлеге дә юк, шуңа күрә бар ачуын гаепсез костюмыннан ала сыман иде.
Фасил абыйдан миңа бик күп хатирәләр, истәлекләр калды. Шуларның иң кадерлесе, билгеле инде, икебез бергә иҗат иткән «Ядкарь» җыры. Аның исеме дә, җисеме дә, көе-моңы да нәкъ менә Фасил абыйны мәңге сагынып сөйләр, искә алыр өчен махсус язылган кебек...
Аның язылу тарихы болай булды... Ул елларда Актёрлар йортында Рабит Батулла оештырган «Ядкарь» берләшмәсе бар иде. Ай саен татар яшьләре җыелып анда кичәләр үткәрәләр, милләт проблемаларын уртага салып сөйләшәләр. Бу кичәләр яшьләр арасында бик тә популяр иде. Батулла миңа шул кичәләрнең гимны булырлык җыр өчен шигырь язарга кушты. Мин аны төн утырып яздым да иртән телефоннан Фасил абыйга укып күрсәттем. Төш турыларында ул миңа шылтыратып, телефоннан үзенең көен уйнарга тотынды. Көй миңа артык гади, бизәксез, моңсыз тоелды. Шул турыда Фасил абыйның үзенә дә әйттем. Бу минем Мәскәүдә, Әдәбият институтында укыган елларым иде. Икенче көнне Мәскәүгә китеп бардым, җыр турында бөтенләй онyттым. Шулай бервакыт Казанга кайткач, Искәндәр Биктаһировның радиодан нииндидер яңа җыр башкаруын ишетеп, әсәрләнеп тын калдым. Сүзләре дә, көе дә таныш, колакка да, күңелгә дә шулкадәр якын иде. «Безнең җыр бит бу – «Ядкарь», – дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым. Шунда ук Фасил абыйга шылтыратып, яңа җыр белән котладым, теге вакытта авыр сүзләр әйтүем өчен гафу үтендем.
Шул көннән башлап, телефоннан шылтыратышканда, безнең беренче сүзебез «күптән инде, күптән очрашкан юк» дип башлана торган булды.
Мин әле хәзер дә иртәләрен уянып киткәч, көнне башлап җибәрергә кыймыйча, шактый вакыт уйларымны туплап, хатирәләргә чумып ятам. Шулчак кинәт кенә өстәлдәге телефон шылтырар да, аннан Фасил абый:

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсең бергә чакларны? –

дип эндәшер кебек. Ә мин аңа:

Үткәннәрдән бары шул җыр калды –
Ул җыр безгә яшьлек ядкаре, –

дип җавап бирермен сыман.

*2005*

# УЙЛЫЙ ТОРГАН ЙӨРӘК

Туфан... Ап-ак кәгазь битенә шушы тылсымлы сүзне язып куйдым да туктап калдым. Бу сүз мине куркыта, бу сүздә ниндидер шом да, гарасат та, олылык һәм олпатлык та бар. Ә инде исемгә әверелгән сүзнең мәгънәсе тагын да зуррак, тагын да тирәнрәк. Бу сүз, бу исем тарих чоңгылларында бата-чума мең бәлаләр кичеп бүгенге көнгә килеп җиткән татар язмышына бик тә аваздаш...

Үз нәсел-нәсәбенең киләчәге хакында чынлап уйлаган кеше баласына очраклы исем кушмый торгандыр. Әти-әнисе тупырдап торган бу улларына туа-туышка ук олы һәм катлаулы язмыш юрагандыр, шуңа күрә татарда сирәк очрый торган гаҗәеп мәгънәле Туфан исеме сайлагандыр...

Ни өчен исем турында шулай озаклап сөйлим соң әле мин? Чөнки әтиең-әниең тапкан, мулла бабай колагыңа пышылдаган исем – ул синең гомерлек шигарең, бер сүзгә сыйган язмыш авазың. Теләсәң-теләмәсәң дә, син аны акларга, ул исемгә лаеклы булырга, җисемеңне исемеңә тәңгәлләштерергә тырышасың. Ә Туфан исемен аклау, аңа лаеклы булу, ай-һай, авыр бурыч!..

Ак кәгазьгә «Туфан» дип яздым да уйга талдым... Шушы көнгә кадәр мин Туфан Миңнуллинны яхшы беләм дип йөри идем. Инде утыз елга якын аралашып яшибез, китапларын да укып барам, пьесаларын карыйм... Әмма аның турында язарга дип утыргач, мин, гомеремдә беренче тапкыр диңгез күргән авыл малае сыман, чарасыздан аптырап, югалып калдым. Чөнки көн саен очрашып-сөйләшеп йөргәндә, аерым-аерым әсәрләрен укыганда, никадәр генә хозурлансам, никадәр сокланcам да, мин диңгезнең аерым-аерым дулкыннарын гына күргәнмен, йотым-йотым һавасын гына сулаганмын икән. Ә инде чыккан барча китапларын, язмаларын күздән кичереп, Туфан Миңнуллинның кылган гамәлләрен бер җепкә тезеп, бөтен әсәрләрен өр-яңадан күңелем аша үткәреп утырганда, гүя беренче мәртәбә чынлап торып аның олылыгын тойдым, мин аны тагын да ныграк аңлый башладым, үзем өчен өр-яңадан ачкан кебек булдым.

Бүген татарның олуг драматургы булса да, иң әүвәл чикләвек төше төсле тыгыз тәнле кыска хикәяләре аша таныш һәм кадерле иде ул безгә. Күңелгә яктылык өсти торган иркен холыклы, изге җанлы авыл кешеләрен яратып та, олылап та, чеметеп тә тасвирлаган бу хикәяләрне инде утыз ел узгач кулга алдым да икеләнеп калдым. Яңадан укыргамы, юкмы? Балачакта без менгән таулар да хәзер әнә калкулык кына булып калган, ул чакта көчкә йөзеп чыккан елгалар да чыпчык тезеннән генә... Заманында классик саналган кайбер язучыларның романнары бүген очсыз-кырыйсыз газета мәкаләсе кебек тоела... Бәлки, укымаскадыр, риясыз күңелгә кайчандыр бәйрәм булып кереп калган ул хикәяләргә тимәскә, вакыт дорфалаган куллар белән кагылып рәнҗетмәскәдер?..

Башта икеләнеп кенә кулга алган китапларны, аерыла алмыйча, күзгә шәфәкъ төсе кунганчы укыганда, мин Туфан хикәяләренең вакыт сынавы узып күңел түрендә калуы, аның бәясе төшмәве өчен куандым. Хикәяләрен генә түгел, өстәлемдә тау-тау өелгән пьесаларын, повестьларын, шигырь-робагыйларын, көндәлек-язмаларын тагын бер кат күңел иләге аша үткәрдем... Һәм Туфан Миңнуллин минем өчен тагын да зураеп, олпат Ил агасы, милләт язмышы өчен кайгырып, ил борчуы белән борчылып яшәүче һәм иҗат итүче олуг зат, фидакяр шәхес булып күз алдыма килеп басты.

Начар кешенең яхшы әсәрләр яза алуына, начар кешедән яхшы язучы чыгуына беркайчан да ышанмадым мин. Бик оста да, образлы тел белән дә язарга мөмкин ул, әмма ләкин күңелендә изгелек, яхшылык ятмаса, укучы аның әсәрен барыбер кабул итми. Иҗат кешесе иң беренче чиратта ихлас булырга тиеш. Бер караганда, ихлас булу бик гади нәрсә кебек. Күңелеңдәге бөтен уйларыңны, хисләреңне кешеләргә ачып салсаң, шул ихласлык буладыр кебек. Әмма монысы аның ихласлык түгел, монысы беркатлылык, ә беркатлы кешене бездә, киресенчә, бигүк хөрмәт итмиләр. Ә ихлас кеше үзенең иң өстә яткан беркатлы уйларын гына түгел, ә күңел түренә яшерелгән катлам-катлам хисләрен, икеләнүләрен, ялгышларын, хәвефләрен башкалар белән бүлешә, үз язмышын башкалар хөкеменә тапшыра.

Туфан Миңнуллинның һәр әсәрендә, әсәренең үзәгендә, бәгырендә ихласлык һәм халык язмышы өчен борчылу ята. Кайвакытта миңа ул хәтта кирәгеннән артык ачылып, чишенеп ташлаган сыман тоела башлый. Әмма укучы аны шушы ялгышлары, хаталары белән бергә кабул итә, аның хәленә керә, аны шушы риясыз күңеле, риясыз хисләре өчен якын күрә. Чөнки ул начар күңелле, начар уйлы адәмнең беркайчан да менә шулай туарыла алмавын, чын хисләрен гомер буе күңел читлегендә бикләп асравын, гомер буе «яхшы кеше» ролен уйнавын бик яхшы аңлый.
Халык теленә керерлек олпат язучы булу өчен, ихласлык янына тагын бик күп сыйфатларга ия булу кирәк әле. Тел байлыгы, сюжет осталыгы һәм башкалар турында сөйләп тормыйм, болары бәхәссез нәрсәләр. Әмма, ни гаҗәп, искиткеч тасвирлы итеп чәчәкле-чуклы җөмләләр белән язылган әсәрләр дә еш кына бер көнлек матур күбәләк кебек ялтырап ала да бик тиз онытыла, каядыр юкка чыга. Чөнки ул әсәрләрдә кешене чынлап торып уйландыра, борчуга сала торган ихлас тойгы, кеше күңеленә дәрт һәм куәт өсти торган илаһи көч булмый. Язучы иң беренче чиратта кешенең иң авырткан урынын, иң тирән ярасын эзләп табарга, үз әсәрен дару үләне итеп шул ярага капларга тиеш. Димәк, язучы үз янәшәсендәге кешеләрнең борчу-кайгыларын, үз халкының язмышын һәрдаим күңеле аша үткәреп яшәргә тиеш. Ә моның өчен иң беренче чиратта шәхес була алу кирәк.
Ә көчле шәхес инде ул олы максаты һәм әйтер сүзе булган, шул сүзне кайда һәм ничек итеп әйтергә кирәклеген яхшы аңлаган изге ниятле кеше. Туфан Миңнуллинны мин нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булган шәхес буларак беләм, шуңа күрә дә бөтен барлыгы белән кабул кылам, хөрмәт итәм.
Ул үз күңелендәге туры сүзне дуска да, дошманга да бәреп әйтә, кайчакта хәтер саклап та тормый, әмма берчакта да позага басмый, урам себерүчене дә үзе белән тиң күреп аралаша, президентлар янында да мескенләнмичә сөйләшә белә. Ил язмышы, халык язмышы хакында сүз барганда, ул беркайчан да читтә калмый, киресенчә, алдын-артын карамыйча, ярсый-ярсый ут эченә ташлана. «Туктагыз әле, агайне, алай түгел, болай бит ул», – дип, күпләрнең фикерен үз ягына борып җибәрә ала. «Ничек шул акыллы башлы җитәкчеләр синең сүзгә колак сала соң?» – дигәч, ул сирәк тешләрен күрсәтеп ихластан елмая да: «Алар баш белән уйлый, ә мин – йөрәк белән. Аермасы шунда гына», – дип куя.
Аның әсәрләренең сере, тылсымлы көче турында мин күп уйландым, аңларга тырыштым, һәм гап-гади бер нәтиҗәгә дә килдем бугай... Туфан Миңнуллин дигән язучының таланты, иҗат үзенчәлеге – кешеләрне, табигатьне, тормышны, гомумән, бар дөньяны ярата белүендә. Кайберәүләр, бәлки: «Туфан бит ул кайчак усал да була, ярсый, нәфрәтләнә дә ала», – дип әйтерләр. Әйе, кирәк чакта ул бик усал, ләкин бу усаллык кемгәдер үч итеп, кемнедер юкка чыгарырга тырышып усаллану түгел, ә гаделлекне, яхшылыкны, изгелекне яклап, үзе яраткан һәрнәрсәне, кешеләрне, милләтне яклап усаллану. Аның әсәрләрендәге яман затлар да бөтенләе белән яман түгел, ә бәлки ялгышкан яисә язмыш карурманында адашкан бичаралар. Алар да Туфанның үз балалары, алар да бу җирдә яшәргә хаклы, алар да Алла бәндәләре. Хәтта җан алырга килгән Газраил дә Туфан Миңнуллин кодрәте белән әкренләп яхшы якка үзгәрә, язучының йөрәк җылысы әкренләп аңа да күчә башлый.
Көндәлек тормышта, фани дөньяда һәммә нәрсә – яхшысы да, яманы да җитәрлек. Урманга барып эзләсәң, агулы гөмбә табарга да, чәчәк җыярга да була. Кем нәрсә эзли, шуны таба... Туфан Миңнуллин кеше күңеленнән, тормыштан яхшылык эзләп, матурлык эзләп яши, тапса, сөенә, тапмаса, бөтен җаны-тәне белән борчыла. Шуңа күрә аның әсәрләрен укыгач, пьесаларын карагач, арыган күңелләргә дәрт өстәлә, бу дөньяда изге эшләр эшлисе, онытылып яратасы һәм яшисе килә башлый...
«Кешенең ниндилеген, кем икәнен чынлап торып аңлыйсың килсә, аның туган ягына барып кара», – диләр. Туып үскән нигезе, нәсел-нәсәбе, яшәгән мохите, кешеләре нинди, димәк, ул да шундый...
Әсәрләрен укып та, кешедән ишетеп тә Кама Тамагы районындагы Мәрәтхуҗа авылы турында шактый белә идем инде. Җәй җитүгә, Туфан үзе якын күргән яшь каләмдәшләрен ияртә дә авылына кайтып китә. Алар бергәләп уйный-көлә мунча салалар, тагын әллә ниләр эшлиләр.

Казанга әйләнеп кайткач, авыз суларын корыта-корыта, көннәр буе анда күргән мажараларын сөйлиләр. Без авыз ачып, кызыгып, көнләшеп тыңлыйбыз. Туфан Миңнуллин язганнарга боларның сөйләгәннәре дә кушылгач, Мәрәтхуҗа тагын да серлерәк, тагын да матуррактыр кебек тоела башлый...
Күпме чакырып, күпме җыенып та бара алмаган идем, әмма Мәрәтхуҗаны күрергә җай бөтенләй уйламаган-көтмәгән җирдән килеп чыкты... «Әйдә, Татарстанның бер башыннан икенче башына хәтле атта сәяхәт итәбез! – диде миңа беркөнне Туфан агай. – Син, мин, Марсель Гали – өчәүләп...» Азнакай районында Туфан Миңнуллинның хәләл җефете, күренекле артистка Нәҗибә Ихсановага якташлары юбилей көнендә ат бүләк иткәннәр икән. Билгеле, аны машина белән көнендә җилдереп китереп тә бирә алырлар иде. Ләкин Туфанның атны үз аягы белән үзе Мәрәтхуҗага алып кайтасы килә. Шулай итеп, балачактан ук ат җене кагылган өч хыялый Азнакай якларына юл алдык. Бу гамәлебез башта миңа чираттагы шагыйранә юләрлек, сабыйлыкка кайту булып тоелган иде. Әмма тузанлы юл буйлап арба өстендә яланаякларын селки-селки барган алтмыш яшьлек Туфан Миңнуллинның бөтенләй яшәреп китүен күргәч, без дә, үзебез сизмәстән, иңнәребезне басып торган еллар йөген алып ташлагандай булдык. Ат арбасын тузанга күмеп юл читенә кысрыклаган иләмсез йөк машиналарын сүгә-сүгә, басуларда чалгы селтәп печән чаба-чаба, урман аланнарында исерткеч исле үлән өсләренә ятып ауный-ауный биш көн, биш төн кайттык без Мәрәтхуҗага. Болгар хәрабәләрен узып, Идел ярына килеп баскач, Туфан, аргы якка таба кулын сузып: «Ә-әнә шунда, таулар артында инде Мәрәтхуҗа», – дип күрсәтте. Безне алырга бер чакрым буйлы баржа килгән иде. «Монысы да Туфанча...» – дип уйлап куйдым мин эчтән генә. Әмма гаҗәпләнәсе нәрсәләр алда булган икән әле...
Шундый мажаралар белән кайта торгач, миңа инде Мәрәтхуҗа авылы әкиятләрдәге Каф таулары артындагы тылсымлы бер бәхет утравы булып тоела башлаган иде. Менә, ниһаять, офык читендә берәм-сәрәм йортлар күренде, кичке эңгердән мәчет манарасы йөзеп чыкты. Урамнары да, юллары да, койма-капкалары, йортлары да нәкъ безнең авылдагыча... Шаккатарлык бер нәрсә юк сыман. Мин, аптырап, Туфан абыйга күтәрелеп карадым. Ә ул бөтен дөньясын оныткан да, үз биләмәсенә сәях чыккан падишаһ кебек, ат арбасында оеп кайтып килә. Монда аңа бөтен нәрсә якын, бөтен нәрсә кадерле, чөнки монда аның үзен дә якын итәләр, яраталар, монда аңа ышаналар. Монда – мәчете дә ул төзегән мәчет, юлы да ул салдырган юл, йорты да, бакчасы да, сулар һавасы да, кешеләре дә үзенеке... Бу – аның үз иле, мөстәкыйль дәүләте кебек. Ул авылындагы һәрбер агач турында, бакчасындагы һәрбер куак хакында шулкадәр яратып, үз итеп сөйли ки, без әсәрләнеп аны тыңлыйбыз һәм, үзебез дә сизмичә, шул арада Мәрәтхуҗага гашыйк була барабыз.
Икенче көнне иртән, машинага утырып, Казанга юл алдык. Туфан абый безгә иярмәде, ул, гүя әнисе кочагыннан аерыла алмаган сабый бала кебек, туйганчы назланырга, сагынуын басарга дип, авылында калды. Без шактый вакыт сөйләшмичә кайттык, һәрберебез эчтән генә хәтер йомгагын сүтеп, сәяхәттә күргәннәрен күздән кичерә, Туфан бүләк иткән бу сихри могҗизадан чыгасы килмичә тын гына бара. Язучы булу өчен иң элек ныклы нигезең, яраткан һәм яраттырган туган төбәгең, туган авылың булу кирәк икән бит... Ябалдашлары бөтен татар дөньясына җәелгән Туфан Миңнуллин иҗатының, Туфан шәхесенең кәүсәсе Казанда булса, аның тамырлары монда – Мәрәтхуҗада икән ләбаса. Аның әсәрләрендәге һәм үз холык-фигылендәге горурлык – туган ягындагы таулардан, бетмәс-төкәнмәс көч-куәте, ярсулыгы офык читендәге мәгърур Иделдән, күңел сафлыгы һәм мәңгелек сабыйлыгы авыл табигатеннән, авыл кешеләреннән күчкән икән бит аңа. «Мәскәүләрдә, Парижларда танылып та, үз авылындагы кешеләр якын итмәгән язучыны мин зур язучыга санамыйм», – дигән иде берчакны Туфан Миңнуллин. Менә хәзер шул сүзләре искә төшеп, мин тагын бер кат аның өчен куанып куйдым.
Туфан Миңнуллинны башкалардан аерып торган тагын бик күп сыйфатлар бар. Аларның берсе – самолётта очмау. Кая гына барасы булса да, ул очкычка утырмас, поездны, машинаны яисә атны сайлар... Моның сәбәбе нәрсәдәдер, белмим, әмма үземчә мин аны болайрак юрыйм... Аның күңелендәге уйлар, хыяллар, кайгы-хәсрәтләр, борчу-мәшәкатьләр шулкадәр күп һәм саллы ки, ул самолётның аларны күтәрерлек көче барлыгына ышанмыйдыр, Җир аны үзеннән җибәрмәс, үз

янына кире тартып төшерер дип шикләнәдер сыман. Кайчакта болай да уйлап куям... Туфан абый һәр нәрсәнең чигенә җитмичә туктамый торган максималист холыклы гаярь кеше, бәлки, ул җирдән аерылып китсәм, кире беркайчан да әйләнеп кайтмам, йолдызларга кадәр очармын дип тә курка торгандыр...

Олпат язучы, мәртәбәле шәхес, танылган драматург Туфан Миңнуллинны бигрәк беркатлы, бала-чага кыяфәтендә тасвирлавыма кайберәүләр аптырап та калырлар, бәлки. Ә ул чыннан да шундый. Сабый холыклы булмаган кеше Мәскәүнең Съездлар сараенда үз алдына куелган «ТАССР» дигән язуның «А» хәрефен каләм белән сызып утыра алыр идеме икән? Татарстанның автономия кысаларыннан чыгып, союздаш республика булырга дәгъва белдергән еллары бу. Туфан Миңнуллин ул чакта СССР халык депутаты. Татарстан үзен бәйсез дәүләт дип игълан иткәч, ул, каләмен алып, әлеге язуның «А» хәрефен сызып ташлый. Моның каршына тагын «ТАССР» дип язылганны китереп куялар. Ул тагын сыза. Әллә ничә мәртәбә шулай кабатлангач, түземнәре бетә һәм, ниһаять, үзгәртеп, «ТССР» дип язарга мәҗбүр булалар. Моны сабыйлык димичә, нәрсә дисең инде? Әмма бу сабыйлыкның төбендә халыкның буыннардан буыннарга күчеп килгән хыялы, теләге, омтылышы ята. Ә сабыйларча беркатлылык һәм үҗәтлек белән шушы тойгыны, шушы хыялны башкаларга җиткерергә тырышу Туфан Миңнуллинның Съездлар сараенда да гади бер депутат кына түгел, ә язучы һәм шәхес булып калуы хакында сөйли. Чөнки язучы гомере буена сабыйлыгын югалтмаган, акыллы сабый булып кала алган илаһи зат бит ул.

Туфан Миңнуллин йокымсырап яшәүче, эшлексез һәм мокыт бәндәләрне, буш күңелле кешеләрне, гомумән, җәмгыятьтәге, тормыштагы бушлыкны яратмый. Ул булган җирдә һәммә нәрсә җанлана, бүлмәләр, зур заллар аның гөрелтесе, аның фикере, аның елмаюы белән тула. Ул бернәрсәгә дә битараф түгел, ул кирәк чакта нәфрәтләнә дә, гаҗәпләнә дә, шакката да белә. Ул әсәрләнеп сөйли дә, әсәрләнеп кешеләрне тыңлый да ала. Шуңа күрә аны һәр җирдә көтеп алалар. Димәк, Туфанда тагын бер сирәк талант – үзен сагындыра белү таланты бар...

Ул һәрвакыт кычкырып сөйләшә, аның килгәнен ярты чакрымнан ишетеп торалар. Гөрелдек тавышы белән ул әйтерсең: «Минем сездән, кешеләрдән бер яшерен серем дә юк. Минем сүзләремне һәммәгез дә ишетегез!» – дип әйтергә тели сыман.

Гаҗәп сыйфатлары тагын бик күп әле Туфан Миңнуллинның. Очрашканда, кочагын җәеп, рәхәтләнеп исәнләшсә дә, саубуллашканда, беркайчан да кешегә кулын бирми ул. Борынгы йолага яисә ырымга ышануы бу, әллә башка берәр сәбәбе бармы, белмим, әмма мин монда бер киная, олы мәгънә күрәм. Әйтерсең аның безнең белән, кешеләр белән саубуллашасы, кешеләрдән аерыласы килми, әйтерсең ул үзе якын күргән кешеләр белән, үз халкы белән һәрдаим янәшә булырга тели.

Татарның бөек шагыйре Хәсән Туфаннан соң, тагын бер тапкыр Туфан исемен аклау, әдәбият диңгезендә югалмыйча, шул исем белән тагын бер тапкыр бөтен халыкка танылу, дан казану үзе бер могҗизадыр! Кече Туфан Олы Туфанның фатихасын алып әдәбиятка килде... «Талантлы син, Кеше туганым!» – ди Х. Туфан үзенең бер шигырендә. Ә миңа ул офыклардан офыкларга кадәр яңгырап: «Талантлы син, Кече туганым!» – дип ишетелә...

Ә Туфан Миңнуллинның таланты милләт язмышын үз язмышы итеп яшәвендә, көчле-куәтле, серле-мәгънәле, шифалы-бәрәкәтле әсәрләр иҗат итүендә, үз халкының бәгырь кисәге, газиз баласы һәм яклаучысы була алуында.

*2001*

# ТУФРАКТАН ЯРАЛГАН ТУФАН

*(75 яшьлек Туфан Миңнуллинның*
*Гамәл дәфтәреннән кайбер сәхифәләр)*

*Туфан Миңнуллинны иң беренче чиратта без язучы, драматург, депутат буларак беләбез. Язган әсәрләре, сәхнәгә куелган пьесалары буенча аңа бәя бирәбез. Әмма, Тукайчарак итеп әйтсәк, Туфан коеп куйган драматург кына түгел, Туфан зур ул, бөек ул, аның күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә.*
*Бу язмамда мин Туфан Миңнуллинның иҗаты хакында түгел, ә үзе турында, аның күпләргә билгеле булмаган кайбер сыйфатлары, соңгы елларда майтарган игелекле гамәлләре, үзенчәлекле гадәтләре турында сөйләргә булдым. Инде кырык елга якын аралашып-күрешеп, киңәш-табыш итешеп яшәгән энекәше буларак, минем моңа хакым бардыр дип уйлыйм.*

### Туфан холкы

Беренче күрүемдә мин иң элек Туфанның чәчләренә игътибар иттем. Урман-чытырман сыман уралып-бөтерелеп үскән, тимер тарак та кермәслек бу куе кара чәчләр астында гадәти генә баш була алмавы көн кебек ачык иде. Тора-бара аның холкы да чәченә охшаш икәнне аңлый башладым. Дөрес, еллар узган саен, бу чәч дулкыннары, үзләренең ярсулыгын бераз югалтып, салмаклана, тынычлана төштеләр. Әмма аңа карап Туфанның холкы үзгәрмәде, ул һаман йөрәк кайнарлыгын, яшьлек бунтарьлыгын югалтмыйча, үз исеменә бәрабәр булып кала бирде.
Шактый вакыт мин Туфанның гел кычкырып сөйләшүенә ияләшә алмый йөрдем. Телефоннан сөйләшкәндә болай да Кама Тамагына ишетелерлек итеп кычкыруы, өч кешелек мәҗлестә өч йөз кешелек залда сөйләгән кимәлдә нотык тотуы минем өчен сәер дә, кызык та тоела иде. Баштарак моны артистлык сәнгатен үзләштергән кешенең һөнәри сыйфаты дип кабул иттем. Алай дисәң, башка артистлар кычкырып та, пышылдап та сөйләшә-гәпләшә беләләр бит. Яши-аралаша торгач, моның да серенә төшендем бугай. Беренчедән, үзе әйтүенчә, аларның гаиләсендә һәммәсе дә һәрчак шулай кычкырып сөйләшкән икән. Мәрәтхуҗа авылында боларның өе яныннан узып барган кешеләр «Габдулланыкыларда тавыш чыккан» дип уйлый торган булганнар. Ә чынлыкта, алар бөтен гаилә белән рәхәтләнеп, чөкердәшеп чәй эчеп утыралар икән. Димәк, бу читтән кергән, өйрәнелгән гадәт түгел, әлеге дә баягы үҗәт холык, эти-әнидән, нәселдән мирас булып күчкән Туфан холкы икән. Ә ул холыкның төбендә, минемчә, шәхесне шәхес иткән иң олы ике сыйфат – ихласлык һәм үз-үзенә ышаныч ята. Үз-үзенә ышанган кеше генә шулай бар дөньяга ишетелерлек итеп аваз сала, бары тик ихлас күңел аша узган әсәрләр генә башкаларның күңеленә юл таба.

### Туфан киеме

Халыкта «кешене киеменә карап каршы алалар» дигән гыйбарә бар. Бу сүзләрдә хаклык булса да, алар нигәдер Туфанга кагылмый кебек. Чөнки Туфанның халәте төрледән-төрле булган кебек, аның киенүе дә гадәти кешенеке төсле түгел. Хәләл җефете, күренекле артисткабыз Нәҗибә ханым берзаман: «Туфан гаҗәеп зәвыклы итеп киенә белә», – дип язып чыккан иде. Аны укыгач, мин көлемсерәп куйдым, чөнки Дәүләт Советы рәисе, гаҗәеп пөхтә киенүче Фәрит Мөхәммәтшинның: «Туфан, бу чалбарыңның үтүк күргәне бармы?» – дигәнен ишеткәнем бар иде. Ә чынлыкта, алар икесе дә хаклы. Көндәлек гадәти халәттә Туфан бик гади киенә, ул таушалган джинсы чалбар белән чәчәкле-чуклы күлмәк киеп, башына ковбой эшләпәсе элеп тә урамга чыгарга мөмкин. Тантаналы кичәдә яисә мәҗлестә – Туфанны танырлык түгел: аның

өстендә яңа гына манекен иңнәреннән төшкән модалы костюм, күз явын алырдай галстук булыр! Ә Сабан туенда, милли бәйрәмнәребездә бөдрә чәчле тубал башына татар түбәтәе менеп кунаклар. Түбәтәйнең дә теләсә кайсын кими: көндәлеккә бизәксез кара түбәтәй сайлый, ә бәйрәмнәрдә чигелгәнен кияргә ярата. Язучыларның Германиядә һәм Австриядә узган халыкара конгрессларында да башыннан төшмәде аның түбәтәй. Татар язучыларын анда иң беренче чиратта Туфан түбәтәе аша танып алалар иде.
Кыскасы, Туфан кайда, кем янында ничек киенергә кирәклеген яхшы белә. Бер караганда, ул киемгә бөтенләй игътибар да итми кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Туфан авылга кайтканда – чын авылча итеп, президент янына барганда – президентларча, халыкара форумнарда Европа фраерларыча киенә.
Минем уйлавымча, күңелендә гармония, тәртип булган кеше тышкы вак-төяк тәртипсезлекләргә артык игътибар итми, ә күңеленә тынычлык таба алмаган, күңелендә болгавырлык хөкем сөргән кеше исә тирә-юнендә, шул исәптән киемендә, бүлмәсендә һәрчак идеаль тәртип урнаштырырга тырыша. Ә Туфан Миңнуллин үзенең тынгысыз күңелендә үзе тәртип урнаштыра, күңеле белән идарә итә белә торган шәхес. Шуңа күрә дә аның киеме һәрчак күңел халәтенә бәрабәр, шуңа күрә дә Туфанның киеме аның үзенә охшаган.

**Туфан гадәтләре**

Туфан, гадәттә, кешеләр белән елмаеп, ике куллап күрешә. Озак күрми торган якын дусларын, очрашканда, кайчак кочаклап та ала. Әмма саубуллашканда беркайчан да кешегә кулын сузмый. Кул биреп саубуллашсаң, бөтенләйгә аерылышкан кебек буласың дип үзенчә юрый ул. Аның таныш-белешләре исәпсез-хисапсыз, дуслары да шактый, ә дошманнары, булса да, берничә генәдер. Алары да, шәхси мөнәсәбәтләрдән бигрәк, милләткә мөнәсәбәт белән бәйләнгән. Ул зур гөнаһ, иң зур җинаять дип үз милләтеңә хыянәт итүне саный. Андыйлар белән Туфан бернинди мөнәсәбәткә дә керми, ялгыш очрашканда да кул биреп исәнләшми.
Телефоннан сөйләшкәндә, ничек сәламләвенә карап кына да аның кем белән әңгәмә корганын аңлап була. Әгәр тыныч кына бер тапкыр «Исәнмесез!» дисә, димәк, ул гадәти танышы яисә бөтенләй белмәгән кеше белән сөйләшә дигән сүз. Әгәр инде йөзенә елмаю иңдереп, тавышына җылылык өстәп рәттән ике мәртәбә «Исәнмесез!» дип кабатласа, теге баштагы әңгәмәдәш якын кешесе яисә хөрмәт иткән мәртәбәле шәхес була. Ә инде тавышына яшьлек дәрте биреп, илаһи серлелек белән өч мәртәбә «Исәнмесез!»не тәкрарласа, димәк, ул нинди дер илаһи зат – хатын-кыз заты белән сөйләшә дигәнне аңлата.
Хәләл җефете Нәҗибә ханым белән Туфан мөнәсәбәте хакында аерым бер фәлсәфи трактат язарлык. Үзара аралашканда, әңгәмә корганда Туфан Нәҗибә ханымга карата шактый кырыс булып та күренергә мөмкин. Ә инде кемдер Нәҗибә апага катырак кагылып, аны кыерсыта башласа, Туфан кинәт кенә нәсел-нәсәбен саклаучы җәнлек-җанвар затына әверелә. Шуңа күрә дә Нәҗибә ханым һәрчак мәгърур, горур кыяфәтле, шуңа күрә дә ул җиргә аягын нык басып йөри, шуңа күрә дә ул сәхнә тутырып рәхәтләнеп иҗат итә.
Еш кына безгә Туфан белән төрле мәҗлесләрдә бергә булырга туры килә. Аны һәркем белә, һәр җирдә аны колач җәеп каршы алалар. Ул теләсә кайда теләсә кем белән уртак тел таба ала. Туфан һәр кешенең күңел түренә юл таба белә, чөнки ул аңа гади әңгәмәдәш дип кенә түгел, ә булачак, язылачак әсәренең фарази бер герое, үз туганы итеп карый сыман.
Шунысы гаҗәп, мәҗлес өстәле янына килеп утыруга, ул, уңга-сулга карамыйча, бар дөньясын онытып ашарга тотына. Шулай бераз тамак ялгап алгач, өстәлдән башын күтәреп, ярамас эш эшләгән малай сыман оялып кына, тирә-юньгә күз сала. Мәҗлес әле башланмаган, кунаклар утырышып та бетмәгән, ә Туфанның инде тамагы яртылаш туеп та өлгергән. Теләсә кайсы мәҗлеснең язылмаган кануннарын бозу булса да, мин аның бу гадәтен аңлап, эчтән генә үземчә аклап утырам. Чөнки Туфан буынының (шулай ук өлешчә безнең буынның да) тамак туйганчы ашарга зар-интизар булып, ачлы-туклы узган балачак һәм яшьлек елларын бик яхшы беләм. Ул елларда без, итагать саклауны онытып, алга куелган барлы-юклы ризыкны тизрәк ашап калырга,

ач корсакны тизрәк тутырырга тырыша идек. «Чир китә, гадәт кала», – дип юкка гына әйтмиләрдер инде халыкта.
Ашыгу гадәте тора-бара аның бөтен яшәү рәвешенә әверелгән кебек тоела миңа. Ул ашыгып ашый, ашыгып эшли, ашыгып иҗат итә, ашыгып яши. Балачактагы барлы-юклы саран ризык кебек, кеше гомеренең дә бик исәпле булуын, санаулы еллардан гына торуын яши-яши бик яхшы төшенгән Туфан. Төрле дәрәҗәдәге җыелышларда, хәтта Дәүләт Советы сессияләрендә дә, һич көтмәгәндә, залдан кинәт кенә кычкырып-кычкырып куюы да әйтәсе фикеренең нәкъ менә шушы мизгелдә кирәк булуын, вакыт кадерен, вакыт мәгънәсен аңлаудан, кыскасы, ашыгып яшәүдән киләдер, ахрысы.
Аның беренче карауга сәер булып тоелган бик күп гадәтләрен мин еллар үткән саен үземчә шәрехләп, үземчә аңларга тырыша идем. Финляндиягә Хельсинки каласына Конгресска баргач, бөтен юлдашлар кибетләрдән кием-салым, төрле сувенирлар эзләп йөргәндә, олпат язучы Туфан Миңнуллинның утын яра торган балта сатып алуын күреп, һәммәбез дә аптырашта калган идек. Ә киләсе сәяхәтебездә аның бөтен Берлин каласын бетереп чылбырлы кесә сәгате эзләве дә сәер тоелды безгә. Ныклап уйласаң, ул күпләр кебек бүгенге көн белән генә яшәми, ә шулай итеп балачакта эшли алмаган эшләрен бүген эшләргә, балачак өметләрен, балачак хыялларын бүген булса да тормышка ашырырга ашыга икән ләбаса.

## Депутат Туфан

Безнең җәмгыятьтә иң нык сүгелгән, иң күп каһәрләнгән кеше кем дисәгез, ул депутат булыр. Ни өчен шулай бу? Чөнки депутат – халык күзенә иң еш чалынучы зат. Аны көн саен диярлек телевизордан күрсәтеп торалар, аны сайлаучылар белән очрашуларга чакыралар, ул безнең тормышыбызны җайга салырга тиешле законнар кабул итә, халык аны «үзем сайладым, шуңа күрә аннан таләп итәргә хакым бар» дип уйлый. (Мәшһүр Тарас Бульба әйтмешли, «Үзем тудырдым, үзем үтерәм» була инде бу.) Ә президентлар, премьер-министрлар ерак, аларга буй җитәрлек, сүз үтәрлек түгел. Министрларны халык бары тик өстәгеләрнең әмерләрен үтәүче, кушканны эшләүче дип кенә кабул итә. Шуңа күрә кемгә буе җитә – шуңа кизәнә, кем аны тыңлый, сүзен шуңа сөйли инде халык, моның өчен үпкәләргә ярамый. Ә чынлыкта Рәсәй дигән илдә дәүләт белән халык сайлаган депутатлар түгел, ә президентлар, хөкүмәт идарә итә. Депутатлар закон чыгара, димәк, өстәл әзерләп, ашъяулык җәеп куя, ә өстәлгә ризыкны әлеге дә баягы президент һәм хөкүмәт әһелләре китерергә тиеш була. Ә халык табында булганы өчен хөкүмәткә рәхмәт әйтә, булмаганын әлеге дә баягы депутатлардан таптыра.
Туфан Миңнуллин заманында шәһәр Советына да, СССР Югары Советына да депутат булып сайланды, инде менә унбиш елдан артык Дәүләт Советы депутаты. Законнар кабул иткәндә, Дәүләт программалары хакында фикер алышканда, бигрәк тә авыл проблемалары, милли мәсьәләләр хакында сүз барганда битараф булган, үз фикерен кистереп әйтми калган чагы юктыр аның. Парламентта чыгыш ясыйсы булсам, мин үзем, гадәттә, алдан әзерләнеп, чыгышымның һичьюгы тезисларын язып куям. Ә ул сессия барган чакта сикереп тора да үзенә ошамаган законны берничә минутта сүтеп ташлый, үз фикерен, тәкъдимен тавышка куйдырта һәм еш кына яклаучыларын да таба. Мин: «Ничек болай законны кат-кат укымыйча, әзерләнмичә генә шулай нигезле, саллы чыгыш ясый аласың син?» – дигәч, ул чалара башлаган мыегы астыннан елмаеп кына куя. Үзе әйтмәсә дә, аңлыйм, ул бит мондый чыгышларга бер-ике көн эчендә генә түгел, инде гомере буе әзерләнгән; күңел сизгерлеге, язучы күрәзәлеге, депутатлык тәҗрибәсе аны теләсә кайсы вакытта халык мәнфәгатен якларлык дәрәҗәгә җиткергән.
Дәүләт Советында халык борчуы белән борчылучы, милләт кайгысын кайгыртучы иң фидакяр депутатларның берсе Туфан Миңнуллин икәнен барыбыз да күреп-белеп торабыз. Әмма иң күп тәнкыйть сүзе ишетүче, төрле югары органнарга өстеннән иң күп шикаятьләр языла депутат та шул ук Туфан Миңнуллин... Кызык бит: берәүләр еллар буе авыз ачып сүз әйтмичә, бер генә игелекле гамәл дә кылмыйча сессияләрдә оеп утыра, аларга сүз әйтүче юк, аларны тәнкыйть итүче дә күренми. Көне-төне милләт мәнфәгатен кайгыртып та, кемнәрдер синнән булмаган

гаепне эзләп, өстеңә бертуктаусыз пычрак атып торганда, тешне кысып түзү өчен зур түземлек һәм егетлек кирәктер. «Алмалы алмагачны гына шулай селкетәләр» дип, үз-үзеңне юатырга гына кала инде андый чакта.

Соңгы 15–20 ел эчендә депутат Туфан Миңнуллин тәкъдиме һәм тырышлыгы белән эшләнгән эшләрне саный китсәм, язмам бик озынга сузылыр. Шуларның берсен генә атыйм... 2002 елда, Республикабыз Конституциясенең яңа редакциясен әзерләгәндә, Туфан ага Төп Законга бер маддә өстәргә тәкъдим итте. Белгәнебезчә, татарларның күпчелеге Татарстаннан читтә яши. Россия төбәкләрендәге милләттәшләребезгә балаларын татар мәктәбендә укыту, туган телләрен, гореф-гадәтләрен саклау, кыскасы, чын милли тормыш белән яшәү елдан-ел кыенлаша бара. Туфан ага тәкъдим иткән әлеге маддә нәкъ менә шушы мәсьәләне хәл итәргә тиеш иде. Бик озак бәхәсләр һәм фикер алышулардан соң, ул, ниһаять, 14 нче маддә булып, Конституциябездә урын алды. Анда «Татарстан Республикасы Татарстаннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятләрен үстерүдә, туган телләрен һәм милли үзенчәлекләрен саклауда ярдәм итә» дип язылган иде. Дөньяга сибелгән татарны бер йодрыкка туплау, бердәм милләт итеп яшәтү һәм саклау өчен үтә дә кирәкле маддә иде бу. Соңрак «Россия хөкүмәте белән берлектә» дигән сүзләр өстәлеп, әлеге статья Татарстан һәм Россия арасындагы вәкаләтләр бүлешү хакындагы Шартнамәдә дә урын алды, һәм ул федераль закон белән расланды.

Еш кына «Язучының төп эше – иҗат, ул үз талантын депутатлык яисә башка җәмәгать эшләренә сарыф итмәскә тиеш» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Мондый кинаяләргә бөек Тукай инде моннан йөз ел элек бик ачык итеп җавап биргән. Чыннан да, әгәр бүген Татарстан парламентында Туфан Миңнуллин кебек милләтпәрвәр язучы-депутатларыбыз булмаса, туган телебезне, милли мәктәпләребезне, милли матбугатыбызны, милли мәдәниятебезне, динебезне яклап кем сүз әйтер иде икән?! Дөрес, эшләнәсе эшләр бихисап, әмма эшләнгәннәрен дә күреп, игелекле гамәл кылучыларга вакытында рәхмәтле була белү дә кирәк.

## Юлчы Туфан

Туфан Миңнуллинның беркайчан да самолётта очмавы, бары җир өстеннән йөри торган транспортта хәрәкәт итүе хакында бер тапкыр язган идем инде. Чыннан да, ул үзенең бөтен яшәү рәвеше белән Җир кешесе, аның язган әсәрләре дә Җир кешесе хакында, үзе дә бөтен килеш-килбәте белән коеп куйган авыл баласы.

Ел саен яз җитүгә, аның, Казандагы бөтен эшләрен ташлап, туган авылы Мәрәтхуҗага бәрәңге утыртырга кайтуын сөйләгәч, баштарак миңа ышанмаганнар иде. Мәскәүләрдә яшәп югары белем алган, инде ярты гасырдан артык Казан каласында гомер иткән мәшһүр драматург, депутат, илкүләм танылган шәхес үз куллары белән бәрәңге утыртып йөрсен, имеш. Нигә кирәк аңа бәрәңге? Теләсә, вагоны белән сатып алырга хәленнән килә, сораса, дуслары машинасы белән китереп аудара ала. Юк шул, Туфанга, тамыры җиргә береккән авыл малаена, үзе утырткан, үзе үстергән бәрәңге тәмлерәк. «Мин буш яткан җирне кызганам, җир дә безнең кебек эшләргә, уңыш китереп яшәргә тиеш», – ди ул... Инде ничә гасыр буе галимнәр кешенең маймылдан килеп чыгуын исбатларга тырыша. Кем ничектер, белмим, ә Туфан нәселе, Туфан кавеме, һичшиксез, җирдән, туфрактан яралган булырга тиеш.

Самолётта очмаса да, шактый ерак сәяхәтләргә чыгарга туры килде безгә аның белән. Иң беренче сәяхәтебез, атлы арбага утырып, Азнакайдан Кама Тамагына, дөресрәге, Мәрәтхуҗага кадәр кайту булды. Ракеталы, самолётлы, машиналы заманда тагын кемнәрнең ярты Татарстанны ат койрыгына карап гизгәне бардыр, белмим, әмма бу мәгънәле һәм маҗаралы сәяхәт язучы Марсель Галиев белән миңа гомер буе сөйләрлек истәлек булып калды.

Кайберәүләр юл йөрүне бушка узган вакытка саный, тизрәк барып яисә кайтып җитәм дә чынлап торып яши башлыйм дип уйлый. Ә Туфан өчен юл гизү дә тормыш, ул юлда да бушка вакыт уздырмый, киресенчә, сәяхәттә тагын да дәртләнебрәк яши башлый. Аның юл капчыгында яшәү өчен бөтен нәрсә дә була: барып җиткәнче юлдашлары белән бергә тукланырлык төрледән-төрле ризык, ипи кисәргә пычак-пәке, чәй эчәргә кружка, хәтта күкрәк кесәсенә сыя торган яссы

шешәсен дә онытмый. Ул һәр тукталышта, төшеп, тирә-юньне күзәтә, кешеләрдән нидер сораша. Поезд кузгалгач, купега кереп, өстәл янына утыра да куен дәфтәренә нидер теркәп куя. Ул юлда да ашкынып яши, юлда да дәртләнеп иҗат итә.
Берлинга килеп төшү белән, Туфан безне кибет карарга алып китте. «Ресторанда болай да әйбәт ашаталар, ашамлык кибетендә нәрсә алырга ниятли тагын?» – дисәм, аның нияте бөтенләй башкада икән. Ипинең бәясе күпме, ит-сөт-каймак кыйммәтме икәнне белешә Туфан, андагы бәяләрне безнеке белән чагыштыра. Аңа монда бөтен нәрсә яңа, бөтен нәрсә кызык. Ул таныш булмаган дөньяны балаларча кызыксынып күзәтә, аңа олыларча бәя бирә, язучы буларак һәр күргәнен күңеленә теркәп бара.
Австриянең Линц шәһәренә Бөтендөнья язучылар корылтаена баргач, ул безне шәһәр базарына ияртеп китте. Моңа кадәр дә аның «халык ничек яшәгәнне беләсең килсә, аның базарын кара» дип әйткәне бар иде. Бу юлы да бәя сорашып, чагыштырып кына йөрер, дип уйлый-уйлый барганда, моның күзе кабак сатучы рәткә төште. Соңгы елларда Туфан агайга «кабак җене» кагылганны белгәнгә күрә, минем моңа әллә ни исем китмәде. Әмма ым-ишарәләр белән аңлатырга тырыша-тырыша, татарча-русча-алманчаны бергә бутап сатучыдан кабак төше соравын ишеткәч, мин дә колакны шомрайттым. «Бакчамда әллә ничә төрле кабак үсә, ә мондые юк, – дип, сабыйларча еламсырап әйтеп куйды ул безгә. – Кабагы белән алсаң, күтәреп кайтуы авыр, ә бу немец төшен генә бирми». Билгеле, әлеге хикмәтле кабакны бөтенләе белән сатып алып, эчендәге орлыкларын гына да алып кайтырга мөмкин иде. Тик Туфан агай андыйлардан түгел, ризыкны, малны әрәм-шәрәм итү аның өчен гөнаһ санала. Ул, гомумән, акча саный белә торган кеше. Беренче һөнәре бухгалтер булгангамы, аның маңгай тире белән тапкан һәр тиене-сумы санаулы. Әмма кайчакларда, тугарылып китеп, чиктән тыш юмартланган чаклары да була Туфанның... Ә немец базарында, без барыбер үзебезнекен иттек, мең хәйлә белән теге кабак орлыгын юнәтеп, Казанга хәтле алып кайттык. Хәзер инде тизрәк көз җиткәнен, Австрия кабагының Туфан бакчасында уңыш биргәнен көтәбез.

## Төзүче Туфан

Заманында Туфанның туган авылы Мәрәтхуҗа «перспективасыз, ягъни киләчәксез авыллар» исәбенә кертелеп, фани дөнья белән хушлашу хәленә җиткән иде. Туган авылны ничек саклап калырга? Аның өчен нишләргә? Мин нәрсә эшли алам? Шундый уйлар белән гасабиланып йөргән Туфан авылга иң элек юл салырга кирәк дигән карарга килә. Мең мәшәкатьләр белән юл салынгач, мәчет-мәктәпкә дә чират җитә. Менә миннән үрнәк алыгыз дигәндәй, шыгырдап торган нараттан төп нигезләренә йорт та салып куя. Аннан күреп, булдыклырак авыл агайлары да каралты-кураларын яңарта башлыйлар. Шулай итеп, авылга әкренләп төс куна, җан керә.
Төзүчелек дәрте Туфанга шул көннәрдә иңгәндерме, белмим, үзем шаһит булган 30–40 ел дәверендә мин аның нәрсәдер кормыйча, нәрсәдер төземичә торган чагын хәтерләмим. Шушы чорда гына ул, эреле-ваклы дачаларын-йортларын бергә исәпләгәндә, үзенә биш тапкыр нигез корды. Берсен төзеп бетергәч, анысын кемгәдер тапшырып, икенчесенә тотынды. Тора-бара масштаблары зурая барып, туган районындагы атаклы Олы Салтык авылында хан сараедай мәктәп салдырды, аны җиһазлауны да өлешчә үз өстенә алды. Кама Тамагындагы район китапханәсе, музей һәм китап кибете урнашкан мәһабәт бина да аның тырышлыгы белән җиткерелде. Кәрим Тинчурин театрын ремонтлауда, Татар яшьләр театрына җылылык кертүдә, Язучылар берлеге бинасын төзекләндерүдә, Тәтеш татар гимназиясен торгызуда, Казандагы 12 нче кызлар гимназиясенә яңа бина коруда да турыдан-туры депутат һәм язучы Туфан Миңнуллинның катнашы бар. Ә бүген ул Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге татар театрларына яңа биналар төзү хәстәрен күреп йөри. Кемнәрдер борынгы һәйкәлләребезне, халкыбызның изге хатирәләрен, аның әхлак нигезләрен җимерү, таркату белән шөгыльләнгәндә, Туфан, алны-ялны белмичә, төзи дә төзи. Язучы белән төзүче һөнәренең бер-берсенә охшаш булуын ул инде бездән әллә кайчан алданрак аңлагандыр кебек.

Бу язмамда мин Туфан Миңнуллинның биниһая бай иҗат дөньясына кагылмаска, аның исәпсез-сансыз әсәрләре хакында сүз алып бармаска тырыштым. Чөнки аның иҗаты барыбызның да күз алдында, аның пьесалары барча татар театрларында гөрләп бара. Халкыбыз инде язучы, драматург Туфан Миңнуллинга күптән үзенең лаеклы бәясен бирде, «Туфан» исемен күңел түрендәге иң кадерле урынга салып куйды.
Бу юлы мин өлкән мәсләктәшем Туфан Миңнуллинның күземә чалынган кайбер гадәтләрен, яшәү рәвешен генә бераз тасвирлап, шәрехләп үтәргә, аның Гамәл дәфтәрен актарып карарга ният кылдым. Мәгънәле һәм бәрәкәтле гомеренең – язмыш юлының яртысыннан артыгына шаһит кеше буларак, аларны үзем күргәнчә, үзем аңлаганча укучыларга җиткерергә җөрьәт иттем. Ә аның иң тулы язмыш юлы, тәрҗемәи хәле – иҗат иткән әсәрләрендә. «Язу» белән «язмыш» сүзләре юкка гына бер тамырдан түгелдер инде.

*2010*

# ОЧАР ӨЧЕН ИКЕ КАНАТ КИРӘК

Татарстан Милли китапханәсендә эшләгән чакта, мин көн саен диярлек аны урамда очрата идем. Яшь чамабыз да, аралашкан даирәләребез дә шактый аерылганга күрә, без бер-беребезне шәхсән яхшы ук белмибез. Әмма күрешкән-очрашкан чакта, нишләптер күптәннән таныш кешеләр кебек сәлам бирешәбез. Олпат һәм мәһабәт буй-сыны, үз бәясен белеп кенә саллы-салмак атлап йөреше, сүзләрен үлчәп вәкарь белән генә сөйләшүе ирексездән аңа карата хөрмәт хисе уята иде. «Чын ир кеше, татарның зыялы заты шундый булырга тиештер», – дип уйлый идем мин ул чакта. Ә инде 1984 елда борынгы татар әдибе Кол Галигә багышланган саллы хезмәте дөнья күргәч, Нурмөхәммәт Хисамов исеме безнең ише каләм чарлаучылар һәм галим-голәмә арасында гына түгел, ә бөтен укымышлы татар дөньясында танылып өлгерде.

Мәктәптә борынгы татар әдәбиятын өстән-өстән генә укыткангамы, безнең өчен шигърияте безнең башы, нигездә, Тукайдан гына башлана кебек тоела иде. Әби-бабайлардан ишетеп белгән риваятьләрне санамаганда, мин үзем татар әдәбиятының, татар шигъриятенең мең еллар буена тупланып килгән байлыгы, аның бөек әдипләре белән Казан университетында укый башлагач кына таныштым дисәм, бигүк арттыру булмастыр кебек. Безне бу иксез-чиксез дәрьяга алып керүче илаһи зат – олуг галимебез Хатип Госман булды.

Нурмөхәммәт Хисамов иҗатын моңа кадәр төрле китапларда басылган лирик-фәлсәфи шигырьләре, төрле сәхнәләрдә яңгыраган җырлары аша тора-бара шактый ук яхшы белә башлаган булсам да, аның борынгы әдәбиятыбызга, Хатип Госманнан гайре моңа кадәр беркемнең дә «теше үтмәгән» яисә кыюлыгы җитмәгән өлкәгә алынуы бераз гаҗәпкә дә калдырды. Чөнки без инде соңгы елларда шагыйрьләрне бары тик Хәсән Туфан шикелле «Хода бәндәсе» итеп, ә галимнәрне социалистик реализм һәм марксизм-ленинизм тарафдарлары сыйфатында гына күрергә ияләшеп беткән идек. Кол Гали иҗатына багышланган хезмәте белән ул бөек Тукайның «мин коеп куйган шагыйрь генә түгел» дигән гыйбрәтле сүзләрен үз мисалында раслады кебек.

Галим Нурмөхәммәт Хисамовны башка күп кенә галимнәрдән аерып торган төп сыйфатларның берсе – аның шагыйрьлегендәдер. Чөнки олуг шагыйрь Кол Галине аңлау һәм аңлату өчен коры гыйльми аналитик акыл гына җитми, шагыйрь рухын, шагыйрь җанын аңлау өчен, һичшиксез, үзеңә дә шагыйрь рухлы булу кирәк. Шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов әсәрләрендә галимлек чалымнары булу, шагыйранә хис белән тәҗрибәле акылның гел янәшә торуы – шулай ук аның иҗатының үзенчәлеген тәшкил итәдер. Аның яшәешенең, аның шәхесенең, аның иҗатының бер канаты шигърият булса, икенчесе – фән, гыйльмияттер. Ә күккә – биеккә менү өчен кошларга ике канат кирәк.

*2010*

# ЯШӘҮНЕ ЗУРЛАУ

Әле дә хәтердә: 1966 елның май ае иде. ВЛКСМ Үзәк Комитеты үткәргән яшь шагыйрьләр фестивалендә җиңүчеләр Мәскәүдән Бөтенсоюз телевидениесе буенча чыгыш ясый. Инде үз республикаларында танылып, бөтен илгә аваз салырга җыенган төрле милләт шагыйрьләре. Менә озынча йөзле, киң маңгайлы егет телевизор экраннарыннан миллионнарча тамашачылар өчен татарча шигырьләр укый:

Чын җырларны җилфердәргә
Биеккәрәк, биеккәрәк эләргә иде!

Яңача, заманча шигырьләр, кешеләрне уйландыру белән бергә, шагыйрьнең олы ниятен, төп шигарен ачып сала торган шигырьләр иде алар. Поэзия сөючеләр бу көнне күпмилләтле совет поэзиясенә яңа шагыйрь килүен күрделәр. 23 яшьлек студент шагыйрь Равил Фәйзуллин шул көнне бу олы трибуна алдында шагыйрьлеккә зур бер имтихан тотты һәм җиңеп чыкты.

Ул көннәрдән соң дистәдән артык ел узды. Тукайлар гомере белән чагыштырып исәпләгәндә, аз вакыт түгел бу. Шул еллар эчендә Р. Фәйзуллинның башкарган эшләрен санап карасаң, гаҗәпкә каласың. Ул искиткеч дәрәҗәдә хәрәкәтчән, шагыйрьлек таланты өстенә эшли белү, хезмәт итә белү дигән зур сәләткә ия икән...

Университет, армия хезмәте, газета-журналларда эшләү, аспирантура, сигез ел буе Язучылар союзында җаваплы эшләр, 13 шигырьләр җыентыгы, 70 тән артык әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар, очрашулар...

Поэзиягә талантлар һәрчак килә тора. Ләкин талант мәңгелек двигатель түгел. Аны гомер буе карап, туйдырып, тәрбияләп торырга кирәк. Р. Фәйзуллин моны бик яхшы аңлый, ул илһам килүен көтеп ятмый шикелле. Ул үзе аңа каршы бара, шигырь аның өчен табигый талант бүләге генә түгел, ә көрәштә яулап алынган крепость.

Язсам гына – бәхетем тулы, бөтен.
Язу эше – намус, кан эше.
Язсам гына – илгә, кешеләргә
Файда итсәм генә мин – кеше!

Әйе, зур шагыйрь булу өчен табигый талантны һәрдаим маңгай тире белән сугарып тору кирәк. Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким иҗаты – шуның ачык мисалы. Р. Фәйзуллинның да эшләү стиле нәкъ шундый.

Күпләр хәтерлидер... Берничә ел элек җәйге челләнең бер эссе көнендә Төзүчеләр культура сараенда Р. Фәйзуллинның иҗат кичәсе булды. Мондый характердагы иҗади отчёт кичәләренең беренчесе иде бу. Катлаулы шагыйрь, тыңлаучылардан әзерлек таләп итә торган шигърият кичәсенә кеше килерме, халык аны яратып кабул итәрме, дип уйлаучылар да булмады түгел ул көнне. Ләкин чын шигърият монда да җиңеп чыкты... Залга сыймаган халык фойеда басып тыңлады. Бу – Равил Фәйзуллинның гына түгел, ә бүгенге поэзиянең, тулы бер буын шагыйрьләренең триумфы иде.

Соңрак мондый күркәм әдәби мәҗлесләр популярлашып китте, тора-бара традициягә әверелде.

Ни гаҗәптер, Р. Фәйзуллин эшләгән бер генә эш тә күренмичә үтеп китми, нинди дәрәҗәдә булса да, вакыйгага әйләнә. Беренче шигырьләре басылуга ук, ул игътибар үзәгенә килеп керде һәм бу бүгенге көнгә кадәр шулай булып кала бирә. Аның басылып чыккан һәр мәкаләсе һәм шигъри циклы, һәр китабы җитди сөйләшүләргә нигез булды, резонанс алды. Вакыт үткән саен, Р. Фәйзуллин иҗаты да «аңлаешлырак» була барды, аңа тәнкыйтьчеләр дә, поэзия сөючеләр дә ияләшеп өлгерделәр. Баксаң, шагыйрь нәкъ замандашы уйлаган нәрсәләрне уйлый, замандашы янган хисләр белән яна икән. Шигъри формасы, сүз агышы да чит-ят түгел, 60 нчы елларда шигърияткә килгән буын укучы белән шулай һәрдаим актив мөнәсәбәттә булды, ул үз укучысын үзе тәрбияләде, үзенә үзе трибуна әзерләде.

Һәм менә, ниһаять, Р. Фәйзуллинның «Шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгы басылып чыкты. Бу китапны кулга алуга, шагыйрьнең үз иҗатына, гомумән, шигърияткә булган мөгамәләсенә

битараф кала алмыйсың. Җыентык бик тә уйланып, җеген җеккә китереп төзелгән. Анда шагыйрьнең әйбәт дип саналган өч йөзләп шигыре тупланган. Полиграфик яктан да, бизәлеш ягыннан да ул күңелдә ихтирам уята, анда тупланган шигырьләрнең, поэзиянең кадерен арттыра. Тикмәгә генә бу китап Мәскәүдә халыкара китап ярминкәсендә югары бәя алмады.
Китапны укып чыккач, бүгенге татар поэзиясенең үсеш процессына шаһит буласың, аның киләчәген күзаллыйсың. Шагыйрьнең һәр әсәре замандашларының борчулары, уй-хыяллары белән аваздаш. Ул дөньядагы бернәрсәгә дә битараф түгел, аның күңеле эчкерсез, хисләре саф.

Вөҗданым белән сөйләшәм –
Шул минем шигъриятем, –

ди шагыйрь.
Андагы шигырьләрдә замандашыбызның каршылыклары, өзгәләнүләре, юанулары, күңел хатирәләре тупланган, җыентык бүгенге уйланучан, таләпчән кешенең фикер-хисләре антологиясе кебек.
Бу китап киләчәктә ныклабрак өйрәнелер, аның турында байтак язылыр әле. Ул зур сөйләшүләргә лаек.
Соңгы арада татар әдәбиятында прозаның алга чыгуы турында күп сөйлиләр. Чыннан да, безнең проза хәзер эзләнү юлында, үсеш юлында. Ләкин поэзия мондый үсеш-эзләнүләрне инде шактый алдан башлаган иде, һәм хәзер инде аның кулга тотып күрсәтерлек зур казанышлары бар. Бөтендөнья әдәбиятының иң асыл җәүһәрләре тупланган 200 томлыкка 17 татар шагыйре керү – безнең поэзиянең урыны турында ачык сөйли. Бу сериянең «Совет поэзиясе» томлыгы Равил Фәйзуллин шигырьләре белән тәмамлана. Шигырьләр туган тел турында, бүгенге яшьләрнең уй-хисләре, идеаллары турында. Шагыйрь «Әллүки»ләр, «Сарман»нар, «Гөлҗамал»лар, «Карурман»нар турында хисләнеп, горурланып сөйли, бөтен илләргә ишетелерлек итеп сөйли.
Шагыйрьләр космонавтларга охшаш. Алар да күккә көн саен күтәрелеп тормыйлар бит, бер менеп төшәләр дә «космонавт» исеме алалар. Ә аннары тагын күнегүләр, өйрәнүләр башлана. Бәлки, болары күккә менүгә караганда да авыррак, газаплырактыр? Ә без аларын күрмибез, без күбрәк күккә карарга өйрәнгән. Р. Фәйзуллинның «күнегүләр» вакытында уңышсызлыкка очраган, иҗат газаплары кичергән чаклары да күптер. Ләкин ул кул кушырып утыра алмый: ул әле мәктәп укучылары өчен шигъри дәреслекләр төзи («Тукайга чәчәкләр», «Юлдаш»); әле каләмдәшләре С. Хәким, Н. Арслан, Х. Туфан, Г. Афзал иҗаты турында мәкаләләр яза, әле хезмәт коллективлары алдында чыгышлар ясый... Менә шулай һәрдаим иҗат активлыгын саклау аны космонавт кебек формада тота, иҗатын күпкырлы итә, шигырьләргә эчке динамика бирә. Һәм, гомумән, үзенең шактый бай иҗаты, гражданлык активлыгы, җәмәгать эшләренең үзәгендә кайнавы, тынгысыз януы белән ул байтак яшь әдәбиятчыларга үрнәк булып тора.
Күренекле шагыйрь Мостай Кәрим әйтмешли, «Р. Фәйзуллин шигърияте бүгенге татар поэзиясендә генә түгел, ә гомумән әдәби хәрәкәттә үзе бер вакыйга ул».

*1978*

# ҖЫРДАН ҖЫРГА

Ялт итеп себерелгән ишегалды. Койма буена яңа гына турап өеп куелган утыннан урман исе аңкый. Әрдәнә янында күпме чөйләргә дә бирешмичә, ярылмыйча калган утын түмәре тора. Сары чәчле, озынча йөзле малай шул түмәр өстенә кунаклаган да гармун күреген тартыпмы-тарта гына. Бармаклар гармун какмалары буйлап бер аска төшәләр, бер өскә менәләр, аннары туктап калалар. Ләкин көй һаман чыкмый гына бит. Малайның күзләрендә үҗәт очкыннар ялтырап китә. Гармун күреген тагын да тырышыбрак тарта, какмаларга тагын да катырак баса башлый ул. Аптырагач, бәләкәй йодрыгы белән гармунына сугып та куя. Шул чагында әнисе болдырга чыга да:

– Рафаэль, улым, гармун уйнарга мунчада өйрәнәләр аны, – дип сүз ката.

Ә малайның мунчада түгел, менә шушы үзе кебек үҗәт утын түмәре өстенә утырып уйныйсы килә шул. Нигә аңа бакалы мунча? Монда ичмасам баш өстендә тургай сайрый, тәрәзә аша радио җырлаганы да ишетелеп тора. Шул тургай тавышларына, радиодагы көйләргә охшатып уйныйсы килә Рафаэльнең. Әнә Рафис абыйсы әллә ничә ай өйрәнде инде. Өйрәнер дә, гармун гел аның кулында булгач. Юкса Әнәс абыйлары Казаннан икесенә дә дип алып кайткан иде аны. Армиягә киткәндә, мин кайтканчы радиодан да остарак сиптерердәй булыгыз, дип кисәтеп китте. Үзең уйный белгәч, әйтүе ансат ул... Абзар тирәсендә нindидер көй көйләп йөрүче Әхәт абый кинәт тынып калды, малаеның гармун кычкыртуын тыңлап тора башлады. Бераздан аның авызы ерылып ук китте:

– Чыга бит, улым, чыга! – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды ул.

Ишегалды ягындагы тәрәзәдән Кәшифә апаның башы күренде:

– Нәрсә, әллә берәр көй чыгардымы?

– Көйнең дә нindие әле – «Умырзая».

Тәрәзә шапылдап ябылды һәм бер мизгелдән әниләре алар янында иде инде.

– Башы гына чыга шул... Азагы ничек әле аның, әнкәй? – дип сорады Рафаэль.

Кәшифә апа, утын өеменә таянып, әкрен генә җыр сузып җибәрде. Рафаэль аңа кушылды. Икенче куплетка җиткәч, Әхәт абый да түзмәде, авыз эченнән генә көйли башлады. Кич җитеп, тургайлар сайрап арыган вакытка, Рафаэль «Умырзая»ны хәйран гына сайрата иде инде.

Аннары җәй буе бер-бер артлы көй артыннан көйне отып, өйрәнеп кенә торды Рафаэль.

Көз җиткәч, аңа баян алып бирделәр. Шәңгәлче малайлары аһ итте инде моңа. Авылда озакламый: «Укытучы Әхәт малае гармунда өздерә генә икән», – дип тә сөйли башладылар. Икенче берәүләре, исе китмәгәнгә салышып: «Нигә уйнамасын, уйнар да, әнисе җыр укыта, менә дигән итеп җырлый, аталары – атаклы гармунчы», – дип кенә куйдылар. Классташлары арасында бу хәлгә баштарак көнләшүче дә, аптырауchы да булмады булуын. «Беткәнмени авылда баянчылар», янәсе. Тик җыр дәресләрендә «укытучы Әхәт малае» баянда үзе уйнап, үзе җырлый башлагач кына күпләр бөрекне кыңгыр якка шудырып куйды. Хәзер инде: «Карале, шулкадәр әнисенә охшаса охшар икән, өздерә генә бит, кәтүк», – дип сөйлиләр иде. Әйтерең дә бар шул, клубта концерт булса, башлап йөрүчеләр кем? – Сәхәбиевлар. Яңа чыккан җырны иң алдан отып алучы кем? – Һаман әлеге дә баягы Сәхәбиевлар.

Ял көне җиттеме, радио янына тезелеп утыралар да гаилә хоры оештыралар. Көйнең һәр бормасын, һәр аһәңен җиренә җиткереп кабатлыйлар. Авылда радио берничә өйдә генә булганга, концерт тыңларга күрше-күләннәр дә керә. Урындыкларга тезелешеп утырган, ишек тупсасына чүгәләгән агайлар тын да алмый җыр тыңлыйлар. Берсе: «Гөлсем Сөләйманова менә бу төшен болайрак суза бит», – дип көйләп тә күрсәтә. Икенчесе: «Кәшифә, болай булса, малаең үзеңнән уздыра», – дип елмаеп куя. Сигезне тәмамлагач, Рафаэль Түбән Камага китәргә була. Урман өстеннән күтәрелеп торган галәмәт биек завод торбалары, шәһәрнең ялт итеп торган йортлары күптән үзенә тартып тора инде аны. Аппаратчы һөнәре үзләштерергә карар кылган Рафаэль, биштәр асып, калага китеп бара. Билгеле, ак йортлар һәм биек торбалар гына кызыктырмый малайны. 1 нче мәктәпнең атаклы татар хорын тыңлаганы, Химиклар сараендагы үзешчән

җырчылар түгәрәге турында да ишеткәне бар аның. Шуның өстенә анда музыка училищесы да ачылган икән...

ГПТУ-44 тә укый башлагач, еш кына «Сәйдәш училищесы» тирәсенә килеп чыккалый ул. Ләкин эчкә кереп карарга кыймый. «Минемише авыл атказанганнары беткәнмени?» – дип, килгән саен борылып китә. Ә үзләренең ГПТУларында хор оештырылуны ишеткәч, иң беренчеләрдән булып язылa.

Чын сәнгатьнең никадәр зур, никадәр катлаулы икәнен беренче кат шушы хорда төшенә ул. «Музыкаль грамота», «сольфеджио» сүзләрен дә тәүге кат монда ишетә, берничә тавышка җырлау күнекмәләрен дә иң элек монда ала Рафаэль. Авылда русчаны ипи-тозлыктан артык сукаламаган малай өчен ГПТУда укуның файдасы зур була. Озакламый, ул татар көйләре белән беррәттән рус җырларын да өйрәнә башлый.

Көннәрдән бер көнне мондый хәл була. Гадәттәгечә, хор җыелып беткәч, җитәкче алга чыгып баса да дирижёрлык итәргә тотына. «Туган җирем Татарстан»ны башкара алар бу көнне. Ләкин, ни хикмәт, хор җитәкчесе, кулын аз гына селкеп тора да туктап кала, аннары, бер куплет җырлагач, тагын тына. Бөтенесе аптырый бу хәлгә. Җитәкчесе берзаман бөтенләй туктый да, хорның бер башына карап, сүз ката:

– Менә бу төштә бик яхшы бер тавыш бар. Әйтегез, кем тавышы ул? – ди.

Егетләр, бер-берсенә карашып, аптырап калалар. Ләкин җавап бирүче булмый. Бераздан өзелгән җыр яңадан ялганып китә. Бу сәер хәл тиздән онытыла. Җыр артыннан җыр кабатлыйлар, киләсе концерт турында сөйләшәләр. Тик эшне бетереп таралышкан чакта гына теге хикмәтнең сере ачыла. Ишектән чыгып барганда, җитәкче, соңгы сүз итеп:

– Сәхәбиев, син беразга калып тор әле, – дип серле генә әйтеп куя.

Шул көннән башлап, Рафаэль хорның алыштыргысыз солистына әверелә. Химиклар сараендагы концертларда да катнаша, училище хорында да җырлый, район радиосы тапшыруларына да язылa ул. Хәзер инде аны Түбән Камада «җырчы егет» дип йөртә башлыйлар. Ләкин училище бетереп, аппаратчы булып эшкә урнашкач та, «Сәйдәш йорты»на барырга кыймый әле ул. Тик әлеге бәхетле очрак бу юлы да сагалап тора аны. Көннәрдән бер көнне, концерт тәмамлангач, Рафаэль янына музыка училищесы директоры Лемар Жураев килә.

– Бик матур җырладыгыз, котлыйм сезне! – ди ул аңа. Аннары, училищега укырга чакырып, китеп бара.

Менә имтиханнар да, укуның беренче айлары да артта калды, Рафаэльнең репертуары да көннән-көн байый бара, осталыгы да үсә. Музыка училищесы авыл малае өчен ачылмаган яңа бер дөнья иде. Кыен көннәр дә күп булды, билгеле. Чөнки музыка мәктәбен тәмамлап килгән, өйдә музыкаль белем алган студентлардан калышмаска кирәк иде аңа. Шуңа күрә Рафаэль укуга бөтен сәләтен, бөтен тырышлыгын, бөтен үҗәтлеген җигә.

Татарстанның илле еллык бәйрәме җитеп килә иде. Көннәрдән бер көнне училищеда Казанга, үзешчәннәрнең республика смотрына бер җырчы җибәрәләр икән дигән хәбәр таралды. Китте ыгы-зыгы, китте имеш-мимеш... Югары курслар бөтенләй чыгырдан чыкты. Ләкин көне җитеп, смотрга 1 нче курс студенты Рафаэль Сәхәбиев баруы игълан ителгәч, барысы да, дөрес эшләгәннәр дигәндәй, тынып калды. Чөнки бу вакытта училищеда үзен танытып өлгергән иде инде Рафаэль.

Килде Рафаэль Казанга, урнашты кунакханәгә. Бары да яхшы, бары да әйбәт, шатланасы гына да бит югыйсә. Ләкин күңеле һаман тыныч түгел аның. Опера-балет театры янына әллә ничә барып килде инде. Кешеләрдән сораштырмый гына консерваторияне дә тапты. Озак басып торды сихри бина янында. Тәрәзәләрдән музыка авазы агыла. Йортның эчендә музыка чишмәсе бар кебек тоелды аңа. Монда кергән һәр кеше шул чишмәдән авыз итәр дә тылсым көче белән сәнгать остасына әверелер сыман.

Сәхнәгә чыгып баскач, тез буыннары калтыраса да, тавышы калтырамады Рафаэльнең. «Ай, кызлар»ны бераз авылчарак һәм егетләрчә дәртле итеп җырлады. Зал гөрләтеп кул чапты. Телевизор караучылар, менә тагын бер җырчы үсеп килә дип, сөенеп, сокланып утырдылар.

Түбән Камага җиңүче булып, дәртләнеп, канатланып кайтса да, күңеле мәңгегә Казанда, Ирек мәйданы янындагы опера театрында, консерваториядә калды аның. Дәрестә утырганда да, концертларда җырлаганда да уйлары гел шул тирәдә бөтерелде. Ләкин укучысы күңелен аңламаган укытучы була димени?! Лемар Жураев егетнең хыялларын бу юлы да күптән сизеп йөргән икән. Беркөнне коридорда туктатты да: «Сәхәбиев, консерваториягә барып карасаң, ничек булыр икән?» – дип сорап куйды. Шатлыктан канатланган Рафаэль берни дә әйтә алмыйча телсез калды.

«Адәм баласы булдыра алмаслык эш юк», – ди торган иде бит әтисе. Каушый-каушый гариза язганда да, аудитория түренә басып, могтәбәр комиссия каршында җырлаганда да күңелдә һәрчак шул сүз торды. Өч турны да үтеп чыкты Рафаэль, әмма монда Түбән Камадагы кебек күтәреп мактаучы да, аһ итүче дә булмады. Шуңа күрә язмышы хәл ителәсе көнне артык дулкынланмый да иде инде ул. Нишлисең, яңадан училищега кайтып китәргә туры килер, ахрысы. Ашыкмый гына хәзерлек группасына алынучылар исемлеге янына килде. Юк, аның исеме юк. Зур күзләргә бер мизгелдә моңсулык керде, куллар салынып төште. Яңа танышлары белән теләр-теләмәс кенә саубуллашып, таралышырга торганда, аларны профессор Бәйрашова туктатты.

– Нигә бер дә шатланмыйсыз, Сәхәбиев, сезне төп группага, 1 нче курска алдык бит, – диде ул. – Комиссия тавышыгызны бик ошатты...

«Ай, кызлар»ны җырлаганда ук хәтергә салып куйганнар икән аны. Озакламый радиога язылырга, телевизион тапшыруларда катнашырга чакыра башладылар. Күбрәк чыгыш ясыйсы, тизрәк «танылासы» килсә дә, шактый вакыт концертларны читләбрәк йөрергә туры килде әле. Чөнки Рафаэльнең җитәкчесе Михаил Кольцов «иртә танылып китүнең» зыяны турында бик яхшы белә. Тиешле осталыкны үзләштермичә, тавышы ныгып җитмичә, сәхнәгә менгән яшьләрнең иҗат юлы күп вакытта кыска гомерле була бит.

Вакыт үткән саен, яшь җырчының үз-үзенә ышанычы арта бара. Хәзер инде ул зур партияләрдән дә куркып калмый. «Сарман»нарны җырлап үскән авыл малае өчен Бизе, Чайковский операларына тотыну бик җиңел булмый, билгеле. Ләкин әлеге дә баягы үҗәтлек, тырышлык һәрчак ярдәмгә килә аңа. Композиторлар Рафаэльнең саф татар дикциясенә дә игътибар итәләр. Татар җырчысы өчен бик мөһим нәрсә бу. Юкса рус мәктәбендә укыган кайбер җырчылар, күпме генә тырышсалар да, телнең бөтен матурлыгын, моңын, яңгырашын биреп бетерә алмыйлар. Һәр телнең үз байлыгы белән бергә үз музыкасы, үз аһәңе дә бар бит әле. Рөстәм Яхинның «Күңелемдә яз», «Син кал, иркәм, бездә», «Җырланмаган әле безнең җыр», Мансур Мозаффаровның «Саумы, Кояш» романсларын нәкъ менә шул чын татар моңы белән башкара ул. Композитор Фасил Әхмәтов белән иҗади дуслык аңа музыканы тагын да тирәнрәк төшенергә, башкару осталыгын үстерергә ярдәм итә.

Җырчыларның шагыйрьләр белән аралашып, дуслашып яшәве бер дә гаҗәп хәл түгел. Киресенчә, бу нәрсә җырчыны да, шагыйрьне дә баета гына төшә. Аннары җырчы шагыйрь белән композитор арасында күпер ролен дә үти бит әле. Илһам Шакиров тәкъдиме белән язылып, бөтен халыкка таралып киткән җырларны кемнәр генә белми?! Рафаэль Сәхәбиев та язучылар белән һәрчак очрашып, аралашып, киңәшләшеп яши.

Көннәрдән бер көнне Язучылар союзының пропаганда бюросы аны шагыйрьләр белән авылга чыгарга чакыра. Уттай урак өстендә колхозчылар белән очрашып, аларның күңеленә дәрт, талган беләкләренә куәт өстәргә кем каршы килә инде?!

Юлга чыгарга вакыт җиткәч кенә, баянчының авырып киткәнен беләләр. Нишләргә? Авылларга хәбәр ителгән, халык көтә. Шулвакыт Рафаэль: «Әйдәгез киттек, баянда да уйнармын, үзем җырып чыгармын», – ди. Һәм чыннан да сынатмый.

Күптән түгел генә консерваториянең 5 нче курс студенты Рафаэль Сәхәбиев Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрына солист-стажёр итеп кабул ителде. Дүрт ел буена дистәләгән арияләр, җырлар өйрәнеп, сольфеджио дәресләренә йөреп, музыка серләренә шактый төшенгән булса да, татар сәнгатенең Фәхри Насретдинов, Азат Аббасов, Мөнирә Булатова кебек осталары белән бергә эшләү яшь җырчыга бик күп нәрсә бирә.

Ялт итеп себерелгән ишегалды. Койма буена яңа турап, өеп куелган утыннан урман исе аңкый. Әрдәнә янында күпме чөйләргә дә бирешмичә, ярылмыйча калган утын түмәре тора. Саргылт чәчле, озынча йөзле егет шул түмәр өстенә утырган да ниндидер бер көй суза. Ләкин җыры бирешергә теләми. Егетнең күзләрендә үҗәт очкыннар ялтырап китә. Аның саен тырышыбрак җырлый ул. Әнисе, болдырга чыгып:

– Рафаэль улым, ташла, мондый катлаулы арияләрне консерваториядә генә өйрәнәләр, – дип сүз ката. – Каникулга кайткансың икән, бер рәхәтләнеп ял ит...

Ә егетнең театрда гына түгел, менә шушы үҗәт утын түмәре өстенә дә утырып җырлыйсы килә. Аны гармун уйнарга өйрәткән урын бит бу. Баш очындагы тургай авазлары, бакчадагы көнбагыш чәчәкләре, инеш буендагы чирәм исләре, чишмә челтерәүләре җырларына да сеңсен иде аның. Бәлки, көннәрдән бер көнне бүген аңа сәерсенеп карап торган авыл агайлары Чайковскийның менә шушы «Евгений Онегин» операсын сокланып тыңларлар әле. Чөнки аны Онегин партиясен үз авылларында үсеп, Зәй буе моңнарын күңеленә җыйган егет – Рафаэль Сәхәбиев башкарачак бит. Ә ул көн ерак түгел инде.

*1975*

# ЯШӘҮ ХИСЕ

Әле сабый чагымда безнең авылга Рәшит Ваһапов, Мөхтәр Әхмәдиев, Оркыя Ибраһимовалар концерт куярга килде. Мөхтәр абый бездә кунды. Аның төн буе ак баянында уйнавын күргәч, мин баянга гомерлеккә гашыйк булып калдым. Шушы бәләкәй вакыттан ук гармун, баян уйнарга өйрәнергә тырышсам да, артык булдыра алмадым. Баян уйнарга өйрәнә алмавым бүгенге көндә тормышка ашмаган иң зур хыялларымның берсе булып кала. Безнең Түбән Кама районы Ташлык авылында музыкантлар байтак һәм гармун-баян культы бик көчле иде. Һәр өйдә диярлек уйный белүче кеше бар. Кичен клубка чыгып ярыша-ярыша уйныйлар. Шул чагында мин аларның үзара сөйләшүләренә колак салам. Алар, татарның иң оста баянчысы буларак, Рифкать Гомәровны телгә алалар. Шул рәвешле мин аларның Рифкатьне авылдашларым авызыннан һәм радио аша ишетеп белә идем. Радиодан, «Рифкать Гомәров уйный» дисәләр, мин һәрвакыт шаккатып, онытылып тыңладым. Әле дә шулай.

Соңрак Мәскәүдә Әдәбият институтында укып йөргәндә, өлешемә зур бәхет тиде: П. Чайковский исемендәге Концерт залына Илһам Шакиров чыгышын тыңларга бардым. Ул чак Илһам ага инде күңелләрдә, ә Рифкатьне башлыча радиодан ишетеп кенә белә идек. Илһам ага белән янәшә баян күтәреп Рифкать Гомәров чыгып баскач, минем өчен бу икеләтә бәхет булды. Без аның белән әнә шунда танышып китеп, көн саен булмаса да, гомер буе аралашып яшәдек. Уртак зур эш тә кырмадык, артык кәеф-сафа корып йөрүләр дә булмады. Безнең аралашу гел иҗат белән бәйле иде. Миңа аеруча ошаган бер нәрсә шул: Рифкать В. Куйбышев клубына үзенең репетицияләренә чакыргалады. Мин «Саз»ның концертларын да тыңладым, зур залларда, хәтта чит илләрдә дә. Ләкин репетициядә катнашу, көе аерым, сүзе аерым булган чи материалдан хор җитәкчесенең җырны дөньяга китерүе, җыр дигән могҗиза яралуны карап тору күпкә кызыклырак иде. Мин моның өчен Рифкатькә бик рәхмәтле. Коллективны җыеп, әнә шулай итеп бер генә кешенең дә мине җыр иҗаты кухнясына керткәне булмады.

«Саз» белән якыннан танышкан шул елларда Рифкатькә багышланган эпиграмма иҗат ителде. (Бу эпиграмма Рифкатьнең шаржы белән 1977 елда «Идел» альманахында дөнья күргән иде.)

Яратмаган җырларны да
«Саз» моңы яраттыра.
«Саз»га оркестр кирәкми,
Баян да ярап тора:
Рифкать уйный, кызлар җырлый,
Егет-җилән дә тик тормый –
Шаккатып карап тора.

Җыр дөньясына беренче мине Илһам Шакиров алып керде дип әйтергә мөмкин, чөнки тәүге җырымны ул яздырды. Иҗатыма зур йогынты ясады. Ә инде җыр нечкәлекләрен миндә Рифкать ныгытты дисәм, ялгыш булмас. Аның белән аралаша башлагач, җыр дигән нәрсәне тагын да тирәнрәк төшендем кебек.

Рифкать беркайчан да зарланмады. Билгеле ки, ул авырлыклар күреп, ятим үскән. Ләкин һәрвакыт тормыш кыенлыкларын мәзәккә әверелдереп, үз күңелен үзе юатып һәм безне дә дәртләндереп яшәде. Композитор Заһид ага Хәбибуллинның бер мәзәген матур һәм тәмле итеп сөйләргә ярата иде ул. Аны мин әүвәл Рифкать авызыннан ишеттем. Балалар белән очрашуга баргач, беркатлы, нарасый күңелле Заһид ага сөйли икән: «Менә, балалар, мин бик авырлык белән үстем, без бик каты авыр заманда яшәдек, чабата кидек, ашарга ризык, кияргә кием булмады. Мин шулай үстем. Рәхмәт Советлар Союзына!

Без сугыш кичердек. Безнең ил немесләр белән сугышты. Илнең егерме миллионнан артык кешесе кырылды. Безнең буын ятим үсте. Күрмәгәнебез калмады. Рәхмәт Советлар Союзына, рәхмәт Советлар Союзына!»

Рифкатьнең шул мәзәкне сөйләве үзенең сагышлы бала чагына күз яше аша елмаюы, авыр яшьлеге белән үзенчә саубуллашуы булган икән. Ул дөньяга һәрвакыт якты күз белән карый иде. Һәрбер читен хәлдән юморга төренеп чыга белү аның хисенә, канына салынган булган, күрәсең.
Минем кабатларга ярата торган бер фикерем бар: дөньяда өч төрдәге кешеләр була. Берәүләрне күргәч, битараф каласың, аның белән бер күрешкәч, башкача очрашмау юлын эзлисең. Икенчеләрен күргәч, үләсе килә башлый, чөнки алар гел елый, сытык була, зарлана, теге җитми, бу җитми. Андыйлар белән очрашуга да күңел тартмый. Ә өченче төр кешеләр – иң яраткан кешеләрем. Аларны күргәч, сөйләшәсе килә. Рифкатьне очраткач та яшисе килә башлый иде. Күңелеңә авыр чакларда үзеннән-үзе аңа тартыласың. Дөньяның тоткасы – әнә шул кешеләр. Болар – әйләнә-тирәдәгеләргә яшәү хисе, яшәү теләге иңдерә белүчеләр. Әле бит ул бер кешегә генә түгел. Сиңа күчкән дәрт, энергия әллә нихәтле дустыңны йә танышыңны үсендереп, канатландырып җибәрергә җитә! Рифкать яшәү дәртен Ходайдан мул итеп алган затлы-зыялы егет иде. «Иде» дип әйтәсе дә килми, чөнки аны җирләгәндә катнаша алмадым – читтә идем. Миңа ул әле дә тере, исәндер сыман, һаман да эшләп йөридер шикелле.
...Киткәненә дә биш ел. Аның юклыгы үзен нык сиздерә. «Тасма» тукталышы тирәсеннән үткәндә, Рифкать искә төшеп, күңел чымырдап куя. Радио тыңласаң, телевизор карасаң да шулай. Бүгенге көндә «Саз» ансамбленең Рифкать эшен, традициясен дәвам итүен теләр идем. Яшәсен иде «Саз». Бу аны хөрмәтләүнең чагылышы булыр иде. Килер заман, Рифкатьне әле тагын да искә алырлар. Әле бик үк төшенеп бетермәсәк тә, еллар узган саен, аның кадере артачак кына! Хәзер дә аның хакында китаплар чыгарырга, төрле тапшырулар эшләргә, туган авылындагы музейны киңәйтеп үстерергә кирәк.
Рифкать бик милли җанлы һәм, һәрбер талантлы шәхес кебек, үзен саклый белми торган, кызганмый торган зат иде. Әгәр ул үзен өф-өф итеп кенә йөртсә, шул кыска арада, бәлки, зур уңышларга да ирешә алмас иде. Ничек кенә булмасын, ул татар моңының нәрсә икәнен чын мәгънәсендә аңлаган, аны халыкка җиткерүнең серләрен белгән сирәк кешеләрнең берсе һәм соңгы егерме-утыз елда милли музыка сәнгатебездәге төп фигураларның берсе булып кала бирә.

*2001*

# НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ

Балалар әдәбияты турында сүз башлауга, иң элек бер сорау туа: нәрсә соң ул балалар әдәбияты, бу әдәбиятка нинди әсәрләр керә? Әлеге сорау безнең татар әдәбиятына гына кагылмый, ул турыда русларда да, чит илләрдә дә бәхәсләр бара. Күп кенә бәхәсләрдә: «Балалар әдәбияты ул – талантлы әсәрләр, һәр талантлы язылган әсәрне балалар яратып укый», – дигән фикер алга сөрелә. Бу сүзләрдә өлешчә хаклык бар, билгеле. А. Пушкинның «Евгений Онегин», Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык», М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» әсәрләре балаларга атап язылмаган бит. Ә шулай да бу әсәрләрне балалар да йотылып укый, китапханәче бирмәсә, урлый-урлый, кача-кача укыйлар. Ләкин әле бу факт – качып уку факты гына «һәр талантлы әсәр балалар өчен» дип әйтергә нигез бирми. Ни әйтсәң дә, әдәбиятның алтын фондына кергән әлеге әсәрләр балалар әдәбияты түгел. Аларның балалар арасында да шундый популяр булуының үз сәбәпләре бар. Беренчедән, бала кеше һәрчак олы булырга, олыларга охшарга тырыша, алар кыланганны кылана, алар эшләгәнне эшли. Икенчедән, монысы инде төп сәбәптер, әлеге классик әдәбият үрнәкләренең, чыннан да, балалар әдәбияты үрнәкләреннән камилрәк һәм талантлырак иҗат ителүендә.

Дөрес, балаларның зурлар өчен язылган әдәбият үрнәкләрен укуына килгәндә, бик талымлы һәм аерата сак булырга кирәк. Бакчага яисә беренче елларда мәктәпкә җитәкләп алып барган кебек, без балаларны олы әдәбиятка да җитәкләп алып керергә, аларга юл күрсәтергә, юнәлеш бирергә тиеш. Юкса әле дөньяга үз карашы формалашмаган баланы әдәбият карурманына ялгызын гына кертеп җибәрсәң, ул анда югалып, адашып калырга мөмкин. Һәр сүзгә, һәр вакыйгага баланың реакциясе искиткеч көчле, әгәр дә бу реакциягә үз вакытында дөрес юнәлеш бирелмәсә, гомер буена төзәтелмәслек хата җибәрелергә мөмкин. Лев Толстой юкка гына, яши башлавымның беренче биш елында мин калган бөтен гомерем буена алган тәэсирләргә караганда күбрәк тәэсир алдым, дип әйтмәгәндер. Һәрберебезнең дә самолётта очкан малай күргәне бардыр. Малай кеше иллюминаторга капланган да шаккатып-гаҗәпләнеп җирне күзәтә. Аңа йортлар шырпы кабы булып күренә, кешеләр кырмыска төсле, басу-кырлар төрле төстәге ашъяулыкка охшаган. Малай әле тегене, әле моны сорый; аңа бары да яңа, бары да кызык...

Классик әдәбият үрнәкләрен укучы бала нәкъ менә шушы самолётта очучы малайга охшаган. Аңа һәрнәрсәне аңлатып, төшендереп бирергә кирәк. Ә бу малайның өендә үз дөньясы: үз уенчыклары, агач аты, үзенең яраткан песие, үзенең дуслары бар. Боларга инде ул үзе хуҗа. Балалар әдәбияты да менә шулай – баланың үз уйларын, үз хисләрен, аның әле яңа формалашып килүче карашын, кыскасы, баланың матди һәм рухи дөньясын чагылдырырга тиеш. Мондый әдәбият баланы зур тормышка әзерли: аны яшәргә, яратырга, нәфрәтләнергә, шатланырга, үз Ватаны белән горурланырга өйрәтә.

Балалар өчен иҗат итүче язучыларыбыздан күбесенең үз бала чаклары сугыш чорына һәм шуннан соңгы елларга туры килгәнгәдерме, Бөек Ватан сугышы тематикасы узган елгы балалар әдәбиятыбызда да зур урын алган. Алардан аеруча игътибарга лаеклылары дип А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестьларын һәм Ш. Рәкыйповның «Кипарислар җыры» исемле документаль повестен санарга була.

Аяз Гыйләҗев һәрвакыт диярлек үзенең әсәрләрендә тормышның әле моңа кадәр ачылмаган ягын күрсәтергә омтыла. Күңелне иң нык борчыган, бимазалаган проблемаларны күтәрә. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» җыентыгындагы өч әсәр дә шундый максат кыйбласына каратып иҗат ителгән. Миңа калса, повестьлар арасында иң уңышлысы, иң камиле – «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят». Автор монда Ватан сугышы чоры авылын бөтенләй яңа яктан күрсәтә, бик тә колоритлы типлар, персонажлар аша шул чор драматизмын, шул чорның ачы романтикасын тасвирлый. А. Гыйләҗев әсәренең иң отышлы сыйфаты – аның тулысы белән гуманлык нигезендә корылуы. Язучы ач-ялангач, хәерче, шыксыз тормышны сурәтләп килә-килә дә, Искәндәр белән Арзуны күрсәтеп, бөтен тирә-юньгә сафлык, җылылык иңдереп куя. Ул һәр

урында этлек эшләргә әзер торган Сирай күңеленнән дә яхшылык эзли һәм таба. Язучы үзе белгән, үзе күргән нәрсәләр турында бик тәфсилләп сөйләсә дә, үзе шаһит булмаган хәлләрне йөгертеп кенә уза – фронт күренешләрен схематик рәвештә генә тасвирлый. Бу исә әсәрдә үз-үзен аклый, әдәбиятның тормышчан булуы турындагы таләпләргә турыдан-туры җавап бирә.
Ш. Рәкыйпов – соңгы елларда хәрби-патриотик тематика өлкәсендә иң күп эшләгән язучыларыбызның берсе. Күптән түгел без аның «Кызлар-йолдызлар» повестен укыган идек. Инде хәзер шуның дәвамы – «Кипарислар җыры» повесте басылып чыкты.
Бу әсәрдә автор, А. Гыйләҗевтән аермалы буларак, үзе күрмәгән, үзе шаһит булмаган нәрсәләр турында яза. Ләкин Ш. Рәкыйпов уңышлы алым тапкан – ул вакыйгалар турында үзе сөйләми, геройның үзеннән, Советлар Союзы Герое, легендар очучы Мәгубә Сыртлановадан сөйләтә. Әсәр совет халкының батырлык елъязмасы булу ягыннан да, конкрет мисаллар ярдәмендә яшь буынга тәрбия бирү ягыннан да искиткеч зур әһәмияткә ия. Автор очучы кызларның сугыш кырындагы халәтен гаять табигый һәм истә кала торган итеп тасвирлый. Коточкыч мәхшәр, атыш-үтереш уртасында гүзәллек, яхшылык символы булган шул кызларны күргәч, сугышның ил өчен, җир өчен, кешелек өчен никадәр кирәксез, ят нәрсә икәненә тагын бер кат ачынып инанасың.
Язучы Рафаэль Мостафинны без моңа кадәр әдәбият белгече һәм М. Җәлил иҗатын өйрәнүче галим буларак белә идек. Яңа китабында да автор үз өлкәсеннән читкә тайпылмаган. «Кечкенә Муса турында хикәяләр» герой-шагыйребез турындагы әдәбиятны тагын да тулыландырды, баетты. Юкса моңа кадәр күбрәк шагыйрьнең Моабит чоры гына игътибар үзәгенә куела иде. Р. Мостафин Мусаның кечкенәдән үк батырлыкка әзерләнеп үсүен, Бөек Октябрь революциясе утында чыныгу алуын бик гади һәм балаларга аңлаешлы итеп тасвирлый. Әсәр кечкенә хикәяләрдән тора, һәр хикәянең үзәгенә шагыйрьнең малай чагындагы бер гыйбрәтле вакыйга алынган. Автор бу вакыйгалардан герой-шагыйрь киләчәктә күрсәтәсе сыйфатларның яралгысын эзли, таба һәм аны бик үтемле итеп укучыга да ирештерә.
Ләкин кайбер очракта язучы, онытылып китеп, матур гына барган парчаның ахырына дидактик нәтиҗә китереп ялгый, авторның әдәбият белгече булуы калкып чыга. Мәсәлән, «Сугыш» дигән парчада җанлы вакыйгалар турында образлы тел һәм сурәтләр белән сөйләп килә дә азактан, һич кирәкмәгәндә: «Җырның, шигъриятнең халык күңелендә нинди зур урын алып торуын, аларның нинди көчкә ия булганын Муса шул чакта аңлый», – дип, бик акыллы итеп очлап куя. Уйлап карасаң, бу җөмлә хикәягә бернинди яңалык өстәми. Автор укучыга үз фикерен чәйнәп каптырырга тырышып, аны яңалык ачу, үзе шул фикергә килү мөмкинлегеннән, ачыш шатлыгыннан мәхрүм итә.
Ф. Шәфигуллинның «Әлфинур» исемле повесте (китап та «Әлфинур» дип исемләнгән) бик кирәкле, бик үтемле темага – производство темасына язылган булса да, кызганычка каршы, әдәбиятка яңалык алып килми, бүгенге яшьләр тормышын, аларны борчыган проблемаларны тулысынча чагылдырмый. Әсәрнең сюжеты да примитив, геройлары да юк нәрсә өчен янып-көеп йөри сыман, уй-хисләре саф булса да, ничектер 70 нче еллар яшьләренеке кебек түгел, ә бик беркатлы. Повестьта кирәксә дә, кирәкмәсә дә, «магазин», «цех начальнигы», «лента» кебек сүзләр очрый, югыйсә аларны бик гади, кешечә «кибет», «цех башлыгы», «тасма» дип әйтеп булыр иде. Автор шигъри тасвирлар, матур чагыштырулар белән әсәргә җан өрергә тырышса да, повесть тернәкләнә алмаган һәм шуңа күрә аның «үз аягы белән» укучыга барып ирешәсенә шик зур.
Инде шул ук китаптагы хикәяләргә килгәндә, алар повестьтан җир белән күк кебек аерылып торалар. Автор монда сюжетны да оста кора, теле дә матур, йөгерек. Хикәяләрнең «Ликандр», «Сөзгәк тәкә», «Зәңгәр шугалак», «Солдатлар кайта» дип исемләнгәннәре – арада иң уңышлылары.
Тирә-юньдәге мохиткә, табигатькә дөрес мөнәсәбәт тәрбияләү –әдәбиятның иң мөһим бурычларыннан берсе. Бала, песи белән тычкан арасындагы мөгамәләне күреп, иң элек яхшы белән яманны, явызлык белән яхшылыкны аңларга, урман-сулар гүзәллеген күреп, сокланырга өйрәнә. Әдәбият балаларда табигатькә карата мәрхәмәтле караш тәрбияләргә бурычлы. Юкса моңа кадәр без үзебезне табигать хуҗасы, аны ничек теләсәк, шулай үзгәртә алабыз, дип уйлый

идек. Хәзер балаларга кешенең әллә каян күктән төшмәгән, ә шушы гади җир баласы, җирнең, табигатьнең аерылгысыз өлеше икәнен аңлатырга кирәк. Язучы Г. Шәрәфинең «Аккошлар кайтыр әле» повестенда сүз шул турыда бара. Әсәр йөгерек тел, нечкә тойгы, кешеләргә ихтирам, ачык күңел белән язылган.
Шулай да табигатькә мөнәсәбәт проблемасы повестьта әле өстәнрәк, җиңелрәк чишелә кебек. Табигать трагедиясе дә җанны тетрәтерлек итеп бирелмәгән. Болын-елгаларның элекке гүзәллеген сурәтләгән юллар бик шигъри, бик матур булса да, аның бүгенге шыксыз хәлен тасвирлаганда авторның хис киеренкелеге, җан ачысы тулы көчендә ачылып бетмәгән. Шуңа күрә үткән гүзәллеккә мәхәббәт хисе зур булса да, бүгенгегә мөнәсәбәт пошыну дәрәҗәсендә генә калган.
Язучы Г. Хәсәнов, шагыйрьләр Х. Халиков, Э. Шәрифуллина китаплары да шул ук темага багышланган. Г. Хәсәновның «Чү! Сайрар кошым оя тибә...» китабындагы парчалар табигатьне танып белүдә кош-кортның, җәнлек-җанварның, үсемлекләрнең холык-гадәтен, төс-кыяфәтен өйрәнүдә балаларга зур ярдәм итә. Парчаларның җанлы вакыйга нигезендә эшләнгәннәре бигрәк тә уңышлы. Китап ахырында кайбер исем-атамалар сүзлеге биреп тә автор бик дөрес эшләгән.
Х. Халиковның «Эшләпәле дуслар» китабы да табигатьне яратырга өнди. Агулы һәм ашарга яраклы гөмбәләрне бер-берсенә каршы куеп, автор кызык кына сюжет оештырган. Бу әсәргә композитор И. Якубов нәни генә опера да язды. Аны телевидение тамашачылары яратып карадылар, тыңладылар. Ләкин бер генә шик бар: агулы гөмбәләрне гел начар итеп күрсәтү дөреслеккә туры килә микән? Белгәнебезчә, табигатьтә бер артык нәрсә дә юк бит.
«Безнең зоопарк» китапчыгы үзенә иң элек рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов ясаган төсле график рәсемнәре белән җәлеп итә. Э.Шәрифуллина, һәр җәнлек-җанварның үзенчәлекләрен истә тотып, матур шигырьләр язган. Ләкин М. Зарецкий тәрҗемәләренең оригиналга адекват түгеллеге, һәм, гомумән, шигъри эшләнеш ягыннан бигүк камил булмавы гына күңелдә ризасызлык хисе тудыра.
Балалар дөньясы ул – маҗаралар дөньясы. Бала һәрнәрсәдән могҗиза, маҗара эзли. Яшерен-батырын түгел, кулына газета-журнал алгач та, иң беренче маҗаралы әсәрләрне укый, китапханәчедән дә фантастик әсәрләр сорый ул. Чөнки мондый әсәрләр аның хыял офыгын киңәйтә, аң-белемен, мәгълүматын арттыра.
Узган ел «Ялкын» журналында ике фантастик повесть дөнья күрде. Аның беренчесен инде укучыларга күптән мәгълүм фантаст-язучыбыз А.Тимергалин иҗат итсә, икенчесен әле бу өлкәдә яшь автор М.Хәсәнов язган. Мәхмүт Хәсәновның «Динозаврлар өнендә» повесте бик гади башланып китә. Бер класс укучылары, укытучылары белән бергәләп, сәяхәткә чыгалар. Башта барысы да гадәти: алар табигать белән хозурланалар, гербарий җыялар. Шулай урманда йөргәндә, көтмәгәндә, җир убылып, Камил белән Мәрсия Җир асты патшалыгына килеп төшә. Шушы өлешенә кадәр повестьтагы хәлләр реаль җирлектә барганлыктан, укучы инде үзенең геройларына ияләшеп, алар белән дуслашырга өлгергәнлектән, җир астындагы маҗаралар да чын тормышта булган хәл кебек кабул ителә. Җир асты елгасы буйлап сәяхәт иткәндә, автор үзенең геройларын төрле кыен хәлләр белән очраштыра, бары тик бала хыялына гына сыярлык могҗизалар сурәтли, укучының белем маясын ишәйтә. Әсәр турында сүзне озынга сузмыйча, редакциягә килгән бер хатны гына укып китик.
*«Хөрмәтле редакция!*
*Мин «Динозаврлар өнендә» дигән фантастик повестьны укыдым. Укыганда инәй елый-елый тыңлап торды. «Балалар әрәм була», – дип борчылды ул.*
*Бүтән мондый повестьлар язмагыз, юкса инәй елый».*
Гомумән, редакциягә килгән йөзләрчә хатлардан күренгәнчә, повесть үз укучыларын тапкан.
А. Тимергалинның «Әүлия ташы» повесте инде балалыктан чыгып баручы буынга – студентлар тормышына багышланган. Әсәрдә буыннар эстафетасы да, халкыбыз тарихына хөрмәт тә, туган җиргә мәхәббәт тә бар. «Әүлия ташы» фәнни информациягә бик бай. Шунысы мөһим, аның геройлары – үзләре шул фәнни дөньяның аерылгысыз бер кисәге, алар һәрдаим фәнни ачыш турында хыялланалар, уйланалар, баш ваталар, ялгышалар, тагын табалар. Повесть вакыйгаларга

бик бай булмаса да, менә шул фикер һәм уй киеренкелеге аңа эчке динамика бирә, шуңа күрә әсәрне кызыксынып укыйсың.
Үткән ел «Яшь ленинчы» газетасы хикәяләргә аеруча бай булды. Газетада иң яхшы хикәягә уздырылган конкурста, гадәттәгечә, Габделхәй Сабитов җиңеп чыкты. Конкурска килгән һәм, гомумән, газетада басылган хикәяләр тематик яктан төрле. Алар арасында Ф. Шәфигуллин, К. Кәримов әсәрләре гомум фоннан камиллекләре белән аерылып торалар.
Балаларның төп эше – уку, белем алу. Балалар арасындагы иң катлаулы, иң төп проблемалар мәктәп чорында туа. Моңа кадәр гаилә атмосферасында һәм берничә дусты арасында үскән бала катлаулы мохиткә килеп керә. Укытучыга мөнәсәбәт, дуслар-иптәшләр, коллектив белән мөгамәлә. Менә шушы мөгамәләләрне, бала җанының үтә катлаулы халәтен бирү – балалар язучысы өчен иң кыенлыдыр. Песи һәм эт, яңгыр яву һәм буран улау, йокы килү һәм физзарядка ясау турында язу – чагыштырмача җиңел эш. Чөнки аларга анык бәя биреп була, алар гомер-гомергә шулай булып килгән. Ә мәктәп тормышы көн саен үзгәреп тора, анда көн саен яңа проблемалар, яңа традицияләр туа. Соңгы елларда бүгенге мәктәп тормышыннан язылган әсәрләрнең сирәк күренүе – балалар тормышын, аларның уй-хыялларын тирәнтен белмәүдән, өйрәнмәүдән килеп чыгадыр. 1976 ел бүгенге балалар тормышының нәкъ менә бүгенге проблемаларын чагылдырган берничә әсәр бирде. Ф. Яруллинның «Яшел утрау хуҗалары», Н. Дәүлинең «Каракай – йорт эте», М. Мәһдиевнең «Ай нигә йөри?», Р. Хафизованың «Без әле кайтырбыз», Г. Минскийның «Фәридә» хикәя-повестьлары, Т. Миңнуллинның «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» пьесасы – бер ел өчен аз түгел бу. Алар һәрберсе балалар тормышының аерым бер өлкәсен күтәрә. Мәсәлән, «Яшел утрау хуҗалары»нда пионерларның җәйге ялы, пионервожатыйлары җитәкчелегендә үз көчләре белән лагерь төзүләре турында сөйләнсә, «Каракай – йорт эте» повестенда кеше белән җәнлек-җанвар, табигать арасындагы бәйләнеш, дус мөнәсәбәт, күңел пакьлеге, ярдәмчеллек бәян ителә. М. Мәһдиевнең «Ай нигә йөри?» хикәясендә бала психологиясе бик оста бирелгән. Авторның теле бик тә балаларча, вакыйгалары натурадан алгандай, ышандыргыч. «Кичке сәяхәт» хикәясендә әтисе кечкенә Искәндәргә әкият сөйләгәч, малай аннан риза булмый:
«– Әти, төлке нигә тавыкны ашый ул?
– Төлке тавык ярата ул, – диде әтисе, берни дә уйламыйча.
– Юк, яратмый ул аны, – диде Искәндәр, кайгырып.
– Нигә алай дисең?
– Яратса, ашамас иде ул аны, – диде ул, авыр сулап.»
Мондый сүзне бары тик бала гына әйтә ала һәм мондый юлларны бала күңелен аңлаган балалар язучысы гына яза ала.
М. Мәһдиев шәһәр малае турында язса, Р. Хафизова авыл балалары турында, күбрәк аларның эшчәнлеге, олыларга хөрмәте, аларда туган җиргә мәхәббәт хисе тәрбияләү турында сөйли, пионер хәрәкәте проблемаларын күтәрә. Әсәрдә малайлык шуклыгы да, кызлар нәзбереклеге дә, авыл атмосферасы да, мәктәптә пионер оешмасы эше дә бик җанлы итеп тасвирланган. Повестьның иң отышлы якларыннан берсе – соңгы елларда бездә онытылып баручы балалык, мәктәп романтикасын күрсәтүендә. Әсәр җиңел укыла. Аны балалар да үз итте.
Т. Миңнуллинның «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» пьесасы маҗаралы сюжетка корылган. Тылсымчы карт укытучы сүзен, әти-әниләре сүзен тыңламаган малайның үзен, әфсен укып, укытучыга әйләндерә, ә укытучыны малай итә. Мәктәп сәхнәләре өчен атап язылган бу әсәр мавыктыргыч һәм сәхнәдә куюөчен гади дә.
Менә ничә еллар инде Шәүкәт Галиев балалар шигъриятен бөтенләе белән диярлек үз җилкәсендә күтәреп бара. Аның шигырьләрендә балалар тормышының төрле яклары урын таба. Ул – әле лирик, әле юморист, әле драматик шагыйрь.
Балалар әдәбиятына кертеп сөйләсәк тә, безнең күп әсәрләребез ул миссияне үтәп бетерми әле. Дөрес, алар балалар турында да була, балалар тормышын да чагылдыра. Әмма андый әсәрләрдә баланың үз уй-кичерешләре, үз хисләре, дөньяга карашы бирелми, ә бала турында олы кешечә

уйлап языла. Балалар әдәбияты исә ул дөньяга бала күзе белән карап, вакыйгаларны бала йөрәге аша үткәреп иҗат ителгән әдәбият. Ш. Галиев нәкъ менә шундый шагыйрь дә.
«Керпе таптык» шигырендә балалар урманнан керпе алып кайталар. Ләкин ул аларга ияләшә алмый, үлә. Бала моны менә болай кичерә:

Әтисе дә, әнисе да көтәләрдер,
Кайтыр диеп сагынышып бетәләрдер...
Алар безгә, мөгаен, гел рәнҗеп тора.
...Керпе һаман йөрәгемне чәнчеп тора...

Бу инде чын балаларча итеп, чын күңелдән әйтелгән юллар.
Шәүкәт Галиев иҗаты әле киләчәктә җентекләп өйрәнелер һәм тиешле бәясен алыр дип ышанасы килә.
Газетада һәм журналда чыккан М. Әгъләмов, Ф. Сафин, М. Галиев, Р. Миңнуллин шигырьләре арасында бик матурлары очраса да, алар зур бер вакыйга була алмыйлар. Моның сәбәбе, минемчә, яшьләр арасында үз иҗатын бөтенләе белән балалар әдәбиятына, балалар өчен иҗатка багышлаган язучылар аз булуда. Яшьләр нәниләргә багышлаган әсәрләрне иҗат тәнәфесендә, йә булмаса кирәге чыкканда һәм конкрет заказ биргәндә генә язалар. Бу нәрсә әсәрләрнең сыйфатына, тирәнлегенә, тәэсир көченә бик зур хилафлык китерә. Югыйсә балалар өчен иҗат итүнең иң зур потенциаль мөмкинлеге әлеге шул яшьләр кулында бит. Беренчедән, яшь язучылар әле үзләре дә яңа мәктәп партасыннан аерылган, мәктәп формасын салган. Димәк, яшь язучы бүгенге балалар тормышын, аларны ни кызыксындырганны, балаларның нинди уй-хыяллар белән яшәвен яхшы белә. Сүз уңаенда әйтеп үтәргә кирәк, балалар өчен язылган күп әсәрләрдә әле һаман да трафарет геройлар, дежур конфликтлар тулып ята. Безнең балаларыбыз әле һаман көне-төне чана шуа, Кар бабай ясый, мылтык тотып урманга ауга йөри. Чынлыкта исә хәзер авылда да чана шуган баланы бик сирәк күрәсең – алар хәзер боз өстендә хоккей уйный. Кызганычка каршы, кар тәгәрәтеп Кар бабай ясаган малай йә кызны да бик еш очратмассың – алар хәзер күзләре талганчы телевизор карый, ә ауга чыгуга килгәндә, беренчедән, бала-чагага мылтык тотарга рөхсәт ителми, икенчедән, хәзер аның урманда аучы атарлык куяны да юк.
Күтәрелмәгән чирәм балалар әдәбиятында шактый зур әле. Форма һәм тема бертөрлелеге, фикер сайлыгы һәм хис ясалмалылыгы – бүгенге көндә балалар әдәбиятының иң зур кимчелекләре шулдыр.
Алтмышынчы елларда әдәбиятка яңа өермә алып кергән Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимовлар балалар шигъриятенә дә яңа сулыш өрә башлаганнар иде. Ләкин бу шифалы җил нишләптер балалар әдәбиятын бөтенләе белән үз артыннан ияртә алмады. Бәлки, моңа әлеге дә баягы игътибар, яңалыкны күреп алып, куәт биреп җибәрү җитенкерәмәгәндер. Үзәк матбугатта балалар әдәбияты мәсьәләләренә, аның теориясенә караган мәкаләләр, китапларга рецензияләр бик еш басыла тора. Мәскәүдә хәтта «Детская литература» дип аталган теоретик журнал да чыгып килә. Ә бездә бу өлкәгә багышланган ник бер проблемалы мәкалә күренсен! Басылган китапларның, әсәрләрнең дә күбесе игътибардан читтә кала.
Соңгы елларда «Идел» альманахы чыга башлагач, яшьләр кинәт активлашып киттеләр. Ләкин бу активлашу күбрәк яшьләрнең үз замандашлары, үз кордашлары турындагы әсәрләр хисабына булды. Бәлки, әлеге дә баягы «Идел» альманахында балалар һәм бигрәк тә яшүсмерләр өчен язылган әсәрләрне дә урнаштырырга кирәктер? Бүгенге көндә аның контингентын күбесенчә студентлар, эшче һәм авыл яшьләре тәшкил итә.
Әйтелгәнчә, яшь язучыларның балалар өчен эшләрлек көч-куәте дә, белеме дә, мөмкинлеге дә җитәрлек. Бу эшнең никадәр мөһим һәм кирәкле икәненә тирәнтен төшенеп, җиң сызганып тотынганда, яшь язучылар киләчәктә татар балалар әдәбиятына үз өлешләрен кертә алырлар. Кыскасы, яшьләр иҗатын бик нык активлаштырырга кирәк.
Безнең халыкта: «Ни чәчсәң, шуны урырсың», – диләр. Миңа калса, балалар әдәбияты турында сөйләшү вакытында әлеге мәкальне искә алу дөрес булыр. Безгә алмашка килүче яшь буын

яхшырак, инсафлырак, белемлерәк булып үссен дисәк, бүген үзебез шул сыйфатлар белән сугарылган талантлы әсәрләрне җиң сызганып иҗат итәргә тиешбез.

*1977*

# ХАЛЫК ИСЕМЕННӘН СӨЙЛИМ ДИСӘҢ...

*(1981 ел поэзиясе турында уйланулар)*

Республикабыз вакытлы матбугатында һәм аерым китаплар бу-лып та бик күп шигъри әсәрләр дөнья күргән. Алар күңелдә күп- төрле уйлар уяталар, күп кичерешләргә дучар итәләр. Шулай да үткән ел басылып чыккан шигъри әсәрләр турындагы сүзне, гадәттәгечә, өлкән буын шагыйрьләр иҗатыннан башлыйсы килә.

Сибгат Хәкимнең шигырьләрен укыгач, аның иҗат ялкынына сокланмау мөмкин түгел.

Билгесез миңа бу Себер,
Миңа, җырчы-шагыйрьгә.
Мин киттем кереп, ияреп
Шул бөек мосафирга.

Сибгат Хәким бөек мосафир артыннан гади генә ияреп йөрми, аның кылган эше белән, аның хыялы, аның идеалы белән үз идеалын чагыштырып карый, үз тормышын, үз язмышын тарихи шәхес бизмәне белән үлчи. Бер караганда бу бик гади булып тоелса да, бөекләр белән каушамыйнитми, тавышың һәм тез буыннарыңны калтыратмый сөйләшә алу сирәк затларга гына бирелә торган бик олы мәртәбә. Зур шагыйрь, тавышыңны халыкка ишеттерерлек шагыйрь булу өчен, табигый талант һәм чиксез зур тырышлык янына тагын мәгънәле горурлык, үз бәяңне белү, үз-үзеңә ныклы ышаныч та кирәк.

С. Хәким шигырьләренең нигезендә хәрәкәт, вакыйга, конкрет бер хәл яисә истәлек була, ә үзәктә – күңел күзе белән генә эзләп табарлык серле үзәктә – идея, төп фикер ята. Билгеле, бу – иҗат итүнең бердәнбер ысулы түгел, иҗатта һәркемнең үз юлы бар. Әмма бу юл – классик поэзиядә һәм шигърияtнең мең еллык тарихи тәҗрибәсендә иң күп һәм иң асыл җәүһәрләр табылган юл. Шәрә идея-фикерне нинди генә чапаннарга төрсәң дә, нинди генә соуслар белән табынга китерсәң дә, ул барыбер кибет манекены яисә майда кыздырылган иске чабата кебек кенә булачак.

С. Хәким шигырьләрендәге бәләкәй тыкрыкларны, карт өянкеләрне, сиреньнәрне, авыл күперләрен, сарык көтүләрен, читән буендагы кычытканнарны, үткән гомерне сагынуны күңел географиясенең тарлыгы белән аңлатучылар да булган. Баксаң, шагыйрь бүгенге дөньяга шул өянкеләр, шул тыкрыклар аша караган, шулай итеп, бик ерак тоелган әйберләрне үзенә якынайткан. Еллар буе бер телескоп төбе сагалап яңа йолдыз ачкан астроном кебек, Сибгат Хәким дә олы дөньяга гомере буе үз тыкрыгы аша караган, шул «телескоп» ярдәме белән башкалар күзенә күренмәгән шигъри йолдызлыклар ачкан икән.

Халык исеменнән сөйләү өчен үзеңне халыкныкы санау гына җитми. Халыкның сине үзенеке дип хисаплавы, сине үз итүе, үзенең бер өлеше итүе зарур. Ә халык үзенең бар сыйфатларын бер җанга, бер күңелгә туплаган шагыйрьләргә генә мондый миссияне ышанып тапшыра.

Чаллыда узган иҗат кичәсендә Сибгат ага Хәкимгә залдан: «Фазыл чишмәсе» кайсы авылда ул? Барып карар идек...» – дип сорау бирделәр. Бер карауга үтә беркатлы тоелган бу сорауның төбендә зур мәгънә ята. Димәк, әлеге кеше шагыйрьгә ышана, үзенә ышанган кебек ышана, Фазыл чишмәсенә ышана. Сибгат агай, тел ачкычы көткән кебек, шактый вакыт тын торгач, әйтеп куйды: «Фазыл чишмәсе һәр авылда бар. Үз авылыңа кайт, энем», – диде. Шушы минутта берничә сүз белән ул әдәбиятның асылын, шагыйрь миссиясенең мәгънәсен әйтеп бирде. Менә ни өчен мин сүземне С. Хәкимнән – Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан күзләре белән безгә сынап карап торучы, алар әманәтен безгә җиткерүче аксакал Сибгат Хәкимнән – башламый булдыра алмадым.

Илдар Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән» дип аталган шигъри трагедиясендә укучыны иң нык тетрәткән, аның күңел түрендәге бар кылларга берьюлы кагылган һәм аны иң ышандырган

урыны – Тукайның патша белән сөйләшү эпизоды. Әсәрнең беренче юлларыннан башлап ук Илдар Юзеев Тукае үзен халык улы булырга, халык исеменнән сөйләү хокукын яуларга әзерли башлый. «Уртада – сиртмәле бишек. Ул гүя «Тәфтиләү» көенә тирбәлә. Көй бишек җырына күчә. Шагыйрьне халык тудыра сыман», – дип яза И. Юзеев иң беренче ремаркада ук. Юк, Илдар Юзеев Тукайны халык арасыннан аерып, купайтып өскә күтәрми. Киресенчә, башкалар шау-шу килгәндә, Тукай бер читтә тын гына тора, бүтәннәр арлы-бирле чапканда, артык каударланмый, ә инде иң кирәк чакта, кешеләр аптырап сүзсез калганда, ул барысы исеменнән дә сөйли, барысының да еллар буе әйтергә теләп тә әйтә алмый килгән уйларына иң кулай сүзләр таба. Әйе, И. Юзеев Тукае – халыкның бәгыре, үзәге, аның күңел ярасы һәм тарих җилләрендә ныгыган яшерен иманы.

Халкым күпме ким-хурлыкта интекте,
Аның рухы кабул итми читлекне.
Чит-ят күрә җаным мондый дөньяны,
Юк, танымыйм яшәү диеп мин аны.
Туган идем бәхет, шатлык чәчәргә,
Мәҗбүр булдым кайгы җырлап яшәргә.
Килми калмас, чынлык дигән чор туар.
Халык бәхете турында да җыр туар.
Бар милләтләр тигез булыр – мин беләм...
Әмма ачык белмим – нинди юл белән.

Бу юлларда – Тукайның бөтен биографиясе, иҗат газаплары, язмыш михнәтләре, иманы, күңел кыйбласы. Бу юлларда – Илдар Юзеев әсәренең төп фикере.

«Очты дөнья читлегеннән» әсәренең жанрын кайберәүләр пьеса дип билгели. Башына «шигъри трагедия» дип куелган бу әсәрне шундый ук ышаныч белән поэма яисә опера өчен либретто дип тә атап булыр иде. Чынлыкта исә, «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясендә И. Юзеевның шагыйрь, драматург, прозаик таланты өчесе бергә укмашкан. Нәтиҗәдә әдәбиятыбызның мактанычы булырлык әсәр дөньяга килгән.

Спортта биеклеккә сикерүчеләр арасында ике төрле рекорд бар: аның берсе – ябык бинада сикерү, икенчесе – ачык һавада сикерү буенча. Гаҗәпкә каршы, бер үк спортчы ачык һавада бина эчендәгегә караганда берничә сантиметрга биегрәк сикерә икән. Югыйсә күпме сикерсә дә, түшәмгә башы тими бит инде аның! Як-ягында – иркенлек, баш өстендә биек күк булу спортчы булып спортчыга тәэсир иткәч, иң сизгер күңелле шагыйрь һәм язучы затларына киң мәйдан кирәклеге турында әйтеп тору зарур микән? Шуңа күрә безгә Тукай белән Җәлил һәйкәлләренә генә сокланып калмыйча, бүгенге шагыйрьләребезне дә илкүләм олы мәйданга кыюрак чыгару турында ныклап уйланырга вакыт җиткәндер.

Үзенә үзе юл салып, тез җимерә-җимерә, терсәк каната-каната илкүләм поэзия мәйданына чыгып барган Равил Фәйзуллин иҗаты турында уйланганда, бу өлкәдәге эшләрнең әле үзагымына куелганын аңлап әрнисең.

Р. Фәйзуллин турында кем ничек фикер йөртәдер, ә минем үзем өчен ул иң әүвәл – көчле шәхес, кызыклы шәхес. Аның иҗат энергиясе, туктаусыз эзләнүләре, үз язмышын һәм әдәбият язмышын кайгыртып янулары һич тә эзсез югалып кала алмый. Киресенчә, Равил Фәйзуллин исеме халык арасында көннән-көн ныграк тарала, илкүләм масштабта таныла бара. Р. Фәйзуллин бүгенге дөньяның эш стилен һәм фикер сөрешен тирәнтен үзләштергән шәхес буларак, кайбер талантлы шагыйрьләребез кебек, аткан шигырь угы артыннан хәерле юл теләп карап кына калмый. Угыннан да алда мишень янына йөгереп барып җитеп, аны иң үзәккә тидерергә тырыша, инде тимәсә, яңадан элекке урынына кайтып, максатына ирешкәнче, тидергәнче ата. Р. Фәйзуллин шигырьләрен, дөньяга килү белән, үз көнегезне үзегез күрегез дип, ташлап китми, аларны йөрергә, сөйләшергә, кешеләр белән аралашырга өйрәтә, ә инде «балалары» аякка баскач, үзе дә игелеген күрә.

1981 елда күләм ягыннан да, шигъри егәрлеге ягыннан да күпләрне көнләштерерлек булып китап киштәләренә менеп баскан «Кошлар юлы» җыентыгын ачып укый башлаганчы ук, күңелгә

шундый уй-фикерләр килгән иде. «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан бу җыентык иң әүвәл үзенең пөхтә төзелеше, эзлеклелеге белән аерылып тора. Бу китап – Р. Фәйзуллинның 20 еллык иҗат юлы, бу китап – шагыйрьнең үз укучысы һәм халкы алдында биргән хисабы.

Равил Фәйзуллинның 15 яшьлек чагында язылган шигырьләрендә үк инде ил язмышы, җир язмышы турында кайгырту кебек иң олы хисләр ярала башлаган икән. Ә берничә елдан соң ул үткән афәтләрнең мәгънәсен һәм мәгънәсезлеген аңларга тырышып, фронтовик авызыннан мондый сүзләр әйттерә:

Әле иртә,
әле караңгы,
әле буран шыңшый, тынмаган...
Бер сыңар кул ялгыз урам көри,
таң атканын көтеп тормаган.

«Улым торып мәктәбенә китәр,
капка төбе булсын көрәлгән...»
Җил уйнаклый.
Нидер әйтмәк булып,
көнбатышка буш җиң төбәлгән.

«Кошлар юлы» җыентыгына кергән шигырьләрнең шактый өлеше беренче тапкыр басыла. Билгеле, шагыйрь аларны күләм өчен генә алмаган, ул үз иҗат биографиясен эзлекле төстә күрсәтергә теләгән. Әлеге шигырьләр арасында Фәйзуллинның «алтын фондына» керерлекләре булган кебек, арада Равилнең шәхси архивын гына бизәрлекләре дә юк түгел.

Гомумән, Равил Фәйзуллин иҗатын ике өлешкә бүлеп карарга була: беренчесе – көйле шигырьләр, икенчесе «ирекле» дип аталган көйсез шигырьләр. Шагыйрь әйтерсең юри, мин сезнең шикелле шома гына, көйле генә дә яза беләм, дип ымсындыра да тагын үзенең колак өйрәнмәгән җырын җырларга тотына. Әйтерсең ул башта колакка да, җанга да якын җырына ияртеп бара-бара да сиздермичә генә үзенең күңел карурманына кертеп адаштыра. Син инде телисеңме-теләмисеңме, шул карурман сукмакларын табарга, шунда үзеңә җан азыгы юлларга, сусыныңны басарга – кыскасы, шул карурман тормышы белән яши башларга мәҗбүр буласың. Әлеге сүз чытырманлыклары арасында адашып йөри-йөри күңелең һәм җаның талкынып беткәч, «Аккошлар», «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...», «Башны салларга салып...», «Дошман – сигез, без – тугыз...» дип аталган якты шигъри аланнарга килеп чыгасың да тагын сөенеп бетә алмыйсың...

Әйе, Р. Фәйзуллин иҗаты тоташ бәйрәм түгел. Күп вакытта аның тавышына кушылып җырлап та булмый, көен таба алмый тилмерәсең. Ләкин тора-бара без аның җайсыз көенә дә ияләшә барабыз. 60 нчы еллар башында «табышмак» дип мөһер сугылган шигырьләр дә хәзер инде ул кадәр башваткыч булып тоелмый.

Р. Фәйзуллин иҗатының көче дә, көчсезлеге дә – аның үз принципларына тугрылыклы булып, һәрвакыт үз йөзен, үз сүзен саклап килүендә. Әлеге яхшы мәгънәсендәге иҗат үҗәтлеге аның балачактан башланган, табышларын көннән-көн ишәйтә барса, шул ук үҗәтлек үзе артыннан калдырмыйча «дегет чиләкләрен» дә ияртеп йөри. Равил Фәйзуллин, инде алда әйткәнемчә, бер темага, бер әйбергә каныкса, аның төбенә төшмичә, аның үзәгенә үтмичә туктамый. Аның шагыйрьлек һөнәре, иҗат газаплары, дус-дошман, җан-күңел-бәгырь-йөрәк кебек үзе яраткан шигъри даирәләре бар. Шагыйрь алар турында әйләнеп кайта-кайта, кат-кат яза, шул язганнарының барысын да диярлек дөньяга чыгара. Бу нәрсә миңа театрга барырга җыенган көяз хатын-кызның көзге алдында дистәләгән күлмәк сайлап изаланганын хәтерләтә. Ләкин көяз хатын да нәтиҗәдә бер күлмәк кенә киеп бара бит. Ә шагыйрь үзенең кайсы «күлмәге» үзенә иң нык килешкәнен яхшы белергә, халык алдына, иң матурын үзегез сайлагыз дип, кырык кат киенеп чыгарга тиеш түгел. Бу урында сүземне йомгаклап шуны әйтәм: җыентык төзегәндә, үз иҗатына таләпчәнрәк (әйтергә кирәк, хәтта – рәхимсезрәк) килеп, бер ноктага бәрә торган шигырьләрнең иң үткерләрен генә калдырганда, «Кошлар юлы»нда аккошлар белән янәшә әрсез

чыпчыклар да күренмәс иде. Моны, бәлки, санның сыйфатка әйләнүенә исәп тотып, күләм артыннан куу белән аңлатырга кирәктер. Ләкин бу мәгълүм теория ике яклы бит: сан арткан саен, сыйфат яхшы якка гына түгел, кире якка да үзгәрергә мөмкин.

Шагыйрьгә бәя биргәндә, аның иҗат җимешләрен үз күңел тәлинкәңә салып үлчәү, аның уйхисләрен үзеңнеке белән янәшә куеп чагыштыру, аның күңел көен үз күңелеңә күчереп карау гына җитми икән. Ренат Харис шигырьләрен укыганда, ул булып уйларга, ул булып фикер йөртергә, ул булып көйләргә, аның хисләре белән хисләнергә тырыштым. «Замана эзләре» дип аталган шигъри йортта үткәргән бер көнемне мин Ренат Харис булып яшәп карадым. Бу эксперимент тора-бара миңа шулкадәр ошап китте ки, мин әле тагын берничә көн рольдән чыга алмыйча интектем; гади генә сүзләргә дә катлы-катлы мәгънәләр өеп, аныңча сөйләштем, сүз сөрешендә көтелмәгән борылышлар ясап, кешеләрне гаҗәпкә калдырдым, көн саен аяк астында уралып йөргән гадәти әйберләрдән ил-җир язмышына бәйле фәлсәфәләр сыгып чыгардым... Җөрьәт итеп кабыгына кереп карасаң, Ренат Харис булып фикер йөртү, Ренат Харис булып ярату, Ренат Харис булып нәфрәтләнү – кыскасы, Ренат Харис булып бу дөньяда яшәү шактый ук кызык икән.

Р. Харис иҗаты полемик характерда. Ул һәрчак кем беләндер килешми, дөнья белән, җиһан белән, тиран белән, мещан белән, хәтта үз-үзе белән берөзлексез бәхәсләшә. Ренат Харис – катлаулы шәхес, аның күңел багажы бай, аның күңеленә төрле традицияләр, алымнар, сурәтләр, принциплар, йолалар, әдәбиятлар, халыклар, илләр сыйган. Менә шул гаҗәеп бай чималны шигырь итеп эшкәртеп чыгару өчен табигый талант өстенә бик күп көч һәм осталык та кирәк. Миңа калса, Ренат Харис үзен зуррак жанрларда, бигрәк тә поэма жанрында, иркенрәк хис итә. Узган елны дөнья күргән «Җәлилчеләр» поэмасында ул үзенең зур фикерләр әйтә алырга сәләтле киң диапазонлы шагыйрь икәнен тагын бер тапкыр раслады.

Шагыйрьнең иң зур максаты кеше ышандырырлык, кеше инандырырлык итеп сөйләү, үзе артыннан кешеләргә ияртә алу, кеше күңелендә бөреләнгән уй-фикергә өстәмә импульс биреп, аны куәтләп җибәрү булса кирәк. Бу яктан караганда Ренат Харис белән гади укучы арасында беркадәр дистанция сакланып килә бирә. Соңгы елларда халык арасында популярлашып киткән җырлары бу аралыкны киметә төшсә дә, кайбер шигырьләрендәге салкын акыл бозын эретү өчен, Ренат Хариска әле шактый йөрәк утын сарыф итү кирәк булачак.

Телдәге саксызлыклар, сүзнең дистәләгән төсмерләренә игътибар итмичә, бер төсмерен генә күздә тотып сөйләшү, сүз агышында очраган чатаклыклар – боларын инде Ренат Харисның иҗат йөзе дип түгел, ә, Тукайча әйтсәк, «ялан кул эше» дип кенә карарга кирәктер.

Без шагыйрьне:

Күзләремә туры кара...  
Сау бул... Киттем... Күзең буйлап  
Ят бер егет үтеп бара, –

дип бары тик үзенчә һәм шул ук вакытта безнеңчә дә әйтелгән юллары, Әнвәр Давыдов истәлегенә язылган «Кәбисә» атлы тетрәндергеч шигырьләре, халкыбыз каһарманнарына багышланган поэмалары, һәр авыл өенә үтеп кергән җырлары буенча рәссам шагыйрь, философ шагыйрь буларак беләбез, аның киләчәк үсешен шул тарафта күрәбез...

Хуш инде, яшьлек, хуш инде,  
Күчәсең бүтәннәргә.  
Миңа калды юл читендә  
Сүгенеп ютәлләргә.

Гайрәтле заманнар үтте,  
Син миннән киңәш сора.  
Кызларың үзеңә булсын,  
Акыллы картлык юра.

Гамил Афзалның «Үрләрдә имәннәр шаулый» җыентыгыннан алынган бу юлларга шагыйрь үзе үк җавап та бирә. Гомере буе, асылда, юморист, сатирик шагыйрь булып, намуссызларга намус

табышып, имансызларга иман иңдереп, сорыкортларның төшләренә кереп йөдәткән кычыткан телле Гамил Афзалга, чыннан да, төпле акыл утырган лабаса. Җитдирәк тонга күчеп әйтсәк, шагыйрь тәнкыйть итеп үстергән кешеләре белән үзе дә үзгәргән. Әйтерсең ул «минем геройларым элек кем иде дә менә хәзер кем булды» дип, алар турында хөрмәт һәм ихтирам белән зурдан кубып сөйли.

Җыентыкка кергән шигырьләрнең күбесенә моңсу юмор белән сугарылган җитди уйланулар, тормыш мәгънәсенә, яшәеш мәгънәсенә төшенергә омтылу хас. Туры сүзле булуы, халыкчанлыгы нечкә юмордан алып – көчле сатирага, гаҗәеп лирик шигырьләрдән алып – лозунг итеп парламентлар түбәсенә эләрлек киң диапазонлы шигырьләре белән Гамил Афзал үзенең Тукай варисларыннан икәнен искә төшереп тора:

Ак тастымаллар җилферди, Сабантуйда атлар,
Ак моң булып җанда йөри Тукай туган яклар, –

дип яза ул «Тукайны сагыну» шигырендә. Тукай турында инде күп язылды һәм моннан соң да язылыр. Әмма Сибгат Хәким иҗатындагы, Илдар Юзеевның шигъри трагедиясендәге һәм Гамил Афзал шигырьләрендәге Тукай башка әдипләр хыялындагы Тукайдан аерылып тора. Бу өч шагыйрь Тукайны әдәбиятыбыз үткәненнән, халкыбыз тарихыннан гына эзләмиләр, алар Тукайны киләчәктән, алдагы көнебездән эзләп табалар, аңа халкыбызның мәңгелек символы, киләчәк юлындагы маягы итеп карыйлар. Алар өчен Тукай татар реалистик әдәбиятына юл ярган бөек шагыйрь генә түгел, ә үзләреннән күп алда – гасыр башында ук – мәңгелек юлга чыккан һәм шуңа күрә бик еракка алга – киләчәккә киткән бөек мосафир. Әле һаман Тукай бишмәтеннән мәдрәсә кандаласы эзләп изаланучы кайбер каләмдәшләребез өчен бу иҗат үрнәкләре бик гыйбрәтле өлге була алыр иде!..

Гамил Афзал, башкаларга таләпчән булу белән бергә, үз-үзенә дә объектив бәя бирү, хәтта ки күп очракларда артык тыйнакланып китү сыйфатларыннан да мәхрүм түгел.

Йолдызлар янган төнемдә
Энҗеләр җыйганым бар.
Арыслан ята күңелдә,
Кулымда куяным бар, –

ди ул бер шигырендә. Кулындагы куянның шактый ук батыр һәм йөгерек куян икәнен белгән хәлдә, без, укучылар, күңелдәге арысланның дөньяга чыгуыннан да өмет өзмибез, тик ул арыслан күңел читлегендә озак ятып, зоопарк баһадиры сыман үшәнләнеп бетмәсен иде дигән теләктә генә калабыз.

Рәшит Гәрәйне татар шигъриятендә беркем белән бутап булмый. Юк, мин һич тә аны башкалардан аерып алып, ачыш ясагандай, күккә күтәреп чөяргә җыенмыйм. Ләкин Р. Гәрәйнең бөтен кан тамырлары, бөтен нервлары белән җиргә береккән, шул җир өчен җанын бирергә әзер торган фидакяр шагыйрь икәнен, бүгенге авыл кешесенең җанын аңлаган шагыйрь икәнен әйтми дә булдыра алмыйм. Шулай ук аның кимчелекләрен дә күрәм: гел җиргә карап, тирә-юньдәге зур дөнья белән багланышын югалтып куйгалавын вакыт-вакыт гел уҗымнар турында җырлап, шул тирәдә генә әйләнүен дә әйтеп китәм. Шагыйрьнең яңа шигъри ачышларын очратып тагын сөенәм:

Йолдызларга карап уйга калдым:
Ничек якты алар бу чаклы!
Бар диеп тә алар белмиләрдер
Мин сукмакка яккан учакны.

Иртән тагын чыбык өстәп киттем –
Күңел тели озак көйрәвен...
Учагымнан элек сүнәр булсаң,
Тибүеңнән тукта, йөрәгем!

Бу юлларны инде үз борынынnан ары җир күрмәгән кеше яза алмый, бу инде – гражданин шагыйрь, иҗат эшенә үтә җаваплы караган шагыйрь йөрәгеннән өзелеп төшкән сүзләр.
Рафаил Төхфәтуллин Әдип Маликовның «Туган як җиле» китабына язган кереш сүзендә аны «кырыс моңлы шагыйрь» дип атый. Моның шулай булуы бик табигый дә. Чөнки Ә.Маликов шигырь һәм поэмаларында үз башыннан кичкәннәрне, үзенең катлаулы биографиясен яза. Ә аның биографиясе – автомат түтәсенә куеп, ерактагы туганнарга һәм сөйгән ярларга хатлар язган, шигырьләр язган кырыс чор биографиясе белән аерылгысыз. Ә.Маликов шигъриятькә халык иҗатыннан, халык җырларыннан килә. Халык иҗатының мең еллар буе чарланып килгән калыпларына ул бүгенге мәгънәне, бүгенге уйларны, Әлмәтнең вышкалы офыкларын, Ерак Көнчыгышның өмет төсле түгәрәк күкләрен кертеп утырта. Әйтерсең ул халык уеп биргән кечкенә һәм тыйнак тәрәзәсеннән олы дөньяга моңсу гына көлемсерәп карап тора.

Атлыйм баскан эзләреннән,
Җырлары арасыннан.
Сикерепләр төшәр сыман
Күзләрем карасыннан.

Ә. Маликовның бу шигыре дөньядан иртә киткән шагыйрәбез Саҗидә Сөләймановага багышланган икәнне белгәч, йөрәк ирексездән сулкылдап куя.
Үзе исән чакта ук Саҗидә Сөләйманова талантлы шагыйрә, халык кабул иткән шагыйрә булып танылган иде. Ул соңгы елларда көчле бер йодрык булып укмашып килгән шагыйрәләребез иҗатының баш бармагы булды, дисәк, шәт, каршы килүче табылмастыр. «Сабыр канатлары» исемле күләмле җыентыгы белән танышып чыккач, мөлаем йөзле шагыйрәбезнең күңеленә күпме вулканнар сыйганын, тел очында күпме тылсымлы сүзләр торганын, аның гомере буена ут-ялкын эчендә борчылып һәм янып яшәвен аңлап таң каласың. Юк, ул башкаладагы кайбер «модный» шагыйрәләр кебек ирдәүкәләнеп, үзенең базарын да төшерми, хатын-кыз булам дип, авыз кырыен яулык чите белән каплап, пышылдап та сөйләшми. Ул үз-үзенә ныклы ышаныч белән һәм үз биеклегеннән торып дөньяга аваз сала, иҗатка көн күрү һөнәре итеп түгел, җан авазы итеп, намус эше итеп карый. Йокысыз төннәр һәм михнәтле иҗат газаплары кичеп дөньяга килгән шигырьләренә ул үзенең бар йөрәк җылысын, күңел яктысын сала:

Ачылмаган кара чәчәкләрем –
әй төннәрем минем, төннәрем!
Сагынып искә алыр кемнәрегез,
хуш исе юк йомык гөлләрнең.

Мин үзем дә әле төсмерләмим,
кемгә ачылыр, кемне сихерләр...
Төннәремнең биген ачып чыга
таң нурыннан тамган шигырьләр.

Таң нурыннан тамган шигырьләр калдырып киткән оптимист рухлы шагыйрәбезне сагынып, киләчәктә без әле аның иҗатына һаман саен ешрак әйләнеп кайтырбыз дип уйлыйм.
Клара Булатованың «Гел кояшка карап» җыентыгына, нигездә, инде моңа кадәр дөнья күргән һәм бәя алган таныш шигырьләр кергән. Шагыйрәнең чәчәнлек рухы белән сугарылган җиңел телле, йөгерек көйле иҗаты үз кыйммәтен югалтмаган. Китап үзенең пөхтәлеге, иң интим хисләрне да яшермичә ачык күңел белән сөйләве ягыннан яшь кызларның истәлек дәфтәрен дә хәтерләтеп куя. Шуңа күрә анда К. Булатованың эчкерсез моң тулы шигырьләре дә, чыннан дә истәлек дәфтәрләрендә генә калырга тиешле куплетлары да очрый.

Зәй кырлары быел коры калмас,
Кар мул ятса – уңыш буласы.
Шундый уйлар белән йөрисең син –
Зур колхозның тырыш хуҗасы.

Мондый юллар шагыйрәнең үзенә дә, китап редакторына да мактаныч була алмый.

Флёра Гыйззәтуллина, тегүче буларак, шигъриятькә энә белән кое казыгандай, озак һәм авыр килде. Әдәбиятка дөбер-шатыр чабып кереп, күзенә ак-кара күренмичә шундый ук тизлек белән чабып чыгып та киткән кайбер каләмдәшләребезгә караганда, җирдәге һәр калкулыкны җан тире түгеп яулаган, үз уңышларының кадерен белгән шагыйрьләрне мин өстенрәк саныйм. Ф. Гыйззәтуллина шигырьләре – хис һәм уйлардан еллар буе үрелгән пөхтә челтәр кебек.

Кеше чагыштыра иң вак әйберләрне
Энә күзе белән.
Мин – тегүче...
Энә күзе аша
Бар дөньяны күрәм.

Дөньяга һәркем үз каланчасыннан карый, аңа тегүче энәсе күзеннән карау да бик мәгъкуль. Әмма хатын-кызның тавык чүпләп бетерә алмаслык көндәлек вак мәшәкатьләренең һәммәсеннән шигъри фәлсәфә чыгарырга омтылу Ф. Гыйззәтуллинаның «Сәлам хаты» җыентыгында да сизелә. Бүгенге дөньяның бар ямен зурлау һәм кеше күңелендәге җөйләрне җөйләү өчен аңа әле, үзенең «шахтёр атлары» белән бергә җигелеп, поэзия йөген шактый тартырга туры киләчәк.
Сибгат ага Хәким кайчандыр: «Әдәбиятка кызлар күп килә, әмма калучылар сирәк», – дигән иде. Менә шул калучылар исемлегенә керергә дәгъва белдергән яшь шагыйрә Нурия Измайлованың узган ел «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясендә «Яратам» исемле җыентыгы басылып чыкты. Исеменнән үк күренгәнчә, шагыйрә дөньяга, кешеләргә гаҗәпләнеп һәм сокланып карый, язмышның гел кояштан гына тормаганын белгән хәлдә кешенең төп максаты бәхеткә омтылу, бәхеткә ирешү икәнен яхшы аңлый:

Дәртем таша. Юлга чыгам.
Озын торна – хыялым.
Аккош булып йөзәр әле
Бер күлендә дөньяның!

Бу юлларда инде шагыйрәнең нык кулы, профессиональ кулы сизелә. Аның шигырьләре күбесенчә якты буяуларга, нарасый хисләргә бай булса да, шигырь артында торган шагыйрәнең шактый ук катлаулы шәхес икәне, дөнья базарындагы товарны сатулашмый-нитми генә күз йомып ала торган беркатлы җан иясе түгеллеге сизелеп тора. Н.Измайлова әле күбрәк үзе турында яза, дөньяга үз «мин»е аша карый, шуңа күрә шактый шигырьләре күз яшьле хисләрдән, интим тойгылардан мөлдерәмә тулып тора. Ләкин ул баскан урынында бер сүзне кабатлап тик тормый, бертуктаусыз эзләнә, яза. «Эндәшмәүчеләр турында» дигән шигырендә ул:

Үз сүзен әйтмәгән кеше
Ул беркем дә түгел әле, –

ди. Һәм без яшь шагыйрәнең киләчәктә дә үз сүзен әйтүенә, тагын да кыюрак һәм үтемлерәк итеп әйтүенә ышанабыз.
Узган ел дөнья күргән шигырь җыентыкларының күбесенә моңа кадәр шагыйрь үткән иҗат һәм тормыш юлына йомгак ясап уйлану, үзенең шигъриятьтә һәм җәмгыятьтә тоткан урынын ачыкларга омтылу хас. Бу нәрсә өлкәннәрне генә түгел, әле әдәбият мәйданына яңа ныклап аяк басып килгән шагыйрьләрне дә читләп үтмәгән. Шамил Маннаповның «Кайту» җыентыгындагы шигырьләренең төп лейтмотивы үткән юлга борылып карап, эшләнгән эшләргә бәя бирү булса, аның шулай юлда туктап уйлануларын киләчәк иҗат өчен мая туплау чоры, киләчәккә ориентир ачыклау чоры дип карарга кирәк. Шагыйрьнең авазы көннән-көн көррәк яңгырый, күңел күзләре үткерләнә, фикри мәгънәсе саллырак була бара.

Килер беркөн картлык,
Барысын да өлгералмам татып.
Калырмындыр тик берсендә генә:
Җилдә генә

Яки силдә генә.
Күктә генә
Яки Җирдә генә.
Кайсында да ярый.
Булсын бары
Туган илдә генә,
Туган илдә генә.

Ватанга, Туган илгә мәхәббәт кебек хисләрне шулай җанга ятарлык итеп әйтеп бирә алган Ш. Маннаповның көн кадагына бәләкәй чүкеч белән суккан шигырьләрен укыгач, бераз аптырабрак та каласың. «Аш – ашка, урыны башка» дигәндәй, газета өчен нindидер вакыйга уңае белән язылган кайбер шигырьләрен монда кертмәгән булса, җыентык, күләм ягына зыян китереп булса да, сыйфат ягыннан откан гына булыр иде.
Чаллы шагыйрьләренең узган ел басылган җыентыклары турында сүз башлаганчы, кирәкле сүзләр таба алмый шактый иза чигәргә туры килде. Мактасам, «үзеңнеке – үзәктә» дип әйтерләр кебек тоелды, йөгереп кенә узып китсәм, хакыйкатькә һәм үземнең иманыма хыянәт итәрмен сыман иде. Ә чынлыкта Кадыйр Сибгатуллинның «Авазлар», Хәниф Хөснуллинның «Алтын тояк», Ямаш Игәнәйнең «Сәфәр чыгам» җыентыкларының нигезен бүгенге поэзиябез йөзен кызартмаслык, күпмедер дәрәҗәдә аның киләчәген күзалларлык шигырьләр тәшкил итте.
«Шагыйрьләр провинциядә туа, башкалада үлә» диләр. Бу сүзләрдә беркадәр хаклык бар кебек. Казанның мемориаль такта куярга урын калмаган стеналарында үзеңә урын сайлап каңгырып йөрүгә караганда, илнең-җирнең үзәгенә әйләнгән, ил-җир язмышы хәл ителә торган урыннарда яшәү һәм иҗат итү, шул бөек үзгәрешләрнең уртасында кайнаган кешеләрнең күңелен көйләү, аларга рухи азык, җан азыгы табышу күпкә мәртәбәлерәк эштер. Бер яктан, андый җирләрдә әдәби сүзнең кирәклеге һәм бәһасе бермә-бер артык булса, икенчедән, гигант эшләр эшләнгән төбәктә шагыйрьнең хис һәм фикер масштаблары да киңәя.
Бездә шагыйрьләргә авылныкы яисә шәһәрнеке дип ярлык тагу гадәткә кереп бара. Кадыйр Сибгатуллинны да моңа кадәр авыл буразналарын, арыш шаулавын җырлаучы – әманәте һәм үз гаме булган шагыйрь дип атап йөртәләр иде.

Иске Чаллы бетми.
Ул үзгәрә.
Искесеннән үсә яңа Чаллы.
Елмая таш безнең куллар тигәч,
таш та аңлый безнең уйны, җанны.
Җимерүче итеп белми дөнья,
таный безне тик төзүче итеп.
Игенчеләр идек, терлекчеләр,
ташчылар да булып үсеп җиттек.

К. Сибгатуллинның шигърият кыры буйлап ярып килгән буразнасы менә шулай, бара-бара Чаллының киң проспектларына кереп тоташты. Ул элеккеге дәрт һәм илһам белән яңа шәһәр урамнары буйлап җырлап үтте, һәм, әйтергә кирәк, үзен авыл җырчысы гына дип түгел, катлаулы заманның үзәгендә кайнаучы, шул заман уйларын җырлаучы шагыйрь итеп танытты. Юк, К. Сибгатуллин иҗатына тематик яктан гына килеп карау һич тә дөрес булмас иде. Аның: «Үткән гомер биктә, капкаларга типмә», – дип, теләсә кайсы төбәктә яшәүче теләсә кайсы һөнәр ияләре ятлап алырлык фәлсәфи гыйбарәләре дә өч-дүрт җөмлә белән сурәт-образ ясап куя торган, рәссамнарга хас шигырьләре дә бар. Ләкин безнең өчен иң куанычлысы – ул заман җилләренә йөз куеп, заман авазына колак салып яши һәм иҗат итә.

Яңа Чаллы көн дә яңа җырын
көйләп тора,
уйнап,
җырлап тора.
Басу аны башак шавы белән
заводларга илтеп тоташтыра.

К. Сибгатуллинның соңгы еллардагы иҗаты да, нәкъ шул башак шавы кебек, үткән белән бүгенне, авыл белән шәһәрне тоташтыра, Чаллы биеклегеннән үрелеп, киләчәккә карый.
Ф. Гыйззәтуллина дөньяны энә күзе аша күзәтсә, Хәниф Хөснуллин аны теодолит күзләре белән манзара кыла.

Теодолиттан карый еракка ул,
Юнәлешне эзли турыга.
Безгә кирәк, кешеләргә кирәк
Геодезистлар кебек булырга.
Бас та үзең җирнең бер читенә,
Күңел күзең аша кара син:
Уртадамы, әллә кырыйдамы
Бу тормышта атлап барасың!

Хәниф Хөснуллин Чаллы төбәгендә туып үскән, шунда каләм чарлаган шагыйрь. Шуңа күрә дә ул бу якларга читтән килгән кайбер кешеләр кебек аһ-ваһ итеп шаккатып кына карамый, үз ягының, шул як кешеләренең язмышы турында борчылып, кайгыртып һәм горурланып яза.
Сабыр холыклы, һәр сүзен үлчәп, тамызып кына сөйләшә торган тыенкы хисле Ямаш Игәнәйнең беренче җыентыгы чыгу белән ук матбугатта аның турында төпле генә берничә мәкалә басылды. Әйе, Я. Игәнәй – сүзнең кадерен, тәмен, исен, төсен сизә торган, хисләрдә чама белә торган шагыйрь. Ул үз йөрәгенең иң нечкә кылларына кагылган нәрсәләр турында гына яза, борчылып, янып, тетрәнеп яза. Аның сигез юллык бер шигырен генә мисал итеп китерик.

Балачак. Кыш. Сугыш. Тәрәзәне
Бодай башаклары күмә иде.
Шул башаклар арасында йөргән
Әти күз алдына килә иде.
Сугыш бетте. Әти кайталмады.
Кырда күптән шаулап бодай үсә,
Тәрәзәгә генә бизәк булып
Бомбалар һәм ракеталар төшә.

Соң чиккәчә тыгыз эшләнгән бу шигырьгә Я. Игәнәйнең үз язмышы да, ил язмышы да, сугыш китергән афәтләр дә сыйган.
Вакыт-вакыт артык тыйнакланып китеп, Я. Игәнәй авыз тутырып бар куәткә кычкырасы урында ишетелер-ишетелмәс пышылдауга күчә, авылдан килеп, беренче тапкыр шәһәр театрына эләккән агай кебек, югалып кала. Сергей Михалков үзенең бер чыгышында: «Скромность – кратчайший путь к неизвестности», – дигән иде. Бу сүзләр турыдан-туры Я. Игәнәйгә атап әйтелгән кебек.
Рөстәм Мингалимовның үткән ел басылган «Ике авыл арасы» дигән әсәре «поэма» дип язып куелмаган булса да, ул идея һәм фикер йөге ягыннан шул жанрга туры килә. Шагыйрь бу әсәрендә дә зур тема һәм проблемаларга теше үтүен, аларны уңышлы чишә алуын исбат иткән, бүгенге дөньяның бар кайгы-борчуын, сөенеч-шатлыгын бер авыл карты җилкәсенә салып, аның җаны аша үткәреп күрсәткән.
Марс Шабаевның аксакаллар тавышы иңә башлаган мәгънәле уйланулары, Кави Латыйпның «Тел өчен» дигән фәлсәфи тукымалы шигыре, Фәнис Яруллинның тормыш матурлыгына, кеше батырлыгына, мәхәббәт сафлыгына дан җырлаган оптимистик мәдхияләре, Нури Арслановның бар яктан камил, төгәл эшләнгән традицион шигырь үрнәкләре, Гәрәй Рәхимнең бәләкәй генә әйберләрдән зур гомумиләштерү ясаган, бөҗәк белән Җир шарын янәшә куеп сөйләштергән әсәрләре узган ел поэзиясенең никадәр күпкырлы һәм бай икәнен күрсәтеп, аны бизәп торалар.
Иҗатында борылыш чорын, яңарыш чорын кичерүче Рәдиф Гатауллинның «Йөзүчеләр» һәм «Бабич» дип аталган озын шигырьләрен дә укучылар үзенчәлекле эзләнү, яңа кыйммәтләр, ачышлар табарга теләү юлындагы бер баскыч буларак кабул итәрләр дип уйлыйм.
Бүгенге шигъриятъ Роберт Миңнуллин һәм Марсель Галиев исемнәре дә башкалар арасында аерылып тора. Аларның беренчесе халык җырларына тартым йөгерек стиль белән үтә җитди

фикерләрне дә җылы юморга төреп бирә белсә, һәм шуның белән укучыны да, тамашачыны да үз авызына каратып тора алса, икенчесе исә, яшерен бер вәкарь белән, үз бәясен бик тә яхшы аңлап акварель буяулар белән, фәлсәфи үзәкле рәсем-шигырьләр ясый.

1981 елда яшь буын шагыйрьләр иҗаты дә байтак кына үсеш кичерде. Рәфикъ Юнысов, Газинур Моратов, Ркаил Зәйдуллин исемнәренең көн үткән саен колакка ятышрак була баруы, иҗат йөзләре ачыклана килүе әнә шул турыда сөйли. Яшь шагыйрьләр үтә образлы язалар, аларның шигырьләре Сабантуй сөлгесе кебек чуар, Сабантуй сөлгесе төсле җете ачык төсләргә бай, аларның шигырьләре Сабантуй сөлгесе сыман һәрчак бик югары эленгән була. Арада дөнья гаме сеңгән шигырьләр белән бергә ил-җир язмышын бер селтәнүдә хәл итәргә кыҗрап тотынганнары, үзеңне җир йөзендә кылынган һәрнәрсәгә: искән җилгә дә, тузган тузанга да, яуган кар-яңгырга да җаваплы итеп тоярга тырышкан әсәрләр дә шактый еш очрый. Яшь шагыйрьләр үткән тарих белән артык мавыгып, бүгенгене һәм киләчәкне дә онытып җибәргәлиләр. Әйтерсең киләчәкнең ачы җиленә җилкә куеп, үткәнгә йөз белән борылалар да артка караган килеш алга таба баралар. Тарих турында язу бүгенгене җырлауга караганда җиңелрәк, чөнки үткән вакыйгаларга инде анык бәя куелган, алар инде тарихи факт буларак та укучыда кызыксыну уяталар. Ә бүгенгене аңлау, бүгенге дөнья матавыкларыннан сөземтә чыгару шактый катлаулы нәрсә. Тарих ул иярләнгән ат булса, бүгенге көн – чабып барган кыргый юртак, аның сыртына бары кыюлар – куш йөрәклеләр генә менә ала.

1981 елда басылган шигъри әсәрләрнең бер өлешен без менә тиз-тиз генә булса да авыз итеп чыктык. Арада телгә һәм җанга ятышлыларын, күңелне кузгатырдайларын да күрдек, шулай ук тамактан үтмәстәйләрен, теш сындырырлыкларын да очраттык. Монысы әле авыз итеп карау, разведка ясау гына булды. Ул шигъри продукция арасында халык үзенең күңел сандыгына салып куярдайлары, үз исеменнән сөйләтердәйләре, үзе белән мәңгелеккә алып китәрдәйләре, һичшиксез, бар. Бу инде бүгенге поэзиябезнең ил гаме белән, ил язмышы белән яшәүче чын халыкчан поэзия икәнен, чын шагыйрьләргә бай поэзия икәнен тагын бер тапкыр раслый.

*1982*

# ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ҖИҢҮ – ИҢ ЗУР ҖИҢҮ

1985 елның май аенда мине партия өлкә комитетының идеология секретаре Рәис Беляев янына чакырдылар. «Тагын нинди гаебемне табып, кайсысы донос язды икән?» – дип, икеләнә-борчыла гына килеп кердем моның кабинетына. Ә ул мин бөтенләй уйламаган-көтмәгән эш белән чакырган икән. «СССР Язучылар союзыннан өч кешене Әфганстанга командировкага җибәрергә булганнар. Бездән бер язучы сорыйлар. Мылтык тотып сугышырга түгел, каләм белән яуга керергә... Әфганнарга Язучылар союзы оештыруда да ярдәм күрсәтергә кирәк. Син минем күз алдында Чаллыда Язучылар оешмасын аякка бастырган идең, димәк, тәҗрибәң бар... Иҗатыңа мая да туплап кайтырсың. Кыскасы, без Татарстаннан сине тәкъдим итәргә булдык. Үзең ничек уйлыйсың?» Әллә инде яшьлек юләрлеге чыгып бетмәгәнгә, әллә эткәйләрдән ишетеп, Әпсәләмов романнарын укып «сугыш романтикасы» белән саташып үскәнгә, кинәт кенә күңелем талпынып: «Мин риза! Барам», – дигәнемне сизми дә калдым. Рәис Кыямович өстәл тартмасыннан саллы гына альбом алып, аңа нидер язды да миңа сузды. «Менә бу альбомны Фикрәт Әхмәтҗанович Табиевка бирерсең. Беләсеңдер инде, ул СССРның Әфганстандагы тулы вәкаләтле илчесе бит. Миннән сәлам әйтерсең. Татарстанны онытып бетермәсен. Ә син юлга җыена тор, авылга кайтып, әти-әниең, туганнарың белән саубуллашып кил. Борчылып калмасыннар, мин сугышка түгел, Табиев янына барам, диген...»

1985 елның җәендә әфган сугышының иң кызган, «дошманнар»ның иң нык котырган чорында Казанда һәм Кабулда баштан узган хәлләрне киләчәктә иркенләп һәм тәфсилләп язармын әле. Ә бүген сүзем Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев турында...

Әфганстанга без өч кеше: төрекмән язучысы, академик Клыч Кулиев, Мәскәүдән Юрий Тарский һәм мин бардык. Кабул аэропортына килеп төшүгә, делегациябезне Әфганстандагы СССР илчелеге хезмәткәрләре каршы алды. Шулар арасыннан озын саргылт чәчле, саргылт мыеклысы мине озата йөриячәк икән. Исеме – Максим, фамилиясе – Пешков, бөтен килеш-килбәте белән койган да куйган Максим Горький инде. Ни гаҗәп, ул чыннан да Максим Горькийның оныгы булып чыкты. Монда илченең киңәшчесе булып эшли икән. Беренче булып сүзне ул башлады: «Табиев: «Казаннан килгән кунакны, безнең уртак якташыбызны, сиңа ышанып тапшырам», – дип әйтте. Фикрәт Әхмәтҗанович иртәгә сезнең делегацияне төштән соң кабул итәчәк». Кабулга килеп, Максим Горький оныгы белән очрашуга ук, мин инде бу сәфәргә чыгуымның никадәр мөһим һәм әһәмиятле эш икәнлеген аңлый башлагандай булдым.

Әфганстанда узган һәр санаулы көнне-сәгатьне мин көндәлегемә теркәп барырга тырыштым. Дөрес, иртәдән кичкә кадәр йә бронетранспортёрда чабып, йә хәрби самолётта яисә вертолётта очып, хәрби частьларда, госпитальләрдә, сәяси төрмәләрдә йөреп, ил җитәкчеләре белән очрашып, язучылар, солдатлар, офицерлар белән аралашып, көч-хәл белән ятакка кайтып егылгач, иркенләп язарга вакыт та җитенкерәми иде. Әмма дәфтәргә теркәгән кадәресе дә бер китапка җитәрлек җыелган икән...

Көндәлегемнең 24 июньдәге битендә мондый сүзләр язылган...

*...Кабулдагы СССР илчелеге биек койма белән әйләндереп алынган. Тышкы яктан – әфган солдатлары, эчтән безнекеләр саклый. Мәйданы бик зур, 18 гектар чамасы, чиста-пөхтә, яшеллек күп.*

*Ф. Ә. Табиев безне ачык йөз белән каршы алды. Казанда без белгән-күргән чактагыдан шактый олыгайган, йөзенә талчыгу, борчылу чалымнары кунган, әмма элекке егетлеген, «әтәчлеген» югалтмаган. Ярты сәгать чамасы Әфганстандагы бүгенге хәлләр, сәяси көрәш, илнең үткәне турында сөйләде. Илне нык өйрәнгәнлеге күренеп тора, үзе дә: «Әфганстан турында русча басылган бөтен китапларны укып чыктым», – ди. Әфган әдәбиятын, шагыйрьләрен, сәнгатен белеп сөйли. Моңа кадәр Әфганстан турында рус язучылары иҗат иткән әсәрләрнең беркатлы, примитив икәнен әйтеп узды. Прохановның әфганнар хакындагы китабын да сүтеп ыргытты. Клыч Кулиев белән дә бераз бәхәскә кереп алдылар. Клыч әфәнде илленче елларда Әфганстанда*

*илче киңәшчесе булып эшләгән, шуңа дари (фарсы) телен дә яхшы белә, әфганнар тормышыннан да шактый хәбәрдар. Ул әфган тормышына багышлап трилогия язуын, язып тәмамлагач, аның буенча «Төрекмән фильм»да алты серияле фильм төшерә башлаячакларын әйткәч һәм бу эштә әфганнар да катнаша алмасмы, дип сорагач, Фикрәт Әхмәтҗанович, гадәттәгечә, үзенең фикерен кистереп әйтте. «Сезнең ул китапларыгызданиләр язылысын чамалыйм мин. Кино куярга ашыкмасагыз иде. Әфганстанны илчелек тәрәзәсеннән карап кына аңлап булмый. Бөтенләй башка ил икән ул, без бөтенләй белмәгән, аңламаган, өйрәнмәгән халык икән ул әфганнар... Андый фильм төшерергә риза булмаячаклар алар. «Миссия в Кабуле» фильмын да кабул итмәделәр монда. Нәрсә-нәрсә, ә үзләренең бәяләрен яхшы белә ул халык. Клыч Кулиев әфган трилогиясен тиздән тәмамларга җыенуын әйткәч, Фикрәт әфәнде көлемсерәп болай диде: «Беренче ике китабын тәмамлый торыгыз, ә Апрель революциясеннән соң булган хәлләр турында язарга ашыкмагыз. Анысын, бәлки, соңрак, бергәләп язарбыз... Шушы ут эчендә ничә ел яшәп, мин дә аңлап бетермим әле мондагы катмарлы хәлләрне».*

Арада иң яше булсам да, Татарстаннан килгәнгәдер инде, Фикрәт Әхмәтҗанович миңа аерым игътибар күрсәтте. Рәис Беляев автограф язып җибәргән «Татар сәнгате» альбомын авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә озаклап, битен биткә актарып-карап чыкты. Ике юлдашыма җиткерергә теләгәндәй, татарның әдәбияты-сәнгатенең зурлыгын-бөеклеген дә ниндидер бер эчке горурлык белән әйтеп узды. Рәссамнардан Лотфулла Фәттаховны (үлгәнен ишетмәгән икән), Харис Якуповны искә алды, Фешинның җәсәден Америкадан Казанга кайтартуы турында сөйләде. Шагыйрь Хәсән Туфанны искә төшереп, аның турында «святой человек» дип әйтте. Сибгат Хәким белән әле хәзер дә хат алышалар икән, аның хәлен белеште (Сибгат ага авырып тора иде), Туфан Миңнуллин турында сорашты. Альбом актара-актара, үзенең әфган илендә икәнлеген дә, янында кемнәр утыруын да онытып, ул хыялында Татарстанга, татар иленә кайтып киткән, бер мәлгә татар дөньясына кереп чумган иде. Гаҗәеп оста оештыручы, мәртәбәле җитәкче, маһир сүз остасы-оратор һәм колачлы фикер иясе булса да, Фикрәт Табиевны мин әдәбият-сәнгатькә, милләт мәсьәләләренә мөкиббән киткән кеше дип әйтмәс идем. Ләкин үзенең туган туфрагыннан, Ватаныннан читкә тибәрелеп, ут эченә барып кергәч, ул да халык-милләт проблемаларына башкачарак карый башлаган, безгә – әдәбият-сәнгать әһелләренә якыная төшкән кебек тоелды шулчак миңа. Бәлки, ялгышканмындыр, бәлки, бу чит-ят җирдә, сугыш өермәсе эчендә ике татар баласының тәхетләр һәм дәрәҗәләрне бер мизгелгә онытып торып, ирексездән тигезләшеп алуы, бер-берсенә рухи якынаюы гына булгандыр. Әллә чыннан да Ватаннан аралар ерагайган саен, бер милләт балаларының күңелләре якыная баруы дөрес микән соң?

Моңа кадәр Казанда төрле җыелышларда һәм очрашуларда кат-кат күреп тә, радио-телевидение аша чыгышларын тыңлап та күңел төпкелләренә, безнең дәрәҗәгә төшә алмыйча, әллә кайда биектә, партия тәхетендә калган мәһабәт һәм буй җитмәс Табиев бу мизгелдә миңа кинәт кенә җиргә иңгән гади һәм олуг шәхес булып тоела башлаган иде. Чыннан да, кешенең чын асылын белер өчен тәхет белән генә түгел, ә сугыш (димәк, ләхет) белән дә сынап карау кирәктер, ахрысы.

Сәгать ярым чамасы шулай хыялга бирелә-бирелә әңгәмә корып утыргач, берзаманны илче кабинетына берәм-берәм зур-зур йолдызлы хәрбиләр керә башлады. «Генераллар җыела башлады, безгә рядовойларга китәргә вакыттыр», – дип, урыныннан кузгалды тәҗрибәле Клыч Кулиев. «Әфганстанда кунактан да зур кеше юк», – дип, Табиев та торып басты. Мин шунда инде күптән тел очында торган сүземне әйтеп калырга ашыктым: «Фикрәт Әхмәтҗанович, безне Бабрак Кармаль белән очраштыра алмассызмы икән? Монда кадәр килеп Бабракны күрмичә китү мәчеткә барып мулланы күрмәгән шикелле була бит инде». Табиев бераз гына уйланып торды да, махсус барысына да ишеттерергә теләгәндәй, хәрбиләрчә яңгыравык тавыш белән болай диде: «Эшләрбез аны. Кармаль у нас в кармане! Так ведь, друзья?!» Хәрбиләр дәррәү көлешкән арада, Табиев безне озата чыкты. Саубуллашканда, мине берәр көнне аерым гына кунакка килергә чакырды. «Вакытын Максим әйтер. Иркенләп татарча сөйләшеп утырырбыз», – диде ул.

Әфганстанда командировка вакытында без һәрвакыт Ф. Табиев кайгыртуын сизеп-тоеп тордык. К. Кулиев, өлкән кеше буларак, күп вакытын Кабулда уздырса, Ю. Тарский белән без ике ай

эчендә, фронт сызыкларын уза-уза, илне аркылыга-буйга йөреп чыктык. 4 июль көнне ил җитәкчесе Б. Кармаль белән дә очраштык. Билгеләнгән ярты сәгать урынына ике сәгатькә якын әңгәмә кордык. Б. Кармаль Әфганстанда татарлар яшәвен дә әйтте. Шул татарларны эзләп йөри торгач, хәтәр хәлләргә эләгеп, миңа дүрт көн хәрби госпитальдә ятып чыгарга да туры килде. Ярдәм кирәк булган саен, Максим Пешков аша Ф. Табиев белән хәбәрләшеп тордык. Аның бер сүзе безнең өчен теләсә кайсы ишекләрне һәм капкаларны ача, бөтен теләкләребезне чынга ашыра иде. Башкалардан аерылып тормас өчен, Ф. Табиев безгә хәрби киемнән йөрергә тәкъдим итте. Үз-үзеңне саклар өчен корал да бирделәр. Кабулда көндез ялгыз йөрү куркыныч, ә төн җитеп, караңгы төшкәч, чын мәгънәсендә атыш-кырылыш, сугыш башлана. Тәрәзәдән «юләр пуля» очып кермәсен дип, идәнгә ятып йоклыйбыз. Беркөнне илчелеккә барып керсәм, шаккаттым: ишегалдындагы машиналар җимерелеп, чәрдәкләнеп беткән, тәрәзәләрдәге пыялалар чәлпәрәмә килгән. Узган төнне «дошманнар» илчелеккә миномёттан атканнар икән. «Исегез китмәсен, мондый хәлләр көнаралаш булып тора монда», – диде миңа Фикрәт Әхмәтҗанович. «Дошманнарны кайчан җиңәрсез икән соң?» – дигәч, ул: «Иң авыры – дошманны дустан аеру монда. Көндез дус кебек, ә төн җитүгә, дошманга әверелергә мөмкин ул», – дип җавап кайтарды.
Дусны дошманнан аеру дигәннән, әфган телевидениесендә әңгәмә вакытында да бирделәр миңа ул сорауны. «Сезнең бездәге дошманнарга мөнәсәбәтегез ничек?» – дип сүз башлады телекорреспондент. Мин беразга югалып калдым, чөнки СССР Язучылар союзында безне сәясәткә катнашмаска, бары тик иҗат турында гына сүз алып барырга кисәтеп куйганнар иде. Ә сорауны җавапсыз калдырып булмый бит инде. Уйлап-уйлап тордым да: «Минем Әфганстанга беренче килүем. Шуңа күрә монда беркемне дә белмим, монда әлегә минем дусларым да, дошманнарым да юк. Мин – Татарстаннан, бөтен дошманнарым шунда, Казанда калды», – дип, шаяртып җавап бирдем. Ә Фикрәт Табиевның хәле минекенә караганда йөз, мең мәртәбә катлаулырак бит. Аңа дус-дошман мәсьәләсендә телекорреспондент каршында түгел, ә бөтен ил, ватан, дөнья җәмәгатьчелеге алдында җавап тотасы. Монда инде шаярып, мәзәк әйтеп кенә котылып булмый. Ф. Ә. Табиев бу олы һәм гаҗәеп катлаулы сынаудан да, үзенең һәм илнең дәрәҗәсен төшермичә, исән-сау чыкты. 1999 елда ул СССР дигән илне очсыз-кырыйсыз сугыштан коткарышты. Кем аңа ничек бәя бирә торгандыр, белмим, әмма мин моны татар холкының, татар акылының, татар каһарманлыгының, гомумән, татар ир-егетенең зур җиңүе дип атар идем. Үз илеңнең хатасын иң югары җитәкчеләргә исбатларга, үзеңнең хатаңны танырга көчең җитү һәм шул хатаны үз кулың белән төзәтүдән дә авыррак җиңү юктыр дөньяда! Бер җөмлә белән әйткәндә, үз-үзеңне җиңү, җиңелеп җиңү иде бу!

*2008*

# ТАБИГАТЬНЕҢ МОҢЛЫ БАЛАСЫ

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче еллары Түбән Кама шәһәренең гаҗәеп тә романтик, шагыйранә чоры булып күңелгә уелып калган. Һәр атнаны татарның иң күренекле шәхесләрен чакырып «Җидегән чишмә» кичәләре үткәрү дисеңме, шәһәрнең моңа кадәр юлбашчылар исемнәрен йөрткән үзәк урамнарына Сөембикә, Бакый Урманче исемнәре кушу, милли гимназияләр, мәктәпләр ачылу дисеңме – болар онытырлык түгел... Ул елларда Түбән Камада миңа ике кешенең берсе шагыйрь, композитор, җырчы яисә рәссам кебек тоела иде.
Шуңа күрәдерме, һәр санны диярлек район газетасында басылып килгән Рифкать Имаев шигырьләренә дә бик табигый бер хәл дип карадым кебек. Аннары ул шигырьләр җете ачык төсләр белән әллә каян чекерәеп тә тормыйлар иде. Болын чәчәкләре кебек гади, тыйнак шигырьләрнең нәзакәтлелеген, чын бәясен аңлау өчен шактый вакыт кирәк булган икән шул.
Шигырьләре кебек, Рифкать үзе дә бик тыйнак кеше. Әдәби мәҗлесләрдә дә түрдән урын дауламый, кичәләрдә дә чәчрәп сәхнәгә килеп чыкмый, китабымны бастырыгыз дип, нәшрият тупсаларын да таптап йөрми. Әмма тыйнаклыкның да бер чамасы булырга тиештер, югыйсә сине бөтенләй күрми, санга сукмый башлаулары да мөмкин.
Бөтенләй үк онытылмаса да, Рифкать тора-бара әдәби мохиттән шактый читләште. Мин инде аның элеккеге шигырьләрен яшьлек мавыгуы гына булгандыр, ул инде шигырьгә бөтенләй кул селтәгәндер, дип тә уйлый башлаган идем. Үзе бер шигырендә әйткәнчә:

Мин дә кулга каләм алам,
Бик язасы килгәндә;
Бүген һәркем шигырь яза,
Мин кешедән ким мәллә?

Моңа кадәр күпме эзләп тә таба алмаган, 1970–1980 елларда «Ялкын» журналында эшләгәндә хатларыма җавап та язмаган Рифкать көннәрдән бер көнне Түбән Камада минем янга үзе килеп керде. Ул инде шактый өлкәнәйгән, чәчләренең аксыл бөдрәләре басылган, бөтен кыяфәте белән дөнья кичкән ир уртасы кешегә әйләнеп калган иде. Әмма күзләрендәге моңсулык һәм ирен читләрендәге тыйнак елмаю сурәте генә югалмаган, нәкъ элеккечә сакланган. Култыгында – кабарып торган калын папка. «Мин сине инде чирек гасыр буе эзлим. Кайда югалып йөрисең?» – дигән соравыма ул салмак кына тавыш белән: «Менә шушы шигырьләрне язып яттым», – диде дә өстәлгә калын папкасын куйды.
Билгеле инде, ул гел шигырь язып кына ятмагандыр, химия төтене йотып заводта эшләгән кешенең тормышында әллә нинди мәшәкатьләр, кыенлыклар да булгандыр. Әмма Рифкать нишләптер болар хакында җәелеп китеп сөйләргә дә, кайберәүләр кебек иркенләп тормыш кыенлыкларыннан зарланырга да теләмәде. Гүяки аның өчен фани дөнья мәшәкатьләре мөһим нәрсә түгел, ә иң мөһиме, тормышының бөтен мәгънәсе һәм максаты култык астына кыстырылган шушы папкада, шигырьләрдә иде...
Ә инде өйгә кайтып, ул шигырьләр эченә кереп чумгач, мин Рифкатьнең хәлен аңладым, аның белән килештем, шигырь юлларына салынган язмыш елларын үз күңелем аша кичердем.
Шагыйрьләр бик күптөрле була. Алар арасында шигырь язучылар, шигырь ясаучылар, шигырь иҗат итүчеләр бар. Ә Рифкать боларның берсенә дә охшамаган, ул шигырьне язмый да, ясамый да, иҗат та итми, ул бары тик күңелдән саркып чыккан уй-хисләрен кәгазьгә теркәп кенә бара кебек. Шуңа күрә алар табигый дә, шуңа күрә алар болын чәчәкләре кебек тыйнак һәм нәзакәтле дә.
Кеше гомере буена үз янәшәсендәге адәм балаларын аңларга, алар белән уртак тел табарга, аларга якынаерга теләп яши. Бу – теләсә кайсы кешенең яшәү мәгънәсе. Әмма кеше күңелен, аның уй-хисләрен гади сүзләр белән генә берничек тә аңлатып булмый. Рифкать Имаевның шигырьләрен укыган саен, мин аның кайгылары белән кайгыра, аның шатлыклары белән шатлана бардым, аны

аңлый башладым, үз иттем, якын иттем. Мин үзем өчен тагын бер шагыйрьне ачтым, мин ихлас хисле тагын бер шагыйрьгә, гыйбрәтле бер язмышка баедым.

Сакла безне давыллардан,
Афәтләрдән, Ходаем!
Шатланам да, кайгырам да, –
Бәхетлемен, мөгаен... –

дип яза Рифкать Имаев. Дөньяда бәхетле кешеләр бик сирәк. Әмма мондый шигырьләр яза алган кеше, һичшиксез, бәхетле булырга тиеш!

*2004*

# «АСРАМАГА ШИГЫРЬ БИРӘМ...»

Соңгы елларда туган ягым Түбән Камага кайткан саен, мине ниндидер үзем дә аңламаган моңсулык баса, күңелемә, җаныма нидер җитми. Йортлар да үз урынында, дуслар, туганнар да бар, ә нигәдер күңелнең бер почмагы буш, бер чите китек...

Менә шушы җыентыкка керәчәк шигырьләрне кулга алып укыганда, күңелем сулкылдый башлагач, ниһаять, аңладым: миңа Түбән Камада, юк, Түбән Камада гына түгел, менә шушы якты дөньяда дустым Мөхәммәт, ак күңелле, риясыз табигатьле, шагыйрь җанлы Мөхәммәт Шәйхи җитми икән!

Бу каты бәгырьле, мәрхәмәтсез һәм кырыс яшәешкә Мөхәммәт, бер караганда, адашып, ялгыш килеп эләккән изге җан кебек тоела иде миңа. Шуңа күрә дә Түбән Камага кайтуга, мин, бөтен эшемне онытып, аның янына ашыга идем. Бер мин генә түгел, аны белгән бик күп мосафир Мөхәммәтнең җылы фатирында үзенең күшеккән күңелен җылытып, аның шигъри учагыннан җанына җылы алып киткәндер. Чынаякларга чәй ясагач, өстәлгә кәгазьләрен таратып сала да Мөхәммәт шигырь укырга тотына. Шигырьләрендә – халык язмышы, мәхәббәт газаплары, туган як моңы, яшәү һәм үлем мәгънәсе.

Мөхәммәт, кешегә ярдәм кирәк булганда, беркайчан да «юк» дип әйтә белми иде. Ярдәме дә күңел юаткыч коры сүз генә түгел, чөнки ул барысын да булдыра, аның кулыннан килмәгән эш юк. Кирәк икән, чалгы алып, болында каерып печәнен чаба, кирәк икән, балта тотып кәртинкәдәй өй сала... Ул авылларда әдәби кичәләр оештырып йөрүче дә, яшь шагыйрьләргә төпле киңәшләр бирүче киң күңелле остаз һәм мәрхәмәтле мөхәррир дә, шулар өстенә менә дигән рәссам да...

Мөхәммәт, Ходай Тәгалә биргән гомеренең бик кыска буласын сизгәндәй, һәрчак ашыгып эшләде, ашыгып язды, ашыгып яшәде. Бар нәрсәгә дә җитешәсе, бөтен җирдә дә буласы, бөтен эшләрен эшләп бетерәсе килә иде бугай аның. Күп нәрсәгә җитешсә дә, үз тормышын көйләргә, исән чакта китабын күрергә өлгерә алмый калды...

Җыентыкка кергән шигырьләрне Мөхәммәтнең үз авызыннан да кат-кат ишеткәнем бар иде. Әмма бүген алар миңа башкачарак яңгырый, бүген аларның мәгънәсе тагын да тирәнрәк, чөнки аларга ике дөнья фәлсәфәсе сыйган...

Гасыр башларында
Бу кадәрле
Авыр булмагандыр Тукайга да...
«Асрамага шигырь бирәм, шигырь,
Сәгъди абзый, җаным, син кайда?!»

Мөхәммәт Шәйхинең бу шигыре, гомумән, шигырь китабы киләчәк буыннарга атап язылган шагыйранә васыять кебек яңгырый. Шуңа күрә җыентыкка кергән һәр шигырь укучы күңеленә барып ирешер, Мөхәммәтнең шигырьләрен «асрамага алучылар» күп булыр дип ышанам.

*2001*

# ТУКАЙ БИЕКЛЕГЕ

Телем ачылганнан бирле шигырьләрен тыңлап, ә инде дөньяга күзем ачылгач, әсәрләрен укып үссәм дә, нишләптер мин Тукай иҗатына бик озак ияләштем, дөресрәге, аның биеклегенә күтәрелә алмаудан гаҗиз булып, күп еллар бу мәһабәт тау итәген әйләнеп йөрдем. Әле бүген, инде ике Тукай гомерен очлап килгән чорда да, һич кенә дә: «Мин Тукайны тулысынча аңладым, мин Тукайны беләм!» – дип авыз тутырып әйтә алмыйм. Бәлки, гомерем буе әйтә дә алмамдыр... Чөнки бу илаһи шәхеснең бөтен җан тирбәнешләрен, фикер зилзиләләрен аңлар өчен үзеңнең дә шуңа охшашрак зат булуың кирәктер.

Әмма, ни әйтсәң дә, еллар узган саен, мин үземнең әкрен-әкрен генә аңа якынлашканымны, көннән-көн аны ныграк төшенә барганымны тоям. Һәм шушы эчке тоем минем өчен Тукайны тагын да серлерәк, кадерлерәк итә...

Минем яраткан шагыйрьләрем шактый күп. Мин аларның кайберләрен өметсезлеккә бирелеп, күңелем гасабиланган чакларда укыйм, кайберләренең китапларын җаным күбәләккә әверелеп кояш нурларына кунып уйнаганда кулыма алып хозурланам. Ә Тукайны исә теләсә нинди халәттә, рухымның теләсә нинди әверелешендә дә укый алам, аннан ләззәт, хис-фикерләремә куәт табам.

Үз гомеремдә мин Тукайны инде берничә мәртәбә ачтым. Аның беренчесе «Шүрәле» һәм «Су анасы» сихеренә бирелеп, шулар белән бергә урман-елга буйларында уйнап үскән балачак елларыма туры килә, икенчесе, ахрысы, Әхмәт Фәйзи, Ибраһим Нуруллин романнарын укыгач булгандыр. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты, Алмаз Монасыйповның Тукай шигырьләренә язылган көй-моңнары да мине шагыйрь күңеленә якынайткандыр. Рәссам Фәйзерахман Әминев ясаган әкияти сурәтләр, серле-тылсымлы авыл табигате мине Тукай иҗатына беренче мәртәбә рәссам күзе белән карарга өйрәтте. Ә инде скульптор Рада Нигъмәтуллина сыннары белән очрашкач, бөек Тукайның бөтен тормыш юлы, иҗат дөньясы кинәт кенә җанланып, күз алдыма килеп баскандай булды.

Моңа кадәр дә төрле күргәзмәләрдә һәм остаханәләрдә Тукайның йөзләгән портретларын, дистәләгән сыннарын караган булсам да, Рада ханымның «Туган тел»не күкрәгенә кыскан нәни «Апуш»ын күргәч: «Менә бу чынлап та безнең Апуш!» – дип пышылдаганымны сизми дә калдым. Бөтен кыяфәтенә ихласлык иңгән бу нарасыйның күкрәгендәге «Туган тел», аның тәне белән берегеп, җанының, бәгыренең бер өлешенә әверелгән сыман. Юк, бу шагыйрь Тукайның гына түгел, ә минем дә, синең дә, һәммә ихлас татар малаеның да балачагы итеп кабул иттем мин ул балчыктан әвәләп ясалган гаҗәеп сынны. Әйе, Рада ханым Нигъмәтуллина үзенең сыннарын башкалар кебек граниттан, таштан яисә мәрмәрдән уеп-чокып ясамый. Аның материалы – Ходай Тәгалә тарафыннан сайланган үзле балчык. Әйтерсең ул үзенең иҗаты белән иң бөек Иҗатчының мәңгелек тылсымын кабатларга, дәвам итәргә омтыла...

Үзем белгән-күргән татар рәссамнары арасында Рада Нигъмәтуллинаны сын-сурәтләренең тышкы бизәлеше, колориты белән генә түгел, бөтен рәвеше, нур бөркеп торган эчке дөньясы белән чын мәгънәсендә татар рухын тасвирлый алган сирәк затларның берсе дисәм, ялгышмамдыр кебек. Ул сыннарда безнең халыкка хас нәзакәтлелек һәм уйчанлык та, шаянлык һәм чаялык та, үҗәтлек һәм тапкырлык та, хәйләкәрлек һәм батырлык та, тирән моң һәм бетмәс-төкәнмәс сагыш та бар. Һәм шул сыйфатларның һәммәсе өстенә Тукай иҗатына иксез-чиксез мәхәббәт, үз халкыңа бирелгәнлек тә килеп кушылгач, шагыйрь әсәрләре белән янәшә торырлык илаһият галереясы барлыкка килгән.

Рада Нигъмәтуллина иҗаты гадәти иҗат кына түгел. Аның иҗатташ рәссам кызлары – Изабелла белән Марина – Рада ханымны һәрчак күккә талпындырып торучы ике канаты кебек. Консерватория тәмамлап, музыкант булырга хыялланган бу ике хыялый кызның тора-бара әниләре тылсымына ияреп, сәнгать институтына барып керүләре, һәм бүген өчесе бер кеше, бер

җан булып үҗәтләнеп һәм канатланып иҗат итүләре Рада ханым Нигъмәтуллинаның чыннан да илаһи зат, олы Иҗатчы булуын тагын бер кат исбатлый кебек.
Һәм менә бүген мин, ниһаять, Тукай иҗатының чираттагы биеклегенә – өченче катына күтәрелдем бугай. Моның өчен мәшһүр сынчыбыз Рада Нигъмәтуллинага, аның тылсымлы иҗатына мең-мең рәхмәтлемен.

*2006*

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ МӘРХӘМӘТ ТАНТАНАСЫ

Теләсә кайсы кеше, авырлык килсә, дус-ишләренә, туганнарына таяна, берәр зур эшкә тотынса да, чит-ятларга түгел, ә иң элек менә шул якыннарына барып сыена. Кешеләр генә түгел, ыру-кавемнәр, халыклар һәм милләтләр дә борын-борыннан үз нәселләре, үз туганнары һәм кардәшләре белән иңгә-иң куеп, ярдәмләшеп яшәгәннәр. Шундый бердәмлекне, якынлыкны саклаган ырулар гына гасырлар кичеп бүгенге көнгә кадәр исән-имин килеп җиткән, мөстәкыйль дәүләтләр төзеп, дөнья мәйданында үз урынын алган.
«Халыклар төрмәсе» дип аталган патша Россиясе күпме генә тырышса да, уртак телле төрки халыкларның бер-берсенә тартылу көчен җиңә алмаган. Беренче мөмкинлек чыгу белән, кардәш халыклар арасындагы бәйләнешләр күзгә күренеп көчәйгән, күңел түрендә йомылып яткан туганлык хисләре җырлар һәм шигырьләр, газета һәм журналлар булып ике арада йөри башлаган. Гадәттә, татарның зыялы затлары төрки телләрдә җиңел аралашкан, шуның өстенә гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белгән. Мәсәлән, Габдулла Тукай төрек, азәрбайҗан, казах, рус әдәбияты белән даими кызыксынып торган, аларны үз телләрендә укыган. Тукайның үз әсәрләре дә ул чордагы төрки халыкларга тәрҗемәсез дә аңлашылган. Борын-борыннан килгән рухи якынлык, һәрдаим аралашып яшәү, уртак имляда язу төрки телләрне бер җепкә тезеп, чәчми-түкми, таратмый саклап килгән. Кардәш төрки халыкларның рухи бердәмлеген ныгытуда бөек мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралы чыгарган мәшһүр «Тәрҗеман» газетасының әһәмияте гаять зур булган. Төрки дөньясының һәр зыялы гаиләсе, мәктәп-мәдрәсәләре, милли җәмгыятьләре һәм китапханәләре бу газетаны алдырган, тора-бара ул төрки дөньяны туплап торучы рухи үзәккә, арадашчыга әверелгән.
Мәшһүр төрек язучысы Нәҗип Фазыл Кысакүрәкнең «Мәрхәмәт» әсәрен укыган вакытта мин, үзем дә сизмичә, менә шулай тарихыбызга сәяхәт кылгандай булдым, бүгенге вазгыятебезне күз алдыннан кичереп, уфтанып куйдым. Егерменче гасыр башындагы инкыйлаблардан соң илебезнең чикләре ябылып, дөньяга чыга алмыйча яшәгәндә, СССРдан читтәге төрки дөньядан аерылуыбызның сәбәпләре билгеле. Ләкин чикләр ачылып, аралашу өчен шактый мөмкинлекләр туугa да инде егерме еллап вакыт узса да, артык зур үзгәрешләр күренмәде. Ә нигә бирелгән мөмкинлекләрдән файдаланмыйбыз? Нигә кардәш халыклар белән театр гастрольләре алмашмыйбыз, җырчыларыбызның, артистларыбызның иҗат турларын оештырмыйбыз, фольклор ансамбльләрен, рәссамнарыбызны бер-беребезгә чакырышмыйбыз, һәм, ниһаять, ни өчен язучыларыбызның, шагыйрьләрнең әсәрләрен бер-беребезнең укучыларына җиткермибез? Мин монда әллә нигә бер оештырылучы чаралар хакында түгел, һәр көн, һәр атна, һәр ай эшләнә торган даими, эзлекле эш, хәрәкәт турында сүз алып барам. Ә кардәш халыкның рухи хәзинәсе безгә аерата якын, аны күрмичә, белмичә яшәү, аның белән үз рухи хәзинәңне баетмау ахмаклык дип саналырга хаклы.
Төрекнең күренекле язучыларын бүген Европа илләрендә дә, шәрекътә дә, хәтта Америкада да яхшы беләләр, алар арасында халыкара бүләкләр, хәтта Нобель премиясе алган әдипләр бар. Төрек язучыларын дөньяның йөзләгән телләренә тәрҗемә итәләр, укыйлар. Ә без, үзебезне кардәш кавем санап та, Тукайдан соң узган йөз елда ничә төрек әдибен татарчага күчерә алдык икән? Төрекнең мәшһүр җырчылары бүген бөтен дөнья буйлап гастрольләргә йөри, ә безгә нигә килми алар? «Әйтсәң – сүз, төртсәң – күз» дигәндәй, мондый мисалларны күпләп санап булыр иде. Халкыбызның Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Туфан кебек бөек шагыйрьләрен, Муса Бигиев, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин кебек мәшһүр фикер ияләрен, классик драматургларыбызны, композиторларыбызны, җырчыларыбызны, рәссамнарыбызны да без әле башка халыкларга тиешле дәрәҗәдә күрсәтә, дөнья мәйданына чыгара алмыйбыз.
Моннан берничә ел элек Асия Рәхимова төрек язучылары әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, нәшриятта чыгаргач, күңелләрдә өмет уянып, бераз җиңел сулап куйган идек. Әмма, ни сәбәпледер, аның бу күркәм үрнәген күтәреп алучы, дәвам итүче булмады. Дөрес, Аяз

Гыйләҗевнең төрек теле укытучысы Фатыйх Котлу тарафыннан тәрҗемә ителгән «Өч аршын җир» әсәре төрек язучылары һәм укучылары тарафыннан бик җылы каршы алынды. «Кунак ашы – кара каршы» дигәндәй, безгә дә җавап итеп шундый ук гамәл кылу кирәк иде дә бит югыйсә... Һәм ничә еллар көтеп-көтеп тә өч йөз татар язучысының берсе дә бу эшкә тотынмагач, галимә Асия Рәхимова төрек әдәбиятының тагын бер үрнәген тәрҗемә итеп, татар укучысы хөкеменә тапшырырга булды.

Әлеге «Мәрхәмәт» әсәрендә сүз Акыл белән Хис, дөресрәге, Акыл хакыйкате белән Хис хакыйкате, Канун дөреслеге белән Күңел, Әхлак дөреслеге хакында бара. Гомере буе «язылган законнар» буенча кешеләргә хөкем карары чыгарып килгән мәртәбәле мәхкәмә рәисе бик зур хата җибәрә: шаһитларның ялган дәлилләренә таянып, бер гаепсез егетне дар агачына астыра. Ә инде бераздан егетнең гаепсезлеге раслангач, ул вөҗдан газаплары кичерә башлый. Моңа кадәр рәхим-шәфкатьнең, кызгану хисенең, мәрхәмәтнең нәрсә икәнен дә белмәгән, бары тик канун күрсәткән хакыйкатькә генә табынып яшәгән мәхкәмә рәисенең кинәт кенә күзләре ачылып киткәндәй була. Баксаң, дөнья белән, кешеләр белән, Канун һәм Акыл гына түгел, ә кызгану, ярату, оялу, хөрмәт итү кебек хисләр дә, димәк, «язылмаган законнар»да идарә итә икән, кешенең рухи дөньясы акыл дөньясына караганда да баерак икән! Автор беркайчан да искерми торган бу мәңгелек теманы гаҗәеп нечкә психологик кичерешләр аша шулкадәр оста итеп сурәтли ки, әсәрнең моннан ярты гасыр элек иҗат ителгәнен онытып, аны әле генә язылган заманча роман укыгандай рәхәтләнеп укыйсың, Мәрхәмәт һәм Мәхәббәт тантанасының шаһиты буласың. Бу китап дөньяга чыкканнан соң, бер талантлы режиссер аны үз күңеле аша үткәреп, сәхнәгә куйса, минемчә, ул тамашачыларны һич тә битараф калдырмас иде.

Шушы бер «Мәрхәмәт» әсәрен укып чыгу гына да күңел түрендә яткан күпме хисләрне кузгатып, кешеләр язмышы, халыклар, илләр язмышы хакында уйланырга мәҗбүр итте. Без бер-беребезгә шулкадәр якын да, охшаш та һәм шул ук вакытта шактый ук үзенчәлекле дә икәнбез ләбаса. Без бары тик бер-беребезне озак вакыт күрмичә торып, яңадан очрашканбыз да, күңелгә хисләр тулышудан нәрсә әйтергә, нишләргә белмичә, беркавымга телсез калганбыз кебек. Мондый хәлдә озак тору ярамас, тизрәк сүз башлап, хәлләрне белешергә дә эшкә тотынырга кирәк. Ике арадагы өзелгән юлларны ялгау, җимерелгән күперләрне торгызу өчен безгә әле бик күп эшләргә кирәк булачак. Ә бу китапны («Мәрхәмәт». ТКН, 2009), бу әсәрне шул юлга салынган тәүге ташларның берсе дип санарга мөмкиндер.

*2009*

# БӘХЕТЛЕ ТАЛАНТ

Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов әсәрләрен караган саен, француз язучысы С. Экзюпериның «Нәни принц» әкиятендәге бер вакыйга искә төшә.

Экзюпери бала чакта үзенең беренче рәсемен ясагач, аны олыларга күрсәтә дә:

– Сезгә бик куркыныч түгелме? – дип сорый.

– Эшләпәнең нәрсәсеннән куркасың? – диләр аңа.

Ә ул бөтенләй эшләпә түгел, фил йоткан елан рәсеме була.

Сәнгать әсәренә куела торган төп критерийны бөек язучы балалар теле белән әнә ничек гади һәм төгәл итеп аңлатып биргән.

Чыннан да, рәссам өчен, рәссам иҗаты өчен иң мөһим сыйфат – аның эчке дөньясы, рухи дөньясы бай булу. Сәнгать әсәре ул кеше кебек. Аңа тышкы матурлыктан битәр хис-тәэссоратлар, уй-фикерләр, гомумән, эчке матурлык, рухи байлык, тирәнлек кирәк. Билгеле, осталыктан башка бу сыйфатларга ирешеп булмый. Ләкин еллар үткән саен, сәләт чаткысы булган кеше тырышлык һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә осталык серләрен үзләштерә ала. Ә менә инде рухи дөнья байлыгына ия булу катлаулырак нәрсә. Моның өчен тумыштан килгән талант та, син яшәгән мохитнең иҗади булуы да, яшәеш законнарын үзләштерү дә, сәнгать тарихын өйрәнү һ. б. бик күп шартлар да кирәк.

Бу яктан алганда, Тавил Хаҗиәхмәтов – бәхетле язмышка, бәхетле талантка ия булган рәссам.

Саба районының Йосыф-Алан авылында туган Тавил дөньяны танып белә башлаган көннәреннән үк табигать матурлыгын, тырыш хезмәт кешеләрен күреп үсә. Малай көннәр буе болыннарда, урманнарда йөри, һәр яфракның, һәр чәчәкнең гүзәллеген күреп соклана, ә күккә ашкан нарат-карагайлар аның хыялларын көннән-көн биеккәрәк күтәрә.

Тавилның әтисе Гыйният агай тирә-якта танылган ювелир була. Ул көмештән беләзекләр, йөзекләр, муенсалар, алкалар коя, аларга үз күңелендәге бизәкләрне төшерә. Тавил да һәрчак аның янында бөтерелә.

Туган як табигатеннән үз җанына иңгән матурлык, әтисеннән күчкән маһирлык, тырышлык, үҗәтлек һәм хыялыйлык рәссам өчен гомер буена җитәрлек байлыкка әверелә. Казан сәнгать училищесында укыганда да, И. Е. Репин исемендәге Ленинград сәнгать институтында олуг рәссамнардан, атаклы академиклардан белем алганда да, шул балачак оеткысы аның талантына этәргеч бирә, һәрчак канатландырып-рухландырып тора, теләсә нинди авырлыкны җиңәргә ярдәм итә.

Иҗатының беренче чорында төрле жанрларда көч сынап караса да, тора-бара графика, бигрәк тә гравюра рәссамны бөтенләе белән диярлек үз дөньясына алып кереп китә.

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романына ясаган иллюстрацияләре белән уңышлы диплом яклагач, инде үз иҗат манерасы формалашкан, максаты, рухи кыйбласы булган рәссам 1963 елда Казанга кайта. Ул елларда татар нәкыш сәнгате (живопись) шактый гына уңышларга ирешкән булса да, графика, бигрәк тә китап бизәү сәнгате әле һаман башлангыч, балалык чорын гына кичерә. Шуңа күрә яшь графикны Казанда дүрткуллап каршы алалар.

Тавил Хаҗиәхмәтов нинди генә эшкә алынса да, аны җиренә җиткереп эшләргә ярата. Шунлыктандыр, инде катлаулы әсәрләргә иллюстрация ясау тәҗрибәсе булуга карамастан, ул, турыдан-туры китап нәшриятына килмичә, «Яшь ленинчы» газетасына эшкә урнаша, «Ялкын» журналына рәсемнәр ясый. Вакытлы матбугатта катнашу аңа бүгенге дөньяны, бүгенге балалар, яшүсмерләр дөньясын бөтен барлыгы белән аңларга ярдәм итсә, көндәлек заказлар рәссамны һәрчак активлыкта тота, осталыгын тагын да камилләштерә. Монда рәссам көн саен диярлек үз коллегаларының фикерен ишетеп тора, рәсемнәре турында укучылардан хатлар ала. Кыскасы, вакытлы матбугат Тавил Хаҗиәхмәтов өчен үзенчәлекле бер мәктәпкә әйләнә.

1966 елдан рәссам даими рәвештә «Ялкын» журналын бизәүдә катнашып килә. Журнал рәссамының бурычлары гади рәссамныкына караганда күпкә катлаулырак. Беренчедән, сурәт

әдәби әсәрнең эчтәлегенә тәңгәл килергә, аның рухын чагылдырырга тиеш булса, икенчедән, аның гомумжурнал композициясенә сыешуы да шарт. Журнал бизәүдә берьюлы дистәләгән рәссам катнаша, димәк, аларның иҗат манерасын белергә һәм алар белән дә исәпләшергә кирәк.
Балалар журналының төп бурычы – яшь буынны идея һәм эстетик яктан тәрбияләү. Т. Хаҗиәхмәтов ясаган тышлыкларның, иллюстрацияләрнең һәрберсе шушы максатны яхшы аңлап иҗат ителгән. Рәссам һәр тышлыкны, һәр сурәтне журнал таләпләренә җавап бирерлек һәм шул ук вакытта үткәннәрен кабатламаслык итеп эшли. Чорыбызның бөек төзелешләрен чагылдырган тышлыкларда бәйрәмчә, тантаналы плакат алымын кулланса, табигать күренешләрен сурәтләгәндә ул һәр чәчәкне, һәр үләнне ювелирларча җентекләп ясый, гади күзгә чалынмый торган матурлыкны күпертеп, зурайтып күрсәтә. Бу гиперболик алым рәссам иҗатында бик еш кабатлана. Ләкин аның «күпертүләре» берчакта да, чамадан узып, арзанлы карикатурага әйләнми.
Журнал-китап бизәүче рәссамга төрле жанрдагы һәм төрле чорга караган әдәби әсәрләр белән эш итәргә туры килә. Дөрес, иҗатларын аерым бер тарихи вакыйгаларга яисә шәхесләргә багышлаган рәссамнар да бар. Ләкин тулы бер тарихи чорны үз күңелең аша үткәреп, аны башкаларга да сәнгать телендә сөйләү теләсә кем кулыннан килә торган эш түгел.
Т. Хаҗиәхмәтов иҗаты белән тулысынча танышып чыккач, аның төрлелегенә, офык киңлегенә шаккатасың. Бүгенге тормышның, яшәешнең бар матурлыгын, замандашыбыз батырлыгын, гигант төзелешләрне сурәтләгән рәссам кинәт кенә Пугачёв яулары шаулаган заманга барып чыга («Канкай углы Бәхтияр» спектакленә ясалган костюм эскизлары) яисә ул «Йосыф белән Зөләйха» кыйссасын сурәтләп, күңел түрендәге иң нечкә кылларга кагыла. Рәссам, тарихи вакыйгаларны сурәтләгәндә, шул вакыйганың төбенә төшәргә, аның моңа кадәр кешеләр аңламаган мәгънәсен аңларга тырыша. Тарихи шәхесләргә ул музей экспонаты итеп карамый, ә бәлки кешеләр күңелендәге мәңгелек сыйфатларны эзләп таба. Шуңа күрә дә «Йосыф белән Зөләйха» картиналары виньетка эчендәге тарихи сурәт булып түгел, ә мәңгелек мәхәббәт символы булып күзаллана, шуңа күрә Тукай чорындагы балаларны бүгенге яшьтәшләре үз итәләр, якын күрәләр.
Рәссам халкыбыз, илебез узган катлаулы тарихны тулысы белән аңларга, һәр вакыйганың алшартын ачыкларга, ул чордагы сәнгать торышын күзалларга тырыша. Шулай итеп ул татар нәкыш сәнгатенең тамырларын, традициясен эзли, аның гносеологиясен өйрәнә. Әлеге эзләнүләр вакытында аның көннән-көн иҗат офыклары киңәя, осталыгы арта бара.
«Һәр рәссам халыктан, халык иҗатыннан чыгарга тиеш, – ди Т. Хаҗиәхмәтов. – Шулай булганда гына халык аны үзенеке итәчәк. Музейларда, күргәзмә залларында тәрбияләнеп, зәвыкларын формалаштырып, халык иҗатына фольклор элементы итеп кенә караган рәссам беркайчан да халыкныкы була алмаячак. Чөнки без иҗат иткән алымнарның, манераларның барысы да, башлангыч, яралгы хәлендә булса да, халык иҗатында чагылыш тапкан. Безгә бары тик аларны таба белергә һәм рухи багаж итеп алырга гына кирәк».
Т. Хаҗиәхмәтовның иҗат уңышларының тагын бер сере – аның эзләнүчән натура булуында. Бөек Октябрь революциясеннән соң илебез узган чорны ул бары тик үзенә генә хас эзлеклелек белән сурәтләде. Беренче рус революциясен Тукай әсәрләре аша тасвирласа, Совет властеның тәүге елларын Г. Ибраһимов, М. Җәлил китапларына ясаган иллюстрацияләр аша күрсәтте. Ә Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллар рәссам бизәгән берничә дистә китапта чагылыш тапты. С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле сувенир җыентыгы исә бу сериянең кульминациясе булып, аны йомгаклап тора.
СССР язучыларының VI съездында С. Михалков балалар һәм яшүсмерләр өчен иҗат ителгән әсәрләрнең бәйрәмчә, күтәренке рухта булырга тиешлеге турында әйткән иде. «Эш беткәч уйнарга ярый» (Г. Тукай), «Тылсымлы көзге» (Ш. Галиев), «Җырларым» (М. Җәлил), «Сандугач һәм Чишмә» (М. Җәлил), «Күңелле Сабантуй» (Җ. Тәрҗеманов), «Курай-малай маҗаралары» (Р. Хафизова), «Халык әйтсә, хак әйтә» һәм башка бик күп китапларның бизәлеше бу таләпкә тулысынча җавап бирә. Рәссамның орнаменталь стиле, җылы, якты төсләр белән берләшеп, китапка камиллек өсти, бөтенлек бирә. Бу китаплар гүзәл архитектуралы бинага охшап тора; син әйтерсең китап ачмыйсың, ә серле әкият сараена килеп керәсең.

Т. Хаҗиәхмәтов китап бизәүче рәссам гына түгел. Ул иҗат иткән «Оргсинтез» сериясе, инде 60 нчы елларда ук төрле күргәзмәләргә куелып, югары бәя алган иде. Акварель белән ясалган пейзажлар, «Хезмәт Батыры» сериясендәге гравюралар, Курчак театрында Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкиятенә эшләнгән курчаклар һәм сәхнә бизәлеше, «Кол Гали» (Н. Фәттах) спектакленә ясаган костюм эскизлары республикабыз сәнгате өлкәсендә зур вакыйга буларак кабул ителделәр.

*1977*

# БУЯУЛАР БЕЛӘН ЧИГҮ ЧИГӘ

Еллар үтеп, олыгая барган саен, кеше үзенең балачагын һаман ныграк сагына. Сабый чакның агач атлары, бетмәс-төкәнмәс уеннары, иксез-чиксез хыяллары, вакыт томанына төрелеп, тагын да серлерәк булып күренә башлый. Шуңа күрә, үткәннәрне искә төшергәндә, күңеле нечкәрмәгән, уйлары сафланмаган кеше юктыр. Рәссам Илдар Зарипов картиналарын караганда, моңа тагын бер кат ышанасың.

Кешеләрне ярату, хөрмәт итү һәр сәнгатьнең иң төп бурычларыннан берсе булырга тиеш. Бу хис Илдар Зарипов иҗатында аеруча яхшы күренә. Рәссам моның өчен бөтен мөмкинлекләрне дә файдаланырга омтыла. Шуңа күрә ул үзенең геройларын аңлы рәвештә – иң гади шартларга куеп сурәтли. Бу урын күбесенчә авыл өе була. Шушы кечкенә генә мәйданга һәм гадәти предметларга Илдар Зарипов зур сабырлык һәм осталык белән мул итеп күңел пакьлеген, җан җылысын күчерә. Бу максатка ирешү өчен ул хәтта пространствоны да кыса төшеп, яссырак итеп ала. Чөнки рәссам үз хисләрен шулай бер җиргә җыеп, туплап бирергә тели. Ачык төсле җылы буяулар бу максатка ирешүдә аңа ярдәм итәләр, картинага бәйрәм рухы һәм яктылык өстиләр. «Бишек», «Әңгәмә», «Казан сылуы Зөлфия», «Бәйрәм», «Нефтьче Әхәт абый», «Остаханәм», «Өйдә» әсәрләрендә Илдар Зарипов геройларының күңеленә, җанына үтеп кереп, аларның матурлыгын, иң нечкә хисләрен күрсәтсә, «Татарстан кешеләре», «Сугыш чоры хатын-кызлары» серияләрендә ул замандашларыбызны кайнап торган тормыш эчендә тасвирлый, авыр еллар хатирәсен күз алдына китереп бастыра. Монда инде рәссамның нык кулы, масштаблы фикере, фәлсәфи уйлары төс булып, рәсем булып киндер өстенә ята.

Илдар Зарипов җирдәге муллыкны һәм шул муллыкны тудыручы кодрәтле һәм куәтле кешеләрне ярата. «Татарстан кешеләре» сериясендә бу бигрәк та ачык күренә. Таза бәдәнле, нык гәүдәле ирләрнең йөзендә үз-үзенә ышаныч хисе, эшләгән эшләре белән горурлану тойгысы ярылып ята. Рәссам аларны эш процессында да күрсәтми югыйсә. Ләкин бу кешеләрнең кытыршы кулларына, сәламәтлек һәм куәт бөркелеп торган килеш-килбәтләренә күз салгач, колакларга хезмәт шавы, тормыш авазы ишетелгәндәй була. Аннары индустриаль пейзаж элементлары белән артык мавыкмыйча, иң алгы планга шул төзелешнең төп хуҗасын кую хезмәт кешесен калкурак итеп сурәтләргә ярдәм итә. Илдар Зарипов моның белән кешенең табигатьтән өстен булуын тагын бер тапкыр раслый, хезмәт кешесенә мәдхия җырлый.

«Сугыш чоры хатын-кызлары» сериясенә характерлар төрлелеге һәм куәтле драматизм хас. Бу әсәрләрдә без рәссам талантының бөтенләй икенче ягын күрәбез. Монда авторның элеккеге сабырлыгы, төсләр нәфислеге әллә кая юкка чыккан. Дошманга нәфрәт хисе белән янган хатыннарның һәр мускулы соңгы чиккә җитеп киерелгән, күзләр – сагыш һәм өмет белән мөлдерәмә тулы. Яраланып кайткан ир, бу афәтләрнең тере дәлиле булып, сугышның кешеләргә күпме кайгы-газап китерүен тәкрарлап тора.

Илдар Зарипов гадәттә серияле картиналар иҗат итә. Бу – аның киң масштаблы фикер йөртүеннән, үзе алган һәр теманы мөмкин кадәр киңрәк, тулырак ачарга тырышуыннан килә. Рәссам үзенең иҗат осталыгын үстерү өстендә дә бик күп эшли. Мәскәүнең Суриков исемендәге сәнгать институтында укыган чакта ук инде ул татар рәсем сәнгатенең милли традицияләре турында ныклап уйлана башлый. Белгәнебезчә, бездә бу сәнгать Октябрь революциясеннән соң гына профессиональ дәрәҗәгә җитеп үсте. Ләкин халык осталары беркайчан да кул кушырып утырмаган: чуклый-чуклый сөлгеләр тукыган, нәкышлар уеп, күз явын алырдай капкалар җиткезгән, йортлар салган, кич утырып челтәр бәйләгән, чигү чиккән, палас суккан. Илдар Зарипов, дөньяның атаклы рәссамнары мирасы белән яхшылап танышкач, осталык туплагач, татар халык иҗатын өйрәнә башлый. Милли традицияләрнең иң кыйммәтлеләрен, иң күркәмнәрен үз күңеленә күчерергә тели рәссам. Озакламый ул шактый зур уңышларга да ирешә. Аның полотноларына карагач, үзең дә сизмәстән, әлеге халык осталарын искә төшерәсең. Юк, Илдар Зарипов милли колорит белән генә татар сәнгатенең үз йөзен тудырып булмаячагын яхшы

аңлый. Милли традиция ул иң элек шул халыкның эчке рухын, уй-фикерләрен, холык-фигылен ачу дигән сүз. Илдар Зариповның һәр картинасында халкыбызга хас булган иң төп билгеләр: эшчәнлек, пөхтәлек һәм батырлык бик ачык чагыла. Ул һәр буяуны, һәр төсне шундый саклык һәм сабырлык белән бер-берсенә үрә ки, әйтерсең төсләр, буяулар белән чигү чигә.
Рәссам Илдар Зарипов – һәрчак тормышның үзәгендә, кайнап торган җирендә. Аның әсәрләрендә нефтьчеләрне дә, иген игүчеләрне дә, авиаторларны да күрергә мөмкин. Заман рухын тоеп иҗат итү рәссамның әсәрләрен халыкка, кешеләргә тагын да ныграк якынайта. Ул дистәләгән республика, Бөтенроссия, Бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнашып уңай бәя алды. «Бишек» картинасы өчен 1972 елда ВЛКСМ Үзәк Комитеты премиясенә лаек булды. 1970 елда «Өйдә» әсәре Ленинградтагы Рус сәнгать музееның даими экспозициясенә кабул ителде. Рәссам әсәрләре АКШ, ГДР, ЧССР, Польша кебек чит илләрдә дә күрсәтелде.
Габдулла Тукай, үз заманында татар сәнгатенең киләчәге турында кайгыртып: «...ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып, Шүрәленең кәкре борынын, озын бармак, мөгезле башларын һәм кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кылып чыгарырлар», – дип язган. Бөек шагыйрьнең хыялы бүгенге көндә тулысынча тормышка ашты: шүрәлеләрне генә түгел, тормышның бөтен якларын, заманның бөеклеген раслаучы «маһир» рәссамнарыбыз, үсеп чыгып, бөтен республикага, илгә танылды, дөнья аренасына чыкты. Илдар Зарипов – шундый рәссамнарның берсе.

*1976*

# «ҖЫРЛАРЫМНАН БЕЛЕРСЕҢ...»

Самолёт бетон юл буйлап бар көченә чабып барды-барды да, кинәт кенә талпынып, җирдән аерылды. Әле генә янәшәдә тезелеп торган мәһабәт йортлар, озата килгән кешеләр аска убылып төшеп киткәндәй булды. Менә самолёт канатларына болыт «пәрәвезләре» уралды, дөнья караңгыланып китте. Күңелгә шом салган бу кара болытлар эченнән мәңге чыгып булмас кебек тоела башлады. Шул арада тирә-юнь яктырып китте: офык түрендә, алтын таҗын ялтыратып, кояш елмаеп тора иде.

Зилә кояш нурларыннан чагылган күзләрен бер мизгелгә чытырдатып йомды, йөрәге, уч төбенә кысып тоткан кош кебек, талпынып куйды. «Нәкъ сәхнәгә чыккан кебек, – дип уйлады ул. – Сәхнәгә чыкканда да шулай җирдән аерылган кебек буласың: әйтерсең атлап түгел, ә очып, йөзеп йөрисең. Рампа утлары да нәкъ кояш кебек күзләргә нур бөрки, йөрәгең дә нәкъ менә шулай ярсып-ярсып тибә башлый».

Зилә инде күптән, беренче класста укыган чакта ук булган хәлне искә төшереп, елмаеп куйды.

Әле яңа гына мәктәпкә аяк басучы балалар «Саумы, мәктәп!» дигән нәни генә спектакль әзерлиләр иде. Мәктәпкә бару зур сөенеч булса да, көне буе бергә уйный торган маэмай белән мыраубикәдән, ияләшкән курчаклардан аерылу бигүк җиңел түгел шул. Зилә менә шул турыда уйларга, курчаклары белән саубуллашканда еларга тиеш. Ләкин ничә тапкыр репетиция ясасалар да, аның күзеннән яшь чыкмый гына бит. Менә беренче сентябрь килеп тә җитте. Зилә киенеп-ясанып мәктәпкә килде. Спектакль башланганда, йөзе балкып тора иде аның. Тик, сәхнәгә чыгып, бераз вакыт узуга, көтелмәгән хәл булды... Беренче класста укый башлавы белән котлап, сәхнәдән «әтисе» аңа гаҗәеп матур курчак бүләк итте. Аннары: «Син зур үстең инде, курчагың менә монда торып торсын, мәктәптән кайткач, дәресләреңне әзерләгәч уйнарсың», – дип, аны шкаф өстенә үк утыртып куйды. Шулчак кинәт кенә Зиләнең күңеле тулды һәм ул, үзе дә сизмәстән, кычкырып елап җибәрде.

Спектакль тәмамлангач, укытучы апалары йөгереп килде дә:

– Рәхмәт, Зилә, булдырдың, чын артист чыгачак синнән! – дип, аның башыннан сыйпады.

Зилә Сөнгатуллина, уйларыннан арынып, самолётның түгәрәк тәрәзәсеннән аска карады. Болыт өемнәре, нәрсәдәндер өреккән галәмәт зур сарык көтүе сыман, бар көченә каршыга таба йөгерә. Болытлар арасыннан урыны-урыны белән, яшел утрау булып, кара-кучкыл урман шәүләләре күренеп кала. «Карурманны чыккан чакта», – дип, эчтән генә көйләп куйды ул. Һәм шулчак, самолётның авыр һавасыннан котылып, астагы урман аланына төшәсе килә башлады. Туган ягы Башкортстанга кунакка кайтты исә, кардәш-ыру, таныш-белешләрне күреп сөйләшкәч тә, урманга китә ул. Әллә инде артык тыйнак, оялчан булганга, бәләкәй чакта да урманнан кайтып керми иде. Чөнки урманда сине беркем күрми, синә каты сүз әйтми, оялтмый. Аннары урманда җырлавы да рәхәт. Зилә әкрен генә «Гөлҗамал»ны башлап җибәрә. Аны кошлар «күтәреп ала». Җыр көчәйгәннән-көчәя бара һәм бервакыт урман, җыр авазлары, меңләгән кайтавазлар белән тулып, үзе дә җырлый башлаган сыман тоела.

«Сезне кем җырларга өйрәтте?» – дип сорагач, һич тә икеләнмичә: «Урман», – дип җавап биргән иде ул бервакыт. Мәктәптә күбрәк рус җырлары җырларга туры килде. Ә урманда нигәдер татар җырлары ятышлырак кебек. Алардагы моң-сагышка урман авазлары, урман шомлылыгы да өстәлгәч, җыр тагын да баебрак, көчәебрәк киткәндәй тоела.

Хәлдән таеп, башлары әйләнгәнче җырлый Зилә. Урманнан кайткач, өйдә җырлыйсы да килми. Өйдә җыры да ничектер корырак чыккан сыман күренә. Әтисе баянда яисә кларнетта уйнап җибәргәч кенә, шәрә стеналар җанланып киткәндәй була, әйтерсең өй ниргәсенә яткан бүрәнәләр үзләренең шау яфраклы урман агачлары икәнен искә төшерәләр. Һәм... Зилә, түзә алмыйча, җырга кушыла, аның белән бергә әнисе дә көйли башлый. Бер-бер сәбәп табып, аларның гаилә концертларын тыңларга күрше-күлән дә җыела.

Зилә сәгатенә карап куйды. Барып җитәргә дә күп вакыт калмаган икән. Аэропортка төшүгә үк, аны эшчеләр янына очрашуга алып китәчәкләр. «Нәрсә сөйләрмен икән?» дип борчылып куйды ул эчтән генә. Үзе турында сөйләр сүз дә юк кебек. Музыка училищесының дирижёрлык бүлегендә укыганнан соң, Казан консерваториясенә керде. Аны тәмамлагач, 1973 елда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлады. «Монмартр миләүшәсе» опереттасында – Виолетта, «Мәхәббәт эчемлеге» операсында – Афина, «Кияүләр» музыкаль комедиясендә – Бәнат, «Су кызы» операсында – Ольга, «Алтынчәч»тә – Алтынчәч, «Дон Жуан» операсында Церлина партияләрен җырлады. Барысын да саный китсәң, күп булыр. Аннары операны бигүк өнәп бетермәгән кешеләр дә шактый күп бит. «Операда моң юк, гадилек юк», – диләр. Дөрес, халык җырларындагы моң-сагыш, уй-хисләр опера арияләрендә була да алмый торгандыр. Ләкин иң элек моның сәбәбен эзләп карарга кирәк. Әнә итальяннар операны алай чит күрмиләр бит. Чөнки алар инде ничәмә-ничә гасырлар буе опера тыңлап үскәннәр, шуңа ияләшкәннәр. Ә бездә беренче опера дөньяга килгәнгә берничә дистә ел гына бит. Шул кыска вакыт эчендә генә дә «Алтынчәч», «Самат», «Җәлил» кебек халык яратып тыңлый торган опералларыбыз сәхнәгә күтәрелде. Алтынчәч ариясен, мәсәлән, хәзер теләсә кайсы авылда үз итмәгән кеше юктыр.

«Тамашачыларга менә шул турыда җиренә җиткереп сөйләргә кирәк, – дип ныклы карарга килде Зилә. – Аннары опера җырчысы халык җырларын да җырлый бит. Ф. Насретдинов, А. Аббасов, З. Хисмәтуллиналарның инде менә ярты гасыр буе халык теленнән төшмәве аларның операда җырлавы белән дә бәйле. Операда җырлаган җырчы профессиональ osталыкка ирешә. Ә осталыкның әле бер җырчыга да зыяны тигәне булмады. Халыкның иң яраткан җырчысы Илһам Шакиров та арияләр башкара бит...»

Зилә күңелдән генә булачак концертының репертуарын барлап куйды. «Күңелдә ике яз», «Җырларымнан белерсең», «Тәфтиләү», «Зөләйха», яңа романслар... Яңа концерт саен яңа җырлар өстәлә, репертуары байый. Яңа туган һәр җырны җырламый ул, үз күңеленә якыннарын, үз тавышына ярашканнарын гына сайлап ала. Җыр Зилә Сөнгатуллина өчен берничә минутлык күңел юанычы гына түгел, җыр – аның гомерлек дусты, юлдашы, җыр аның язмышы бит.

*1980*

# ИЛАҺИ МОҢ ИЯСЕ

Менә инде балачактан бирле мин аның җырларын тыңлап, кырык елга якын аның белән аралашып-күрешеп яшим, әмма әле һаман да авыз тутырып: «Илһам Шакировны яхшы беләм, яхшы аңлыйм», – дип әйтә алмыйм. Бер мин генә түгел, башкалар да шундый хәлдәдер дип уйлыйм. Илһам Шакировны бөтен тирәнлеге белән аңлау, аның илаһи моңының серләренә төшенү өчен җырчының җан авазын үз күңелең аша үткәрергә, халкыңның ачы язмышын һәрдаим бәгырь түрендә йөртергә кирәктер...

Илһам Шакиров – кабатланмас моң иясе, татар җырын иң югары профессиональ дәрәҗәгә күтәргән уникаль башкаручы, дибез. Моңа беркемнең дә шиге юк. Әмма аның бөеклеге шунда гына микән? Югыйсә безнең татарда халыкара мәйданга чыгарлык соклангыч тавышлы башкаручыларыбыз, халык күңелен яулаган гаҗәеп популяр җырчыларыбыз бар бит... Бәлки, аның бөеклеге – бөтен җаны-тәне белән милләт баласы булуында, гомер буе милләт кайгысы белән кайгырып, милләт шатлыгы белән шатланып яшәвендәдер? Алай дисәң, бездә фидакяр милләтпәрвәрләр дә шактый күп бит. Әллә соң аның бөеклегенең сере яшәү рәвешендә, холык-фигылендәме икән? Алай дисәң, безнең татарда гыйбрәтле язмышлы, киң күңелле, җор телле, олыны – олы, кечене кече итә белүче мәгънәле затлар, ярдәмчел җаннар шактый еш очрый бит. Әллә соң аның бөеклеге инде онытылып барган халык җырларын эзләп табып, аларга җан иңдереп, җан җылысы өреп, яңадан үз халкына, тыңлаучыларына бүләк итүендә микән? Алай дисәң, бездә музыкаль җәүһәрләребезне берәмтекләп җыеп, халкыбызның рухи хәзинәсенә кире кайтарган музыка белгечләребез, композиторларыбыз да бар бит. Ә, бәлки, аның бөеклеген үзенең дә композитор булуы, «Син сазыңны уйнадың», «Һаман истә», «Идел буе каеннары» кебек мәшһүр җырлар иҗат итүе белән аңлатып буладыр?! Алай дисәң, безнең йөзләгән популяр җырлар иҗат иткән композиторларыбыз да бар бит әле...
Әйе, бездә сәнгатьнең һәр өлкәсендә югары дәрәҗәләргә ирешкән, дан алган талант ияләре бар. Әмма Илһам Шакировның күңеленә Ходай Тәгалә бер генә сәләтне түгел, ә берничәне берьюлы өеп биргән. Ул – кабатланмас җырчы, моң иясе булуы белән бергә, менә дигән композитор, югары зәвыклы музыка белгече, фольклорчы, шома каләмле журналист, үз иҗатташларына һәрчак хәерхаһлы булган ярдәмчел дус һәм яшь талантлар өчен олы җанлы остаз, милләт язмышын үз язмышы иткән фидакяр шәхес тә. Аның бөеклеге дә менә шушындадыр – дистәләгән сәләтне үз күңеленә туплап, аларны бер илаһи көчкә әверелдерә алуындадыр... Әгәр теләсә, аннан менә дигән язучы, журналист, музыка белгече яисә композитор да чыккан булыр иде. Әмма ул башка юлны сайлаган – шушы сәләтләрнең һәммәсен күңел казанына салып кайнаткан да, тылсымчы Әбүгалисина кебек, халкының җанына дәва булырлык шифалы җыр-моң уйлап тапкан. Илһам Шакиров менә ярты гасыр буе шушы шифалы җырларын халык күңеленә иңдереп, милләтнең җанын дәвалап йөри.
Шулай бервакыт Нью-Йорк шәһәрендә яшәүче профессор Рифат Табиның машинасында барганда, магнитофоннан Илһам Шакиров тавышын ишеткәч, мин, үз-үземә яңа Америка ачкандай, татар җырының нинди зур көчкә, хәтта тылсымга ия булуын аңлый башлагандай булдым. Рифат әфәнде гомерендә бер мәртәбә дә Татарстанда булмаган, татар артистларын, җырчыларын да күргәне юк, Илһамны да ишетеп кенә белә. Аның әби-бабалары инде унтугызынчы гасырда ук Россиядән күчеп киткән кешеләр, хатыны – Алман иленнән, балалары – чып-чын американнар. Ә Рифат Табиның күңеле татар җырына сусаган, ул, бөтен дөньясын, Америкасын онытып, татар җырын тыңлый, Илһам Шакировны тыңлый. Аэропортта озатканда да ул: «Татар халык җырлары җибәр әле», – дип саубуллашып калды. Америкага икенче баруымда мине Рифат әфәнденең студент улы, инглиз телле чын американ Тимур каршы алды. Машинага кереп утыруга, ул магнитофон төймәсенә басты, һәм аннан, мине шаккатырып, Илһам агайның дәртле-моңлы «Ай былбылым» җыры агыла башлады.

Истанбул шәһәрендә яшәүче профессор Надир Дәүләт өендә дә, Вашингтондагы профессор Сәлах абый бакчасында да, фин, кытай, литва, белорус татарлары янында да безне татар җыры белән каршы алдылар, татар җыры белән озатып калдылар. Төрле илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән очрашкан саен, мин татар җырының милләт сагында торучы күзгә күренмәс гаскәр, уртак моң белән күңелләребезне якынайтучы, милләтебезне берләштерүче илаһи көч булуына ныграк ышана бардым. Ә Илһам Шакиров моның шулай икәнлеген инде күптән аңлаган, бүгенге заманда дәүләтсез милләтне бары тик уртак хыял, уртак максат, уртак дин, уртак хис һәм уртак моң белән генә саклап булырга мөмкин икәнлеген белгән икән...

Дөньяда үз теләге белән юкка чыгарга җыенган халык юктыр. Татар халкы да инде ничәмә-ничә гасыр буе илсез-дәүләтсез килеш тә тырышып-тырмашып яшәргә, әдәбиятын-сәнгатен үстерергә, гореф-гадәтләрен, динен, телен сакларга тырышып яши. Аллага шөкер, инде бетәргә дучар ителгән телебез дә соңгы елларда әкренләп тернәкләнә башлады, моның өчен махсус кануннар, хөкүмәт карарлары кабул ителде. Әмма законнарыбыз юк чагында да безнең фидакяр тел сакчыларыбыз – милләтпәрвәр язучыларыбыз, шагыйрьләребез, галимнәребез, мәгърифәтчеләребез булды. Җырчы Илһам Шакиров та алар янәшәсендә, алар арасында иде. Аның җырлары гына түгел, милли сәнгатебез хакындагы җитди мәкаләләре, радиога язылган әңгәмәләре, концерт вакытындагы кыска һәм үтемле сүзләре дә халкыбызның милли аңын уятуга гаять зур этәргеч булды, һәр концерт азагында залны аякка бастырып «Туган тел»не җырлату тора-бара Илһам «бисмилла»сы белән гадәткә керде, Тукай җыры чын мәгънәсендә милли гимнга әверелде.

«Сез тел дә тел, дисез. Монысы әйбәт, чөнки телсез милләт булмый, – диде миңа бервакыт Илһам абый. – Ә моңсыз, җырсыз, музыкасыз милләт буламы соң? Нигә без бу хакта сөйләмибез? Нигә без татар милли музыка сәнгатен үстерү турында дәүләт программасы кабул итмибез? Әнә яһүд халкы теле беткәндә дә юкка чыкмаган. Чөнки аларның рухы сынмаган, милли аңнары сүрелмәгән. Ә рухны, милли аңны саклауда җырның, моңның роле гаять зур...» Илһам Шакиров әле бүген дә үзе турында түгел, әнә шулай милләт язмышы турында уйлый, аның киләчәген кайгырта. Һәммә татар баласының теле татарча бишек җыры тыңлый-тыңлый үзенең туган телендә – ана телендә ачылсын иде дип хыяллана.

Безнең республиканы, гадәттә, «нефть төбәге» дип йөртәләр, үзебез дә кайчак «безнең төп байлыгыбыз – нефть» дияргә яратабыз. Бу, чыннан да, шулай. Әмма республиканың төп байлыгы нефть булса, милләтебезнең иң олы хәзинәсе дип мин Кол Гали, Сәйф Сараи, Кол Шәриф, Тукай, Сәйдәш, Урманчеларны атар идем. Инде ил агасы яшенә җиткән Илһам Шакировның да шушы илаһи затлар белән янәшә торучы бөек җырчы һәм шәхес булуына шигебез юк. Шуңа күрә дә без бүген, горурланып, татар халкын «Илһамлы халык» дип әйтә алабыз!

Ил кайгырса,
илдә Илһам җылый,
Ил сөенсә,
илдә Илһам көлә.
Бәгырьләрне
безнең телә-телә,
Чорлар аша узып
бер җыр килә.

Илһамлы сүз –
бары туган җирдә,
Иң татлы моң –
бары туган телдә...
Шатлыгым да,
хәсрәтем дә минем,
Бәхетем дә бары туган илдә.

*2005*

# ҖӘЛИЛ РУХЫНА ТУГРЫЛЫК

Рафаэль ага Мостафин белән беренче күрешүем-танышуым бүгенгедәй хәтердә. 1967 елның язында мин, Мәскәүдәге Әдәбият институтына керү нияте белән, иҗат конкурсына шигырьләремне җибәргән идем. Ә конкурс бик зур – бер урынга ике йөздән артык кеше, шуңа күрә аннан үтүемә өмет бәләкәй иде. Ниһаять, көннәрдән бер көнне Мәскәүдән сөенечле хәбәр килеп төште: мин иҗат конкурсыннан узганмын һәм август башында имтиханнар тапшыру өчен башкалага барырга тиешмен икән. Бу хәбәрдән башым әйләнеп, бөтенләй иләсләнеп калгандай булдым. Инде икенче курсны тәмамлап килгән җирдән Казан дәүләт университетына укырга йөрүдән дә туктадым. Сине Мәскәү кадәр Мәскәүдә атаклы Әдәбият институтында көтеп торганда, ничек инде журналистика бүлегендә укып ятасың, имеш. Минем хыял журналистика түгел, ә шагыйрь булу бит!

Шулай канатланып йөри торгач, моңа кадәр язган шигырьләремнең иң яхшы дигәннәрен сайлап, көннәрдән бер көнне «Казан утлары» журналына юл тоттым. Поэзия бүлеге мөдире Нури Арслан, карт арыслан ялы сыман саргайган чәчләрен бармаклары белән тарый-тарый, шигырьләремә күз йөртеп чыкты да, мәктәп баласы кебек кулымнан җитәкләп, баш мөхәррир Рафаэль Мостафин янына алып кереп китте. «Ишеттем, синең хакта ишеттем мин, – дип, күптәнге танышы сыман каршы алды редактор мине. – Әдәбият институтында уку әйбәт анысы, бездән Габдрахман Әпсәләмов белән Рәшит Гәрәй тәмамлаган иде аны. Шигырьләреңне редколлегия әгъзасы Хәсән Туфанга бирербез. Ул хупласа, журналда бастырырбыз... Тик менә университетны ташлавың гына кызганыч. Бөтен дөньяда атаклы университет бит ул. Үз язмышың үз кулыңда инде, соңыннан үкенерлек кенә булмасын. – Шулай диде дә ул бераз уйланып торды. Аннары болай дип дәвам итте: – Августка кадәр шактый вакыт бар бит әле, өч ай тулай торакта кандала симертеп ятканчы, әйдә, теләгең булса, журналда эшләп ал. Бездә хәзер журналга язылу кампаниясе бара, районнарга чыгып, шул эш белән шөгыльләнерсең».

Монысы инде минем өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә иде. Әле моңа кадәр хәтта район газетасында да эшләп карамаган, соңгы арада кая барып бәрелергә белмичә, ике каен арасында адашып йөргән хыялый малайны татарның иң мәртәбәле журналына эшкә чакырсыннар әле!

Шушы көннән, шушы мизгелдән башлап, Рафаэль абый Мостафин минем өчен илаһи бер затка әверелгәндәй булды. Еллар узган саен, мин аның яңадан-яңа асыл сыйфатларын ача бардым, аның чын мәгънәсендә олы җанлы, кече күңелле кеше булуына инандым.

«Казан утлары»нда эшләгән берничә ай эчендә мин Рафаэль абыйның кешеләргә игелекле мөнәсәбәтен күреп, үземә гомер буена җитәрлек тормыш дәресләре алдым. Ул журналга килеп-китеп йөрүче авторларны, редакциядә эшләүче хезмәткәрләрне генә түгел, хәтта минем кебек малай-шалайны да үзе белән тигез күреп сөйләшә, аның кыяфәтендә дә, сүзләрендә дә бернинди дорфалык, мин-минлек, тәкәбберлек чаткылары юк иде. Шуңа күрәдер редакциядә бер чакта да кирәкмәгән ыгы-зыгы, шау-шу чыкмый, һәркем үз эшен күңел биреп, яратып эшли. Редакторның ышанычын аклыйм дип, мин дә айлар буе районнардан кайтып кермәдем, бер меңнән артык кешегә журнал яздыру турындагы хәбәрне җиткергәч, ул бөтен редакцияне җыеп, миңа тантаналы шартларда яшел төстәге гармун бүләк итте.

...Сиксән яшьлек юбилеен көтеп ала алмыйча, аңа бер ай чамасы гына калгач, якты дөнья белән саубуллашкан аксакалның баш очында авыр уйларга чумып басып торганда, күңелемдә әлеге көннәр яшен уты кебек яктырып киткәндәй булды, аннары җил тузгыткан календарь битләре сыман, берәм-берәм Рафаэль абыйлы көннәр хәтердә йөгереп узды...

Рафаэль Мостафин дигән әдипнең иҗат сере, Рафаэль Мостафин дигән шәхеснең үзенчәлеге нәрсәдә соң? Бервакыт мин: «Начар кешедән яхшы язучы чыгуына ышанмыйм», – дип әйткән идем. Бу сүзләр белән килешмәүчеләр дә булырга мөмкин. Чөнки иҗат кешесенә алай кистереп бәя бирү бик авыр. Әмма күңелендә яманлык яткан кеше, никадәр генә сәләтле булса да, аның әсәрләре башкалар күңеленә илаһи хис булып барып җитә алмый. Рафаэль Мостафинның бөтен

әсәрләре, барча кылган гамәлләре илаһият белән сугарылган, аның бар максаты – кешеләргә, илгә, халыкка игелек кылу. Ә игелек кылу өчен, табигый сәләт өстенә көрәшче холкы, батырлык, түгәрәк иман һәм туры кыйбла да кирәк булуы беркем өчен дә сер түгелдер.
1968 елның язында, әлеге очрашудан соң төгәл бер ел узгач, Рафаэль абый барчабызны шаккатырып, кинәт өр-яңа яктан ачылып китте... Апрель аенда Татарстан язучыларының чираттагы корылтае-съезды булырга тиеш иде. Шунда катнашырга чакырып, миңа да Мәскәүгә хат килеп төште. Минем инде Әдәбият институтында укучы төрле милләт, төрле ил язучылары белән аралаша торгач, күңелемә «сүз иреге», «демократия», «хөррият» кебек яңа фикерләр оялап, холкым да бераз иркенәеп, телем дә ачыла башлаган иде. Мәскәүдәге, бигрәк тә безнең институттагы халык һәр шәүләдән куркып тормый, үз фикерен ярып әйтә, кирәген таләп итә белә иде. Мин дә, шулардан күрмәк, съездда үз сүземне әйтергә исәп итеп кайттым. Әмма мине Казанда тиз суындырдылар, кистереп, яшь-җилкенчәккә сүз бирелмәячәген әйттеләр. Ә чыгышымда мин барлык союздаш республикаларда яшьләр өчен берничә журнал чыгуы, СССРда сан ягыннан бишенче урында торучы татарларның да яшь язучылар өчен әдәби журналы булырга тиешлеге хакында сөйләмәкче идем. Сүз бирмәсләрен белгәч, без, университет студентлары белән җыелышып, төне буе шушы таләпне берничә йөз данә итеп кәгазьгә күчереп яздык. Икенче көнне ул өндәмәләрне шагыйрь Зөлфәт белән Г.Камал театры балконыннан залга чәчәргә тиеш идек. Әмма ул көнне без һич тә көтмәгән искитәрлек вакыйга булды.
Съезд үтә торган театр залы язучылар, төрле республикалардан килгән кунаклар, партия хезмәткәрләре, махсус оешма вәкилләре, әдәбият сөючеләр белән шыгрым тулы, президиумда – аксакал әдипләр, партия өлкә комитеты җитәкчеләре, олы кунаклар. Чираттагы сүзне «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рафаэль Мостафинга биргәч, һәммәсе дә тын калдылар. Чөнки ул – тиражы бер йөз меңнән арткан олпат әдәби журнал редакторы, шуның өстенә язучылар арасында зур хөрмәт яуларга өлгергән бай мәгълүматлы, төпле фикерле, объектив карашлы тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече. Соңгы елларда журналда басылган әсәрләргә, татар әдәбиятына тәфсилле күзәтү ясаганнан соң, ул, кинәт кенә сүз сөрешен башка якка борды да, революциягә кадәр татар китапларының, газета-журналларының хәзергегә караганда берничә мәртәбә күбрәк чыкканын әйтеп, дәлил рәвешендә аларның исемнәрен һәм саннарын атый башлады, кайберләрен, кулына алып селки-селки, залга да күрсәтте. Шул мәлдә президиум рәтләре буйлап ток йөгереп узгандай булды, ә залдагы халык, нишләргә белмичә, бер мәлгә өнсез калды... Озак та узмады, һушына килергә өлгермәгән өнсезләр өстенә безнең өндәмәләр яңгыры яуды. Бер-бер артлы килгән әлеге ике вакыйга бер-берсенә шулкадәр аваздаш иде ки, кайберәүләр аны махсус шулай оештырылган, махсус сценарий буенча эшләнгән дип тә уйлагандыр, ләкин бу һич кенә дә алай түгел иде. Тирәннәнрәк уйласаң, бәлки, боларның икесе арасындагы бәйләнешләрне, мантыйкны да табарга мөмкиндер. Татар җәмәгатьчелегендә, бигрәк тә зыялы затлар, язучылар, иҗат әһелләре арасында хөр фикер ияләре ишәя барып, милли мәнфәгатьләрне кайгырту, милләт хокукларын яклау сүзләре ишетелә башлаган чаклар иде бу. Ә монда хөр фикерле әсәрләр бастыручы «Казан утлары» журналының һәм, һичшиксез, аның киң карашлы редакторының да тәэсире зур булгандыр. Чөнки без, яшь шагыйрьләр, нәкъ менә шул «Казан утлары»ның, Рафаэль Мостафинның игелекле дәресләрен, «яңа җәдитчелек мәктәбен» үтүче шәкертләр идек. Шуңа күрә ул көнне, ул чакны безнең фикерләребезнең һәм гамәлләребезнең тәңгәл килүе бик тә табигый булгандыр.
Илебездәге, бигрәк тә татар тормышындагы милли күтәрелешне, милли яңарышны без, гадәттә, узган гасырның сиксәненче-туксанынчы еллары белән бәйләп сөйлибез. Әмма милләт хакын даулау күпкә элегрәк, алтмышынчы елларда ук башланган иде инде. Морзалар нәселеннән чыккан язучы Әмирхан Еники әсәрләре, тугры Тукай мәктәбен узган галим Ибраһим Нуруллин чыгышлары, башбирмәс шагыйрь Салих Баттал поэмалары, Җәлил рухлы Рафаэль Мостафин гамәлләре әлеге милли күтәрелешнең нигез ташлары булды.
Рафаэль Мостафин киңкырлы, әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итүче әдип булса да, аны татар укучысына, төрле халыкларга һәм илләргә таныткан әсәрләре, һичшиксез, Муса Җәлилгә багышланганнары. Шагыйрьгә охшатыбрак әйтсәк, Җәлил турында уйласам, минем күз алдыма

Рафаэль Мостафин килеп баса, Рафаэль ага турында уйласам – Муса Җәлил. Халкыбызның каһарман шәхесе турында үзебездә дә, читләр арасында да язучылар күп булды. Ләкин Рафаэль Мостафин Җәлил турында әсәрләр язып, китаплар чыгарып кына калмады, аңа үзенең бөтен иҗади талантын, бөтен гомерен багышлады. Ә Җәлилнең рухи газапларын аңлар өчен үзең дә шул газаплар эчендә янарга, Җәлилнең рухи бөеклеген төшенер өчен үзеңә дә шул биеклеккә күтәрелергә кирәк.
Шулай берчакны Милли китапханәдә чәй өстәле янында күңелләрне туара-туара эч серләребезне бүлешеп утырганда, Рафаэль абыйдан: «Җәлил турында төрле фикерләр йөргән вакытта сезнең икеләнгән чакларыгыз булдымы? – дип сорап куйган идем. – Идел-Урал легионы эшчәнлеге хакында бездә мәгълүмат бик аз бит. Җәлил анда нинди уй-фикерләр белән йөрде, ни гамәлләр кылды, нинди идеяләрне алга сөрде икән?» Минем бу сорауларны ишеткәч, ул кинәт кенә кабынып киткәндәй булды. «Җәлилгә мин үземә ышанган кебек ышанам, хәтта үземнән артыграк та ышанам бугай әле. Шагыйрьнең шигырьләре – аның рухи васыяте кебек. Ә васыять язганда, үлем белән йөзгә-йөз очрашканда, кеше алдаша алмый! – дип кистереп әйтте ул. – Җәлилнең тормыш юлын, әсирлектәге көннәрен, иҗатын ныграк өйрәнгән саен, мин аның каһарман рухлы, милли җанлы шәхес һәм шагыйрь булуына ныграк инана барам!»
Ул Җәлилне аклаучы да, яклаучы да, саклаучы да булды. Германиядә яшәүче милләттәшебез Гариф Солтан белән бәхәскә кереп, соңыннан матбугатта төрле язмалар пәйда булу сәбәбен мин Җәлилгә җаны-тәне белән бирелгәнлектән, аңа үтә нык ышанычтан килә дип әйтер идем. «Бу дөньяда һәркем үзенчә хаклы», – дигән бер философ. Милләткә, халыкка хезмәт итүнең төрле юллары бар. Ә бу очракта Рафаэль Мостафин Муса Җәлил сайлаган юлны иң дөресе, иң турысы, иң гаделе дип саный икән, минемчә, аның моңа тулы хакы һәм кире каккысыз дәлилләре бар.
Әле узган елны гына Муса Җәлилне үз пычракларында әвәләргә маташучы кемсәләрнең язмалары басылып чыккач, гадәттә һәрчак саллы-сабыр кыяфәтле Рафаэль абыйның күңеленнән тынычлык качты. Җәлил рәнҗешен – ул үз рәнҗүе, Җәлилгә кизәнүне үзенә кизәнү кебек кабул итте. «Җәлилгә пычрак ату – татар халкын пычратырга тырышу, Җәлилне мыскыллау – татар халкын мыскыллау ул!» – дип әрни-әрни сөйләгәне әле бүген дә колак төбендә яңгырап тора кебек. Шушы мәсьәлә хакында Язучылар берлегендә сүз чыккач, кемдер аңа бу кешеләрне мәхкәмәгә бирергә дә тәкъдим иткән иде. «Әтиемнең әтисе Төхфәт бабай миңа өч нәрсә васыять итеп калдырган иде. Эчмә, кеше белән ямьсезләнмә-судлашма, хатын аерма, диде ул. Моңа кадәр аның васыятенә хыянәт итмәдем. Менә хәзер Җәлил хакына судка барсам да, бабай рәнҗемәс иде, мөгаен». Йөрәгеннән саркып чыккан бу сүзләрне ул, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, пышылдап диярлек әйтте.
Чынлап та, без белгән Рафаэль абый нәкъ Төхфәт бабай васыятендәгечә яшәде. Ул – кеше буларак затлы, зыялы, итагатьле; иҗат әһеле буларак – туры сүзле һәм гадел; җәлилче буларак – кыю йөрәкле, фидакяр рухлы, ә ир-ат һәм гаилә башлыгы буларак барчабызга үрнәк эти һәм йорт хуҗасы иде. Рафаэль агайны искә төшергәндә, мин аның бу асыл сыйфатларының чишмә башын, сәбәпчеләрен эзлим. Киң күңеллелек, миһербанлык, кешелеклелек сыйфатлары аңа гасырдан артык гомер юлы узып бакыйлыкка күчкән әнисеннән иңгәндер. Ә пөхтәлек, төгәллек, егетлек, батырлык, билгеле инде, яшьли фронтта һәлак булган әтисеннән – полк командиры Әхмәт абыйдан мирас булып калгандыр.
Үзенең якташы һәм иҗатына рух бирүче Муса Җәлил кебек, Рафаэль ага Мостафин тормышта да, әдәби хәрәкәттә дә гаҗәеп актив шәхес иде. Ул бернәрсәгә дә битараф түгел, һәр вакыйгага аның үз мөнәсәбәте, үз фикере бар. Муса Җәлил иҗатын һәм шәхесен өйрәнү белән бергә ул дистәләгән татар язучыларының иҗат портретларын шәрехләп, тасвирлап чыкты. Казан һәм Мәскәү газета-журналларында аның фәнни-популяр тел белән язылган үтемле мәкаләләре һәрчак әдәбият сөючеләрнең игътибар үзәгендә булды. Ул бигрәк тә әдәбиятка яңа аяк басып килүче яшь язучыларга игътибарлы иде. Үзенең төп иҗат мәйданы итеп әдәби тәнкыйть өлкәсен сайласа да, ул илнең күренекле язучылары рәтендә саналды. СССРдагы иң популяр ун татар язучысы арасында Рафаэль Мостафин исеме дә аталуы менә шул хакта сөйли дә инде. Әле бүген дә Мәскәүдәме, Ташкенттамы, Алма-Атадамы – кайда гына: «Нинди татар язучысын беләсез?» – дип

сорасаң, һичшиксез, Тукай һәм Муса Җәлил исемнәре белән беррәттән Рафаэль Мостафин исемен дә атамый калмыйлар.

Рафаэль Мостафин бу дөньяда ни өчен яшәгәнен белеп яшәде, аның иҗатының максаты, кыйбласы да һәрчак туры һәм анык иде. Ул кешеләрдән, тирә-юньнән, тормыштан, дөньядан һәрдаим яхшылык эзләде. Яманлыкны күрсә, аяусыз көрәште. Муса Җәлилне аклау һәм яклау ул илебездәге хаксызга рәнҗетелгәннәрнең һәммәсен дә яклап көрәшү иде. Ә «яшел кәфенгә төренеп», ләмгә чумган Кабан күлен һәлакәттән коткару – шулай ук уртак йортыбыз – Җир шарын экологик афәттән аралауның конкрет бер гамәле булды. Үз иҗатының, үз гамәлләренең дөньяны аз гына да булса яхшы якка үзгәртә алуын күреп, чиксез куана иде ул. Ә язучы кеше өчен иҗат ләззәтен кичерү бер бәхет булса, аның нәтиҗәләрен күрү икеләтә бәхеттер.

*2011*

# СЕЗГӘ БАШ ИЯР КӨННӘР

Сибгат ага Хәкимне мин еш кына Ирек мәйданында очрата идем. Бик ярата иде ул Ирек мәйданын. Шагыйрь күңеленә хуш килгән исеме өченме, әллә меңьеллык тарихлы шәһәрнең кыл уртасында – үзе яшәгән йорт янәшәсендә булгангамы, һәр иртә-кичләрен Ирек мәйданын урамый калмый иде. Менә ул ике кулын артка кушырып куйган да, башын бераз югары чөеп, моңсу күзләрен күккә төбәгән һәм, кая баруын да искәрмичә, салмак кына атлый, вакыт-вакыт, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, иреннәрен кыймылдатып куя. Аны шушы илаһи халәтеннән аерырга базмыйча, мин бераз вакыт читтән генә күзәтеп торам, аннан, батырлыгым җыеп, каушый-каушый сүз катам. Хәл-әхвәлен сорагач та, ул җәелеп китеп үзе турында сөйли башламый, иң элек синең хәлеңне белешә, аннары әкренләп шигърият дәрьясына, әдәбият дөньясына, язучы-шагыйрьләр иҗатына кереп китә. Әле генә моңсулык-сагыш саркып торган күзләрендә шулчак очкыннар кабынгандай була. Аның белән күрешеп сөйләшкәч, үзең дә сизмәстән, бер мәлгә тормыш ваклыкларыннан арынып, бар җаның белән өскәрәк – илаһи дөнья түренәрәк күтәрелгәндәй буласың, әдәбиятның, шигъриятнең тылсымлы көченә чын-чынлап инана башлыйсың. Чөнки ул кайберәүләр кебек шигъри мизгелләре белән генә түгел, ә бөтен яшәеше, бар булмышы, бар рәвеше белән коеп куйган шагыйрь иде.

Ул елларда без, яшь шагыйрьләр, әле генә авылдан Казанга килеп, таш бәгырьле шәһәр кырыслыгына ияләшә алмыйча йөрүче ятим балалар кебек идек. Казанда авыр чакта таянырга әти-әни дә, барып сыеныр, киңәш-табыш сорарлык якын кешеләр дә юк. Гәүдәләребез шәһәрдә булса да, бөтен җаныбыз – авылда, шуңа күрә шигырьләребез, укыган әсәрләребез дә, нигездә, авыл турында. Тулай торакта моңсуланып утырганда, радиодан яңгыраган таныш җырны ишеткәч, күзгә ирексездән яшьләр тыгыла...

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Рәшәң белән битем юдың син;
Һәрвакытта бергә уртаклаштың,
Уртаклаштың барын-югын син.

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Җилфердәде яшел күлмәгем...
Ни өчендер башка төштә түгел,
Үрләреңдә яшем түгәмен.

Карале, сугыш афәтләрен узган, утлар-сулар кичкән олпат шагыйрь Сибгат Хәким дә үзенең авылын нәкъ безнең шикелле ярата, безнең шикелле сагына икән ләбаса. Дөресрәге, без аның кебек яратабыздыр, сагынабыздыр инде. Туган йортка кайтып, туганнарның җан җылысын, күңел ышыгын тоярга теләгәндәй, без, үзебез дә сизмәстән, аксакал шагыйрьгә тартылабыз, аның янына җыелабыз. Чөнки Казанда безгә әни назы, әтинең күз карашы, әти сүзе җитми. Безнең җаннар әти-әни җылысын сагынган, күңелләр олылар киңәшенә сусаган. Ә Сибгат ага, чынлап та, безне нәкъ әтиләрчә якын күреп каршылый, уңышларыбызны күреп, җылы сүз белән башыбыздан сыйпый, хилафлыкларыбыз булса, яратып кына орыша. Шундый чакларда аның мәңге моңсу күзләрендә балачак шаянлыгы уянгандай була, шул чакларда ул, бәлки, үзенең иң кадерле кешесен – әнисен искә төшерәдер...

Туган якта күреним генә үрдән,
Шатлыгыннан арыш ду кубар,
Сөенчегә бүләк өмет итеп,
Кырлар буйлап йөгерер дулкыннар.

Алда авыл, әнкәй торган авыл,
Ветпунктны гына үтсеннәр,
Ул дулкыннар безнең иске зират

Коймасына ятып үксерләр.

Нинди зур сагыш, нинди ихлас хисләр һәм олы мәхәббәт сыйган бу шигъри юлларга! Нинди гади һәм күңелгә якын сүзләр, һәр сүз челтәр бәйләмендәге камил күзәнәк кебек нәкъ үз урынында! Табигый талант, шигъри камиллек үрнәге менә шушындый була торгандыр инде.
Әмма, ни гаҗәп, Сибгат Хәким шигъриятен аңлау, кабул итү өчен миңа шактый еллар кирәк булды. Баштарак бөек Тукай иҗатына шулай ук тешем үтмәгән иде. Әмма монда бер аерма бар: Тукай шигърияте, аның тел һәм фикер хасияте, гомумән, Тукай дөньясы миңа артык катлаулы тоелса, Сибгат Хәким шигырьләре, киресенчә, артык гади сыман күренә иде. Еллар узган саен, бу шагыйрьләр әкренләп рухыма якыная барды, һәм бүгенге көндә инде Тукай белән Сибгат Хәким иҗаты тулысынча күңелемнең иң түренә кереп оялады. Әлеге ике мәшһүр шагыйрь иҗатындагы уртак уй-фикерләргә тап булган саен, мин Сибгат Хәкимнең Тукай мәктәбен тулысынча узган иң талантлы шәкерт булуын аңлый бардым. Ә бу олуг шагыйрьнең беренче карашка гади күренгән шигырьләрендәге эчке асыл мәгънәгә төшенү өчен миңа тормыш тәҗрибәсе туплау һәм үземә дә Сибгат Хәким мәктәбен узу кирәк булган икән...
Читтән карап торганда, Сибгат Хәким бик тә юаш, гаҗәеп басынкы холыклы булып күренә. Әйе, ачуы чыкканда да тавыш күтәреп сөйләшми, кычкырышмый, йодрык төйнәп ярсый-ярсый чыгышлар ясамый, урам җыеннарында ялкынлы нотыклар тотмый. Аның кыяфәте һәрчак тыныч, тавышы басынкы, әмма сүзләре башкаларныкыннан саллырак була торган иде. Ул үз фикерен кабаланмыйча гына, әмма үзәккә үтәрлек итеп җиткерә, шуңа күрә аның пышылдап әйткән сүзләре дә бик еракка ишетелә, ул яратса да, яратмаса да, икейөзлеләнмичә ихластан сөйли, шуңа күрә аның белән каләмдәшләре дә, зур-зур түрәләр дә исәпләшәләр.
Кемнәрдер юашка санап йөргән шагыйрь авызыннан, шагыйрь каләменнән вакыт-вакыт «баш күтәрлек» кыю фикерләр дә чәчрәп чыга иде. Менә бу юлларны язу өчен ул елларда никадәр зур рухи батырлык кирәк булгандыр...

Яңа буын шагыйрьләрен көтә,
Җәлилләрдән бушап, төрмәләр.

Әле шәхес культы шаукымнары басылып бетмәгән, шул бушаган төрмәгә үзеңне илтеп тыгарга да күп сорап тормаган заманнар бит бу...
Ә Тукай иҗаты Сибгат Хәким өчен гомер буена рухи юл күрсәткеч, шигъри кыйбла булды. Аның һәр көне, һәр кылган гамәле Тукай «бисмилла»сы белән башлана иде. Шуңа күрәдерме, еллар үткән саен, Сибгат аганың шигъри сурәтләре һич тә тоныкланмый, төсләре уңмый, фикерләре искерми. Әйтерсең лә ул һаман безнең арада, әйтерсең лә ул үзенең мәгълүм шигырьләрен, Габдулла Тукайга багышланган «Кырыгынчы бүлмә» поэмасын әле бүген генә язган...

Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда?
Мең елдан соң да бер синең, илем,
Кайтасыңны беләм Тукайга.
Шуны ләкин син онытма, «Болгар»,
Кырыгынчы бүлмә барлыгын.
Тукайның зур мәңге тере җаны
Шунда ята, кара, бар, энем...

...Һәм кинәт кенә, киерелеп яңакка суккандай, сискәндергеч юллар, бүгенге ачы хакыйкать авазы, шагыйрь җанының кайтавазы яңгырый...

Тынгысыз чат тынгы бирмәс җанга,
Үзем тынгач, шушы чат тынар.
Тукай тавышы, кычкыра кук Тукай,
Бер генә сүз яңгырый: саттылар...

«Кырыгынчы бүлмә» поэмасының моннан нәкъ кырык ел элек, 1971 елда язылганын белгәч, шагыйрьнең әүлиялыгына, алдан күрүчәнлегенә сокланмый кала алмыйсың.
Сибгат ага Хәким иҗатында иң күп кабатлана торган сүзләр «сагыш» белән «язмыш» сүзләредер. Аның бөтен иҗаты да сагышлы язмышлардан тора кебек. Милләт язмышы, Тукай язмышы, әдәбият язмышы һәм үз язмышы... Вафатына ярты ел кала, 1986 елның 16 гыйнварында, ул үзенең көндәлегенә мондый юллар язып калдырган: *«Буран, салкын, сулау авыр... Язучылар союзында җыелыш булды. Өйгә хәтле Рәдиф култыклап алып кайтты. Сугышта яралыларны алгы сызыктан шулай алып чыгалар иде. Фронт искә төште. Үзем дә кайчакта алып чыккаладым. Әдәбият – алгы сызык. Хәзер үземне алып чыгалар. Минем өчен алгы сызыклар бетте. Әз генә дә үкенмим, борчылмыйм, ике фронтта да ахырынача сугыштым...»*
Бу сагышлы һәм әрнүле юлларга шагыйрьнең бөтен тәрҗемәи хәле, иҗат юлы, гыйбрәтле язмышы сыеп беткән кебек.
Без белгән заманда Сибгат ага яныннан һәрчак яшь шагыйрьләр, яшь җырчылар, рәссамнар, композиторлар өзелмәде. Иҗат белән яшьлек аның өчен аерылгысыз төшенчәләр кебек иде. Гомер дисбесенең соңгы төймәләрен санавын күңеле белән сизсә дә, аның һич кенә дә картлык белән килешәсе, картлыкка бирешәсе килми иде. Соңрак җырга әверелгән «Минем таныш өянкеләр» шигырендә бу хакта ул болайрак яза:

Сезгә эндәшми, мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Җитте минем дә, сезнең күк,
Картайдым, дияр көннәр.

Җырчы Рафаэль Сәхәбиевне очраткан саен, язучы Аяз Гыйләҗев аннан шушы җырны җырлатмыйча калмый иде. Зинданнардан да исән чыккан яңгыравык тавышы белән бөтен Матбугат йортын гөрләтеп килгән Аяз абый, җырның беренче куплетын тыңлауга, дымланган күзләрен яшереп читкә борыла, ә инде:

Кайда ул бергә ашкынган,
Бергә шаулаган көннәр?
Минем таныш өянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр? –

дигән сүзләргә җиткәч, сабый бала кебек сулкылдап еларга ук тотына иде. Ә Сибгат ага читтән генә моңсу елмаеп карап тора, күзләре тулы сагыш булса да, ул еламый, әйтерсең лә бу шигырьне ул үзе турында түгел, махсус Аяз агайга атап язган, әйтерсең лә аның гыйбрәтле язмышын шигъри юлларга салган. Ә без, яшь шагыйрьләр, сулыш та алмыйча, өнсез калып, читтән генә күзәтеп торабыз. Нәкъ шушы мизгелдә кеше язмышының, тормыш мәгънәсенең серенә төшенгәндәй булабыз, шигъриятнең илаһи дөньясына кереп чумабыз.
Сибгат ага җаны-тәне белән тормышка, кешеләргә, якты дөньяга гашыйк кеше иде. Аның һәр әсәре туган ягына, туган халкына мәхәббәт белән сугарылган. Шуңа күрә дә шигырьләреннән күңелнең иң караңгы почмакларына да яктылык иңгәндәй була, әсәрләрен укыгач, җаныңа яшәү дәрте өстәлә. Остазыбызның вафатын ишеткәч, мин төне буе йоклый алмадым, хәсрәтле уйларымны шигырь юлларына салырга тырышып, ак кәгазьгә иң самими хисләремне сөйләдем.

Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,
Туу белән үлем булган чакта.
Чәч агаргач шигырь язып кара...
Һәркем шагыйрь юләр балачакта.

Еллар йөге баскач иңнәреңә,
Очып кара хыял канатында.
Гомер буе җыйган байлыгыңны
Син чәчәргә тиеш, таратырга.

Ай-кояшка тиңдәй Тукай барда,
Туфан барда шагыйрь булып кара...
Охшатам мин моңлы язмышымны
Кояш нуры иңгән болытларга.

Гашыйк идем язгы бураннарга,
Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.
Исемемне онытмаслар әле,
Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.

Мин киткәч тә дөнья матур булыр,
Моңсуланыр Аккош күле генә...
Аккош булып бер кайтырмын әле,
Ышанмагыз минем үлемемә.

Мин ул төнне, үз-үземне онытып, Сибгат ага кайгысы белән кайгыра, Сибгат ага булып сөйләшә башлаганмын икән ләбаса...

Кешегә озын гомер теләгәндә, гадәттә: «Йөз яшә!» – дип әйтәләр. Шагыйрь Сибгат Хәким бөек Тукайның йөзьеллыгын бәйрәм иткән елда фани дөньядан бакыйлыкка күчте. Быел исә аның үзенә йөз яшь тулган булыр иде. Ә шигырьләре, җырлары исән, алар бүген дә яши, алар бүген дә безнең белән бергә.

Дистәләгән яшь шагыйрьне кулларыннан җитәкләп шигърият дөньясына алып кергән, аларга һәрчак аталарча күз-колак булган остаз-шагыйрь, ярты гасыр буе татар әдәбиятының алгы сызыгында торган көрәшче шагыйрь, чын мәгънәсендә халык шагыйре Сибгат ага Хәким еллар узган саен безгә якыная, кадерлерәк була бара. Өянкеләр турындагы әлеге җырны тыңлаганда инде бүген минем дә күзләремә ирексездән яшь тула. Шулчак хыял офыгында шагыйрьнең шәүләсе чагылып киткәндәй була, һәм мин, үзем дә сизмәстән, әлеге җырның сүзләрен бераз үзгәртеп «сезгә баш ияр көннәр» дип тәмамлыйм.

*2011*

# ТАТАР ЭЗЛӘП – АМЕРИКАГА,
# ЯКИ НИ ӨЧЕН ЭЗЛИЛӘР СОҢ ТАТАРНЫ?

Америкага беренче генә баруым түгел. Беренче сәфәрем нәкъ егерме ел элек, 1991 елда булган иде. Гадәттә мин АКШка андагы милләттәшләребезне күрү, аларның нинди уй-ниятләр белән яшәүләрен күрү өчен барам. Гомумән, кайсы гына илгә барсам да, иң әүвәл анда яшәүче татарларны эзлим. Моңарчы Көньяк Кореядан башка татар тапмаган илем булмады. Югыйсә заманында анда да татарлар яшәгән. Бәлкем, хәзер дә берничәсе калгандыр. Вашингтонда Сәгыйть Сәлах дигән бик күренекле милләттәшебез белән очрашкан идем. Ул – татар дөньясында гына түгел, Америкада да бик күренекле шәхес. АКШның атом-төш коралы буенча комитет әгъзасы, атомчы физик ул. «Заманында Көньяк Кореяда, Сеул шәһәрендә 26 татар гаиләсе бар иде. Шушы утызлап гаиләнең татар мәктәбе эшләде. Кулдан җыеп булса да, атналык газета чыгара, барча милли бәйрәмнәребезне, йолаларыбызны үткәрә идек. Үз зиратыбыз, мәчет кебек кечкенә генә йортыбыз, муллабыз бар иде. Гомумән, мәхәллә булып, тулы канлы милли тормыш белән яшәргә тырыша идек», – дип сөйләгән иде ул. Өч ел элек Сеулга баргач, Сәгыйть әфәнде биргән адрес буенча ул урынны эзләп карадым. Әмма ләкин анда хәзер зират та, мәктәп тә юк. Фәкать күккә ашкан йортлар гына кукраеп утыра.

Ни өчен эзлим соң татарны? Кан тартмаса – җан тарта, җан тартмаса – кан тарта, диләр. Бәлкем, икесе дә тартадыр. Чөнки бөтен тормышым, кылган гамәлләрем халкыбыз язмышына бәйле. Шуңа күрә татарны өйрәнүем – халкыбызны аңларга тырышу. Татар кешесе кем ул? Америкада, Англиядә, Финляндиядә... нинди ул? Менә шуларны күргәч, татар кешесенең гомуми портреты күз алдына килеп баса. Без еш кына, бердәм булыйк, бергә булыйк, дип сөйлибез. Бу – бик әйбәт шигарь-өндәмә. Әмма алай дип әйтеп кенә бердәмләшеп булмый. Безгә аралашырга, бер-беребезнең уй-фикерләрен белешергә, мөмкин булган кадәр шушы уй-фикерләргә куәт өстәргә һәм үз бергәлегебезне, зур милләт икәнлегебезне тоеп, күңелебезгә сеңдерергә кирәк. Югыйсә Финляндиядә – 800, Америкада – берничә мең, Төркиядә ничәдер йөз мең кеше тупланмый икән, барыбер үзен зур милләт итеп сизә алмаячак.

Әле менә берничә көн элек кенә Екатеринбургтан Сабантуйдан кайттык. «Телебез, йолаларыбыз бетә дип боегып калган идек. Әмма Сабантуйга кырык мең татар җыелгач, Татарстан, Башкортстан республикалары, Свердловск өлкәсе җитәкчеләре килгәч, бөтен стадион, тирә-як урамнар гөрләп торгач, түбәбез күккә тиде, үзебезне зур халык итеп тойдык. Сабантуйга җыелган барча халык татар икәнлегенә горурланып китте», – дип сөйләделәр миңа анда. Менә шушы милли горурлык хисен саклау өчен, очрашып, күрешеп торырга, бер-беребезгә көч-куәт бирергә кирәк.

Американың төрле шәһәрләрендә милли җәмгыятьләребез бар. Минем Вашингтон, Нью-Йорк, Торонто, Монреаль шәһәрләрендәге татар җәмгыятьләрендә булганым бар. АКШ белән Канада бер дәүләт кебек инде, араларында чикләр дә юк диярлек. Әмма төрле штаттагы татарлар берләшсен өчен бер зур, уртак оешма булдырырга кирәк. Бу теләкне алар үзләре дә әйтеп килә. Без дә шундый теләк булганлыгын белдереп килдек. Моның өчен алар иң әүвәл уртак план-ниятләр корып, эшләрен тәңгәлләштерергә, бер-берсенең чарасына йөрергә, аралашып, хуплашып торырга тиеш. Алар моны үзләре дә аңлый, әмма оешып бетә алмый иде. Тагын бер нәрсә бар: АКШ хөкүмәте федераль дәрәҗәдәге җәмгыятьләргә грант бирә. Ким дигәндә – 100 мең, күп дигәндә 600 мең доллар акча дигән сүз бу. Безнең Вашингтон, Нью-Йорк, Сан-Франциско кебек шәһәрләрдә милли җәмгыятьләребез булса да, әлегә федераль, илкүләм оешмаларыбыз юк. Ә штатларда исә андый программа каралмаган. Менә әзәри, төрекләрнең андый федераль оешмалары бар. Әйтик, төрек җәмгыяте ел саен шушы максатта АКШ хөкүмәтеннән 600 мең доллар акча ала. Милләттәшләребез әлеге милли оешмаларга әгъза булып керә икән, взнос түләп тора, чөнки ул җәмгыятьләрнең ике-өч катлы үз бинасы бар. Ул биналарны тотарга, анда төрле

чаралар, бәйрәмнәр уздырырга кирәк. Кеше хасталанса, үлеп китсә, мәшәкате артыннан йөрү зарур. Бу эшләрне финанс ярдәменнән тыш башкарып булмый. Америкада бай кешеләр аз булмаса да, һаман-һаман акча җыеп йөрү күңелле эш түгел. Аннан соң кеше баеган саен, чыгымнары да арта бит. Әйткәнемчә, федераль оешма булса, аңа шушындый саллы ярдәм бирелә. Баруыбызның бер максаты шул федераль оешманы оештыру эшен тизләтү иде. Без бергә Нью-Йорк шәһәрендә зур җыелыш үткәрдек. Төрле штатлардан татар җәмгыятьләре җитәкчеләре җыелды. Шунда әлеге фикеребезне кабат яңгыратып бәхәсләшеп тә алдык, берләшмә булдырырга дигән карарга килдек. Без аларга, киләсе елда Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы корылтае була, шул корылтайга хәтле бер зур татар берләшмәсе булдырып, шул илкүләм оешманың вәкилләре, делегатлары булып килсәгез иде, дигән шарт куйдык.

Аннан соң без Сан-Франциско шәһәре Сабан туенда булдык. Ул Нью-Йорктан шактый еракта, кыйтганың икенче бер читендәге шәһәр. Аралары – 5 мең чакрым. Шушылай җир читендә Сабантуй үткәрүләре шаккаткыч хәл! Алар шулхәтле матур милли киемнәрдән, үз өйләрендә өчпочмак, гөбәдия, чәкчәк, бавырсак пешереп килгәннәр. Балалары шулхәтле матур. Бәйрәмгә дусларын да чакырганнар. Әйтик, казахлар, башка милләт вәкилләре дә бар иде. Дөрес, анда ат чабышлары, милли көрәш юк инде. Әмма бик кызык, бик күңелле булды. Йөрәгемә сары май булып ятканы – анда хәмер сатылмады, кызмача йөрүчеләр күренмәде, тостлар әйтешеп, бер-берсен буш сүзләр белән макташулар юк.

Тагын бер үзенчәлеккә игътибар иттем: анда да татарлар төрле катлау, төркемнәргә бүленә башлаган. Иске татарлар һәм яңа татарлар бар. Иске татарлар XIX гасыр азагында, XX гасыр башында, революциядән соң килгән, сугышта әсирлеккә эләккәннән соң кайтмый калган. Болары инде чын гореф-гадәтләребезне саклаган, телләре безнекенә караганда да чистарак: урыс сүзләре, башка тел сүзләре катнашмаган, саф татар әдәби теле. Бик диниләр. Әмма яңа килгәннәр башка төрле. Аларны әллә ни кабул итеп бетермиләр. Аларның төп максаты – акча эшләү. Моны үзләре дә яшерми икән. Күбесе татарча да белми, дин хакында мәгълүматлары аз, гореф-гадәтләрне өстән-өстән генә белә, хәмергә бик хирыс, диләр. Шуңа күрә аларны якын китерәселәре килми. Әмма без, аларны бик читләштермәгез, аерып куймагыз инде, алар да безнең милләт балалары, әкренләп үзегезгә якынайтыгыз, үзегездәге асыл сыйфатларны аларга да сеңдерә алмассызмы; әүвәл аерым-аерым чакырыгыз, бөтенесе дә сез әйткәнчә түгелдер; шушылай үз арагызга кертсәгез, милләтебез тагын да ныграк укмашыр; акча эшләргә килгәннәр икән, өсләре бөтәйгәч, «ачның күзе – икмәктә, тукның күзе – хикмәттә» дигәндәй, яшәү мәгънәсе, милләт турында уйлый башларлар, дип киңәш бирдек.

Күптән түгел генә АКШка күчеп киткән мәгълүм шәхесләрдән Сабан туена улы белән бергә Мәсгудә Шәмсетдинова килгән иде. Ә инде Нью-Йорктагы җыелышта үзем белгән ике профессорны күрдем. Шулардан Рифат Таби – бигрәк тә мәшһүр кеше. Ул – Нью-Йорктагы атаклы технология университеты профессоры. Бик зыялы кешеләр җыелган иде. Алар, илдә күренекле 18 татар профессоры барлыгын беләбез, дип әйтте. Бәлкем, соңгы арада аларның саны арткандыр да. Чөнки соңгы елларда күчеп китүчеләр күбәйде.

Мине тагын шаккатырганы шул булды: Татарстанда булган барча вакыйгаларны белеп, ишетеп торалар. Чөнки Интернет бар. Бәлкем, ул бер-беребезне якынайтыр, диләр. Әмма бүген Интернетка татар фикерен, милләтебезгә кагылышлы хәбәр-мәгълүматларны кертү җитешми дип тә борчылалар. «Бер-беребезне макташып утыру бәйрәмдә урынлы. Безгә көндәлек тормыштан объектив мәгълүмат кирәк», – дип әйттеләр.

АКШта өч көн ярым гына булсак та, тәэсирләребез бик бай булды. Аерым алганда, артистларыбызны, бигрәк тә алар башкаруында яңгыраган борынгы көй-җырларны яраттылар. Аларны кат-кат кузгатып, үзләре дә кушылып җырладылар. Ни гаҗәп, бөтен җырларның сүзләрен беләләр. «Туган тел»не нәкъ бездәгечә басып җырлыйлар. Миңа бу җәмгыятьтә, сайлап алып җыйган кебек, бөтенесенең дә затлы, зыялы, укымышлы булуы бик ошады. Гомумән, чит илләрдә булып, төшеп калган, әтрәк-әләм татарны күргәнем юк әле (шунысы кызык: татар җәмгыятьләре җитәкчеләре, унлап кеше махсус машина номерлары булдырган, андый язуларны кыйбатрак бәягә сатып алырга була икән. Ул номерларга «tatar» дип язылган. Мәшһүр биючебез

Ирек Мөхәммәтов милләттәшләребезне нәкъ менә шундый номерлы машиналар аша табып алган). «Әгәр яшьләр бераз гына төрле якка тайпыла башласа, син үзеңне генә түгел, без татарларны хурлыкка калдырасың дип, аларны шунда ук урыннарына утыртабыз», – ди алар. Кардәшләребез тарихны яхшы белә, чит илләрдәге мөһаҗир милләттәшләребезнең ничек яшәве белән даими кызыксынып тора. Аларда борынгы документларыбыз бик яхшы сакланган. Менә миңа Оркыя ханым дигән бер күренекле милләттәшебез бер букча борынгы китап биреп җибәрде. Анда Тукай үзе исән вакытта чыккан китаплар, Кытайда, Япониядә мәктәптә укыган дәреслекләр бар. Күченгәндә күп әйберне ташлап калдырырга туры килсә дә, алар бервакытта да китапларын ташлап калдырмаган. Хәтта ул елларда язылган көндәлекләр дә сакланган. «Менә шуларны килеп өйрәнүче булсын иде», – дип калды алар.

Мин 1991 елда Америкага барган чагымда ук Муса Җәлил белән бергә «Идел-Урал» легионында булган кешеләр белән танышкан идем. Хәзер аларның күбесе исән булмаса да, архивлары, көндәлекләре сакланган. «Зинһар, нинди документларыгыз бар, барысын җыеп, безгә алып килеп, Татарстан архивына яки Милли китапханәгә тапшырсагыз иде», – дип мөрәҗәгать иттем кардәшләребезгә. Бик теләп ризалаштылар. Гомумән, чит илләрдә яшәгән татарларда, бигрәк тә өлкән буында документлар шактый күп. Өч ел элек Япониядә булган вакытта Таминдар Мохит белән күрешкән идек. Ул – Гаяз Исхакый, Габдрәшит Ибраһимов белән аралашып калган кеше. Аңарда бик бай архив барлыгын беләм. Әмма ләкин мин барган чакта ул бик хаста, юл казасына очраган иде. Шуңа күрә мәчеткә барып миңа әлеге архивын күрсәтә алмады. Ул архивны да табарга, өйрәнергә иде. Анда заманында Кытайда, Кореяда, Япониядә булган татар җәмгыятьләренең документлары бар. Өлкән буын исән чагында әлеге документларны өйрәнсәк, тарихыбыздагы шактый гына ак тапларны бетерә алыр идек.

*2011*

# «БИШ МЕҢ САРЫК БУЛСА – АЗ, БИШ МЕҢ АРЫСЛАН БУЛСА – КҮП»

Соңгы елларда Русия төбәкләре белән беррәттән дистәләгән чит илләрдә Сабантуй үткәрү йола гына түгел, дәүләт дәрәҗәсендәге зур вакыйгага әйләнде. Без, республика җитәкчелеге фәрманы белән иҗат төркемнәре оештырып, әлеге бәйрәмнәрдә катнашабыз. Бу бик зур теләктәшлек таба, төрле төбәктә яшәгән милләттәшләребез моның өчен безгә зур рәхмәт әйтә. Күптән түгел без Кытайдагы Өремче һәм Голҗа шәһәрләрендә Сабантуйда булып кайттык. Шунда китәр алдыннан бер абзый миңа: «Мәскәүдә, Екатеринбургта Сабантуй үткәрүне аңлыйм, анда бик күп милләттәшләребез яши. Ә биш мең татар яшәгән Кытайга бару кирәкме, бу сан бик аз түгелме соң?» – дип сүз каткан иде. «Биш мең азмы-күпме дип әйтәсез. Әгәр биш мең сарык икән, ул бик аз, әгәр биш мең арыслан булса, бу бик күп», – дип җавап бирдем мин аңа.

Кытайдагы татарларны күргәч, чынлап та, анда биш мең арысланга тиң милләттәшебез яшәвенә инанып кайттым. Бер миллиард ярым кеше – Җир шарының дүрттән бер өлеш халкы яши торган Кытайда да татарны яхшы беләләр. Шушы миллиардлаган кеше гомер сөргән илдә үз татарыбызның ил парламентында депутат булуы, Борһан Шәһиди кебек милләттәшебезнең дәүләт җитәкчесе урынбасары булып эшләве бу хакта яхшы сөйли. Без уйгыр традицион медицинасы хакында фундаменталь хезмәт язган 84 яшьлек Рәкыйп ага Аббас белән очрашып сөйләштек. Без анда профессор Абдулла Аббас белән күрештек. Ул ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы да. Аббас хәзерге вакытта Шенҗаң-Уйгыр автономияле районы депутаты. Ә менә милләттәшләребез Борһан Шәһиди белән Әсгать Исхаков заманында Бөтенкытай парламенты депутаты булып сайланган булганнар. Аларның «район» дигәне халык саны һәм биләгән җире буенча безнең республикадан ун мәртәбә зуррактыр. Анда татарларыбыз чагыштырмача аз булса да, һәрберсе диярлек затлы, зыялы кешеләр. Алар тарихыбызны да әйбәт белә, бүгенге көнкүрешебездән дә яхшы хәбәрдар.

«Чит илләрдә Сабантуй нигә кирәк» диләр кайвакыт. Беренчедән, ул – безнең бик борынгы милли бәйрәмебез. Бүген ул бәйрәм генә түгел, татарны берләштерүче иң мөһим чараларның берсе дә. Әле Екатеринбургтагы федераль Сабантуйда булганнан соң берәүдән шундый сүз ишеттем. «Мин моңарчы татарга мөкиббән, милләтпәрвәр кеше түгел идем, әмма бу Сабантуйга гади кеше булып килдем, татар булып кайтып киттем. Чөнки анда татарның зур, көчле, бөек халык икәнен күрдем», – дип әйтте ул миңа. Бергә җыелгач кына халыкның көче, куәте күренә. Әгәр Екатеринбург Сабан туенда 40 мең кеше, Татарстан, Башкортстан президентлары, Свердловск өлкәсе губернаторы катнашкан икән, бу халыкның дәрәҗәсе, көч-куәте зур булуы хакында сөйли. Көч-куәт Америка татарларында да яхшы күренә. Ә инде Кытайда моны күреп тагы да сокландым. Миллиард ярым халык бит. Шунда аң-белем, укымышлылык ягыннан татарлар иң алдынгы урында санала икән. Бөтенесе диярлек югары белемле. Һәрберсе диярлек үз эшенә мөкиббән киткән, оста кешеләр.

Сабантуй дигәннән. Билгеле, ул бездәге Сабантуйлардан бераз аерыла, нигездә, концерт-тамаша рәвешендәрәк үтә. Америкадагы шикелле монда да милли ризыкларны өйләрендә пешереп алып киләләр. Әмма, башка илләрдән аермалы буларак, Кытай татарлары фольклорыбызны, борынгыдан килгән җыр-биюләребезне яхшы белә икән. Хәтта без онытkan борынгы җырларның да сүзләрен беләләр. Алар осталык ягыннан безнең җырчы-музыкантлардан һич калышмый, моңыбызга һич хилафлык китерми.

Бервакыт үз делегациябез белән бер ашханә янышнан үтеп барабыз, колак салып тыңлап карасак, татар җыры җырлыйлар. Әмма сүзләре аңлашылмый. Шаккаттык: нинди җыр бу? «Сарман»ны җырлыйлар икән. Безне озатып йөргән, табигый, кытайча яхшы белгән татар егетләре: «Бездә кытайлар да, уйгырлар да татар җырларын тәрҗемә итеп үзләренчә җырлый», – дип җавап бирде. «Без бик дус яшибез. Аларны туйларыбызга, мәҗлесләребезгә чакырабыз. Анда гел җырлап

утырабыз. Алар шунда җырларыбызны отып алалар да җырлап йөриләр», – дип аңлаттылар безгә. Кытай музыкасы да, татар музыкасы да пентатоникага нигезләнгән, бик охшаш бит. Андагы милләттәшләребезнең җырга мәхәббәте нигә шушылай зур, көчле икән дисәк, бездәге консерватория, филармония, театр, телевидениене – һәммәсен анда шушы татар җыр-биюе алыштыра. Шуңа күрә гомер буе җырлап яшиләр, гореф-гадәтләребезне дә онытмыйлар. Бигрәк тә «Сарман»ны, «Уракчы кыз»ны матур җырлыйлар. Анда Шадия исемле бер кызның татар моңы белән кытай моңын оста кушып җырлавына исебез китте. Без аны үзебездәге «Татар моңы» конкурсына да катнашырга чакырдык. Кытай мәктәбендә – белем, шул ук вакытта үз гаиләсендә татар тәрбиясе алган бу кызның башкару осталыгы, һич шикләнмим, Татарстандагыларны сокландырмый калмас.

Билгеле, анда да телне саклау проблемасы бар. Милләттәшләребезнең кайберләре теле ягыннан уйгырлашып, кайберләре казахлашып, үзбәкләшеп, кытайлашып бара. Әмма ләкин җаннары, бәгырьләре – татар. Анда, билгеле, безнең сөйләгәнне тулысынча аңлыйлар. Әмма үз сөйләмнәрендә уйгыр, казах, үзбәк телләре тәэсире көчле. Аннары алар һәммәсе дә Татарстанга бик мөкиббән китә. Хәзерге вакытта башкалабыз Казанда 58 кытай татары югары белем ала. Төркиядә, Финляндиядә, Польшада да татарлар байтак югыйсә. Үзбәкстанда, Кыргызстанда, Казахстанда милләттәшләребез аеруча күп. Әмма ул яклардан нишләптер татар баласының шушылай күпләп Казанга укырга килгәне юк әле. Кытай татарларының Казанга булган хөрмәте анда яшәүче башка халыкларга да күчкән. Уйгырлар, казахлар да безгә Казан, Татарстан турында кат-кат сөйләде. «XIX–XX гасырларда татарлар безгә мәгърифәт алып килде», – дип рәхмәт әйтте алар. Уйгырның бер атаклы язучысы: «Монда казахлар, үзбәкләр дә күп, әмма Татарстан кебек, шушындый мәртәбәле делегацияләр җибәреп, үз кардәшләрен олылаган, хөрмәтләгән башка милләт юк әле», – дип, Сабантуйда чыгыш ясады. «Безгә шундый ихтирам күрсәткән өчен Татарстан җитәкчеләренә рәхмәтебезне җиткерегез», – дип калдылар милләттәшләребез. Без, үз чиратыбызда, каршы алып, озатып йөргән милләттәшләребезгә, аеруча Казанда укучы студентларның җитәкчесе Торсынтой Галиевкә зур рәхмәтебезне белдерәбез.

*2011*

# САУМЫ, КИТАП!

Әйдәгез, бүген мин сезне гадәти булмаган очрашуга – Китап иленә кунакка чакырам...
Казан университетының кайда икәнен барыгыз да беләсез инде. Менә шул ак мәрмәр колонналы бина каршында сезне шәһәребезнең иң матур йорты каршы алыр. Казан тарихын яхшы белүчеләр аны әле хәзер дә «Ушков йорты» дип атыйлар, ә инде бүгенге яшьләр, заманчалатып, «Ленин китапханәсе» дип кенә йөртәләр. Ярый, сүземне озынга сузмыйм, рәхим итегез, түрдән узыгыз!
Сырлап-бизәп эшләнгән гаҗәеп матур бу йортның юлбарыс тоткалы ишеген ачып керүгә, нинди патша сараена килеп эләктем икән дип аптырап калмагыз. Борынгы баскычлар буйлап икенче катка менегез. Баскыч култыксаларындагы арыслан, аждаһа сыннарына, стеналардагы күз күрмәгән сәмруг кош сурәтләренә озаклап карап торырга вакыт юк бүген. Фабрикант Ушков төзеткән бу йортның үзе турында гына да аерым китап язарлык! Тс-с! Чү-ү! Монда кычкырып сөйләшергә, шауларга ярамый! Аяк очларына гына басып Зур уку залына үткәч, Мәгарәгә килеп керәбез. Юк, юк, алдамыйм, чып-чын Мәгарәгә! Әнә түшәмнәрдән, стеналардан таш сөңгеләр асылынып тора, Мәгарә диварларын үрмә гөлләр, чәчәкләр сарган... Могҗиза! Әйдәгез, Мәгарә уртасындагы борынгы түгәрәк өстәл янына тезелешеп утырыйк әле. Мин сезне бүген менә шушы мәһабәт сарайның – серле Китап йортының 125 еллык тарихы буйлап сәяхәт итәргә чакырдым. Сүземне нидән башлыйм икән? Нидән булсын, иң беренче көннәреннән үк инде... Тыңлагыз!.. 1830 елда... Юк, 1844 елда... Юк ла, 1865 елда... Юк ла инде, 1906 елда... Туктагыз әле, башламас борын буталып беттем.
Әллә соң бу турыда... китапханәгә нигез салган кеше үзе – Николай Иванович Второв сөйләсенме? Гаҗәпләнмәгез, дуслар, бу тылсымлы Мәгарәдә теләсә нинди могҗиза эшләп була. Чөнки монда бөтен кешелек дөньясының Акыл һәм Хыял көче тупланган КИТАП патшалык итә. Кирәк икән, Второвны гына түгел, йортның элеккеге хуҗасы Ушковны, беренче татар китапханәчесе Закир Сәетзадәне, хәтта атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзине дә чакырып китерербез. Күзләрегезне беразга гына йомып торыгыз да яңадан ачыгыз. Сезнең каршыгызда **Николай Иванович Второв сөйли...**
«Сүзне китапханә рәсми төстә ачылган 1865 елдан түгел, чыннан да, әле генә сез атаган 1830 елдан башлау дөресрәк булыр. Нәкъ менә шул елның 30 июлендә патша хөкүмәте Россиядәге бөтен губерна шәһәрләрендә җәмәгать китапханәләре ачу турында карар кабул итә. Карар кабул итүен итә, әмма ләкин аны тормышка ашыру өчен бер тиен дә акча бирми. Монысын инде шәһәр байлары, зыялылар һәм сәүдәгәрләр үзләре хәл итәргә тиеш дип саный. Кызганычка каршы, берничә мәртәбә җыелышып киңәшсәләр дә, алар арасында акча янчыгын чишәргә атлыгып торган кеше табылмый.
Бу вакыйгалар турында миңа әтием И. А. Второв сөйләде. Ул үз заманының алдынгы карашлы кешеләреннән иде. Н. М. Карамзин, И. П. Тургенев, В. А. Жуковский, А. С. Пушкиннар белән очрашып-аралашып яшәгән кеше буларак, әти китапка аерым бер хөрмәт белән карый иде. Әтием вафат булганнан соң, аның бай китапханәсе мирас булып миңа калды. 1844 елда Казан университетында укыткан җиремнән мине Петербургка эшкә күчерделәр. Киткән чагымда мин әтиемнең китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк итеп калдырдым. Анда төрле телләрдәге 1908 китап һәм журнал бар иде.
Казаннан китүемнән соң егерме ел узгач, 1864 елда, әлеге бүләк-китапханәнең язмышы белән тагын бер кат кызыксынырга булдым. Бу вакытта инде мин Эчке эшләр министрлыгының хуҗалык департаментында вице-директор булып эшли идем. Җавап бик тиз килде. Шәһәр башлыгы П.А.Прибытков 1865 елның 10 гыйнварында (хәзерге исәп буенча 24 ендә) җәмәгать китапханәсе ачылу турында хәбәр итте. Мин бүләк иткән китапларга 20 ел буе бина таба алмаганнар, алар 20 ел буе караңгы бүлмәләрдә тузан җыеп ятканнар икән. Инде, ниһаять, китапханә ачылуына да шәһәр башлыкларының аң-белемгә юл сабарга теләве түгел, ә бары тик минем башкалада зур дәрәҗәгә ия булуым гына сәбәпче икән... Ярый, «Соң булса да, уң булсын»

диләрме әле татарларда? Менә бүген... 125 ел үткәннән соң да... эти бүләк иткән китапларның исән булуын күреп куандым. Аларны иң кадерле җирдә – сирәк китаплар фондында саклавыгыз өчен бик зур рәхмәт... Ә милли мөселман китапханәсе ачу мәсьәләсен ничек хәл иттегез соң? Ул елларда ук татар зыялылары бу турыда сүз кузгата башлаганнар иде бит...»
Шулчак Мәгарә түрендәге бер ишек акрын гына ачылып, аннан татар зыялыларыча ыспай-пөхтә киенгән түбәтәйле кеше пәйда булды. Керә-керешкә ул мыек астыннан елмаеп сүз башлады...
**Закир Сәетзадә сөйли...**
«Үз дәүләте, үз хөкүмәте булмаган халыкның сүзенә кем колак салсын?.. Мөселман китапханәсе ачу кирәклеген тагын утыз ел буе исбатлап йөрергә туры килде. 1905 елгы шифалы үзгәрешләр булмаса, белмим, татар китапханәсе кайчан гына ачылыр иде икән әле...
Безнең татар халкы китапка һәрвакыт мөкиббән киткән. Китап сүзе татарда изге сүз саналган, кешеләр китап тотып ант итә торган булганнар, һәр өйдә китап иң кадерле урында сакланган. Ләкин татарча китаплар инде 200 ел буе басылып килүгә карамастан, Рәсәйдә шул басмалар тупланган һәм рәсми рәвештә эшләүче китапханәләр булмаган. XIX гасырның икенче яртысында гына да 3300 исемдәге 26 миллион 864 мең данә татар китабы дөнья күргән югыйсә...
Татар халкы өчен җан атып йөргән Һади Максуди, ниһаять, 1906 елның 2 гыйнварында Казанда мөселман җәмәгать китапханәсе ачу өчен рөхсәт ала. Шәһәр башлыклары «сәдаканы» бик аз тамызгач та, ул югалып калмый, китапханә өчен үз мөлкәтеннән өлеш чыгара, хәтта шәхси китапларын да китереп тапшыра, ярдәм сорап бертуган Кәримовларга һәм башка татар байларына мөрәҗәгать итә.
Мәчеттән һәм базардан башка җыелышыр урыны булмаган мөселманнар өчен китапханә ачылу чын бәйрәмгә әверелә. Һади Максуди чакыруы буенча китапханәгә эшкә алынгач, мин татар халкының аң-белемгә никадәр сусавын, китапка хөрмәтен үз күзләрем белән күрдем. «Болгар» кунакханәсенең өченче катында урнашкан китапханәгә халык, мәчеткә килгән кебек, юынып-чистарынып, иң яхшы киемнәрен киеп килә иде. Шәкертләр, укучылар, һөнәрчеләр китапханәгә керү өчен иртән иртүк чират ала торганнар иде. Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтовлар да еш кына кереп безнең хәлне беләләр, сорашалар, үзләре дә китаплар алып укыйлар иде. Гомумән, берничә елда Шәрык китапханәсе бөтен укымышлы татарларның мәдәният үзәгенә әверелде. Ләкин озакламый Казанда канлы бәрелешләр башланды. 1918 елда акгвардиячеләр мине атып үтерделәр...»
Әлеге шомлы сүзләр ишетелүгә, Мәгарә тетрәп куйгандай булды. Закир Сәетзадә шул арада каядыр юкка чыкты. Тынлыкны бүлеп, Мәгарә түрендәге ишек ачылды. Аннан барыбызга да таныш кеше... Мирхәйдәр Фәйзи күренде...

**Мирхәйдәр Фәйзи сөйли...**
«Дөньялар бераз тынычлангач, Мулланур Вахитов исемендәге Шәрык китапханәсе яңадан гөрләп эшли башлады. Озакламый анда Габдулла Тукай исемендәге балалар бүлеге дә ачылды. Минем үземә дә 1923 елның сентябреннән 1924 елның июненә кадәр шунда китапханәче булып эшләргә туры килде. Сез әлегә кадәр мине «Галиябану» пьесасын язган драматург буларак кына беләсездер. Гаҗәпләнмәгез, бер мин генә түгел, русның атаклы шагыйре, мәсәлче Иван Крылов, бөтен дөньяга танылган галим Лобачевский да заманында китапханәче булып эшләгән. Лобачевский хәтта үзенең китапханәче вазифасын Казан университеты ректоры булуга караганда да өстенрәк санаган...
Шушы китапханәдә хезмәт итүем вакытында мин балалар белән бергә әдәбият түгәрәге оештырдым. Без анда китап күргәзмәләре, төрле кичәләр үткәрә торган идек. Кайберәүләр әдәби түгәрәккә бары тик шигырь яисә хикәя язучылар гына йөрергә тиеш дип уйлый торгандыр. Ә минемчә, анда барлык әдәбият сөючеләр, китап дуслары йөрсә, файдасы тагын да зуррак булыр иде.
Менә шулай гомерем буе китап яраттым, гомерем буе китап белән аралашып, серләшеп, кайгымны уртаклашып яшәдем мин. Дусларым хыянәт иткән чаклар булды, әмма китаплар миңа

беркайчан начарлык кылмадылар, начарлыкка өндәмәделәр. Бу дөньяда китаптан да яхшырак юлдаш, китаптан да ышанычлырак иптәш юк...»
Шулай диде дә... Мирхәйдәр Фәйзи, салмак кына атлап, Мәгарә ишегеннән кереп китте. Әйдәгез, без дә аның артыннан иярик...

**Китаплар ни сөйли...**
Әгәр В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсендәге барлык китапларның да ни сөйләгәнен белергә җыенсагыз, бу хыялыгыздан башта ук ваз кичәргә киңәш итәм. Чөнки мондагы өч миллион китапны укып чыгу түгел, хәтта ашык-пошык актару өчен генә дә сезнең гомерегез җитмәячәк. Шуңа күрә китапханәгә килгәндә, һәр укучы үзенә нинди китап кирәк икәнен белергә тиеш. Ә инде белми икән, ул чакта китапханәчеләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.
Ә-әнә, теге бүлмәдә, гадәттә, галимнәр, аспирантлар, студентлар утыра. Унҗиденче, унсигезенче, унтугызынчы гасырларда басылган китап битләрен сак кына ачып, үткән буыннар белән, тарих белән сөйләшә алар. Ул китапларның чын бәясен, кадерен аңлар өчен аларны үз кулларың белән тотып карарга кирәк. Сирәк китаплар бүлегендә саклanучы кулъязмалар һәм борынгы китапларны уку нияте белән безгә Казаннан һәм Татарстаннан гына түгел, илебезнең төрле төбәкләреннән киләләр, хәтта чит илләрдән дә мөрәҗәгать итәләр.
Галимнәргә комачауламыйк, юлыбызны дәвам итик. Менә бу бүлектә татар китаплары һәм туган якны өйрәнүгә багышланган басмалар тупланган. Моннан төгәл алтмыш ел элек, 1929 елда, Шәрык китапханәсе безнең китапханәгә кушылганнан соң килгән китаплар бу. Әлеге киштәләр яныннан узган чакта, мин үзем һәрвакыт тукталып уйга чумып торам. Әйтерсең нахакка рәнҗетелгән, яндырылган һәм юкка чыгарылган меңнәрчә китаплар рухын рәнҗегән күңелем аша үткәрәм. Китап язмышы да кеше язмышы кебек шул. Алар да дөньяга килә, аларны да кыерсыталар, зинданнарга ябып куялар, ә кайберләрен кирәксә-кирәкмәсә дә күккә чөяләр, ә кайберләрен учакларга салалар. Утызынчы-илленче елларда татар халкының иң асыл кешеләре белән бергә гасырлар буе тупланып килгән иң асыл китаплары да юкка чыгарылган... Шушы бушаган киштәләрне тутыру өчен, без хәзер әби-бабайларның сандык төпләрендә, башка республикалардагы, чит илләрдәге китапханәләрдә исән калган китапларны берәмләп җыябыз. Ләкин бу бик тә катлаулы һәм күп хезмәт сорый торган эш. (Әгәр сезнең өегездә шундый китаплар булса, без аларны бик теләп үзләренең ишләре янына куяр идек. Алар монда халкыбызга хезмәт итәр, киләчәк буыннарга мирас булып калыр иде.)
...Менә безнең китап иленә кыскача сәяхәтебез тәмамланып та килә. Дөресрәге, сезнең өчен бу сәяхәт әле башлана гына.
Хыялланып, вакыт узганны сизми дә калганмын. Сез саубуллашып чыгып барасыз түгелме соң инде? Ярый, урамга чыккач, кешеләрнең йөзенә игътибар беләнрәк карагыз әле! Әгәр дә каршыгызга очраган кешенең йөзендә яктылык, күзләрендә нур күрсәгез, ялгышмассыз. Бу, һичшиксез, акыллы китап битләреннән күчкән яктылык – иман нуры булыр.
Казан урамнары буйлап сәяхәт кылган чакта Ленин урамының иң түрендә урнашкан гаҗәеп гүзәл йорт яныннан үтәргә онытмагыз. Көндез килсәгез дә, төнлә узсагыз да – аның тәрәзәләре һәрчак якты булыр, аның заллары якты йөзле, якты күңелле кешеләр белән шыгрым тулып торыр.

*1990*

# КИТАПКА ХИТАБ

Моннан берничә ел элек миңа үзебезнең тел һәм дин кардәшләребез янына – Төркиягә барырга туры килгән иде. Шул сәяхәт вакытында иң истә калган хатирәләрнең берсе – Эфес шәһәре һәм бигрәк тә аның борынгы китапханәсе булды. Безнең эрага кадәр бер гасыр элек салынган бу атаклы каланың нәкъ үзәгендә бик ерактан ук иң зур, иң матур, иң мәһабәт бина – китапханә бинасы күренеп тора. Моннан ике мең ел элек яшәгән патшалар, фараоннар китапханәләрне үзләренең сарайларына караганда да затлырак итеп төзегәннәр. Кеше гомеренең бик тә кыска икәнен, кеше акылын, кеше аңын, кеше рухын һәм кешелек хәтерен бары тик Китап аша гына саклап калырга һәм киләчәк буыннарга тапшырырга мөмкин булуын яхшы, бик яхшы аңлаган алар. Акыллы патшалар иң элек үз халкының язмышы, аның рухи байлыгы турында кайгырткannар, аңа мәңгелектән урын эзләгәннәр.
Әйдәгез, без дә күзләребезне йомып, бераз гына хыялланып алыйк әле. Әйтик, Казан каласы әле һаман җимерелмәгән, Сөембикә патшабызның китапханәсе бүген дә исән, ди... Шул китапханәдәге китапларны укып, без бүген инде күптән онытылган тарих сәхифәләрен барлап чыгар идек, тарихи хәтерен җуйган халкыбызга үзенең чын, бозылмаган тәрҗемәи хәлен сөйләп, аның боек күңеленә өмет һәм ышаныч рухы иңдерер идек. Кызганычка каршы, Сөембикә китапханәсе һәм тагын шундый йөзләгән-меңләгән язма һәм басма әсәрләребез инде мәңгегә юкка чыккан. Алар белән бергә катлаулы һәм данлы тарихыбыз да онытылган, халык хәтере саеккан...
Бәхеткә каршы, безнең киләчәгебез бөтенләй үк өметсез түгел әле. Соңгы елларда халкыбызның үз туган теленә, гореф-гадәтләренә, тарихына сусаганын күрү, милләттәшләребез күңелендә милли горурлык хисе уяна башлавын тою бик тә куанычлы хәл. Ә халык тарихын, аның рухи байлыгын өйрәнү өчен иң кулай урын – китапханә.
Республикабызның В. И. Ленин исемендәге баш китапханәсе үзенең 125 еллык бәйрәмен билгеләп үткән көннәрдә минем бу турыда авыз тутырып әйтәсем, бөтен кешеләргә дә ишетелерлек итеп кычкырасым килә. Чөнки безнең китапханәдә, шулай ук университет һәм Фәннәр академиясе Казан филиалы китапханәләрендәге мең бәлаләр аша исән калган рухи хәзинәнең нинди зур бәягә ия булганын, аларны нинди кадер-хөрмәт белән сакларга кирәклеген әле бик күпләребез бүген дә аңлап бетерми.
Рәсми төстә 1865 елның 24 (10) гыйнварында ачылган, ә инде китаплары аңа кадәр берничә дистә еллар буена җыела килгән безнең китапханә бүгенге көндә бөтен илдә иң борынгы һәм бай китапханәләрдән санала. Аның киштәләрендә моннан ике, өч, дүрт гасыр элек басылган 3 миллионга якын китап саклануын, бу китапханәгә даими төстә 51 мең кеше йөрүен генә әйтеп үтсәк тә, алда санап үтелгән сүзләрне дәлилләү өчен җитәр иде. Ә инде болар янына сирәк китаплар фондындагы А. Пушкин, М. Лермонтов, Л. Толстой, И. Тургенев, Ш. Мәрҗани, Һ. Атласи, Һ. Максуди, Г. Исхакый һәм тагын йөзләгән әдипләрнең үзләре исән чакта басылган китапларын да өстәсәк, аннары даими төстә килеп торучы меңнән артык исемдәге газета-журналларны да искә төшерсәк, әдипләребез һәм күренекле кешеләребезгә багышланган очрашу-кичәләрне, китап күргәзмәләрен, гарәп язуы өйрәтү дәресләрен һәм тавык та чүпләп бетерә алмаслык башка мәдәни мәшәкатьләрне дә хәтердән уздырсак, Ленин китапханәсенең эшчәнлеге тагын да ачыграк булып күз алдына килеп басар иде.
Ләкин минем мактанып, горурланып сөйли торган сүзләрем шушы урында өзелеп, җанны һәрдаим борчып, тырнап торган шомлы уйлар өскә калкып чыга. Чөнки безнең китапханә – татар халкының милли, рухи үзәге булырга тиешле баш китапханәбез бүген гаҗәеп авыр хәлдә. Мәдәниятле һәм бай тарихлы халыклар өф-өф итеп, каравылчы куеп тимер сейфларда гына саклый торган иң кадерле һәм күп очракта бердәнбер (!) данәдә генә булган китапларыбыз инде ничә еллар буена тынчу һәм кысан бүлмәләрдә идәннән түшәмгә кадәр утын әрдәнәсе сыман өелеп ята: чери, туза, бозыла, битләре биткә ябыша, тышлыклары куба, хәрефләре танымас хәлгә

килә. Бүгенге көндә 300 мең китап сакланырга тиешле бернинди уңайлыклары булмаган бинадагы 3 миллионга якын китапның күбесе менә шундый язмышка дучар ителгән. Нишләргә? Өч ел буена талашып-ызгышып, үтенеп-ялварып сорый торгач, ниһаять, безгә ВЛКСМ өлкә комитетының өч катлы бинасыннан өлеш чыгарырга булдылар. Моңа кадәр биш дистә комсомол вожагы хакимлек иткән бинага үзебезнең юеш подвалларда тилмереп яткан 500 мең китапны күчергәч, без рейхстагны алган совет солдатлары кебек куанган, бәйрәм иткән идек. Ләкин бәйрәм рухы бик тиз сүрелде. Ярты ел эчендә генә дә уртак бинабызның өченче катында үзгәртеп кору белән мәшгуль булган данлы комсомол эшлекләләре безне, димәк, китапларны, инде өченче мәртәбә су белән бастырдылар. Җитәкчеләрнең һәммәсе дә сүздә безнең хәлне аңлый, вәгъдәләр бирә, тик бирәү дә мәсьәләне чынлап торып хәл итәргә җыенмый.

Китапханә кемгә кирәк? Җитәкчеләребезгә генә өмет баглап, аларның китапханәгә өстәмә бина бирүен яисә яңасын салуын тыныч кына көтеп ятсак, безнең болай да таланган рухи хәзинәбезне, соңгы байлыгыбызны да бөтенләе белән югалтуыбыз бик ихтимал. Китапханә, сезнең һәм безнең өчен, үзен бай тарихлы, якты киләчәкле халык итеп күрергә теләгән милли иманлы, таза рухлы кешеләребез өчен кирәк. Без бөтенебез бергәләп тотынган очракта гына халкыбызның гасырлар буена саклап килгән иң зур байлыгын – Китап битләренә салынган Хәтерен бөтенләй юкка чыгудан коткарып, киләчәк буыннарга тапшыра алачакбыз.

*1990*

# ТАРИХ МЕҢ ДӘ СИГЕЗ ЙӨЗ ДӘ...

*Шушы елның егерме дүртенче гыйнварында В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсе ачылуга 125 ел тула. Хәзер аны халыкта «Ленин китапханәсе» дип йөртәләр. Татарстанда гына түгел, хәтта бөтен илдә иң зур, иң бай, иң борынгылардан саналган китапханәнең олы юбилее уңае белән сүзебезне моннан 125 ел элек булган хәлләрдән башлыйк...*

**1844 елда** Казан университеты галиме Николай Иванович Второв Петербургка күчеп киткәндә, әтисенең китапханәсен губерна идарәсенә бүләк итеп калдыра. 903 исемдәге 1908 китаптан торган бу китапханәдә рус һәм дөнья классиклары әсәрләре, тарих һәм география буенча хезмәтләр, төрле журналлар тупланган була. Республика фәнни китапханәсенә иң беренче нигез салган әлеге китаплар әле хәзер дә сирәк басмалар бүлегенең иң кадерле хәзинәләреннән санала.
Ләкин китап язмышы да, кеше язмышы, халык язмышы сыман, гел бәйрәмнән генә тормый икән. 1844 елдан башлап егерме ел дәвамында бу китаплар бер бинадан икенче бинага, бер кулдан икенче кулга күчеп йөри, кайберләре югала. Бәхеткә, Казаннан киткән Н. И. Второв Эчке эшләр министрлыгындагы хуҗалык эшләре департаментының вице-директоры дәрәҗәсенә күтәрелә, һәм көннәрдән бер көнне ул үзе бүләк итеп калдырган китапларның язмышы белән кызыксынырга ният итә. Ул чорда да «олы башкала»ның сүзе үтемле булган, күрәсең, шәһәр башлыгы П. А. Прибытков тиз арада Н. И. Второвка китапханә ачылу турында хәбәр итә, хәтта уку залына кую өчен аның портретын да сорый. Билгеле, Н. И. Второв китапханәгә үз портретын түгел, китапларның төп хуҗасы булган әтисенең сурәтен җибәрә, һәм бу портрет озак еллар буе китапханәнең элеккеге бинасында (хәзер анда Казан шәһәр Советы аппараты урнашкан) эленеп тора.
**1865 елның 24(10) гыйнварында** тантаналы төстә Казанда беренче җәмәгать китапханәсе ачыла. Тантанада чыгыш ясаучы В. П. Вишневский болай ди: «Мисыр патшаларының берсе бик мәһабәт китапханә салдырып, аның ишеге өстенә «ҖАН ДӘВАСЫ» дип яздырган булган. Бүген ачыла торган җәмәгать китапханәсендә андый сүзләр язылмаса да, бу йортка йөргән кешеләрнең күңеле һәрчак көр, иманы нык, җаны сәламәт булыр дип ният итәбез, шушы изге теләкләр белән аңа фатиха бирәбез».
Безнең архивта беренче һәм икенче атнада китапханәгә кемнәр йөрүе хакындагы документ саклана. Беренче атнада анда 110 китап укучы килгән, икенче атнада инде аларның саны 140 ка җиткән. Алар арасында 62 университет студенты, 21 семинария укучысы, 14 гимназист, 8 укытучы, 7 чиновник, 7 сәүдәгәр, 1 дин әһеле, 13 һөнәрче булган. Түләүсез җәмәгать китапханәсен Казан халкы тиз арада үз итеп өлгергән. Ачылуының икенче елында аның 8503 укучысы булса, егерме ел үткәч, 1886 елда, аңа инде 15134 кеше йөрүе турында мәгълүматлар бар. 1906 елда китап укучыларның саны 38196 га җиткән.
Шәһәрдәге бердәнбер җәмәгать китапханәсенең фондлары да күзгә күренеп үсә. 50 еллык юбилеен үткәргәндә, андагы китапларның саны 30 меңнән артып китә, уку залына 110 исемдәге газета-журнал алдырыла.
Гомер-гомергә язма һәм басма китапка изге нәрсә итеп караган татар халкының укымышлы вәкилләре дә шәһәрдә милли китапханә ачу мәсьәләсен кузгаталар. Җәмәгатьчелек таләбен Һ. Максуди берничә мәртәбә шәһәр Думасына да җиткерә. Кат-кат сораулардан, үтенүләрдән, ялварулардан соң, ниһаять,
**1906 елның 16(2) гыйнварында** татарлар өчен шәһәрнең Яңа бистә өлешендә аерым филиал ачыла. Ачылган вакытта анда 915 исемдәге 1277 том татар, гарәп, фарсы, төрек, рус телләрендәге китаплар була. «Болгар» кунакханәсенең өченче катындагы ике бүлмәне биләгән китапханә тиз арада татар укымышлыларының яратып йөри торган урынына әйләнә.
Китапханә бүлмәләреннән иртәдән кичкә кадәр Казанның «Мөхәммәдия», «Халидия», «Касыймия» мәдрәсәләре шәкертләре, укытучылар, укучылар, сәүдәгәрләр, кәсепчеләр,

һөнәрчеләр өзелми. Китаплар һәм укучылар саны ягыннан татар филиалы берничә ел эчендә төп бинадагы рус китапханәсен куып җитә. Шул елларда чыккан газеталарда татар китапханәсенә керү өчен озын-озын чиратлар тезелүен хәбәр иткән мәкаләләр басыла.

1922 елның маеннан ул «Мулланур Вахитов исемендәге Шәрык китапханәсе» дип йөртелә башлый. Китапханәдә белешмә-библиография эше җайга салына, фәнни хезмәт белән шөгыльләнүчеләр өчен аерым бүлмә ачыла, балалар өчен Габдулла Тукай исемендәге бүлек оештырыла. Әлеге бүлектә эшләүче атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи җитәкчелегендә әдәби түгәрәк төзелә, анда төрле әдәби кичәләр, китап күргәзмәләре үткәрелә. Шушы китапханәдә эшләгәндә, М. Фәйзи «Коммунага» исемле пьеса язып, балалар көче белән аны сәхнәгә дә куя.

Егерменче ел азакларында, утызынчы ел башларында төрле эреләндерүләр, үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә бу китапханә бер оешмадан икенчесенә күчеп йөри, аның озак еллар буенча бөртекләп җыйган бай фонды бүлгәләнеп, төрле китапханәләргә таратыла. Ахыргы чиктә Шәрык китапханәсе шәһәр үзәк китапханәсенең татар бүлеге итеп үзгәртелә.

Безнең китапханәдә әлеге татар филиалы ачылу тарихы белән бәйләнгән бер бик кызыклы документ бар. Әле китапханәнең татар бүлеге ачылганчы ук, 1905 елның 11 декабрендә, 30 татар хатын-кызы җыелышып шәһәр башлыгына болай дип хат язалар: *«Казан шәһәр идарәсенең һәм мөселман халкының игелекле эшләре нәтиҗәсе буларак, җәмәгать китапханәсенең мөселман бүлеге ачыла. Ләкин, безнең дини кануннарыбыз кушуы буенча, бу гали аң-белем йортына бары тик ир-атлар гына кертеләчәк. Без, мөселман хатын-кызлары, үзебезнең аң-белемебезне баету максатыннан, шушы уку йортына йөрергә телибез һәм шул турыда сездән, Галиҗәнапларыбыз, көненә ике сәгать китапханәгә бары тик хатын-кызлар гына йөрү өчен рөхсәт сорыйбыз».*

Саргаеп беткән бу кәгазь битенең өстәге сул як почмагына матур хәрефләрне сырлый-сырлый мондый сүзләр язылган, безнеңчә әйтсәк, виза салынган... *«Китапханә комитетына. Уңайрак бинага күчкәнгә кадәр үтенечне канәгатьләндерү мөмкин түгел».*

1913 елда гына «мөселман хатын-кызларына якшәмбе көннәрне сәгать 12 дән 14 кә кадәр китапханә филиалына йөрергә рөхсәт бирелә».

Бүгенге көндә Республика китапханәләрендә эшләүче алты меңгә якын китапханәченең барысы да диярлек, китап укучыларның яртысыннан күбрәге хатын-кыз булуын искә төшерсәк, бу хәл аерата сәер тоела башлый.

Инде бүгенге көнгә, бүгенге укучыларыбыз, бүгенге китапханәчеләребез һәм китапларыбыз янына әйләнеп кайтыйк, аларның хәлен белешик...

**1990 елның 24 гыйнварында** В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсе ишеген ачып кергән китап укучыларны кемнәр каршы ала, нинди китаплар көтә? Казанда һәм республикада яшәүче халыкның рухи һәм профессиональ ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен һәр елны китапханәгә 140 мең данә басма әдәбият, бер мең исемдәге журнал, йөзләгән газета һәм музыкаль язмалар алдырабыз. Безнең китапханәгә барлыгы 51 мең кеше йөри. Ел дәвамында алар 1 миллион 550 мең китап алып укыйлар. Йөздән артык китапханәче төрле һөнәр ияләренә, студентларга, аспирантларга, галимнәргә, укучыларга җаны теләгән китапны табарга булыша, һәр көн саен меңләгән төрле белешмә бирә, библиографик кулланмалар әзерли, китап күргәзмәләре оештыра, кичәләр үткәрә. Болар өстенә без әле республикадагы ике меңгә якын дәүләт китапханәсенә даими методик ярдәм күрсәтәбез, аларның эшенә юнәлеш бирү, контроль булдыру максаты белән командировкаларга йөрибез, фәнни-практик конференцияләр үткәрәбез, культура институты студентлары өчен практик дәресләр бирәбез, китапханәара абонемент аша читтә яшәүче 6 мең укучыны китаплар һәм ксерокопияләр белән тәэмин итәбез.

Республика фәнни китапханәсе Татарстанның иң зур информация үзәкләреннән санала. Иртәнге тугыздан кичке сәгать тугызга кадәр Казанның һәм республиканың төрле оешмаларыннан безгә мең төрле сораулар белән шылтыраталар. Уйлап табучыларны – яңа патентлар, язучыларны – үзләренең төрле телләрдә чыккан әсәрләре, җитәкчеләрне – республика хакында ил матбугатында чыккан хәбәрләр, тарихчыларны – борынгы китаплар, музыка сөючеләрне – яңа язмалар, чит тел һәм гарәп графикасын өйрәнүчеләрне безнең дәресләр кызыксындыра...

Һәр атнаның җомгасы – китапханә өчен иң тыныч көн. Бу көнне безгә укучылар килми. Китапханәчеләр үзләре генә каталогларны тәртипкә китерәләр, тузган-искергән китапларны гамәлдән чыгаралар, атна буена җыелып килгән сорауларга җавап әзерлиләр.
Әнә сирәк китаплар бүлегендә – иң кадерле урында – Второв фонды. Менә монда Карамзинның, Ломоносовның, Державинның, Пушкинның, Гогольнең, Тургеневның, Мәрҗанинең, Тукайның әле үзләре исән чакта ук басылган китаплары. Бу басмаларны, бәлки, китапханәче Лобачевскийлар, химик Бутлеровлар, пешекче Пешковлар, гыйсъянчы Такташлар, студент Җәлилләр, Туфаннар, Кутуйлар кулларына тоткандыр... К. Маркс, Ф. Энгельс, Чернышевскийның менә бу әсәрләрен Кокушкинода сөргендә ятучы Володя Ульянов соратып алдыргандыр... Болары утызынчы-илленче еллар мәхшәреннән мең маҗаралар белән исән калган гарәп һәм латин язулы китапларыбыз. Аларның саргайган битләренә күпме милләттәшебезнең күз нуры сеңгәндер, аларның битләрендәге якты иман нуры күпме кешеләрнең күңеленә күчкәндер. Киштәләр арасыннан атлый-атлый, унтугызынчы, унсигезенче гасырны үтәсең, унҗиденче гасырга барып чыгасың.
Бик ләззәтле дә, шулай ук газаплы да ул китап иленә сәяхәт. Китап язмышы ул – безнең язмыш, китап язмышы ул – халык язмышы. Казан ханлыгы җимерелгән – Сөембикә китапханәсе юкка чыккан, халыкка азмы-күпме ирек бирелүгә, иң элек тагын китаплар, газета-журналлар дөньяга килә башлаган, шәхес культы котырган елларда халыкның иң асыл кешеләре белән бергә иң асыл китаплары да һәлак булган.
«Халыкның культура дәрәҗәсен белү өчен аның милли китапханәсенә кереп карау җитә», – дип дөрес әйтә торгандыр академик Д. С. Лихачёв.

## Киләчәк турында

уйлый башласам, минем күз алдында мәгарәдә китап укып ятучы Әбүгалисина белән Әбелхарис килә дә баса. Әллә инде безнең китапханәдә нәкъ шул әкияттәге сыман мәгарә булганга, әллә инде монда Әбүгалисина кебек фанатиклар эшләгәнгә күрә – еллар узган саен, республиканың Үзәк китапханәсе минем өчен бу дөньяның иң кыйммәтле байлыгы тупланган иң зур хәзинә сараена, дөнья үзәгенә әверелә бара. Әгәр берәр галим кандидатлык яисә докторлык диссертациясе якласа, китапханәче аның көннәр буе мәгарәдән чыкмыйча утырганын искә төшереп сөенә, КамАЗда яисә бүтән заводта нинди дер яңа ачышны кулланышка кертсәләр, монда үзе почта аша җибәргән патентларның да өлеше бар дип куана, студентның кояштай балкып имтиханнан чыгуын күрсә, урамда яисә трамвайда берничә кешенең яңа китап турында бәхәсләшүен ишетсә, ирексездән елмаеп куя.
Татарстандагы Үзәк китап йортының киләчәген менә болай итеп күз алдына китерә алар...
Тагын төгәл биш елдан, Казанның нәкъ үзәгендә, М. Вахитов һәйкәле артындагы калкулыкта, алты катлы мәһабәт бина калкып чыгар. (Бүгенге көндә аның проекты эшләнә инде.) Мәрмәр һәм гранитка төренгән бу гүзәл йортта китап белән кызыксынган һәммә кеше өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылыр. Компьютерлар сиңа кирәкле китапны яисә белешмәне күз ачып йомганчы табарга булышыр, ксерокс тиз арада күчермәләр эшләп бирер, әти-әниләре белән килгән балалар өчен видеомагнитофоннан мультфильмнар күрсәтелер... Китапханәдәге әдәби театрда аерым әсәрләргә багышлап спектакльләр уйналыр, язучылар иҗатына багышланган кичәләр үткәрелер. Татар китабы музее оешканнан соң, төрле китапханәләрдә кадерсез булып яткан борынгы басмаларыбыз бер йортка тупланыр. Тора-бара Республика фәнни китапханәсе хәзергечә Татарстанда гына түгел, ә бөтен илдәге татар китапханәләренең үзәгенә әверелер, аларның эшенә юнәлеш бирүне, татар китабын пропагандалау буенча методик ярдәм күрсәтүне ил күләмендә үз җилкәсенә алыр...
Татлы хыялга бирелеп, мин әле бүген китапханәчеләрнең, (димәк, хөрмәтле хатын-кызларыбызның!) илебездә иң түбән хезмәт хакы алуларын да, аларга фатирлар һәм ясле-бакчаларны иң соңгы чиратта гына бирүләрен дә әйтергә онытпыйм. Илебездә иң түбән хезмәт хакы алучыларның иң югары культуралы кеше тәрбияләргә тиеш икәнен дә әйтмәдем. Дөресрәге,

иң зур китапханәбезнең – Ленин китапханәсенең олуг юбилее көннәрендә «юк-бар» белән тагын бер тапкыр кәефне төшерәсем килмәде.
Ныклабрак уйласаң, чыннан да, китапханәчеләр безнең илдә, юк, илдә генә түгел, бөтен дөньяда иң бай, иң бәхетле халык бит! Гасырлар буена кешелек акылы туплап килгән искиткеч хәзинәнең хуҗасы булу, белемгә, яктылыкка омтылган меңнәрчә, миллионнарча кешеләргә үзеңнең һәрчак кирәк икәнеңне тоюдан да зуррак бәхет булуы мөмкинме соң?!

*1990*

# БЕЗ КЕМНӘН КИМ?[1]

Дөньяда ел саен миллиардлаган тиражлар белән миллионлаган исемдә китаплар чыгып тора, ә вакытлы матбугат битләрендә басылган язмаларның саны тагын да күбрәк. Фәннең төрле өлкәләрендә ачышлар артыннан ачышлар, әдәбият-сәнгать өлкәсендә меңләгән яңа исемнәр, яңа әсәрләр туа. Дәрья кебек җәелгән бу информация дөньясында булган хезмәтләрне барлау, классификацияләү буенча хәзер бөтен илләрдә фәнни үзәкләр оештырыла. Шушы максатлардан чыгып, гомуми һәм аерым өлкәләргә караган энциклопедияләр төзелеп, басылып килә. Әйтик, менә СССРда универсаль «Зур совет энциклопедиясе» белән рәттән, «Совет тарих энциклопедиясе», «Кыскача әдәбият энциклопедиясе», «Географик энциклопедия», «Юридик энциклопедия» кебек хезмәтләр дә чыга башлады.

Информациянең туктаусыз арта баруы яңа төр энциклопедия төзүгә дә китерде. Сүз «Кемне кем дип белергә?» («Кто есть кто?») тибындагы аерым шәхесләрне эченә алган энциклопедияләр турында бара. Бездә чыккан «Татар совет язучылары» дигән белешмә дә шундыйлар рәтенә керә. Хәзер андый энциклопедияләр аерым регион буенча гына түгел, дөньяга билгеле шәхесләрне эченә ала торганнары да басыла башлады, һәм алар бик кирәк. Чөнки информация муллыгы заманында теге яки бу өлкәдәге ачышларны чагылдыручы хезмәтләр белән рәттән теге яки бу өлкәдә дөнья күләмендә нинди кешеләр эшләвен эченә алганнары да кирәк, алардан башка фәнни, мәдәни элемтәләр тоткарланыр иде.

Менә шуларны искә алып, шәхси энциклопедияләр чыгару да тормышка аша башлады. Бу эшкә беренче булып Англиядәге Кембридж шәһәрендә керештеләр. Моннан чирек гасыр элек анда «Халыкара биографик үзәк» (ХБҮ) дигән фәнни-энциклопедик информация институты оешты. Бу эшнең башында фәннәр докторы, хәзерге көндә дә шушы институтның генераль директоры булып эшләүче Эрнест Кэй торды. Башта бу институт үз эшен «Халыкара биографик сүзлек» исеме астында гомумирәк характердагы шәхси энциклопедия төзүдән башлаган иде. Хәзер исә «Кемне кем дип белергә?» дигән 16 төр атамалы энциклопедияләр хәзерләнә. Менә кайберләренең исемнәре: «Дөньяның күренекле язучылары», «Дөньяның күренекле музыкантлары һәм композиторлары», «Дөньяның атаклы табиблары», «Эшлекле хатын-кызлар», «Эшлекле ирләр», «Дөньяның интеллектуаллары», «Төрле өлкәләрдә зур уңышларга ирешкән кешеләр»... Кайберләре ел саен диярлек чыгып тора, арада 20 дән артык басма булып чыкканнары да бар. Аларга 200 меңнән артык шәхес турында белешмә урнаштырылган, һәр шәхеснең исеме, туган елы, гаиләсе, нинди уку йортын тәмамлавы, кайда һәм кем булып эшләве, фәнни һәм мактаулы исемнәре, нинди оешмаларның эшендә катнашуы, басылган китаплары һәм аның турында басылган әдәбиятның исемлеге китерелә. Ул кеше белән элемтәгә керү өчен аның адресы да урнаштырыла.

ХБҮ үрнәгендә 1967 елда АКШның Төньяк Каролина шәһәрендә шундый ук энциклопедияләр хәзерләүче яңа бер фәнни үзәк: «Америка биографик институты» (АБИ) ачыла, һәм ул, нигездә, Америка илләре буенча шәхси энциклопедияләр төзүгә керешә: «Америка лидерлары», «Американың данлыклы шәхесләре», «Американың күренекле хатын-кызлары» кебек энциклопедияләр чыгарыла. Соңгы вакытта биредә дөньякүләм энциклопедия төзүгә дә керештеләр. АБИ чыгара башлаган «Халыкара танылган лидерлар» дигән белешмәдә бөтен илләрдәге күренекле шәхесләр урын ала башлады.

Менә шушы ике фәнни үзәк 1991 елда Торонтода халыкара конгресс оештырды. Аңа әлеге институтлар чыгарган энциклопедияләргә кергән кешеләр сайлап чакырылды. Безнең беребез (Ә.Кәримуллин) ХБҮнең «Халыкара биографик сүзлек», «Дөньякүләм интеллектуаллар», «Зур уңышларга ирешкән лидерлар» дигән энциклопедияләргә кертелгән һәм шуннан чыгып конгресска чакырылган иде. Икенчебез (Р.Вәлиев) халкыбызның язма һәм басма мирасын барлау эше белән шөгыльләнүче, милли китап репертуарын төзүне юлга сала башлаган шәхес, республикабызның Үзәк китапханәсе директоры, язучы кеше буларак игътибарга лаек булды. Ул

гына түгел, Разил Вәлиев ХБҮ чыгара торган энциклопедиягә дә кертеләчәк – институт редколлегиясе аның биографиясе, китаплары һәм иҗаты белән танышкач шундый карарга килгән.
Торонтода үткәрелә торган конгресска депутатлар булып без менә шулай чакырылдык. Сәнгать, мәдәни һәм фәнни элемтәләр буенча эшләүче бу җыенга 200 дән артык делегат – Гана, Нигерия, Яңа Каледония, Австрия, Финляндия, Швеция, Кытай, Япония, Тайвань, Португалия, Австралия, Германия, Көньяк Африка Республикасы, Мексика, Сингапур, Франция, Заир, Греция, Уганда, Италия, Норвегия, Израиль, Эфиопия, Югославия, Гонконг һәм башка илләрнең вәкилләре килде. АКШтан һәм Англиядән, шулай ук Канададан делегатлар күбрәк иде. Советлар Союзыннан өч кенә кеше, аларның да икесе – татар, ә өченчесе Карагандадан, Казахстан геология институты фәнни хезмәткәре Раиса Гавриловна Теплякова иде.
Делегатлар арасында фән докторлары, профессорлар, югары уку йорты ректорлары, язучылар, рәссамнар, артистлар, эшкуарлар, дәүләт эшлеклеләре бар иде.
Конгрессны ХБҮ генераль директоры доктор Кэй ачты. Ул үзенең чыгышында бу халыкара конгресста беренче тапкыр буларак совет делегациясе катнашуын да әйтеп үтте һәм делегатларны безнең белән таныштырды. Аннан делегатларны Америка биографик институты вице-президенты мисс Жанет Эванс котлады, ул да ике конгресс арасында башкарылган эшләр, чыгарган хезмәтләр белән таныштырып үтте.
Беренче утырыш «Африка илләренең сәяси хәле һәм аларның үсеш мөмкинлекләре» дигән темага багышланган иде. Анда төп доклад белән Уганда республикасының вице-президенты доктор Самсон Кисекка чыкты, аннары унлаган делегат чыгыш ясады, дистәләгән сораулар бирелде.
Икенче доклад «Атлантиканың ике ягында инглиз теле» дип атала иде. Ул темага төп докладны АКШның Мичиган университеты профессоры доктор Наср Раджа Тәүфик ясады. Ул инглиз теленең дөньяда тоткан урыны, аның бөтен Җир шарына таралуына, киләчәгенә тукталды. Дөньяга таралганда инглиз теленең ничек итеп төрле телләр йогынтысына эләгүе, шуннан килеп чыккан кызыклы хәлләр турында мисаллар белән тулыландырылган бу доклад зур кызыксыну тудырды.
Һәр көнне, нигездә, ике зур доклад тыңланды, алар буенча фикер алышулар үткәрелде. Алар «Америка индеецларының мирасы», «Канададагы билингвизм мәсьәләләре», «Дөньядагы күренекле хатын-кызлар», «Сәнгать, мәдәният һәм әдәбиятның халыкларның якынлашуында тоткан роле», «Нәкыш сәнгате һәм сынлы сәнгать», «Ни өчен халыклар бер-берсеннән башка яши алмыйлар» кебек темаларны эченә алды.
Конгресста барлык докладлар, чыгышлар инглиз телендә генә барды. Дөрес, Римнан килгән бер делегат һәм Тайваньнан килгән тагын бер кунак дискуссиядә үз телләрендә чыгыш ясадылар, ләкин алар да әйтәсе сүзләрен үзләре белән алып килгән тәрҗемәчеләр аркылы инглиз телендә кабатлаттылар. Конгрессның үз тәрҗемәчеләре юк иде. Шулай булса да, без югалып калмадык. «Кемне кем дип белергә?» дип аталган махсус очрашуда (ул аерым группаларга бүлеп үткәрелде, без исә «Әдәбият һәм сәнгать» дигән бүлектә катнаштык) без дә үзебез белән якыннанрак таныштырдык. Шунда ук татар дигән халыкның килеп чыгышы, чит илләрдә бу халыкны монгол яулары белән буташтырып аңлауның хата булуы турында сөйләдек. Халкыбызның тарихы, аның бүгенгесе һәм милли азатлык өчен көрәше турында да әйттек. Америка индеецлары турындагы докладтан соң, без бу индеецлар теленең төрки телгә якын торуын һәм ерак заманнарда безнең алар белән кардәш булуыбыз мөмкинлеген күрсәтеп үттек. Шуннан соң безнең белән кызыксыну, танышырга теләүчеләр арта төште.
Китәргә ике көн кала, көндезге ашка төшкәч, безнең янга ике ханым – кара тәнле америкалылар килеп утырды. Аларның берсе фән докторы Левин Вауги – Нью-Йорктан, икенчесе Калифорниядән художник Элен Монтенлг булып чыкты. Болар безнең кайсы илдән килүебез белән кызыксындылар, «СССРдан килдек», – дигәч, болар: «Ә-ә, алайса, сез урыслар инде», – дип, СССРны «бик яхшы» белүләрен сиздерделәр. «Без урыслар түгел, ә татарлар», – дигәч, аптырап калдылар. Без аларга СССРда йөзләгән төрле халык яшәвен санап күрсәттек, шулар белән бергә анда татарлар, кырым татарлары дигән халыклар яшәвен дә аңлатырга тырыштык.

Шушы темага сүз барганда, яныбызга озын буйлы, пөхтә киенгән бер егет килде: «Биредә татарлар турында сүз бара, әллә арагызда татарлар да бармы?» – дип сорады. Без аннан, татарчалап: «Әллә сез үзегез дә татармы?» – дип сорадык. Бу егет, елмаеп, шатланып, үзенең татар булуын әйтте. Шуннан, өстәл янында бергә утырган американлылардан гафу үтенеп, без татарчалап үзара танышуга керешеп киттек. Бу егет Румыниядән килгән татар булып чыкты. Чаушеску заманында анда татарларның телен, мәктәбен кысрыклаулар, экономик чикләүләр башлангач, алар, Румынияне ташлап, бу якка килеп чыкканнар икән. Егетнең исеме Мостафа, фамилиясе Доган булып чыкты. Безнең татарча сөйләшеп торуны күреп, яныбызга тагын бер татар кыяфәтле егет килде. Анысы кырым татары (Зыятдин Сибат), алар икесе дә без яши торган кунакханә рестораныңда официант булып эшлиләр икән. Ул да түгел, яныбызга берсеннән-берсе чибәр ике яшь ханым килде. Аларның берсе Мостафаның хатыны Фәридә (исемен сорагач, ул, Мостафага күрсәтеп, «Бу минем хуҗам» диде), ә икенчесе Зыятдинның хатыны Сәриян булып чыкты.

Ашау-эчү онытылды. Без, өстәлне калдырып, кунак йортының киң вестибюленә чыгып, әңгәмәне дәвам иттек. Рәсемнәргә төштек. Аларның тормышлары белән кызыксындык, адреслар алыштык, тагын күрешергә килештек... Алар эш кешеләре иде, иркенләп сөйләшергә вакыт җитмәде, тагын очрашырбыз дип аерылдык. Тик икенче көнне аларның ял көне булып чыкты, ә өченче көнне инде без яңадан очраша алмыйча китеп бардык.

Элегрәк безнең беребез (Ә. Кәримуллин) Кембриджга, ХБҮ чыгара торган энциклопедиягә кертү өчен биш татар галимен тәкъдим иткән иде. Ләкин ни өчендер бу тәкъдимне игътибарсыз калдырдылар. Конгресска баргач, без шуның сәбәпләрен ачыкларга булдык. Әлеге мәсьәлә буенча ХБҮнең генераль директоры урынбасары мисс Тодди белән сөйләштек. Алар без җибәргән исемлекне алганнар, тик ХБҮ чыгара торган энциклопедияләргә килгән мондый тәкъдимнәр меңнәрчә икән. «Без теге яки бу шәхесне энциклопедиягә кертү өчен башта аның басылган хезмәтләре белән танышабыз, ул шәхес турында чыккан материалларны өйрәнәбез. Тик шуннан соң гына ул шәхесне кертү-кертмәү мәсьәләсен үзебезнең редколлегиябездә карыйбыз, шунда хәл итәбез», – диде ул. Аннан: «Сез күрсәткән кешеләрнең китаплары АКШ һәм Англия китапханәләрендә юк. Алар турында Европа телендә чыккан матбугатта да материаллар тапмадык. Шуңа күрә без аларны энциклопедиягә тәкъдим итә алмадык», – дип аңлатты.

Безнең беребез (Ә. Кәримуллин) инде утыз елдан артык Англия, Америка, Франция, Төркиядәге институтлар, фәнни оешмалар белән китаплар алыша, аның барлык китаплары диярлек чит илләрнең аерым китапханәләрендә тупланган. Бу басмаларны алар илара бик җиңел табыша алалар икән. Шул ук вакытта бу хезмәтләр турында АКШ, Англия, Франция, Польша, Венгрия, Япония, Төркия һәм Чехословакиядә чыккан мәкалә-рецензияләр дә ХБҮ компьютерлары хәтеренә кертелгән икән. Менә шуннан чыгып, алар Ә.Кәримуллинны эзләп тапканнар һәм аңа үзләренең энциклопедияләренә кертү өчен анкеталар җибәреп торалар икән. (Шуны истә тотарга кирәк: бу ике энциклопедия чыгаручы институтта аерым илләрнең төп телендә чыга торган басмалар белән генә эш итәләр. Әйтик, аларда татар телендә теге яки бу татар галименең китабы бар икән, ул алар өчен җиде йозак артында кала.)

Шундый нәрсәләрне ишеткәч, безнең исебезгә Татарстан китап нәшриятына, университетка, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына чит илләрдән китаплар сорап язган хатлар килүе һәм бу хатлар буенча бернәрсә дә диярлек эшләнмәве, чит ил китапханәләре, фәнни оешмаларының сораулары канәгатьләндерелми калуы искә төште. Шулай ук безнең галимнәребез дә үзләренең китапларына булган чит илдән килгән сорауларны канәгатьләндерергә ашыкмыйлар: искедән калган курку гадәте көчле. Безне чит илләрдә начар белүнең, галим һәм әдипләребезнең исеме республикабыз чикләреннән ерак үтә алмавын өлешчә менә шулай бикләнеп ятуыбыз белән дә аңлатырга була.

Безнең беребезгә (Ә. Кәримуллинга) Гарвард университетының фәнни китапханәсендә булырга, анда Татарстанда совет чорында чыккан китаплар белән танышырга туры килгәне бар. Ул анда Казанда 1940 елдан соң чыккан нибары 35–40 лап кына китап саклануын күрә. Шул ук вакытта

Башкортстан, Чувашия кебек күрше республикаларда соңгы ярты гасыр дәвамында чыккан йөзләрчә китаплар бар икән.
ХБҮнең генераль директоры урынбасары Тодди белән сөйләшү шуны ачыклады. Әгәр без бу Үзәк чыгара торган энциклопедияләргә кемне генә тәкъдим итсәк тә, ул шәхеснең барлык китапларын һәм аның турында чыккан мәкалә, монография, биобиблиографик белешмәләрне дә аларга җибәрергә тиешбез, чөнки татар галимнәренең, язучыларының китаплары ул илләргә бик аз бара. Менә шул материаллар белән танышкач кына, ХБҮ энциклопедиягә тәкъдим итү мәсьәләсен хәл кыла һәм кирәк дип тапкан очракта ул кешегә анкета җибәрә.
ХБҮ дә, АБИ да, безнеңчә әйтсәк, үз көнен үзе күрә, ягъни үзе әзерләп чыгарган китаплар сатудан килгән акчага эшли. Бу ике оешмада да фәнни-тикшеренү ассоциацияләре бар, аларга әгъза итеп алынган кешегә энциклопедияләргә аерым шәхесләрне киңрәк тәкъдим итү хокукы бирелгән, шул ук вакытта тәкъдим ителгән аерым шәхесләр турында белешмәләр язу да йөкләтелүе мөмкин. Аңа әгъза итеп алынган кеше ХБҮ, АБИ оештыра торган конгрессларга льготалы түләү белән чакырыла ала. Моннан тыш ассоциациягә керү өчен зур гына взнос та түләргә кирәк. Бу хәл күрсәтелгән энциклопедик үзәкләрнең матди хәле мактанырлык булмавыннан килә. Менә шуннан чыгып, энциклопедиягә кергән шәхес үз исеме кергән басмаларны да үзе сатып алырга тиеш булып чыга.
Матди ягы шулай йомшак булу сәбәпле, үткәрелә торган конгрессларга катнашу өчен взнос та түләргә туры килә. Ул взноска кунакханә, ашау-эчү чыгымнары да керә. Бу конгресска бару, анда катнашу өчен взнос түләргә безгә берничә предприятие спонсорлык ярдәме күрсәтте. (Без аларга үзебезнең рәхмәтебезне белдерәбез.) Взнос Лондон банкына 1990 елның 31 декабренә хәтле барып җитәргә тиеш иде, ә аны күчерү Внешэкономбанкның Татарстан бүлегенә йөкләнгән иде. Тик взнос Англиягә 1991 елның 2 гыйнварында гына барып җиткән. Без взносны соңга калып җибәрү аркасында командировкага дигән кесә акчасыннан колак кактык.
Бу безгә гаять зур авырлыклар, уңайсызлыклар тудырды. Аэрофлот самолёты белән 30 июньдә Монреаль аэропортына килеп төштек. Ә Монреальдән Торонтога 600 километр чамасы. Кесәбездә бер цент та акча юк. Автобуска гына да 60 доллар кирәк. Әгәр шул чакта безгә ярдәм кулы сузучы булмаса, шул ук көнне Монреальдән Мәскәүгә кире кайтып китәргә тиеш була идек...
Конгресс программасында Торонто шәһәре, аның музейлары, Ниагара шарлавыгы белән танышу кебек экскурсияләр, музыка һәм театр спектакльләрендә катнашу күздә тотылган иде. Ләкин алар һәрберсе түләүле. Һәр яктан су белән әйләндереп алынган Торонтоны катер белән карап чыгу өчен генә 70 доллар түләргә кирәк. Без, кесәбездә җилләр уйнаганга, бернәрсә күрмибез инде дип уйлаган идек. Шәһәрнең бер башыннан икенче башына хәтле диярлек җәяүләп, даны бөтен дөньяга билгеле булган Торонтодагы Онтарио музеен эзләп киттек. Музейга килгәч, аның директоры янына кердек. Үзебезнең кайдан килүебез, кем булуыбыз, бу музейны бик күрәсебез килүе турында әйттек, шул ук вакытта керү өчен билетка акчабыз булмавын да, оялып кына булса да, ачып салдык. Һәм директор безне үзе, контролёр янына алып барып, музейга кертеп җибәрде. Бу музейга бару өчен оештырыла торган экскурсия билеты өчен 65 доллар түләргә кирәк иде.
Канадага барып, Ниагара шарлавыгын күрми кайтудан да кызганыч нәрсә булырмы? Ул Торонтодан 160 чакрым ераклыкта, анда Онтарио музеена барган кебек җәяү барып булмый. Конгресс оештырган экскурсиягә түләү бәясе – 98 доллар. Аллага шөкер, монда да ярдәмгә килүче изге җаннар табылды. (Бу турыда соңрак сөйләрбез.)
Конгресс эшләгән көннәрдә, алдан җибәрелгән взнос буенча, безнең икебезгә бер бүлмә тиеш һәм көненә ике тапкыр кунакханә ресторанында ашату каралган иде. Беренче көннең кичке ашы – Казаннан ук алып чыккан сохариларны краннан агызып алган суга манып ашау булды.
Америкада кешеләр елмаеп, көлеп яшиләр. Танышмы син, юкмы, лифтта булсын, өстәл янына килеп утыр – синең белән елмаеп исәнләшәләр, танышалар, сөйләшә башлыйлар. Конгресста без күп кенә делегатлар белән таныштык, аралаштык. Алар арасында Сиднейдан килгән рәссам Ева Куббос, Австралиянең күренекле рәссамы һәм сынчысы Франк Пам, «бәхетле» Болгариядән качып, Германиягә күчеп киткән, картиналары дөнья күргәзмәләрендә бүләкләр алган рәссам

Васил Живков (ул хәтта үзе белән тәрҗемәче дә алып килгән иде), Варшавадан килгән физиолог-психотерапевт Барбара Бартель, Тайваньнан килгән артист Боон-Кихо, Чикагоның Илиононс университеты профессоры Стевен Аллен Владем, инде искә алынган Наср Раджа Тәүфик, галим һәм әдип, доктор Осман Төркай...

Осман Төркай белән көн саен диярлек аралаштык, аңа Татарстанда чыккан китаплар бирдек, ул үзенең инглиз телендә басылган шигырьләр җыентыгын бүләк итте. Осман үзе Кипрда туган төрек. Инде 25 ел буе Англиядә яши, шундагы югары уку йортларында белем алган, Лондон университетында философия укыткан. Англиядә чыга торган төрек телендәге «Хөр сүз», «Ватан» журналларының редакторы, күренекле журналист та, ЮНЕСКО һәм башка төрле әдәби оешмаларның лауреаты, дөньякүләм танылган җәмәгать эшлеклесе дә. Аның утыздан артык проза һәм поэзия китаплары төрек һәм инглиз телләрендә басылган.

Бу конгресста катнашу безнең өчен зур бәйрәм вә сабак та булды. Без анда күп әдипләр, галимнәр белән таныштык, элемтәләр урнаштырдык, бер-беребезгә китаплар җибәрү турында килештек. Дөньяның төрле төбәкләрендә яшәүче шәхесләрне күзәттек, үзебезне алардан бер дә ким хис итмәдек. Конгресста катнашу безнең дөньяга карашыбызны да киңәйтте, үзебезнең хәлебезне дөресрәк аңларга юл ачты, без үзенә күрә яңа бер университет тәмамлаган кебек булдык. Шул ук вакытта ХБҮ һәм АБИ чыгара торган энциклопедияләрдә татар халкының күренекле шәхесләрен чагылдыру юлларын ачыкладык, үзебезнең халкыбыз турында да хак сүзләр әйтә алдык. Конгресс барган көннәрдә аңа бәйләнешле күргәзмә дә оештырылган иде. Анда шушы ике оешма чыгарган энциклопедияләрнең аерым данәләре, күргәзмәгә килгән рәссамнарның хезмәтләре һәм каталоглары, аерым автор әсәрләренең рекламалары да күп куелган иде.

Югарыда, без Монреальгә килгәч, ярдәм кулы сузучы табылды, дип әйтеп үткән идек. Без Канадага барыр алдыннан «Ватан» җәмгыяте аркылы анда татарлар барлыгын белешергә тырыштык. «Ватан» җәмгыятендә Канадада яшәүче татарлар турында мәгълүмат юк иде. Безнең беребез (Р.Вәлиев) әле генә АКШта булып кайтты, ул анда вакытта Канадада яшәүче бер татар кешесенең адресын таба һәм АКШта яшәүче татарлар бу кешегә безнең Канадага киләчәгебезне, безне каршы алырга һәм Монреальдән Торонтога барырга ярдәм итүен сорый. Шул ук вакытта икенчебез (Ә.Кәримуллин) Австралиянең Сидней шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Рәшид Мансурга хат яза: «Канадада берәр татар кешесен белмисезме?» – дип сорый.

Рәшид Мансурның анда Маньчжуриядә чакта Хайлар шәһәрендә бер мәктәптә укыган Тәнзилә исемле классташы яши икән, аның адресын җибәрә. Хәзерге көндә Токиода вакытлыча яшәүче, Канада башкаласы Оттава шәһәрендә торучы Аяз Агишка да без шундый сорау белән мөрәҗәгать иткән идек. (Аяз Агишка исемен Гаяз Исхакый үзе кушкан, үз исемен биргән. Ул 1990 елда Казанда булып китте.) Ул безгә Монреальдә яшәүче милләттәшебез Равил Бикбайның адресын җибәргән иде.

Монреальгә килеп төшү белән, безне совет генерал консуллыгының вице-консулы Кадышев Леонид Юрьевич каршы алды. Безнең Канадага кайчан килүебез турында чит илләрдәге ватандашларыбыз белән элемтә тотучы ил күләмендәге «Родина» ассоциациясе Канадага хәбәр итеп куйган иде. Безнең Канадага баруыбыз билгеле булгач, «Ватан» җәмгыяте андагы милләттәшләребезне барлау, алар белән элемтә урнаштыру эшен дә йөкләгән иде. Ул безгә Канадага бару өчен самолётка билет алуда да ярдәм итте. Бу эштә «Родина» ассоциациясе «Ватан»га булышлык күрсәтте. Без Канадага барышлый «Родина»га кергәч, безне бу оешманың ике зур җитәкчесе Н. А. Панков һәм В. Г. Еременко үзләренә чакырып алдылар. Без алар белән ике сәгатькә якын әңгәмә корып, чәйләр эчеп утырдык. Алар безне Татарстанның мөстәкыйльлек алуы белән котладылар, урыс һәм татар халыклары игезәк халык, дип сөйләделәр, республикабызда бара торган үзгәрешләргә уңай бәя бирделәр һәм безне Канадада да каршы алу өчен СССРның Монреальдәге консуллыгына телеграмма сугачакларын әйттеләр.

Әнә шул телеграмма буенча да инде безне биредә СССРның Монреальдәге вице-консулы каршы алды. Аңа үзебезнең нинди кыен хәлдә калуыбызны сөйләп торганда, безне Талип Кудеки диган милләттәшебез килеп тапты. Инде әйтеп үткәнчә, Америкадагы милләттәшләребез безнең Канадага баруыбыз турында аңа хәбәр иткәннәр иде. Үз чиратыбызда без дә аңа телеграмма

суккан идек. Монреальдән Торонтога бару мәсьәләсен хәл итүдә безгә Талип ярдәм итте. Соңыннан ул үзе дә Торонтога килеп, безне шәһәр белән таныштырып йөрде. Аның аркылы без Канададагы татарлар һәм башка бик күп нәрсәләр турында сөйләштек, информация алдык. Ул үз чиратында СССРдагы татарларның хәле, тормышы белән кызыксынып, бик күп сораулар яудырды.

Талип Кудеки Маньчжуриядә Хайлар шәһәрендә туган, анда белемне урыс мәктәбендә алган, әти-әниләреннән иске татар-гарәп графикасын өйрәнгән. Кытайда «социализм» «җиңә» барган саен, Маньчжуриядә калган татарларны кыса башлаганнар. Аларның бер өлешен 1945–1946 елларда ук көчләп СССРга кайтаралар, күбесен төрмәләргә утырталар. Татарларга яшәү өчен урын калмый башлагач, Талипның әтисе, йорт-җирен, җыйган җиһазларын ташлап, гаиләсен алып, Маньчжуриядән чыгып китәргә мәҗбүр була. Тора-бара алар Канадага килеп урнашалар. Бирегә килгәч, Талип нинди генә кара эштә эшләмәгән – урам себергән, савыт-саба юган, аннан таксида эшли башлаган. Шул арада ул Монреаль университетын тәмамлаган. Хәзерге көндә Монреаль колледжларының берсендә архитектура һәм сызым укыта. Монреальдә эшләп килүче «Мөселман төрки дәрнәге» (җәмгыяте) оештырган, хәзерге вакытта да аның эшендә актив катнаша. Төрки-татарлар арасында милли, дини эшләр белән җитәкчелек итә. Кышын атна саен татар балаларын җыеп, аларга туган тел дәресләре бирә, татар җырларын өйрәтүне оештыра. Күрсәтелгән оешма төрки мөселманнар арасында Корбан, Рамазан бәйрәмнәрен үткәрү, никах, үлем-җитем мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә. Татар балаларына туган тел укыту эшен Талип үзенең йортында алып бара. Әле мәчет ачу өчен ул үз йорты янында урын да алган. Күрсәтелгән оешма каршында китапханә дә эшли. Төрки һәм дини китапларны алар Төркиядән алалар. Без Казаннан алып килгән татар китапларын күргәч, Талип бик сөенде. Үзем укып чыккач, мин аларны шул китапханәгә тапшырачакмын, диде. Без аңа киләчәктә татар халкы һәм аның тормышын чагылдырган, Казанда чыккан китапларны җибәреп торырга сүз бирдек. Мәчет ачылгач, Талип аның каршында мәдрәсә ачу, китапханә оештыру, төрле кичәләр, очрашулар алып бару турында да планнар белән яши. Монреальдә төрекләр шактый күп булса да, татар гаиләләре 5–6 дан узмый, ди. Алар үзләренең дини, милли традицияләрен төрекләр белән бергә алып баралар. Вакытында дөньякүләм спорт ярышлары үткәрелгән Калгари шәһәрендә дә берничә татар гаиләсе яши икән.

Талип Кудекиның нәсел-нәсәбе – Пенза ягыннан. Аның бабасы заманында Маньчжуриягә килеп чыккан. Талипның хатыны Наилә – чибәр, зифа гәүдәле, тыныч табигатьле ханым. Аларның ике уллары бар. Кечесе Илханга өч кенә яшь, ә Кенанга – унбер яшь. Кенан быел бишенче классны тәмамлаган. Бик оста һәм матур итеп татарча сөйләшә, үзен иркен һәм шул ук вакытта тыйнак тота. Ул безне, абыйлары кебек якын күреп, шатланып каршы алды. Кенан татар телен генә түгел, төрек, инглиз, француз телләрен дә камил белә. Хәзер немецча өйрәнә. «Шул телләрне үзләштергәч, мин дөньяның теләсә кайсы ягына бара алачакмын», – ди. «Бераз үсеп кенә җитим, мин бабаларым җиренә кайтып Казанны, Татарстанны күрәчәкмен, бәлки, бөтенләй дә кайтырмын әле», – дип тә әйтеп куйды. Кудекилар гаиләсендә татар җырларыннан торган зур фонотека бар, алар татар җырларын бик яхшы беләләр. Без аларга татар көйләре язылган җиде кассета бүләк иттек. Талип бу җырларның күчермәләрен алып, биредәге татарларга таратам дип калды.

Шунысын да әйтергә онытканбыз: Талип һәм аның хатыны Наилә урыс телен дә яхшы беләләр, Талип татар тарихын яхшы белә. Ул Япония һәм Кытайда чыккан татар китапларын укып барган. Юморга бай, шат күңелле, җаны-тәне белән милли рухта яшәүче, зур белемле бу егет белән танышкан саен күңелләр күтәрелә, бу очрашу, танышу безнең өчен зур бәйрәм булды. Инде аның гаиләсе белән танышкач: «Юк әле, безне тарихтан сызып ташларга ашыкмасыннар, без бар, безнең милләтебез бетмәячәк», – дип уйлыйсың. Икенче яктан, татар җирлегендә яшәп тә телен, гореф-гадәтләрен онытып, маңкортка әйләнүчеләр артуына йөрәкләр сызлый.

Безнең Канададагы икенче танышыбыз инде искә алып үткән Тәнзилә ханым иде. Ул да Маньчжуриядә Хайлар шәһәрендә туган. 1945 елны Кытайга совет гаскәрләре кергәч, биредә ачылган урыс мәктәбендә укый башлаган, пионер, комсомолга кергән, «ирекле» совет иле, Ленин

турында җырлар җырлап, белем ала башлаган. Әтисенең дә советларны мактап йөрүенә карамастан, аларга Кытайда яшәргә урын калмый: йорт-җирләрен ташлап, качып киткәннәр. Алар Австралиягә юл алалар. Австралиягә күчеп килгәч, Тәнзилә тиз арада инглиз телен өйрәнә, мәктәптә яхшы укучы булып танылa. Урыс телен яхшы белүе аркасында, аны Австралия даирәләре СССРдан килгән дәүләт делегацияләрен йөртүче тәрҗемәче итеп чакыра башлыйлар.
СССРның Австралиядәге илчелеге бервакыт урыс телен пропагандалау җәһәтеннән бер группа Австралия укучыларын СССРга сәяхәткә чакыра, аларны герой-шәһәр Волгоград буйлап йөртәләр. Бу сәяхәткә Тәнзилә дә чакырыла. Волгоградка килгәч, Тәнзилә: «Мине бер-ике генә көнгә булса да Уфага җибәрегез», – дип сорый. Шунда аның татар кызы икәнен беләләр һәм шуннан соң аңа мөнәсәбәт тә үзгәрә. Тәнзилә шундый шартларда Австралиядән Голландиягә китә. Әти-әнисе Австралиядә кала. Әтисе хәзерге көндә вафат, әнисе әле дә Австралиядә яши, ара-тирә кызы янына Торонтога килеп йөри.
Торонтога килгәч, Тәнзилә госпитальдә, төрле эшләрдә эшли. Аннан читтән торып Торонто университетының филология факультетын тәмамлый. Шул университетның фәнни китапханәсендә эшкә кала. Хәзерге вакытта Торонтодагы бер колледжда эшли. Чит илләрдән Канадага килүче эмигрантларга инглиз телен укыта, компьютерларда эшләү буенча дәресләр бирә. Тәнзилә дә Талип кебек полиглот: ул татар, төрек, инглиз, француз, голланд, урыс, немец телләрен камил белә. Боларның икесенең дә татарча сөйләшүе шулхәтле төгәл, матур, әдәби – аларның гомер буе татар мохитеннән читтә яшәгән булуына ышанасы да килми. Бездә вузларның татар бүлеген бетергән кайбер кешеләр дә әдәби телне алар хәтле белмиләрдер, мөгаен.
Тәнзиләнең ире Тимур – югары квалификацияле инженер-электронщик. Аның әтисе поляк, ә әнисе Казан татары.
Без Торонтога килүнең икенче көнендә, сохарины суга манып кичке аш ашап утырган чакта, телефон шылтырады: Тәнзилә безне шулай эзләп тапты. Эше күп булуга карамастан, ул икенче көнне яныбызга килде. Таныштык, бик озак сөйләшеп утырдык, аңлаштык. Үзенең эшчәнлеге, акылы, гадилеге, гүзәллеге белән безнең күңелләрне яулап алды. Ул дә безне икенче көнне Торонто белән таныштырды. Үзләренә кунакка алды. Без анда аның ире Тимур белән дә таныштык. Тәнзиләнең үз хисабына салган йортында булдык. Ул йорт – подвал өлешен дә хисапласаң, өч катлы. Янында берничә сотый бакча, йорт бөтен уңайлыклар белән җиһазланган. Талипның да шундый ук уңайлы, зур бакчалы үз йорты бар.
Тәнзиләгә әнисен үз янына чакыру өчен атнага 30–40 сәгать эшләргә туры килә. Быел аның Уфадагы туганы да килергә җыена икән. Шуңа күрә ул өстәмә дәресләр алырга булган, вакыты бик тыгыз. Тәнзилә белән Талип бер-берләрен күптән беләләр, аралары 600 чакрым булса да, аралашып яшиләр икән.
Безнең Ниагара шарлавыгына бара алмавыбызны белгәч, Талип та, Тәнзилә дә, эш сәгатьләрен үзгәртеп, Талип Монреальдән үк килеп, безне шарлавыкка алып киттеләр. Юлда барганда, Талип: «Быть в церкви и не видеть батюшку», – дип урысчалатып шаяртып алды.
Бу көнне конгресс тәмамлана, аның йомгаклау утырышына кайтып җитәргә кирәк булу сәбәпле, Ниагара шарлавыгында без бары сәгать ярым гына була алдык. Шул вакыт эчендә аның тавыш-гөрелдәүләре колакта музыка кебек яңгырап торды, шарлавыкның төрле урыннарында булдык, тау трамвае белән өскә менеп тә күзәттек, шарлавыктан җил күтәреп сирпи торган су тамчыларында коендык.
Ниагара шарлавыгын тасвирлау өчен сүзләр көчсез. Аны үзең күрми торып, аның көчен, мәһабәтлеген сүз белән генә аңлату мөмкин түгелдер. Шарлавыкның янына килү өчен бервакыт махсус кораблар бар. Анда барыр алдыннан сиңа яңгыр, су үтми торган киемнәр бирәләр. Ул корабларны да карап тордык, аларның шарлавык янына барып җитәргә көчләре җитми, дулкыннар аны йомычка кебек кире кага...
Ниагара шарлавыгы ике өлештән тора. Аның берсе – АКШ ягында, ә икенчесе, иң көчлесе һәм мәһабәте – Канада ягында. АКШ ягында да шарлавык янына меңләгән кешеләр килгән, безнең якта да меңләгән экскурсантлар. Кемдер шарлавыкны кинога төшерә, кемдер рәсемгә ала. Без дә шарлавык фонында рәсемгә төштек. Теләгән кеше билет алып шарлавыкны АКШ ягына чыгып

карый ала. Шарлавыкның үзеннән 200 метр арырак асылма күпер, кабинасына утыр да АКШ ягына чык. Ике яктан да шарлавык белән яхшырак танышу өчен зур вышкалар куелган. Төнге шарлавыкны төрле төсләр белән бизәп яктырту өчен прожекторлар әзерләнгән.

Ниагара шарлавыгы янында үзеңне икенче төрле, илаһи хис кочагында кебек тоя башлыйсың. Шарлавык белән танышып, аның гүзәллеге эчендә яшәгән минутларда дөньяда моннан да соклангыч башка табигать могҗизасы бар микән дип уйлыйсың. Бу шарлавыкны тудыру өчен илаһи көч үзенең барлык кодрәтен җәлләмәгән, ахрысы, дигән уйлар башка килә. Шушы шарлавыкны күрү өчен генә булса да дөньяга килү кирәк булган, ахрысы...

Канадага сәяхәтебез матди яктан нихәтле койты булмасын, Ниагарага барып чыгу, аның белән танышу, аның бөек көчен, сулышын тою бөтен нәрсәне онытттырды...

Без, Ниагара шарлавыгыннан тыш, Торонто һәм Монреаль шәһәрләре белән дә таныштык. 1 июль көнне, Канаданың милли бәйрәме вакытында, аның мәйданнарында булдык, Канада халкының җыр-биюләрен күрдек, тыңладык, безгә бүләк итеп биргән кечкенә Канада флагчыкларын күтәреп йөрдек. «Кытай шәһәрчеге» дигән өлешендә ике-өч тапкыр булдык. Биредә урам-урам кытай кибетләре, иероглиф белән язылган матур, төсле рекламалар, яшелчә, ит, җимеш, электроника кибетләре, универмаглар тезелеп киткән. Кая карама – кытайлылар, кытай музыкасы, кешеләр кулында кытай телендә Торонтода чыга торган газеталар... Шунда бер нәрсә искә төште: 1946 елга хәтле Маньчжуриянең Харбин, Мукден, Чан-чунь һәм башка шәһәрләрендә квартал-квартал татар кибетләре, ашханәләре булган, алар «Нур», «Идел», «Болгар», «Урал», «Сакмар», «Чулман», «Иртыш» кебек исемнәр йөрткәннәр, анда да татар рухы кайнап торган...

Торонто үзенең өсте ачыла һәм ябыла торган, йөз мең кеше сыйдырышлы стадионы белән дә дөньяда дан тота. Эченә керә алмасак та, яныннан карап уздык. Торонтодагы Онтарио музее белән танышу да бездә зур тәэсир калдырды. Бу музейны караган кеше китап укымыйча да җирдә кешелек һәм табигать тарихын күз алдына китерә аладыр.

Кире кайтышлый без иртән Монреальгә килеп төштек. Безне анда Талип Кудеки каршы алды. Үз машинасында дүрт сәгать буена Монреаль белән таныштырып йөрде. Без биредәге небоскрёблар, шәһәрнең атаклы архитектура корылмалары, шул исәптән халыкара ярминкә уңае белән төзелгән гаять зур монументаль сарай белән дә таныштык. Монреаль – Квебек дигән провинциянең бер шәһәре. Биредә, Торонтодан аермалы буларак, дәүләт теле – француз теле. Шуңа күрә монда барлык рекламалар, барлык язулар, урам, метро исемнәре, белешмәләр – бар да француз телендә. Инглиз телендә мөрәҗәгать итсәң, сиңа җавап та бирмәүләре мөмкин.

Торонтода да, Монреальдә дә көннәр бик эссе торды. Ни өчендер Канада безнең хәтергә салкын ил булып кереп калган. Аның табигате Татарстан табигатенә якын тора икән: сүз Канаданың көньяк өлеше турында бара. Җәй җитүгә, Канада халкы, илләрендә шундый җылы булуга карамастан, Американың Флорида якларына, Италиягә, шәрык һәм Европа илләренә чыгып китә. Чит илләргә барып ял итүне генә чын ял дип саныйлар, ахрысы, алар.

Без биредә юл газапларыбыз, Торонто һәм Монреальнең гүзәллеге, Канаданың табигате, кибетләренең байлыгы, халкының ачык йөзле, елмаеп яши торган халык булуы, төнге урамнарының салават күпере кебек төрле утлар тәкыясына үрелеп януы, урам тулы машиналар һәм башка нәрсәләр турында язып тормыйбыз.

Менә шуларны күргәч, «бәхетле совет илендә» яшәвебезнең, коммунистик идеологиянең нинди зур «уңышларга» китерүен тагын да ачыграк аңлый башлыйсың. Юкка гына чит илләргә бару өчен шундый зур киртәләр булмаган икән элекке вакытларда. Дөрес, ул киртәләрнең күбесе әле дә алынмаган, бер киртәне икенчесе – экономик киртәләр белән генә алыштырдылар, ә нәтиҗәсе бер үк диярлек...

Әгәр Татарстан мөстәкыйль булса, без дә шул чит илләрдә, тарихның ачы җилләре илтеп ташлауга да карамастан аякка баскан, бай тормышта яшәүче милләттәшләребездән ким яшәмәс идек, диясе килә.

*1991*

# ЛОНДОННАН КАЗАН КҮРЕНӘ[1]

Заманында иң зур империалистик дәүләт булган, Җир шарының өчтән берен диярлек биләп торган, «Бөекбритания өстендә кояш батмый» дип мактанырга яраткан Англия безнең өчен хыялый томан эчендәге серле дөнья иде. Шуңа күрә бирегә, дөресрәге, Бөекбританиянең Берләшкән Корольлекләре һәм Төньяк Ирландия дип йөртелә торган бу илгә, без зур кызыксыну белән бардык. Кешелек тарихында зур роль уйнаган, аның рухи вә матди тәрәккыендә тирән эз калдырган Англияне, аның бүгенге халәтен «капшап» карыйсы, үз күзләребез белән күрәсебез килә иде.

Безгә Кембриджга чакыру кәгазе килеп төшкәч, Садри Максудиның «Англиягә сәяхәт» (Казан, 1914) дигән юлъязмасын янә укып чыктык. Ул 1909 елның июнь аенда Дәүләт Думасы депутатларыннан торган 20 ләп кешелек делегация составында Англиядә 20 көнгә якын яшәгән, аны аркылыга-буйга гизеп чыккан, премьер-министрда кунакта булган, күп шәһәрләрдә, музей һәм бакчаларда йөргән; парламент мәҗлесләрендә утырган, зур очрашуларда татарлар турында нотыклар сөйләгән... Аның Англия хакында бай информациягә нигезләнгән бу хезмәте әле моңа хәтле укучылардан яшерелеп, җиде йозак астында тоткынлыкта яткан иде...

Бу китапта без Кембридж турында да гаять кызыклы күзәтүләр, белешмәләр таптык. Аның Кембриджга багышланган урыннарын кат-кат укып чыктык. Ул юлъязмалар үз вакытында «Йолдыз» газетасы битләрендә дә басылган. Англия белән таныштыручы бу китап бүгенге көндә дә кыйммәтен җуймаган.

Безне Англиягә Халыкара Биографик Үзәк чакырган иде. Кембридж шәһәрендә урнашкан бу фәнни үзәк Американың Төньяк Королина шәһәрендәге Биографик Институт белән бергәләп биредә 12–19 июльдә Халыкара фәнни конгресс үткәрә икән. «Дөньяда мәдәни һәм фәнни элемтәләр һәм сәнгатьләр» дип аталган бу конгресс инде 19 тапкыр уздырыла. «Кемне кем дип белергә?» сериясе белән Кембриджлагы фәнни үзәк «Зур уңышларга ирешүчеләр», «Танылган әдипләр һәм авторлар», «Атаклы хатын-кызлар», «Атаклы композиторлар һәм башкаручылар», «Атаклы ирләр», «Дөнья интеллектуаллары» һ. б. исем-темалар астында уналты төрле энциклопедияләр чыгарып килә. Ә Америкадагы фәнни институт тагын биш-алты исемдә шундый ук энциклопедияләр нәшер кыла. Әгәр Англиядәге үзәк чыгарган энциклопедия бөтен дөнья кешеләрен, шәхесләрен үз эченә алырга тырышса, АКШтагы фәнни үзәк Америка, Австралия, Океания зыялыларына, шәхесләренә күбрәк игътибар бирә.

Бу фәнни үзәкләр дөнья матбугатын даими күзәтеп баралар һәм үзләре, теге яки бу шәхесне эзләп табып, аңа мөрәҗәгать итәләр. Безне алар, менә шулай эзләп табып, эшләгән эшләребез, кылган гамәлләребез хакында тулырак мәгълүмат туплаганнан соң, үзләренең ике-өч энциклопедияләренә керткәннәр иде. Хәзер алар безне респондентлары итеп билгеләделәр, үзләренең киңәш комиссияләренең әгъзалары итеп алдылар. Безнең бурычыбыз – Татарстандагы һәм, гомумән, татарлар арасындагы күренекле кешеләрне шул энциклопедияләргә тәкъдим итү һәм алар үзләре эзләп тапкан шәхесләрнең фәнни, иҗтимагый эшчәнлеге турында информация бирү, аерым кешеләрдән килгән материалларга бәяләмә язу.

Шушы максаттан чыгып, Халыкара Биографик Үзәкнең «Өметле яшьләр» исемле энциклопедиясенә инде егермеләп татар егете һәм кызын тәкъдим иттек. Алар арасында талантлы студентлар, шагыйрьләр, җырчылар бар... Бу кандидатлар яңа чыгачак «XXI гасырга керүчеләр» исемендәге энциклопедиягә тәкъдим ителде. Киләчәктәге тематик энциклопедияләргә кертү мәсьәләсе инде аларның алдагы эшчәнлегенә караячак. Бу сериягә тәкъдим ителә торган кешеләр 17–29 яшь арасында булырга тиеш. 30 яшьтән узган зыялылар өчен инде алда әйтеп үтелгән энциклопедияләр чыгарыла. Без бу төр энциклопедияләргә кертү өчен Татарстаннан унлап кешене тәкъдим иттек. Алар арасында академиклар М. Хәсәнов, М. Госманов, Р. Фәхретдинов, Ш. Чабдаров, Т. Сиражетдинов, әгъза-корреспондент Г. Даутов, бизнесмен Н. Бех... һ. б. танылган шәхесләр бар.

Без тәкъдим иткән кандидатларның барысы да өйрәнү өчен кабул ителгән. Моны безгә конгресска килгәч әйттеләр. Инде аларга энциклопедиягә кертү өчен кирәкле мәгълүматлар туплау нияте белән сорау-анкеталар да җибәрелүен белдек. Конгресска килгәч, беренче эш – бу фәнни үзәкләрнең бер ел эчендә кылган гамәлләре турында хисап һәм киңәш алышулар булды. Шушы конгресста безнең эшкә уңай бәя бирделәр һәм, алдагы елда тагын 10–15 кеше тәкъдим итә аласыз, дип, заявка бланклары тапшырдылар. Шуны да истә тотарга кирәк: без тәкъдим иткән кандидатларны энциклопедиягә кертү буенча анда гаять зур эш алып барыла. Ул шәхесләрнең басылган китаплары, алар турында чыккан әдәбият белән танышу нигезендә мәсьәлә йә уңай, йә кире якка хәл ителә. Соңгы сүз, билгеле, аларныкы.

Конгрессның икенче – төп өлеше, башка фәнни форумнардагы кебек, фәнни докладлардан торды. Быелгы конгресста түбәндәге секцияләр эшләде: «Сәнгать дәүләт ярдәменнән башка уңышлы үсә аламы?», «Дөнья базары вә спорт», «Антарктиданың планетадагы глобаль үзгәрешләрдә тоткан урыны»... Әдәбият-сәнгать өлкәсенә багышланган секцияләрдә «Графология», «Юмор», «Музыка», «Поэзия» темалары буенча группалар эшләде. Конгресста йөздән артык илдән 250 ләп делегат катнашты. Аларның күпчелеге – галимнәр, профессорлар, язучылар, артистлар, рәссамнар... Табиблар, бизнесменнар, дәүләт эшлеклеләре дә аз түгел иде. Кайбер илләрдән хәтта вице-премьер-министрлар, Нобель премиясе лауреатлары, атаклы җәмәгать эшлеклеләре дә килгән иде.

Без конгрессның икенче өлешендә «Татарстан: аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге» дигән темага икәүләп язган доклад белән чыктык. Башта безнең беребез (Разил Вәлиев) конгрессны мөстәкыйльлек алган Татарстан исеменнән котлады. Котлау татар телендә булды. Аны төрек шагыйре, галим Осман Төркай инглизчәгә тәрҗемә итеп торды. Аннан доклад укылды (Әбрар Кәримуллин). Ул инглиз телендә язылган иде. Әйтергә кирәк, безнең доклад тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Бу докладны тыңлаучы күп кенә делегатлар дөньяда Татарстан дигән дәүләт барын беренче тапкыр ишеткән булып чыкты. Докладтан соң без шактый популяр делегатларга әйләндек. Алар бездән һаман: «Сез үзегез урысмы?» – дип сорыйлар. Инде без: «Натураль татарлар», – дигәч, ышанмыйлар. Алар татарларны кысык күзле, кара-кучкыл табак битле, кәкре аяклы, ыржайган тешле ярым кыргый халык дип беләләр икән. Безгә, бер төркем делегатлар белән очрашып, халкыбызның монгол татары түгеллеген, дөньяда төрки кавеменнән булган дистәләрчә халык яшәвен кат-кат аңлатырга, монголларга бернинди катнашыбыз булмавы турында, болгар-татар милләте икәнлегебез, төркилегебез хакында тәфсилләп сөйләргә туры килде. Гасырлар буе безне монгол дип белгән халыкларга ун-унбиш минутлык сөйләшүдә, бер докладта үзебезнең кем икәнлегебезне төшендерү тулысынча мөмкин түгелдер. Шунысы аяныч: дөнья халыклары алдында без әле һаман татар-монгол булып калабыз икән...

Докладта һәм очрашулар вакытында без Татарстанның мөстәкыйль дәүләт булуын, аны халык референдум юлы белән, тыныч юл белән яулап алуын сөйләдек. Алар Литва, Латвия, Эстония, Грузия, Үзбәкстаннарның хәзер мөстәкыйль дәүләт булуларын яхшы беләләр. Ә Татарстанны белмиләр... Хәтта Польша, Финляндия, Төркия кебек күрше илләрдән килгән делегатларның да бу турыда мәгълүматлары бик аз. Шулай да безнең бу сүзләребезне ишеткәч, делегатлар мөстәкыйльлек алу белән бик теләп котладылар, аягүрә басып кул чаптылар... Билгеле, безгә бик күңелле булды.

Очрашулар вакытында безнең мөстәкыйльлекнең Россия һәм башка илләр тарафыннан әле дә танылмавын, аны ныгыту өчен дөнья халыклары һәм дәүләтләренең безне яклавы кирәген аңлаттык. Үз илләренә кайткач, Татарстан турында дөрес информация бирүләрен, безнең мөстәкыйльлекне тану өчен үзләренең хөкүмәтләренә мөрәҗәгать итүләрен сорадык. Бу сорау һәм тәкъдимнәребезне без күбрәк АКШ, Германия, Франция, Польша делегатларына әйтергә тырыштык. Биредәге делегатлар арасында югары даирәләргә якын кешеләр булуын да истән чыгармадык. Без бу турыда поляк язучылары Барбара Петрозалин-Скворанска, Жанна Чемиловска, Австралиянең атаклы рәссамы Эва Каббас, Польша профессоры Тадеуш Лахович, немец язучысы Вильгельм Флотманн, Канада юристы Борис Тесноф, Индонезия парламенты әгъзасы Соемарио белән аерым-аерым сөйләштек.

Конгресс вакытында без ким дигәндә биш-алты дистә делегат белән таныштык, аралаштык, сөйләштек. Алар арасында Татарстанга бизнес эшләре белән бик киләсе килгән яшь кенә чибәр ханым Джой Бозелли, шулай ук Татарстан белән кызыксынучы Гонконг психиатры Чоман Чонг, Америка композиторы Петерсон Давиес, Төркия профессоры һәм язучысы Исмаил Эрсәвим, япон профессоры Атсуо Накадава, Австралия язучысы Рут Голдхорре, швед галиме Антони Робертсон-Пеарс, Малайзия дипломаты Винсент Вин Син Вонг... һ. б. исемнәр бар.

Конгресска килгән рәссам һәм язучыларның бер өлеше үзләренең күргәзмәләрен дә оештырдылар. Кытай рәссамы, төсе-кыяфәте белән татар хатыннарыннан аерылмый торган чибәр Хиу Ли, үзе безнең белән килеп таныштьы һәм күргәзмәсенә чакырды. Бу күргәзмәдә без күп кенә Япония, Кытай делегатлары белән аралаштык, соңыннан Кытайдагы татарларның тормышы, Кытай халкы этногенезы турында да сөйләштек... Алар арасында Кытай Язучылар берлеге рәисе Хохуаи Зонг, язучы Чайхоу Ши, Мех колледжы президенты профессор Ваэн Ху, юрист һәм бизнесмен доктор Чунгюи Шен һ. б. бар иде.

Югарыда искә алган Соемарио һәм аның хатыны Дра Сри Соемариоти мөселман булып чыктылар. Без алар белән очрашкан саен, «Әссәламегаләйкем» дип, ерактан ук сәлам биреп күрешә идек, тора-бара шактый ук якын дуслар булып киттек.

Без бу конгрессны Татарстанның мөстәкыйльлеген таныту, аның турында төрле ил вәкилләре арасында мәгълүмат тарату өчен киң файдаланырга тырыштык. Шулай ук делегатларның, үз илләренә кайткач, безнең халык турындагы ялган карашларның кайдан килеп чыгуы турында да үз халыкларына аңлатуларын сорадык. Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуда безнең ул илләр тарафыннан танылуга да мохтаҗлыгыбызны белдердек.

Англия хәтле Англиягә баргач, анда күргәннәр, ишеткәннәр турында да бераз әйтеп китү кирәктер. Ләкин баштан ук искәртеп куябыз: без биредә Англиянең нинди ил булуы, аның шәһәрләре, музейлары, һәйкәлләре, тарихи урыннары турында сүз алып бармыйбыз. Бу хакта инде матбугатта күп язылган. Аннан бу илнең музей, һәйкәлләре, тарихи урыннары белән танышырга артык вакытыбыз да, матди мөмкинлегебез дә булмады. Конгресс 12 июльдә ачылачак, дип, безгә алдан хәбәр иткәннәр иде. 12 июльгә билет булмау сәбәпле, без 11 июль самолётына билет алдык. Конгресс делегатларының бары 12 июльдә генә торырга урнаштырылуы турында да ассызыклап язганнар иде. Шуңа күрә бер тәүлек вакытны без Лондонның Хитроу аэропорты вокзалында үткәрергә дип планлаштырган идек. Без Лондонның Хитроу аэропортына көндез 13 сәгать 45 минутта килеп төштек. Таможня процедураларын үтүгә бер сәгать вакыт китте. Мәскәү һәм Лондон таможняларында «кысыр» чемоданнарыбызга әйләнеп тә карамадылар. Безнең бер-ике пар киемебез, кырыну-юыну әйберләребез, китапларыбыз чик сакчыларында кызыксыну уятмады. Лондон аэровокзалына чыгып, инде кайда бер тәүлек вакытны уздырырбыз дип, кресло-кәнәфиләр карап йөргәндә, безне көтеп торучы ике таныш кеше күрдек. Аларның берсе – атаклы төрек шагыйре Осман Төркай, ә икенчесе – татар шагыйре Равил Бохарай иде.

Равил Бохарайны Татарстан укучылары яхшы белә. Аның моннан берничә еллар элек Казанда шигырь җыентыклары дөнья күрде. Аннан ул шактый еллар Мәскәүдә яшәде. Ул анда татар әдәбияты әсәрләрен венгр, итальян, урыс телләренә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнде. Венгриягә барып чыкты, Германиядә, Япония, Төркиядә булды, аннан Австралиядә шактый вакыт яшәде. Менә хәзер ул Англиядә яши һәм эшли. Чит-ят илдә үз танышыңны, үз милләттәшеңне очрату нинди шатлык булуын аңлавы авыр түгел. Равил Лондоннан ерак түгел Исламабад дигән кечкенәрәк шәһәрчектә яши икән. Биредә Әхмәди дигән дини оешма бар, ул анда ислам дине буенча аерым әсәрләрне урыс теленә тәрҗемә итү белән мәшгуль. Лондондагы Би-би-си радиосы аша урыс телендә татар тарихы, Татарстанның сәяси хәле турында чыгышлар ясап тора, шулай ук аның тавышын без «Азатлык» радиосы аркылы да ишетәбез. Кыскасы, чит илләрдә яшәсә дә, аның уе, гамәле үз милләте белән бәйле, максаты – аңа хезмәт итү. Шуны да әйтеп үтәргә кирәктер: биредә бөтен дөньяга таны таралган татар балет осталары да яши. Ә аларның татарны яклап, аның турында кайгыртып кыл да кыймылдатканнары юк. Киресенчә, алар үзләрен татар дип тә танымыйлар, телләрен дә «онытканнар», милләттәшләре белән аралашырга да теләмиләр...

Безне каршы алучыларның икенчесе Осман Төркай – дөньякүләм танылган шәхес. 1988 елда Англиянең Пен-клубы тарафыннан ул Нобель премиясенә тәкъдим ителгән була. О.Төркай – Кипр төреге, Кипрда һәм Англиядә белем алган, Лондон университетын тәмамлаган. Төрек һәм инглиз телендә чыккан дистәдән артык шигырьләр җыентыгы авторы. Англиядәге Кипр төрекләре ассоциациясенең генераль секретаре. Англиядә инглиз телендә чыга торган «Туркиш ньюс» журналы һәм төрек телендә чыга торган «Топлумун сеси» журналының баш редакторы. Дистәләгән әдәби, фәнни оешмаларның почётлы әгъзасы, күп тапкыр алар тарафыннан бүләкләр алган олуг шәхес.
Осман Төркай белән безне каршыларга тагын ике кеше килгән булып чыкты. Алар Мостафа Гөнчәй вә аның хатыны Омайя Гөнчәй иде. Мостафа да Кипр төреге, ул 30 елдан артык Англиянең атаклы Бритиш телефон компаниясенең инженеры булып эшләгән. Хәзер Англиядәге төркиләр җәмгыятенең рәисе. Бу комитетның максаты – Англиядә яшәүче бөтен төрки халыкларның мәдәни үзәген булдыру, телләрен, милләтләрен саклап калуда ярдәм итү, аларны берләштерү... Шушы максат белән Мостафа атналык «Пазар» исемле газета чыгаруга керешкән. Күләме белән 24 битле төрек телендәге бу газета үзенең битләрендә дөньядагы төрки халыклар тормышы, элекке СССРда яшәгән халыкларның милли азатлык өчен көрәше, Төркия, Кипр төрекләре хәле турында информацияләр урнаштыра. Җәмгыять хәзер инглиз телендә «Төрки дөнья» исемле журнал чыгару өчен әзерлек эшләре алып бара. Ул журналның максаты – төрки дөнья белән дөнья халыкларын таныштыру. Мостафаның бу изге эшендә уң кулы – аның хатыны Омайя ханым. Мостафа Англиядә яшәүче барлык халыклар белән элемтә урнаштыру өчен тырыша. Ул хәзерге көндә биредә 100 мең чамасы Кипр төрекләре, 35 мең чамасы госманлы төрекләре яшәвен әйтте, шулай ук азәрбайҗаннар, Казан төркиләре дә бар, ди, ләкин алар белән элемтәсе юк икән. Англиядәге төрекләр өчен биредә кичке мәктәпләр оештырылган, әдәби-музыкаль кичәләр булып тора. Англиягә килеп чыккан күренекле төрки халык вәкилләре белән очрашулар үткәрелә. Хәтта алар Лондонда яшәүче төрекләрдән аерым футбол командасы да төзегәннәр. Бу комитетның икенче максаты – Англиядә яшәүче төрекләрне һәм, гомумән, төрек халкын Англиядә һәм инглиз телле илләрдә таныту, алар турында дөрес мәгълүмат бирү.
Каршы алучылар аэропортка үз машиналары белән килгәннәр иде. Алар, безнең киләсене белеп, Лондон үзәгендәге Интер-континенталь исемле отельдә бүлмә дә алып куйганнар булып чыкты. Без, машинага утырып, аэропорттан Лондонга юл алдык. Ярты сәгатьтән инде килеп тә җиттек. Кунакханәгә урнаштык та, анда бер минут та утырып тормыйча, Лондон белән танышырга чыгып киттек. Лондонның Пикадули, Оксфорд дип аталган үзәк урамнары буйлап атлыйбыз, күзләребез – бер-берсенә охшамаган гүзәл биналарда, офисларда. Британ музее яныннан да узып киттек. Трафальгар мәйданында да булдык. Лондонның визит карточкасына әйләнгән, 1805 елда диңгез сугышында Англиянең җиңүенә багышлап корылган бу һәйкәл янында Югославиядәге сугышка каршы зур митинг бара иде. Аннан ерак түгел без «Печән базары урамы»на барып чыктык... Тукаебыз, Казанның Печән базары искә килеп төште. Биредә «Печән базары» дип аталган театр да бар икән... Бу турыда төрек дусларыбызга да әйтеп, көлешеп алдык.
Лондонның иң үзәге булган Соно мәйданын узып бераз баргач, Д’арблай дигән урамда Осман һәм Мостафа туганнар эшли торган йортка кердек. Шушы бинаның бишенче катында Осман һәм Мостафа бәйләр чыгара торган журналлар, газеталар редакциясе урнашкан. Без биредә бер-ике сәгать сөйләшеп утырдык. Алар бу очрашу турында, Татарстан хакында үзләренең матбага битләрендә язу максаты белән бездән мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алырга тырыштылар. Киләчәктә Татарстан һәм аның халкы турында мәкаләләр язып торуыбызны үтенделәр. Кич җиткәч, Равил Бохарай: «Минем Исламабадка соңгы автобусым китә», – дип, ашыгып бездән аерылды. Ә төрек дуслар, тәгам җыярга дип, безне ресторанга алып киттеләр. Бу – Лондонның үзәгендә урнашкан «Эфес» исемле төрек рестораны булып чыкты. Аның хуҗалары Казим вә Ибраһим исемле төрек кешеләре икән. Алар һәм анда эшләүчеләр Осман белән Мостафаны бик яхшы беләләр, инде безнең дә төркиләр булуыбызны белгәч, ерак юлдан килгән мосафирлар икәнебезне ишеткәч, бик яратып каршы алдылар, шимали төрекләре хәле турында сораулар бирделәр... Без биредә чын мәгънәсендә Шәрык ризыклары белән сыйландык.

Тамак ялгап алгач, Мостафа бәй безне үзенең машинасында төнге Лондон белән таныштырырга алып китте. Без Британия парламенты Вестминстер сарае, Биг Бен манарасы, Букенгэм сарае яныннан узып киттек, Темза елгасы аркылы салынган юлдан Ватерлоо урамына чыктык, шуннан борылып, отелебезгә кайттык. Лондон белән танышу өчен безнең нибары 4–5 сәгать вакытыбыз булды, инде иртән Кембриджга юл тотарга тиеш идек. 12 июльдә иртә торып, тизрәк урамга чыктык. Лондон белән ныграк танышасыбыз килә иде. Безнең отель атаклы Гаид Парк белән рәттән генә. Англиянең «демократик үзәге» булып саналган, вакытында биредә Садри Максуди булган, андагы митингларны күргән, ораторларны тыңлаган «Халык парламенты»на – Гаид Паркка кереп киттек. Садри Максуди эзләре төшкән юллардан митинг үтә торган почмакка бардык. Көн иртә, әле шәһәр уянып кына килә. «Халык парламенты»ның тәнәфес вакыты иде...
Шәһәрдә бераз йөргәч, ашыгып кунакханәгә кайттык. Тиздән Мостафа бәй килеп, безне Хитроу аэропортына алып китте. Хитроу аэропортыннан Кембриджга 80 миль чамасы. Без, автобуска утырып, юлга чыктык. Аэропорттан Мостафа бәй озатып калды. Ике сәгать буена күзебезне автобус тәрәзәсеннән алмадык... Англиянең кәртинкә кебек басуларын, кырларын, урманнарын күпме карасак та карап туярлык түгел. Юллар тигез, юл күрсәткечләре дә сәнгатьчә эшләнгән. Әкияттәге кебек матур йортлар, хуторлар, кечкенә шәһәрчекләр... Бигрәк тә шаккатырганы – иген кырлары. Анда һәр адым җир эшкәртелгән, игеннәр күкрәп үскән. Бирედә игеннең биеклеге 30–40 сантиметрдан артык түгел. Ә безнең илдә арышның буе метрдан артык, бодай да шул тирә, арпа да шактый биек. Күрәсең, бездә салам кыйммәтрәк нәрсәдер. Юл буйлары матур итеп киртәләнгән, урыны-урыны белән бизәкле коймалар белән аерылган. Көтү-көтү сарык, сыер, атлар. Аларны көтүчеләр дә юк, үз ирекләрендә, мул яшел болынлыкларда, кырларда утлап йөриләр...
Без икебез дә авыл балалары булгангадыр, Англиянең басу-кырларына, чәчкән бөртекләренең мул үсүенә, малларның көрлегенә, кырлардагы тәртипкә сокланып туя алмадык...
Менә Кембридж шәһәренә килеп җиттек. Шәһәр эчендә шәһәр булып урнашкан Изге Джон колледжының капкасы янында автобусыбыз туктады. Без регистрация үттек, һәрберебезгә берәр «фатир» бирделәр (ул «фатир» турында алда сөйләрбез).
Без урнашкан колледж үзе бер шәһәр-крепость икән. Аның бианалары моннан 400–500 ел элек төзелгән, дүртәр, бишәр катлы готик стильдәге архитектура, сәнгать сарайлары... Колледж крепость кебек, зур бианалар белән әйләндереп алынган. Аның аркылы Кам елгасы ага, ә елга аркылы салынган күпер үзе бер бина. Колледж территориясендә зур болын, су каналлары, агачлыклар. Йортлар тирәсендә чәчәкләр.
Кембридж – үзе шәһәр-университет, Англиянең иң борынгы, иң данлыклы университетларыннан. Бу шәһәр башта ук университет буларак төзелгән. 16 колледжы бар. Һәр колледж без урнашкан кебек аерым крепость-шәһәрчектән гыйбарәт, һәр колледж мөстәкыйль уку йорты да. Кембридж турында, аның колледжлары хакында Садри Максуди тасвирламасына күз салып карыйк: *«Кембридж шәһәре кечкенә (*хәзер анда 200 меңләп кеше яши. – *Ә. К., Р. В.), матур бер шәһәр, бөтен әтрафы яшеллек, болынлык. Шәһәр уртасыннан Кам елгасы ага, ә аның ярлары гранит ташлар белән ябылган, ныгытылган. Венециядәге кебек бу елга буенча гондолаларга утырып сәйяр кылалар. Урамнары пакь, йортлары матур. Бакчалар бик күп, һәрбере тәрбияле. Кечкенә шәһәрнең рәвеше безнең Россия җәнүбендәге дача йеренә, курортка охшаштыр. Кембридж колледжлары, Россиядәге һәм Франциядәге кеби, көндез килеп, дәрес ишетеп кенә китә торган йерләр түгел... Студентлар дарелфөнүнханәсендә һәм кунып торадыр. Бу – бер хосусият. Икенче кызык: Россиядә һәр шәһәрнең дарелфөнүне бер идарә мәркәзендә буладыр. Хәлбуки Кембридж шәһәрендәге дарелфөнүн андан зияда доходы, идарәсе, уставы, рәисе башка колледж дигән мәдрәсәләрдән мәркүбдер. Һәр колледжның үзенә мөдир вә берничә мөгаллимнәре бардыр. Колледжларда лекция укучы профессорлар аңа буйсынмый, аларның аерым бәйсез бер «һәйәте» бар. Колледжда уку түләүле. Колледжның һәрбере бик бай. Һәрберсенең доходы зур, имеш... Колледж бианаларының эчке төзелеше безнең Ислам мәдрәсәләренә бер җәһәтдән охшашдыр. Хөҗрәләре (фатирлары) бүленгән. Бинаның уртасында нәкъ Истамбул мәдрәсәләрендәге кеби бер мәйдан бар. Студент хөҗрәсе – ул өч бүлмәдән гыйбарәт. Берсе – алда, киемнәр сала*

*торган бүлмә, икенчесе – иҗтиһад бүлмәсе. Өченчесе – ятак бүлмәсе, һәрберсе гаять пакь, матур, бизәкле диварларда – рәсемнәр, шүрлекләрендә – гаять матур төпләнгән китаплар».*

Хәзер студентлар яши торган хөҗрәләр тагын да камилләшкән, анда компьютерлар, суыткычлар, һәр дүрт студент өчен ванна, душ, кухня, күпсанлы башка уңайлыклар...

Кыскасы, монда уку, белем алу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Әнә шуңа күрә дә Кембридж дөньяга бөек шәхесләр биргән, атаклы фәнни, интеллектуаль үзәккә әйләнгән, аның даны бөтен дөньяга таралган. Инде алда әйтеп үтелгән Халыкара Биографик Үзәк тә юкка гына Кембриджда барлыкка килмәгән. Кембридж университеты кешелек дөньясына бөек Байронны бүләк иткән, биредә Чарльз Дарвин, даны дөньяга таралган дәүләт эшлеклесе, галим, дипломат Генри Пальмерстон укыган... (Безнең пленар утырышлар Пальмерстон исемен йөрткән Актлар залында барды.)

Кембридж университетында яклаган диссертациянең авторитеты гаять зур. С. Максуди Кембриджда вакытта бирегә докторлык диссертациясе яклау өчен атаклы Тимирязев килгән була, шул мәҗлестә С. Максуди да катнаша...

Күпләр бу каланы музей-шәһәр дип тә атыйлар. Бер музейда без дә булдык. Анда Мисыр, Антик дөнья, Европа, Көнчыгыш сәнгать әсәрләре, без исемнәрен дә ишетмәгән рәссамнарның гүзәл картиналары – нинди генә коллекцияләр тупланмаган! Биредәге музейлар студентларның эш һәм тәҗрибә урыны да. Анда керү һәркем өчен бушлай. Без булган бу музей үзенең байлыгы белән бөтен Казан музейларыннан да баерактыр.

Конгресс барышында бер көн экскурсия көне иде. Без ул көнне иртән үк 70 чакрымнар тирәсендәге Сандрингал замогына юл тоттык. Ул Англия короле Георг V нең җәйге резиденциясе булган. Король сарае үзенең замоклары, кеше кулы белән гүзәлләндерелгән табигате, урманнары, күлләре, чәчәкле аллеялары, бай картина галереялары, тупланган җиһазлары белән Санкт-Петербург янындагы Петергофтан күпкә матуррак, гүзәлрәк, баерак... Англияне, дөресрәге, Бөекбритания корольлегенең барлык илләрен әйләнеп чыккан, аның бай замоклары, музейларын тамаша кылган Садри Максуди да әлеге сәнгать хәзинәләрен күреп шаккатуын яза. Садри Максуди шуның белән бергә бу җәүһәрләрнең төрле илләрне басып алу юлы белән тупланган байлык булуын да әйтеп үткән. Аларның күбесенең башка халыклар хәзинәсе булуын ассызыклап язып чыккан.

Конгресс тәмамланырга ике көн кала, Кембриджга Равил Бохарай килеп төште. Аны безнең янга Осман белән Мостафа бәй җибәргән икән. Алар Лонданда яшәүче төрекләр мәҗлесен җыеп, шунда безне чакырырга карар кылганнар. Аларның Лондонда яшәүче танышларының, милләттәшләренең Татарстан хәлләре турында яхшырак беләселәре, ишетәселәре килә икән... Без Лондонда вакытта ук Осман белән Мостафа бәйгә Лондонга бер-ике көн алдан кайтып, шәһәр белән ныграк танышырга, илебездәге хәлләрне тирәнрәк аңлатырга, әдәби элемтәләр урнаштыру хакында сөйләшергә ниятебез барлыгын әйткән идек. Ләкин бик теләсәк тә, Равил белән Лондонга бер-ике көнгә китә алмадык. Хитроу аэропортына кадәр алынган автобус билетын кире тапшырып, яңасын алып булмады. Ә билетның яңасын алу шактый кыйммәт, 18 фунт, безнеңчәгә күчерсәк, 5 мең сум чамасы тора... Аннан, Лондонга кайткач, без ике көн буена кайдадыр кунарга, кайдадыр, нәрсәдер ашарга тиешбез. Әлбәттә, алар безне яңадан отельгә урнаштырырлар, ашатырлар-эчертерләр иде. Ләкин кеше хисабына яшәргә, аларны акча ягыннан масрафка салырга намусыбыз риза түгел иде. Менә шулай итеп, без Лондондагы кардәш милләттәшләр белән очрашудан, башкала белән ныграк танышудан тыелырга мәҗбүр булдык.

Безнең өчен иң үкенечлесе – Британия музеенда була алмау... Аның китапханәсендә бөтен дөньяда чыккан китапларның иң бай тупланмасы бар. Анда безнең милли китапларыбыз, рухи хәзинәләребез дә сакланырга тиеш. Мәсәлән, 1935–1945 елларда Мукденда Гаяз Исхакый чыгарган «Милли байрак» дигән газета да анда бардыр дип уйлыйбыз. Озак еллар җаваплы сәркатибе булып торган Оркыя ханым Дәүләткильди бу газетаның һәр номерын шушы музей китапханәсенә җибәреп торуын үзе исән чакта ук безгә әйтеп калдырган иде. (Оркыя ханым Төркиядәге Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләтнең әнисе.) Безне ул газетаның музейга килеп җитүе, саклануы кызыксындыра иде. Чөнки бу газета – татар тарихының,

мәдәниятенең кыйммәтле хәзинәсе, аның битләрендә татар халкының язмышы, елъязмасы чагылган. Анда Гаяз Исхакыйның авторлыгы күрсәтелгән 50 ләп мәкаләсе басылган. Шулай ук 1917 елдан соң Германия, Польша, Япония һ.б. илләрдә татар зыялылары, милли азатлык өчен көрәшкән затлар чыгарган дистәләгән газета-журналларның да биредә саклануы-сакланмавын ачыклыйсыбыз килгән иде. Бу материалларны барлау, табу, аларны фәнни әйләнешкә кертү безнең йолкынган, таланган тарихыбызны торгызу өчен нинди зур әһәмияткә ия булуын без бик яхшы аңлыйбыз. Нишлисең, кая барма – ярлылык, акчасызлык итәктән тота шул.

Менә шулай итеп, бу сәяхәт бераз үкенеч тә китерде. Шунысын да әйтик: анда бару өчен мөмкинлекләр эзләү, табу гаять дәрәҗәдә авыр булды, кемнәр алдында гына йөз ертып баш иярга туры килмәде. Югыйсә без бит анда турист булып, күңел ачып йөрү өчен түгел, ә эш буенча, татар халкының мәнфәгатьләрен яклау өчен дип барган идек.

Англиядә без АКШ, Канада, Төркиядә күрмәгән бернәрсәгә тап булдык. Монда әйбер алда әйтеп үткән илләрдәгедән күпкә кыйммәтрәк. Ирләр күлмәгенең гадәтие 15–20 фунт стерлинг. Шәһәр эчендә йөрүче автобуска билет бәясе ярты фунттан алып бишәр фунтка хәтле – ераклыкка карап... Ике литр сөт – бер фунт. Ә Англиядә уртача хезмәт хакы – 1000 фунт чамасы. Ә аның 400 фунты фатирга, ут, су, газга түләргә китә. Дөрес, инглизләр безнең белән чагыштырганда бай яшиләр. Ләкин анда да тормыш җиңел түгел. Шуңа күрә эмигрантлар Англиягә омтылмый. Алар Австралия, Канада, АКШ кебек илләрне сайлыйлар.

Англиядә хәерчеләр дә очрый. Алар бездәгеләр кебек кул сузып хәер сорамыйлар. Йә гитара уйнап, йә саксофон кычкыртып, алларына берәр савыт куеп акча җыялар. Музейларына керү буш булса да, керә торган җирдә шундый савыт куелган. Анда: «Мөмкин булса, музейга ярдәм итегез», – дип язылган. Лондонның урам асты юлларында, паркларда төн үткәрүче, йоклап ятучылар да, фатирсыз кешеләр дә аз түгел. Юк-юк дисәк тә, Кембридж һәм Лондон урамнарында исерекләр дә күренгәли: Кембриджда көн уртасында өч исерек (үзләре яшь кешеләр) урам чатында ертык киемнәрдән аунап яталар иде... Без кызыксына башлагач, бу өч исерекне Россиядән килгән кешеләр дип аңлаттылар, дөресме-юкмы, анысын ачыклый алмадык.

Англиянең бай ил икәнен аның йортлары, урамнары, кибетләре кычкырып тора. Инглизләр үзләренең кешелек тарихына керткән зур өлешләрен бик яхшы беләләр, аңа бик нык күнеккәннәр. Әгәр син аларның бу ягын мактап сүз әйтсәң, алар моны гап-гади нәрсә итеп, исләре китмичә, шулай булырга тиеш дип кенә кабул итәләр. Без аларга Садри Максудиның Англия турындагы гаять кызыклы юлъязмалары булуы турында сөйләгәч, аны, бәлки, инглиз укучысына җиткерү кирәктер дигәч, моны игътибарга алучы да булмады. Әйтик, менә без бүген бер инглизнең татар халкы турында шундый китап язуын белсәк, ул безнең өчен сенсация булыр иде, аны икенче көнне үк басып чыгару ягын карар идек... Инглизләрне без картайган халык дип атар идек. Төркиядә, АКШта, Канадада, мәсәлән, без һәр йортның өстендә милли байраклары җилфердәвен күреп сокландык, кая барма, ул илләрнең гербы, милли флагы үрнәкләре сатыла, күп кешенең күкрәгендә милли герб значоклары...

Англиядә булган атна-ун көн эчендә без бары Лондонда гына бер йорт өстендә милли флаг күрдек. Канадада, АКШта төрле бәйрәмнәр милли флаг тоткан кешеләр белән тулган була. Торонтодагы бер бәйрәмне карарга баргач, безгә, мәйданга килеп керү белән, Канада флагын бүләк иттеләр, өрәңге яфрагы төшерелгән значогын күкрәкләребезгә кададылар. Кембриджда ике бәйрәм күрергә туры килде: берсе – җыр бәйрәме, икенчесе – балалар бәйрәме. Икесенең берсендә милли байрак күренмәде...

Англия үзенең байлыгыннан, зур тарихыннан арыган, картайган, күп төсләрне күрми һәм тәмнәрне тоймый башлаган кешене хәтерләтте. Ләкин шул ук вакытта биредә кешеләрнең акчага бик хирыс икәнен атлаган саен тоеп торасың. Аларда кешегә карата миһербанлык, ярдәмчеллек җитми, ясалмалылык, салкынлык сизелеп тора. Әллә инде без укыган китапларда, күргән фильмнарда Англияне гел томанлы ил дип тасвир кылганга, барып күргәнгә кадәр Бөекбритания утравы океан уртасыннан йөзеп баручы томанга төрелгән кораб булып күз алдына килеп баса иде. Ләкин, ни кызык, атна-ун көн эчендә без анда бер генә томанлы көн дә, төтенле завод та күрмәдек. Киресенчә, галәмәт зур заводны хәтерләткән төтенле-томанлы Казаныбыздан соң,

Лондон белән Кембридж үзләренең яктылыгы һәм чисталыгы белән күзләребезне ачкандай булды.

Дөрес, бу язмада Англиядә күргәннәрнең һәммәсен дә тәфсилләп сөйләп тормадык. Сәяхәтебезнең маҗаралы, аянычлы көннәре һәм көтелмәгәндә күңелгә шатлык китергән мизгелләре хакында югыйсә бик озаклап хикәя кылып булыр иде. Безнең Кембридждагы телефоныбызны эзләп табып, Нью-Йорктан шылтыраткан Рифат Табиның тавышын ишетү, аның безнең өчен борчылып һәм кайгыртып, кирәксә, ярдәм кулы сузарга әзер торуын белү, билгеле, бик күңелле булды. АКШта яшәүче профессор, милләттәшебез Рифат Табиның авазы безгә милли хиснең никадәр изге һәм көчле икәнлеген тагын бер кат искәртте. Ә инде Кембриджда яшәүче мөселманнар җәмгыяте үзләренә кунакка дәшкәч, без дөньядагы бер миллиард халыкны берләштергән динебезнең куәтен һәм зурлыгын тойдык, үзебезнең шул Ислам дөньясы балалары икәнлегебезгә куандык.

Англиягә сәяхәт вакытында без чит илләрне һәм кешеләрне күреп, алар белән аралашып, аларга үзебезне, дөресрәге, Татарстанны һәм татар халкын күрсәтеп кайттык.

«Англиядә, Лондонда нишләп томан юк?» – дип сорагач, Осман Төркай, елмаеп, болай диде: «Дуслар килгән чакта томанлы көнне дә кояш чыга. Сез безгә ешрак килегез, үзара ешрак йөрешик, аралашыйк. Шулай итсәк, арадагы томаннар таралыр. Менә сез килгәнче мин Татарстанны бөтенләй диярлек белми идем. Лондоннан Казан күренми иде. Ә хәзер күренә!»

Осман Төркайның сүзләренә өстәп шуны гына әйтәсе килә: Татарстанны тизрәк дөнья илләре танысын, Татарстан дөнья мәйданына чыксын, Татарстан Җир шарының теләсә кайсы ноктасыннан күренерлек булсын иде.

*1992*

# «БӘЙРӘМ БҮГЕН!»

Ниһаять, безнең урамга да бәйрәм килде! Моңа кадәр без башка һөнәр ияләренең бәйрәмнәрендә кунак буларак кына катнаша, алардан яхшы мәгънәсендә көнләшә идек. Мәдәният хезмәткәрләренә, бигрәк тә китапханәчеләргә үксетеп караган, аларга кирәкле һәрнәрсәне дә иң соңгы чиктә генә сыкраныпынгырашып бирә торган җәмгыятьтә башкача була да алмагандыр инде. Менә, ниһаять, чират безгә дә җитте, иң соңгылардан булып илдә «Китапханәчеләр көне» игълан ителде. «Соң булса да, уң булсын» диләр халыкта, анысы өчен дә рәхмәт!

Ныгытып уйласаң, кешелекнең чын тарихы, цивилизацияле, аң-белемле тарихы Китап галиҗәнаплары дөньяга килгән чорда башлана. Язу уйлап табылганчыга, кульъязма һәм басма китаплар күренә башлаганчыга кадәрге заманны кешелекнең балачагы, хәтта тарихка да ныклап уелып калмаган чоры, дисәк, ялгыш булмас кебек.

Китап язган, китап бастырган, китап тараткан халыкның аң-белем дәрәҗәсе, уй-гамәл мөмкинлекләре язуы булмаган халыкларга караганда күпкә өстенрәк булуы хакында бәхәс кузгатып торуның кирәге юктыр. Халыкны олы бер рух тирәсенә туплап, миллионлаган кешеләрне бер әхлак, бер гадәт-йола, бер тәртипкә күндереп килгән дин тәгълиматлары да безгә һәм безнең әби-бабаларыбызга, нигездә, «Олуг китап» аша барып ирешкән. Димәк, безнең халыкны гасырлар буена Китап тәрбияләп, ышаныч һәм өмет биреп киләчәккә алып барган һәм мөмкин булган кадәр тарих упкынына төшеп югалудан саклап калган.

Китапның һәм китапханәләрнең дәүләт, җәмгыять һәм халык язмышында нинди зур урын тотканын борынгы заманнарда ук бик яхшы аңлаганнар һәм тәрәккыяткә ирешкән илләрдә моңа бүген дә зур әһәмият бирәләр. Императорлар һәм патшалар, ханнар һәм солтаннар үзләренең башкалаларында иң үзәктә китапханәләр өчен иң матур биналар төзеткәннәр. АКШ, Франция, Канада, Англия, Германия, Корея һәм Кытай, Төркия һәм Согуд Гарәбстаны кебек илләрдә соңгы елларда үз илләре бөеклегенә бәрабәр китапханәләр салынуы бу илләрдә яшәүче халыкларның үз киләчәкләрен чын-чынлап кайгыртуы хакында сөйли.

Кайсы гына шәһәргә, кайсы гына илгә барсам да, иң беренче эшем итеп мин китапханәгә, базарга һәм зиратка кереп чыгам. Чөнки шушы өч урында булсаң, мондагы халыкның культура дәрәҗәсен, икътисади хәлен һәм үзенең үткәненә, тарихына мөнәсәбәтен күзаллый аласың. Әллә ни ерак йөрмичә, үзебезнең Татарстан авылларына барсаң да, һәммә җирдә диярлек китапханә башка оешмалардан пөхтәлеге, чисталыгы, тәртибе белән аерылып тора. Татар авылларында әле хәзер дә китап укучылар китапханәгә, мәчеткә кергән кебек, аяк киемнәрен салып керәләр. Ягез, кайсыгызның кибеткә, колхоз-совхоз идарәсенә, җирле хакимият бинасына яисә клубка аяк киемен салып кергәнне күргәнегез бар? Булса да, бик сирәктер. Ә китапханәгә керәләр, аяк киемен урамда калдырып, баш киемен салып керәләр. Бу инде халыкның китапка табынуыннан, бу инде китапханәчегә изге зат итеп караудан килә.

Татарстан Милли китапханәсенең төп бинасын белмәгән кеше бик сирәктер. 1919 елны, дөньяның асты өскә килгән заманда, бу гүзәл бина безнең китапханәгә бирелә. Әле бүгенге көндә дә китапханә залларында бу йортның хуҗасы Ушковтан калган бәллүр люстралар эленеп тора, шул чорның шәмдәлләре, сәгатьләре, төрледән-төрле бизәкләре, серле мәгарәләре, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән каминнары – барысы да исән-сау, барысы да үз урынында.

Кайчакта уйланып куям: әгәр дә бу гаҗәеп бинаны берәр башка оешмага бирсәләр, дәүләт конторасы яисә кибет-мазар ясасалар, әлеге тарихи җәүһәрләр сакланган булыр идеме икән?

Илләр, дөньялар мең кат буталып, җәмгыятебез тәртипсезлекнең, әхлаксызлыкның соңгы чигенә җиткән бер чорда, китапханәләрнең авырлык белән булса да җан асравы, аларда әле һаман да чисталык һәм пөхтәлек, халыкның рухи хәзинәләренә, тарихына олы хөрмәт, кешеләргә кешечә яхшы мөгамәлә саклануы – үзе бер куанычтыр. Чөнки безнең киләчәгебез кыргый эшкуарлар, надан малтабарлар, тар маңгайлы чиновниклар кулында булырга тиеш түгел. Алар килер дә китәр, ә халык калыр. Ә халыкның иң аңлы, иң өметле өлеше бүген, караңгы төнне учак янына ашыккан юлчы кебек, театрларга, музейларга, китапханәләргә килеп елыша, үз күңеленә алардан яктылык, җылылык алырга омтыла.

Китапханәгә бару, киштәләргә тезелеп сине көтеп торган акыл ияләре белән очрашып, күзгә-күз фикер алышу, андагы сихри тынлыкка чумып, хыял диңгезендә йөзү – һәркем өчен бер рухи бәйрәмдер. Ә инде безнең өчен бүген – бәйрәмнәрнең дә бәйрәме, китапханәләр көне!

Тарихта тәүге мәртәбә үткәрелә торган бәйрәмебез котлы булсын, һөнәрдәшләр! Иреннәрегез һәрчак елмаю белән тулып торсын!

*1996*

# КИТАПХАНӘ – ХАЛКЫБЫЗ РУХЫН САКЛАУЧЫ ҮЗӘК УЛ

Бүгенге катлаулы тормыш шартларында Дәүләт Советы сессиясенең көн тәртибенә халкыбызның рухи тормышында әһәмиятле урын тоткан китапханәләр эше турындагы мәсьәлә кертелүне республика җитәкчеләренең, депутатларыбызның бу өлкәгә даими игътибар итүе дип санарга кирәк.

Чыгышымның башында мәсьәләнең Дәүләт Советы сессиясе дәрәҗәсенә күтәрелү сәбәпләрен искә төшереп үтәсем килә.

1999 елда Россия Федерациясе хөкүмәте Россия мәдәният министрлыгының кайда күпме дәүләт китапханәсе булырга тиешлеген күрсәткән нормативларын раслады. Бу нормативлар буенча Россия Федерациясе субъектларындагы 500 дән ким кеше яши торган авылларда эшләп килүче китапханәләр «нормативтан югары», ягъни «сверхнормативный» дип табылды.

Әлеге нормативлар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2002 елның июнендә безнең республикадагы социаль гарантияләр дәрәҗәсен билгеләгән карар кабул итте. Үз чиратында, республиканың 2003 елгы бюджет проектын хәзерләү барышында, Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан икътисади һәм социаль эзләнүләр үзәге мәдәни учреждениеләрне дәүләт финанславы буенча исәпләүләр эшләде. Бу исәпләүләр буенча Татарстан Республикасының 500 дән ким кеше яши торган авылларындагы 304 авыл китапханәсе алдагы елларда дәүләт бюджетына кертелмәскә тиеш булды. Әлеге китапханәләрнең күпчелеге – егерменче гасырның утызынчы елларында дәүләт тарафыннан оештырылып эшли башлаган, Бөек Ватан сугышы елларында да ябылмыйча авыл халкына хезмәт итеп килгән, 70–80 ел эчендә бай китап фондларын, биналарын, бигрәк тә һәр авылның рухи, сәяси һәм тәрбияви тормышында әһәмиятле традицияләрен булдырган зур тарихлы мәдәният учаклары. Аларның юкка чыгуы яки танымаслык булып үзгәрү мөмкинлеге барыбызны да борчый. 2003 елгы бюджет проектын тикшерү барышында безнең фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясендәге халык депутатлары, бу хәлгә аеруча игътибар итеп, әлеге китапханәләрне саклап калу юлларын эзли башладылар. Дәүләт Советының XIII пленар сессиясе 2003 елгы бюджет проектын тикшергәндә, алар бу мәсьәләгә махсус тукталдылар. Бюджетны аерым чыгымнардан азат итү кирәклеге белән бергә, әлеге китапханәләрне ничегрәк саклап калу мөмкинлеге турында да сорау туды. Әлбәттә, бу катлаулы мәсьәләне тирәнтен өйрәнеп бетермичә әлеге сорауга тулысынча җавап бирү мөмкин түгел иде. Сессия һәм Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев, бу мәсьәләне ныклап өйрәнергә, нәтиҗәләрне алдагы сессиядә депутатларга җиткерергә дип, безнең комиссиягә протокол рәвештә йөкләмә бирделәр.

Сессиядә «нормативтан югары» дип саналган китапханәләрне аларның эш юнәлешләрен үзгәртү юлы белән саклап калу максатыннан чыгып берничә тәкъдим әйтелде. Әйтик, тиешле шартлар булган авылларда авыл китапханәсе белән мәктәп китапханәсен яки аралары 3 чакрымнан ким булган авылларда урнашкан «нормативтан югары» китапханәләрне берләштерү.

XIII сессиядән соң безнең комиссиядә бу мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен махсус эш төркеме расланды. Әлеге төркемгә халык депутатлары, шулай ук мәдәният, мәгариф министрлыклары, халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләләре идарәсе, Республика профсоюз оешмасы, Татарстан икътисади һәм социаль эзләнүләр үзәге, Татарстан Милли китапханәсе вәкилләре кертелде. Бу эш төркеменә «нормативтан югары» дип саналган иң күп китапханәләр булган Аксубай, Яшел Үзән һәм Кайбыч районнарына барып, мәсьәләнең торышын тикшерергә һәм, махсус анкеталар эшләп, бөтен республикадагы әлеге китапханәләр турында мәгълүмат булдырырга кушылды.

Төркем шул юнәлештә ике ай ярым эш алып барды, аннан бөтен нәтиҗәләрне туплап комиссиягә тапшырды. Комиссия әлеге материалларга нигезләнеп махсус белешмә эшләде, Дәүләт Советы

карары проектын әзерләде. Алар сезгә таратылды, һәм мин әлеге мәсьәләне хәл иткәндә безнең тәкъдимнәрне якларсыз дип ышанам.
Сүземне эшче төркем өйрәнеп кайткан Аксубай, Яшел Үзән һәм Кайбыч районнарындагы хәлләрдән башлыйм. Өйрәнү күрсәткәнчә, Аксубай районында «нормативтан югары» 17 китапханә исәпләнә. Чынлыкта алар 15 кенә. Ике авылда халык саны арту сәбәпле, алардагы китапханәләр бүгенге көндә Министрлар Кабинеты эшләгән нормативларга сыеша. Тагын 7 авылда мәктәп китапханәсе юк, димәк, авыл китапханәләрен алар белән кушып булмый. Авыл һәм мәктәп китапханәләре булган өч авылның икесендә мәктәп китапханәләре урнашкан бүлмә 9 кв.метрдан артмый, ә бер мәктәп бинасы бик искергән. Дөрес, аралары 3 чакрымнан ким булган ике авыл китапханәсен кушу мөмкинлеге бар. Тик, болай иткәндә, кушылган китапханәдә эш күләме арта, китапханәчеләр штатын арттырырга туры килә. Моннан бюджетка бер тиен дә файда калмый.
Яшел Үзән районында «нормативтан югары» 6 китапханә исәпләнә. Аларның бишесендә китапханәчеләр ярты ставкага эшли, китапханәләрне кушып, берәр ставка ясаганда, бюджет бер елга нибары 78 мең 700 сум гына отачак.
Кайбыч районында әлеге «артык» дип саналган китапханәләр унберәү исәпләнә. Әмма күптән түгел булып үткән җирле үзидарә органнарын үзгәртү барышында аларның саны сигезгә генә калган. «Нормативтан югары» дип исәпләнгән өч авыл китапханәсе күрше тирәдәге өчәр-дүртәр авылга хезмәт күрсәтә. Китапханәләрне кыскартсаң, дистәдән артык авыл халкы китапханә хезмәтеннән мәхрүм калачак, чөнки аларның берсендә дә мәктәп китапханәсе эшләми. Бу районда аралары 3 чакрымнан ким булган авыл китапханәләре дә юк. Райондагы «нормативтан югары» дип саналган китапханәләрне япкан очракта җиде ярым китапханәче штаты кыскартылачак. Шунысы да бар: бу китапханәләрнең барысы да клуб биналарында эшли. Димәк, коммуналь чыгымнарны янга калдыру мөмкинлеге юк. Райондагы өч авыл китапханәсенең биналары искергән. Район хакимиятенә аларга ремонт ясау чарасын күрергә кирәк. Эш төркеме Кайбыч районында бердәнбер китапханәне (Афанас авылы) ябарга мөмкин дип саный – аның бинасы авария хәлендә. Бу өч район белән хәлләр әнә шундый.
Әйткәнемчә, безнең комиссия республикадагы бөтен район хакимияте башлыкларына да «нормативтан югары» булган китапханәләр турында мәгълүмат алу өчен анкеталар җибәрде.
Республикабызның 38 районы һәм шәһәре җитәкчеләре, шулай ук китапханә хезмәткәрләре «нормативтан югары» дип саналган китапханәләрне саклап калуның кирәклеге турында хәбәр итәләр. Республиканың берничә районында гына сессиядә мәсьәлә хәл ителгәнче үк үзгәрешләр кертергә өлгергәннәр – Минзәләдә ике авыл китапханәсе кыскартылып мәктәп китапханәләренә күчерелгән, Әгерҗе районында өлкәннәр һәм балалар китапханәләрен берләштергәннәр, Лениногорск районында ике авыл китапханәсен кыскартканнар һәм өч китапханәченең эш хакын яртышар ставкага калдырганнар.
Комиссия фикеренчә, республикада «нормативтан югары» дип исәпләнгән 300 китапханәне һич кенә дә ябарга ярамый. Аларның барлыгы 71 мең китап укучысы бар. Китапханәләр урнашкан авылларда 89 мең кеше яши. Шулардан 16 меңе балалар, 46 меңе эшләүче кешеләр, 27 меңе пенсионерлар. «Нормативтан югары» дип саналган 104 китапханә урнашкан авылларда мәктәп китапханәләре дә бар. Әмма аларның иң зур күпчелеге 15 кв. метрдан артмаган кысан бүлмәләрдә урнашкан, авыл китапханәсеннән күчереләчәк китаплар анда сыймый.
Авыл китапханәләрен мәктәп китапханәләренә күчерү мәсьәләсе бик тә катлаулы. Беренчедән, биналар кечкенә, икенчедән, башлыча кичтән генә китапханәгә йөри торган авыл кешесен укулар беткәч юып, җыештырып куелган мәктәп бинасына кертү мәктәптә уку-укыту эшен оештыруның санитар кагыйдәләренә каршы килә.
Шул ук вакытта мәктәп китапханәләренең барысында да диярлек уку заллары һәм олылар өчен нәшер ителә торган газета-журналлар юк.
«Китапханәләр һәм китапханә эше турында»гы Татарстан Республикасы Законындагы авыл китапханәләре эше турындагы таләпләрнең күбесен мәктәп эченә урнашкан кысан бүлмәләрдә башкарырга мөмкин түгел.

Республикадагы «нормативтан югары» дип саналган 156 авыл китапханәсе үзләре урнашкан авыллардан тыш әле тагын тирә-юньдәге 366 кечкенә авыл халкына хезмәт күрсәтә. Шулай итеп, әгәр әлеге 304 китапханә ябылса, республикабызның 514 авылы китапханә хезмәтеннән мәхрүм булачак.

Финанс чыгымнарын санаудан тыш, авыл китапханәләренең авыл һәм, гомумән, халыкның рухи тормышындагы урынын, һәр китапханәнең үзенә генә хас булган үзенчәлекләрен дә искә алмыйча булмый. Әйтик, татар халкының күренекле уллары Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Таҗи Гыйззәт, Хәсән Туфан, Нәҗип Думави, Зәки Нури, Газиз Кашапов, чуваш әдәбияты классигы Полорусов Шәләбиләрнең туган авылларындагы китапханәләр «нормативтан югары» исемлегенә кертелеп, ябылу куркынычына дучар булдылар. Аларның күбесе бит халкыбызның рухи тарихында атаклы авыллар – Кушлавыч, Шырдан, Кармәт, Яңа Дума һәм башкалар... Каюм Насыйриның туган авылы Кече Шырдан китапханәсенә аерым тукталасы килә. Комиссиянең эшче төркеме бу авылда да булды. Авыл китапханәсе Каюм Насыйри үз акчасына төзегән элеккеге авыл мәдрәсәсе бинасына урнашкан. Дөрес, Каюм Насыйри заманыннан калган бу агач бина инде бик нык искергән, тузган. Әмма аның мемориаль бина, тарихи бина икәнен онытмаска кирәк. Безнең комиссия бу китапханәне ябарга түгел, киресенчә, дәүләт исәбенә төзәтеп, яңартып, аңа «Каюм Насыйри исемендәге мемориаль китапханә» дигән исем бирергә кирәк дип саный.

«Нормативтан югары» дип саналган китапханәләр исемлегендә 296 татар авылы китапханәсе һәм шулай ук 3 чуваш, 2 рус, 2 удмурт, 1 мордва авыл китапханәсе керә. Бу китапханәләр – әлеге милләтләрнең рухи мәдәниятен, әдәбиятын, милли телдәге китапларны саклаучы бердәнбер милли мәдәният үзәкләре. Аларны ябып кую республикабызның бүгенге милли сәясәтенә һич кенә дә туры килмәс иде.

Россия Федерациясе мәдәният министрлыгы мәгълүматларына караганда, бер китапханәчегә төшкән эш күләме, китап укучылар саны һәм кулга китап бирү күрсәткечләре буенча Татарстан Республикасы Россиянең 89 регионы арасында алтынчы урынны алып тора. «Нормативтан югары» дип исәпләнгән китапханәләрне кыскартсаң, китапханәчеләргә эшләү тагын да авыраячак.

«Нормативтан югары» дигән китапханәләр исемлеге билгеле булгач, бу китапханәләр урнашкан авыллардагы китап сөючеләр, республикабыз районнары һәм шәһәрләрендәге китапханә хезмәткәрләре, җитәкчеләр, республикабызның мәдәни җәмәгатьчелеге әлеге авыл китапханәләренең язмышы өчен тирән борчылуларын белдерә башладылар. Республика һәм район газеталарында басылган күпләгән мәкаләләрдә, чыгышларда инде авылда бердәнбер мәдәният учагы булып кала барган китапханәләрне саклауның зур әһәмияткә ия икәнлеге әйтелде. Бүгенге көндә китапханә ул гади китап фонды гына түгел, ә халкыбыз рухын саклаучы үзәк тә, хокук бозучылар, наркомания, эчкечелек, рухсызлык белән көрәш урыны да. Моны да истән чыгармаска иде.

Минемчә, бу залда да, республикабыз җәмәгатьчелегендә дә эшләп торган китапханәләрне ябарга теләүчеләр юктыр. Шул ук вакытта без дәүләт кабул иткән карарларны да үтәргә тиешбез. Шуңа күрә безгә мәсьәләне үзара килешеп, иң кулай мөмкинлекләрне файдаланып хәл итәргә кирәк. Әнә шулар нигезендә безнең комиссия сессиягә карар проектын эшләде. Безнеңчә, күпмилләтле республикабыз үзенчәлекләрен искә алып, әлегә яшәп һәм эшләп килә торган китапханәләребезне саклап калу максатларында нормативларыбызны яңадан бер карап, аларны яңартырга кирәк. Карар проектында моны тормышка ашырырга конкрет тәкъдимнәр бар.

Сүземнең соңында шуны да әйтәсем килә. Китапханәләрнең санын саклап калу гына әле аларның эшен яхшыртуга, алга җибәрүгә төп сәбәп була алмаячак. Сүз дә юк, китапханәләребез эшен тагын да яхшыртуда кадрлар, китап фондын арттыру, биналарны төзек хәлдә тоту мәсьәләләре беренче чиратта тора. Ә инде нормативлар мәсьәләсенә килгәндә, без бик нык тырышып һәм зурдан кубып китапханәләрне киметү нормативларын тормышка ашырырга тотындык. Ә бит бу өлкәдә башка нормативлар да бар – әйтик, китап фондларын яңарту, биналарның зурлыгы, аларны җылылык һәм башка коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү нормативлары, көндәлек басмаларга язылу һәм башкалар. Бу нормативларның күбесе үтәлмәсә дә, нишләптер ул хакта чаң

сугарга җыенып торучылар юк. Бүген без барыбыз да – Татарстан Мәдәният министрлыгы, республикабызның Милли китапханәсе, район һәм шәһәрләрдәге үзәк китапханә системасы җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, район һәм шәһәр хакимиятләре, җирле үзидарә органнары – боларны һәрдаим истә тотарга тиешбез.

*2003*

# МИЛЛИ КИТАПХАНӘ ДИГӘН ГАЛӘМ БАР

Минем беренче укыган китабыммы? «Китапханә хәбәрләре» журналының чираттагы санын ачып җибәрә торган мәкаләне язачак кеше алдында, гадәттә, шушы сорауга да җавап бирү бурычы куела... Рәссамнар Лотфулла Фәттахов белән Харис Якупов искиткеч матур итеп бизәгән ике томлык «Татар халык әкиятләре» иде минем беренче китапларым. Табигый хәл: балачакта игътибар беренче чиратта рәсемнәргә юнәлә. Баланы укуга җәлеп итүдә аларның әһәмияте бик зур. Ә укырга мин дүрт яшемдә өйрәндем. Апаларым дәрес әзерли иде, мин янәшә утырам, игътибар белән тыңлыйм, китапларын актарам... Биш яшьләр тулганда, республика газеталарын эштән арып кайткан әткәйгә – колхоз рәисенә – кычкырып һәм булдыра алган кадәр сәнгатьле итеп укый идем.

Түбән Кама районының Ташлык авылында башлангыч белем алдым. Җәйгә чыккач, алдагы уку елы өчен дәреслекләр бирәләр иде һәм, иң кызыгы, сентябрьгә кадәр аларның барысын да, хәтта математикадан мәсьәләләр җыентыкларын да, мавыктыргыч әдәби әсәрләргә тап булган кебек, йотлыгып укып чыга идем. Алга таба укуымны дәвам иткән күрше Шәңгәлче авылында заманына күрә әйбәт кенә китапханә бар иде. Анда булган китапларның барысын да диярлек укыдым, хәтта марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен «кимерергә» тырышып карадым. «Алга бер адым, артка ике адым»ны чынлап торып укый башлаган идем дә (исеме әдәби әсәрнекенә охшаган бит, шул кызыктырды), теш үтмәгәч, туктадым. Мөгаен, нәкъ менә шул мавыгып, аерыла алмыйча китап укыган елларда, минем күңелдә үскәч китапханәче булу теләге уянгандыр да.

Мин Казан университетында укыдым, Мәскәүдә Әдәбият институтын тәмамладым, профессиональ язучы булдым һәм 1986 елда республиканың баш китапханәсенә директор итеп билгеләндем. Бу вакытларда үземне шактый ук гыйлемле, күп укыган кеше дип саный идем.

Күз алдыгызга китерегез, менә яңа килгән директор буларак китапханә белән танышып йөрим, китап саклау бүлмәләренә керәм. Китап киштәләре яныннан таң калып үтәм... Киштәләр, киштәләр, киштәләр – чиксезлеккә сузылган кебек озын, ә биеклекләре түшәмгә кадәр. Өч миллион китап. Барысын да укып чыгар өчен күпме вакыт кирәк? Аз да түгел, күп тә түгел – 6 мең кеше гомере җитә икән! Шулчак чын-чынлап тетрәнү кичердем мин. Кешелекнең күпгасырлык үсеше белән бергә тупланып, тыгызланып шушы китап битләренә салынган гыйлем, фикер, шигърият дәрьясы каршында үземне нindидер акыллы башка санап торам бит әле! Республика китапханәсе киштәләрен бер кат карап узу гына да мине җиргә төшереп бастырырга җитә калды. Тетрәнү халәтеннән исә авыр һәм акрын чыктым. Ләкин балачактан ук китапны бөтен рухым белән яратуым күңел халәтемне дөресләде, алга таба гамәлләремне Китапка хезмәт итүгә юнәлдерде.

Галиҗәнап Китап патшалыгында язучылар, наширләр, китапханәчеләр, китап сатучылар һәм китап укучылар булырга тиеш. Татарстан Милли китапханәсендә боларның һәммәсе дә бар, бар гына да түгел, алар үзара бәйләнештә һәм актив хәрәкәттә. Безнең китапханәдән файдаланучы 60 мең кеше арасында Казанда, республикада яшәүчеләр һәм илнең башка төбәкләреннән килгәннәре бар. Алар төрле милләттән, төрле һөнәр ияләре, төрле буын кешеләре. Яшьләр, студентлар күбрәк. Бу аңлашыла да: беренчедән, Казан – студентлар шәһәре, икенчедән, бәхәссез ки, мөстәкыйль тормыш юлына аяк басканда кешегә китапның ярдәме аеруча кирәк.

Китап сатучылармы? Алар да бар, чөнки безнең биналарда китап сату эше дә җайга салынган. Сатудагы китаплар арасында китапханә үзе нәшер иткәннәре дә аз түгел. Китапханәдә махсус булдырылган «Милли китап» нәшрияты республикадагы наширлек эшчәнлегендә үз урынын алды инде.

Нәшрият эшчәнлеге турында сүз чыккач, «Китапханә хәбәрләре» журналы турында да әйтергә кирәк. Ул елга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә чыга, бизәлеше саннан санга камилләшә бара, форматы – А4. Әлеге басма өчен һәрберебезнең мәкалә, кызыклы хәбәр язып бирү мөмкинлеге бар – журнал тулысы белән штаттан тыш авторлар җибәргән язмаларга нигезләнә.

Күргәнегезчә, Милли китапханә хезмәткәрләре китап биреп торучы гади китапханәчеләр генә түгел, алар – киң профильле белгечләр дә. Араларында методистлар, гыйльми хезмәткәрләр, язучылар, журналистлар, тәрҗемәчеләр, компьютерчылар, наширләр дә бар.

Китапханә атамасындагы «Милли» төшенчәсе турында. Ни өчен «Милли китапханә»? Бу – бөтен дөньяда кабул ителгән төшенчә. «Милли» – дәүләтнеке дигән сүз. Аңарга без икенче мәгънә дә салабыз. Ягъни, бер яктан, дәүләт китапханәсе буларак, ул Татарстандагы барлык катлау кешеләренең, шулай ук Президент Аппараты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты кебек югары органнарның да ихтыяҗларын канәгатьләндерсә, икенче яктан, Татарстан Республикасы өчен генә түгел, ә барлык татар халкы өчен баш китапханә булып тора. Төгәлрәк әйтсәк, бездә татарлар өчен, татарлар турында һәм татар дөньясына караган әдәбият мөмкин булган кадәр тулы туплана. Дөрестән дә, татар милләте турындагы барлык мәгълүматны, гыйлемнәрне, язма һәм басма әдәбиятны җыючы, саклаучы, эшкәртүче һәм төркемләүче, таратучы һәм танытучы китапханә дөньяда башка юк. «Милли китапханә» статусы аңа 1991 елда бирелде.

Вазифаларыннан чыгып караганда, Татарстан Милли китапханәсенә фәнни-мәгълүмати мәдәни үзәк дигән билгеләмә бик туры килә. Китапханәнең фәнни эшчәнлеге белән абруйлы һәм югары дәрәҗәле Гыйльми шура җитәкчелек итә, аңа дөрес юнәлеш бирә. Гыйльми шурага академиклар, фән докторлары һәм кандидатлары, китапханә-библиография эше белгечләре керә.

Тарихчы галим һәм язучы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Госмановның күп еллардан бирле кульъязма китаплар буенча китапханә хезмәткәрләре өчен фәнни киңәшче булып эшләве – безгә горурлык. Аның киңәш-консультацияләре – бәһасез мәгълүматлар җиткерүче, яңа ачышларга юнәлтүче, тарихи чыганакларны барлаучы фәнни лекцияләр дәрәҗәсендә.

Вафатына кадәр, озак еллар бездә галим-филолог, ТФА академигы Әбрар Кәримуллин иске басма китаплар буенча консультант булып эшләде. Аның татар китабы тарихына, филологиягә һәм библиографиягә караган хезмәтләре зур кыйммәткә ия. Хәзер Татарстан Милли китапханәсендә Ә.Кәримуллинның тормыш юлын һәм гыйльми-иҗади эшчәнлеген чагылдырган мемориаль бүлмә булдырыла.

Республиканың баш китапханәсендә сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге оештырылу да очраклы хәл түгел. Моңа гыйльми көчләрнең һәм фондларның тиешле дәрәҗәдә булуы мөмкинлек бирде.

Чит телләрдәге әдәбият бүлегенең аерым бүлекчәләре буларак китапханәдә Америка үзәге һәм Алман уку залы ачылды. Аларны ачу тантаналарында АКШның Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Джеймс Коллинз һәм Алманиянең Россиядәге илчелеге мәдәният атташесы Альбрехт Конц әфәнделәр катнашты, – бу үзе үк әлеге вакыйгаларның әһәмиятен күрсәтә. Бирedә үк Интернет-үзәк уңышлы эшли, аның ярдәме белән онлайн тәртибендә бушлай тренинглар, тематик семинарлар һәм башка төрле чаралар үткәрелә.

Милли китапханәнең ни өчен мәдәни үзәк булуы ачык аңлашыла – кайда китап, шунда мәдәният. Ләкин бу җәһәттән дә Татарстан Милли китапханәсенең үзенчәлекләре, аерым эш юнәлешләре бар. Китапны тудыручыларга, китап патшалыгындагы төп затларның берсе булган язучыларга, тирән ихтирам һәм игътибар белән карыйлар бирedә.

Сер түгел, язучының үзе иҗат иткән әсәрләр турында, роман булсынмы ул, әллә кечкенә шигырь җыентыгымы, укучы фикерен беләсе килә. Менә ике дистә елга якын инде республикадагы барлык китапханәләр катнашында без «Ел китабы»н билгелибез, чәчмә әсәрләр, тезмә әсәрләр, балалар әдәбияты һ. б. номинацияләр буенча конкурс үткәрәбез. Кайсы китапларның иң укылышлы, популяр икәнлеген белү дә кирәк бит. Ә бу очракта хәрәмләшүгә юл куелмый – җиңүчеләр заказ белән матбугатта бастырылган рецензияләр аша түгел, ә китапханәләрдәге укучы формулярларында күрсәтелгән мәгълүматлар буенча билгеләнә. Минемчә, китапханәчеләрнең әлеге катлаулы эше, «Хезмәтенә иҗади мөнәсәбәт һәм әдәбиятны үстерүгә керткән өлеше өчен» дип, бик югары бәяләнергә лаеклы. Шушы уңай белән китапханәчеләребезне бүләкләп үтү җаен да табарга кирәктер безгә.

Әйе, китапханәчеләр язучы-китап укучы бәйләнеше турында кайгырта, моның әдипләргә генә түгел, гомумән, әдәбиятка, халкыбыз мәдәниятенә файда китерүен аңлап эш итә. Ә язучылар арасында еллар буе китапханәгә кереп карамаганнары да бар. Әгәр алар үз китапларын еш кына «балалары» дип атыйлар икән, димәк, бу «балалар» ятим, караучысыз дигән сүз. Әйдәгез, бу мәсьәләгә башка кагылмыйча, китапны язуга да, язылгач, аның алга таба хәрәкәтен, ягъни укучыга барып җитүен оештыруга да иҗади караучы әдипләр хакында сөйләшик.
Киләсе елның апрелендә Бөтендөнья язучылар берләшмәсенең (Халыкара ПЕН-клубның) бер өлеше булган Татар ПЕН-үзәге оешуга 10 ел тула. 140 ил вәкилләрен берләштергән әлеге язучылар гаиләсенә безне Мексикада кабул иттеләр, ә ПЕН-үзәк үзе нәкъ менә Татарстан Милли китапханәсендә туды һәм шушында эшли. Дистә ел дәвамында Татар ПЕН-үзәге инглиз телендә дистәләрчә татар әдәбияты үрнәкләрен бастырып чыгарды (Г. Тукайның «Шүрәле»се, Р. Фәхретдиновның «Татар тарихы», «Татар халык әкиятләре» һ. б.), аларны Шотландиядә, Польшада, Финляндиядә, Англиядә, Македониядә, Мексикада, Норвегиядә узган Бөтендөнья язучылар конгрессларында таратты... Ә безнең китапханә үзәкләштерелгән тәртиптә ел саен әлеге китапларны дөньяның эре китапханәләренә, университетларына җибәрә. Үзебезнең республика да, әлбәттә, читтә калмый.
Милли китапханәгә 2005 елның 24 гыйнварында 140 ел тула. Аз вакыт түгел бу. Шушы вакыт эчендә китапханәчеләрнең ничәмә-ничә буыны алмашынган! Биналарыбызның бүлмә-заллары аша күпме укучы узган да, күпме китап сәхифәләре укылган!
Мин Татарстан Милли китапханәсендә эшләүче китап хадимнәрен, республиканың барлык китапханәчеләрен, язучыларны һәм китап укучыларны, гомумән, барлык китап сөючеләрне Олуг Китап Йортының юбилее белән чын күңелдән котлыйм. Уңышлар телим сезгә, дуслар!

*2005*

# ТАТАР КИТАБЫ... ҖИР АСТЫНА ЮЛ ТОТА

Гөнаһ шомлыгына каршы, акчаның беркайчан да җитми торган бик начар сыйфаты бар. Акча ул авыл укытучысына да, Абрамовичка да җитми, тик бу җитмәүнең масштаблары гына төрлерәк. Менә без бүген монда, нигездә, кемгә нәрсә җитмәве турында сөйләшергә, фикер алышырга дип җыелдык та инде.
Ике министрның да докладларын мин сәнгать әсәре тыңлагандай йотлыгып тыңладым. Бигрәк тә яңа икътисад министрыбыз докладын тыңлагач, тормышлар кинәт кенә яхшырып, дөньялар яктырып киткәндәй булды, күңелдә өмет чаткылары уянып, Такташ әйтмешли, офыкта коммунизм кыры күренгәндәй тоелды. Бирсен Ходай, дип, эчтән генә «бисмилла» да әйтеп куйдым.
Бүгенге көндә халык телендәге, халык бәгырендәге иң авырткан җир – эш хакы дисәм, моңа беркем дә каршы килмәстер. Россиядә минималь хезмәт хакын күтәрү турында карар кабул ителгәч, бу мәсьәлә тирәсендәге бәхәсләр тагын да ныграк кызып китте. Бүгенге көндә республиканың кайсы гына бюджет оешмасына барып керсәң дә, сүзне шуннан башлыйлар һәм шуның белән тәмамлыйлар. Дөрес, соңгы елларда илкүләм проектлар ярдәмендә һәм шулай ук республикабыз мөмкинлекләрен файдаланып мәгариф оешмаларында һәм кайбер башка өлкәләрдә бераз алга китеш булды. Мәдәният хезмәткәрләренә дә бер урында озак еллар эшләгән өчен өстәмә түләү мәсьәләсе хәл ителде. Әмма шушы уңай үзгәрешләрдән соң да республикабызда мәгариф хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 6 мең сум, мәдәният өлкәсендә 4,5 мең сум чамасы гына тәшкил итә. Бүгенге көндә мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлап эшкә килгән югары белемле хезмәткәргә нибары 2,5–3 мең сум чамасы хезмәт хакы түләнә. Мондый хезмәт хакына юньле тормыш кору түгел, җан асрау мөмкинлеге дә юклыгын аңлаган хезмәткәрләр гипермаркетларга, бизнес оешмаларына, банкларга, башка төшемлерәк урыннарга эшкә урнашуны кулайрак күрә. Әгәр киләчәктә бу мәсьәләдә үзгәрешләр булмаса, тагын берничә елдан бюджет оешмаларында кадрлар кытлыгы соңгы чиккә җитәчәк. Бигрәк тә республиканың иң зур мәдәни оешмалары авыр хәлдә калачак. Хөкүмәтебез Казандагы иң мәртәбәле театрларга һәм иҗат коллективларына, Архив идарәсенә өстәмә түләүләр билгеләп, бу мәсьәләне хәл итүдә беренче адымнарын ясады инде. Киләсе ел бюджетында Милли музейга, Милли китапханәгә, республикабызның яшүсмерләр, балалар һәм сукырлар китапханәләренә, башка шәһәрләрдәге театрларга да шундый ук өстәмәләр билгеләнү каралса, тагын бер адым алга китеш булыр иде. Бу урында әдәбият-сәнгать әһелләренең хезмәт хакын тәшкил итүче гонорар фондларының инде ничә еллар буе үзгәрешсез калуын да әйтми калу мөмкин түгел.
Безнең республикада театр һәм музыка сәнгате дә, рәсем һәм нәкыш сәнгатебез дә, әдәбиятыбыз да ил күләмендә алдынгылардан санала. Әмма, ни кызганыч, бөтен сәнгатьләр арасында иң үтемле саналган кино сәнгате бездә әле һаман балалык чорыннан чыга алмый тилмерә. Кино сәнгатен үстерү өчен бездә югары дәрәҗәдәге әдәбият та, артистлар һәм режиссёрлар, музыкантлар да бар. Әмма тиешле матди-техник база булдырмый һәм җитәрлек финанс бирелми торып, кино сәнгате нindидер әкияти тылсым белән генә барлыкка килмәячәк. Соңгы елларда Казан шәһәрендә оештырылган «Алтын мөнбәр» мөселман кинофестивале күңелебездә горурлык хисләре уяту белән бергә безнең алга яңа бурычлар да куйганын һич тә онытырга ярамый.
Безнең халкыбыз борын-борыннан мәгърифәтле, китаплы халык булган. Гасырлар буена дәүләтсез, республикасыз яшәгән вакытларда да безне юкка чыгудан, югалудан дин белән мәгърифәт саклап калгандыр. Безнең бүген дә, шагыйрь Хәсән Туфан әйтмешли, Татарстанлы чакта да югаласыбыз, юкка чыгасыбыз килми. Әмма бүген татар китабының, татар басмаларының һәм газета-журналларының нинди аянычлы хәлдә икәнлеге барыбызның да күз алдында. Аларның тиражлары көннән-көн кими бара, китап кибетләре берәм-берәм ябылып, китап тарату системасы әкренләп үзе дә таралып бетте, мәктәп китапханәләренә матур әдәбият бөтенләй диярлек сатып алынмый. Компьютер заманы килде дисәк тә, компьютер һәм интернет

системасында безнең урыныбыз әле бик-бик кечкенә. Бауман урамындагы тарихи Матбугат йорты ябылып, андагы нәшриятның һәм редакцияләрнең шәһәр читендәге тыкрыкларга күчерелүе дә халкыбызның рухи тормышына, әдәбиятка һәм мәдәниятктә карата булган дәүләти мөнәсәбәткә дәрәҗә өстәмәде. «Аптыраган үрдәк арты белән суга чума» дигәндәй, Татарстан китап нәшрияты үзенең кибетен Бауман урамындагы гипермаркетның подвалында ачарга мәҗбүр булды. Гасырлар буена халкыбызга рух биреп, аны яклап һәм саклап килгән татар китабының шулай әкренләп җир астына юл тотуы бик тә шөбһәле һәм символик мәгънәгә ия. Хәерлегә генә булсын инде...

Россия Президенты В. В. Путин үзенең быелгы юлламасында китап һәм китапханәләр хакында аерым басым ясап, тәфсилләп сөйләде. Үзебезнең Илбашыбыз М.Шәймиевнең әдәбият-сәнгатькә һәрчак хәерхаһ булуын барыбыз да күреп һәм сизеп торабыз. Шуларны истә тотып, икенче укылышка әзерләгәндә, татар китабына һәм республика матбугатына ярдәм йөзеннән бюджетка тиешле үзгәрешләр кертелсә, халкыбыз рәхмәтле булыр иде.

Депутатлар тәкъдиме һәм президентыбыз хуплавы белән без быелның гыйнвар аенда мәгариф өлкәсендәге оптимальләштерү мәсьәләсе хакында парламент тыңлаулары уздырган идек. Бу беренче чиратта мәгарифне җан башына исәпләп финанслауга бәйләнгән иде. Парламент тыңлауларында чыгыш ясаган депутатлар һәм белгечләр милли мәгарифнең киләчәк язмышы хакында бигрәк тә борчылып сөйләделәр. Нормативлар буенча бер сыйныфта авыл мәктәпләрендә – 14, шәһәр мәктәпләрендә 25 бала укыту каралган. Әмма барыбыз да белгән тарихи сәбәпләр аркасында, бигрәк тә милли мәктәпләрдә сыйныфларга бүгенге көндә бу кадәр бала җыю мөмкин түгел. Беренчедән, моңа демографик үзгәрешләр сәбәп булса, икенчедән, милли мәктәпләрнең юктан бар булып, әле яңа гына тернәкләнеп килүе дә зур роль уйный. Аннары шәһәрләрдә үткән гасырның 90 нчы елларында ачылган күпчелек милли мәктәпләрнең балалар бакчаларында һәм яраклаштырылган төрле биналарда урнашуы да ата-аналарның һәм балаларның ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Шуларны истә тотып, депутатлар милли мәктәпләр өчен махсус нормативлар кабул итүне сорап хөкүмәткә мөрәҗәгать юллаган иде. Ләкин шушы көнгә кадәр әлеге мәсьәләнең хәл ителгәне юк. Чөнки ул әлеге дә баягы бюджет акчасына бәйләнгән.

Татарстанның «Телләр турында»гы Законында ике дәүләт телен яхшы белгән һәм үз эшендә кулланган өчен хезмәткәрләргә 15 процентка кадәр өстәмә түләү каралган. Өстәмә түләүне билгеләү тәртибе хөкүмәт әзерләгән положение белән хәл ителергә тиеш. Әмма яңартылган Законны кабул итүебезгә өч ел вакыт узса да, бу положениенең әле һаман да эшләнеп беткәне һәм кабул ителгәне юк. Димәк, шул сәбәпле законның әлеге статьясы эшләми, «Телләр...» Законының нәтиҗәлелеге кими дигән сүз. Тел турындагы законыбыз телдә генә калмасын, ә тиешле финанс белән ныгытылып, дәүләт күләмендә чын-чынлап гамәлгә ашырылсын иде.

Соңгы еллардагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә урыннардагы мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре биналарын төзек һәм тиешле хәлдә тоту бурычы җирле хакимиятләргә йөкләнгән. Әмма, белгәнебезчә, җирле хакимиятләрнең финанс мөмкинлекләре бик чикләнгән. Шуның аркасында бүгенге көндә район һәм авыл мәктәпләренең, Мәдәният йортларының байтагы авария хәлендә яки төрле дәрәҗәдә төзекләндерүне таләп итә. Әнә шул максатлар өчен җирле хакимият органнарына киләсе елгы республика бюджетыннан тиешле күләмдә субвенцияләр бүлеп бирүне тормышка ашырырга кирәк.

Россиядә, шул исәптән бездә дә тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр һәм корылмаларны төзекләндереп саклау эше әле һаман тиешенчә хәл ителмәгән. Аларны дәүләтнеке булмаган оешмаларга биреп, шулар исәбенә төзекләндерү эше дә бер урыннан кузгалып китә алмый. Шуның өчен бу биналарны һәм корылмаларны, бигрәк тә аларның тарихи һәм мәдәни әһәмиятләре зур булганнарын, нигездә, дәүләт бюджеты исәбенә төзекләндерергә кирәк. «Мирас» программасына тәгаенләнгән 100 млн. сум акча белән генә бу проблеманы хәл итү һич тә мөмкин түгел. Киләсе ел бюджетында бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирелсен иде.

Безнең комитетка караган өлкәләр һәм оешмалар, нигездә, берсе дә бүген-иртәгә үк акча эшләүгә корылган даирәгә керми. Әмма, шуны сәбәп итеп, без аларга тиешле игътибар бирмәсәк, бүген

табыш китерә торган өлкәләрнең дә киләчәктә авыр хәлдә калулары көн кебек ачык. Әгәр без үзебезнең, республикабызның һәм халкыбызның киләчәге турында уйлыйбыз икән, димәк, беренче чиратта икътисадка этәргеч булган фәнгә һәм халыкны – халык, кешене кеше иткән мәгарифкә, мәдәнияткә һәм сәнгатькә игътибар арттырырга тиешбез. Шулай ук киләсе ел бюджеты проектында кайбер структураларга 60–80 процент үсеш билгеләп тә, фундаменталь фәнни эзләнүләр өлкәсендә мондый үсешнең нибары 0,03 процент кына каралуы һич кенә дә аңлашылмый. Мәгариф һәм мәдәният учреждениеләрен компьютерлар, ксерокслар һәм башка заманча җиһазлар белән тәэмин итү, янгынга каршы чаралар өчен дә бюджеттан һичшиксез өлеш чыгарылырга тиеш дип саныйбыз.

*2007*

# КИТАП КИШТӘЛӘРЕ ЧАКРЫМНАРГА СУЗЫЛГАН

Дөньяның бик күп илләрендә китап ярминкәләре үткәрелә. Аларның иң атаклысы – Германиянең Майндагы Франкфурт шәһәрендә оештырыла. Ә инде Шәрык дөньясы өчен иң күренеклесе – Каһирәдәге китап ярминкәсе. Быел ул анда кырык икенче тапкыр үткәрелде. Аңа дөньяның бөтен илләре дә чакырыла.

Без андагы әллә ничә чакрымга сузылган күргәзмәләрне күреп шаккаттык.

Быелгы Каһирә ярминкәсендә төп шәрәфле кунак Россия Федерациясе иде. Ә инде РФ делегациясендәге иң төп урынны Татарстан күргәзмәсе алып торды. Димәк, Татарстан Россияне күрсәтте дисәк тә, хакыйкатьтән ерак китмәбез. Гомумән, безгә аерым бер игътибар булды. Каһирә опера театрында Татарстаныбызның җыр һәм бию ансамбле бик зур концерт күрсәтте. Шыгрым тулы зал, аягүрә кул чабулар, «Афәрин!», «Браво!» – дип кычкырулар күңелебезгә шулхәтле хуш килде. Югыйсә чит илләргә чыгучы кайбер иҗат коллективлары, читкә без татар сәнгатен алып чыкмыйбыз, анда татар сәнгатен тыңламыйлар, карамыйлар, шуңа күрә Европа операларын алабыз, дип әйтәләр. Бу сүзләрнең хак түгеллегенә без тагын бер тапкыр ышанып кайттык. Татарны азмы-күпме булса да дөнья белә башлады инде. Каһирәдә бүгенге тормышыбыздан күпмедер хәбәрдар булсалар, зыялылар үткәнебезне шактый яхшы белә, кызыксына. Мәмлүкләр, һуннар чорын да, Муса Бигиевебезне дә беләләр анда. Гомумән, анда татарга хөрмәт, ихтирам хисен мин һәрдаим тоеп йөрдем.

Күргәзмәбез дә бик бай иде. Татар китабы башка илләрнең, башка халыкларның китабыннан һич кенә дә кайтыш түгел. Мин эчтәлеген генә түгел, тышкы ягын, бизәлешен, полиграфик эшләнешен күз алдында тотам. Полиграфия сәнгате ягыннан китапларыбыз дөньяның иң яхшы нәшриятларында дөнья күргән басмалар белән янәшә торырлык.

Инде күпме тираж белән басылуга килсәк, хәзер дөньяда китапны иң әүвәл аз гына санда, берничә йөз данәдә генә чыгарып карыйлар. Сынау тиражы була инде бу. Ул электрон вариантта сайтка куела да, кешеләр Интернет аша ул китапка заказ бирә. Күпме заказ җыелса, шулхәтле чыгаралар. Шунысы кызык: чит илләрдә тираж гадәттә күрсәтелми. Бездә әле китапның алдындамы, артындамы күпме данә чыкканы язып куела. Анда заказ җыелган саен, бастырып сатуга чыгаралар. Россия китаплары хәзер гадәттә 1–3 мең данә басыла. 10–15 мең данәдә басылучылар бик сирәк. Димәк, тиражлар төшү бер бездә генә түгел. Бу нәрсә, билгеле, безне куандырмый, әмма ләкин уйландыра.

Күргәзмә барышында, алты көн эчендә шактый «түгәрәк өстәл» оештырылды. Без шуларның алтысында катнаштык. Соңгы «түгәрәк өстәл» безнең татар әдәбиятына багышланды. Без анда «Таттрансгаз» оешмасы җитәкчесе Рифкать Кантюков ярдәмендә әле генә басылып чыккан Габдулла Тукай китабын тәкъдим иттек. Татарда әле мондый затлы китапның чыкканы юк иде. Каһирәдә без Тукайны үзәккә куеп, татар әдәбияты турында сөйләдек.

Ә инде Мәскәүдән, Петербургтан килгән урыс язучылары анда ике тапкыр А.Чеховка багышланган «түгәрәк өстәл» үткәрде. Чөнки быел Чеховның тууына 150 ел тула. Менә шул сөйләшүләрдә дөньяда иң күп укыла торган язучылардан Чехов, Достоевский, Толстой исемнәре аталды.

Күргәзмәдәге төп максатыбыз дөнья җәмәгатьчелегенә татар әдәбиятын, татар сәнгатен күрсәтү булды. Анда бит гадәттә галимнәр, белгечләр, дәүләт әһелләре килә. Дөньяның төрле илләреннән журналистлар җыела. Безнең делегация әгъзаларыннан бик күп интервью алдылар. Татарның китап сәнгатен дөньяга күрсәтү өчен бу бик үтемле чара. Моның башка юлы юк. Без бүген дөньяның бөтен илләрен Казанга болай җыя алмыйбыз. Әгәр шушындый мөмкинлек бар икән, киләчәктә дә аннан файдаланырга кирәк.

Ә инде китапны соратып алуга килгәндә, мин анда Мисырның Милли китапханә җитәкчеләре белән очрашып халыкара китап алмашу хакында – гарәп китапларын үзебезгә алдыру, Милли китапханәбездә булганнарын аларга җибәрү турында килештем. Киләчәктә рәсми килешү дә

булыр. Татарстан Милли китапханәсе моңарчы дөньяның бик күп илләре, аерым алганда, Америка конгрессы китапханәсе, Төркия, Германия, Кытай һәм башка илләр белән дә китап алмашты. Менә хәзер Мисыр белән дә шушындый халыкара китап алмашу эшен башлап җибәрергә уйлыйбыз.

Әйткәнемчә, анда искиткеч зур китап, кулъязма базары, гаять бай архивлар, китапханәләр бар. Әгәр берничә яшь галимебезне Каһирәгә җибәреп, шушы китап, кулъязма тауларында казыну, эзләнү мөмкинлеге тудырсак, һичшиксез, татар кулъязмалары да, татар тарихына кагылышлы кулъязмалар да, фәнни хезмәтләр дә табылыр.

Без анда Мисыр мәдәният министры киңәшчесе Ибраһим Әнвәр әфәнде белән киләчәктә Мисырда татар әдәбияты антологиясе чыгару һәм Казанда Мисыр әдәбияты антологиясе нәшер итү турында сөйләштек. Көзен Казанда Мисыр мәдәнияте көннәре үткәрү турында да килешенде. Бу хакта мәдәният министрыбыз Зилә Вәлиева алар белән килешүгә ирешкән булган икән. Инде аларның да фикерләрен, карарларын ишетеп кайттык. Киләчәктә антология беренче китабыбыз булса, аннан 125 еллыгына гарәп телендә Тукай әсәрләрен бастырып чыгару турында да килештек. Янә киләчәктә татар әдәбиятының борынгы чорыннан башлап бүгенгегә кадәр дөнья күргән күренекле әсәрләрен ел саен бер-ике китап итеп бастырып чыгару турында сөйләштек. Без моны алмашу тәртибендә эшләмәкче булабыз: алар үзләрендә безнең бер авторны чыгара икән, монда аларның бер авторы дөнья күрәчәк.

Халыклар күңеленә иң якын юл – әдәбият, сәнгать аша. Шуның өчен дә саубуллашу кичәсендә: «Сез, билгеле, татар кешесе хакында сугышлар тарихы аша беләсездер. Әмма тарих шактый катлаулы. Сугыш ул – илләрне, җирләрне басып алуга корылган. Әмма бүген безнең ниятебез яңа җирләр яулап алу түгел. Бүгенге максатыбыз – күңелләрне яулап алу. Кешеләрнең, халыкларның күңелен яулап алу аларның җирләрен, биләмәләрен яулап алуга караганда күпкә катлаулырак. Без шушы катлаулы эшне эшләр өчен сезгә килдек», – дип әйттем аларга.

*2010*

# МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ӨЧЕН ТАВЫШ БИРӘЧӘКМЕН

Хөрмәтле депутатлар, мин сезнең алда үз телемдә, татар телендә чыгыш ясарга җыенган идем. Ләкин мин хәзер барыгызның да, шул исәптән рус туганнарның да, рус телендә сөйләшүче татарларның да мине ишетүләрен һәм аңлауларын телим. Әгәр дә алар мине бүген рус телендә дә аңламасалар, ул чагында без бер-беребезне беркайчан да аңлый алмабыз дип куркам.
*(Текстның алдагы өлеше русчадан тәрҗемә итеп бирелә.)*
Минем белән барысы да килешерләр дип уйлыйм, Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе киләчәктә инде хәзергечә яши алмаячак. Ләкин гасырлар буена кешеләр аңына сеңдерелгән империячел фикерләү үзеннән-үзе генә бетми. Нәкъ менә шунлыктан бездә дә, башка милли республикаларда да Россияне һәм СССРны яңарту һәм деколонизацияләү процессының туктамавына ышаныч юк. Сәяси һәм экономик суверенитетка омтылу менә шуннан килеп чыга. Татарстанның РСФСР һәм СССР составында булуы бүгенге көнгә кадәр бернинди закон актлары һәм договорлар белән беркетелмәгән. Хәзер гаделлекне тергезер чак җитте.
Бу мәсьәләдә интеллигенциянең позициясе Татарстанның мөстәкыйльлеген яклап чыгучы сәяси көчләрнең күпчелеге позициясенә туры килә. Һәм бу позицияне республикада яшәүче барлык милләт кешеләре дә аңларга тиеш, чөнки аларның күпчелеге Татарстанда яшәргә уйлый һәм төп халыкка каршы көрәшергә җыенмый. Ә 150 миллионлы рус халкының һәм 7 миллионлы татар халкының көчләр нисбәте бездә азчылык дип аталган рус халкының хокуклары чикләнер дип шикләнергә урын калдырмый.
Шушы уңайдан ТАССР Югары Советы Президиумы тарафыннан расланган Декларация проекты турында берничә сүз әйтәсем килә. Аның хокукый асылын халык кыен аңлый, бу исә җәмгыятьнең билгеле бер өлешендә кискен реакция тудырды. Декларациянең беренче статьясы – Татарстанны Россия һәм СССР субъекты дип игълан иткән статья һәртөрле тәнкыйтьтән түбән. Киләчәктә безнең Югары Советка андый мөһим карарларны әзерләгәндә ашыгучанлык күрсәтмәскә кирәк булыр, аларны юридик яктан исбатларга кирәк. Татарстанның мөстәкыйльлеген мин аның төзелеше демократик булганда гына кыйммәтле дип саныйм. Шул ук вакытта безнең шартларда Татарстанның мөстәкыйльлегеннән башка җәмгыятебезне демократияләштерүгә өметләнү беркатлылык булыр иде. Миңа калса, мөстәкыйль дәүләтчелеккә баруның хәзерге этабында, беренче чиратта, Татарстан республикасының яңа Конституциясен эшләү турындагы мәсьәләне күтәрергә кирәк. Аны бөтенхалык тикшерүе, референдум аша кабул итәргә кирәк булачак. Сүз нәкъ менә Төп Законга карата референдум турында бара, ә дәүләт статусы мәсьәләсе буенча референдум турында түгел.
Депутатларның күпчелеге үзләренең сайлау алды программаларында Татарстанның союз статусы өчен көрәшергә ныклы ниятләре барлыгы турында белдерде. Димәк, халык, сайлаучылар, безне яклап тавыш бирүләре белән республикабызның суверенитеты өчен дә тавыш бирделәр. Россиянең, Украина, Белоруссия, Молдова һәм башка республикаларның статусы мәсьәләсе дә референдум юлы белән түгел, бездәгечә, Югары Совет сессияләрендә хәл ителде ич.
Референдум юлы белән кабул ителгән Төп Закон республика халкының ихтыярын башка дәүләтләрнең аны, халыкара хокук традицияләрен исәпкә алып, танымыйча булдыра алмаслык итеп чагылдырыр иде. Шуның белән бергә, мөстәкыйльлек алуның дәвамлы процесс булуын да онытырга ярамый. Бередә, юридик нигезләр белән беррәттән, экономик һәм социаль нигезләрне дә булдырырга кирәк, чөнки чын дәүләт мөстәкыйльлегенә ирешү тиешле сәяси актны күпчелек тавыш белән кабул итүгә генә кайтып калмый.
Әйе, халык әле безне консерватив Югары Совет дип саный. Ниһаять, бүген яңа сайланган парламент корпусы халыкка үзенең чын йөзен күрсәтер. Һәм без көчләр нисбәтен белербез, үзебезнең арада чын демократлар, интернационалистларның күпме икәнлеген, консерваторларның, торгынлык чорындагы аппаратчыларның күпме икәнлеген белербез. Үз

республикасының патриотлары һәм бөек державачылык шовинистлары, империячел фикерләү һәм сталинизм варисларының да күпме булуы ачыкланыр.
Мин бу сессиядә нәрсә өчен конкрет тавыш бирәчәкмен соң? Беренчесе – тулы суверенитет өчен. Икенчедән, мин исемләп тавыш бирү, аны матбугатта игълан итү ягында. Өченчедән, мин суверенитет һәм базар мөнәсәбәтләре шартларында яшәү өчен хөкүмәт программасын ашыгыч рәвештә төзүне яклап тавыш бирәчәкмен. Әгәр безнең хөкүмәтнең мөстәкыйль экономик политикасын эшләү юлларын күрмәве ачыкланса, ул отставкага китәргә тиеш була.
Кайбер иптәшләр, безнең Татарстанда суверен республиканы идарә итәргә сәләтле кешеләр юк, диләр. Әйе, моңарчы бездә сәләтле лидерлар күренмәде, чөнки безгә ирек бирелмәде. Республиканың суверен мөстәкыйльлеге булмады, шуңа күрә, лидерларга да ихтыяҗ булмады. Суверен республика булса, бездә менә дигән җитәкчеләр килеп чыгачак.
Үзен хөрмәт иткән теләсә кайсы халык ирекка һәм тигезлеккә омтылырга тиеш, бу – дөньяда бөтен тереклек иясенең табигый теләге. Ә башка халыкларның законлы хокукларын танырга теләмәү – элементар цивилизациялелекнең булмавы, халыкара хокукны санга сукмау һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетү турында гына сөйли ул.

*27 август, 1990*

# МӘДӘНИЯТКӘ – ӨЧ ТИЕН

Безнең җәмгыятебез бик каты чирле. Әхлаксызлык көчәюдән алып экономиканың бозылуына кадәр бөтен бәлаләребезнең төп сәбәбе – мәдәниятсезлегебездә. Әгәр кешелекнең мәдәни тәҗрибәсе тормышта исәпкә алынса, минем инануымча, без мондый мөшкел хәлгә төшмәгән булыр идек.

Халык арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, узган ел кешеләрнең 80 процентын товар һәм хезмәт күрсәтү бәяләренең күтәрелүе, 84 процентын азык-төлек белән начар тәэмин итү, 42 процентын торак шартларының начарлыгы аеруча борчыды. Шул ук вакытта җавап бирүчеләрнең 8 процентын гына мәктәпләрдә укытуның торышы, 5 процентын гына мәдәният учреждениеләренең җитмәве, 8 процентын кирәкле китапларны алу мөмкинлеге булмау, 18 процентын гына җәмгыятьтә әхлак һәм әдәпнең торышы борчый булып чыкты.

Бу – кешеләрдә мәдәниятkә һәм гыйлем эстәүгә ихтыяҗ юк дигән сүз түгелме? Кешеләр хәерчелектән тәмам гарык. Без халыкның хайван хәленә калуына, бар белгәне ашау-эчү дә йокы гына булуына һич тә юл куймаска тиешбез. Экономикада туган хәлләрнең колы булу – халыкның интеллектуаль халәте бозылуга булышу ул. Белем һәм мәдәният дәрәҗәсе буенча без инде болай да дөньяда 28 нче урында торабыз.

Мәдәниятнең зарурлыгын бар кеше дә аңлый кебек, тик аның социаль яклау, азык-төлек яки сәламәтлек саклау шикелле үк мөһим икәнлегенә әлегә төшенеп җитмиләр. Үзгәртеп кору башланган 1985 елдан 1990 елга кадәр илдә мәдәният ихтыяҗларына бюджеттан акча бирү 1,6 процентттан 1,2 процентка төште. Бу, әлбәттә, безнең бөтен мәдәни сәясәтебезнең җимерелүен күрсәтә. Мәдәният хезмәткәрләре күптән түгел Бөтенсоюз күләмендә үткәргән биш минутлык «забастовканы» без үлеп бара торган, ә кай җирләрдә инде бөтенләй тыны киселгән мәдәниятебезне кызганып, биш минут тын тору дип кабул иттек.

Бер кешегә исәпләгәндә, быел республикада мәдәнияткә 11 сум 60 тиен тотылачак, ягъни суверен Татарстан Республикасында яшәүчегә көненә чама белән 3 тиен туры килә. Ә менә аракы, бишектәге сабыйларны да һәм хәлсез карт-корыларны да кертеп исәпләгәндә, 1989 елда җан башына 60 тиенлек, ягъни 20 тапкыр күбрәк сатылган.

Ә 1991 елда эш ничегрәк торачак соң? Бюджет проектында мәдәният тармагына 93,9 миллион сум бирү (шул исәптән капитал төзелеш 6 миллион сум) каралган. Бер кешегә бюджет (капитал төзелешне исәпкә алмаганда) 18 сум 19 тиен акча тотуны күздә тота. Ә нормативның минималь күләме – 21 сум 30 тиен. Димәк, бюджетта шушы күләмнән чыгып исәпләгәндә дә 6,5 миллион сум акча кимрәк каралган. Мәдәният хезмәткәрләренең эш хакын республика күләмендәге уртача эш хакы дәрәҗәсенә күтәрү өчен безгә өстәмә рәвештә 9,3 миллион сум кирәк.

Мәдәнияткә акча бүлү мәсьәләсендә тагын бер сәер нәрсә бар. Республиканың мәдәният комплексына бирелгән хәерче акчаларның да байтак өлеше киредән бюджетка кайтарыла. Әмма халык хуҗалыгының башка тармакларыннан аермалы буларак, рәсми отчетларда ни өчендер чыгымнар гына күрсәтелә. Керемнәр турында ләм-мим, алар бөтенләй юк кебек килеп чыга. Мәсәлән, наширлек эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган табышның яртысыннан күбрәге бюджетка керә, бу төп тармаклар китергәннән күпкә артык. Концерт оешмалары табышларның 60 процентын бюджетка бирәләр. Минем ышануымча, бездәге иң куәтле промышленность гигантлары арасында да шундый пропорциядә салым түләүчеләр бик аздыр. Шуңа әллә кайчан кертелгән тамашалар оештыру налогын өстәгез. Ул шәһәрләрдә кинотеатрлар җыемының 55 процентын, авыл җирләрендә – 10 процентын тәшкил итә.

Бүгенгә кадәр бюджет капчыгының тишекләрен мәдәният исәбенә ямау тенденциясе дәвам итә. Реаль шартларны исәпкә алмыйча, матди-техник ресурслар белән тәэмин итми торып, түләүле хезмәт күрсәтү планы ел саен 15–20 процентка арттырыла. Аны теләсә нинди юллар белән алалар. Сыйфат түбәнәя, ул хезмәтнең кайберләренең мәдәният белән һичбер уртаклыгы юк. Түләүсез хезмәт күрсәтүне түләүле белән алыштыру балалар һәм үсмерләр, инвалидлар,

пенсионерлар, күп балалы гаиләләр һәм халыкның аз тәэмин ителгән башка төркемнәре мәнфәгатьләренә суга.

Республика районнарына һәм шәһәрләренә, шулай ук республика учреждениеләренә мәдәният буенча чыгымнар күләмен киләсе елга ТССР Финанс министрлыгы билгеләгән. Планда эш хакы фонды җитәрлек каралмаган. Бишенче статья буенча исә «Китаплар алуга, укыту һәм фәнни чыгымнарга» акча 1990 елга караганда 20 процент күбрәк билгеләнгән. Ә газета-журналлар – 2–3, китаплар 3–10 тапкыр кыйммәтләнә бит. Димәк, киләсе елда республика китапханәләре күп кенә газет һәм журналлардан баш тартырга мәҗбүр булачаклар, иң әйбәт китаплар китапханә киштәләренә килеп җитмәячәк.

Республиканың суверенлык алуына бәйле рәвештә уңай үзгәрешләргә өметебез бар. Инде бюджетны Мәскәүдәге «агайлар» түгел, бәлки үзебезнең депутатларыбыз бүләчәк. Монда, әлбәттә, күп нәрсә хөрмәтле депутатларыбызның мәдәнилегенә бәйле.

Мин заманында тулы булмаган урта мәктәптә укыган идем. Директорыбыз, шук кеше буларак, сәер сораулар бирергә ярата иде. Бервакыт ул безгә «директор, без высшего образования неполной средней школы» дигән тәгъбирне татар теленә тәрҗемә итәргә кушты. Бик озак азаплады ул, ләкин безнең тәрҗемәдән канәгать булмады. Аннары үзенең авыр балалык еллары, сугыш турында, отставкага чыккан җиде класс белемле старшинаны тулы булмаган урта мәктәп директоры итеп билгеләүләре турында сөйләде. «Ни чын белемем, ни тиешле тәрбиям һәм мәдәниятем юк, ә менә мәктәп директоры булып эшлим», – диде ул, көрсенеп. Аннары болай дип өстәде: «Директор без высшего образования неполной средней школы», безнеңчә, татарча әйткәндә, «тулыр-тулмас урта мәктәпнең булыр-булмас директоры» була инде». Бу гыйбрәтле хәлне нигә сөйләде икән дип аптырамагыз. Безнең сайлаучылар арасыннан да шундый шук кешеләр табылып, мәдәнияткә дигән акчаны кисеп утыруыбызны күргәч, «народный депутат суверенной Республики Татарстан» дигән гыйбарәне «булыр-булмас мөстәкыйль республиканың тулыр-тулмас депутаты» дип татарчага тәрҗемә итүеннән куркам мин.

Республика суверенлыгын тәэмин итү өчен без ел саен Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия бюджетларына күчерелгән өч миллиард сум акчабызны Татарстан бюджетына кайтарып бирүне катгый таләп итәргә тиешбез. Мәдәниятне финанслау өчен реаль чыганак менә шул, ул төзелеш, хезмәт күрсәтү сферасы яки азык промышленносте авызыннан тартып алуны сорамый. Ләкин Союз һәм Россия җитәкчелеге белән сөйләшүләр күрсәткәнчә, Татарстанга үз байлыгын бирәү дә кире бирергә җыенмый. Димәк, алдагы елларда да мәдәният мәсьәләләре монда түгел, ә анда хәл ителәчәк.

Хәзер мәдәният хезмәткәрләренең бөтен өмете бездә – халык депутатларында, республика Югары Советында һәм ТССР Министрлар Советында. Әгәр без мөстәкыйль булырга ниятләгәнбез икән, аңа нык торып, зыялы кешеләрчә ирешергә тиешбез.

*1990*

# ТЕЛСЕЗ ХАЛЫК – САНСЫЗ ХАЛЫК

Телләр хакындагы мәсьәләне, дөресрәге, канун проектын тикшергәндә сүземне Тукай шигыре белән башламасам, гөнаһ булыр сыман.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Соңгы елларда, империяләр җимерелеп, аларның дәүләт гимннары онытылып барган чорда, мөстәкыйль дәүләте дә, мөстәкыйль гербы да, байрагы да, гимны да, мөстәкыйль Конституциясе дә булмаган халыкның беркемнән дә сорамыйча, үз ихтыяры белән Габдулла Тукайның менә шушы изге шигырь-җыруын гимнга әверелдерүе бик күп нәрсә турында сөйли. «Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы» ди Тукай. Әйе, туган телебез аркасында, аның аркылы без әлегә татар халкын, аның әдәбиятын һәм мәдәниятен күпмедер дәрәҗәдә саклап кала алдык. Әмма ләкин соңгы дүрт гасырда, бигрәк тә соңгы җиде дистә ел эчендә туган телебез үзе дә безнең аркада бик күп нәрсә күрде. Заманында патшалар теле булып, халыклар арасында аралашу өчен дипломатик даирәләрдә кулланылышта йөргән татар теле, дәүләт теле статусына гына түгел, хәтта халыкара статуска ия булган тел, бүгенге көндә парламентлардан һәм дәүләт идарәсе органнарыннан, уку йортларыннан һәм фәнни оешмалардан, завод-фабрикалардан һәм почта-телеграфтан, гомумән, дәүләт тормышыннан куып чыгарылып, «Асрамага бала бирәм, кем ала?» дип, ятим Тукайны сатып йөргән базарларда һәм кайбер иманлы авылларда гына сакланып калды. Бүгенге көндә татар балаларының бары тик җиде проценты гына үз ана телләрендә белем алуы проблеманың никадәр җитди булуы хакында бик ачык сөйли.

Бүген тикшерелә торган Закон проекты «Татарстан халыклары телләре турында» дип аталса да, сүземне татар теленнән башлавым өчен залда утыручы депутатлар да, сайлаучыларыбыз да мине гаепләмәсләр дип уйлыйм. Бүген һәммә халыкның үз телен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыруны таләп итәргә хакы бар. Чөнки телсез халык, чын мәгънәсендә халык була алмый, аның культурасы да, әдәбияты да, гореф-гадәтләре, йолалары да туган тел яшәгән вакытта гына яши. Ә инде бәйсез, суверен дәүләт төзибез дип җан атып йөреп тә шул ук вакытта минем туган телем аяк астына салып таптала икән, ул күзгә күренеп үлеп бара икән, ул чакта инде миңа бернинди бәйсезлекнең дә, суверенитетның да кирәге юк. Үз туган телен дә яклап һәм саклап кала алмаган халык беркайчан да үзенең Дәүләт суверенитетын яклап зур эшләр майтара алмаячак.

Татар теле генә түгел, безнең республикада бүгенге көндә рус теленнән башка һәммә телләр дә бик каты авыру, хаста хәлендә. Чуваш һәм мари, удмурт һәм мордва, украин һәм яһүд телләре дә дәүләт яклавына мохтаҗ. Шуңа күрә Закон проектының 10 нчы статьясында «Татарстан Республикасы гражданнарына туган телен һәм Татарстанның башка халыклары телләрен өйрәнү һәм укыту өчен шартларны дәүләт тәэмин итә» дип язылган, һәм бу инде безнең республикада татар һәм рус телләренә генә түгел, ә барлык телләргә дә тиешле игътибар һәм шартлар тудырылачагына гарантия бирә.

Үз халкыннан аерылмаган, үзен шул халыкның баласы дип санаган һәркем өчен туган тел – иң якын һәм иң изге тел. Инде әйткәнемчә, бу татарларга һәм русларга гына түгел, һәммә халыкларга да кагыла. Ләкин әлеге Закон проектында татар теленә аерым игътибар ителергә, аның яшәве өчен аерым шартлар тудырырга кирәклеге беркемдә дә шик уятырга тиеш түгел. Татар халкы – без яшәгән республикага исем биргән халык, татар халкы, димәк, үзенең телен һәм дәүләтчелеген бүгенге көндә бары тик шушы җирдә – Татарстанда гына саклап кала һәм ныгыта ала. Ә башка халыкларның мондый мөмкинлекләре шулай ук үз халыклары исем биргән республикаларда һәм дәүләтләрдә тормышка ашырыла. «Телләр турында»гы Закон проектын яклап даими комиссияләрдә һәм радио-телевидение аша халык каршында чыгышлар ясасам да, мин шәхсән үзем аннан йөз процентка канәгать түгел. Бүгенге көндә рус теле белән татар телен тигез хокуклы

дип игълан итү демократия ягыннан караганда бик дөрес булса да, татар теленең һәм рус теленең бүгенге хәлләрен һәм җәмгыятьтә тоткан урыннарын искә төшергәндә, бу ике телгә бертигез шартлар тудыру татар теленең тиз арада дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алуына шик калдыра. Инде бетеп, югалып барган, авыру әби хәлендәге татар телен әзмәвер ирдәй рус белән бер мәйданга чыгарып, «менә сез икегез дә тигез хокуклы, көрәшегез» дип әйтүне мин демократия белән дә, кеше хокукларын яклау белән дә берничек тә аңлата алмыйм. Авыру кешегә, хаста адәмгә һәр дәүләттә, һәр халыкта, һәр гаиләдә аерым шартлар тудырыла: аңа ризыкның да тәмлерәге, урынның да йомшаграгы бирелә. Шулай итмәсәң, аның терелүе икеле. Бүгенге көндә татар теле дә хаста хәлендә, әгәр без аңа аерым игътибар биреп, аерым шартлар тудырмасак, дәүләт теле дип игълан итеп кенә аны үлемнән саклап кала алмаячакбыз.
Законда һәммә нәрсәне дә тәфсилләп язып булмый, «Телләр турында»гы Канун кабул ителгәч, хөкүмәт тарафыннан аны гамәлгә кертү һәм тормышка ашыру программасы төзелергә тиеш. Кайбер бер телле депутатлар әлеге Законны гамәлгә кертү, татар телен өйрәтү бик кыйммәткә төшәчәк, дип, әле тумаган балага бүген ук кабер казырга маташалар. Үзләренә «демократ» кушаматы тагып та, башка халыкларның, үзләре белән янәшә яшәгән һәм эшләгән кешеләрнең телләрен һәм хокукларын өч тиенгә дә санамаган бу депутатларны мин халык мәнфәгатьләрен яклаучы, республика халыклары дус һәм тыныч яшәсен дип кайгыртучы парламентарийлар дип атый алмыйм. Безнең бер депутатыбыз «татар телен аякка бастыру, аны өйрәнү өчен ун миллиард сум акча кирәк» дип, минем туган телемне, дәүләт телен өйрәнмәү һәм өйрәтмәс өчен халык арасында коткы салып йөргәндә, ул үзен депутат итеп сайлаган татар яисә чуваш сайлаучыларының милли горурлыклары, рухи ихтыяҗлары турында уйлап карадымы икән, алар белән бу турыда киңәштеме икән?! Кеше никадәр генә каты бәгырьле булса да, бу бик кыйммәткә төшәчәк бит дип, үлем түшәгендә яткан авыруга дару сатып алырга акчасын кызганмас, киресенчә, ул соңгы тиенен тотып булса да үзенең туганын яисә дустын үлем тырнагыннан коткарып калырга тырышачак. Без беребез дә моңа кадәр һәм бүгенге көндә республикада рус телен өйрәнүгә тоткан миллиардларны санамадык, ә инде татар теле һәм башка халыкларның телләре турында сүз кузгалгач, тиеннәрне санарга тотындык. «Телләр турында»гы Закон проекты юристлар экспертизасын гына түгел, ә мораль яктан да экспертиза аша үтәргә, бу законны һәммәбез дә үз күңелебез, үз вөҗданыбыз аша үткәрергә тиешбез. Әгәр инде без үзебезне «демократ» дип атаганбыз икән, ул демократиянең җирән сакалдан башка атрибутларын да үстерик.
1990 елның 30 августында татар һәм рус телләрен дәүләт теле дип игълан иткәннән соң, ике елга якын вакыт узды. Димәк, бу Закон инде моннан ким дигәндә ел ярым элек кабул ителергә тиеш иде. Закон проекты дистәләгән иләк аша узып, ниһаять, бүгенге сессиянең көн тәртибенә кертелде. Төп проект белән бергә сезгә тагын башка вариантлар да таратылды. Һәр вариантта да игътибарга алырлык статьялар бар. Әмма ләкин мин һич тә икеләнмичә төп вариантны – Татарстан Югары Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе тәкъдим иткән вариантны кабул итәргә кирәк дип саныйм. Бу сессиядә нигездә кабул иткәннән соң, ул проект яңадан комиссиягә кайтарылып, киләсе сессиягә сезнең тәкъдимнәр белән тулыландырылып яңадан көн тәртибенә кертелер һәм тулаем кабул ителер дип уйлыйм.
Ике ел элек Татарстанның Дәүләт суверенитеты турындагы декларациядә без бертавыштан татар һәм рус телләрен дәүләт теле дип игълан иткәнбез икән, бүген инде берәүнең дә моңа ревизия ясап утырырга хакы юк. Декларация бары тик декларация генә булып калмасын өчен реаль эшләр эшләргә күптән вакыт җиткәндер. «Телләр турында»гы Закон кабул итү әлеге декларацияне һәм референдум нәтиҗәләрен тормышка ашыруда безнең алга таба бер адым атлавыбыз булыр.
Мин үземнең чыгышымны Тукай сүзләре белән башлап җибәргән идем. Туган тел үз милләтен хөрмәт иткән һәркемгә дә: французга да, инглизгә дә, украинга да, руска да, чувашка да, башкортка да, татарга да кадерле һәм якын. Ә кадерле әйберне күз карасы кебек сакларга һәм якларга кирәк. Тукай сүзләре белән башланган чыгышымны мин атаклы авар шагыйре Рәсүл Гамзатовның һәммәбезгә дә билгеле шигъри юллары белән тәмамлыйм:

Кого-то исцеляет от болезней
Другой язык, но мне на нём не петь,
И если завтра мой язык исчезнет,
То я готов сегодня умереть.

*1992*

# СӨЙЛӘНМИ КАЛГАН НОТЫК

*Соңгы арада белгәне дә, белмәгәне дә депутатларны пассивлыкта гаепләп, аларның тетмәләрен тетәргә ияләшеп киттеләр. Үземне артык «пассивлар», сессиядә йокымсырап утыручылар рәтенә кертмәсәм дә, мин бүгенге парламенттагы эшемнән тулысынча канәгать түгел. Дөрес, сайлаучыларга парламент эшенең бары тик телевизордан күрсәтелгән өлеше генә билгеле. Ә Югары Советның төп эше даими комиссияләрдә, сайлаучылар наказларын, гозерләрен үтәүдә, закон проектлары эшләүдә чагыла... Кызганычка каршы, сайлаучылар боларның берсе турында да хәбәрдар түгел.*

*Әле иң кызганычы шунда ки: төн йокыларын калдырып, йөзләгән материаллар өйрәнеп чыгышка әзерләнгәннән соң да еш кына сиңа сессиядә сүз бирмиләр. Ике ел ярым буена минем дистәгә якын шундый чыгышым җыелды инде. Сессияләрдә генә түгел, «кирәкмәс сүз сөйләр» дип, ахрысы, соңгы арада гына миңа, кат-кат мөрәҗәгать итүемә дә карамастан, Татарстан халыклары корылтаенда (23 май, 1992 ел), Бөтендөнья татар конгрессында (19 июнь, 1992 ел) сүз бирмәделәр. Демократик дәүләт төзибез дип лаф орып та, халык депутатының авызын томалап, сүз әйттермәскә тырышуны аңлый да, сайлаучыларыма аңлата да алмыйм. Шунысы гаҗәп: Татарстанның бәйсезлегенә аяк терәп каршы торучы, Россия империясе мәнфәгатьләрен кайгыртучы депутатларыбыз сүз ирегеннән рәхәтләнеп файдаланалар, алар өчен микрофон һәрвакыт ачык.*

*Язучы кеше буларак, мин киләчәктә бу сөйләттерми калган чыгышларымны бер китап итеп чыгарырмын дип өметләнәм. Хәзер сезнең игътибарыгызга шуларның берсен – Бөтендөнья татар конгрессында сөйләнмәгән, дөресрәге, сөйләтелмәгән нотыгымны тәкъдим итәм... Югыйсә анда калыпка сыймаган бер сүз дә юк иде...*

Бүген безнең йортта олуг бәйрәм.

Бүген үзенең күңелендә милли хис һәм иман нуры йөрткән һәммә татар кешесе өчен олуг тантана. Бүген Җир шарының Татарстанлы ягында көннең иң озын мәле, бүген Җир кояшының Татарстанда иң биеккә – көн үзәгенә җиткән чагы.

Татарның бәйрәмнәре күп түгел: Корбан бәйрәме, Рамазан, Нәүрүз, Сабантуй һәм башкалар... Соңгы җитмеш елда без менә шушы санаулы бәйрәмнәребездән дә колак кага яздык, хәтта Сабантуйны да башка халыклардан качып-посып кына үткәргән чакларыбыз булды. Ә бүгенге бәйрәм – татар халкының милли конгрессы – мин белгән тарихта беренче мәртәбә үткәрелә. Әйе, без бу көнне, бу бәйрәмне, кимсетелү һәм хаксыз хурлауларга теш кысып түзә-түзә, гаҗәеп озын дүрт гасыр буе көттек. Бүгенге бәйрәм ул – күңел вә рух тантанасы, бүгенге бәйрәм ул – яхшылыкның һәм гаделлекнең яманлыкны җиңеп өскә чыга баруы, бүгенге бәйрәм ул – халкыбызның «бәйсезлек», «хөррият» дип аталган олы юлга чыгар алдыннан бер тукталып тын алуы, бергә җыелып уйлануы.

Без бүген монда кемнедер җиңүебез өчен куанырга, тантана итәргә җыйналмадык. Без бүген монда татар халкының дөнья халыклары арасында үзенә лаеклы урын дәгъвалавына, Татарстанның дөньядагы бәйсез дәүләтләр янәшәсенә басарга омтылуына фатиха бирү өчен килдек. Без бүген биредә үзебезгә, халкыбызга һәм җөмһүриятебезгә яңа куәт туплау өчен кулай юллар эзләргә, шул хакта фикер алышырга, максатлар ачыкларга дип җыйналдык. Ә безнең бер-беребез белән сөйләшәсе сүзләребез бик күп, бу залда утырган һәр кешенең милләттәшләренә һәм газиз халкына әйтер сүзе бар. Милләтне милләт итәр өчен иң элек уртак рух һәм уртак иман, уртак тел һәм уртак мәдәният, уртак хыял һәм уртак максат кирәк. Ә бүгенгесе көндә безнең максатыбыз да, иманыбыз да, рухи кыйблабыз да бер, ул да булса бәйсез, мөстәкыйль, суверен дәүләт – Татарстан җөмһүрияте төзү. Чөнки дәүләтсез халык беркайчан да дөнья мәйданында бил алышырлык көчле-гайрәтле халык була алмый, чөнки дәүләтсез милләтнең күңеле ятим баланыкы сыман китек, рухы сүрән, киләчәге томанлы була. Татар халкын, татар милләтен саклап

калу, аны дөньяга чыгару өчен бүген безгә иң әүвәл Татарстанны саклап калырга, аңа үзебездән куәт бирергә, аны бөтен дөньяга күрсәтергә кирәк.
Ләкин моңа ничек ирешергә соң? Без монда берничә мең татар җыелышып, матур сүзләр сөйләүдән генә татар милләте тәрәккый итәрме, дөнья безнең авазны ишетерме, башка илләр безне танырмы? Әтәч кычкырганга карап беркайда да таң атмый, ә, киресенчә, әтәч таң атканга куанып кычкыра. Шуңа күрә, без монда еллар буена җыелып килгән хис-тойгыларыбызны бераз тыя төшеп, дөньяви эшләр һәм мәшәкатьләр хакында, алда торган бурычларны ничек бергәләп чишү, хәл итү турында нигезле, төпле сүз алып барсак, чын мәгънәсендә яхшы һәм файдалы эшләр майтара алыр идек.
Татар халкы – гаҗәеп моңлы, хисле, сагышлы халык. Әйдәгез, бүген гасырлар буе җыелып килгән хәсрәт-кайгыларны беразга онытыйк та, аска иелгән башларыбызны югары күтәреп, тураеп басыйк, үзебезнең горур, мәгърур, булдыклы һәм каһарман халык балалары икәнебезне искә төшерик! Елап һәм сыкрап, зарланып һәм офтанып, кемгәдер яисә нәрсәгәдер үч саклап яшәгән кеше беркайчан да олы шәхес була алмый. Чөнки елаган һәм зарланган кешене хөрмәт итмиләр, яратмыйлар, ә бәлки кызганалар гына. Бүген үткәннәргә үч саклаудан да мәгънә юк. Дөнья халыклары танысын, дөнья халыклары үз итсен өчен безгә бүген үчле булырга түгел, көчле булырга кирәк!
Әле күптән түгел Татарстан Президенты Минтимер әфәнде Шәймиевнең чит республикаларда һәм мәмләкәтләрдә вәкиллекләр ачу турында фәрманы чыкты. Ләкин бу бик вакытлы һәм кирәкле фәрманны тормышка ашыру җиңел булмаячак, аның юлына төрле киртәләр корылуы да бик ихтимал. Ә тарих безгә дүрт йөз кырык елдан соң үз авазыбызны дөньяга ишеттерү өчен шундый форсат биргән икән, моннан файдаланмый калырга һич кенә дә хакыбыз юк! Рәсми дипломатия өлгермәгән, җитешмәгән җирдә безгә халык дипломатиясен эшкә җигәргә кирәк. Әлегә рәсми илчелекләребез булмаса да, бүген дөньяның дистәләгән илләрендә күпсанлы һәм куәтле татар диаспоралары бар. Бу корылтайда шушы диаспора идарәләренә татар халкының һәм Татарстанның рәсми булмаган илчелекләре – вәкаләтле вәкиллекләре статусы биреп, аларга татар халкының һәм Татарстанның мәнфәгатьләрен яклау бурычын йөкләсәк, без дөнья илләренә тиз арада Татарстанның тавышын ишеттерә, позициясен ныгыта алыр идек. Кыскасы, безгә күктән бәхет төшкәнен, кемнеңдер «бәйсезлек» бүләк иткәнен көтеп ятмаска, бүген үк, хәзер үк булган бөтен мөмкинлекләребездән файдаланырга кирәк. Җир шарының теләсә кайсы төбәгендә, теләсә кайсы илдә яшәгән татар кешесе үзен татар халкының һәм Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиле, илчесе итеп тоярга, аның мәнфәгатьләрен яклап көрәшергә тиеш.
Без – бу залда утыручы һәммәбез дә, төрле төбәкләрдә яшәүче башка милләттәшләребез дә – бер-беребезгә охшаган да, охшамаган да, без бер-беребезне аңлыйбыз да, ә кайчакта аңлап та бетермибез. Әйе, татар халкы бик күптөрле. Менә шушы күптөрлелектән файдаланып, бер бөек татар халкыннан дистәләгән вак милләтләр ясарга дәртләнеп йөрүчеләр дә булуы ихтимал. Дөньяда бүленә һәм бүленми торган нәрсәләр бар. Милләт шуларның бүленми торганнарына керә. Юкка гына татарда «аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» дип әйтми торганнардыр инде. Бүгенге көндә татар халкын төрле вак халыкларга бүлү – милләт өчен үлемгә тиң. Шуңа күрә халкыбызның күптөрле булуын без аның искиткеч зур байлыгы дип кабул итәргә, төрле төбәкләрдә гомер сөрүче халкыбызның аерымлыкларын түгел, ә һәммәбезне дә бөек милләт янына берләштерүче уртак хисләрен, уртак моңнарын, уртак йолаларын, уртак бәйрәмнәрен эзләп табарга, ишәйтергә һәм үстерергә тиешбез.
Мин үземнең бу чыгышымны балачакта хәтергә уелып калган бер вакыйганы сөйләп тәмамламакчы булам...
Авылда минем бик тә диндар әбием бар иде. Шулай беркөнне әбием, гадәттәгечә, намазлык өстендә дога укып утырганда, тәсбихнең җебе өзелеп, төймәләре идәнгә чәчелде. Мин йөгереп килеп әбигә тәсбих төймәләрен җыярга булыша башладым. Туксан тугыз төймәле тәсбихнең туксан сигез төймәсен табып, әби белән яңадан җепкә тезеп куйдык. Ләкин күпме эзләсәк тә, идән ярыгына төшкән туксан тугызынчы төймә табылмады. Бу көнне әби кичкә кадәр кулына тәсбих алмады. Мондый хәлне күрмәгәнгә, мин аннан: «Әби, нигә тәсбих тартып дога укымыйсың?» –

дип сорадым. Әби авыр итеп көрсенеп куйды да болай диде: «И-и, улым, син берни дә аңламыйсың шул әле, туксан тугыз төймәле тәсбихемнең бер төймәсе җитми, ә мондый тәсбих белән дога укысам, минем догам дөрес булмый...»

Менә бүген сезнең каршыгызга чыгар алдыннан мин нигәдер әбиемнең шушы сүзләрен искә төшердем.

Бөтендөнья татар корылтаена бүген дөньяның туксан тугыз төбәгеннән милләттәшләребез килгән. Бу туксан тугыз төбәктә туксан тугыз холыклы, туксан тугыз кыяфәтле, туксан тугыз фикерле ватандашларыбыз яши. Үзебез туксан тугыз төрле булсак та, безнең теләгебез һәм максатыбыз бер – татар халкын югары мәдәниятле, хөрриятле, тулы хокуклы милләт итү, Татарстанны дөнья мәйданына чыгару. Туксан тугыз төбәктә яшәүче милләттәшләребезнең берсен генә онытырга да бүген безнең хакыбыз юк! Чөнки дөньяның төрле төбәкләрендә яшәүче туксан тугыз төрле татар халкы – бер җепкә тезелгән туксан тугыз тәсбих төймәсе кебек. Шул төймәнең берсен генә югалтсак, бер генә татар төбәген онытсак та, бүген безнең уртак иманыбызга хилафлык килер, безнең һәммәбез өчен уртак, изге догабыз дөрес булмас, аны Аллаһы Тәгалә кабул кылмас.

*1992*

# КАЛГАН ЭШКӘ КАР ЯВА

Кем ничектер, мин үземне иң беренче чиратта кеше дип саныйм, аннары татар милләтенең бер вәкиле, аннары Татарстан Җөмһүрияте гражданы дип исәплим. Менә мин шушы өч кит – кеше, милләт һәм гражданлык китлары өстендә басып торам. Минем хатыным бармы-юкмы, мин солдатка яраклымы-юкмы – анысы икенче мәсьәлә, шулай ук кайда пропискада торуым, нинди фатирда яшәвем дә ул кадәр үк мөһим түгел. Иң мөһиме, инде әйткәнемчә, кеше булу, милләтеңә тугры булу, аның лаеклы гражданы булу. Әмма ләкин ике башлы козгын сурәте төшкән паспортта безнең кайда яшәвебезне, каныбызның ничәнче группа булуын, солдатка яраклымы-юкмы икәнлегебезне, хатын белән тору-тормавыбызны язачаклар, ә кайсы милләт баласы булуыбызны теркәмәячәкләр. Димәк, мине Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән хокукымнан – татар милләте вәкиле булудан, шул хакта рәсми төстә теркәлүдән мәхрүм итәчәкләр. Бүгенге көндә милләтләр өчен, халыклар өчен моннан да зуррак җинаятьнең булуы мөмкин түгел. Үткән кече сессиядә мин инде бу хакта шактый иркенләп, тәфсилләп сөйләдем, ул сүзләрне хәзер кабатлап торасым килми. Әмма мине һаман шул бер сорау борчый: «Кемгә кирәк булды икән бу мәсьәләне кузгату?» Безнең татарда «кычытмаган җирне кашу» дигән әйтем бар. Яңа паспорт мәсьәләсе дә шуңа охшаган. Хәзерге паспортларыбызда барысы да үз урынында, барысы да күрсәтелгән иде. Һәм менә тоттылар да, «авырткан башка тимер тарак» дигәндәй, шушы проблеманы тартып чыгардылар. Безнең Конституциябездә акка кара белән язылган: «Татарстан кешеләре ике гражданлыкка ия» диелгән. Әгәр дә Конституциябездә теркәлгән ике гражданлык ике суверен дәүләтнең суверен паспортларында чагылмый, аларда ике телле инкяр ителә икән, без халкыбызның бөтен ышаныч-өметен аяк астына салып таптыйбыз, үткән чакырылыштагы Югары Совет кабул иткән Төп Законыбызны сызып ташлыйбыз, Дәүләт суверенлыгы турындагы декларациябездән, референдум нәтиҗәләреннән баш тартабыз дигән сүз.

1990 елның 30 августында әлеге Декларацияне кабул иткәндә, Президентыбыз, ул вакыттагы Югары Совет Президиумы рәисе М. Ш. Шәймиев болай дип әйткән иде: «Дәүләтчелегебезне торгызуның ике олы максаты бар. Аның беренчесе – халыкның тормыш шартларын яхшырту, аны мул тормышта яшәтү, икенчесе милләтебезгә рухи яңарыш тәэмин итү».

Әгәр инде безгә биреләчәк паспортларда милләт инкяр ителгәч, милләт булмагач, билгеле, милли мәсьәлә дә, милли яңарыш, рухи яңарыш та булмаячак. Милләт булмагач, аның «дәүләт теле» дип игълан ителгән теле дә, милли мәдәнияте дә, милли мәгарифе дә әкренләп сүнеп-югалып бетәчәк.

Соңгы арада милләтсез һәм туган телсез паспорт турындагы шомлы уйлар көнен дә, төнен дә баштан чыкмый. Әгәр дә без шушы паспортны алабыз икән, әгәр дә без моның белән ризалашабыз икән, без үз-үзебез белән, үзебезнең намусыбыз, вөҗданыбыз белән гомерлек бәхәскә керәчәкбез. Әгәр без, депутатлар, моңа юл куйсак, үзебезгә һәм милләтебезгә хыянәт иткән кешеләр булачакбыз. Чөнки без монда, парламент әгъзалары булу белән бергә, һәммәбез дә кайсыдыр бер милләтнең вәкилләре дә бит әле.

Урыс милләте үзе дә бүген бетү, югалу тарафына юл тота. Ныклап уйласаң, бу авантюра, бу провокация татарга, башкортка, чувашка, марига гына түгел, ә бәлки иң беренче чиратта урысның үзенә үк каршы эшләнгәндер дә әле? Шушы милләт исемен йөрткән дәүләтне, федерацияне таркату өчен эшләнгәндер? Юк, татарга гына каршы кылынган гамәл түгел бу, татар монда икенче чиратта... Шуңа күрә урыс иптәшләр, «бу безгә кагылмый» дип, тыныч кына утырмасыннар иде.

Вкладыш яисә өстәмә бит турында сөйләп торасым да килми, аның «филькина грамота», «кәҗә паспорты» икәнлеге һәммәбезгә дә ачык. Җитмәсә, хәтта шушы «вкладыш» дип аталган законсыз кәгазь кисәге бары тик Татарстанда яшәгән татарларга гына биреләчәк, имеш, ә читтә – Оренбургта һәм Чиләбедә, Әстерханда һәм Пермьда, башка җирләрдә яшәгән татарлар бу «кәҗә билетыннан» да мәхрүм калачаклар.

Моннан биш ел элек, I Бөтендөнья татар конгрессы алдыннан, оештыру комитеты кайсы илдә күпме татар яшәвен ачыклау өчен төрле тарафларга хатлар юллаган иде. Франциядән җавап килде: «Бездә милләт исәбе юк», – дигәннәр. Англиядән, Алманиядән, тагын бик күп илләрдән шундый ук җаваплар алынды. Ул вакыттагы премьер-министр М. Г. Сабиров җитәкчелегендәге оештыру комитеты, күпме тырышса да, кайсы илдә күпме милләттәшебез яшәвен конгресс делегатларына ирештерә алмады, һәм әле бүген дә без дөньяда күпме татар булуын анык кына әйтә алмыйбыз. Ә үзенең исәбен-санын да белмәгән халыкны сансыз халык, димәк, мәгънәсез, сантый халык дип атарга да буладыр. Әйе, Франциядә милли мәсьәлә, бәлки, юктыр да, чөнки анда, нигездә, французлар гына яши, калганнары – килеп-китеп йөрүчеләр. Алманиядә – алманнар, Англиядә – инглизләр, Төркиядә төрекләр генә яшәгәч, анда милләтне документта теркәү, язу, бәлки, хаҗәт тә түгелдер. Ә Россия Федерациясе һәм безнең Татарстаныбыз – күпмилләтле дәүләтләр. Шуңа күрә дә бу проблема бездә бар һәм киләчәктә дә булачак.

Көтмәгәндә-уйламаганда башыбызга ишелеп төшкән бу проблема, бу афәт искиткеч катлаулы, бу – милләт күләмендәге, дәүләт күләмендәге конституцион мәсьәлә. Россиянең яңа паспортында безнең өчен иң мөһиме – дәүләтчелекнең нигез ташы булган гражданлык гарантиясе төшеп калган, анда безгә үзебезне «Татарстан гражданы» дип язарга мөмкинлек калмаган, анда минем туган телемә, дәүләт телебезгә урын табылмаган. Димәк, без яисә бу сәмруг кошлы паспортны кабул итмәскә, яисә, дәүләтчелегебездән һәм тоткан кыйблабыздан ваз кичеп, Конституциябезгә үзгәреш кертергә, Россиянең яңа паспортында каралганча, «Татарстан кешеләре бер генә гражданлыкка – Россия гражданлыгына ия» дип язарга тиеш булабыз. Билгеле, бу залда утырган депутатларның һәм Татарстан мәнфәгатен яклаган ватандашларыбызның берсе дә андый юлга басмаячак дип уйлыйм.

Бу хәлдән ничек чыгарга, кемнәрдер тарафыннан уйлап табылган мәкерле «паспорт проблемасын» ничек чишәргә соң? Бу хакта уйламаган кеше безнең республикада гына түгел, хәтта бөтен Рәсәйнең үзендә дә бик сирәктер бүген. Ләкин әлеге сорауларның һәммәсенә дә җавапны Казан урамнарыннан яисә Мәскәү коридорларыннан түгел, ә үзебезнең Конституциябездән, әле генә 5 яшен тутырган, заманында халыкара экспертларның югары бәясен алган беренче мөстәкыйль Конституциябездән эзләргә кирәк.

Татарстан Конституциясенең 19 нчы маддәсендә «Татарстан Республикасының үз гражданлыгы бар» дип язылган. Гражданлыгы бар икән, димәк, аны дәлилләүче документы – паспорты да булырга тиеш. Аның тышлыгында парламент кабул иткән барс сурәте ясалсын, эчендә һәркемнең милләте күрсәтелсен, текстлар ике дәүләт телендә язылсын.

Бары тик Татарстан паспорты йөрткән кешеләр генә Татарстан гражданы саналсын һәм бары тик шул паспорт ияләре генә Татарстанда сайлау һәм сайлану хокукына ия булсын. Бары тик Татарстан гражданнары гына Татарстандагы байлыкларга дәгъва кыла алсын, бары тик аларга гына Татарстандагы социаль льготалардан файдалану хокукы бирелсен. Шушы хокукларны парламентта закон белән беркетеп, барлык халыкка җиткергәч, Татарстан паспортының ни дәрәҗәдә югары абруйга ия булачагына минем шигем юк.

Конституциянең шул ук 19 нчы маддәсендә «Татарстан гражданнары Россия гражданлыгына ия» дигән сүзләр дә бар. Димәк, теләгән кеше Россия паспортын да ала ала. Бу бигрәк тә Россиягә эше төшкән, Татарстаннан читкә йөргән кешеләргә кирәк булачак. Әмма ул паспортның тышлыгында Рәсәйдә яшәүче төрле дин тоткан төрле милләт вәкилләренең берсен дә кимсетмәгән, рәнҗетмәгән законлы дәүләт гербы торсын. Эчендә милләт күрсәтелсен, совет паспортындагы кебек, текстлар ике телдә дә язылсын. Ул паспортта милли республикалар өчен аерым бит кертүне мин антиконституцион гамәл дип саныйм. Чөнки Татарстан Конституциясенең шул ук 19 нчы маддәсендә «Һәр кеше гражданлыкны сайларга һәм аны үзгәртергә хокуклы. Гражданлыктан яки гражданлыкны үзгәртү хокукыннан мәхрүм итү тыела» дип, акка кара белән язылган. Әгәр дә минем әби, мәсәлән, бары тик Татарстан гражданы гына булырга теләсә, берьюлы ике гражданлыкны күрсәткән Рәсәй паспорты аны бу хокукыннан мәхрүм итәчәк, димәк, ул паспортның үзенә кирәксез битләрен ертырга тиеш булачак. Бары тик Россия гражданы гына

булырга теләгән кешегә дә шулай ук көчләп Татарстан гражданлыгы тагылачак. Бу инде турыдан-туры Конституцияне бозу, кеше хокукларын инкяр итү дигән сүз.

Бездә «татарның акылы төштән соң» дигән әйтем бар. Без инде менә биш ел буена Гражданлык турында закон кабул итүне таләп итә тордык, әмма максатыбызга ирешә алмадык. Инде менә төш вакыты, эш вакыты узгач, Рәсәй безне кәкре каенга китереп терәгәч, башны кашырга тотындык. Инде бүген дә ярты-йорты карар кабул итеп, тынычланып аерылышсак, без һәммәбез дә үзебезнең вкладышыбызны тотып калачакбыз. Минем тәкъдимем шул: Татарстан гражданлыгы турындагы Закон кабул иткәнгә кадәр Татарстан җирендә Россиянең яңа паспортларын бирми торырга. Аз-маз үзгәртелгән Рәсәй паспортына риза булып, Татарстан паспорты эшләүне киләчәккә калдырсак, Татарстанның беркайчан да үз паспорты булмаячагына минем иманым камил. «Калган эшкә кар ява» дип юкка гына әйтмиләр бит бездә. Кулыбыздагы СССР паспортлары әле 2005 елга кадәр гамәлдә булачак, димәк, без паспортсыз тормыйбыз. Татарстан гражданлыгы турындагы Закон проектын киләсе пленар сессиягә әзерләп тапшырырга. Ул Законда Рәсәйдә һәм башка илләрдә яшәүче татарларның Татарстан гражданлыгын алу мөмкинлеген дә күздә тотарга.

Минем бу тәкъдимнәрем тулысынча Татарстан Конституциясенә тәңгәл килә һәм шуңа күрә закон сагында торучы депутатларыбыз да, Татарстан Конституциясе үтәлешенең гаранты булган президентыбыз да бу сүзләргә колак салырлар дигән өметтә калам.

*1992*

# СУГЫШКА КОМАНДИРОВКА

1995 елның 11–14 гыйнвар көннәрендә Татарстан Республикасының рәсми делегациясе Чечен Республикасында һәм Ингушетиядә булды. Анда бару өчен безгә Татарстан президенты һәм хөкүмәте АН-26 махсус йөк самолёты бирде. Үзебез белән медикаментлар, дарулар, балалар өчен туклану әйберләре һәм 4 тонналап ашамлык – барлыгы 60 миллион сумлык кирәк-ярак алып бардык. Шул ук самолётта Кызыл Хач һәм Ярым ай вәкиле, язмыш һәм хәрби түрәләрнең кушуы буенча уллары Чечен Республикасына килеп эләккән ике ата-ана да очты. Егетләрнең берсен дудаевлылар әсир итеп алганнар, һәм ул айдан артык инде Грозныйда Президент сарае бункерында утыра.

11 гыйнварда Минеральные Воды шәһәре аэропортында безнең делегацияне Ингушетиянең сәламәтлек саклау һәм социаль яклау министры Йосыф Тимерханов, республика шифаханәсенең баш табибы Магомед Арапиев каршы алды. Аннары гуманитар ярдәмне, ике йөк машинасына төяп, Ингушетия Республикасы башкаласы Назрань шәһәренә илттек һәм сәламәтлек саклау министры җаваплылыгына тапшырдык. Моңарчы башка республикалардан һәм илләрдән гуманитар ярдәм гадәттә Моздокка китерелгән булган, һәм ул тиешле кешеләргә, ягъни качакларга, яралыларга, зыян күрүчеләргә еш кына барып та җитмәгән. Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре безгә Чечнядагы һәм Ингушетиядәге яралы кешеләр өчен билгеләнгән медикаментларның Моздокта урланып, югалып бетү фактлары турында сөйләделәр. Ә без алып килгән әйберләр икенче көнне үк инде Кызыл Хач колоннасы белән бергә Чечняга – яралылар һәм зыян күрүчеләр тотыла торган районнарга озатылды.

12 гыйнварда безнең делегацияне Ингушетия вице-президенты, отставкадагы генерал-лейтенант Борис Николаевич Агапов кабул итте. Ул Чечен низагы зонасындагы хәл турында сөйләде, кеше хокукларының, беренче чиратта кешенең яшәүгә булган хокукын бозуларның конкрет фактларын китерде, бу мәгънәсез, кешелексез, үтә дә аяусыз сугышны фаҗигале нәтиҗәләргә китерә ала торган «куркыныч ялгышлык» дип атады. «Минем карашымча, бу ялгышлыкны яки явызлыкны бер генә нәрсә белән аңлатып була: безнең дәүләт җитәкчелеге бербөтенлек проблемасын бары тик территория ягыннан аңлый, күрәсең. Ә чынлыкта башка нәрсәнең бөтенлеге – милләтләрнең бөтенлеге турында кайгыртырга кирәк иде бит», – диде Б. Агапов.

Гәрчә Россиянең рәсми массакүләм мәгълүмат чаралары һәм федераль хакимият һәр көнне һавадан бомба ударына тотуларның булмавы турында ант итсәләр дә, чынбарлык бу сүзләрнең ялган булуын күрсәтә. Сугышның чын картинасын без үз күзләребез белән күреп кайттык. Чечен һәм Ингушетия республикалары күгендә тәүлек буе бомбардировщиклар, хәрби самолётлар оча, тыныч авылларны һәм торак пунктларны бомбага тоталар. Грозный ягына таба тәүлек буена танклар, БТРлар һәм башка сугыш техникасы агыла. 48 сәгатьлек килешү игълан ителүгә карамастан, безнең күз алдында Грозныйны һәм аның бистәләрен бомбага тотуны дәвам иттеләр.

Әңгәмә азагында Ингушетия вице-президенты, рус генералы бик тирән уйланып болай диде: «Моңа ышануы да мөмкин түгел, ә шунысы хак: Россиягә чечен халкы түгел, ә Чечен Республикасының территориясе кирәк. Аның нефте, башка файдалы казылмалары, таулары, җире кирәк. Әмма бу җирдә яшәүче кешеләр кирәк түгел...»

Ингушетия Президенты сараенда очрашканнан соң без вокзалда һәм тимер юл вагоннарында ничек кирәк алай урнашкан качаклар лагеренда булдык. Чечен качаклары безгә игълан ителмәгән җинаятьчел сугыш башланганнан бирле бер ай дәвамында үзләре кичергән дәһшәтле хәлләрне сөйләделәр. Аларның күп кенә туганнары, танышлары һәм якыннары бомбага тотулардан һәм артиллериядән атулардан һәлак булганнар, ә могҗиза белән генә исән калганнары Грозныйдан һәм башка торак пунктлардан китү ягын караганнар.

Аларның кием-салымы да, ашамлыклары да, медикаментлары да юк. 200 мең халкы булган Ингушетия Республикасы үзендә тагын Төньяк Осетиянең Пригородный районыннан куылган 78 мең ингушны һәм рәсми төстә теркәлгән 50 меңнән артык чечен качагын сыендырган.

Шифаханәләр авырулар һәм яралылар белән тулы, дарулар җитми, хәтта гади генә бәйләү материалы һәм шприцлар да юк. Куркыныч эпидемия башланып китүе дә ихтимал.
Гуманитар ярдәмне тапшырудан һәм чечен кризисы тирәсендәге хәлне ачыклаудан тыш, республика җитәкчелеге безнең алга Татарстаннан чакырылган һәм хәзерге вакытта Чечен җирендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр турында мәгълүмат җыю бурычын да йөкләде. Казанда чакта ук инде без президент, Югары Совет Рәисе, һәм премьер-министр адресына, башка дәүләт органнарына һәм җәмәгать оешмаларына килгән барлык хатларны һәм мөрәҗәгатьләрне өйрәндек. Татарстаннан чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең гаскәри частьлары номерларын һәм кайда урнашуларын ачыкладык. Назраньга килеп җитүгә, хәрби хезмәткәрләрнең бу исемлеген без вице-президент Б. Н. Агаповка, Халык җыены (парламент) рәисенең беренче урынбасары М. А. Гулиевка, Ингушетия Республикасы һәм Россия Федерациясе җитәкчелегенә, Гадәттән тыш хәлләр министрлыкларына, Ингушетия сәламәтлек саклау министрына, атаклы хокук саклаучы С. А. Ковалев группасына тапшырдык. Россия Дәүләт Думасы депутатлары А. А. Осовцов, М. М. Молоствов, В. В. Борщов, Ю. А. Рыбаков әсирлектә һәм госпитальләрдә ятучы якташларыбыз турында мәгълүматлар җыюда безгә зур ярдәм күрсәттеләр. Аларның ярдәме белән без хәзерге вакытта Грозный подвалларында һәм бомбадан качу урыннарында ятучы әсир солдатлар һәм офицерлар исемлеген ала алдык. Аннары «Мемориал» җәмгыяте активистлары аша әсир хәрби хезмәткәрләр турында башка мәгълүматларны да ачыкладык. 94 хәрби әсир исемлегендә 13 татар фамилиясе бар. Татарстаннан чакырылган ике хәрби хезмәткәр турында тулы мәгълүмат алдык. Мәсәлән, Чаллы шәһәреннән рядовой А. А. Осовицкий һәм Теләче районыннан рядовой Р. З. Якупов хәзерге вакытта дудаевлылар кулында әсирлектә тотыла. Без бункерда Рәдиф Якуповны үз күзләре белән күргән һәм аның белән сөйләшкән кешеләр белән дә очраштык. Рәдифнең әтисе безнең белән иде, ул да бу кешеләр белән сөйләшә алды.
Безнең делегациянең һәм Ингушетия вице-президенты Б. Н. Агаповның рәсми мөрәҗәгать итүенә карамастан, федераль хакимият җитәкчеләре безнең белән элемтәгә керүдән баш тарттылар, ә Россия армиясенең хәрби начальниклары безнең иминлекне тәэмин итү мөмкин түгеллекне әйттеләр, шунлыктан безне Моздокка җибәрмәделәр. Фронт сызыгында булган чакта, 12 гыйнварда Россия армиясе офицерлары безнең белән элемтәгә керергә ашыкмадылар, сорауларга җавап бирүдән тайчандылар, солдатларның хезмәт итү шартлары турында дөрес булмаган мәгълүматлар бирделәр. Мин хәрби техниканың һәм хәрби хезмәткәрләр төркеменең Грозныйга таба хәрәкәт итүен видеотасмага төшерә башлагач, әгәр бу эшне дәвам итсәгез, бернинди кисәтүсез ут ачачакбыз, дип кисәттеләр. Без солдатларның ни өчен әти-әниләренә хат язмаулары турында да кызыксындык. Командирлар моңа кыска гына: «Язасылары килми», – дип җавап бирделәр. Ә соңыннан, солдатлар белән аерым әңгәмә вакытында, командирларның хат язуны тыюлары ачыкланды.
13 гыйнварда фронт сызыгында без Ингушетиянең гадәттән тыш хәлләр буенча министрлыгы җитәкчелеге һәм Россия министрлыгы вәкиле белән очраштык. Озак үгетләүләребездән соң һәм ата-аналарның ачы күз яшьләрен күреп, безне Грозныйга гадәттән тыш хәлләр буенча министрлык хезмәткәре озата барырга булды. Кайчандыр ул Җ. Дудаев аппаратында хезмәт иткән, шунлыктан боевикларның кайда урнашуын һәм безнең хәрби хезмәткәрләр ята торган подвалларны яхшы белә. Җирле кеше буларак, ул мине һәм Татарстан хөкүмәте вәкиле М. Җиһаншинны Россия солдатлары саклый торган төп юлдан түгел, ә үзе белгән авыл юллары буйлап алып барды. Урыс-Мартан торак пунктыннан ерак та түгел Дудаев ополченецлары чолганышына килеп эләктек. Гаҗәп, дудаевлылар ачык йөзле һәм аралашучан булып чыктылар. Безнең гуманитар миссия белән Татарстаннан килүебезне белгәч, алар бик тиз арада куркыныч ополченецлардан шәфкатьле хуҗаларга әверелделәр. Миңа видеокамерага төшерергә дә рөхсәт иттеләр. Әсирлеккә эләккән Татарстан хәрбиләрен беренче мөмкинлек булуга ук безнең вәкил кулына тапшырырга вәгъдә бирделәр.
Ингушетия җитәкчелеге һәм гади кешеләр белән – чеченнар һәм ингушлар, руслар һәм әрмәннәр, кабардиннар һәм балкарлар белән очрашулар вакытында без Татарстан турында бик күп мактау

сүзләре ишеттек. Алар хәзерге шартларда үз мөстәкыйльлегебезне ныгыту буенча республика җитәкчелеге үткәрә торган сәясәтне дөрес дип саныйлар.

Юлда безгә менә айдан артык инде Грозный урамнарында меңләгән мәетнең аунап ятуын сөйләделәр. Болар, нигездә, Россия солдатлары, ә дудаевлылар үзләренекен төнлә җирлиләр икән. Кыргыйланып беткән этләр солдатлар һәм офицерларның үле гәүдәләрен кимерәләр. Соңгы вакытта алар, ач бүреләрдәй, тере кешеләргә дә ташлана башлаганнар.

Шаһитларның сөйләвенчә, тыныч халык арасыннан инде 20 меңгә якын кеше һәм Россиянең берничә мең солдаты һәлак булган. Грозный ут эчендә, шәһәрнең үзәге нигезенә кадәр тар-мар ителгән. Әмма Грозный һаман да бирешми.

Митингларда һәм урамнарда халык федераль җитәкчелеккә, бигрәк тә Егоров, Грачев, Ельцин һәм Степашинга ләгънәт укый, халыкның бер өлеше Дудаевны да тәнкыйтьли.

Чеченнар һәм руслар, солдатлар һәм тыныч халык бездән әлеге канлы суешны башлап җибәргән кешеләрне тагын һәм тагын бер тапкыр акылга чакырырга, күп газаплар күргән бу җирдә тынычлык урнаштыруда ярдәм итүебезне сорап мөрәҗәгать иттеләр. Татарстан Республикасының, аның җитәкчеләренең абруен белгән һәм ихтирам иткән хәлдә, алар безнең аша сезгә, парламентарийларга, халык депутатларына һәм җөмһүриятебезнең барлык кешеләренә мөрәҗәгать иттеләр.

Инде соң булса да, бүген кан коелуны туктатырга мөмкин әле. Моның өчен республикаларга, халыкларга берләшергә, бу дәһшәтле рәхимсез көчкә куәтле киртә куярга кирәк. Югары Совет Президиумы, Президентыбыз, Югары Совет Рәисе, җәмәгать оешмалары инде күп тапкырлар сугыш хәрәкәтләрен туктату һәм сөйләшүләр өстәле янына утыру таләбе белән мөрәҗәгать иттеләр. Әмма, кызганыч, безнең тавышны ишетмәделәр. Димәк, үз улларыбызның гомерен саклап калу хакына, киләчәгебез хакына без бүген тагын да катырак итеп кычкырырга һәм бөтен көчкә чаң кагарга тиешбез.

*1995*

# МӘДӘНИЯТ ЯЗМЫШЫ КЕМНӘР КУЛЫНДА?

Депутатларның иң актив, иң шау-шулы чагы, гадәттә, бюджет кабул иткәндә була. Ул сессиядә һәркем кулыннан һәм теленнән килгән кадәр үз өлешен дәгъвалый, таләп итә һәм кайберәүләр сирәк-мирәк кенә булса да максатларына да ирешә. Әмма бюджет үтәлешен тикшергәндә, шул ук кешеләр нигәдер башларын аска иеп тып-тын гына утыралар. Нишлисең, вакыт узган, акча тузган – хәзер сүз куертудан ни мәгънә?

Бюджеттан акчаның иң азын кемгә бирәләр? Кемгә булсын, әлеге дә баягы мәдәнияткә, фәнгә, мәгарифкә, сәламәтлек саклауга, яшьләр белән эшләүгә... Ләкин бу әле мәдәнияткә, мәгарифкә һәм фәнгә килгән афәтнең башы гына. Бюджетта карала торган өлешнең елдан-ел кими баруы өстенә, соралган финансның чиреге дә бирелмәве янына тагын бер олы каза – кабул ителгән бюджетның нәкъ менә әлеге дә баягы мәдәният, мәгариф һәм фәнгә дигән өлешенең нибарысы яртылаш кына үтәлүе килеп өстәлә. Мәсәлән, узган ел бюджетында халык хуҗалыгына каралган өлеш – 70 процентка, дәүләт органнарын финанслау 93 процентка үтәлгән булса, мәгарифкә нибарысы – 39, мәдәнияткә – 69, сәламәтлек саклауга – 54, яшьләргә – 34, «Телләр турында»гы Законны тормышка ашыруга тәгаенләнгән акчаның 54 проценты гына иясенә барып җиткән.

Бюджетны кабул иткән алдагы сессиядә мин «мәдәнияткә акчаны 1 сумга кимрәк бирсәк, киләчәктә хокук саклау органнарына 10 сум артыграк бирергә мәҗбүр булачакбыз» дигән идем. Кызганычка каршы, нәкъ әйткәнчә килеп чыккан, 1994 ел бюджетында мәдәнияткә 31 процент акча биреп бетерелмәгән булса, милициягә 35 процент артыграк бирелгән. Мине берүк дөрес аңлый күрегез: җинаятьчелеккә каршы көрәшергә, хокук саклау органнарын җитәрлек дәрәҗәдә финанслауга мин һич кенә дә каршы түгел. Әмма җинаятьчелекне бетерүнең бердәнбер чарасы импортный күсәк сатып алу яисә яңа төрмәләр төзү генә дип уйлау да дөрес түгел. Культурасыз, мәдәниятсез җәмгыятьнең беркайчан да җинаятьчелектән башы чыкмасына иманым камил.

Ә республикада культураның хәле көннән-көн мөшкелләнә бара... Театрларыбызның күбесе ярым җимерек хәлдә, аларны ремонтларга акча юк. Г.Камал исемендәге Академия театрының әле һаман производство биналары җиткерелмәгән. Быел республикабызның баш китапханәсе – Татарстан Милли китапханәсенә 130 ел тула. Һәм быел без шушы юбилей белән бергә тагын бер күңелсез датаны – китапханәгә яңа бина төзү турындагы беренче хөкүмәт карары чыгуның 30 еллыгын да билгеләп үтәчәкбез. Ул тарихи карардан соң инде хөкүмәтнең һәм Югары Советның китапханә бинасы төзүне тизләтү турында алты (!) карары чыкты, әмма ләкин бүгенге көнгә кадәр төзелешнең башланганы юк һәм кайчан башланасы да билгеле түгел.

Соңгы өч елда гына республикада 134 клуб, 70 китапханә ябылды. Бүгенге көндә 40 китапханә һәм 87 клуб авария хәлендә, 155 китапханәгә һәм 571 клубка капиталь ремонт ясарга кирәк. 14 районда халыкка китапханә хезмәте күрсәтү өчен библиобуслар юк. Әгәр дә эшләр болай барса, авылларда бердәнбер мәдәният учагы булган күп кенә китапханәләр үзләреннән-үзләре юкка чыгачаклар. Мәсәлән, узган 1994 елда атаклы Сарман, Теләче районнарындагы китапханәләргә берданә дә китап алынмады. Ютазы, Кама Тамагы, Менделеев, Яңа Чишмә, Теләче районы авылларындагы китапханәләр нибарысы берәр, икешәр газетага гына языла алдылар.

Штатлар кыскартуны да республикада һәм районнарда иң элек культурадан башлыйлар. Андый кыскартулар буенча Арча, Спас, Мөслим, Актаныш, Питрәч, Биектау районнары аеруча активлык күрсәтәләр. Мәсәлән, Спас районындагы 27 авыл китапханәсенең һәммәсендә дә җыештыручылар, ә 14 мәдәният йортында сәнгать җитәкчеләре кыскартылган, 21 кочегар урыны юкка чыгарылган. Ягылмаган, җыештырылмаган мәдәният йортының чын мәгънәсендә культура учагы булуына мин һич тә ышана алмыйм. Ә кыскарту ягыннан Актаныш районы республикада рекорд куйды. Район Советы президиумы карары белән үткән елны анда барлыгы 75 мәдәният хезмәткәре, шул исәптән 26 сәнгать җитәкчесе, методист һәм рәссам, 28 китапханәче һәм 15 техник хезмәткәр кыскартылды. Әлки районында культурага каршы көрәш шундый ук кызу

темплар белән алып барыла. Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакын халык хуҗалыгындагы уртача хезмәт хакы белән тигезләү турында карарлар чыкса да, хәл бу өлкәдә дә һаман начарая гына бара. Мәсәлән, 1994 елда культура хезмәткәрләре аена уртача 113710 сум, димәк, халык хуҗалыгында эшләүчеләрнең 79,5 проценты дәрәҗәсендә хезмәт хакы алган булсалар, быелгысы елда бу тагы да кимеде һәм ул нибары 71,3 процент тәшкил итә.
Болай да әлле-мәлле хәлдәге мәдәниятебезнең бөтен республика күләмендә көннән-көн ныграк кыерсытыла баруы хакында тагын бик күп саннар китерә, сәгатьләр буе сөйли алыр идем.
Мин финанс министрының «культурага акча юк» дигән сүзләренә тамчы да ышанмыйм. «Елый белеп еласаң, сукыр күздән яшь чыга» дигәндәй, күңел биреп эзләсәң, культурага да акча табып була икән. Әнә бит, бюджетта каралмаган булса да, Мәскәүдә үткәрелгән триумфаль мәдәният көннәре өчен миллиардлар табылды. Дистәләгән миллиардларны авызыбыздан өзеп, Җиңү паркы да салып куйдык. Дөрес, үзебез кабул иткән Законны үзебез үк бозып, нишләптер аның капкасына бары тик бер дәүләт телендә «Парк Победы» дип кенә яздык. Нәрсә, бу «бөек җиңүгә татарның һәм татар теленең катнашы юк» дип, тагын бер кат татар сугышчыларының исенә төшерү булдымы, әллә болай, гадәт буенча гына эшләндеме, әмма факт факт булып кала...
Гомумән, «Телләр турында»гы Закон, ярлы гаиләдә теләмичә тапкан артык бала кебек, дөньяга килгән көненнән үк кыерсытылуга дучар булды. Беренчедән, Законны һәм Дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча көндәлек эшне башкаручы дәүләт органы төзелмәве, икенчедән, Законны дәүләт органнарының үзләре үк санга сукмаулары, турыдан-туры бозулары, хәтта бюджетта каралган хәерче акчасының да нәкъ менә шул әлле-мәлле хәлдәге туган телебезне торгызуга каралган өлеше яртылаш кына үтәлүе – безнең бу гаҗәп катлаулы проблемага мөнәсәбәтебезне бик ачык күрсәтә. Олы юл буендагы күрсәткеч язуларына, авыл-сала, инеш-елга, колхоз-совхоз исемнәренә, аларның ничек язылышына, шәһәрләребез бизәлешенә юри генә игътибар итегез әле. Закон кабул ителгәннән соң нәрсә үзгәрде, татар һәм рус телләрен дәүләт телләре дип игълан иткәннән соң, без үзебез күпмегә үзгәрдек икән? Өйләребездәге радио һәм телевизорлар 4–5 программада тәүлек буе, нигездә, бер телдә генә сөйли. Өлешчә шәһәр бюджетыннан финансланучы «Эфир» һәм башка район-шәһәр телестудияләре, безнең Законга төкереп тә бирмичә, һаман бер телдә генә үзенекен сукалый.
Бүген безнең милли культурабыз, милли мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз өстенә тагын бер куркыныч афәт килә... Әгәр матбугатка язылу, китап бастыру киләчәктә дә шушы темплар белән барып, аңа дәүләт һәм хөкүмәт дәрәҗәсендә караш тамырдан үзгәрмәсә, тагы берничә елдан татар халкы газетасыз, журналсыз, дәреслексез, китапсыз, гомумән матбугатсыз һәм телсез калачак. Юк, күпләр өмет баглаган радио-телевидение дә коткара алмаячак безне. Чөнки, ни гөнаһ шомлыгы, XXI гасырга кереп барган бер чорда Татарстан халкының чиреккә якын өлеше үз республикасының телевидение тапшыруларын һаман да карый алмый, ә заманында бөтен республиканы һәм халыкны үз янына җыеп торган радионы тулысы белән диярлек авыллардан һәм шәһәрләрдән куып чыгару процессы бара. Ягез әле, безнең район авылларында, 50–60 нчы еллардагы кебек, һәр өйдә радио яисә репродуктор бар, дип, кайсы хакимият башлыгы бүген кистереп әйтә ала. Алдагы сессияләрдә депутат Туфан Миңнуллин, ачына-ачына, ярсый-ярсый, татар матбугатының, татар халкының язмышы турында сөйләде. Әмма, язучы Фәнис Яруллинга өченче катта лифт туктату проблемасын хәл итүне санамаганда, Дәүләт Советының бүгенге көнгә кадәр әле артык нәтиҗәле эше күренмәде. Туфан абый гафу итсен, ул әле яшь депутат, тора-бара аңлар: күпме генә өзгәләнсә дә, кызганыч, аның сүзләренә дә артык колак салучы булмас. Без дә биш ел буе өзгәләндек. Без дә яндык, ә нинди нәтиҗәгә ирештек... «Юаш булсаң – басарлар, усал булсаң – асарлар. Телсез-тешсез кеше булсаң – зур нәчәлник ясарлар», – дип юкка гына әйтмәгәндер безнең халык.
Мәдәниятнең язмышы бүген кемнәр кулында? Зинһар өчен, бу сорауга «мәдәният министры кулында» дип әйтергә ашыкмагыз. Ул заманнар узды. Мәдәният министрлыгы бүген, нигездә, республика оешмалары өчен генә җавап бирә. Чөнки ул оешмаларга каралган акча гына аның кесәсе аша үтә. Ә районнарда һәм шәһәрләрдә мәдәният проблемалары белән тулысынча хакимият башлыклары шөгыльләнә. Әгәр хакимият башлыгының күңеле культурага ята икән,

әгәр ул чын мәгънәсендә халык язмышы өчен кайгыртучы зыялы, белемле интеллигент кеше икән, димәк, районда мәдәнияткә, мәгарифкә, туган телгә, гореф-гадәтләргә игътибар булачак. Әгәр дә инде хакимият башлыгының йорты районда мәдәният сараеннан да мәһабәтрәк икән, әгәр аның мәдәнияткә ихтыяҗы мәҗлестә гармун тартып, «Баламишкин»ны җырлап утыруга гына кайтып кала икән, димәк, бу районда мәдәниятнең хәлләре мөшкел булачак.

Мин Президент сараена сирәк барам, әмма барган саен рәсемнәргә карап, сәгатьләр буе сокланып йөрим. Йомышымны үти алмыйча кайтсам да, ул йорттагы гүзәл картиналар ирексездән күңелне тынычландыра, киләчәккә өмет уята. Ә сезнең менә кайсы да булса район хакимияте бинасында шундый зәвык белән тупланган картиналар галереясын яисә югары сәнгатьле бизәлешне күргәнегез бармы? Әйе, Чаллы мэриясе бинасын, Сабадагы элекке хакимият бинасында ачылган чын мәгънәсендә сәнгать йортын һәм тагын шундый берничә районны санап буладыр. Әмма алар аз, бик тә аз. Президентыбыз, киләчәктә хакимият башлыкларын билгеләгәндә, аларның эшлеклелек сыйфатлары белән бергә культура дәрәҗәсенә, рухи дөньясына, мәдәнияткә, мәгарифкә, туган телгә булган мөнәсәбәтләренә дә игътибар итсә иде. Безнең халыкта түрәләргә хөрмәт, башлыкларга охшарга тырышу гадәте бик борынгы заманнардан килә. Әле дә истә, моннан берничә ел элек республикабызның бер җитәкчесе затлы мехтан фуражка тектереп кигән иде. Бер айдан соң Министрлар Кабинетындагы утырышка хакимият башлыклары җыелды. Карасам, шаккаттым: илле хакимият башлыгының иллесенең дә башында шундый ук фуражка. Соңрак бу фуражканы совхоз директорлары, колхоз рәисләре тектереп киде, аларның мехы очсызрак иде, билгеле. Тора-бара республикада мондый фуражка кимәгән җитәкче үзен чалмасыз мулла кебегрәк хис итә башлады.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: безнең республикада җитәкчеләрнең абруе зур. Әмма урындагы җитәкчеләр аларның фуражкаларын гына түгел, ә күңел байлыкларын, халык язмышын кайгырту кебек олы сыйфатларын да үзләренә үрнәк итеп алсыннар иде.

Билгеле, 1994 ел бюджетын гамәлгә кую, башкарып чыгу гаять катлаулы булды. Ел дәвамында без аны яңадан карап, үзгәрешләр кертергә мәҗбүр булдык. Әмма ләкин бу үзгәрешләрнең берсе дә безнең файдага, мәдәният, мәгариф файдасына булмады. Бюджет үтәлеше турындагы процентлар шул хакта сөйли. Әмма «өметсез – шайтан» диләр. Бүген без яңа премьер-министрдан, яңа һәм тагын да яңарачак хөкүмәттән халык язмышына, аның рухи байлыгына, мәдәниятенә, мәгарифенә, теленә, гореф-гадәтләренә яңача, яхшы караш көтеп калабыз.

*1995*

# АЛДА БЕЗНЕ НИ КӨТӘ?

Алты ел буена Татарстан халык депутаты булып тору дәверендә минем әле бер генә тапкыр да трибунага тыныч күңел, канәгать йөз белән чыгып басканым булмады. Нишлисең бит, «без өйләнгәч, төн кыскарды» дигәндәй, безнең кебекләр парламентка сайлангач кына дөньяларның асты өскә килеп, тормышлар катмарланып китте.

Мин бүген Россия империясенең бөтенлеген саклау өчен геноцид юлына баскан карагруһларны да, дүрт йөз ел буена караңгы зинданда утырган газиз халкына амнистия таләп итүче милләтпәрвәрләрне дә, төшләрендә Мәскәү танкларын күреп, дерт итеп уянып китүче җитәкчеләребезне дә бик яхшы аңлыйм. Ләкин минем яисә безнең һәммәбезнең дә аңлавыннан ни файда? Без, үзебезнең иманыбызны, халкыбызның, республикабызның тоткан юлын аныклап, 1990 елның 30 августында Дәүләт бәйсезлеге хакында Декларация кабул иттек. Без, кая барганыбызны бик яхшы аңлап, үзебезнең беренче президентыбызны сайладык, без, кая барырга ярамаганын бик яхшы аңлап, заманында Россия Президентын сайлауда катнашмадык. Татарстан халкының күпчелеге аңлы рәвештә референдумда республикабызның мөстәкыйльлеген, тәрәккыяткә ирешкән башка милләтләр һәм халыклар белән тигез вәкаләтле булуны дәгъва кылып тавыш бирде. Һәм, ниһаять, 1992 елның 6 ноябрендә без, моңа кадәр башкарган эшләребезне бер тәртипкә салып, йомгаклап, тарихыбызда беренче мәртәбә мөстәкыйль Конституциябезне кабул иттек.

Бу җиңүләрнең берсе дә җиңел генә бирелмәде. Әгәр дә без соңгы биш-алты ел эчендә, бөкрәйгән билләребезне турайтып, бераз тураеп басканбыз икән, әгәр дә без һәммәбез дә бераз гына булса да үзен чын мәгънәсендә тигез хокуклы кеше итеп, ә республикада яшәүче башка милләт вәкилләре үзләрен тулы канлы шәхес итеп хис кыла башлаганнар икән, монда безнең һәммәбезнең дә әче суыкларда, көзге яңгырларда Азатлык мәйданында көн үткәргән әбиләр һәм бабайлардан башлап, бернинди кыенлыкларга да карамыйча, безнең табыннарыбызга нигъмәт иңдерүче игенчеләрнең дә, күпме мәсхәрәле сүзләр ишетеп тә, күңелләре сүрелмәгән, рухлары сынмаган тулы иманлы депутатларның да, иң авыр һәм катлаулы хәлләрдән дә исән-сау чыккан һәм, иң мөһиме, әле моңа кадәр республика халкын да исән-сау алып чыга алган президентыбызның да өлеше бик зур. Болар инде барысы да тарихка кергән һәм аларны берәү дә оныта да, оныттыра да алмаячак.

Дөресен әйтим, шулай да соңгы көннәрдә минем кәефем бик начар. Бөтен илнең, барча халыкларның күз алдында Россия армиясе, федераль хакимият империяне саклап калу сылтавы белән тулы бер республиканы җир белән тигезләде, тулы бер халыкны кырып бетерүне максат итеп куйды. Иң куркынычы шул: Рәсәй халкының 90 проценты бу вәхшилеккә каршы икәнен әйтеп торса да, аларга колак салучы, аларның сүзен тыңлаучы юк. Әллә соң бу кешелекнең бетүгә таба юл тотуымы, әллә бу, чыннан да, ахырзаман җитүме соң?!

Без Татарстанда ике телне – татар һәм урыс телләрен дәүләт теле дип игълан иттек. Безгә җавап итеп булса кирәк, озакламый Россия дә президент Указы белән үз дәүләтендә икенче дәүләт теле итеп дөньядагы иң аңлаешлы телне – танклар һәм бомбалар «телен» кабул итте, һәм тезгеннән ычкына башлаган субъектлар бу «телнең» мәгънәсенә тәрҗемәсез дә бик тиз төшенделәр һәм ашыга-ашыга, берсен-берсе уздыра-уздыра моңа кадәр кабул иткән мөстәкыйль карарларын һәм законнарын яңадан сүтәргә, моңа кадәр кылырга өлгергән «ялгышларын» төзәтергә тотындылар. И-их, беркатлы сабыйлар! Имештер дә безгә яхшы патша – урыс патшасы – ирек вәгъдә итте, имештер дә без, ниһаять, үз җиребездә үзебез хуҗа булдык! Татарстанны урап алган мари урманнарындагы атакага ташланырга әзер торган Рәсәй танклары турында ишеткәч, безнең күңелләрне тагын шом басты, ә инде Ичкериядәге вәхшилекләрне күргәч, бөтен хыялларыбыз яңадан чәлпәрәмә килде. Кешеләрнең күңеленә яңадан шик-шөбһә, икеләнү, өметсезлек, курку кереп оялады. Шушы авыр хисләрдән котылу өчен, без әле Президент сарае өстенә авышкан Сөембикә манарасына, әле кан төсенә кергән Мәскәү Кремленә карый-карый яңа законнар язарга,

элеккеләренең «хаталарын» төзәтергә тотындык. Безнең бүген кыла торган бу гамәлләребезгә тарих нинди бәя бирәчәген фараз кылу кыен. Әмма без 110 еллыгын билгеләп үткән бөек Тукай бүгенге буынның кыласы гамәлләрен алдан күреп, моннан төгәл 88 ел элек болай язып калдырган:

Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгъмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып,
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

Бел, хәзер дөнья кяфергә һәм сиңа җәннәт әле;
«Мөэминә зиндан» булыр ул, тотса мәскәүләр якаң!

Милли хәрәкәт, дәүләтчелегебезне торгызу, милли рухыбызны уяту өчен барган көрәш хәрәкәте соңгы елларда бераз сүрелеп, тынычланып калган кебек булды. Әмма бу тыштан, өстән караганда гына шулай. Ә чынында исә мәйданнарда, митингларда кешеләр күңеленә кереп калган бу очкын эчендә җаны булган һәр милләт баласының рухи дөньясына мәңге сүнмәс ут салды. Соңгы елларда ирешкән уңышларыбызның иң зурысы, минемчә, халыкның милли аңын уяту, гасырлар буена коллыкта ятып, милли рухы, милли горурлыгы оеган, йокыга талган халыкны кузгатып, аны бер олы максат – дәүләтчелегебезне торгызу максаты белән яшәтә башлау булды.
Болары инде эшләнгән эшләр, кылган гамәлләребез, болары әле юл башындагы беренче казыклар гына. Ә алда безне нинди эшләр көтә, без кая барабыз соң әле?
Милләтне тулысынча азат вә хөр итү өчен ул милләтнең күпчелеген шушы уй, шушы өмет, шушы хыял белән яшәтү, шушы максат тирәсенә туплау кирәк. Бу максатка ирешү өчен бүген бездән халкыбызның булган рухи мирасын барлап, аларны тәртипкә салу, телебезне, динебезне яклау, милли мәгариф системабызны аякка бастыру, мәдәниятебезгә җан өрү, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны яңарту таләп ителә. Әгәр дә безнең балалар бакчасыннан башлап югары уку йортларына кадәр эзлекле мәгариф системабыз булмаса, әгәр дә безнең һәммә дәүләт оешмасында, һәммә кибеттә һәм хастаханәдә, автобуста һәм трамвайда, Президент сараенда һәм парламент залында татар теле тулы хокуклы хуҗага, чын мәгънәсендәге дәүләт теленә әверелмәсә, әлеге хыялыбыз мәңгелек матур хыял булып кына калачак.
Без инде хәзер йодрык төйнәп лозунглар кычкыру яисә матур, купшы сүзләр сөйләп кешеләрне юату чорын уздык. Бүген конкрет сүзләр, конкрет эшләр вакыты җитте. Әгәр инде милләт кадәр милләт үзенең киләчәк буыннары, халкының киләчәге өчен бер Милли университет та ача алмый икән, бу милләтнең киләчәгенә ышанып, ул халыкның җитәкчеләрен милләт мәнфәгатен яклаучылар дип әйтеп буламы икән? Әгәр дә без татар авылларындагы китапханәләрне – китапсыз, клуб һәм Мәдәният йортларын бер сыңар баянсыз калдырабыз, китап кибетләрен аракы кибетенә әйләндерәбез, тәүлегенә нибары алты сәгать сөйләүче телевидениебезнең алтын вакытының дүрттән өч өлешен милләт өчен бөтенләй кирәге булмаган буш һәм хәтта зыянлы тапшыруларга бирәбез икән, әгәр дә без Татарстаныбызда чыккан товарларга татарча ярлык язарга оялабыз икән, әгәр дә парламентта безнең законнарыбыз әле һаман бер телдә – урыс телендә генә кабул ителә икән, димәк, без әле һаман үз сүзебезне сүз итә алмыйбыз, димәк, без әле мөстәкыйльлек турындагы Декларациябездә, Төп канунубыз – Конституциядә язып куйган максатыбызга ирешә алмаганбыз.

*1996*

# ТЕЛ ЯЗМЫШЫ – ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

**Нәрсә соң ул дәүләт теле?**

Хөрмәтле халык вәкилләре! Мөхтәрәм җәмәгать! Мин чыгышыма тагын «мөхтәрәм Илбашы – Президент» дип тә язып куйган идем. Кызганычка каршы, Президентыбыз биредә юк. Булмаса да сөйлим инде. Мин үзем авылда ишле гаиләдә үскән кеше. Безнең өйдә, әти булмаганда, бервакытта да җитди карар кабул итмиләр иде. Ярый, «әти» юкта булса да сөйләп калыйк.

Без бу сессияне бик озак көттек. Күңелләребездә еллар буена җыелып килгән уй-фикерләребезне, рәнҗү һәм үпкәләребезне, өмет һәм хыялларыбызны тагын бер кат шушы трибунага чыгып сөйләп, эчләребезне бушату өчен генә түгел, инде дә, ниһаять, безнең сүзләребезне ишетерләр, инде дә татар теленең тулы хокуклы дәүләт теле булырга тиешлеген аңларлар, аның өчен кирәкле шартлар тудырырлар дигән өмет белән көттек без бу олуг мәҗлесне.

«Телләр турында»гы Закон кабул ителгәннән соң республикада эшләнгән эшләрне, бигрәк тә мәгариф өлкәсендәге алга китешләрне монда беркем дә инкяр итәргә җыенмый. Әмма сүз бүген эшләнгән эшләр турында гына түгел, ә күбрәк алдагы бурычлар һәм проблемалар хакында барырга тиештер. Моннан җиде елга якын элек, 1990 елның 30 августында, без Татарстанда ике телне – татар һәм рус телләрен дәүләт телләре дип игълан иттек. Ә нәрсә соң ул дәүләт теле? Безнең аңлавыбызча, иң беренче чиратта дәүләт теле ул – дәүләт белән идарә итү, дәүләтнең һәммә эчке һәм тышкы эшләрен, тормышын алып бару, шул дәүләттә яшәгәннәрнең үзара аралашу теле.

Дәүләт теле дип игълан ителгән тел шул дәүләттә дөньяга килгән һәр сабыйга ана сөте белән бергә үк кертелә башлап, ясследә, балалар бакчасында, мәктәптә һәм югары уку йортында тулы хокуклы тел булырга, дәүләтнең һәр гражданины шушы дәүләт телендә аралашу, белем алу, эш йөртү дәрәҗәсендә тәрбия алырга тиеш. Суверенитетлы дип аталган дәүләткә исем биргән халыкның телен белмичә һәм белергә дә теләмичә, шул халык белән аңлашып, тату-дус яшәргә, бигрәк тә аның белән идарә итәргә тырышу кемнәрнеңдер күңелендә ризасызлык уята икән, мин ул кешеләрнең хисләрен бик яхшы аңлыйм. Чөнки дус-тату яшәү бары тик бер-береңә тигез дәрәҗәдә хөрмәт белән караганда, гореф-гадәтләрне, йолаларны, бер-береңнең телен тигез дәрәҗәдә хөрмәт иткәндә генә була ала. Татар телен тергезү һәм аякка бастыру өлкәсендә шактый эшләр эшләнсә дә, ни өчен җиде елга якын вакыт эчендә безнең туган телебез дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алмады? Зинһар өчен, рус телле коллегаларым мине дөрес аңласыннар. Мин бүген, нигездә, татар теленең аяныч хәле турында сөйләрмен. Алар, әнә, мине тыңламыйлар да, наушниклар да алмаганнар... Бу һич кенә дә рус теленә битарафлык түгел. Ә татар теленең бүгенге көндә, рус теле белән чагыштырганда, Татарстан дип аталган республикада хәле үтә мөшкел булуыннан гына.

Без бит барыбыз да беренче чиратта иң авырткан җиребез турында сөйлибез. Хәле авыррак булганнарга иң элек ярдәм кулы сузарга тырышабыз. Ә чыннан да, ни өчен бездә татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителеп тә, чынлыкта бары тик бер тел – рус теле генә дәүләт теле вазифаларын үти? Минемчә, моның төп сәбәбе – «Телләр турында»гы Законны тормышка ашырырга, иң беренче чиратта шушы эш белән шөгыльләнергә тиешле кешеләребезнең, бигрәк тә җитәкчеләребезнең, ышанычлары булмауда, күңел кыйблаларының шул якка таба борылмавында. Юк, тыштан алар бу Законга каршы түгел. Ә эчтәге иманнары башка. Эчтәге каршылык тыштагы кирәклектән көчлерәк. Чөнки алар безнең илдә, безнең системада бүгенге көнгә кадәр әле бер генә карарның, бер генә законның, хәтта Конституциянең дә тулысынча үтәлмәвен, бер генә дәүләт яисә хөкүмәт программасының да чынга ашмавын бик яхшы беләләр. Аны үз күзләре белән күреп торалар. Боларын да шул ук язмыш көтүенә шикләнмиләр. Ә ышаныч һәм иман булмаган җирдә теләк булмый. Теләк булмаган җирдә акча булмый, акча булмаган җирдә эш тә тиешле дәрәҗәдә бармый. Мисал өчен ерак йөрисе юк. Мәсәлән, бюджеттан елның-елында

акчаның иң азын кемгә бирәләр? Кемгә булсын? Әлеге дә баягы милләтне милләт иткән, аның телен үстергән, рухи дөньясын, аң-белемен баеткан мәгарифкә, мәдәнияткә, фәнгә, радио-телевидениегә, газета-журналлар чыгаруга, китапханәләргә.

Минималь хезмәт хакын кабул иткән законыбыз нәкъ менә мәгариф, сәламәтлек саклау һәм мәдәният өлкәләре өчен чын мәгънәсендә афәт булып чыкты. Гореф-гадәтләребезне, динебез һәм телебезне моңа кадәр авыл коткарып һәм саклап калган булса, инде менә милләтебезнең соңгы таянычына – татар авылына да әҗәл чираты җитте бугай. Авылда театр да, филармония дә, цирк та, концерт заллары да, университетлар да, академияләр дә юк. Анда булса шул бер мәктәп, бер клуб, бер китапханә генә, аларны да кыскарткач, авылда тулы хокуклы хуҗа булып дуңгыз фермасы, тавык кетәклеге һәм 100 төрле аракыдан киштәләре сыгылып торган бердәнбер кибет кенә кала. Татар авылының соңгы китапханәчесен, соңгы клуб мөдирен кыскарткан кешене мин бүген, һич тә тартынмыйча, үз кавеменең, үз халкының дошманы дип атар идем. Белгәнебезчә, республика мәдәният оешмаларында эшләүче 17 мең кешенең һәр унынчысы, димәк, 1 мең 700 мәдәният хезмәткәре кыскартылырга тиеш. Димәк, революция елларында чит илләргә сөрелгән, Гражданнар сугышы чорында атылган, асылган, Бөек Ватан сугышы елларында кырылган, Сталин төрмәләрендә черегән, инде болай да соңгы чиккә җитеп сыегайтылган, хәлсезләнгән милләтебезнең өрфия калынлыгындагы интеллигенциясе – зыялылар катлавы – тагын да юкарачак һәм бөтенләй бетүгә таба юл тотачак. Нигездә, бары тик кара эшчедән, игенчедән, сыер савучыдан һәм дуңгыз караучыдан, төрмә сакчыларыннан һәм дәүләт чиновникларыннан гына торган милләтнең киләчәге булмавы барыбызга да яхшы билгеле.

Соңгы елларда без башкалабыз Казанда һәм район үзәкләрендә шау-шулы бәйрәмнәр ясарга шактый остарып җиттек. Әмма, тулаем алганда, республикада культураның хәле көннән-көн мөшкелләнә бара. Театрларыбызның күбесе ярым җимерек хәлдә, аларны ремонтларга акча юк, татарча сорасаң да юк, русча сорасаң да юк. Соңгы өч елда гына да республикада 134 клуб, 5 китапханә ябылды. Бүгенге көндә 33 китапханә һәм 115 клуб авария хәлендә. 91 китапханәгә һәм 591 клубка капиталь ремонт ясарга кирәк. 33 районда халыкка китапханә хезмәте күрсәтү өчен библиобуслар юк, хөкүмәт хисабына китап чыгару мөмкин булмаган нәрсәгә әверелде. Укучылар өчен дәреслекләр бастыру дәүләт күләмендәге хәл ителмәс проблемага әйләнде. Мәсәлән, 1996 елда республикабызның өч районында татар китабы алу өчен китапханәләргә бер тиен дә акча бирелмәде. Мин моңа гаҗәпләнмим дә. Әгәр кайбер җитәкчеләребез үз гомерләрендә мәктәптә укыгандагы ботаника дәреслегеннән соң кулларына ялгышып та китап тотып карамаганнар икән, алар ничек итеп китап һәм китапханәләр турында кайгыртсыннар ди инде! Дәреслексез балалар укытып, китапсыз китапханә ачып, гармунсыз клублар тоткан булып, без нинди рухи яңарыш, милләтнең киләчәге, татар теленең чәчәк атуы турында сөйлибез соң? Президентыбыз киләчәктә хакимият башлыкларын билгеләгәндә, аларның эшлеклелек сыйфатлары белән бергә культура дәрәҗәсенә, мәдәнияткә, мәгарифкә, сәнгатькә, туган телгә булган мөнәсәбәтләренә дә игътибар итсә иде. Район һәм шәһәр хакимият башлыкларының җитәкчелек осталыгы ничә центнер ит, сөт, ничә тонна ашлык җитештерү белән бергә халыкның аң дәрәҗәсен ничә карышка үстерүе, туган телгә, гореф-гадәткә, рухи байлыкка мөнәсәбәте, һич югында, елына ничә китап, газета-журнал укуы, ничә тапкыр театр, концерт, музей, китапханәгә баруы белән билгеләнергә тиештер.

Кыскартып, мин соңгы сүземне генә әйтәм, вакытым бетте. Безгә акча да бирмиләр, сүз дә бирмиләр, килеп җитте заманалар. Мин үземнең чыгышымны «Нәрсә соң ул дәүләт теле?» дип башлаган идем. Әйе, дәүләт теле ул – гамәлдәге дәүләтнең гербыннан, флагыннан, гимныннан да югарырак торырга тиешле төп дәүләтчелек атрибуты. Ул – халыкның һәм дәүләтнең уйлау, фикерләү, яшәү рәвеше. Әгәр дәүләттә дәүләт теле дип аталган телне белмичә һәм кулланмыйча да рәхәтләнеп яшәп, эшләп һәм ул дәүләт белән идарә итеп була икән, димәк, бу тел инде чын мәгънәсендә дәүләт теле түгел һәм ул беркайчан да дәүләт теле була алмаячак.

*1997*

# «ЮК ШУЛ БЕЗЛӘРДӘ БЕРЛӘШМӘК...»

*(Иртән уянгач беренче уем)*

1906 елда, татар халкы рухи яңарыш кичергән бер чорда, Габдулла Тукай, ачынып, мондый сүзләр язган: «Юк шул безләрдә берләшмәк; Юк бергә-бергә гөрләшмәк, Бер җан, бер тән булып, һәр нечкә серне бергә серләшмәк...» Татарның иң зур кимчелеген, иң олы фаҗигасен 20 яшьлек бөек Тукай берничә сүз белән искиткеч төгәл әйтеп биргән.

Әйе, милләтне милләт итәр өчен иң әүвәл шушы олы бергәлек: уртак рух һәм уртак иман, уртак тел һәм уртак мәдәният, уртак хыял, уртак максат кирәк. Ә хәзерге көндә безнең максатыбыз да, иманыбыз да, рухи кыйблабыз да бер, ул да булса бәйсез, мөстәкыйль суверен дәүләт – Татарстан җөмһүрияте төзү. Чөнки дәүләтсез халык беркайчан да дөнья мәйданында бил алышырлык көчле-гайрәтле олы халык була алмый, дәүләтсез милләтнең күңеле ятим баланыкы сыман китек, рухы сүрән, киләчәге томанлы була. Татар халкын, татар милләтен саклап калу, аны дөньяга чыгару өчен бүген безгә иң элек Татарстаныбызга куәт бирергә, аны лаеклы рәвештә ил-көнгә күрсәтергә кирәк.

Милләт ул, кызганычка каршы, үз милләте өчен җан атып йөргән кешеләрдән генә тормый. Бүген генә түгел, бу гомер бакый шулай булган. Үзебез нинди булсак, милләтебез, халкыбыз шундый. Милләтне туры юлга чыгару өчен иң әүвәл үзеңә туры юлга басарга, милләткә иман иңдерү өчен иң элек үзеңә иманлы булырга кирәк.

«Иман» сүзе минем өчен колач җитмәслек киң мәгънәгә ия. Дин, әхлак, тәрбия, намус кебек изге төшенчәләр белән беррәттән «милли идея» дигән тәгъбирнең дә күңел түребездә булырга тиешлегенә иманым камил. Соңгы арада Русия үзенең милли идеясе нидән гыйбарәт булырга тиешлеге хакында баш вата. Тарихчылар, галимнәр, дәүләт җитәкчеләре, берсеннән-берсе уздырып, концепцияләр язалар, бәхәсләшәләр. Әмма шунысы ачык: дөньяда бер милләт тә үзенә милли идея уйлап тапмый, чөнки милли идея ул – милләтнең җаны, бәгыре, кыйбласы, тоткан юлы, максаты, Иманы. Милли идея милләт белән бергә формалаша, дөресрәге, милли идея милләтне милләт итеп яшәтеп килә, маяк булып, аны һәрчак алга дәшеп тора.

Гап-гади мәктәп укучысыннан: «Русиянең милли идеясе нидән гыйбарәт?» – дип сорасаң, ул, һич икеләнмичә: «Башка халыкларны буйсындырып, шулар хисабына яшәүдән, «мәңге бүленмәс» империяне саклаудан», – дип әйтер иде. Чөнки мәктәп дәреслекләрендә бу идея турыдан-туры шәрехләнә, бүгенге көндәлек матбугат та көне-төне шул турыда язып һәм тәкрарлап тора.

«Татарның милли идеясе нидән гыйбарәт?» дип тә артык баш ватып торасы юк. Безнең милли идеябез, һичшиксез, татарның дәүләтчелеген торгызу, дәүләтчелеген ныгыту. Бәлки, кайберәүләр: «Иң беренче чиратта туган телне гамәлгә кертү, гореф-гадәтләрне кайтару, милли мәгариф системасын булдыру һ. б. кирәк», – дип әйтерләр. Дөрес, болар һәммәсе дә кирәк. Әмма дәүләтчелекне булдырмый, чын мәгънәсендә милли дәүләт төземи торып, боларның берсен дә кирәкле дәрәҗәдә, дәүләт дәрәҗәсендә тормышка ашырып булмаячак.

Мин инде шактый илләрдә булдым, АКШ кебек милли төсмере булмаган, нигездә, тук һәм бай тормышны идеал иткән дәүләтләрне дә, Төркия, Польша, Англия, Испания, Израиль сыман милли дәүләтләрне дә күрергә туры килде. Мул тормышның рәхәтлекләрен, халыкка уңайлыкларын таныган хәлдә, мин милли дәүләтләрнең дөнья культурасына, сәнгатенә, әдәбиятына, фәненә, гомумән планетабыз цивилизациясе-тәрәккыятенә милләтсез дәүләтләргә караганда күбрәк өлеш керткәнен аңладым.

«Татарстан киләчәктә кайсы юл белән: милләтсез АКШ яисә милли төсмерле, милли җанлы Европа һәм Азия дәүләтләре юлы белән китәргә тиешме?» – дип сорасалар, мин, һич икеләнмичә, соңгысын сайлар идем. Чөнки бары тик милли төсмере, милли аңы булган дәүләттә генә шул дәүләтне оештырган һәм аңа исем биргән милләтнең теленә кадер-хөрмәт була, бары тик милли дәүләттә генә халыкның гореф-гадәтләре, йолалары саклана, аңа күңеле тарткан ризык ашарга,

рухына яраклы дин тотарга, милли мәгарифне үстерергә мөмкинлек тудырыла. Кемгә ничектер, милли төсмере булмаган дәүләт төзүдә катнашасым да, анда яшисем дә килми. Әгәр андый дәүләттә яшисем килсә, мин инде күптән АКШка күчеп киткән булыр идем.

Милләтнең күпчелеге милли идея тирәсенә тупланмый торып, аның гамәлгә ашуы мөмкин булмаган хәл, чөнки революцион юл белән китерелгән үзгәрешләр, күргәнебезчә, озын гомерле булмый. Милләтне бер уртак идея тирәсенә туплауда гомер-гомергә бездә милләтчеләр, милләтпәрвәрләр төп рольне уйнап килгән, чөнки татарның 1552 елдан соң башка көче, башка мөмкинлекләре булмаган. Дәүләтсез, патшасыз милләтне халыкның рухи көче, рухи ныклыгы, иман берлеге саклап калган. Милләтебезнең зәгыйфьләнгән рухына куәт биреп, аны исән-имин килеш бүгенге көнгә кадәр китереп җиткергән өчен без туры иманлы һәр милләтчебезгә, күңелендә милли горурлык хисе саклаган һәммә милләттәшебезгә, милләт кайгысын кайгыртучы дәүләт һәм хөкүмәт башлыкларына чын күңелдән олы рәхмәтебезне әйтергә тиешбез. Аллага шөкер, милләтпәрвәрләребезнең фидакярлеге, җитәкчеләребезнең тырышлыгы, ныклыгы һәм маһирлыгы белән соңгы арада, акрынлап-акрынлап булса да, Татарстан дигән дәүләт тернәкләнә башлады. Чын мәгънәсендә дәүләт булып дөньяга аваз салу өчен аңа әле бик күп сынаулар узарга туры киләчәк. Ә бу сынауларны җиңеп узар өчен иң беренче чиратта милләтебезне бер йодрыкка туплау, төрле хәрәкәтләр һәм оешмалар арасындагы мәгънәсез низаглардан котылу, милли хәрәкәт белән дәүләт җитәкчелеге арасында уртак тел табу кирәк.

Җыенып олы юлга чыкканчы, иң элек кая барасыңны һәм анда ни өчен барасыңны ачыкларга, юлыңда нинди киртәләр очратачагыңны чамалау мөһим. Ә безнең юлдагы иң олы киртә әле озак еллар Русия белән мөнәсәбәтләрне ачыклау булачак. Татарстан белән Русия арасында төзелгән Шартнамә – ике президентның кул кысышып егетләрчә килешүе нәтиҗәсе. Тик президентлар, никадәр әйбәт булсалар да, мәңгелек түгел, ә халык – мәңгелек. Бүген безгә үзебезнең Конституциябезне, «Татарстан – суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты» дип язылган Төп Законыбызны, Татарстанның статусын ачыклау өчен үткәрелгән референдум нәтиҗәләрен бөтен халкыбыз, бөтен милләтебез, дәүләт башлыкларыбыз белән бергәләп тормышка ашыра башларга, бу хакта кыюрак һәм максатлырак гамәлләр кылырга вакыт җиткәндер.

Безнең Татарстаныбызда татарлардан кала сан ягыннан икенче урында торган рус халкы өчен мөмкин булган һәммә шартлар да тудырылган. Укыйсың килсә, рус мәктәбе бармы – бар, балалар бакчасы, яслеләр бармы – бар, техникумнар, югары уку йортлары бармы – бар, рус театрлары, музейлары, китапханәләре, газеталары, журналлары, нәшриятлары, телевидениесе, радиосы бармы – бар. Бар, бар, тагын бер тапкыр бар! Монысы Татарстанда булды. Ә Русиядә хәлләр ничек? Татарстанда руслар сан ягыннан икенче урында булса, Русиядә татарлар да нәкъ шулай, руслардан кала икенче урында тора. Әйдәгез, «рус демократлары» шыплап тутырылган Русия башкаласы Мәскәүне генә алып карыйк... Мәскәүдә татар балалар бакчалары бармы, булса, җитәрлекме? Юк! Һич юк! Мәктәпләр, татар техникумнары, вузлары бармы? Юк. Театрлар, китапханәләр, музейлар, нәшриятлар бармы? Юк. Татарча газета-журнал чыгамы, радио сөйлиме, телевидение күрсәтәме? Юк, юк, тагын бер тапкыр юк! Шушындый тигезсезлеккә, шушындый тибәрелүгә, кысылуга һәм санга сукмауга нормаль кеше, нормаль халык, нормаль милләт түзеп торырга тиешме? Җавап бер генә – юк! Без беркемнән дә артыгын сорамыйбыз, без бары тик үзебезгә тигән өлешне, милләтләр тигезлеген генә таләп итәбез.

Бөек шагыйребез Тукай сүзләре белән башланган бу язмамны Шәехзадә Бабичның шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

И татар, калдың хөр һәм азат,
Хөрлеккә, көрлеккә алдың хак.
Артыңны – салкынны онытып,
Алга бак, кальбең як, ялкынлат.

*1999*

# ДӘРЕСЛЕК ЯЗУ – БӨТЕН ҖӘМГЫЯТЬ БУРЫЧЫ

Бүген Татарстан Республикасы парламенты безгә, Татарстан Республикасы халык депутатлары, төрле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, галимнәр, мәгариф системасының гамәли хезмәткәрләре һәм югары уку йортлары мөгаллимнәре белән бергә, конструктив, профессиональ сүз алып бару өчен үз трибунасын бирде. Безнең парламент тыңлауларының максаты – мәгарифнең сыйфатын арттыруга, белем алуның даирәсен киңәйтү, укучыларның бушлай белем алуга конституциячел хокукларын, шул исәптән дәреслекләр белән бушлай тәэмин ителү хокукларын гамәлгә ашыруга, бу нисбәттән бигрәк тә мохтаҗ гаиләләрдәге сәләтле балаларга ярдәм күрсәтү. Безнең өчен яңа гасыр нинди булачак? Яңа меңьеллык гыйлемлелек, профессиональлек гасыры булсын өчен безниләр эшләргә тиеш? Болар барысы да беренче чиратта безнең үзебездән тора. Мәгариф системасы киләчәкнең иң зур байлыгын тудыра: шуңа күрә без югары технологияләр уйлап табарлык белемле, җаваплы, талантлы һәм әдәпле кешеләр, сәләтле ватандарлар, ватанпәрвәрләр тәрбияләүне үзебезнең төп бурычыбыз дип саныйбыз. Өченче меңьеллыкта яшь буынны нәрсәгә һәм ничек өйрәтү сезнең һәм безнең эшчәнлеккә бәйле. Мәктәпләребезне тәмамлаучы балалар сәламәт булырга, тырышып эшләргә, үз иленең байлыгын арттырырга, туган халкының тарихын, мәдәниятен һәм телен өйрәнергә тиеш.

Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре гомуми төп белемнең дәүләт мәгариф учреждениеләрендә бушлай булуын һәм теләгән һәр кешегә шул белемнәрне үзләштерүне гарантияли. Укучыларны дәреслекләр белән бушлай тәэмин итү әлеге хокукны гамәлгә ашыруның мөһим чараларының берсе булып тора. Укучыларны үз вакытында сыйфатлы дәреслекләр белән тәэмин итү мәгариф җитәкчеләренең һәм акча бүлүче дәүләт оешмаларының төп бурычы булырга тиеш.

Базар мөнәсәбәтләренә күчү финанслар белән тәэмин ителеп килгән заказның гамәлдәге бердәм дәүләт системасын бетерүгә китерде, бу хәл дәреслекләрне чыгару күләмнәренә, укучыларны адреслы тәэмин итүгә тискәре йогынты ясады.

Русия Федерациясе хөкүмәте күрсәтмәсе буенча 1997 елдан Русия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарына дәүләт мәгариф учреждениеләрен дәреслекләр белән тәэмин итү тәртибен мөстәкыйль билгеләү тәкъдим ителде.

Әмма Русия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советы тарафыннан үткәрелгән парламент тыңлаулары материалларына караганда, хәзерге вакытка кадәр Русия Федерациясенең күп кенә субъектларында укучылар дәреслекләр белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителми. Бу эш беренче чиратта Русия Федерациясе субъектларының бюджетында акча җитәрлек булмау сәбәпле, шулай ук оештыру кыенлыклары аркасында тукталып тора. Русия Федерациясе субъектларының күбесе үз бюджетларында дәреслекләр сатып алу чыгымнарын җитәрлек дәрәҗәдә карамыйлар, шуңа күрә ул кайбер очракларда ихтыяҗның 10 проценттан да азрагын тәшкил итә.

Русия Федерациясе Мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, 1999/2000 уку елында төбәк бюджетларыннан финанслау күләмнәре, алдагы уку елы белән чагыштырганда, 412,3 миллион сумнан 280,5 миллион сумга кадәр, ягъни 1,5 мәртәбә диярлек кимеде. Русия буенча дәреслекләр белән тәэмин ителеш уртача 83 процент тәшкил итә. Төбәгенә карап, ул 54 проценттан (Архангельск өлкәсе, Рязань өлкәсе, Төмән өлкәсе һ. б.) 98 процентка кадәр (Вологда өлкәсе, Хабаровск крае, Мурманск өлкәсе һ. б.) һәм 100 процентка кадәр (Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре) җитә. Татарстанның мәгариф учреждениеләрендә федераль һәм төбәк дәреслекләре кулланыла. Татарстанда бүген бюджет акчалары исәбеннән федераль дәреслекләр белән тәэмин ителеш 62 процент чамасы булса, ә төбәк дәреслекләре белән тәэмин итү 80 процентка якын. Республика мәктәпләрендә дәреслекләр җитмәү, аларны сатып алу өчен акчалар 1997 елдан бирле мәгариф учреждениеләре ихтыяҗына карап түгел, ә республика бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып бирүгә бәйле.

## Федераль дәреслекләр турында

Соңгы елларда дәреслек базарындагы басмалар саны көннән-көн арта бара. Русия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан куллануга тәкъдим ителгән федераль дәреслекләр бастырып чыгару белән Русиянең 55 нәшрияты шөгыльләнә (90 нчы елларга кадәр дәреслекләрне «Просвещение» нәшрияты гына чыгара иде). Тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлеге 1000 нән артып китә. Һәр предмет буенча һәр сыйныф өчен 3–5 исемдәге дәреслек чыгарыла. Хәзер укытучылар үзләре теләгән дәреслекне алу мөмкинлегенә ия, ягъни укучыларны уку процессында төрле төркемнәргә дифференциацияле бүлү мөмкинлеге барлыкка килде.

Республика мәктәпләренә ел саен якынча 3–3,5 миллион нөсхә федераль дәреслек кирәк, хәзергә бу ихтыяҗ нибары 15–20 процентка гына канәгатьләндерелә. 2000 елдан башлап федераль дәреслекләргә заказлар бирү бюджетта каралган акчаларга бәйле рәвештә ел саен 3–3,5 миллион нөсхәдән 1,3 миллион нөсхәгә кадәр кими бара.

Федераль дәреслекләргә заказларның ел саен мәҗбүри кими баруы аларның мәктәп китапханәләре фондларында да бертуктаусыз кимүенә китерә. Шуңа күрә дә ата-аналар үз акчаларына федераль дәреслекләрне ел саен күбрәк сатып алалар. 2000 елда алар 25 миллион сумлык дәреслек сатып алганнар, бу, 1999 ел белән чагыштырганда, 1,5 мәртәбә артык дигән сүз. Әмма җәмгыятьнең социаль катлауларга һаман саен ныграк бүленүе, басмаларның хакы арта баруы аркасында, укучы балалар арасында дәреслекләр белән тәэмин ителеш аермасы күбәя. Хәзер бер укучыга кирәкле дәреслекләр комплектының уртача хакы 1000 сумга якын тора. Билгеле инде, айлар буе хезмәт хакы алмаган ата-ана өчен бу бик зур проблемага әверелә.

Хәзерге вакытта ватандашларыбызның, бигрәк тә яшьләрнең сәләтләрен үстерү юлында матди киртә барлыкка килде, бу бигрәк тә мәгарифкә кагыла. Күп кенә гаиләләр балаларының мәктәп портфельләрен тиешенчә «тутыра» алмыйлар. Бюджет акчалары урынына бюджеттан тыш акчалар куллану тенденциясе, җәмгыятьнең төрле катлауларга тагын да ныграк бүленүе аркасында, мәгарифнең демократик системасын иҗтимагый катлаулар системасына әверелдерү куркынычын тудыра.

Бу хәл мәктәп китапханәләренең китап фондлары ярлылануга да бәйле. Дәреслекләрнең якынча 45–50 проценты 4 елдан артыграк файдаланыла, шуңа күрә дә алар бик тузган, ә уку басмаларының 25 проценты эчтәлек ягыннан искергән. Мәктәп китапханәләренең китап фондлары соңгы 5 ел эчендә кими бара һәм белем алу сыйфатына тискәре йогынты ясый. Үз чиратында белем бирү һәм әхлак-тәрбия сыйфатының начарая баруы җәмгыятькә зур зыян китерә. ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, хәзерге яшьләрнең интеллекты буенча Русия дөньяда 50 нче урында тора, димәк, безне инде Венесуэла, Ливан, Кувейт кебек илләр дә узып киткән. Без мәгарифкә милли керемнең 10 процентын тоткан елларда Галәмгә очтык. 1970 елда без гомуми халык санына карата студентлар саны буенча дөньяда 2 нче урында тора идек (АКШтан соң), ә хәзер 15 нче урынга тәгәрәдек.

## Милли-төбәк компоненты предметлары буенча дәреслекләр һәм уку-укыту методик әсбаплары

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Закон кабул ителүгә бәйле рәвештә республикада татарча укытучы мәктәпләр саны артты. Татар теле рус телле мәктәпләрнең дә уку-укыту планнарына кертелде, нәтиҗәдә республика укучыларының 99 проценты татар телен өйрәнә башлады. Моның өчен, билгеле, барлык мәктәпләрне дә татар телендә кирәкле дәреслекләр һәм уку-укыту методик әсбаплары белән тәэмин итү кирәк.

Соңгы дистә ел эчендә безнең җәмгыятебез, татар дөньясы танымаслык булып үзгәрде. Дөрес, бу үзгәрешләрнең барысы да без теләгәнчә уңай якка гына булмады. Әмма күзгә күренеп торган иң зур казанышыбыз – сүз иреге, матбугат хөрлеге һәм милли аңның үсүен беркем дә инкяр итә алмас. Менә шушы казанышларыбызны булдыру юлында иң авыр йөкне тартып баручыларның берсе – «Мәгариф» милли нәшрияты иде.

Үз милли мәгариф системасын булдырмаган халыкның киләчәге юклыгын исбатлап тору кирәк түгелдер. Безнең халкыбыз һәрвакыт белемгә омтылган, һәм шушы омтылыш аны бетү-югалудан саклап калган. Шуңа күрә, «Мәгариф» нәшрияты ачылгач, милләтебез өстәмә бер куәт, яңа сулыш алган кебек тоелды. Без, ниһаять, үз дәреслекләребезне үзебезчә язып, үзебезчә бизәп, үзебезчә бастыру мөмкинлегенә ирештек. Нәшрият хезмәткәрләре, бүгенге заман мәктәбенең, бүгенге заман баласының ихтыяҗларын җентекләп өйрәнеп, республикабыз һәм милләтебез алдына куелган олы бурычларны истә тотып, үз эшләрен бик тиз арада җайга салдылар.

Дөрес, әле бугаздан алып торган финанс һәм кадрлар кытлыгы, полиграфик мөмкинлекләрнең чикле булуы, Татарстаннан читтә татарлар яшәгән өлкәләр белән элемтәләр кимүе нәшрият җитәкчеләрен һәрчак бимазалап, борчып тора. Бу мәсьәләләр хәл кылынмыйча торып, татар милләтен бер мәгариф системасына кертү, бер рух тирәсенә туплау, бербөтен милләт итүнең мөмкин түгеллеге барыбызга да яхшы мәгълүм.

Дөньяның алга киткән илләре тәрәккыяткә ирешү юлында иң беренче адымнарын мәгарифкә игътибарны арттырудан башлаганнар. Чөнки теләсә кайсы җәмгыятьнең төп бурычы – кеше тәрбияләү, аң-белемле, итагатьле, вөҗданлы һәм оста һөнәрле шәхес үстерү икәнне яхшы белгән алар.

Хәзер республиканың барлык гомумбелем учреждениеләрендә күпчелеге «Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән төбәк дәреслекләре кулланыла. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре белән тәэминителеш 100 процент тәшкил итә, ә татар теленә тәрҗемә ителгән федераль дәреслекләр белән 60 процент кына. Тәрҗемә ителгән дәреслекләр җитмәү Русия нәшриятларыннан гаять кыйммәт торучы лицензия хокукы алу кыенлыклары белән аңлатыла. Республика мәктәпләрен төбәк дәреслекләре белән тәэмин итү буенча гамәлдәге проблемаларны хәл итү өчен Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан төбәк дәреслекләре турында закон проекты әзерләнде, анда төбәк дәреслекләрен бастырып чыгаруны һәм таратуны финанслау республика бюджетындагы якланылган аерым юл (защищённая статья) рәвешендә карала. Озакламый бу закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советында каралырга тиеш.

Татарстан Республикасында Русия Федерациясенең барлык субъектларындагы бердәм мәгариф стратегиясен чагылдыручы федераль мәгариф программасын гамәлгә ашыру белән бергә мәгарифнең милли-төбәк компонентларын әзерләүгә зур игътибар бирелә, милли-төбәк компонентын барлыкка китерүнең төп чыганагы төбәкнең табигый-географик, тарихи-мәдәни, социаль-икътисади үзенчәлегенә бәйле. Милли-төбәк компоненты төбәк мәгариф программалары, дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары аша гамәлгә ашырыла. Соңгы елларда республика мәктәпләре яңартылган уку-укыту программалары нигезендә төзелгән яңа дәреслекләр белән тәэмин ителде. Бу дәреслекләр татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, Татарстан тарихы, Татарстан географиясе һ. б. өлкәләргә карый.

Мәктәп дәреслекләрен әзерләгәндә, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы һәм нәшрият хезмәткәрләре республиканың интеллектуаль куәтен тулырак файдаланырга тырышалар. Дәреслек авторлары арасында Л. Шакирова, Р. Гарифьянова, А. Әсәдуллин, Н. Андрамонова, М. Зәкиев, Ф. Сафиуллина, А. Әхмәдуллин, А. Яхин, Ф. Галимуллин, В. Хаков, М. Әхмәтҗанов, Р. Фәхретдинов, Ә. Тайсин кебек танылган галимнәр бар. Кызганыч, дәреслек авторлары арасында әлегә яшь галимнәр күп түгел.

Полиграфик бизәлеше, иллюстрацияләре буенча төбәктәге дәреслекләр федераль дәреслекләрдән калыша. Кызганычка каршы, гомуми белем бирү мәктәпләре өчен дәреслекләр әзерләү бүгенге көндә, нигездә, Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгы һәм «Мәгариф» нәшрияты проблемасы гына булып кала бирә. Министрлык фикеренчә, мәгарифкә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТФАнең Тарих институты һәм башка бүлекчәләре тиешенчә әһәмият бирмиләр, Русия Федерациясе Мәгариф министрлыгына караган Милли мәгариф институтының татар филиалы ябылу да милли мәгариф өчен зур югалту булды. Дәреслек язу ул – бөтен җәмгыять бурычы, хөкүмәт һәм дәүләт дәрәҗәсендәге мөһим бурыч булырга тиеш.

Һичшиксез, дәреслекләр әзерләү һәм нәшер итү – хезмәтне бик күп сорый торган, техник яктан бик катлаулы эш. Бүгенге китап һәм дәреслек базары югары сыйфатлы чит ил һәм Русия

басмалары белән тулган, конкурентлык дәрәҗәсе бик югары. Әлбәттә, китапның төп мәгънәсе аның текстында, дәреслекнең эчтәлеге төп рольне уйный. Аннан соң китап карап торышка да яхшы тәэсир калдырырга һәм үтемле товар булырга тиеш. Шуңа күрә китапны бизәү һәм бастырып чыгару – бөтен бер команданың эш нәтиҗәсе, анда барысы да мөһим: камил әдәби тел, әйбәт тәрҗемә теле, төгәл терминология, яхшы дизайн һ. б.

Русия Федерациясе һәм БДБ төбәкләренең татар мәктәпләрендә Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан әзерләнгән программалар, дәреслекләр, методик һәм башка төрле әдәбият файдаланыла.

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татар балалары өчен милли, мәдәни һәм уку-укыту ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында Мәгариф министрлыгы тарафыннан татар телендәге мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итү буенча тиешле оештыру эшләре башкарыла. Ләкин бүгенге көнгә кадәр Русия Федерациясе һәм БДБнең күп кенә төбәкләрендә барлык телләүчеләрне татар дәреслекләре белән тәэмин итү мөмкин түгел (бигрәк тә Башкортстан, Төмән, Пермь өлкәләренә карый бу). Әлеге эш беренче чиратта җирле бюджетларда акча җитмәүгә, төбәкләрдәге татар мәктәпләрен уку әсбаплары белән тәэмин итүне җайга салучы тиешле программаларның юклыгына бәйле.

### Югары уку йортлары дәреслекләре турында

Фәнни-тикшеренү институтлары һәм Татарстан Республикасы вузлары галимнәре татар теле, татар әдәбияты, фольклор, сәнгать һәм татар халкы тарихы буенча гомуми белем бирү мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм уку әсбаплары булдыруда актив катнашалар, моннан тыш «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәл итү өчен табигать һәм физика-математика фәннәре өлкәсендә эшләүче 36 күренекле галим җәлеп ителде, алар махсус фәнни шурага берләштеләр, татар телендә 100 гә якын дәреслек, уку әсбаплары төзеделәр һәм нәшер иттеләр, аларның кайберләре татар телендә укыту өчен файдаланыла.

Югары уку йортларындагы китапханәләр фонды елдан-ел искерә бара һәм хәзерге заман таләпләренә торган саен азрак җавап бирә. Соңгы 7 елда югары уку йорты китапханәләренә дәүләт бюджетыннан 1 сум акча да бирелмәгән. Шул ук вакытта яңа алынган китапларның 75 проценты югары уку йортларының үз басмаларыннан тора, аларның сыйфаты тиешле таләпләргә җавап бирми. Экспертлар бәяләгәнчә, югары уку йортларында дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән тәэмин ителеш әлеге уку йортлары арасында гына түгел, дисциплиналар арасында да бик нык аерыла. Психология, икътисад, социология, чит телләр, культурология, фәлсәфә, тарих, сәясәт белеме, хокук фәннәре буенча югары уку йортлары китапханәләре бигрәк тә нык мохтаҗлык кичерәләр. Уртача тәэмин ителеш таләп ителгән күләмнең 12–15 процентыннан артмый. Югары уку йортларының зур күпчелегендә дәреслекләр фондының 75 проценты 1975–1980 елларда чыгарылган әдәбияттан тора, ягъни алар инде күптән искергәннәр. Охшаш профильдәге югары уку йортларында укыту материаллары бастырып чыгарганда, кабатлауларны булдырмау өчен координация һәм мәгълүмат үзәге булдыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Бу – югары уку йортларына басмалар чыгару өчен акчаны да, вакытны да янга калдырырга мөмкинлек бирер, аларның сыйфатын да күтәрер иде.

### Чуваш, удмурт, мари һәм мордва мәктәпләре өчен дәреслекләр турында

Соңгы елларда республикада милли мәгарифнең үсешенә бәйле рәвештә шулай ук чуваш, удмурт, мари һәм мордва этник-мәдәни компонентлары булган мәктәпләр саны артты. Әмма әлеге мәктәпләр өчен дәреслекләр җитешми. Бүгенге көндә удмурт, мари, мордва нәшриятларында дәреслекләр чыгару эшендә планлылык юк, эзлеклелек сакланмый. Болар барысы да әлеге мәктәпләрдә уку-укыту барышына тискәре йогынты ясый. Укучыларны рус телле мәктәпләргә караганда түбәнрәк халәттә калдыра. Әлеге нәшриятларның дәреслекләре ирекле сатуда юк,

аларны бары тик заказ белән генә алдырырга мөмкин. Аеруча мордва телендәге дәреслекләр белән хәл катлаулы.

## Мәктәп китапханәләрен әдәби, тармак һәм фәнни-педагогик әдәбият белән тәэмин итү проблемалары һәм аны яхшырту юллары

Китапханә фондларының ярлылануы һәм әдәби тармак, фәнни-педагогик әдәбият белән тәэмин итүнең канәгатьләнмәслек булуы мәгарифне җитәрлек финансламауның аяныч нәтиҗәсе.

Соңгы 10 ел эчендә мәктәп китапханәләре фонды бөтенләй диярлек яңартылмады. Республика мәктәпләрендә әдәби фондның торышы түбәндәгечә:

рус телендәге әдәбият – 9874617 нөсхә (1994 ел белән чагыштырганда 8 процентка кимрәк);

татар телендәге әдәбият – 3272964 нөсхә (1994 ел белән чагыштырганда 3 процентка кимрәк).

Барлык гомуми белем бирү учреждениеләрендә дә рус телендәге чит ил әдәбияты, чит ил язучыларының, Русия язучыларының, шулай ук рус һәм татар әдәбияты классикларының әсәрләре аз. Мәктәпләргә белешмә, фәнни-өйрәнү, педагогик әдәбият, дөньяви классика буенча тәнкыйди әдәбият, музыка, сәнгать тарихы буенча әдәбият җитми. Галимнәр яшь кешенең интеллектуаль яктан формалашуы өчен кимендә 250 ләп китап кирәк дип саный. Урта мәктәпләр һәм вузларның түбән курсларында укучылар өчен дә уку-укыту программасын үзләштерергә нәкъ шулкадәр җитди әдәбият кирәк.

Татарстанда 2419 мәктәп китапханәсе бар. Татарстан китапханәләренең проблемалары гомумрусиянекенә охшаш. Русия Федерациясендә 65 мең мәктәп китапханәсе исәпләнелә. Бу – дөньядагы иң зур китапханәләр челтәре. Әмма мәктәп китапханәсенең мәгариф системасындагы урынын һәм ролен аңлау Русиядә дә, Татарстанда да җитәрлек түгел әле. Бөтен дөньяда бүген мәктәп китапханәләрен укытучыларның һәм укучыларның ихтыяҗларын тәэмин итә торган мәгълүмат үзәкләренә, медиатекаларга әверелдерү эше бара, ә Русия китапханәләрендә компьютер техникасы түгел, хәтта гади генә китаплар һәм дәреслекләр белән тәэмин итү проблемасы да хәл ителми.

Соңгы 10 ел эчендә илдәге икътисади һәм социаль үзгәрешләр мәгарифкә мөнәсәбәтне тулысынча үзгәртте. Җәмгыятьне мәгълүматлаштыру процессының йогынтысы күзгә күренеп арта. Бу, беренче чиратта, китапханәләрнең материаль-техник базасын ныгыту һәм аларны мәгълүмат туплау максатларында үзгәртүне таләп итә. Русиянең Мәгариф министрлыгында нәкъ шул максаттан дәреслекләр, китапханәләр һәм медиатекалар идарәсе оешты. Квалификацияне күтәрү институтларында китапханә эше, фәнни-ысулый үзәкләр барлыкка килә, шулай ук мәктәп китапханәләренә ысулый ярдәм күрсәтүче китапханә белгечләре әзерләнә.

Бүгенге шартларда мәгарифнең, дәреслекләрнең, әдәби һәм тармак әдәбиятларының сыйфатына таләпләр арта. Шуңа бәйле рәвештә мәктәп китапханәләрен китаплар белән тәэмин итү, Татарстанда нәшер ителүче дәреслекләрнең сыйфатын күтәрү тиз арада хәл ителергә тиешле иң мөһим мәсьәлә булып тора.

Яшь буынга сыйфатлы белем биреп кенә язылган һәм язылмаган законнарны ихтирам итә торган милләтпәрвәр шәхес, туган иленә, туган халкына тугрылыклы хезмәт итүче, җәмгыятькә файдалы, намуслы һәм гадел кеше тәрбияләргә мөмкин.

*2001*

# ИСТАНБУЛДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ[1]

Кояшлы Төркия җөмһүрияте җиренә чираттагы тапкыр аяк басып, Татарстан парламенты әгъзасы буларак, бүген шушы олы мөнбәрдән сезнең барыгызны да, республикабызның Президенты М. Ш. Шәймиев, Дәүләт Советы һәм хөкүмәтебез исеменнән кайнар сәламлим. Ата-бабаларыбыздан мирас булып калган уртак туганлык һәм дуслык традицияләребез югалмас, киләчәктә дә дәүләтләребез, татар һәм төрек милләтләре арасында сәяси һәм икътисади, мәдәни һәм әдәби, рухи багланышлар өзелмәс, киресенчә, яңа югарылыкка күтәрелеп, ныгыр һәм тагын да файдалырак нәтиҗәләр китерер дигән ышаныч белдерәм.

Татар язучыларының бер вәкиле, әдәби хәятка һәм милли сүз сәнгатенә, китап дигән изге затка аеруча якын торган кеше буларак, бүгенге бәйрәм, бу тантаналар минем күңелемдә иң куанычлы һәм бер үк вакытта дулкынландыргыч хисләр өермәсен кузгатты. Туган халкым әдәбиятының шушы рәвешчә дөньяга таныла баруы бер минем өчен генә түгел, теләнә, әдәбиятына, мәдәниятенә мәхәббәт һәм ихтирам саклаган һәр татар кешесе өчен ни дәрәҗәдә шатлыклы күренеш икәнлеген әйтеп-аңлатып торуның кирәге дә юктыр дип беләм.

Без өченче меңьеллык бусагасын атлап керсәк тә, әдәбиятыбызның үз ел исәбе. Төгәлрәк итеп әйткәндә, сүз сәнгатебезнең унбиш гасырлык тарихы бар. Әле 922 елда Болгар дәүләтенә килгән гарәп сәяхәтчесе, елъязмачысы Әхмәд ибне Фазлан биредә мәктәпләр, мәчетләр булуы турында, гарәп язуының кулланылуы хакында теркәп калдыра. Мәктәп-мәдрәсәләр булган икән, димәк, аларда укучыларның күңеленә матур тәэсир ясауга исәп тотылган, сәнгатьчә алымнар белән язылган әсәрләр дә булган дигән сүз. Бу очракта без инде төрки халыклар өчен уртак булган гомуми язма ядкярләр турында әйтеп тә тормыйбыз. Гомумтөрки, Борынгы Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларындагы әдәбиятыбыз сәхифәләре хәзерге көнгә кадәр килеп җиткән бәхетле милләт без. Димәк, моннан мең еллар элек тә борынгы кавемнәребез затлы, мәдәниятле, язулы-китаплы булган. Шуңа да алардан начарлык, явызлык орлыклары чәчелеп калмаган, гыйлем, мәгърифәт һәм сүз энҗеләре безгә мирас булып килеп ирешкән.

Озын тарихлы татар әдәбияты чишмәсенең башы халык авыз иҗатына барып тоташа. Болгар бабаларыбызның килеп чыгышына, гореф-гадәтләренә һәм күрше халыклар белән мөнәсәбәтләренә караган риваятьләр, кыйссалар борынгы гарәп-фарсы, урыс чыганакларында һәм болгарларның үз әсәрләрендә дә теркәлгән. Ул риваятьләр халык аңында бүген дә яшиләр.

Татар халкының борынгы авыз иҗаты үзенең үсешендә күп кенә башка төрки кабилә һәм халыкларның фольклоры белән бәйләнешкә кергән, безнең бабаларыбыз аларның фольклор әсәрләре белән таныш булган. Күроглы, Алпамша, Кузы Күрпәч, Таһир-Зөһрә турындагы эпос һәм легендаларның татарлар арасында җирле төрдәшләре иҗат ителү шул хакта сөйли.

Халык авыз иҗаты язма әдәбият үсүенә нигез булган. Бик борынгы төрки фольклор үрнәкләре һәм шулар нигезендә туган язма әдәбият башлангычлары тел кардәшлегендә булган халыкларның уртак мирасы итеп карала. Язмачылык традицияләре борынгы булган төрки әдәбиятлар шушы уртак тамырлардан үсеп тармакланган. Руник һәм уйгыр язулы Орхон-Енисей ядкярләре, юрау рәвешендәге һәм үгет-нәсыйхәт әсәрләре, «Котадгу белек» кебек дидактик истәлекләр, «Диване лөгатет-төрк»тәге үрнәкләр, төрки халыкларның уртак байлыклары буларак, һәркайсы әдәбият тарихында урын алган, ул әдәбиятларның үсешенә тәэсир иткән һәм аларны үзара бәйләп торган. Шундый йогынты һәм бәйләнешләр эчендә татар әдәбияты һич тә үзенең мөстәкыйль йөзен югалтмаган, камилләшә-камилләшә үзенчәлекле, бай традицияле зур әдәбият булып формалашкан.

Идел буе болгарларында ислам дине рәсми төс алгач, Гарәп көнчыгышыннан, Иран һәм Урта Азиядән килгән язма китаплар арасында дөньяви эчтәлекле, фән һәм матур әдәбият әсәрләре дә аз булмаган. Фирдәүси, Низами, Сәгъди әсәрләренең, «Мең дә бер кичә», «Кәлилә вә Димнә»

хикәятләренең халыкка бик электән таныш булуы шул хакта сөйли. Гарәп һәм фарсы әдәбиятлары аша халкыбыз антик дөнья, борынгы Юнан, Византия мәдәният җимешләре белән дә танышкан. Татар әдәбияты тарихында гарәп-фарсы телле әсәрләр хәтта аерым катламны тәшкил итә.

Шундый әдәби җирлектә шагыйрь Кол Галинең нәфис әдәбият казанышы булган «Кыйссаи Йосыф» әсәре иҗат ителә. Ул татар әдәбиятының бөтен тарихы буена поэтик үрнәк булып килә. Аның традицияләренең бүгенгә кадәр дәвам итүе әсәрдәге сәнгать чараларының һәм гомумкешелек идеяләренең тормышчанлыгы хакында сөйли. Урта гасырларда Идел буеның иң күренекле иҗат җимеше булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тулысынча сакланып калган һәм ул татар халкының күңелендә, йөрәгендә иң мактаулы урын алган.

Болгар һәм Казан ханлыгы чорлары арасында шаулап үскән Идел-Урал буе язма әдәбияты мәдәни мирасыбыз тарихында гаять зур әһәмияткә ия. Ул үзенә кадәрге төрки Шәрык рухи казанышларын мул файдалану, аларны иҗади үзләштерү нәтиҗәсендә туган һәм үскән. Алтын Урда – халкыбыз тарихының ике гасырлык гадәти тарихы гына түгел, ә татарны татар иткән тиңдәшсез бер чор да ул. Алтын Урда әдәбиятының үзәгендә кеше, аның эчке дөньясы, эш-гамәле, җәмгыять һәм табигать белән бәйләнешләре. Ул, гадәттә, мөселман, Аллаһыга ышанучы зат. Бу чор әдипләре – Котб, Харәзми, Сәйф Сараи, Рабгузи, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб – белемлелек, әдәплелек, итагатьлелек, шәфкатьлелек, сабырлык кебек сыйфатларны кеше идеалының мөһим өлешләре итеп санаганнар. Аларның фикер-кичерешләргә бай шигъри юллары – поэтик камиллекләре, гармоник яңгырашлары белән классик әдәбиятыбызның матур үрнәкләре. Шуны күрәбез ки: Алтын Урда чоры язма мәдәнияте үзенең үсеше, эстетик байлыгы, поэтик дәрәҗәсе белән үз дәверенең алдынгы әдәбиятлары югарылыгында торган. Ә инде XIV йөздә ул төрки дөньяның әйдәп баручы үзәгенә әверелә. Госманлы әдибе Әхмәдигә, үзбәк шагыйре Лотфыйга, азәрбайҗан классигы Нәсимигә Алтын Урда әдәбиятының шифалы тәэсире үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Казан ханлыгы чоры язма мәдәниятендә үзенең үлемсез «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» әсәрләре белән бөек шагыйребез Мөхәммәдьяр йолдыз булып балкый. Ул Урта гасыр ислам мәдәнияте һәм Европадагы Яңарыш чоры ирешкән фәлсәфи тәгълиматларга аваздаш кыю фикер-карашлары белән мәйданга чыга. Аның әдәби иҗаты кешелек цивилизациясен үзенең ачышлары, казанышлары белән баеткан ислам мәдәниятенең гүзәл мирасы булу бездә тирән горурлык хисе тудыра. Чыгышы белән төрек халкы вәкиле булган шагыйрь Өмми Камал иҗаты Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Ул – бер халык әдибенең икенче бер халык әдәбиятына да бер үк дәрәҗәдә хезмәт итеп, аның да аерылгысыз вәкиле булып китүенә ачык мисал. Ханлыкның мәшһүр дин эшлеклесе сәет Колшәриф тә безгә шагыйрь буларак билгеле.

Дәүләт мөстәкыйльлегенә ия булу рухи үсешне алга әйдәүче көч булып тора. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында үсешнең зур булуы аңлашыла, чөнки бу дәүләтләр чын мәгънәсендә мөстәкыйль иде.

Алтын Урданың таркалуы, бераздан аңа нигезләнеп туган татар ханлыкларының да бетерелүе Идел-йортның мәдәниятенә коточкыч зур зыян китерде: элеккеге казанышларның күпчелеге юкка чыкты, яңаларын тудыру өчен шартлар җитмәде. Әмма шуңа да карамастан борынгы төрки, болгар чыганаклары белән азыкланган, гарәп-фарсы әдәбиятыннан көч-куәт алган Алтын Урда мәдәни традицияләре тәмам өзелмәде.

Иҗатларында әдәби традицияләр дәвамчанлыгын саклап, яңа буын әдипләргә тапшыра барган XVII йөз шагыйре Мәүла Колый, татар шигъриятенең инде югала башлаган биеклеген XVIII–XIX гасырлар чигендә кабат кайтарган Габдерәхим Утыз Имәни, аңардан соң мәйданга чыккан Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, Габделҗәббар Кандалый исемнәрен атау, һичшиксез, күңелдәге горурлыкны тагын да арттыра. XIX йөз – XX йөз башы татар әдәбияты тагын Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Заһир Бигиев, Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Кәрими, Шакир Мөхәммәдев, Закир Һади, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла исемнәре белән дә билгеле.

XX йөз башындагы татар мәдәнияте яңарышы иң беренче чиратта дөньяда бары тик 27 ел гына яшәп, бинихая зур иҗат мирасы калдырган бөек талант иясе, милләткә фидакярләрчә хезмәт

иткән мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукайдан аерылгысыз. Соңгы дистә елда халкыбызга кабат әйләнеп кайткан (Төркия Җөмһүриятенең һәм төрек халкының да олуг ярдәм-булышлыгы белән) Гаяз Исхакый иҗаты үзе ни тора! Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал кебек язучы, шагыйрь, драматургларыбызның татар әдәбияты тарихында күренекле урыннары бар.

Татарстанның автономияле республика булып яши башлаган чорларыннан соңгы әдәбиятыбыз үсешен дә һичничек инкяр итеп булмый. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» татар шигъриятен дөньякүләм яңгыратты. Шагыйрьләр Һ. Такташ, Ф. Кәрим, С. Баттал, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин; прозаиклар М. Галәү, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, А. Расих, Р. Төхфәтуллин, Ә. Еники, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев; драматурглар К. Тинчурин, М. Фәйзи, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Т. Миңнуллин һ. б. бик күпләр XX гасыр сүз сәнгатебез үсешенә гаять зур өлеш керткән иҗат көчләре булдылар.

Татар язучылары гомер-гомергә халык, милләт мәнфәгатьләрен алга куеп иҗат иттеләр, бик катлаулы хәлләрдә дә кыйблаларыннан тайпылмадылар.

Татар әдәбиятының үткән юлын кыскача яктырткан бу «сәяхәт»тә татар һәм төрек мәдәниятләренең, әдәбиятларының үзара багланышы аз гына күләмдә булса да чагылыш тапты. Төрек һәм татар халыкларының килеп чыгышында, кавем буларак оешуында бер үк төрки катламның хәлиткеч роль уйнавы – бәхәссез хакыйкать. Озак еллар буе үзара аралашу нәтиҗәсендә этник уртаклыкка нигезләнгән тел якынлыгы, мәдәни охшашлык тагын да арта, тагын да көчәя төшә. Колониаль изүгә дучар ителгән дәвердә дә татарлар төрекләр белән рухи элемтәләрен саклап калырга тырышалар. Кызганыч ки, Октябрь инкыйлабыннан соңгы 60–70 ел эчендә ике арадагы традицион багланышлар тәмам бетү дәрәҗәсенә җитте. Рәсәйдә һәм Татарстанда иҗтимагый-сәяси вазгыять үзгәрүнең нәтиҗәсе буларак, XX гасыр азагында төрек-татар багланышлары янә җанланып, көчәеп китте. Бу дәүләтләребез алып бара торган сәясәткә дә, аерым затларның фидакяр эшчәнлегенә дә бәйле.

Татар язучыларының әсәрләре – Төркиядә, төрек әдипләренең һәм галимнәренең әсәрләре, фәнни хезмәтләре Татарстанда тәрҗемә ителеп дөнья күрә, уртак гыйльми тикшеренүләр алып барыла. Шушы уңайдан бер мисал китереп үтәсем килә. Төркиянең Мәрмәрә университетындагы тюркологик тикшеренүләр, ягъни бөтен төрки дөньяны өйрәнү белән шөгыльләнә торган институтны безнең милләттәшебез, хөрмәткә лаек галим Надир Дәүләт җитәкли. Ул үзе дә Рәсәйдә яшәүче төрки халыкларның тарихына, мәдәниятенә караган кызыклы эзләнүләр алып бара, әһәмиятле хезмәтләр бастыра. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе аның «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917 еллар)» дигән фәнни хезмәтен татар теленә тәрҗемә итеп, 1998 елда Казанда бастырып чыгарды. Бу китапның дөнья күрүе Татарстанның фәнни даирәләрендә мөһим бер вакыйга буларак кабул ителде.

Күпсанлы фәнни-гамәли конференцияләр, әдәби-мәдәни корылтайлар, сәнгать бәйрәмнәре бик еш ике милләт вәкилләренең уртак катнашлыгында уза, милли театрларыбыз фестивальләргә, гастрольләргә йөрешә, ике дәүләт халыклары өчен дә файдалы китап күргәзмәләре оештырыла, мәгариф өлкәсендә дә хезмәттәшлек ныгый бара: Татарстанда төрек лицейлары, гимназияләре эшли, яшьләребез Төркия уку йортларында белем ала, Төркиядән килеп тә Татарстан югары уку йортларында укыйлар, республикабызда татар һәм төрек телләрендә «Заман-Татарстан» газетасы нәшер ителә, «Тюрксой» халыкара оешмасы эшчәнлеге кысаларында мәдәниятләребезне үстерү буенча күп гамәлләр тормышка ашырыла, Татарстан Милли китапханәсе Төркия Милли китапханәсе һәм Төркиядәге берничә университетның китапханәләре белән даими рәвештә китаплар алмашып тора, Татарстанның һәм Төркиянең Дәүләт архив хезмәтләре арасында төзелгән килешүләр нигезендә ике халыкның да тарихына караган кыйммәтле документлар ачыклана, архив хәзинәләре аларның күчермәләре белән тулылана, Төркиядә яшәп эшләгән, иҗат иткән мәшһүр татарлар Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура һәм башкаларның мираслары халкыбызга кайтарыла. Болар – рухи-мәдәни багланышларыбызның гомумиләштереп саналган кайбер чаралары гына әле.

Безнең мәсләк ачык – рухи яктан бер-беребезне баету, күңелләребезне аңлау аша туганлыкны ныгыту. Бу исә куллана торган язуларыбызны аңлаешлы итү, әдәби һәм сәнгати әсәрләр алмашу, дини асылыбызга кайту, шулар ярдәмендә затлы төрки традицияләрне мөмкин кадәр торгызу. Алар, билгеле булганча, гомумкешелек кыйммәтләренең олы диңгез-океаннарына барып тоташа.

Бу көннәрдә Төркиянең бай тарихлы, олы мәдәниятле мәшһүр шәһәре Истанбулда уза торган Татар әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре – менә шуның ачык мисалы.

*2001*

# АҢЛАШЫП ЯШӘҮГӘ НИ ҖИТӘ?

Бүгенге Татарстан җирендә борын-борыннан, нигездә, төрки һәм фин-угыр халыклары яшәгән. Татарлар, башкортлар, болгарлар, чувашлар, кыпчаклар, хазарлар, марилар, удмуртлар, мукшылар, эрзялар – бу җирләрдә абориген халыклар.

Тарихи мәгълүматлары безгә килеп җиткән соңгы мең-мең ярым ел эчендә бүгенге Татарстан җирләрендә янәшә гомер иткән әлеге халыклар арасында бер генә сугыш булуы да билгеле түгел. Алар гомер-гомергә бер-берсе белән килешеп, бер-берсен аңлап, бер-берсенең гореф-гадәтен, яшәү рәвешен, динен, телен, җырын хөрмәт итеп яшәгәннәр. Мин моны бүген без фикер алыша торган этник һәм дини толерантлыкның ачык бер мисалы, тарихи нигезе дип бәяләр идем.

Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач һәм бүгенге Татарстан җирләренә Россиянең үзәк өлкәләреннән рус крестьяннары күчереп утыртылгач, мондагы халыклар инде руслар белән янәшә яши башлыйлар. Баштагы елларда бу янәшә яшәү җайлы гына, тавыш-тынсыз гына бармаган. Рус крестьяннары күчереп утыртылган урыннарда үзара бәргәләшү, корал тотып сугышу очраклары еш булып торган. Бу бәрелешләр ундырышлы табигатьле Идел, Кама һәм башка елга ярларындагы татар авылларын читкә сөреп, аларга рус крестьяннарын күчереп утырту, татар кешеләренә Казан шәһәренең үзәк өлешендә яшәүне тыю, булган мәчетләрне җимерү һәм яңаларын төзүне тыю, абориген халыкларны көчләп христиан диненә күчерү аркасында килеп чыккан. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: гаять зур милли һәм дини кысуларга дучар ителгән татар халкының Казанда һәм Зөя каласында күпләгән чиркәү, монастырьлар салуга каршы кораллы көрәш белән чыгулары яки бунт күтәрүләре тарихта билгеле түгел. Бу күренешне, әлбәттә, татар халкының Алтын Урда чорыннан ук килгән толерантлык традицияләрен дәвам итүе дип бәяләргә була.

Бүгенге көндә татар халкының һәм Татарстандагы башка абориген халыкларның Татарстан Республикасы халкының 43 процентын тәшкил иткән рус халкы белән янәшә тыныч яшәве – әнә шул түземлелек, гасырлар буена урнашып килгән аңлашып яшәүне дәвам итү нәтиҗәсе ул.

Татар халкы бүген дә Татарстандагы абориген халыклар белән тугандаш, якын күршеләр булып, кыен вакытта бер-беренә ярдәм итешеп яши. Безнең республикада бу халыкларның йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары, дистәләгән милли мәктәпләре, балалар бакчалары эшли, газеталары басыла, республика һәм муниципаль радио-телевидениесендә тапшырулары оештырыла. Казанда һәм бу халыклар вәкилләре тупланып яшәгән һәр районда аларның милли-мәдәни оешмалары эшли, республикада һәм районнарда оештырыла торган сәнгать фестивальләре һәм конкурсларында аларның үзешчән коллективлары һәм артистлары катнаша. Бездә татар халкының милли бәйрәмнәре белән беррәттән бу халыкларның милли бәйрәмнәре дәүләт хакимияте катнашында үткәрелә.

Республикабызга соңгы елларда килеп төпләнгән башка милләт вәкилләренең милли һәм дини үсешенә дә юллар ачык. Республиканың Милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясе ярдәме белән Казанда гына да украин, белорус, казах, таҗик, үзбәк, әрмән, төрек, азәрбайҗан, ассирия, яһүд, алман, әфган, башкорт һ. б. халыкларның милли-мәдәни җәмгыятьләре эшләп килә. Казанның Халыклар дуслыгы йортында эшләү өчен хөкүмәт аларга даими ярдәм күрсәтеп тора.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Телләр турында»гы Закон нигезендә татар һәм рус телләре Татарстанда тигез хокуклы дәүләт телләре санала. Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законы нигезендә хәзер республикадагы гомуми белем бирү мәктәпләрендә рус һәм татар телләре тигез күләмдә укытыла. Республика һәм муниципаль радио һәм телевизион компанияләр үзләренең тапшыруларын рус һәм татар телләрендә алып бара. Республикада рус телендә 102 газета-журнал басыла, ел саен йөзләрчә китап нәшер ителә. Татарстанда гомуми белем бирүче 1007 рус мәктәбе, гимназиясе һәм лицее, аерым белгечлекләр буенча 66 махсус урта белем бирү уку йортлары, 559 балалар бакчасы эшли.

Толерант җәмгыять төзү, үзара килешеп яшәү өчен иң беренче чиратта һәр кешенең, һәр милләтнең мәнфәгатьләрен тигез кайгырту, һәркемгә тигез мөнәсәбәт кирәк. Бер карашка гади кебек тоелган шушы шартларны үтәми торып, бу өлкәдә уңышларга ирешү мөмкин булмаган нәрсә.

Инде сөйләгәнемчә, без Татарстанда кулдан килгән кадәр шушы тигезлекне сакларга тырышабыз, бездә ул – гомумдәүләт күләмендә хәл ителә торган мәсьәлә, республиканың милли сәясәте. Дөрес, әлегә бар нәрсә дә ал да гөл дип әйтергә мөмкин түгелдер. Патша Россиясе вакытында да, коммунистик режим чорында да бездә күбрәк бер милләтнең мәнфәгатьләре генә алга сөрелде, ә калганнары, ассимиляция хәрәкәтенә буйсынып, үзләренең бетү, үлү көнен көтәргә мәҗбүр ителде. Әле бүген дә без бу тенденцияләрдән арындык дип әйтә алмас идем. Мәсәлән, Татарстанда ике дәүләт теле – татар һәм рус телләре – тулы хокуклы дип саналса да, дәүләт эшләрендә, югары уку йортларында, гомумән, җәмгыятьтә рус теле бик нык өстенлек итә. Безнең рус теленә бернинди дә тискәре мөнәсәбәтебез юк, әмма татар кешесенең дә, һич югында, үзенең милли республикасында үз телендә белем аласы, дәүләт белән идарә итәсе, нәфис фильмнар чыгарасы, тәүлек буе туган телендә телевизион тапшырулар карыйсы, үз теленә кулай булган имляда язасы килә...

Россия Дәүләт Думасының махсус закон чыгарып, татарларның латин язуына күчүен туктатуын без демократик җәмгыятькә хас булмаган гамәл буларак кабул иттек. Дөресрәге, без аны акылыбыз белән дә, күңелебез белән дә кабул итә алмадык. Чөнки бу антидемократик закон Россия Конституциясенә каршы килеп кенә калмый, ә халыкара хокук нормаларын боза, кеше хокукларын чикли. Татарларның латин язуына күчәргә теләвен Мәскәүнең кайбер даирәләрендә бу Россияне таркатуга китерәчәк дип аңлатырга тырыштылар. Монысы инде бөтенләй сафсата! 1552 елны Казан ханлыгы җимерелеп, рус дәүләте эчендә яши башлаганнан бирле татарлар 400 елга якын гарәп имлясында язсалар да, Россия таркалмады бит. Ә нишләп татарлар латинга күчкәч кенә җимерелергә тиеш икән соң ул? Аннары ... татар алфавитына гына таянып торган дәүләт нинди дәүләт ди инде ул?!

Кеше заты Аллаһы Тәгалә тарафыннан шундый итеп яратылган инде – ул бары тик үзен хөрмәт иткән кешене генә хөрмәт итә ала. Әгәр дә ике милләт вәкиле озак еллар буе янәшә яшәп тә бер-берсен хөрмәт итәргә өйрәнмәсә, арадан берсе күбрәк хөрмәткә ия булса, киләчәктә моның күңелсез нәтиҗәләргә китерүе мөмкин. Тыштан килешеп, ризалашып яшәгән кебек күренсәләр дә, арадан берсенең – хокуклары кимрәк булганының – күңел түрендә үпкә, рәнҗү хисе яшеренеп ятачак. «Карале, – дип уйлаячак ул, – мин аның телен дә яхшы беләм, тарихын, гореф-гадәтләрен, динен дә хөрмәт итәм. Ә ул минем телемдә исәнләшә дә белми, тарихымны санга сукмый, гореф-гадәтләремне, динемне хөрмәт итми. Димәк, ул мине үзенә тиң санамый...» Дус яшәү, тату яшәү өчен безгә иң беренче чиратта бер-беребезне хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк. Ә хөрмәт итү өчен бер-береңне яхшы белү шарт.

Соңгы елларда Россиядә һәм дөнья күләмендә ислам диненә «террорчылар» кушаматы тагарга тырышу, исламнан бары тик яманлык кына эзләү дә күпмилләтле һәм күп динле җәмгыятьнең нигезен какшата, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да ныграк катлауландыра.

Татарлар – Россиядә руслардан кала сан ягыннан икенче урында торган халык. 7 миллионлы татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши, ә калганнары үзләренең тарихи ватаннары булган төбәкләрдә – Россиянең төрле республикаларында һәм өлкәләрендә гомер кичерә. Инде әйткәнемчә, Татарстанда бөтен милләт вәкилләре өчен һәммә яклап тигез шартлар тудырылса да, Россия төбәкләрендә милли мәсьәлә бик тә берьяклы хәл ителә. Мәсәлән, Казанда яшәүче 500 мең рус кешесе өчен үз туган телләрендә эшләүче меңләгән балалар бакчалары һәм мәктәпләр, дистәләгән югары уку йортлары, театрлар, радио-телевидение тапшырулары – һәммәсе дә бар. Без моны күпсенмибез, бу бик яхшы дип уйлыйбыз, киләчәктә дә шулай һәммә халыкның мәнфәгатьләрен тигез кайгыртырга тырышачакбыз. Хәзер инде мисал өчен Россия башкаласы Мәскәүдәге хәлләргә күз салыйк. Бүгенге көндә Мәскәүдә дә, Казандагы руслар кебек, 500 мең чамасы татар яши. Ә шул 500 мең татарның милли мәнфәгатьләрен кайгырту мәсьәләсе анда ничегрәк хәл ителә соң? Мәскәүдә бүген милли компонентлы 1 кечкенә татар мәктәбе,

шундый ук 2 балалар бакчасы бар һәм шуның белән вәссәлам! Татар театрлары юк, татар радиосы, телевидениесе юк, татарча чыгучы газета-журналлар юк. Татар кешесе дә башка ватандашлар белән бер үк күләмдә налог түли, татар кешесенең дә башкалар белән тигез хокуклы булырга хакы бар бит югыйсә.

Көнбатыш илләренә, бигрәк тә Америкага барып чыккач, без андагы халыкның үз иленә, үз дәүләтенә ихтирамын күреп, патриот булуына гаҗәпләнәбез. «Ә без нишләп шулай патриот түгел икән?» – дип баш ватабыз. Монысының да җавабы бик гади: кеше дәүләтне ихтирам итсен өчен иң элек дәүләт кешене ихтирам итәргә тиеш! Безнең халыкта моны «Кунак ашы – кара-каршы» диләр. Кеше кадере булмаган җирдә илнең, дәүләтнең дә кадере юк. Толерантлык ул кеше белән кеше арасында аңлашып, килешеп яшәү генә түгел, ә дәүләт белән кеше арасындагы шундый ук үзара ихтирамлы мөнәсәбәт тә бит әле.

Бүген сөйләшә торган мәсьәлә – дөнья күләмендә иң мөһим һәм иң катлаулы мәсьәләләрнең берседер. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен әле озак еллар, хәтта гасырлар кирәк булачак. Әмма Җир шары дип аталган шушы түгәрәк йортыбызда безнең килешеп, аңлашып яшәүдән башка юлыбыз юк.

*2002*

# ВАТАНДАШСЫЗ ДӘҮЛӘТ БУЛМЫЙ

Без бу көнне бик тә борчылып һәм хәвефләнеп, шомланып һәм өметләнеп көттек. Халык депутатлары һәм республика җитәкчеләре генә түгел, бөтен Татарстан халкы, дөньядагы барча татар халкы шулай көтте бу көнне.

Менә инде ике ел буе Русия үзенең бөтен дәүләти куәтен, сәяси арсеналын милли республикаларга каршы көрәшкә юнәлтте, халыкларның барлы-юклы хокукларын чикләүгә, әле яңа тернәкләнә башлаган демократия чаткыларын сүндерүгә багышлады.

Русиянең иң югары закон чыгару органы булган Дәүләт Думасы үзенең кайбер җитәкчеләре авызыннан «күпмилләтле дәүләтнең бәла булуы, киләчәктә милли республикаларның бетәргә тиешлеге» хакында игълан итте. Күп тә үтмәде, әлеге идеяне тормышка ашыру максатыннан Русия Конституциясендә булмаган законсыз округлар оешты һәм Идел-Урал төбәгендәге милли республикаларның башкаласы итеп өлкә шәһәре Түбән Новгород билгеләнде. Бу гамәл, билгеле, безнең өчен көтелмәгән нәрсә булмады, ул тулысы белән патша Русиясенең һәм коммунистик режимның милли сәясәте һәм империячел идеологиясе традицияләрен дәвам итүгә корылган иде. Казан каласының Аурупа белән Азия арасындагы капка булуы, аның ил күләмендә әһәмиятле стратегик җирдә урнашуы хакында инде күп сөйләнде, моның шулай икәнлеген Мәскәүдә дә, хәтта чит илләрдә дә таныйлар. Тануын таныйлар, әмма Мәскәүдән Казанны күрмәмешкә салышалар, читләп үтәргә тырышалар. Уйлап карагыз әле: менә шул стратегик урында урнашкан Казанда Русиянең нинди стратегик, илкүләм мөһим үзәге бар?

Тимер юл һәм елга флоты үзәкләре – Горькийда (Түбән Новгородта), һава юлы үзәге гомер-гомергә Самарада булды, хәрби округ үзәге Свердловскида һәм Самарада урнашты, хәтта Казанның атаклы хәрби училищеларын да өлкә шәһәренең филиалларына әйләндереп калдырдылар. Мондый фактларны бик күпләп санап булыр иде... Димәк, Русия безгә, милли республикаларга ышанмый. Үзе Мәскәүгә берсүзсез буйсынуны, Мәскәүне һәм Русияне яратуны таләп итә, ә үзе беркемгә дә ышанмый һәм беркемне дә яратмый. Бу нәкъ бөек Пушкин әйткәнчә булып чыга инде:

Мой дядя самых честных правил,
Когда не в шутку занемог.
Он уважать себя заставил
И лучше выдумать не мог.

Менә инде ике елга якын Татарстан парламенты үзенең законнарын Русия законнары белән тәңгәлләштереп изалана. Билгеле, Русиянең закон кырында, закон басуында тәртип урнаштыру кирәктер. Ләкин бу тәртип бөтен Русияне бертөсле һәм тип-тигез кукуруз басуына әйләндереп калдырырга тиеш түгелдер бит?! Тәртип урнаштыру – халыкларны һәм республикаларны бер стройга, тигез рәтләргә тезеп, аларга униформа кидереп идарә итүне аңлатмыйдыр бит?! Баланың, туа-тумыштан, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән үзенчәлекләрен, үзенә генә хас мөмкинлекләрен һәм сәләтен исәпкә алмаган гаиләдән ил өчен файдалы, талантлы шәхес үсеп чыкмаган кебек, милләтләрнең һәм республикаларның, төбәкләрнең үзенчәлеген исәпкә алмаган илнең дә перспективасы юк. Әйе, Русия безне үзенең бер аерылгысыз өлеше, үз гаиләсенең бер әгъзасы дип саный. Ә үзе безгә ышанмый. Үз баласына ышанмаган, гаиләдәге бөтен бәхәсләрне бары тик йодрык һәм көч белән, суд карарлары аша гына хәл иткән «ата-анага» нинди хөрмәт, нинди ышаныч булырга мөмкин соң?

Русиянең Конституция суды үзенең карарлары белән республикаларны суверенлык хокукыннан мәхрүм итте. Ә бу хокук, бу статус безнең республикада бөтенхалык җыены – референдум белән расланган иде. Судның җинаятьчене хөкем итәргә тиешлеген беләм, ә тулы бер халыкны хөкем итәргә, үз гражданнарының хокукларын күрәләтә аяк астына салып таптарга нинди дә булса судның хокукы бармы икән?!

Шушы көннәрдә Русия Дәүләт Думасы милли республикаларның моңа кадәр булган үз гражданлыкларын тартып алырга җөрьәт итте. Ә югыйсә Русия Конституциясендә акка кара

белән, республикалар – дәүләт, дип язылган. Ә дәүләт гражданнарсыз, ватандашларсыз була алмый. Республикаларның үз гражданлыгы хәтта Сталин, Брежнев чорларында да, шәхес культы, «торгынлык» заманнарында да бар иде. Алайса, без хәзер нинди чорда, нинди каргалган заманда яшибез икән соң?!

Соңгы вакытта, милли республикаларның законнарында тәртип урнаштырам дип, Мәскәүдәге кайбер акыллы башлар үзләре дә буталып беттеләр бугай инде. Мәсәлән, Татарстан Конституциясендә моңа кадәр президентның Ярлыкау комиссиясе оештырырга хакы булуы расланган иде. Бездә президент фәрманы белән андый комиссия оештырылды, һәм ул берничә елда шактый гына игелекле эшләр эшләп өлгерде. Гаделсез хөкем ителгәннәрне ирекккә чыгарырга булышты, туры юлга баскан тоткыннарга ярдәм кулы сузды. Әмма Татарстандагы шушы игелекле комиссия суд карары белән юкка чыгарылды. Күп тә үтмәде, Русия президентының Указы чыкты, Указда исә мондый комиссияләрнең кирәклеге һәм Русия субъектларында оештырылырга тиешлеге игълан ителде. Һәм без яңадан үзебезнең президентыбыз Указы белән әле генә бетерелгән комиссиябезне терелтергә тиеш булдык. «Сул кулы нәрсә эшләгәнне уң кулы белми» дигәне шушы була торгандыр инде...

Татар алфавитын латин язуына күчерү дә һич көтмәгәндә «Русиянең дәүләт иминлегенә яный торган гамәл» булып чыкты. Шундый карарга килгән Дәүләт Думасы, Русиянең көчсезлеген танып, аны бөтен дөньяга игълан итте.

Дүрт йөз ел буе татарлар гарәп графикасында язып һәм укып та җимерелмәгән Русия, алар фикеренчә, без латин язуына күчү белән таркалырга тиеш булып чыкты. Әгәр дә эшләр шушылай дәвам итсә, Русия Дәүләт Думасында татарларга нинди дин тотарга, нинди түбәтәй кияргә, пәрәмәчне һәм бәлешне ничек пешерергә, балаларны сөннәткә ничек утыртырга өйрәткән яисә аларны тыйган яңа законнар чыгуы да бик мөмкин әле. Сәяси һөҗүмнәр, икътисади һәм салым тышаулары кидерү, суд һәм прокуратура атакаларыннан соң республиканы, татар халкын эчтән таркату хәрәкәте – диверсия эшләре башланды. Моның өчен иң кулай чара итеп чираттагы халык санын алуны файдаланырга булдылар. Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты хөкүмәткә бер татардан биш-алты татар милләте ясау турындагы документ әзерләп бирде. Тиз арада милләт ясап, шул ясалма милләтнең башлыгы булырга хыялланган кайбер кайнар башлар Мәскәү һәм Түбән Новгород юлын таптый башладылар. Милли республикаларның һәм әле бүгенгә кадәр яшәп килгән милләтләрнең дә мәнфәгатен кайгыртмаган, кайгырту урынына аларның Русиягә бары тик бәла генә китерүен тәкрарлаган, аларның киләчәген шик астына куйган Мәскәү даирәләренең типтәр яисә ногайбәк, мишәр яисә керәшен, әстерхан яисә себер татары язмышы өчен борчылуын һәм кайгыртуын мин күз алдына китерә алмыйм. Татар халкы – бик күп кавемнәрне берләштергән, заманында берничә дәүләт төзегән борынгы һәм бердәм халык. Без бер-беребезне ихтирам итеп, бер-беребезгә булышып, тарихи бердәмлегебезне киләчәктә дә саклап калырбыз һәм алдагы халык саны алу сынавыннан сынып түгел, ә ныгып чыгарбыз дип өметләнәм.

Әйе, без бу көнне, Конституциябез язмышы хәл ителәчәк көнне, бик борчылып көттек. Мәскәү кабинетларында талана-талана шактый зәгыйфьләнгән, көчсезләнгән беренче мөстәкыйль Конституциябезнең язмышы өчен кайгырдык. Һәм, кулымны йөрәгемә куеп әйтәм, бүген безгә тәкъдим ителә торган проект нәтиҗәдә без көткәнгә караганда яхшырак булып чыкты. Безнең юристларыбыз, сәясәтчеләребез, галимнәребез һәм бигрәк тә җитәкчеләребез Конституциябезнең умыртка сөяген саклап калу өчен мөмкин булганның барысын да эшләгәннәр.

Конституциянең үзгәртелгән вариантында әлегә республика гражданлыгы да сакланган, татар һәм урыс телләре дәүләт телләре дип игълан ителгән, президентның ике дәүләт телен белергә тиешлеге дә расланган. Татарстанның җир асты һәм җир өсте байлыклары гомумхалык (аның Татарстан халкы икәнен өстисе булыр) мөлкәте дип игълан ителгән, парламент эшчәнлегенә демократия төсмерләре өстәлгән...

Депутат Туфан Миңнуллин белән без, Конституция комиссиясе әгъзалары буларак, Төп Законыбыз проектына бер яңа статья тәкъдим иткән идек. Проектта ул 11 нче маддә[1] буларак урын алган һәм анда мондый сүзләр язылган: *«Татарстан Республикасы Татарстаннан читтә*

*яшәүче татарларның милли мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүдә, үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм итә».* Билгеле, монда сүз матди ярдәм турында түгел, ә методик булышлык, милли кадрлар әзерләү, китаплар, дәреслекләр бастыру, культура хезмәте күрсәтү хакында бара...

Конституция комиссиясенең эше бик демократик төстә барды, анда һәрбер төзәтмә тәфсилләп тикшерелде. Һәм нәтиҗәдә һәрьяклап уйланган, төрле дәрәҗәләрдә килештерелгән шушы проект депутатларга тәкъдим ителде. Конституция комиссиясе әгъзасы буларак, бу проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә дип кул күтәрсәм дә, минем бүген әйтмичә кала алмый торган бер сүзем бар. Ул сүз Татарстанны суверен дәүләт һәм халыкара хокук субъекты дип игълан иткән 61 нче маддә хакында. 1992 елда Конституцияне кабул итүдә актив катнашкан депутат һәм әлеге статья язмышы хәл ителгәндә килештерү комиссиясе әгъзасы булган, референдум вакытында шуны яклап тавыш биргән Татарстан ватандашы буларак мин бу статьяның төшеп калуы яисә үзгәртелүе белән һич тә килешә алмыйм. Дөресрәге, референдум нәтиҗәләренә ревизия ясарга минем мораль яктан да, юридик яктан да хакым һәм хокукым юк. Бер минем генә түгел, башка депутатларның да, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының да мондый хокукы юк. Моны без уйлап чыгармадык, бу – халыкара хокук нормасы, андый нормаларны Татарстан да, Русия дә бертигез хөрмәт итәргә һәм үтәргә тиеш.

Бу хәлдән чыгуның законлы ике генә юлы бар: йә гамәлдәге Конституциянең 61 нче маддәсе шул килеш сакланып калырга тиеш, яисә аның буенча яңа референдум үткәрергә кирәк. Шул вакытта гына без халык мәнфәгатьләрен яклаучы, халык ышанычын аклаучы, закон сагында торучы гадел һәм намуслы халык депутатлары булып кала алачакбыз.

*2002*

# БЕРДӘМЛЕК ҖИТЕП БЕТМИ

Конгрессның үткән корылтаенда башкарма комитет сайланганнан соң, аның утырышында мине башкарма комитет рәисе урынбасары итеп куйдылар. Һәм шунда миңа нигездә фән, мәгариф, мәдәният мәсьәләләре белән шөгыльләнү эше йөкләнде. Бу минем өчен бик якын өлкә, чөнки мин Дәүләт Советында да шушы проблемалар белән шөгыльләнәм. Гомумән, минем үземнең эшчәнлегем шушы проблемалар белән бәйләнгән. Аларны без конгресс, Татарстан Дәүләт Советы һәм дәүләт оешмалары белән бергәләп алып барырга тырыштык. Һәм бу бик дөрес тә.

Конгресс турында бик күп сүзләр сөйлиләр. Конгресс оешу чыннан да, бик зур вакыйга, ул – бик зур оешма. Аның төп максаты бөтен дөнья татарларын берләштерү, аларны рухи яктан – мәгарифен, мәдәниятен үстерүдән гыйбарәт. Әмма конгресс карарлар кабул итеп кенә бу мәсьәләне тормышка ашырып булмый. Әгәр дәүләт оешмалары, хөкүмәт бергәләп эшләмәсәләр, конгрессның уңышлары бик кечкенә булыр иде. Шуңа күрә без эшебезне күбрәк дәүләт оешмалары, дәүләт органнары белән бергәләп алып барырга тырыштык.

Без конгресс утырышларын, аның башкарма комитеты, бюро, күчмә утырышларын берничә мәртәбә Дәүләт Советы комиссиясе белән бергәләп үткәрдек. Шулай ук хөкүмәт оешмалары, министрлыклар белән бергәләп үткәргән очраклар да булды. Безнең һәр күчмә утырышыбыз һәм башкалары да каралган мәсьәлә буенча тармак министрлары катнашуында үтте. Шуңа күрә кайбер уңышларыбыз да булды.

Билгеле, мин һич кенә дә барысы да ал да гөл дип әйтә алмыйм. Чөнки дәүләт белән, хөкүмәт белән бердәм эшләү без теләгәнчә тиешле дәрәҗәдә үк булмады.

Киләчәктә менә бу мәсьәләгә игътибар итәргә иде. Һәм шуны алдан күреп, без Конституциянең яңа редакциясе эшләнгән вакытта, ягъни аңа төзәтмәләр керткән вакытта, халык депутаты Туфан Миңнуллин белән бергәләп, бик зур авырлыклар белән булса да, яңа бер статья эшләүгә ирештек. Үзгәртелгән Конституциянең 14 статьясында: *«Татарстан Республикасы Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга мәдәниятләрен, телләрен үстерүдә, үзенчәлекләрен саклауда ярдәм итә»,* – дип язылды.

Бу – бик зур нәрсә. Моңа кадәр без конгресс тарафыннанмы яисә дәүләт, хөкүмәт тарафыннанмы татарларга ярдәм кулы сузарга теләсәк, кулга сугалар иде. Сезнең моңа нинди нигезегез бар, нинди законыгыз бар, бу хакта Конституциягездә бернинди сүз дә юк, диләр иде. Менә хәзер безнең Конституциябездә бу хакта аерым статьябыз бар. Ләкин Конституция турыдан-туры эшләп китсен өчен аңа хөкүмәт карарлары кирәк. Хәзер без, Татарстанның төзәтмәләр кертелгән Конституциясенең 14 статьясын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт программасы төзергә кирәк, дип, хөкүмәткә мөрәҗәгать иттек. Ул программада мәктәпләргә, китапханәләргә, ягъни башка мәдәният учакларына, милли оешмаларга, гомумән, читтә яшәүче татар халкына мөмкин кадәр ярдәм итү каралган булырга тиеш.

Билгеле инде, бу матди ярдәм Татарстан хисабына гына булмаячак. Бу ярдәм күбрәк милли кадрлар әзерләү буенча, аларга культура хезмәте күрсәтү, татар мәктәпләренә методик әсбаплар, дәреслекләр әзерләү буенча булачак. Әмма аның кайберләре, мәсәлән, дәреслекләр, китаплар, кайвакытта бушлай да булырга мөмкин. Ә күп вакытта безнең республика хөкүмәте урыннардагы хөкүмәт җитәкчеләре белән элемтәгә кереп, килешүләр төзеп, алардан заказлар алып, бергәләп эш итәргә тиешләр. Ә без үз чиратыбызда монда, Татарстанда, бу эшне башларга тиеш булырбыз, дип уйлыйм мин.

Бу бик әһәмиятле. Әгәр без шуны җайга салсак, минемчә, дөньяда, аеруча Россиядә сибелеп яшәгән татарларга конкрет ярдәмебезне күрсәтә алырбыз. Чөнки алар безгә, ярдәм итегез, дип, бик күп тапкырлар мөрәҗәгать иттеләр инде. Алар бездән матди ярдәм генә көтми, аларга, мәсәлән, артистларны, театрларны җибәрергә кирәк, укытучылар җитми, кадрлар әзерләүдә ярдәм кирәк. Без үзебезнең уку йортларында чит төбәкләрдән килгән милләттәшләребезгә

имтихан тапшырганда ташламалар бирергә, яшьләрне монда китертеп укытырга, белемне арттыру курсларына чакырырга тиешбез һ.б. Гомумән, бу яктан караганда эш җитәрлек.

Тагын бер нәрсә – ул да булса татарның эшмәкәрләрен бергә берләштерү. Бу юнәлештә инде конгресс шактый күп эш башкарды. Татарның эшлекле кешеләрен Казанда җыеп очрашулар да, фикер алышулар да үткәрелде. Әмма алар әле тулысынча тупланып бетеп, үзләренең тапкан малларының бер өлешен татар милләтен үстерүгә сарыф итәргә әзер түгел. Моның өчен алар: «Әгәр Татарстанда сәүдә эшләре, эшмәкәрлек элемтәләре урнаштыру өчен ниндидер бер ташламалы шартлар булдырылса, без, үзара элемтәләрне җайга салып, табыштан кергән сумманың күпмедер өлешен милли хәрәкәткә, милли үсешкә юнәлтә алыр идек», – диләр. Моны, билгеле инде, конгресс дәрәҗәсендә генә кабул ителгән карар белән хәл итеп булмый. Монда хөкүмәт карарлары һәм үзебезнең президентыбызның ярдәме кирәк булачак.

Минем иң зур теләгем шул: Бөтендөнья татар конгрессы Россиядә һәм дөньяда булган барлык татар иҗтимагый оешмаларын берләштерүче үзәккә әверелсен иде. Бүгенге көндә ул шул юлдан бара да. Дөньяга сибелгән татарны, бигрәк тә Россия төбәкләрендәге эшмәкәрләрне берләштерсен һәм, әйткәнемчә, аларның табышлары шушы эшкә юнәлтелсен иде.

Урыннардагы хөкүмәт, дәүләт оешмалары белән элемтәләребезне дә ныгытасы бар. Чөнки бу юнәлештә башкарасы эшләр күп әле. Һәм дә инде безнең кабул иткән карарларыбызны үтәү юлында конгресс активрак эшләсен иде. Без үткән конгресста, татарның үз милли телевидениесе, радиосы булырга тиеш, дигән идек. Шөкер, бу үтәлде.  Кызганычка каршы, үтәлмәгәннәре дә байтак шул. Үткән конгресста шулай ук Милли университет ачарга дип тә карар кабул иткән идек. Әмма ул үтәлмәде.

Шулай ук латин графикасына кайту турында да карар кабул иткән идек. 1999 елның 15 сентябрендә Татарстан Дәүләт Советы бу хакта закон да кабул итте. Ни кызганыч, закон әле һаман да үтәлми. Моның ике төп сәбәбе бар. Берсе – үзебезнең арадагы каршылык, бердәмлек җитмәү. Аеруча татар галимнәре, укытучылар арасында бердәмлек җитми. Икенчесе – бу эшкә Мәскәү килеп тыгылды. 5 сентябрьдә үтәчәк Дәүләт Советы сессиясендә без бу мәсьәләне көн тәртибенә кертәчәкбез һәм анда Россия Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать кабул итәргә җыенабыз. Чөнки «Россия халыклары телләре турында»гы Законга үзгәрешләр кертү беренче укылышта кабул ителде. Без Дәүләт Думасы депутатларына, аны икенче укылышта йә карамаска, йә кабул итмәскә, дип мөрәҗәгать итәбез. Чөнки ул Россия Конституциясенә дә каршы килә.

Бүгенге көндә җәмәгать оешмасын эшләтү авыр. Ул акчасыз, чыгымсыз гына эшли алмый. Иң беренче чиратта яңа сайланган башкарма комитетка үзенең гамәли эшли торган активын булдырырга кирәк. Мин аппарат турында әйтмим, ул эшли. Аның янында ниндидер бер аналитик үзәк кирәк, минемчә. Ул бүгенгә кадәр булган эшләребезгә йомгак, анализ ясап, киләчәктә нинди юлдан барырга, безнең нинди өстенлекле проблемаларыбыз бар – шуларга юнәлеш биреп, фәнни нигезләмә ясап юл күрсәтүче аналитик үзәк булырга тиеш. Бу – бер. Икенчесе – төбәкләрдә конгрессның рәсми вәкилләре булырга тиеш. Төрле мәдәни үзәкләр, мохтариятләр булуы бик яхшы. Әмма алар һәммәсе дә җәмәгать оешмалары. Берничә төбәктә, мәсәлән, Мәскәүдә, Балтыйк буенда, Себердә, ерак чит илләрдә хезмәт хакы алып эшли торган вәкилләр булса иде. Бу җаваплылыкны арттыра. Ул кешеләрдән эш тә таләп итәргә була.

Күрәбез, проблемалар җитәрлек. Алар барысы да бөтен дөньяга чәчелгән татарны бергә туплауга, берләштерүгә юнәлдерелгән.

*2002*

# ТУГАН ИЛЕМ, ТАТЛЫ ТЕЛЕМ

«Татарстан Республикасы телләре турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә 10 ел тулды. Телләр турында махсус закон кабул итү, һичшиксез, Татарстанда яшәүче халыкларның һәркайсын, бигрәк тә татар халкын дөнья халыклары арасында милләт буларак таныту, телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү эшен дәүләт күләмендә хәл итү өчен мөмкинлек ачты.

Шулай да республика халкын, һәр татар кешесен, бигрәк тә үз эшчәнлекләрендә туган телне киң файдаланучы һөнәр ияләрен бер сорау борчый – без 10 ел эчендә «Телләр турында»гы Закон маддәләрендә куелган максатларга ирешә алдыкмы, телләребезне законда күрсәтелгән дәрәҗәдә саклауга, өйрәнүгә, үстерүгә ирештекме? Бу – шактый катлаулы сорау. Аңа тулысынча җавап алу өчен җентекле фәнни өйрәнү таләп ителә. Шулай да без бүген бер нәрсәне ышанып әйтә алабыз: «Телләр турында»гы Законны кабул итү һәм аны Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы нигезендә тормышка ашыру эше Татарстанда яшәүче барча халыкларның, бигрәк тә татар халкының милли, рухи һәм иҗтимагый үсешенә уңай йогынты ясады, һәм ул бүген дә шулай булып кала. Туган телебезнең республикабыз тормышына һаман саен киңрәк һәм тирәнрәк керә баруы барыбызның да күз алдында. Конституциябез тарафыннан татар телен урыс теле белән беррәттән дәүләт теле дип игълан итү милләтебезнең гомерен озайтуга, милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салуга бик зур өлеш кертте. Тормышыбызда инде тәмам югалып бетә язган икетеллелекнең көн тәртибенә куелып, күпмедер дәрәҗәдә тормышка ашырыла баруы, мәктәпләрдә ике дәүләт теленең берсе булган татар телен өйрәнү күләменең артуы, милли балалар бакчалары, туган телдә яңадан-яңа матбугат чараларының ишәя баруы, үзебездә – Дәүләт Советында, сессияләрнең синхрон тәрҗемә белән тәэмин ителүе һәм документларның ике телдә алып барылуы, Министрлар Кабинетында, республикабыз районнарында һәм шәһәрләрендә тел мәсьәләләре буенча махсус комиссияләр төзелү, туган телне өйрәнү буенча курслар оештырылу – 10 ел элек боларның берсе дә яки бөтенләй юк, яки булса да бик зәгыйфь дәрәҗәдә иде.

Шул ук вакытта 10 ел эчендә республикабызда яшәүче башка тугандаш халыкларның телләрен өйрәнү һәм үстерү буенча да байтак эш башкарылды. Чуваш, удмурт, мордва, мари авылларындагы китапханәләрне һәм мәктәпләрне туган телдәге китаплар һәм дәреслекләр белән тәэмин итү, күрше республикаларның көндәлек матбугатына язылу, мәктәпләрдә туган телдә укыту сизелерлек яхшырды. Татарстанның милли-мәдәни оешмалар ассоциациясенә берләшкән төрле милләт вәкилләре тарафыннан туган телдә милли бәйрәмнәр үткәрү, үзешчән сәнгатьнең үсеше, кичке һәм якшәмбе мәктәпләре, төрле курслар оештыру Татарстан халыклары телләрен көндәлек тормышта куллану даирәсен арттырды.

«Телләр турында»гы Законны тормышка ашыруның 10 еллык тәҗрибәсе безгә киләчәктә бу эштә кирәк булачак яңа юнәлешләрне дә күрсәтте. Шул ук вакытта без, 10 еллык тәҗрибәгә таянып, Программада билгеләнгән кайбер чараларны тагын да ачыкларга, аларга төзәтмәләр кертергә, кайбер билгеләмәләрне тормышка ашыру вакытын тагын бер кат уйларга кирәклеген дә аңладык. Тормыш таләбеннән килеп чыккан кайбер мәсьәләләрнең безнең законыбызда чагылып бетмәгәнлеге дә мәгълүм булды. Шуларны искә алып, безнең комиссия Законга өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә һәм Дәүләт программасын яңартырга кирәк дигән карашта тора.

Табигый ки, Законга һәм Программага өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү өчен башта ул өстәмәләр һәм үзгәрешләрне билгеләргә, ачыкларга, барларга кирәк булачак. Безнең комиссия хөкүмәт вәкилләре белән беррәттән соңгы елларда бу эш белән даими рәвештә шөгыльләнде. «Телләр турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыруның урыннардагы торышы белән якыннанрак танышу һәм бу мәсьәлә буенча җирле Советлар депутатларының, хакимиятнең, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләренең һәм хезмәт ияләренең фикерләрен, тәкъдимнәрен өйрәнү максатында 2002 елның 20 июнендә безнең комиссия Балык Бистәсе районында күчмә утырыш уздырды. Анда без Дәүләт Советы Президиумына телләр турындагы мәсьәләне чираттагы

сессиянең көн тәртибенә кертүне тәкъдим иттек. Әлеге эшнең бөтен республика күләмендә ничек барышын өйрәнү максатында Татарстандагы район һәм шәһәр Советларына чираттагы сессияләренең көн тәртипләренә әлеге мәсьәләне кертеп, «Телләр турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча тәкъдимнәрен безнең комиссиягә юллауларын сорадык. Ярты ел эчендә безнең комиссия байтак җаваплар алды. Җирле Советларның күбесе, телләр турындагы мәсьәләне тормышка ашыру тәҗрибәсеннән чыгып, «Телләр турында»гы Законга һәм Дәүләт программасына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә кирәк, дигән тәкъдим белән чыктылар.
Шунысы куанычлы: җирле Советлар Законга һәм Программага үзгәрешләр кертүне тәкъдим итеп кенә калмыйлар, ә үзләре әһәмиятле дип санаган конкрет өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне дә Дәүләт Советына юллыйлар. Аларның шактые безнең комиссиядә хуплау тапты, без аларны Законга һәм Программага үзгәрешләр кертү вакытында һичшиксез искә алырбыз.
«Телләр турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча халык депутатларының Казан шәһәр Советының шактый уңышлы эшләвен билгеләп үтәсе килә. Казан шәһәр Советы 1998 елның 20 февралендә Казан шәһәрендә телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча махсус программа кабул итте. Күптән түгел генә бу программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелде. Иң әһәмиятлесе шул: Казан шәһәре ел саен үз бюджетының 1 процентын «Телләр турында»гы Законны тормышка ашыру өчен бүлеп бирә. Бу бик яхшы башлангычны республикабызның бөтен район һәм шәһәрләре дә гамәлгә кертсә, «Телләр турында»гы Законны тормышка ашыру эше күзгә күренеп алга китәр иде.
Әмма шунысын да әйтми булмый: Казан шәһәрендәге мәктәпләрдә татар телен өйрәнү эше ярыйсы гына булса да, бу эш балалар бакчаларында, хәтта татар балалар бакчаларында да тулысынча канәгатьләнерлек түгел. Кайбер бакчалардагы татар төркемнәрендә үзләре дә юньләп татарча сөйләшә белмәүче тәрбиячеләр эшли, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телен өйрәнү әсбаплары юк диярлек. Казан шәһәр Советының безнең комиссиягә юллаган тәкъдимнәрендә дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар арасында үзара бәйләнешләрнең ике дәүләт телендә дә алып барылмавы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүдә дәүләт телләренең икесен дә файдалану тулысынча тормышка ашырылмавы турында әйтелә. Бу хәл программада да тиешенчә чагылыш тапмаган. Әлеге мәсьәләләрне тормышка ашыру эше дәүләтнеке булмаган милекле предприятиеләрдә һәм оешмаларда аеруча начар куелган. Чөнки «Телләр турында»гы Закон үзе дә законны үтәүне бары тик дәүләт органнарыннан гына таләп итә. Законга үзгәрешләр керткәндә, бөтен төрдәге милекле предприятиеләр һәм оешмаларга да Законны үтәргә мәҗбүр итә торган билгеләмә өстәргә кирәк булыр.
Хәтеребездә, 90 нчы еллар башында татар һәм урыс газеталары, радио һәм телевидениесе татар телен өйрәтү буенча бик әйбәт дәресләр алып бара башлаган иде. Тора-бара алар нигәдер юкка чыкты. Тел мәсьәләсе – мәңгелек мәсьәлә, аны берничә елда гына хәл итеп булмый. Шуңа күрә безгә килгән күпсанлы мөрәҗәгатьләрдә республика матбугатында, дәүләт телерадиокомпанияләрендә тел мәсьәләсенә игътибар җитмәүгә борчылуны урынлы дип саныйбыз. Газетта-журнал мөхәррирләре, телерадиокомпания җитәкчеләре үзләре дә әлеге проблеманы яхшы аңлыйлар, һәм бу мәсьәлә озакламый хәл ителер дип уйлыйбыз. «Яңа гасыр» телевидениесендә шулай ук дин, әдәп, әхлак мәсьәләләренә багышланган тапшырулар да әзерләнсен иде. Ә инде дәүләтнеке булмаган газеталарда һәм теле-радиокомпанияләрдә татар теленең бөтенләй санга сугылмавын анда эшләүчеләрнең һәм җитәкчеләрнең татар халкына, аның теленә булган тискәре мөнәсәбәте дип бәяләүдән башка чарабыз юк. Республикага исем биргән, халыкның күпчелеген тәшкил иткән кавемгә шундый тискәре карашның сәбәбен мин үзем берничек тә аңлый да, аңлата да алмыйм.
Закон кабул ителүгә 10 ел тулса да, без бүгенге көнгә кадәр республикада эзлекле, тәмамланган милли мәгариф концепциясе булдыра алмадык. Югары уку йортларында татар теле һаман ятим бала хәлендә көн күрергә мәҗбүр. Ә республиканың зур предприятиеләре, берләшмәләре, заводлары һәм фабрикалары дәүләт теле булган татар телен әлегә кадәр проходнойларыннан, капкаларыннан да кертмәделәр. Меңәрләгән татар кешеләре эшләсә дә, аларда бер белдерү, бер

игълан, бер эш кәгазе дә татарча язылмый. Ә КамАЗда исә моңа кадәр татарча чыгып килгән бердәнбер «Нур» газетасын да ябарга җыеналар икән дип ишеттек. «Телләр турында»гы Законның хезмәт урынында ике дәүләт телен дә файдаланучы хезмәткәрләргә 15 процентка кадәр өстәмә түләү каралырга тиеш дигән билгеләмәсе дә тиешенчә үтәлмәде. Кайберәүләр моны, тарайтып, татар телен белгән өчен түләү дип кабул иттеләр. Әмма сүз аерым бер тел турында гына түгел, ә ике дәүләт телен дә гамәли эштә куллану турында бара. Урысча әйтсәк, «надбавка за практическое применение в работе двух государственных языков» була инде ул.
Милли университет ачуның республикабыздагы һәм аннан читтәге татар иҗтимагый тормышын үстерүдәге әһәмияте турында районнар һәм шәһәрләрдән килгән күп кенә тәкъдимнәрдә әйтелә. Кайберәүләр уйлавынча, бу – бер төркем депутатлар яки сәясәтчеләр генә куерта торган мәсьәлә түгел, ә халык таләбе. Ә менә халык депутатларының Яшел Үзән Советы «Телләр турында»гы яңа Программа кысаларында «Балалар бакчасыннан – мәктәпкә» дигән махсус, комплекслы программа кертүне тәкъдим итә. Бу – әйбәт тәкъдим. Чаллы, Минзәлә, Арча, Кукмара, Саба, Ютазы һ. б. җирле Советлардан килгән тәкъдимнәр дә игътибарга лаеклы.
Җирле Советлардан килгән тәкъдимнәрдә «Телләр турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыруның беренче елларында актив кына башланып киткән кайбер чараларның тора-бара сүлпәнәюе яки бөтенләй онытыла баруы турында борчылулар да бар. Әйтик, бөтен республика күләмендә оешмаларда, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, авыл һәм шәһәрләрдә татар телен өйрәнү буенча төрле-төрле дәрәҗәдә, төрле-төрле ысуллар белән эшләүче курслар оештыру эше нык сүлпәнәйде.
Закон һәм Программа кабул ителгән еллар белән чагыштырганда, соңгы арада шәһәр һәм шәһәрара транспортта тукталыш исемнәрен һәм башка мәгълүматларны ике дәүләт телендә игълан итү бик нык кимеде. Автовокзал, тимер юл вокзалы, аэропорт һәм елга портларында бу эш акрынлап онытыла бара. Урамнардагы, юл читләрендәге, предприятие, учреждение, төрле оешмалар биналарының эчендәге һәм тышындагы язмаларны ике дәүләт телендә башкару да җитәрлек күләмдә алып барылмый. Булганнары да бик күп хаталар белән языла. Төрле бәйрәмнәр һәм тантаналар белән котлау открыткалары, чакыру кәгазьләре, нигездә, бары бер телдә – урыс телендә генә басыла. Татарстанда татарча телеграммалар җибәрү һәм кабул итү эше һич тә канәгатьләнерлек түгел. «Телләр турында» Закон кабул итүебезгә 10 ел узса да, моңа кадәр әле без Татарстанда татар телендә татар хәрефләре белән телеграммалар җибәрә һәм кабул итә алмадык. Элемтә бүлекләренә бу мәсьәләне хәл итү өчен җиһазлар алырга акча бирүне сорап безнең комиссия 2003 елгы бюджет проектына тәкъдим кертте.
Җирле Советлардан килгән тәкъдимнәрдә шулай ук татар телендә китап бастыру, аларны таратуның торышы да «Телләр турында»гы Закон һәм Дәүләт программасы таләпләренә туры килмәве искәртеп үтелә, татар әдәбияты классиклары һәм танылган язучыларның әсәрләрен кабат бастырып укучыларга җиткерү эшен яхшыртырга кирәклеге әйтелә. Чыннан да, соңгы 10 ел эчендә татар китабына кытлык бик нык артты. Ниһаять, 2003 елда бу эшнең шактый җанлануына өмет итәбез. Президентыбыз Минтимер Шәймиев ярдәме белән бүгенге көндә типографияләрдә танылган язучыларыбызның күптомлы әсәрләре басылып ята. Инде аларның авторларына җан асрарлык гонорар түләү эше дә җайга салынырга тора. Киләчәктә күптомлыкларны укучы кулына китереп җиткерү эшен хәл итәсе бар. Күпчелек халыкның, бигрәк тә авыл кешеләренең, хәзер китап сатып алырлык, газета-журналга языларлык акчасы юк. Бүгенге көндә татар китаплары һәм газета-журналлары, нигездә, китапханәләр аша укучыга барып җитә. Шуңа күрә китапханәләребезне мөмкин булган кадәр саклап калырга һәм аларның матди хәлен ныгытырга кирәк.
Соңгы елларда «Телләр турында»гы Законны гамәлгә ашыруның сүлпәнәюе законны бозган өчен җавапка тарту ысулларының эшләнмәгән булуы белән дә бәйле. Шуны искә алып, безнең комиссия «Административ хокук бозулар буенча Татарстан Республикасы кодексы» проектына «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын бозу» хакында махсус маддә кертүне тәкъдим итте, һәм ул депутатлар тарафыннан кабул ителде. Бу маддә буенча «Телләр турында»гы Законны бозган затларга биштән алып ун минималь хезмәт хакы күләмендә штраф

салу күздә тотыла. Әмма штраф салу юлы белән дә законны тулы көченә эшләтә алу мөмкин булмастыр. Татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теленә әйләнсен өчен иң элек суверен дәүләтебез булу кирәк. Дәүләт хезмәткәрләре шул телдә сөйләшкәндә, шул телдә эш йөрткәндә, дәүләт белән идарә иткәндә генә әлеге тел – бу очракта татар теле – чын мәгънәсендә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алачак. Яшәү һәм эшләү өчен артык кирәге булмаган телне, ул телне белмичә дә рәхәтләнеп яшәп булган илдә, беркайчан да тиешле дәрәҗәдә өйрәнмәячәкләр. Ә кеше шулай яратылган: үзенә кирәкмәгән эшкә беркайчан да үз теләге белән алынмый, үзенә кирәкмәгән телне беркайчан да өйрәнми ул.

Күптән түгел Русия Дәүләт Думасы кабул иткән һәм Президент В. В. Путин кул куйган латин имлясына күчүне тыючы мәгълүм законның киләчәктә татар телен үстерүгә никадәр зыян китерәчәге хакында монда озаклап сөйләп торуның кирәге юктыр дип саныйм. Без инде бу мәсьәләне сессиядә өч мәртәбә карап, Русия җитәкчеләренә Дәүләт Советының мөрәҗәгатьләрен юллаган идек. Кат-кат сөйләүдән мәгънә юк, хәзер безнең Русия Конституция судына мөрәҗәгать итүдән башка чарабыз юк. Әгәр инде анда да Конституцияне бозган карар кабул итсәләр, кеше хокукларын яклаучы халыкара оешмаларга һәм судларга мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк.

Кыскасы, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында» һәм «Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы»на өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законнары проектларын эшләү – өлгергән мәсьәлә. Дәүләт Советы да, Татарстан хөкүмәте дә моңа әзер, һәм бу эшне, озакка сузмыйча, 2003 елның беренче ярты еллыгында бергәләп башкарып чыгарга мөмкин булыр дип саныйм.

*2003*

# БҮЛЕНГӘННЕ БҮРЕ АШАР

Алда безне халык язмышын, ил язмышын хәл итә торган гаҗәеп зур вакыйга – сайлаулар көтә. «Безнең сайлауда беренче мәртәбә генә катнашуыбыз түгел. Монысы да узар, бер нәрсә дә үзгәрмәс. Тормыш моңа кадәр ничек барган, шулай ук дәвам итәр», – дип уйлаучылар да бардыр. Әмма мин мондый фикер белән килешмәс идем.

Беренчедән, без дөньяларның гаҗәеп тиз үзгәргән чорында, милләтләр һәм дәүләтләр язмышы хәл ителгән яңа шартларда яшибез. Икенчедән, Русиядәге романтик революция еллары үтеп, хакимияткә айнык башлы, каты куллы, кырыс күңелле прагматиклар килә башлады. Шуңа күрә безгә дә, кемнәрнеңдер рәхим-шәфкать күрсәткәнен, бәхет өләшкәнен көтеп утырмыйча, үз көнебезне үзебез күрү, үз хакыбызны үзебез яклау вакыты җитте. Ә үз хакыбызны, Татарстаныбыз мәнфәгатьләрен Русия күләмендә яклау өчен Русия Дәүләт Думасында безнең турыда, сайлаучылары турында чынлап торып кайгыртучы, шул кайгыртуны матур сүзләр белән генә түгел, ә конкрет тәкъдимнәр, яхшы законнар белән дәлилләүче депутатларыбыз булу кирәк.

Моннан 4 ел элек Дәүләт Думасына депутатлар сайлаганда, без әлеге романтик революция шаукымнарыннан айнып җитә алмаган идек әле. Аннары, Татарстанда туып, Татарстанда үсеп, Татарстаннан сайланып, зур вәкаләтле кешегә әверелгән депутатның үз сайлаучыларын, халкын онытуын, оныту гына түгел, хәтта шул халык мәнфәгатьләренә каршы килгән карарлар һәм законнар кабул итүен без күз алдына да китерә алмаган идек. Мәсәлән, Татарстан Дәүләт Советы халык фикерен җентекләп өйрәнеп, сайлаучылар белән кат-кат фикер алышып, ниһаять, бер фикергә килеп, бик тә кирәкле закон кабул итә. Ә шул ук халык, шул ук сайлаучылар тарафыннан сайланган, зур вәкаләтләр алган Дәүләт Думасы депутаты, әлеге законга куәт бирәсе, аны Русия күләмендә яклыйсы урында, киресенчә, бөтен көчен салып, аңа каршы көрәшә башлый.

Мондый мисалларны без 4 ел буе күреп, күзәтеп килдек. Татарстаннан сайланган депутатларның берничәсе 4 ел буена Татарстанның хакын хаклап, хокукын яклап дүрт кәлимә сүз дә әйтә алмадылар, ә кайберләре исә турыдан-туры Татарстанга каршы көрәш юлына бастылар. Бер республикадан, бер халыктан сайланган депутатлар, бертуганнар кебек киңәш-табыш итешеп, уртак мәсьәләләрне бергәләшеп хәл итәсе урынга, бер-берсе белән тарткалаша башладылар, кайберләре хәтта берсе-берсе белән исәнләшмәс, күрешмәс хәлгә җиттеләр. «Гаугалы йортта бәрәкәт булмас» диләр халыкта... Шуңа күрә дә алар ил күзенә күренерлек зур эшләр эшли, игелекле гамәлләр кыла алмадылар. Монысы инде булган хәлләр, бу инде – безнең ачы тәҗрибәбез. Ә киләчәктә нишләргә, алдагы сайлаулар вакытында ничек итеп тагын алданмаска икән соң безгә?

Шушы яшькә җитеп, минем әле халыкка бары тик яхшылыклар гына эшләргә вәгъдә итмәгән кандидатны, халык мәнфәгатьләрен якларга җыенмаган партияне күргәнем булмады. Вәгъдә белән ялган һәрвакыт шулай матур була торгандыр инде ул. Менә бүген дә егерме партиянең егермесе дә бары тик яхшылык кына вәгъдә итә, теркәлгән кандидатларның да телләрендә бал да май гына. Әмма безгә инде буш вәгъдәне – изге нияттән, матур сүзләрне матур эшләрдән аера белергә вакыт җиткәндер. 40–50 яшькә җитеп, ил файдасына 50 тиенлек тә эш башкармаган кешенең депутат булгач кына кинәт үзгәреп китүенә һич кенә дә ышана алмыйм мин.

Газеталарда басылып чыккан партияләр исемлеген укыгач, егет чакларым искә төшеп китте. Яшь чагында чибәр кызлар бик күп була бит ул, кайсын сайларга белми аптырап бетәсең. Ә тормыш корып яши башлау өчен аларның барысына да берьюлы өйләнеп булмый, арадан берсен генә сайларга туры килә. Киләчәктә кайсы партия вәкилләренә тавыш бирү мәсьәләсен дә ордым-бәрдем генә хәл итәргә ярамастыр. Ул партиянең «әти-әнисе», димәк ки, лидерлары кемнәр, аларның тоткан кыйблалары кайсы якта, яшәү рәвешләре нинди, ул партия тирәсенә ниндирәк кешеләр тупланган, аларның моңа кадәр халык файдасына эшләгән эшләре бармы, үз язмышыңны алар белән бергә бәйләп буламы?

Соңгы арада мин дә үз-үземә кат-кат шундый сораулар бирдем, үз тирәмдәге фикердәшләрем, тәҗрибәле кешеләр белән киңәштем. Дөресен әйтим, бер партиянең дә куенына кермичә, егет кеше булып, бер читтән генә карап торырга ниятләгән чакларым да юк түгел иде. Безнең Президентыбыз, Дәүләт Советы Рәисебез дә, тагын йөзләгән-меңләгән акыллы һәм төпле ил агаларыбыз да соңгы араларда Русиядәге сәяси вазгыять хакында еш уйланганнардыр, четерекле сорауларга җаваплар эзләп, йокысыз төннәр үткәргәннәрдер, дип уйлыйм. Чөнки бүген бу хакта уйламаган кеше – ул үз язмышына да, ил язмышына да битараф, ваемсыз кешедер. Әгәр дә бүген шулай бар нәрсәгә битараф булып, горур кыяфәт белән бер читтә басып торсаң, син сәясәт арбасыннан төшеп каласың, димәк, синең язмышыңны башкалар хәл итәчәк. Ә инде ниндидер хәрәкәткә, кайсыдыр партиягә кушылып, нәрсәдер хәл итәргә теләсәң, башта кемнәр янына кушылуыңны һәм алар белән бергә халык һәм милләт файдасына ниләр эшләп булачагын бик ныклап уйларга кирәк.

Партияләр күп, ә безнең язмышыбыз, безнең максатыбыз берәү генә. Шуңа күрә безгә артык бүлгәләнмичә, бөтен көчләребезне бер тирәгә туплау кирәк. Бердәм булганда гына без үз хакларыбызны хаклый алырбыз, бердәм булганда гына үз максатыбызга ирешә алырбыз. Бу бердәмлек безгә Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында гына түгел, һәрдаим кирәк булачак. Чөнки бу сайлаулардан соң дөнья бетми, алда әле Татарстан Дәүләт Советына сайлаулар, Президент сайлаулар, җирле үзидарәгә сайлаулар көтә...

«Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» диләр безнең халыкта. Шуңа күрә халкыбызны өчкә яисә егерме өчкә бүлгәләү, аның көчләрен таркату киләчәктә һич кенә дә безнең файдага, сайлаучылар файдасына, республика файдасына булмаячак. Чөнки халык бары тик бердәм булганда, бер максат тирәсенә тупланып, үзенең лидерлары, милләт маягы булырдай ил агалары тирәсенә оешып алга атлаганда гына, кыйбласын бутамыйча, киләчәк көннәргә исән-имин барып җитә ала.

*2003*

# ЛАТИН ГРАФИКАСЫ ЯЗМЫШЫ – СУДЬЯЛАР КУЛЫНДА

Моннан берничә көн элек Татарстан Дәүләт Советына Татарстан Югары судыннан чакыру килеп төште. Баксаң, безнең прокурорыбыз «Латин язуы турында»гы Законыбызны Россия законына тәңгәл килмәүдә гаепләп судка биргән, һәм без 2 март көнне татар халкының үзе теләгән хәрефтә язарга хакы бармы-юкмы икәнлегенең бер прокурор һәм бер судья тарафыннан хәл ителүе шаһитлары булырга тиешбез икән.

Мондый әкәмәтләрне инде күп күрсәк тә, инде безнең бар булган хокукларыбызны берәм-берәм йолкып бетерә барсалар да, бәлки, монысына кагылмаслар, әлифбага, хәрефкә үк тотынмаслар дип өметләнгән идек. Аннары, прокуратура да, суд та хокук саклау оешмалары дип аталалар, димәк, алар иң беренче чиратта кешенең, халыкларның хокукларын чикләргә түгел, ә якларга тиешләр. Ә хәреф сайларга, нинди язуда язарга да хакы, хокукы булмаган халыкның ничек итеп шул хокук саклау органнарына, җитәкчеләргә, депутатларга ышанычы һәм хөрмәте булсын икән?

Ә бүген без Россия Федерациясе Президентын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау алдында торабыз. Бу зур эш вакытында республикабыздагы сәяси тотрыклылык саклану барыбыз өчен дә бик мөһим. Әлеге мәсьәләне сессиянең нәкъ менә бүгенге көн тәртибенә кертү турыдан-туры әнә шул сәяси тотрыклылыкны саклау ниятеннән дә эшләнә.

Мәсьәләнең бүгенге көнгә кадәр булган тарихына кыскача гына күзәтү ясап китәргә рөхсәт итегез: инде егерменче гасыр башларында ук Татарстан җәмәгатьчелеге тарафыннан татар әлифбасын латин әлифбасына күчерү мәсьәләсе күтәрелә. 1927 елда татарча язу латин графикасына күчә һәм ун елдан артык кулланышта була. 1938 елның 30 декабрендә ВКП(б) Политбюросы, бернинди белгечләрдән һәм җәмәгатьчелектән сорап тормыйча, татар алфавитын кириллицага күчерергә дип карар чыгара. Әмма фәнни оешмалар, телчеләр, язучылар, журналистлар, мәгариф хезмәткәрләре арасында кириллица язуы татар теленең авазлар системасына да, орфографиясе һәм грамматикасына да туры килмәве турында әледән-әле бәхәсләр, ризасызлыклар туып тора. Тик бу хәрәкәт совет системасының тоталитар сәясәте шартларында киң таралыш таба алмый.

Россия Федерациясендә яңа демократик җилләр исә башлаган 80 нче елларда гына әлеге мәсьәлә яңадан өскә калкып чыкты һәм чит илләрдәге, БДБ илләрендәге, Россия төбәкләрендәге һәм Татарстанның үзендәге киң җәмәгатьчелек дистә елга якын фикер алышкач, 1997 елда Бөтендөнья татар конгрессы, Җир шарының бөтен төбәкләреннән җыелган делегатлар исеменнән татар әлифбасын яңадан латин графикасына кайтару турында эш башлауны сорап, халкыбызга, хөкүмәтебезгә һәм Дәүләт Советына мөрәҗәгать итте. Озакламый татар галимнәре Дәүләт Советына «Татар әлифбасын латин графикасы нигезендә яңадан торгызу» турында закон проекты эшләп тапшырдылар. Дәүләт Советы һәм хөкүмәтебез бу закон проектын киң халык тикшерүенә куйды.

1999 елның 15 сентябрендә Татарстан Республикасында «Татар әлифбасын латин графикасы нигезендә яңадан торгызу» дигән Закон кабул ителде. Инде тарихи гаделлек тантана итте дип кенә торганда, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасындагы бер төркем депутатлары бу Законны Россия иминлегенә яный торган документ дип бәяләделәр һәм «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы федераль Законга Россиядәге милли республикаларда кириллицадан башка әлифбаларны тыюны күздә тоткан төзәтмә кертү тәкъдиме белән чыктылар. Татарстанның әлифба турындагы законының Россияне таркатуга һәм илнең иминлеген какшатуга нигезләнгән икәнен раслар өчен Дәүләт Думасы Татарстанга махсус комиссия җибәрде.

Әлбәттә, комиссия Татарстан җирендә андый җимерү эше булуын раслый торган бер генә дәлил дә таба алмады. Шуңа да карамастан комиссия, Думага кайткач, Татарстанның бу законы Россия

иминлегенә яный дип хисап бирде. Бу арада инде Россия матбугатында Татарстанга әнә шул яланы яккан бик күп чыгышлар да булды.
Әлеге шау-шуларның нәтиҗәсе булып Дәүләт Думасында «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Федераль законның 6 нчы маддәсенең 3 нче пункты итеп Россия Федерациясе республикаларында дәүләт теле булган милли телләргә кириллицадан башка әлифба куллануны тыя торган билгеләмә өстәлде.
Татар җәмәгатьчелеге, президентыбыз һәм Дәүләт Советы Россиянең бу законсыз законын кабул иттермәскә тырышып күп көч куйды. Дәүләт Советы башта Дәүләт Думасы депутатларына, аннары Федераль Советка, ниһаять, Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга Россия Конституциясенең 68 нче маддәсенең 2 һәм 3 бүлекләрен, 71, 72, 73 нче маддәләрен, шулай ук Россия Федерациясе ратификацияләгән регионнар телләре һәм аз санлы халыклар телләре турындагы Европа хартиясен һәм Европа Советы әгъзалары булган дәүләтләрнең милли азчылыкларны яклау конвенциясен тупас боза торган бу законны кабул итмәскә һәм аңа кул куймаска өндәгән мөрәҗәгатьләр белән чыкты. Президентыбыз Минтимер Шәймиев мәсьәләнең латин алфавитына кайту-кайтмау проблемасыннан тайпылып, сәяси һәм хокукый яссылыкка күчүенә басым ясады. Монда бит сүз татар халкының нинди әлифба, нинди графика файдалануы турында гына түгел, ә иң беренче чиратта кеше һәм халыклар хокуклары, Россиянең үзен Федерация итеп оештырган милләтләр һәм халыклар хокукларын күз карасы кебек сакларга тиешлеге, ниһаять, Россия эчендә федератив мөнәсәбәтләрне тагын да үстерү, ныгыту, димәк, Россия Федерациясен ныклы хокукый нигезләргә күчерү турында бара.
Шунысын да әйтергә кирәк: Татарстан җәмәгатьчелеге бу катлаулы хәлдән хокукый дәлилле, цивилизацияле чаралар белән генә чыгарга омтыла. Безнең комиссия, мәсьәләгә тулырак ачыклык кертүнең кирәклеген аңлап, «латинга кире кайту өчен Татарстан Конституциясе хокукый мөмкинлек бирәме?» дигән сорау белән Татарстан Конституция судына мөрәҗәгать итте. 2003 елның 24 декабрендә Татарстан Конституция суды карары безнең бу сорауга уңай җавап бирде. Без, инде болай булгач, тыныч кына алга таба барырга була дип, Комиссия исеменнән Россия Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган депутатларга Россиянең кириллицадан башка әлифбаларны тыя торган законын гамәлдән чыгару турында федераль закон проекты эшләүләрен сорап мөрәҗәгать итәргә уйладык. Әмма, инде әйткәнемчә, 2004 елның 18 февралендә Дәүләт Советына Татарстан Республикасы прокурорының «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Россия Федерациясе Законының 3 нче маддәсенә өстәмә кертү турындагы Федераль закон нигезендә «Татар әлифбасын латин графикасы нигезендә яңадан торгызу турында»гы Татарстан Республикасы Законын гамәлдән чыгаруны сораган гаризасының 2004 елның 2 мартында Татарстан Югары судында каралырга тиешлеге турындагы хат килеп төште.
Сүземнең башында мин, без тикшерә торган мәсьәләне сессиянең көн тәртибенә кертү Россия Федерациясе Президентын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау алдыннан җәмгыятьтә булган тотрыклылыкны саклап калу максатыннан да эшләнде, дигән идем. Чыннан да, Татарстан Югары судында 2 мартта булачак суд процессы сайлау алды ыгы-зыгысында болай да активлашкан җәмәгатьчелекнең латин графикасын яклаучы күпчелеге белән аны өнәмәгән өлеше арасында, республикабызда яшәүче аерым милләтләр арасында, галимнәр, журналистлар, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре, укучылар, студентлар арасында һич кирәк булмаган каршылыклар, бәхәсләр, шау-шулар, бүлгәләнүләр китереп чыгарырга мөмкин. Бу хәрәкәт табигый рәвештә дә, кайбер кайнар башлар тарафыннан махсус та оештырылырга мөмкин. Төрле регионнарда сайлау алдыннан пычрак технологияләрнең ничек кулланылуын да истән чыгармаска кирәк. Бусы – бер, һәм бик җитди мәсьәлә. Икенчедән, Россия регионнарының законлы хокукларын чикләүгә корылган бу гамәл Россия Президентын сайлау барышына ничек тәэсир итәр икән? Шул ук вакытта парламентыбызга депутатлыкка кандидат булып баручылар 2 мартта үзебезнең судның үз законыбызны тыюына берничек тә каршы килә алмаячаклар. Мондый чарасызлык, чынлыкта, көчсезлек, депутатлыкка дәгъва кылучы кандидатларыбызга карата халык яки сайлаучы ышанычын какшатмасмы?

Бу борчылулар, бу сораулар турында барыбыз да тирәнрәк, җитдирәк уйланыйк әле. Уен түгел, сайлауларга 12 көн калганда үзебезнең Югары суд Татарстан парламенты кабул иткән, халыкның рухи язмышын хәл итүдә хәлиткеч урын тоткан законнарның берсен гамәлдән чыгарып ташлый ди. Һәм бу эш Россия Конституциясен санга сукмыйча, аның белән исәпләшмичә, кеше һәм халыклар хокукларын бозу, чикләү юлы белән эшләнә.

Безнең комиссия бүген дә бу катлаулы хәлдән чыгуның хокукый, цивилизацияле башка юллары барлыгына ышана. Россия Конституциясенең 125 нче маддәсе нигезендә «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Федераль законның 3 нче маддәсендәге Россиядәге милли Дәүләт телләрендә кириллицадан башка имляны файдалануны тыя торган 6 нчы пунктны конституционмы, юкмы икәнлеген шәрехләүне сорап Россия Федерациясе Конституция судына мөрәҗәгать итик. Ә Татарстан Югары суды «Татар әлифбасын латин графикасы нигезендә яңадан торгызу турында» Татарстан Законын караячак суд утырышын бу мөрәҗәгатькә җавап килгәнчегә кадәр кичектереп торырга тиеш дип саныйм.

Әгәр дә Россия Конституция суды, Россия Конституциясен санга сукмыйча, хокукый карар урынына сәяси карар чыгарса, республикабыз һәм халкыбыз хокукларын чикләргә юл куйса, безнең өчен бердәнбер юл –халыкара оешмаларга һәм кеше хокуклары буенча халыкара судка мөрәҗәгать итү генә кала.

Язмамны Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең латин язуы тирәсендә барган ыгы-зыгылар хакында Россия матбугатында рус телендә басылып чыккан әңгәмәсеннән бер өзек белән тәмамлыйм: «Это решение было основано на резолюции Второго съезда Всемирного конгресса татар, а также выводах ученых Академии наук Татарстана, оно согласуется со статьей 68 Конституции Российской Федерации, по которой государство «гарантирует всем ее народам право на сохранение родного языка, создание условий для его изучения и развития», а республикам предоставляет право «устанавливать свои государственные языки». Приняв поправки к Закону РФ «О языках народов Российской Федерации», центр фактически нарушил собственную Конституцию, а также ряд международных норм, в частности европейскую рамочную Конвенцию о нацменьшинствах. Такой шаг можно рассматривать как покушение на право народов на свободное развитие языка. Можно обсуждать вопрос, насколько своевременен переход татарского языка на латинскую графику, но нельзя оспаривать само это право. Более того, приняв такие поправки, Федеральное собрание вмешалось в исключительные полномочия субъекта Федерации. Все эти нарушения происходят на фоне отсутствия ясной национальной политики, соответствующей нормам демократического федеративного государства».

*2004*

# «ТОТСА МӘСКӘҮЛӘР ЯКАҢ...»

Россия Федерациясендә дәүләт органнарын үзгәртеп кору турындагы Россия Президенты тарафыннан тәкъдим ителгән закон проекты хакында сөйләү җиңел эш түгел. Мин бу урында кемнедер тәнкыйтьләп үз-үзеңне авыр хәлгә кую яисә, киресенчә, кемнедер мактап һәм яклап дивидендлар җыю турында икеле-микеле сүзләр алып бармыйм. Монысы мине артык борчымый. Иң авыры, иң кыены монда син сөйләгән сүзнең, син әйткән фикернең барыбер беркемгә дә, бернәрсәгә дә тәэсир итмәвендә. Чөнки мәсьәлә инде күптән кирәкле даирәләрдә хәл ителгән, тиешле кешеләргә күрсәтмә бирелгән, ә син бу микрофоннан гына сөйләү түгел, Айга менеп кычкырсаң да, бер нәрсә үзгәрмәячәк. Хәлебезнең бөтен авырлыгы, безнең бүгенге утырышыбызның бөтен мәгънәсе яисә мәгънәсезлеге дә менә шушындадыр. Мин бүген монда үземне алтмыш меңнән артык сайлаучыларымның мәнфәгатен кайгыртырга тиешле депутат итеп түгел, хәтта шушы илнең тулы хокуклы гражданины, гап-гади бер кешесе дип тә хис итә алмыйм. Чөнки бу илдә мине тыңламыйлар, мине ишетмиләр, минем белән исәпләшмиләр, минем фикеремне санга сукмыйлар. Ә инде Кеше кадере булмаган илдә ниндидер абстракт демократия, федерализм, милләтләр, телләр, диннәр тигезлеге турында сүз алып бару бөтенләй мәгънәсез нәрсә.

Менә шундый халәттә, шундый вазгыятьтә без нишли алабыз соң? Күкрәгебез белән амбразурага ташланып, үз-үзебезне корбан итикме? Өстән төшкән теләсә нинди фәрманны хуплап утырган замандагы кебек дәррәү кул күтәрикме? Әллә, акыллы кыяфәт чыгарып, дәшмичә генә елмаеп утырыйкмы? Безнең татарда: «Усал булсаң – асарлар, юаш булсаң – басарлар, урта гына кеше булсаң – синнән түрә ясарлар», – дип юкка гына әйтмәгәннәрдер инде. Бүтәннәр теләсә нәрсә эшләсен, ә мин бүген үз сүземне әйтмичә, дәшмичә кала алмыйм.

Юк, мин бу чыгышымда илдә үзе белгәнчә тәртип урнаштырырга тырышучы Россия Президентын да, аның «ә» дигәненә «мә» дип торучы күндәм Дәүләт Думасын да гаепләргә җыенмыйм. Чөнки аларны гаепләүдән бернинди мәгънә дә юк. Чөнки алар бүтәнчә уйлый, бүтәнчә фикер йөртә, бүтәнчә эшли һәм идарә итә белмиләр. Һәм, ни кызганыч, белергә дә, өйрәнергә дә теләмиләр.

Илгә, кешеләргә терроризм куркынычы янаганын, дәүләттә тәртип урнаштырырга кирәклеген без барыбыз да яхшы аңлыйбыз. Әмма тәртипне ничек урнаштырырга икәнен генә белмибез. Көч белән, көсәк белән, куркыту юлы белән генә бүген илдә тәртип урнаштырып буламы? Әллә аның башка, үтемлерәк юллары бармы? Бәлки, тәртипне күпмедер дәрәҗәдә көч белән дә урнаштырып буладыр. Әмма бу сәясәт перспективалы сәясәт түгел, бу – вакытлы юаныч, үз-үзеңне алдау гына. Илдә тәртип урнаштыру өчен бөтен хакимиятне бер йодрыкка, бер кулга туплау түгел, ә, киресенчә, өлкәләргә һәм республикаларга күбрәк мөстәкыйльлек биреп, һәр субъектта үз көчләре, үз мөмкинлекләре белән тәртип урнаштыруны законлы юл белән тәэмин итү отышлырак булыр иде. Колхоз рәисе күпме көч кулланып та, авылдагы һәр өйдә, һәр гаиләдә тәртип урнаштыра алмаган кебек, Мәскәүдән торып һәр төбәк белән идарә итү, тәртип урнаштыру – мөмкин булмаган эш. Һәркем иң беренче чиратта үз өендә үзе тәртип урнаштырырга тиеш. Азмы-күпме мөстәкыйльлек алган килеш тә Татарстанның соңгы ун-унбиш елда никадәр алга китүе, милләтләр һәм диннәр арасында ыгы-зыгы тудырмыйча, үз өендә, үз республикасында дус-тату яшәве моңа бик ачык мисал бит югыйсә.

Президентларны, губернаторларны Мәскәүдән билгеләп куюның киләчәктә нәрсәгә китерәсе барыбызга да билгеле. Россия, гадәттә, упкын читенә барып җитеп, үзенә таркалу куркынычы янаганда гына милләтләргә бераз ирек биреп ала. Бу хәл 1918 елда да, 90 нчы еллар башында да булып алды. Әмма мондый иркенлек озак дәвам итми. Бу юлы да шулай булды. Гомер-гомергә бер милләтле дәүләт төзергә хыялланган Мәскәү, нефть бәяләре арту аркасында бераз тернәкләнә башлауга, яңадан шул күптәнге хыялын тормышка ашырырга тотынды. Белгәнебезчә, дөнья тәҗрибәсендә бер президентны икенче президентның билгеләп кую мисалы юк. Әгәр безнең

президентыбыз киләчәктә кемдер тарафыннан билгеләп куела икән, димәк, Татарстан республика буларак, дәүләт буларак яшәүдән туктый, Россиянең гап-гади бер өлкәсенә әйләнеп кала дигән сүз. Ә моны тормышка ашыру өчен иң элек Россиянең Конституциясен үзгәртергә, аның 5 нче маддәсендәге «милли республикаларның дәүләт булуы» хакындагы юлларны сызып ташларга кирәк булачак.

Әйе, безгә тәкъдим ителгән закон проектында президентыбызның Россия Президенты тәкъдиме белән Татарстан парламенты тарафыннан сайланып куелачагы әйтелә. Ләкин бу чираттагы күз буяу гына. Россия Президенты ике мәртәбә рәттән тәкъдим итеп тә, парламент ул кандидатураны расламаса, безнең Дәүләт Советы куып таратылачак. Бу бит инде турыдан-туры куркыту, өркетү, көч куллану дигән сүз. Шулай булгач, монда ничек инде халыкның ирекле сайлау хокукы хакында сүз алып барырга мөмкин? Закон проектында ачыктан-ачык әйтелгән... «Мин сезгә президентлыкка бер кандидат тәкъдим итәм. Сез йә шул бер кеше арасыннан бер кешене сайлап раслап куясыз, йә мин сезне куып таратам. Ә тараткannan соң, барыбер шул ук кешене президент итеп билгелим. Димәк, нишләсәгез дә, барыбер минемчә була». Ничек кенә тырышсам да, мин мондый вертикаль ныгытуның демократик принципларга туры килүен, бу куркытып билгеләп куюның ни өчен «сайлау» дип аталуын аңлый алмадым.

Россиянең иң зур бәласе – үз халкына ышанмауда, үз халкын яратмау, хөрмәт итмәүдәдер. Бүген генә түгел, гасырлар буена дәүләт халыкны юләрсетеп, алдап килде. Әле безнең гомердә генә, күзгә туры карап, иң зур трибуналардан: «Сез коммунизмда яшәячәксез», – дип алдадылар. Аннары 2000 елда бөтен кешене дә фатирлы итәбез дип алдадылар. Аннары: «Күпме теләсәгез, шулкадәр ирек алыгыз», – дип вәгъдә иттеләр дә берничә елдан соң барлы-юклы ирегебезне дә тартып алдылар. Менә бүген тагын халыкка, илгә бу үзгәрешләрнең нинди яхшылыклар алып килүен, демократик принципларның, халыкара хокук нормаларының бозылмаячагын вәгъдә итәләр. Мине, хәтта илдәге дәүләт корылышының үзгәрешеннән, республикаларның хокуклары кысылудан да бигрәк, дәүләтнең үз гражданнарына ышанмавы, үз республикаларын, өлкәләрен санга сукмавы, алар белән исәпләшмәве ныграк рәнҗетә.

Күзләрем белән күреп, күңелем белән сизеп торам: бу закон проектын Россиядәге бөтен төбәкләр дә, шул исәптән безнең парламент та яклап тавыш бирәчәк. Берәүләр моны безнең бердәмлегебез билгесе дип аңлатыр. Бәлки, алар үзләренчә хаклы да булыр. Моннан гасыр ярым чамасы элек бөек француз язучысы Виктор Гюго исә: «Бөтен кеше дә бертөрле уйлый торган җирдә, гадәттә, беркем дә уйламый», – дип әйткән булган. Кем белә, бәлки, Виктор Гюго тагын да хаклырактыр... Анысын инде вакыт галиҗәнаплары күрсәтер.

Әгәр дә Россия киләчәктә дә шулай Жириновский-Рогозиннар сызган юлдан баруын дәвам итсә, безне алда әле тагын да зуррак сынаулар көтәчәк. Ләкин без ул сынаулар алдында сыгылып төшәргә, мәшһүр шагыйребез әйтмешли, «вакытында җирне селкеттек, инде беттек, инде беттек» дип күз яше сыгып, өметсезлеккә бирелеп утырырга тиеш түгелбез. Кемнәр ничектер, ә мин үз халкыма, республикабыз халкына ышанам. Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында тарихның иң катлаулы сынауларыннан да исән чыккан халык бүген дә югалып калмас, үзенең туры сүзен әйтер, үзе сайлаган депутатларга һәм дәүләт җитәкчеләренә катгый таләпләрен куяр һәм, иң мөһиме, мәдәниятле, мәгърифәтле, туган телле һәм дәүләтле халык булып яшәү хыялыннан беркайчан да ваз кичмәс дип ышанам.

Россия – бик тә үзенчәлекле һәм сәер ил. Хакимияткә килгән һәр илбашы анда үзенең эшен реформалар ясаудан башлый. Һәр президентның, хөкемдарның үз революциясе була. Шуңа күрә дә безнең яшәү өчен, рәхәт тормыш кичерү өчен бирелгән бердәнбер гомеребез үзебез теләгәнчә яшәп түгел, ә кемнәрдер белән көрәшеп, кемнәрнедер җиңеп, кемнәрдәндер җиңелеп үтә. Узган бер гасыр эчендә генә дә без инде ничәмә-ничә реформа кичердек, ничәмә-ничә революциянең канлы көрәшләрен уздык. Мең, миллионнарча корбаннар биреп булса да, шушы көнгә кадәр килеп җиттек.

Алла боерса, монысы да үтәр һәм без чираттагы бу сынаулардан да исән-имин чыгарбыз дип өметләнәм.

Чыгышымны бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 1908 елда язган һәм бүген дә бик актуаль шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгъмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып,
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

Бел, хәзер дөнья кяфергә һәм сиңа җәннәт әле;
«Мөэминә зиндан» булыр ул, тотса мәскәүләр якаң!

*2004*

# ГАДЕЛ БУЛЫЙК!

*(2005 ел бюджеты турында)*

Елның-елында, Дәүләт Советында алдагы ел бюджеты каралганда, безнең Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты иң күп тавышланучы, иң күп дәгъвалаучы, иң күп сораучы, дөресрәге, соранучы комитет була. Моның башкача булуы мөмкин дә түгел. Чөнки безнең комитет белән мөнәсәбәттәге министрлыклар, дәүләт оешмалары һәм учреждениеләре, нигездә, бары тик бюджет хисабына гына яши һәм эшли ала.

Икенче яктан караганда, республикабыз халкының аң-белем дәрәҗәсен үстерү, халкыбызның меңнәрчә еллык тарихын һәм мәдәниятен саклау, яңарту, халкыбыз рухын баету, фән казанышларыбызны дөньякүләм югарылыкка җиткерү, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне цивилизацияле хәл итү мәсьәләләре республикабыз тормышының, яшәү рәвешебезнең нигез ташлары булып тора. Ә инде нигез ташларын җимермәү һәм җимерттермәүнең никадәр әһәмиятле икәнлеге һәр җитәкчегә, һәр депутатка, һәр ватандашыбызга ачык билгеле.

Аңлашыла ки, боларны тормышка ашыру өчен бүген беренче чиратта акча кирәк. Билгеле, без һәммәбез дә сораган кешене түгел, биргән кешене яратабыз. Әмма без бүген монда ярату-яратмау, мәхәббәт турында сөйләшү өчен түгел, ә булган байлыгыбызны ничек гадел итеп бүлү хакында фикер алышырга җыйналдык.

2005 ел бюджет проекты Дәүләт Советына килеп җитүгә үк, без аны үзебезнең комитетта җентекләп өйрәнә башладык. Хөкүмәт әһелләре, бигрәк тә Финанс министрлыгы җитәкчеләре белән кат-кат киңәштек. Нәтиҗәдә инде безнең кайбер сорауларыбызга ачыклык та кертелде. Мәсәлән, киләсе елга бюджетта эшләүчеләрнең хезмәт хаклары 20 процентка артырга тиеш булса да, нишләптер иҗат әһелләре өчен хезмәт хакы булган гонорарларны арттыру бюджет проектында каралмаган иде. Бу хактагы безнең тәкъдимебезне тиз арада өйрәнеп, хәл итү чараларын күргән өчен иң беренче чиратта премьер-министр Рөстәм Нургали улы Миңнехановка һәм финанс министры Радик Рәүф улы Гайзатуллинга рәхмәтләребезне җиткерәсем килә.

Республика бюджетының иң зур өлешен дәгъвалаучы өлкә ул –мәгариф өлкәсе. Бу аңлашыла да. Мәктәпкәчә тәрбия, башлангыч һәм урта мәктәптә уку-укыту, урта һәм югары белемле һөнәр ияләре әзерләү, булган белгечләрнең белемнәрен арттыру, камилләштерү – җәмгыятьнең иң мөһим бурычы һәм әлеге бурычны үтәү өчен без кулдан килгәннең барысын да эшләргә тиеш. Киләсе ел бюджеты боларның һәммәсен дә исәпкә алырга тырышып төзелгән. Шулай да безнең комитетның бюджет проектына кайбер җитди тәкъдимнәре дә бар. Без сессиянең узган утырышында Мәгариф министрлыгын президентыбыз тәкъдиме белән «Мәгариф һәм фән министрлыгы» дип үзгәрттек. «Фән» дигән гаять катлаулы һәм бюджет финанславыннан башка яши алмый торган өлкә килеп өстәлгәч, министрлыкның вазифалары, эш даирәсе дә билгеле бер күләмдә артачак. Ә арткан вазифаларны үтәү өчен кирәкле күләмдә финанс чыгымнары таләп итела. 2005 елга исәпләнгән бюджет проектында бу мәсьәлә әлегә ачык калган. Әлбәттә, без бюджет проектының министрлык үзгәртеп корылуга кадәр үк эшләнә башлавын аңлыйбыз һәм шуңа күрә беркемне дә гаепләргә җыенмыйбыз. Әмма бюджет проектын беренче укылышта кабул иткәч, бу мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтып, күпме өстәмә чыгым кирәклеген санап, ул сумманы өстәмәсәк, Мәгариф министрлыгын үзгәртеп коруыбыз матур бер документ булып кәгазьдә генә калачак.

Бюджеттан җитәрлек дәрәҗәдә акча бүлеп бирелмәү сәбәпле, мәгариф өлкәсенең елдан-елга көчеп һәм ишәеп, зураеп баручы берничә проблемасын исегезгә төшереп үтәсем килә:

– мәктәпләрдәге җиһаз, мәктәп остаханәләрендәге станокларның тузу-җимерелүе бүгенге көндә 60 проценттан 80 процентка кадәр җитә. Бюджетта бу мәсьәләне хәл итү өчен акча каралмаган;

– республикабызда махсус белемле эшче көчләргә кытлык зур булса да, Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2005–2008 елларда башлангыч һөнәри белем бирү программасына финанс чыгымнары күздә тотылмаган;
– 2000–2002 елларда президентыбыз инициативасы һәм Дәүләт Советы карары белән уку-укыту учреждениеләренә 3 еллык гарантия белән 13 мең компьютер алынган иде. Хәзер аларның гарантия вакыты чыкты. Аларга сервислы хезмәт күрсәтү мәсьәләсе дә бюджет проектында юк;
– Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасында инновация белемен үстерү буенча 2005–2010 елларга программа төзегән иде. Бу хакта Куркынычсызлык советында һәм укытучыларның август конференциясендә ныклы вәгъдәләр бирелгән булса да, аңа да нишләптер бюджет проектында урын табылмаган;
– дәреслекләрнең бәясе дә елдан-ел арта бара. Ә 2005 елга исәпләнгән бюджет проектында республика мәктәпләренә дәреслекләр алу өчен 2004 елгы күләмдә генә чыгым карала. Бу очракта бәяләр артуны искә алмасак, балаларыбызның 20–30 проценты дәреслекләрсез генә укырга мәҗбүр булачак.
Безнең комитетның исеме юкка гына «мәдәният» сүзеннән башланмый торгандыр. Чөнки кешене кеше иткән нәрсә иң беренче чиратта хезмәт тә, хәтта спорт та түгел, ә мәдәният-культура, мәгърифәт һәм фәндер. Халкының һәм дәүләтенең киләчәге турында кайгырткан кеше иң беренче чиратта менә шушы өлкәләргә игътибар итәргә тиеш. Без барыбыз да моның шулай икәнен бик яхшы аңлыйбыз, әмма акча бүлешер вакыт җиткәч, нишләптер тагын каты терсәкле, тыгыз бәдәнлеләр алга чыга, ә мәдәният, мәгариф, фән әһелләре бер читтә моңаеп карап кала. Моннан ике атна элек хөкүмәтебез киләсе 2005 елда гамәлдән чыгарылып торучы программаларның һәм үз карарларының исемлеген игълан итте. 28 пункттан торган бу исемлекнең шактый өлешен әлеге дә баягы мәдәният, мәгариф, фән өлкәләре алып тора, димәк, алар киләсе елда да акча чыганакларыннан мәхрүм калачаклар, димәк, бу өлкәдә үсеш, алга китеш булмаячак... Димәк, республикадагы авария хәлендәге йөзләрчә клубларыбыз, китапханәләребез, мәктәпләребез, музейларыбыз, тарихи һәйкәлләребез ремонтланмаячак. Ә инде янгыннан соң 15 ел буена сафка баса алмаган Үзәк музеебыз, 6 хөкүмәт карары чыгып та, яңа бина күрә алмаган Милли китапханәбез турында сөйли-сөйли безнең телләребез талды. Алтын-көмешкә төрелгән банклар, хакимият биналары, баскет-холлар, спорт сарайлары салырга каяндыр акчасы да, инвесторлары да табыла, ә мәдәнияткә, мәгарифкә, фәнгә дигәндә, һаман бер сүз – «акча юк».
Без инде ничәмә-ничә ел буе халкыбызның күренекле фән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә һәйкәлләр, бюстлар кую турында сүз алып барабыз, ел саен исемлекләр төзибез. Әмма бу эшнең әле һаман урыныннан кузгалып китә алганы юк. Безнең комитет киләсе елда Казанның 1000 еллыгы уңаеннан башкалабызда халкыбызның иң данлыклы, иң күренекле шәхесләренә инде, ниһаять, һәйкәлләр куелыр дип өметләнә. 2005 ел бюджетында бу мәсьәлә һичшиксез хәл ителергә тиеш.
Соңгы арада мәдәният учреждениеләре өчен аренда түләве 20 мәртәбә артты. Казан музыка училищесында ул, мәсәлән, хәтта 23 мәртәбәгә арткан. Ә бу чыгымнар нишләптер киләсе елгы бюджетта каралмаган.
Янгын, террорчылык һәм диверсион куркынычларны кисәтү мәсьәләсе бүген бөтен ил күләмендә кискен тора. Әмма мәдәният йортларын, театрлар һәм башка халык күп җыела торган тамаша биналарын бу афәттән саклау өчен чыгымнар бюджет проектында күренми.
Фән өлкәсенә тотылган чыгымны кайберәүләр юкка әрәм ителгән, суга салынган акча дип саныйлар, ахрысы. Фәннәр академиясе сораган акчаның елдан-ел яртылаш кына бирелеп барылуын югыйсә мин башкача аңлата алмыйм. Ә ныклабрак уйласаң, фәнгә бүген бирелгән бер сум акчаның берничә елдан ун, хәтта йөз сум булып кире кайтуы көн кебек ачык бит! Мәсәлән, моңа кадәр безнең фундаменталь фәнебез эшчәнлеген оештыручы, үстерүче НИОКР фондыбыз бар иде. Аның ярдәме белән галимнәребезнең бик күп фәнни ачышлары халкыбыз һәм республикабыз файдасына эшли башлады. Яңа бюджет проектында исә НИОКР фонды бөтенләй күренми. Киләчәктә ул федераль дәрәҗәдә ничек хәл ителер? Аның эшен кем һәм нинди финанс чыганакларына нигезләнеп алып барыр? Безгә бүген бу сорауларга төгәл җавап табарга кирәк.

Бюджет проектын эшләүчеләр бу сорауларны колакларына элеп, икенче укылышка кадәр аңа ачыклык кертсеннәр иде.

2005 елга бюджет проектын әзерләгән вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Бауман урамындагы төп бинасыннан Кремль эчендәге башка бер иске бинага күчерелде. Анда тиешле шартлар тудыру, ремонт эшләре башкару өчен 2005 ел бюджетында чыгымнар каралырга тиеш.

Соңгы елларда безнең республикада аеруча зур үзгәрешләр кичергән өлкә ул – гомуми мәгълүмат чаралары һәм матбугат.

Иҗат берлекләре, газета-журналлар, нәшриятлар, радио-телевидение компанияләре үз кыйблаларын табу, үз эшчәнлекләрен дәвам итү һәм камилләштерү өчен сарыф итәргә, иҗат белән шөгыльләнергә тиешле алтын вакытларын бакыр акча эзләп үткәрергә мәҗбүрләр. Дөрес, мәгълүмат чаралары гел бюджетка гына өмет итеп утырмаска, төрле юлларын табып, үзләре дә акча эшләргә тиештер. Әмма бездә малтабарлык һөнәре, реклама эше тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган, бигрәк тә милли матбугат органнарының бу ысул белән акча табу мөмкинлекләре бик нык чикләнгән.

Киләсе елда мәгълүмат чараларының эшчәнлеген тәэмин итү, яңаларын ачу өчен «Татмедиа» агентлыгы бюджеттан 154 миллион сум өстәмә акча сорый. Без бу хакта әле хөкүмәт әһелләре белән тагын бер кат фикер алышырбыз, икенче укылышка үзебезнең конкрет тәкъдимнәребезне бирербез дип уйлыйм.

Төнлә утырып язган шушы чыгышымны иртән укып чыктым да кинәт моңсу булып китте, хәтта күзгә яшьләр килде. Җитмәсә, колак төбендә телевизордан субъектларның хокукларын киметү, федераль бюджетка күбрәк керем бирү турында туктаусыз сөйләп торалар. Россия җитәкчелеге көчәнә-көчәнә үзенең вертикаль органнарын торгызырга, ә безне горизонталь хәлгә куярга, җиргә сузып салырга тырыша. Менә шундый шартларда безгә нишләргә, үз-үзебезне саклап калу өчен нинди гамәлләр кылырга, каян өстәмә керем чыганаклары табарга, халкыбызның тормышын яхшырту өчен нинди чаралар күрергә кирәк? Гел зарланып йөрүдән, йөз депутат бергәләшеп хор белән елап утырудан файда чыкмас, бу катлаулы сорауларга хөкүмәт әһелләре белән бергәләп җаваплар эзләргә туры киләчәк. Ә бүген исә 2005 ел бюджеты проектын беренче укылышта кабул итеп, иртәгәдән аңа үзебезнең өстәмәләребез һәм төзәтмәләребезне әзерли башларга кирәк дип саныйм.

*2004*

# 2006 ЕЛГА ҖИТДИ ӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН

Күптән түгел республикабыз министрлыклары һәм Министрлар Кабинеты карамагындагы оешмаларның 2005 ел йомгакларына багышланган коллегия утырышлары булып узды. Алар Татарстан Республикасының иң югары җитәкчеләре катнашында үтте. Коллегия утырышлары турында массакүләм мәгълүмат чаралары чыгышларын игътибар белән карап баручы һәм кайбер коллегия утырышларында катнашучы буларак, мин бу коллегияләр эшен 2006 елгы бюджетыбызга җитди әзерләнү чаралары дип бәяләр идем. Коллегия утырышларында сүз, нигездә, 2005 елгы эшләр турында барса да, алар киләчәктәге, ягъни 2006 елдагы тормышыбызда нәрсәләрне аеруча искә алырга, кайсы өлкәләргә күбрәк игътибар итәргә, икенче төрле әйткәндә, алдагы ел бюджетын беренче чиратта кайсы максатларга юнәлтергә икәнен билгеләргә тырыштылар. Дәүләт Советының бүгенге утырышында карала торган 2006 елгы бюджет проектын без, телибезме, теләмибезме, әнә шул коллегияләрдә әйтелгән фикерләр, теләкләр, тәкъдимнәр белән чагыштырып карарга, бюджет проекты министрлыклар һәм дәүләт органнары күтәргән мәсьәләләрне искә алганмы, әллә аларга күз йомганмы икәнлеген ачыкларга мәҗбүрбез. Чөнки алдагы елгы бюджет әлеге министрлыклар һәм дәүләт органнарының эшчәнлеген дөрес оештыру, шуның аша республикабыз халкы тормышын яклау, мөмкин булса, аны яхшырту максатыннан эшләнә һәм кабул ителә.

Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе буларак, мине бюджет проектының республикабыз тормышының әнә шул өлкәләренә багышланган өлешләре кызыксындыра. Бу урында быелгы, ягъни 2005 елгы бюджет һәм аның үтәлеш нәтиҗәләре турында да берничә сүз әйтеп китәсе килә. Без инде ничәмә дистә еллар еллык бюджет кабул итәбез һәм ел азагында аның үтәлмәвеннән, ягъни бюджетта каралган акчаның байтак өлеше бүлеп бирелгән субъектларга килеп җитмәвеннән зарлана килдек. Быел, Аллага шөкер, бюджетта каралган акча тулысы белән диярлек адресатларына барып җитте. Әле алда елның тагын ике ае бар икәнен искә алсак, 2005 елгы бюджетның 100 процент үтәлү мөмкинлеге дә бар дип фараз итә алабыз. Бу бюджетны төзүчеләрнең дә, аны кабул итүче депутатларның да, бюджет үтәлүгә җаваплы түрәләрнең дә йөзенә кызыллык китерми дигән сүз.

2005 елгы бюджет мәдәният өлкәсендә аеруча күзгә күренерлек гамәлләр кылды дип әйтергә мөмкин. Беренче чиратта ул Казаныбызның 1000 еллык юбилее белән бәйләнгән иде. Менә берничә генә мисал: ничәмә-ничә еллар җәмәгатьчелек таләп иткән эшләрдән бөек шагыйребез Кол Галигә, сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшевкә һәйкәлләр салынды, Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры иң югары сыйфат белән реставрацияләнде, Милли музеебызның төп өлеше, ниһаять, яңадан торгызылды. Шуларга өстәп бөек рус шагыйре Державинга, бөек актер Качаловка, төрки халыклар тарихын өйрәнүгә гаять зур көч куйган Лев Гумилёвка һәйкәлләр салынуны, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Качалов исемендәге Рус драма театры, Чаллы һәм Бөгелмә театрлары биналарын, Чаллыдагы орган залын реконструкцияләүне, Казан Кремлендә Эрмитаж үзәге булдыруны искә алсак, әлбәттә, республикабыз мәдәни тормышының нигез ташларын тәшкил иткән бу объектларның төзелүе, яңаруы, үзгәртеп корылуы барыбыз өчен дә күркәм күренеш. Шул ук вакытта Кәрим Тинчурин исемендәге театр, Казан курчак театры, Татар яшь тамашачылар театры, филармониянең концерт залы биналарының заман зәвыгына һич кенә дә җавап бирмәве, Татарстан милли китапханәсенең яңа бинасын төзү эшенең инде ничәмә-ничә еллар буе чигерелеп килүе, Казан зоология һәм ботаника бакчасының инде тәмам юкка чыгу дәрәҗәсенә килеп җитүе безне бик тә борчый. Болар барысы да турыдан-туры республикабыз бюджеты, финанс чыгымнары белән бәйле. Безнең комитет әлеге өлгереп җиткән мәсьәләләрнең бюджетта бөтен төгәллеге белән чагылыш табуын тели. Без бу мәсьәләләрне бюджет проектын икенче укылышка әзерләгән төзәтмә таблицабызда һәрберсен ачык итеп чагылдырырбыз.

Казанның 1000 еллыгы турында сүз чыккач, шунысын да әйтеп китәргә кирәк: республикабызда, бигрәк тә Казан шәһәрендә, бу олы юбилейга багышланган спорт һәм ашап-эчеп, комарлы уеннар уйнап күңел ача торган корылмалар мәдәни биналарга караганда күпкә артык һәм зур колач белән төзелде, үзгәртеп корылды. Ә менә мәгариф һәм фән өлкәләренә караган биналарга игътибар зур булды дип әйтеп булмый. Дөрес, үзенең дә юбилее үткәрелгән Казан дәүләт университеты биналары төркеме (комплексы) иң югары дәрәҗәдәге сыйфат һәм зәвык белән торгызылды, Татарстан һәм Болак урамнары чатында яңа университет өчен өр-яңа бина салынды. Әмма Татарстандагы фәнни үзәк булган Фәннәр академиясе эшләү шартлары булган бинасыз калды. Шулай ук Казанның үзәк һәм кунаклар йөри торган урамнарыннан читтә, ягъни кварталларда урнашкан югары, махсус һәм гомуми урта белем бирә торган училищелар һәм мәктәпләр, нигездә, элеккеге кыен хәлләрендә кала бирделәр. Шул ук вакытта 2006 елгы бюджетта аларның уку кабинетларындагы һәм остаханәләрендәге җиһазларның тузуы – 60, кайчакта хәтта аннан да күбрәк процент тәшкил итә. Аларны яңарту өчен 2006 елда кимендә 12 миллион сум акча кирәк. Республикадагы мәктәп-интернатлар, балалар йортлары, коррекция мәктәпләре, һөнәр училищелары һәм техникумнарындагы ашханәләр һәм азык-төлек блоклары суыткычлары һәм технологик җиһазларының тузу дәрәҗәсе 45 тән 62 процентка кадәр җитә. Аларны яңарту өчен киләсе елга 17 миллион ярым акча кирәк. Шулай ук физик яктан зәгыйфь балаларны укыту йортларын һәм укыту-тәрбияләү эшләрен тәртиптә тотарга да бюджет проектында финанс чаралары җитәрлек каралмаган. Быел дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләрен финанслау мәсьәләсе дә бик нык катлауландырылды. Кайбер җитәкчеләр һәм хокук хезмәткәрләренең федераль законнарны дөрес аңлатмаулары аркасында Татарстанда дәүләтнеке булмаган, ләкин дәүләт стандартлары белән укытыла торган мәгариф учреждениеләре дәүләт ярдәменнән мәхрүм калу куркынычы астында тора. Федераль законнар регионнарда дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләренең региональ бюджетлардан финанслануына каршы килми. Ә бездә моны аңларга теләмиләр. Без андый мәгариф учреждениеләренең дәүләт мәнфәгатьләренә туры килгәннәренә финанс ярдәме күрсәтү ягында. Безнең комитет бу мәсьәләләрдә дә төзәтмәләр таблицасы эшләячәк.

Былтырдан башлап мәгариф һәм фән эшләрен бер министрлык башкара. Быел фән өлкәсендә безнең катлаулы мәсьәләләр аеруча күбәеп китте. Моңа өлешчә фән турындагы федераль закондагы җитешсезлекләр һәм ул законга ялгыш аңлатма бирүләр сәбәпче булды. Татарстан Фәннәр академиясе бинасыз гына түгел, бөтенләй статуссыз һәм финанссыз кала язды.

Безнең комитет Татарстан Фәннәр академиясен саклап калу һәм аны 2006 елгы бюджет белән дәүләт яклавына алу ягында. Татарстандагы фәнни хәрәкәтне яклап, безнең Комитетка күп кенә мөрәҗәгатьләр килә. Әйтик, бөтенроссия сәяси партиясе «Бердәм Россия»нең Татарстан региональ бүлеге башкарма комитеты рәисе В. Н. Бударин «Дулкын» Гравитация дулкыннарын өйрәнү үзәге фәнни эзләнүләрен дәүләт тарафыннан финанслауны сорап хат җибәргән. Бездә шулай ук Татар энциклопедиясенең татар телендәге томнарын чыгаруга, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты биналарына коммуналь һәм аренда түләүләренә ярдәм итүгә, бигрәк тә республикабыздагы фундаменталь һәм гамәли эзләнүләргә бюджет тарафыннан финанс чыгымнары каралуны сорап язган хатлар, мөрәҗәгатьләр бар. Безнең комитет боларны да, бюджет икенче укылышта каралуга әзерләнгәндә, төзәтмәләр таблицасында чагылдырачак.

Соңгы елларда массакүләм матбугат чаралары тормышында зур үзгәрешләр бара. Базар мөнәсәбәтләре бу өлкәдә дә нык активлаша. Бүгенге көндә дәүләтнеке булмаган нәшриятлар чыгарган китаплар, газета-журналлар, радио-телевидение тапшырулары дәүләт кулында булганнарга караганда да күбрәк сыман. Ләкин шунысы бар: полиграфик яктан дәүләт басмалары күп очракта дәүләтнеке булмаган басма продукттан нык калыша. Шул ук вакытта эчтәлек, әдәби эшләнеш һәм әхлак ягыннан дәүләт кулындагы массакүләм мәгълүмат чаралары күп чакта ота төшәләр. Шуңа күрә бүген китап, газета-журнал нәшер итү, радио-телевидение тапшыруларына дәүләт ярдәмен арттырырга, халкыбызның рухи традицияләрен, һәр халыкның гореф-гадәтләрен, телен, милли менталитетын саклап калуга дәүләт чыгымнарын кызганмау сәясәтен алып барырга иде. Бу мәсьәләләр 2006 елгы бюджетта тулысынча чагылыш тапмаган. Безнең комитетка

матбугат мәсьәләләренә кагылган байтак хатлар, үтенечләр, мөрәҗәгатьләр килә. Без аларның иң әһәмиятлеләрен тәкъдимнәр рәвешендә бюджет проектына төзәтмәләр итеп файдаланачакбыз.

Һәр елның бюджет хәрәкәте берничә баскычтан тора. Без, гадәттә, бюджетны, ярым шаярып, бәлеш белән чагыштырабыз. Бәлеш пешереп ашауның да тәртибе бар. Башта бәлеш ясау өчен базарлар һәм кибетләр буйлап төрле азык-төлек җыясың, аннары аларны эшкәртеп бәлешне ясыйсың, аннан соң аны пешерәсең. Табынга куйгач, бәлешне бүләсе бар. Иң татлы, иң тәмле кисәкләр кемгә эләгә – бу инде бәлеш хуҗалары кулында. Татарстан Республикасы халкы быел 2006 ел бәлеше өчен әйбәт кенә азык-төлек әзерләде – авыл хуҗалыгында уңыш көтелмәгәнчә диярлек мул булды. Нефть табу һәм сату өлкәсе дә Татарстан бәлешенә зур өлеш кушты. Татарстан хезмәт ияләре һәм армас-талмас җитәкчеләребез өстәлендә олы бәлеш пәйда булды. Бу бәлеш инде бәлеш хуҗалары тарафыннан бүленеп тә куелган. Инде безгә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, шушы бәлеш бүленешенә ризалык бирәсе генә калды. Әмма бу да бик катлаулы эш. Бәлеш кисәкләре һәркемгә дөрес бүленгәнме? Кемнәрдәдер үпкә-сапка калмыймы? Ә иң мөһиме, үзенә бүленгән бәлеш кисәге һәркемгә 2006 елдагы тулы эшчәнлеген тәэмин итәрме? Бу урында мин уйланырга, бәлешнең бүленгән һәр кисәгенең гадел булуына ирешергә омтылырга киңәш итәм. Бюджет проектын икенче укылышта караганда моңа мөмкинлек бар әле. Ә әлегә безнең комитет бәлешне шушы хәлендә беренче укылышта кабул итәргә тәкъдим итә.

*2005*

# «БИК КҮП ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫП КАЙТТЫК...»

Депутатның эше – күптөрле, күпкырлы. Дәүләт Советында законнар язып, кабул итеп, үтәлешен контрольдә тотудан гына гыйбарәт түгел. Вәкаләтле орган вәкиле буларак, депутатның республикабыз, халкыбыз исеменнән эш йөртергә, сүз әйтергә хакы бар. Хакыбыз гына түгел, ул безнең бурычыбыз да. Ә инде республикабыз, халкыбыз, сайлаучыларыбыз исеменнән сүз йөртү өчен, билгеле инде, Казанда утырып кына эш йөртеп булмый: чит төбәкләргә, чит илләргә дә чыгарга кирәк була. Анда үзеңнең халкыңны, мәдәниятеңне, сәнгатеңне кайгыртып чыгышлар ясарга туры килә. Билгеле, соңгы елларда чит илләргә бик еш чыгам дип әйтә алмыйм, әмма быел ике илгә бару мөмкинлеге булды.

Апрельдә Төркиягә «Диалог Авразия» (ДА) дигән оешманың эшендә катнашу өчен бардым. «Диалог Авразия» платформасына элекке Советлар Союзының, Азиянең, Европаның кайбер дәүләтләре керә. Безнең уртага салып сөйләшә торган сүзләребез – Европа һәм Азия халыкларының уртак проблемалары һәм аларны хәл итү юллары. Без сәясәткә бик артык кагылмыйбыз, мәдәният, мәгариф, дин, гомумән, рухи дөньяга кагылышлы мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәбез.

Ни өчен бу платформаны төзергә кирәк иде? Чөнки бөтен дөньяда бүгенге көндә глобальләшү процессы бара. Илләр белән илләр, халыклар белән халыклар, дәүләтләр белән дәүләтләр ярыша-көрәшә. Бу көрәштә кемнәрнеңдер җиңеп чыгуы, кемнәрнеңдер җиңелеп калуы мөмкин. Җиңелгән халыклар мәйданнан чыгарга тиеш булалар. Аларның телләре дә, гореф-гадәтләре дә юкка чыгарга мөмкин. Гомумән, кайбер халыкларның бөтенләй юкка чыгуы ихтимал. Бу беренче чиратта әдәбиятка, мәдәниятка кагыла. Ә безнең юкка чыгасыбыз килми. Ә ничек итеп дөнья мәйданыннан китмәскә? Ничек мәдәниятне, әдәбиятны, гореф-гадәтне, мәгарифне, динне саклап калырга? Моның өчен берләшергә кирәк.

Соңгы вакытта Россия Белоруссия белән берләшергә, славян халыкларын үз тирәсенә тупларга тырыша. Инглиз телле, испан телле халыклар да үз проблемаларын бергәләп хәл итәргә омтылалар. Ә ни өчен без – төрки телле халыклар берләшмәскә тиеш әле? Бигрәк тә аз санлы һәм үз дәүләтләре булмаган халыклар мондый берләшүгә мохтаҗ. Шуңа күрә бу платформага (ДА) без бик теләп кердек. Безнең анда татар милли комитеты бар. Анда һәр дәүләтнең берәр милли комитеты эшли. Әмма Казаннан килгән безнең делегация таләбе буенча Россиянең ике милли комитетын (Россия һәм Татарстан) оештыруга ирештек. Татарстан комитеты җитәкчесе итеп мине сайлап куйдылар.

Бу «Диалог Авразия» оешмасы үзенең журналын чыгара. Мин анда редколлегия әгъзасы, Татарстанга, татар халкына багышланган мәкаләләр бастырабыз. Күптән түгел аның Татарстанда вәкиллеген ачтык. Халыкара «ДА» журналының Казанга багышланган махсус санын да чыгардык. Аны егермедән артык илгә тараттык. Журнал төрек, рус, инглиз телләрендә бастырыла.

Чит илләргә баргач, җыелышларда утырып, чыгышлар ясап кына калмыйбыз, мәдәният һәм мәгариф әһелләре белән дә очрашабыз. Бу юлы да шулай булды. Мине бигрәк тә Төркиядәге шәхси мәктәпләр кызыксындырды. Россия һәм Татарстан законнары буенча без дә андый мәктәпләр ачарга хокуклы. Татарстанда нибары 12 шәхси мәктәп бар. Ләкин алар аяныч хәлдә, дәүләтнең финанс ярдәме юк. Шәхси мәктәпләр дәүләт мәктәпләренә конкурент буларак та кирәк. Мәгариф ул – бик консерватив өлкә. Ә шәхси мәктәпләр бик тиз үзгәрә, чөнки алар ата-аналардан җыелган акча исәбенә эшли, шуңа күрә укытучыларның җаваплылыгы да бермә-бер арта. Шәхси мәктәпләрдә акчаның тотылышына ата-аналар контрольлек итә.

Төркиядә мәктәпләрнең 50 проценты – шәхси мәктәпләр, хәлле кешеләр балаларын шунда бирергә тырыша. Ә бездә байлар үз балаларын чит илләргә җибәрә, Татарстанда хәзер андый балалар бернечә йөз. Әгәр үзебездә халыкара дәрәҗәдәге шәхси мәктәпләр ача алсак, бай ата-аналар балаларын шунда бирә алыр, акча да чит илләргә китмәс, салым да Татарстан казнасына

керер, балалар да чит мохиттә чит тәрбия алмас иде. Ә укытучыны чит илләрдән дә чакыртып китереп укытып була бит.
Төркиядә без бу мәсьәләне нык өйрәндек. Алга таба моны хәл итәргә мөмкин булыр дип уйлыйбыз. Казан мэры Илсур Метшин да тәкъдимне хуплады. Казанда киләчәктә халыкара дәрәҗәдәге бер мәктәп ачылырга мөмкин. Андый мәктәпләр булдыру күз уңында тотылырга һәм анда тәрбия мәсьәләсе беренче урынга куелырга тиеш.
Әле күптән түгел Туфан ага Миңнуллин белән Президентыбыз М. Ш. Шәймиев янында булып, төп мәсьәләләрнең берсе итеп шуны куйдык, югыйсә бүгенге көндә мәктәптә тәрбиягә бик аз урын бирелә. Балаларның бозыклыгы, тәртипсезлеге, җинаятьчелек, наркомания – бөтенесе дә тәрбия җитмәүдән килә. Укытучы иң беренче чиратта тәрбияче дә булырга тиеш. Ата-ана баласын укырга биргәндә «кеше булсын» дип бирә бит. Кыскасы, әлеге проблемаларны уртага салып сөйләшүләр булачак әле.
Икенче сәяхәтем күптән түгел Германиягә булды. Анда ПЕН-клуб конгрессына бардык. Халыкара язучылар оешмасы буларак, ПЕН-клуб 1921 елда оештырылган, үзәге – Лондонда. ПЕН-клуб 99 илдән 141 ПЕН-үзәкне берләштерә. Россиядә ике ПЕН-үзәк бар: рус һәм татар ПЕН-үзәкләре. Без анда тулы хокуклы әгъза. ПЕН-клуб ел саен язучыларның Бөтендөнья халыкара конгрессын үткәрә. Быел без бу конгресска Татарстаннан бишәү (Туфан Миңнуллин, Әхәт Мушинский, Харрас Әюпов, Зиннур Мансуров һәм мин) бардык. Безнең төп максатыбыз – татар әдәбиятын дөньяга таныту. Татар ПЕН-үзәге ел саен татар язучыларының ике китабын яисә халык иҗаты әсәрләрен, инглизчәгә тәрҗемә итеп бастырып, дөньяга тарата.
Баруыбызның тагын бер төп сәбәбе – Муса Җәлилнең 100 еллык юбилее. Берлинга килгәндә, Җәлилне дөньяда белүләренә шигебез зур иде. 7 миллионлы кечкенә татар халкының татарча язган шагыйрен – Җәлилне беләләрме икән? Чөнки илләр күп, халыклар күп. Без рус ПЕН-үзәге җитәкчеләре белән, Моабит һәм Плетцензее төрмәләренә барып, шагыйрь утырган камераларга чәчәкләр салып кайттык. Моны белгәч, конгресска килгән язучылар арасында шактый популяр кешеләргә әйләндек, безнең белән исәнләшә башладылар. Уйламаганда-көтмәгәндә конгресста безгә сүз бирделәр. Туфан ага һәм мин, шуннан файдаланып, анда үз ана телебездә Муса Җәлил, татар халкы, татар әдәбияты, Татарстан турында сөйләдек. Чыгышларыбызны инглизчәгә тәрҗемә итеп (Туфан аганың оныгы Данияр тәрҗемә итте, ул Казан дәүләт университетының халыкара мөнәсәбәтләр факультетында укый), бөтен язучыларга тараттылар.
Бездән соң ПЕН-клуб президенты – чех язучысы Груша Муса Җәлил турында чыгыш ясады. Без шаккаттык: батырлыгын да, иҗатын да белә. Германиядә иң гаҗәпләндергәне – 141 илдән җыелган 470 язучы, аягүрә басып, Җәлилне искә алды. Бу инде Түбән Кама, Казан, Татарстан гына түгел, Җәлилнең кадерен бөтен дөнья белә дигән сүз.
Мин моннан гыйбрәт алдым: юбилей алдыннан үз илебездә төрле шәһәрләрдә төрле чаралар уздыру, һәйкәл кую тәкъдимнәрен керткән идек. Шунысы гаҗәп: бөтен дөньяда танылган Муса Җәлилгә үзебездә һәйкәл куяргамы-юкмы, кая куярга – тыкрыккамы, мәктәп ишегалдынамы, мемориаль такта куяргамы-юкмы, дип икеләнеп калучылар булды. Берлинда шуларны уйлап, тетрәнеп калдым. «Бөек рейх»ка каршы эш алып барып, Плетцензее төрмәсендә башы киселгән шагыйрьгә Германиядә шундый хөрмәт. Нәфис фильм чыгарганнар. Шигырьләре дөнья телләренә тәрҗемә ителә. Халыкара дәрәҗәдә ихтирам аңа бүгенге көндә.
Ә бездә, кинотеатрга Җәлил исемен калдырыргамы-юкмы дип (Түбән Каманы күздә тотам), еллар буе бәхәс барды. Бу бернинди әдәп-әхлак кысаларына да сыймый. Үзебез патриотик тәрбия җитми дип сөйлибез. В. В. Путин да күтәрде моны. Ә патриотик тәрбия өчен дөньяда Җәлилдән дә кулай шәхес булырга мөмкинме? Аның тормышын, батырлыгын, иҗатын пропагандалаудан да зуррак патриотик тәрбия булырга мөмкинме? Кинотеатрдан Муса Җәлил исемен сөртеп алып ташлыйбыз икән, моны балалар күреп тора, бу бит антипатриотик тәрбия булачак. Түбән Камада, һичшиксез, иң үзәктә, бик тә күренекле урында Җәлилгә һәйкәл куелыр дип ышанам. Җәлил ул – мәктәп ишегалдына куярга мәктәп директоры түгел, Халыкара масштабтагы зур шагыйрь, герой! Җәлилгә һәйкәл юкка гына Казанда Кремль янына куелмаган.

Германиядә безне югары дәрәҗәдә кабул иттеләр. Германия президенты, федераль канцлер Меркель, Берлин бургомистры белән очраштык. Анда без милләттәшләребез белән, татар рәссамы Шамил Гыймаев белән дә күрештек. Ш.Гыймаев Берлин стенасында кырыклап метрда рәсем ясаган. Ике татар җәмгыяте бар Германиядә. Бик кызыклы яшиләр, җыела торган урыннары, татарча өйрәнү курслары бар. Укытучылары – Казаннан күчеп килгән фәннәр кандидаты Эльмира исемле кыз. Берлинда тюркология институтында татар телен, татар халкын өйрәнүче студентлар да, укытучылар да, галимнәр дә бар.

Шунысы кызык: Берлинның иң матур җирендә, паркта, ел саен Сабантуй үткәрәләр. Бәйрәмгә башка Европа илләреннән дә татарлар килә икән. Быел да уздырырга җыеналар. Сабантуйның видеофильмын карадым: безнең авылда Сабантуй ничек үтә, анда да шулай ук. Шаккаттым: бөтен уеннар, ярышлар безнең авылдагыча. Ат чабышы гына юктыр, Берлинда ат каян алсыннар, дип уйлаган идем. Хәтта анысын да уйлап тапканнар: малайларын җилкәләренә утыртып, ат урынына ир-атлар узыша. Кызык, үзләре тәгәри-тәгәри көләләр. Батырга тәкәсен дә тапканнар. Безнең халык үлми, татар, кая гына китсә дә яши икән. Телен онытмаска, динен дә, йолаларын, гореф-гадәтләрен дә сакларга тырыша.

Тагын бер гаҗәпләндергән нәрсә – Берлинда көндез урамда кеше бик аз, берән-сәрән генә. Озатып йөрүчеләрдән, нишләп болай халык күренми, йоклыйлармы әллә, дип сорагач, ник урамда булсын, бездә халык эштә, урамда йөрүчеләр туристлар алар, диделәр. Биш миллион кеше яши торган Берлиндагы тәртипкә, чисталыкка да исебез китте.

Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшкән татарларның зиратын да эзләп бардык. Берлиннан 50 километр ераклыкта урман эчендә икән. 209 татар әсире җирләнгән, исемнәре язып куелган. Кабер ташлары, зур һәйкәл дә бар. Барысы да пөхтә эшләнгән, зираттагы тәртипкә, чисталыкка гаҗәпкә калдык. Немецлар үзләренә каршы сугышкан кешеләрнең каберләрен дә шулай тәртиптә тоталар икән.

Туфан абый белән без ПЕН-клуб җитәкчесе Груша белән, язучыларның мондый конгрессын Казанда уздырып булмасмы, дип сөйләшкән идек. Бу мәсьәлә аларны кызыксындырды. Бигрәк тә башкалабызның 1000 еллыгы узганнан соң. Казан – Көнбатыш һәм Көнчыгыш культурасының, ике диннең очрашкан, кисешкән урыны, бик кызыклы шәһәр, дип әйттеләр. Үзебезнең җитәкчеләребез белән уртак тел таба алсак, 2009 елда Бөтендөнья язучылары конгрессын Казанда уздыру мөмкинлеге тууы ихтимал. Аны уздыру өчен күп илләр чиратта тора. Конгресс 2007 елда – Сенегалда, 2008 елда Мексикада узачак. Әгәр 2009 елда үзебездә уздыра алсак, Татарстанны дөньяда таныту өлкәсендә зур вакыйга булыр иде.

Игътибарыбызны җәлеп иткән бик кызыклы тагын бер нәрсә: бездә әгәр дә татар кызы руска кияүгә чыкса, бик сирәк очракта гына ире аның телен өйрәнә, аның гореф-гадәтләрен кабул итә. Безгә Берлинда төрле гаиләләр белән очрашырга туры килде. Татарларны мактап сөйләгән немец егете Марк безнең белән рәхәтләнеп татарча сөйләште. Мәскәүдә укыганда Әлфирә исемле татар кызына өйләнгән. Әлфирә аңа шарт куйган: «Минем телемне өйрәнсәң генә кияүгә чыгам, авылга кайткач, әнием белән татарча сөйләшерлек булсын. Әнием белән татарча сөйләшә алмый торган кешегә мин кияүгә чыга алмыйм, югыйсә болай да чит милләт кешесенә чыгуымны хупламыйлар, авылда миңа оятка калырлык булмасын», – дигән. Берлинда яшәүче бу немец егете татар телен өйрәнгән.

Тагын бер татар кызы яһүдкә кияүгә чыккан. Шул яһүд, хатынының таләбе буенча, Берлинга татар теле курсларына йөреп, хатынының телен өйрәнә. Инде безнеңчә аңлый башлаган. Ә үзебездә хәтта күршедә яшәүчеләр татарча исәнләшергә өйрәнмиләр дә, теләмиләр дә. Бер-береңнең телен, гореф-гадәтләрен өйрәнеп, хөрмәт итеп яшәгәндә генә чын дуслык була ала.

Германиядән без бик күп гыйбрәтләр алып кайттык. «Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал» дип юкка гына әйтмидер инде безнең халык.

*2006*

# МИЛЛӘТКӘ – ӘФЬЮН

*(Татарстан Республикасы Президенты*
*Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә мөрәҗәгать)*

*Мөхтәрәм Минтимер Шәрип улы!*

Дәүләт кадәр дәүләт сүтелгәннән соң, җәмгыятьтә күчеш чоры вакытында менә икенче дистә ел инде көн саен төрле бәла-казалар булып тора. Шөкер, аларның күбесе хәл ителеп килә, һәм тормышыбыз камиллеккә таба бара. Ләкин һәр чор, үзенең яңа авыруын да китереп чыгарып, рухиятебезне гариплэндерүче яңадан-яңа шаукымнарга җирлек бирә. Без уңышларыбызга артыграк куанып җибәреп, аяк астында гына яткан бик куркыныч афәтне күз уңыннан ычкындыргандыз; әлеге афәт, шушы рәвешле дәвам иткән очракта, безне иртәме-соңмы коточкыч фаҗигагә китерәчәк.

Сүз бүгенгесе көндәге җыр сәнгатенең халыкны гариплэндерүче әфьюнга әйләнеп баруы хакында. Радио-телевидение аша һәм концерт залларында яңгыраган күп кенә мәгънәсез, төссез һәм оятсыз җырлар халыкның зәвыгын тупасландыра, рухын гариплэндерә. Композиторларны көй язарга, авторларны җыр сүзләре иҗат итәргә, җырчыга җырларга өйрәтеп алтын киңәшләрегезне бирсәгезче дип мөрәҗәгать итүебез түгел. Хосусый милек икътисадта шәп нәтиҗәләр бирә алса да, рухият, тәрбия өлкәсендә дәүләт контроле юкка чыгарга тиеш түгел дип беләбез! Андый контроль хәтта икътисадта да бар. Татарстан дәүләте бу өлкәдә төп координатор – эшләрне җайга салучы, көйләүче, буразнадан читкә тайпылырга ирек бирмәүче бердәнбер вәкаләтле көч дип исәпләп без ялгышмыйбыз.

Әйе, аңлашыла, сәнгать аерым кулларга күчеп бара. Базар икътисады заманында бу уңай күренеш. Ләкин дәүләт шәхси кибет хуҗаларына, бозылган ит, казылык яки бүтән ризыкны саттырып, гавамны агуларга мөмкинлек бирми бит! Ә «хосусый эстрада фабрикалары һәм кибетләре» рәхәтләнеп халыкны исәнгерәйтү, гариплэндерү эшен дәвам итә.

Хәер, искергән казылыктан соң адәм баласы ашказанын юдыртып яки клизма ясатып фаҗигадән котыла ала. Ләкин кешенең күңеленә, рухына, баш миенә «клизма» ясап булмый бит! Зинһар, безне дөрес аңлагыз! Бу – җан авазы, йөрәк тавышы. Ниндидер аерым кеше-авторларның һәм шәхси компанияләрнең җыр сәнгатендә эшләргә лицензияләре булса да, яшь буынны, милләтне рухи яктан гариплэндерергә лицензия-хокуклары юк лабаса!

Сезнең күптән түгел әйткән фикерегез әдәбият, сәнгать һәм тәрбия өлкәсендә гамәл кылучыларга бу болгавыр заманда төп критерий булырга тиеш. Тормышыбызга бик куркыныч чир үтеп керде: ул – төрле тискәре күренеш-гамәлләргә кешенең акрынлап ияләшә баруы, күнегүе (привыкание) дигән олуг фикер ишеттек без Сезнең авыздан узган язда.

Буш көйләргә, тозсыз, оятсыз сүзле һәм мәгънәсез җыр текстларын такмаклап сикергән җырчы кисәкләренә тамашачыбыз бер күнегеп, ияләнеп китә икән, соңыннан аның рухын сафландыру, күңелен нурландыру гаять кыен булачак...

Сезнең Указ нигезендә быелгы ел Әдәбият-сәнгать елы дип игълан ителде. Һәм өстебездә торган афәттән нәкъ быел ук арына алмасак, бу хатаны киләсе ел төзәтер дигән бернинди өмет-ышаныч юк бездә.

Дөрес аңлашылсын, без цензура кертергә җыенмыйбыз, андый гамәлдән Ходай сакласын! Үз заманында Руслан Аушев дигән күренекле шәхес һәм зирәк акыллы сәясәтче, «Экспресс-газета» кебек «чүп чиләкләре»н Ингушетия территориясенә кертүне махсус Указ белән тыеп, милләтен аз гына булса да рухи пычранудан аралап кала алган иде.

Безнең анык тәкъдимнәр шуннан гыйбарәт: Мәдәният министрлыгы каршында сәнгать киңәшмәсе төзергә. Аның составына өлкән буын, урта буын һәм яшь буын әдәбият-сәнгать әһелләре (композитор, язучы, җырчы) керергә тиеш. Киңәшмәне компетентлы җитәкчебез – мәдәният министры җитәкләргә тиештер. Бу Зур сәнгать киңәшмәсе дип аталсын. Икенчесе, Язучылар һәм Композиторлар берлеге идарәләре каршында Кече сәнгать киңәшмәләре эшләргә тиеш.

Һәр эстрада әсәре, һәр җыр әлеге дәрәҗәле киңәшмәләр фатихасы белән генә тамашачыга барып ирешсен.

Киңәшмәләрнең аерым Уставлары булып, әлеге документларда иң беренче чиратта яшь иҗатчыларга ярдәм итү күздә тотылсын иде. Һәм шулай ук әлеге сәнгать киңәшмәләре шоу-бизнес белән шөгыльләнүче хосусый компания, шәхси эшмәкәрләрнең җыр сәнгате өлкәсендәге эшчәнлекләрендә ышанычлы терәк, аларга иҗади яктан ярдәм итүче дәрәҗәсендә булырга тиеш.

*Илһам ШАКИРОВ, Әлфия АВЗАЛОВА*
*Зилә СӨНГАТУЛЛИНА, Венера ГАНИЕВА,*
*Мирсәет ЯРУЛЛИН, Разил ВӘЛИЕВ*
*һәм бер төркем сәнгать әһелләре*
*2006*

# «ХАККЫБЫЗ УРТАК ВАТАНДА ШАКТЫЙ УК...»

Балалар бакчасыннан башлап югары уку йортына кадәр эзлекле милли мәгариф системасы булмаган милләт алга киткән милләтләр исәбенә керми. Үз туган телендә белгечләр әзерләмәгән, туган телендә югары белем бирмәгән халык дөнья халыклары базарында алга киткән халыклар белән бер дәрәҗәдә тора алмый. Вакыт узган саен аның базар бәясе бөтенләй төшеп, тора-бара милләт кадәр милләтнең кабилә хәлендә калуы яисә бөтенләй юкка чыгуы да мөмкин. Әмма якты дөньядан беркемнең дә үз теләге белән китәсе килмәгән кебек, татар халкының да күрә торып үз гомерен чикләргә теләге һәм хакы юк. Шуңа күрә без монда югалу һәм бетү хакында түгел, ә милләтне үстерү турында, аның киләчәге хакында сүз алып барырга дип җыелдык.

Бүген Татарстаннан читтә чын татар булып, димәк, туган телеңне, гореф-гадәтләреңне, йолаларыңны, динеңне, милли мәдәниятеңне һәм милли мәктәбеңне саклап һәм яклап яшәү бик катлаулы. Әмма бу залга җыелган фидакяр җаннар һич кенә дә җиңел язмыш сайлап, җиңел тормыш эзләп йөрүчеләр түгел. Сезне һәм безне бүген иң беренче чиратта милләтебезне саклап калу һәм үстерү, аны дөнья мәйданына чыгару мәсьәләсе борчый. Ә милләтне милләт иткән нәрсәләр иң беренче чиратта милли мәдәният, милли мәгариф, милли аң һәм шуларны оештырып, үстереп, куәт биреп торучы милли элита!

Әмма милли элита могҗиза белән күктән төшә торган нәрсә түгел. Аны уйлап табып та, спортчылар кебек сатып алып та булмый. Аны үзебезгә әзерләргә һәм тәрбияләргә кирәк. Җәмгыятьтә зыялы затларны тудыра, үстерә, тәрбияли торган берничә урын бар. Шуларның иң беренче чираттагылары – гаилә белән мәктәп!

Гаилә бүгенге көндә үз функцияләрен тулысынча үтәп бара алмый. Аның җәмгыятьтәге роле, дәрәҗәсе бик түбән. Үзен саклау һәм үстерү өчен татарларның үз милли идеологиясе булырга тиеш. Ә бу идеологияне бүгенге татар гаиләсе бирә аламы соң? Ала, әмма андый гаиләләр, кызганычка каршы, бик аз, бармак белән генә санарлык.

Милли элитаны, зыялы яшьләребезне тәрбияләүдә балалар бакчасының, мәктәпнең, махсус уку йортларының роле гаҗәеп зур. Ләкин безнең балалар бакчаларыбыз, мәктәп-вузларыбыз бу функцияләрне үз җилкәсенә күтәрә аламы соң? Бу – бик авыр сорау. Чөнки бүген Россия төбәкләрендә чын мәгънәсендә милли мәгариф системабыз юк. Димәк, мәктәп тә, вуз да бу функцияне үти алмый. Ә инде гомуми идеяләр белән халыкның тормышын яхшырту, аны бай итү кебек максатлар бик мөһим булса да, милләтебезне алга таба яшәтү өчен болар гына җитми. Мәсәлән, христиан мәктәбендә яисә православие чиркәвендә хак мөселман баласын тәрбияләргә шартлар булмаган кебек, гомуми урта мәктәптә дә безнең милләтнең мәнфәгатьләрен, проблемаларын тулысынча искә алган, милли рухлы чын татар балалары тәрбияләрлек мәгариф системасы була алмый. Гомуми урта мәктәп гомуми шаблон кеше тәрбияли.

Бүген Россиядә рус халкы җитәкчелегендә халыкларны берләштерергә тиешле дәүләт сәясәте хакында закон кабул итәргә җыеналар. Шундый максатны алга куйган, шундый сәясәтне алга сөргән Россия мәгариф системасы татар яшьләрен милли рухта тәрбияләргә булышыр дип мин һич кенә дә уйлый алмыйм.

Безнең милләтнең терәге булырлык затлардан мин аерым урынны зыялы байларыбызга, меценат-хәйриячеләргә бирер идем. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар байлары милләт өчен ниләр генә эшләмәгәннәр?! Мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар, газета-журналлар чыгарганнар. Рус дәүләте, патша хөкүмәте татарларга мәктәп-мәдрәсәләр ачарга бер тиен дә акча бирмәгәнне күреп, татар байлары бу изге эшләрне ихлас күңелдән үз өсләренә алганнар. Бүгенге көндә дә безнең зыялы байларыбыз бар, әмма чын зыялылары бармак белән генә санарлыктыр. Миллионерларыбыз, хәтта миллиардерларыбыз бар, алар завод-фабрикалар тоталар, акчалары бихисап. Тик менә араларында милли мәктәпләр ачкан кешеләр бармы? Булса да, бик сирәктер. Мәсәлән, Төркиядә байлар, мая туплауга ук, иң элек балалар өчен мәктәп салдыра. Халык ихтыяҗы өчен кирәк булган биналарга үз акчасын бирә. Ә бездә акчасы булган кеше гомеренә

бер авыл мунчасы кадәр мәчет салдыра да шуңа бабасының, әтисенең яисә үзенең исемен кушып, сөенеп яши. Һәм... шуның белән вәссәлам!
Зыялы яшьләребезне үстерүдә шулай ук үзебезнең Милли университетыбыз төп рольне уйнарга тиеш иде. Иң беренче чиратта бу уку йортын без татар халкының тарихын, рухи байлыгын, мәдәниятен өйрәнүче университет итеп күз алдына китерәбез. Андагы студентлар татар-рус телләрен һәм кимендә бер чит телне яхшы үзләштерергә тиешләр. Әмма телләр өйрәнү генә җитми, милләт каршындагы проблемаларны чишү өчен күп нәрсә кирәк. Милли университетта Россия төбәкләрендә һәм хәтта чит илләрдә яшәүче татарларның сәләтле яшьләре килеп укырга һәм аларга элитар мөгаллимнәр белем бирергә тиеш дип уйлыйм мин. Әмма шуны да онытмыйк: нинди дер бер уку йорты кысаларында гына татарны үстерү, татар ренессансы ясау шулай ук хыял! Без бүген Россия күләмендә татар халкын үстерү буенча Дәүләт программасын булдыру чараларын күрергә тиешбез. Әйтик, Башкортстанда башкорт халкын үстерү буенча программа бар. Бәлки, ул аларга ярыйдыр, чөнки башкортларның күпчелек өлеше Башкортстанда яши. Ә бит безнең татар халкының яртысыннан күбрәге читтә, бик зур өлеше Россия төбәкләрендә яши. Шуңа күрә андый Программаны Татарстан күләмендә генә кабул итү безгә бик үк мәслихәт түгел. Без Конституциябезнең 14 нче маддәсен нәкъ менә читтәге татарлар мәнфәгатен искә алып кабул иттек. Тик бу маддә гамәлгә керсә дә, әллә ни зур уңышка ирешә алмадык. Безнең Конституциябез Татарстанда гына хокукый көчкә ия. Димәк, мондый Программаны Федераль хакимият белән килешеп, бөтен Россия күләмендә тормышка ашырырга кирәк.
Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Россия Президенты Владимир Путин халкыбызга аерым бер ихтирам белән сөйләгәч, Россия дәүләтчелеген төзүдә, оештыруда татарларның ролен ассызыклап үткәч, күңелдә өмет чаткысы уянды. Бәлки, киләчәктә Россия һәм Татарстанның югары дәрәҗәдәге җитәкчеләре сөйләшү, килешүләр аша бу мәсьәләне хәл итү юлын табарлар? Моның өчен мөмкинлек тә чыгарга тора. Бу – Татарстан белән Россия арасында вәкаләтләр бүлешү хакындагы яңа Шартнамә проектын әзерләү... Ул инде Татарстан парламенты тарафыннан кабул ителеп, Мәскәүгә җибәрелде. Ниһаять, Шартнамә кабул ителер, аңа кул куелыр, аның нигезендә хөкүмәтара, министрлыкларара килешүләр дә төзелер. Шул вакытта инде без бүген күтәргән кайбер мәсьәләләр дә хәл ителер дип өметләнәм мин.
Милли проблемаларны хәл итү мәсьәләсен үз республикабызда да тиешле югарылыкка куясы бар әле. Конституциябездәге 14 нче маддә кабул ителгән, ә аны тормышка ашыру буенча хөкүмәт Программасы кайда соң? Ул үзеннән-үзе һичкайчан тормышка ашмаячак. Бу мәсьәлә милли яшьләребезне тәрбияләү проблемасына турыдан-туры кагыла, чөнки татарның милли элитасы Татарстанда гына әзерләнми. Әгәр без татарны бербөтен, бердәм милләт итеп күрергә телибез икән, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең рухи ихтыяҗларын кайгыртуны үзебезнең төп эшләребезнең берсе дип санарга тиешбез. Чөнки татарның зыялы затларын тәшкил итүче язучыларыбыз, сәнгатькярләребез һәм галимнәребезнең шактый өлеше моңа кадәр Татарстаннан читтә туып-үсеп киләләр иде... Әгәр без үз вакытында аларга ярдәм күрсәтмәсәк, мөмкинлек бирмәсәк, милли элита тәрбияләү турында күкрәк тутырып сөйли дә, максатларыбызга ирешә дә алмаячакбыз.
Шуңа күрә киләчәктә ике дәүләт программасы кабул ителергә тиеш. Аның берсе – Конституциябезнең 14 нче маддәсен тормышка ашыру буенча Татарстан программасы булса, икенчесе – Россия күләмендә татар халкын үстерү, алга җибәрү программасы.
Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтү мәсьәләсе Дәүләт Советы тарафыннан 2004 елның 1 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Законда һәм бу Законны тормышка ашыру буенча Дәүләт программасында да ачык әйтелгән. Программаның 4 нче бүлеге тулысы белән Татарстаннан читтә татар телен саклау һәм үстерүгә багышланган. Мин корылтай делегатларына «Телләр турында»гы Татарстан Законын һәм аны тормышка ашыру буенча Дәүләт программасын җентекләп өйрәнергә һәм көндәлек эштә файдаланырга тәкъдим итәр идем.
Милли мәгариф мәсьәләсе – гомуммилләт күләмендә иң мөһим һәм иң катлаулы мәсьәләләрнең берседер. Аны хәл итү өчен безгә озак еллар буе бергәләп тир түгәргә, баш ватарга кирәк булачак.

Әмма бу мәсьәләне хәл итмичә торып, без милләтебезнең киләчәгенә зур өметләр баглый алмыйбыз.

Үземнең чыгышымны мәшһүр авар шагыйре Рәсүл Гамзатовның шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

Кемнәргәдер башка телләр шифа,
Иманымнан минем чигенгән юк...
Туган телем юкка чыга икән,
Мин үләргә әзер бүгеннән үк...

*2006*

# БЕЗ КЫТАЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА ЯШӘМИБЕЗ!

Барыгызга да билгеле булганча, быелгы 2006 елны президентыбыз Әдәбият-сәнгать елы дип игълан итте. Үткән елны бюджет кабул иткән вакытта без әле бу хакта белми идек. Һәм шуңа күрә ел бюджетына Әдәбият-сәнгать елын югары дәрәҗәдә үткәрү өчен кирәкле финанс чыгымнарын салып калдыра алмадык. «Соң булса да, уң булсын» дигәндәй, без әлеге бурычыбызны 2007 ел бюджетында искә алырбыз дип ышанам. Чөнки әдәбият-сәнгать ул вакытлы күренеш түгел, ул ел саен кирәк, ул һәрчак дәүләт ярдәменә мохтаҗ.

Быелгысы елны без Татарстанның «Мәдәният» кануныла үзгәрешләр кертеп, анда озак еллар бер урында эшләгән мәдәният хезмәткәрләренә 15 проценттан 40 процентка кадәр өстәмә түләү хакындагы маддәне өстәдек, моның өчен бюджеттан 97 миллион сум акча бүлеп биреләчәк. Билгеле, бу закон проекты төрле дәүләт структураларында бик зур каршылыкларга очрады. Әлеге мәсьәләне уңай хәл итү өчен үзенең саллы сүзен әйткән Президентыбызга, хөкүмәтебезгә һәм Дәүләт Советы Рәисенә рәхмәтләребезне җиткерәбез. Шул ук Законда мәдәният-сәнгать оешмаларына грантлар билгеләү хакындагы маддә дә кабул ителде. Без аңа 130 миллион сум биреләчәге хакында сүз алып барган идек. Әмма киләсе ел бюджетында моның өчен 50 миллион сум гына тәгаенләнгән. «Егет сүзе бер булыр» дип, хөкүмәтебезнең элек килешенгән сумманы табуыннан без әле дә өмет өзмибез.

Соңгы вакытта безнең сөйләмебезгә «оптимизация» дигән бер бик тә хәвефле сүз килеп керде. Татарчага тәрҗемә иткәндә, ул «акча кыскарту», «мәктәпләрне, мәдәният сарайларын, башка бюджет оешмаларын ябып яисә бер-берсенә кушып, акчаны янга калдыру» дигәнне аңлата. Оптимизацияне нигәдер иң беренче чиратта мәктәпләрдән башларга булдылар. Билгеле, бу кемгәдер зыян кылырга теләүдән түгел, ә аптыраганнан, акча җитмәгәннән эшләнәдер. Әмма мондый катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә, кат-кат уйлап, җиде кат үлчәп, бер кат кисеп эшләргә кирәктер.

Комитетларда бюджет проекты хакында сүз алып барганда, без Икътисад министрлыгының тагын бер яңалыгына тап булдык. Киләсе елдан башлап театр әһелләре үзләренең хезмәт хакларының 40 процентын бюджеттан түгел, ә үзләре «акча» эшләп табарга тиешләр икән. Заманында без бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы дәүләт тарафыннан якланган-гарантияләнгән маддә, русча әйтсәк, «защищённая статья» дип игълан иткән идек. Сәнгать өлкәсендә, театрда чумара да, коррупция дә, малтабарлык та була алмый. Йә, әйтегез әле, Шәүкәт Биктимеров яисә Ринат Таҗетдинов бүген ничек итеп үзенә-үзе хезмәт хакы эшли алсын?! Алар көне буе репетициядә, кичен театрда. Ә инде профессиональ иҗат әһелләреннән күрә торып шабашниклар ясарга теләү, шуны рәсми төстә тәкъдим итү – берничек тә безнең дәүләт сәясәтебез була алмый.

Язучыларның, журналистларның, композиторларның, рәссамнарның гонорарлары да, торгынлык чорлары белән чагыштырганда, дистәләгән мәртәбә ким. Ә гонорар – алар өчен шул ук хезмәт хакы бит ул.

Икътисад министрыбыз киләсе елны республикада уртача хезмәт хакының ун мең сумнан артып китәчәге хакында игълан итте. Кемнең, нәрсәнең уртачасы соң ул? Мәдәният хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы – өч мең сум чамасы, мәгарифтә – дүрт мең, банкирларда – безгә билгеле булганы – утыз мең, аена миллион сум алучылар да бар. Киләчәктә, мондый уртача статистика белән кеше көлдермичә генә, «мәдәнияттә шулкадәр», «мәгарифтә шулкадәр», «эшмәкәрләрнеке шулкадәр» дип, реаль саннар белән сөйләсәгез иде. Сөйләү генә түгел, республикабыздагы халыкның тормыш дәрәҗәсен кайгырту, хезмәт хакын арттыру өчен конкрет чаралар күрү безнең һәммәбезнең дә төп бурычы булырга тиеш.

Безне шулай ук җирле үзидарә системасына күчкән мәдәният-мәгариф оешмаларының язмышы да бик нык борчый. Элек дәүләт яклавы аркасында гына эшләп килгән мәктәп-китапханәләребез, медицина учреждениеләребез, балалар бакчаларыбыз берәм-берәм юкка чыкмасмы? 5

октябрьдәге парламент тыңлауларында Чистай хакиме үз районында инде берничә клубның, китапханәнең һәм мәктәпнең ябылуы хакында ачынып сөйләде бит. Бүгенге көндә йөзләгән мәктәпләрнең, мәдәният йортларының, китапханәләрнең җимерек булуы хәлнең никадәр катлаулы булуы хакында сөйли. Авылга инвесторлар килүе бер яктан бик әйбәт. Алар авылга яңа техника, яңа технология алып киләләр. Әмма инвесторларга иң беренче чиратта мәгариф, мәдәният, халыкның рухи байлыклары түгел, ә матди табыш, матди байлык кирәк. Эшләр болай барса, авылда әкренләп социаль-культура объектлары юкка чыгып, эшсезләр саны артып, халкы таралып, бик күп йортларның тәрәзәсенә такта кадакланырга мөмкин. Ә авыл безнең өчен иген үстерү, сыер-сарык асрау урыны гына түгел, авыл – безнең халкыбызның рухи нигезе, чишмә башы. Авылларыбызны, димәк, халкыбызны саклап калу һәм бөтәйтү өчен безгә «Татарстан авылларын социаль-икътисади яктан үстерү буенча комплекслы Дәүләт программасы» кабул итәргә кирәктер.

Моннан ике ел элек Татарстан Мәгариф министрлыгының исеме Мәгариф һәм фән министрлыгы дип үзгәртелде. Әмма 2006 елгы бюджетта министрлыкның фән өлешенә тотылачак чыгымнарына акча каралмады. Былтыр безнең комитет бу турыда сүз кузгаткач, әле министрлыкның фән өлешенең структурасы да формалашмаган, фән өлеше эшли башлагач, бюджетка кертелер, диделәр. Ләкин киләсе елгы бюджет проектына да министрлыкның фән өлешенә финанс каралмаган, димәк, министрлык 2007 елда да фән эшләре белән тиешле дәрәҗәдә шөгыльләнә алмаячак. Без бюджет проектын эшләүчеләрдән бу мәсьәләне искә алуларын сорыйбыз.

Елның-елында Татарстан Фәннәр академиясе гаять зур фәнни потенциалы булган фәнни оешмаларның тулы көченә эшли алырлык финанс мөмкинлекләре булмавы турында әйтеп килә. 2007 елгы бюджет проектында да фәнне үстерү өчен җитәрлек акча каралмаган. Аерым алганда, хезмәткә түләү өчен – 13 миллион 653 мең сум, Россия Федерациясе хөкүмәте карары нигезендә хезмәт хакын дәвамлы рәвештә арттыру өчен – 10 миллион 530 мең сум, фундаменталь эзләнүләр үткәрү өчен – 38 миллион 500 мең сум, эре инновацион мега-проектлар өчен 60 миллион 500 мең сум акча кирәк. Шунсыз галимнәребез киләсе елда тулы көчкә фәнни эшләр башкара алмаячак.

Татарстан Республикасында телләрне үстерү буенча Дәүләт программасында «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе чит илләрдә һәм Россиядә татарлар тупланып яши торган төбәкләрдә хәбәрче пунктлары ачарга тиеш дигән бүлек бар. Әмма аларны ачу өчен елның-елында бюджетта акча каралмый. Без ел саен бу мәсьәләне күтәрәбез. Ләкин бюджет проектын эшләүчеләр бу сүзләргә колак салмыйлар. 2007 елгы бюджетта да бу эшкә акча бирү күздә тотылмаган. Телерадиокомпаниягә Татарстаннан читтә дүрт хәбәрче пункты ачу өчен 16 миллион 800 мең сум акча кирәк.

«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенә 2007 елгы бюджет нәкъ 2006 елгы бюджет күләмендә, ягъни 150 миллион акча билгеле. Ә бит бюджет проектында 2007 елга башка оешмаларга 17 процент индексация каралган. Телерадиокомпаниягә бирелгән чыгымнарда бу саннар искә алынмаган. Ә инде бүгенге көндә үзе дә авыр хәлдә булган татар телендә тапшырулар оештырып акча эшләү – мөмкин булмаган нәрсә. Киресенчә, татар теле, татар тапшырулары үзләре ярдәмгә мохтаҗ.

Хөрмәтле җәмәгать! Ходайга шөкер, безнең республикабыз Идел буе округында да, бөтен Россия күләмендә дә төшеп калганнардан түгел. Икътисадыбыз да елдан-ел тернәкләнә бара. Авыл хуҗалыгында эшләүчеләр дә һәммәбезне сөендереп елның-елында мул уңыш җыя, шәһәрләребез, кайбер авылларыбыз да әкренләп төзекләнә. Әмма халыкта «Яхшылыкның чиге юк» дигән әйтем бар бит. Хәзер инде безнең тагын да яхшырак – Европа дәрәҗәсендә, Европа стандартларында яшисебез килә.

Бюджет мәсьәләсен караганда, комитет утырышында мин бер җитәкчебезгә: «Без быел нинди елда яшибез?» – дип сорау биргән идем. Ул, ике дә уйламыйча: «Эт елында, – дип җавап бирде. Аннары: – Ә киләсе ел Дуңгыз елы була», – дип тә өстәде. Әйе, чыннан да, Кытай календаре буенча без быел Эт елында яшибез. Ә Татарстанда – Әдәбият-сәнгать елы. Ишетеп белүемчә, киләсе елны да бер гуманитар өлкәгә багышлау турында фикерләр бар икән. 2007 ел бюджеты проектын икенче укылышка хәзерләгәндә хөкүмәт әһелләребез һәм депутатларыбыз төзәтмәләрне

Кытай календаре буенча түгел, ә Татарстан календаре буенча әзерләсәләр, без аларга бик тә рәхмәтле булыр идек.

*2006*

# РУХИ ГАРИПЛЕКТӘН САКЛАНЫЙК

Министрның тәфсилле докладыннан соң ниндидер яңа фикер яисә тәкъдим әйтү мөмкин дә түгелдер кебек. Әмма шулай да үземнең кайбер уйларым белән уртаклашсам, бер дә артык булмастыр дип исәплим.

Узган Әдәбият-сәнгать елында без, депутатлар, һәрвакыттагыча, Мәдәният министрлыгы оештырган һәр чарада катнашып, кулдан килгән кадәр үз өлешебезне кертергә тырыштык. Инде менә ун елга якын без республикадагы мәдәният хезмәткәрләренә үз һөнәре буенча озак эшләгән өчен өстәмә хезмәт хакы түләү мәсьәләсен хәл итәргә тырышкан идек. Бу тырышлыкларыбыз, ниһаять, узган елда тормышка ашты. Әлеге максатларга республика бюджетыннан 100 млн.сум чамасы өстәмә акча бүлеп бирелде. Бу казанышыбыз Мәдәният министрлыгы белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетының чын мәгънәсендә бергәләп эшләү нәтиҗәсе, уртак уңышыбыз булды. Форсаттан файдаланып, мин безнең тәкъдимнәребезнең закон дәрәҗәсенә җитүенә хәер-фатиха биргән президентыбызга, хөкүмәтебезгә, депутатларыбызга барча мәдәният хезмәткәрләре исеменнән рәхмәт сүзләре әйтсәм, урынлы булыр кебек. Шулай ук әлеге яңартылган Закон нигезендә профессиональ иҗат коллективларына җәмгысы 50 млн. сумлык грантлар бирелү дә бик күркәм яңалык булды.

Әдәбият-сәнгать елы рәсми төстә тәмамланса да, узган елны көн тәртибенә куелган мәсьәләләр безнең белән бергә калды һәм без аларны Хәйрия елында да, алдагы елларда да шундый ук уңыш белән хәл итәргә тиешбез. Ә проблемалар хәл ителгән саен, аларның тагын да мөһимрәкләре, тагын да зурраклары пәйда була тора.

Узган елны республикабызны шаулаткан вакыйгаларның берсе – тарихи-мәдәни һәйкәлләребезне саклауга багышланган иде. Бу мәсьәлә әле бүген дә тулысынча хәл ителмәгән, аны хәл итү өчен хөкүмәтебез, парламентыбыз һәм җирле органнарның үзара килешеп эшләүләре таләп ителәчәк. Иң беренче чиратта безгә инде күптән «сакаллы» проектка әверелгән «Мирас» программасын тиз арада кабул итеп, бюджеттан акча бүлеп бирергә һәм, ниһаять, аны гамәлгә ашыра башларга кирәк. Әмма ни өчендер бу үтә дә мөһим һәм озак перспективага исәпләнгән мәсьәләне хәл итү өчен нибарысы өч ел вакыт бирелгән. Әгәр дә ул Дәүләт программасы кысаларына кертелеп, 10 еллык программа итеп төзелсә һәм закон белән расланса, аның статусы да, мөмкинлекләре дә бермә-бер арткан булыр иде. Проект авторлары җиңелрәк юлны сайлап, минемчә, эшне катлауландыра гына төшкәннәр кебек.

Инде әйткәнемчә, узган елны «Мәдәният» Законына аерым маддә өстәлеп, республикабызда мәдәният өлкәсендә беренче мәртәбә грантлар системасы гамәлгә керә башлады. Быелгысы һәм алдагы елларда аның сферасын киңәйтә төшеп, Мәдәният сарайларына, китапханәләргә, музейларга һәм башка мәдәният оешмаларына грантлар бирә башласак, республикабызның рухи тормышы күзгә күренеп җанланып китәр иде. Илкүләм приоритетлы проектлар арасында мәдәнияткә урын табылмавына безнең президентыбыз ачыктан-ачык үзенең ризасызлыгын белдергән иде. Менә шушы гаделсезлекне бетерү өчен республикадагы мәдәният оешмаларына, һич югында, берәр миллион сумлык 50 грант билгеләнсә, күләгәдә калган мәдәният бакчасына якты кояш нурлары төшкән сыман булыр иде. Ә мәдәниятнең, бигрәк тә милли мәдәниятебезнең чишмә башы, төп нигезе авылларда, шул ук мәдәният йортларында, китапханәләрдә, музейларда булуын истә тотсак, бу гамәлнең никадәр мөһим икәнлеге тагын да ныграк ачыклана төшә.

Быелгы Хәйрия елында гомерләрен әдәбият-сәнгатькә багышлап, лаеклы ялга чыккан ветераннарыбызга да аерым хөрмәт күрсәтелә башлар, аларга игътибар бераз булса да артыр дип уйлыйбыз. Мәсәлән, Мәскәүдән һәм С.-Петербургтан үрнәк алып, иң мәшһүр һәм ярдәмгә мохтаҗ әдәбият-сәнгать ветераннарына махсус стипендияләр билгеләүне гамәлгә кертсәк, бик тә яхшы булыр иде. Беренчедән, бу гамәл ветераннарны мескенлеккә төшүдән коткарса, икенчедән, сәнгать дөньясына яңа аяк басучы яшьләр алдында сайлаган профессияләренең, гомерлек һөнәрләренең абруен бераз булса да күтәрер иде.

Менә без, ниһаять, күптән борчылып көткән җирле үзидарә шартларына аяк бастык. Аның кыенлыклары, очы очка ялганмаган җирләре сезгә дә, безгә дә яхшы билгеле. Әгәр дә без бүген, әле камилләшеп җитмәгән Россия законнарына нигезләнеп, үзебезнең бөтен мәдәният оешмаларыбызны уптым илаһи башы-аягы белән җирле үзидарә җилкәсенә өеп куйсак, авыл-район мәдәнияте бик тә авыр хәлгә төшеп, тора-бара бөтенләй күтәрәм хәлгә калырга мөмкин. Аннары аларның берәм-берәм ябылып, бермә-бер кимүләре дә котылгысыз булачак. Юк, мин һич кенә дә бүгенгесе көндә җирле үзидарәләргә республика казнасыннан бүленеп бирелә торган ярдәмне инкяр итәргә җыенмыйм. Әмма бу ярдәмнең күләме җан асрарга да көчкә-көчкә генә җитә, ә алга бару, үсеш турында хыялланасы гына кала. Компьютерсыз, китапсыз китапханәләрнең, музыка уен кораллары, музыкаль аппаратуралары, сәхнә җиһазлары булмаган, дистә еллар буена ремонт күрмәгән мәдәният сарайларының бүгенге кешенең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмавы, заман таләпләренә туры килмәве барыбызга да мәгълүм бит.

Безнең республикада елдан-ел бик тә кирәкле һәм яхшы законнар кабул ителә тора. Аларның күбесенең проектлары хөкүмәт тарафыннан эшләнә. Әмма шул яхшы законнарның гамәлгә ашуы гына җитенкерәми. Мәсәлән, моннан берничә ел элек без «Мәҗбүри данә турында» республика Законы кабул иткән идек. Шул Закон нигезендә зур китапханәләр һәм архивлар республика нәшриятларында басылган китапларның һәм башка төрле басмаларның, аудио-видеоязмаларның һәммәсен дә мәҗбүри төстә бер-ике данә алып барырга тиешләр. Әмма бу Закон һаман тулысынча эшләп китә алмый, республикада чыккан мәгълүмати продукциянең нибары 60–70 проценты гына тиешле урыннарга барып җитә. Хөкүмәтебез бу өлкәдә дә үзенең каты кулы белән тәртип урнаштырса, киләсе буыннар һәм тарих өчен тупланган мәгълүматларыбыз тагын да баерак һәм тулырак булыр иде.

Узган елны нәшриятларыбыз складларында саклanучы 25 миллион сумлык китаплар хакында да шактый сүзләр булды. Ә шул ук вакытта республикада ел буена бер дистәдән артык китап ала алмаган китапханәләребез байтак. Мәсәлән, узган елны Биектау, Кайбыч, Чүпрәле, Апас, Теләче районнарында китап сатып алу һәм подписка оештыру өчен бер китапханәгә уртача 2–6 мең сум акча бирелгән. Әмма 2 мең сумга бүген бер яхшы альбом яисә атлас та алып булмый бит! Ә балалар китапханәләренең хәле тагын да аянычрак. Мәсәлән, Буа районында узган елны бер китапханәгә балалар өчен нибарысы – 5 китап, Балтач районында – 9 китап, Алабуга, Әгерҗе, Кама Тамагы районнарында бер яңа китап сатып алынган. Быелгы Хәйрия елында республикабыз китапханәләренә балалар китаплары алу буенча махсус акция оештыра алсак, бик тә игелекле эш кылган саналыр идек. Чөнки мәдәнияттән, китаптан, сәнгатьтән аерылган бала әкрен-әкрен рухи гариплеккә дучар ителергә мөмкин. Ә рухи гариплек физик гариплектән дә куркынычрак нәрсә.

Чыгышым озынга китә башлады бугай, әйтер фикерләрем күп булса да, туктарга вакыт җиткәндер. Әмма, зинһар өчен, минем бу чыгышымны тәнкыйть сүзләре дип түгел, ә үзебезнең алдыбызга куелган максат, бурыч дип кабул итсәгез иде. Чөнки болар һәммәсе дә хөкүмәт җилкәсенә генә төшкән проблемалар түгел, ә барыбыз да бергәләп, җиң сызганып эшләргә тиешле эшләр. Ә бу теләкләремнең киләчәктә хәл ителәчәгенә минем һич кенә дә шигем юк. Шулай булмаса, сезнең каршыга басып бу хакта сүз сөйләп торуның, лаф оруның кирәге дә булмас иде.

*2007*

# МӘКТӘПСЕЗ АВЫЛ – КИЛӘЧӘКСЕЗ АВЫЛ

Россия Президенты тарафыннан 2005 елның көзендә игълан ителгән илкүләм проектлар гомумхалык масштабындагы мәсьәләләргә әйләнде. Дүрт төп юнәлеш арасында «Мәгариф» проектының булуы бүгенге көндә дәүләтнең мәгарифне үстерүгә җитди игътибар бирүе дигән сүз. Гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, яшәеш сыйфатын яхшырту дәүләт сәясәтенең үзәк мәсьәләсе булса, мәгариф аның аерылгысыз бер өлеше. Әйе, сүз дә юк, мәгариф системасында җитди үзгәрешләр кирәклеге көн кебек ачык.

Укытуның сыйфатын күтәрү максатыннан мәгариф учреждениеләрен реструктуризацияләү, матди ресурсларны оптимальләштерү илдә демографик хәлнең җитди булуы белән дә аңлатыла. Бу исә тормышыбыздагы социаль һәм психологик киеренкелекне елдан-ел көчәйтә, бигрәк тә авыл җирлегендәге халыкны борчуга сала. Демография мәсьәләсендә безнең республика да искәрмә түгел. Бездә дә балалар туу саны кими: димәк, һәр елны мәктәпкә килүче балалар саны да кимеп бара. Быелгы уку елында гына да республика мәктәпләрендә укучылар саны 25 меңгә кимеде. Алдагы елларга да өмет аз – хәл тагын да кискенләшер кебек.

2005 елда Татарстанда гомумбелем учреждениеләрен этаплап модернизацияләү башланды. ТР Министрлар Кабинеты тарафыннан авыл гомумбелем учреждениеләре челтәрен реструктуризацияләү буенча 2007 елга кадәр максатчан программа кабул ителде, 2009 елга кадәргесе дә әзерлек стадиясендә.

Аз комплектлы башлангыч һәм урта мәктәпләрне урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләренең структур бүлекчәләренә үзгәртеп кору башланды. Сүз дә юк, андый мәктәпләрдә укыту шартлары һәм сыйфаты күпкә югарырак. Аларда матди-техник база да, кадрлар, финанс һәм идарә ресурслары да нәтиҗәлерәк файдаланыла. Шулай булуга да карамастан, база мәктәпләре барлык проблемаларны да хәл итә ала дигән сүз түгел. Бу мәсьәләгә комплекслы якын килү кирәк.

Кызганычка каршы, авыл мәктәпләре саны кыскару тенденциясе үзен елдан-ел ныграк сиздерә. Соңгы алты ел эчендә генә дә алар 122 гә кыскарды. Төп сәбәп – демография, балалар җитмәү. Бүгенге авыл мәктәбе укучы балаларның азаеп баруы белән аерылып тора. Игътибар итсәк, аз комплектлы мәктәпләр шактый күбәйде. Россия буенча, уртача алганда, аларга барлык мәктәпләрнең 44 проценты (ә кайбер регионнарда 90 процентка кадәр), ә Татарстанда 44,3 проценты туры килә. Һәр 5 ел саен һәр икенче авыл мәктәбе аз комплектлы мәктәпләр сафына күчәргә мөмкин. Белгечләр әйтүенчә, демографик ситуация якындагы елларда да уңай якка үзгәрмәячәк әле.

Гомумбелем бирү учреждениеләрендә реструктуризация үткәргәндә төп күрсәткеч итеп сыйныфларның тулылыгы алына. Ләкин бу таләпне үтәү авылда гына түгел, шәһәрдә дә зур проблемага әверелде. Бүгенге көндә безнең республикада сыйныфларны тутыру буенча норматив, тулаем алганда Россиядәге кебек үк, шәһәр җирлегендә – 25, ә авыл мәктәпләре өчен 14 бала күләмендә билгеләнгән. Икътисади күзлектән караганда, 25 һәм 14 саннары, мөгаен, рациональ чишелештер. Тик мәсьәләнең социаль һәм милли ягы да бар ич әле. Үзегез уйлап карагыз, бала кече яшьтән үк үзен әйләндереп алган тирәлектән, гаилә мохитеннән аерыла. Бу аңа ата-ана назы, туган йорт җылысы җитми дигән сүз. Шул ук балалар, үсеп җиткәч, үзенең кече ватаны булган туган авылы, аның кешеләре турында кайгыртырга тиеш. Ә балалык елларында йөрәгенә кереп оялаган гамьсезлек, салкынлык гомере буена сакланмасмы соң? Моңардан тыш, төптәнрәк фикер йөртсәк, авылны аның соңгы зыялы кешеләре – укытучылар да ташлап чыгып китсә?! Димәк, авыл үзенең кешеләрен генә югалтып калмый, ә инде анда традициягә салынган мәдәни мохит, гасырлар буена килгән тормыш, яшәеш рәвеше дә җимерелә дигән сүз. Мәсәлән, татар авылларында мәктәп һәм мәчет, русларда мәктәп һәм чиркәү гомер-гомергә халыкның рухи үзәге булган. Практикадан күренгәнчә, мәктәбе ябылган авыллар күз алдында әкренләп үлеп бара.

Моннан тыш, сыйныфларны тутыру буенча куелган нормативлар туган телдә белем алуны җитди тоткарларга, хәтта балаларны бу бәхеттән бөтенләй мәхрүм итәргә дә мөмкин. Бу исә ана телендә белем алуга хокук бирүче РФ Конституциясенең – 68, ТР Конституциясенең – 34, «Мәгариф турында»гы РФ Законының – 6, ТРның шундый ук законындагы – 4 һәм туган телдә белем алуны гарантияли торган «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында»гы Законның 2 нче һәм 9 нчы маддәләренә каршы килә. Сыйныфларны тулыландыру барышында милли мәктәпләр һәм сыйныфлар өчен авылда һәм шәһәрдә аерым нормативлар булдыру зарур, минемчә.

Әгәр дә без тамырларыбызны һәм гореф-гадәтләребезне саклап килүче авылларны югалтырга теләмәсәк һәм балаларыбыз ана телендә сыйфатлы белем алсын дисәк, билгеләнгән нормативларны, һичшиксез, яңадан карарга кирәк. Бүгенге көндә, укытучылар һәм белгечләр фикере буенча, милли сыйныфларга шәһәрдә 16, авыл мәктәбендә 8 укучы норматив итеп алынса, чынбарлыкка якынрак килербез кебек.

Сыйфатлы белем бирү проблемасын без бүген база мәктәпләре оештырып хәл итмәкче булабыз. Ә бит аның белән дә шактый проблемалар туачак. Балаларны көн саен якын-тирә авыллардан әлеге мәктәпкә китерәсе була. Биредә үзеннән-үзе мәктәп автобуслары һәм юлларның торышы нинди дигән сорау да килеп баса. ТРның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2007–2009 елларда республикада 1200 чакрым чамасы асфальт юл салырга кирәк.

Укытучылар һәм ата-аналарның борчылуы да урынлы. Иске маркадагы «КАВЗ-397653» автобуслары балалар йөртү өчен җайлы түгел. Ә бит ниятләр тормышка ашса, киләсе уку елыннан һәр көнне 2 мең бала һәр иртәне мәктәпкә бару өчен юлга чыгачак (хәзер 1 меңнән артык бала шулай йөри). Әле ул балаларны һәр җирдә дә автобуслар үз авылларыннан алып китми, трассага кадәр берничә чакрымны җәяү чыгарга кирәк.

Тагын бер мөһим проблема, ул – кадрлар мәсьәләсе. Оптимизация барышында ел саен билгеле бер күләмдә укытучылар эшсез кала. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белгечләре исәпләвенчә, якындагы өч елда 5860 хезмәткәр, шул исәптән 4036 педагог ставкасы кыскартылачак. Авылда алар өчен кулай эш бармы, база мәктәпләрендә аларның барысына да эш табылырмы? Күрәсез, биредә дә хәл итәсе мәсьәләләр шактый.

*2007*

# БЕЗДӘ БҮГЕН ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР...

*(2008 ел бюджетын кабул иткәндә)*

Менә без тагын депутат тормышының иң шау-шулы, иң кызыклы һәм бәхәсле чорына кердек. Бюджет капчыгын уртага куеп акча бүлгән вакытта хәтта ел буе йокымсырап йөргән, сессияләрдә моңа кадәр бер кәлимә сүз әйтмәгән депутатларның да теле ачыла, алар да кинәт кенә активлашып, дәртләнеп киткәндәй була. Бу хәл табигый дә. Чөнки без бүген акча бүлеп кенә утырмыйбыз, ә киләсе елда республикада кайсы өлкәләргә аерым игътибар бирү, халыкның үзәгенә үткән иң катлаулы мәсьәләләрне ничек хәл итү хакында бергәләп уйланабыз, борчылабыз, баш ватабыз.
Кайберәүләр әйтүенчә, бюджетның кереме дә, чыгымы да инде кат-кат саналган, аны кемгә ничек бүлү хакында Икътисад министрлыгы да, Финанс министрлыгы да, башка министрлыклар да премьер-министр һәм президент алдында әллә ничә мәртәбә хисап тоткан. Димәк, аларча, барысы да уйланган, өстә хәл ителгән, булганы гадел бүленгән, безгә хәзер шул бюджетны бары тик хуплыйсы гына калган.
Әмма, гөнаһ шомлыгына каршы, акчаның беркайчан да җитми торган бик начар сыйфаты бар. Акча ул авыл укытучысына да, Абрамовичка да җитми, тик бу җитмәүнең масштаблары гына төрлерәк. Менә без бүген монда, нигездә, кемгә нәрсә җитмәве турында сөйләшергә, фикер алышырга дип җыелдык та инде.
Ике министрның да докладларын мин сәнгать әсәре тыңлагандай йотлыгып тыңладым. Бигрәк тә яңа икътисад министрыбыз докладын тыңлагач, тормышлар кинәт кенә яхшырып, дөньялар яктырып киткәндәй булды, күңелдә өмет чаткылары уянып, Такташ әйтмешли, офыкта коммунизм кыры күренгәндәй тоелды. Бирсен Ходай, дип, эчтән генә «бисмилла» да әйтеп куйдым.
Әмма ләкин, матур хыялларыбыздан да баш тартмыйча, бүгенге хәлебезгә аек акыл белән бәя биреп карыйк әле.
Бүгенге көндә халык телендәге, халык бәгырендәге иң авырткан җир – эш хакы дисәм, моңа беркем дә каршы килмәстер. Россиядә минималь хезмәт хакын күтәрү турында карар кабул ителгәч, бу мәсьәлә тирәсендәге бәхәсләр тагын да ныграк кызып китте. Бүгенге көндә республиканың кайсы гына бюджет оешмасына барып керсәң дә, сүзне шуннан башлыйлар һәм шуның белән тәмамлыйлар. Дөрес, соңгы елларда, илкүләм проектлар ярдәмендә һәм шулай ук республикабыз мөмкинлекләрен файдаланып, мәгариф оешмаларында һәм кайбер башка өлкәләрдә бераз алга китеш булды. Мәдәният хезмәткәрләренә дә бер урында озак еллар эшләгән өчен өстәмә түләү мәсьәләсе хәл ителде. Әмма шушы уңай үзгәрешләрдән соң да республикабызда мәгариф хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 6 мең сум, мәдәният өлкәсендә 4,5 мең сум чамасы гына тәшкил итә. Бүгенге көндә Мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлап эшкә килгән югары белемле хезмәткәргә нибары 2,5–3 мең сум чамасы хезмәт хакы түләнә. Мондый хезмәт хакына юньле тормыш кору түгел, җан асрау мөмкинлеге дә юклыгын аңлаган хезмәткәрләр гипермаркетларга, бизнес оешмаларына, банкларга, башка төшемлерәк урыннарга эшкә урнашуны кулайрак күрәләр. Әгәр киләчәктә бу мәсьәләдә үзгәрешләр булмаса, тагын берничә елдан бюджет оешмаларында кадрлар кытлыгы соңгы чиккә җитәчәк. Бигрәк тә республиканың иң зур мәдәни оешмалары авыр хәлдә калачак. Хөкүмәтебез Казандагы иң мәртәбәле театрларга һәм иҗат коллективларына, Архив идарәсенә өстәмә түләүләр билгеләп, бу мәсьәләне хәл итүдә беренче адымнарын ясады инде. Киләсе ел бюджетында Милли музейга, Милли китапханәгә, республикабызның яшүсмерләр, балалар һәм сукырлар китапханәләренә, башка шәһәрләрдәге театрларга да шундый ук өстәмәләр билгеләнү каралса, тагын бер адым алга китеш булыр иде. Бу урында әдәбият-сәнгать әһелләренең хезмәт хакын тәшкил итүче гонорар фондларының инде ничә еллар буе үзгәрешсез калуын да әйтмичә мөмкин түгел.

Безнең республикада театр һәм музыка сәнгате дә, рәсем һәм нәкыш сәнгатебез дә, әдәбиятыбыз да ил күләмендә алдынгылардан санала. Әмма, ни кызганыч, бөтен сәнгатьләр арасында иң үтемле саналган кино сәнгате бездә әле һаман балалык чорыннан чыга алмый тилмерә. Кино сәнгатен үстерү өчен бездә югары дәрәҗәдәге әдәбият та, артистлар һәм режиссёрлар, музыкантлар да бар. Әмма тиешле матди-техник база булдырмый һәм җитәрлек финанс бирелми торып, кино сәнгате нинди дер әкияти тылсым белән генә барлыкка килмәячәк. Соңгы елларда Казан шәһәрендә оештырылган «Алтын мөнбәр» мөселман кинофестивале, күңелебездә горурлык хисләре уяту белән бергә, безнең алга яңа бурычлар да куйганын һич тә онытырга ярамый.

Безнең халкыбыз борын-борыннан мәгърифәтле, китаплы халык булган. Гасырлар буена дәүләтсез, республикасыз яшәгән вакытларда да безне юкка чыгудан, югалудан дин белән мәгърифәт саклап калгандыр. Безнең бүген дә, шагыйрь Хәсән Туфан әйтмешли, Татарстанлы чакта да, югаласыбыз, юкка чыгасыбыз килми. Әмма бүген татар китабының, татар басмаларының һәм газета-журналларының нинди аянычлы хәлдә икәнлеге барыбызның да күз алдында. Аларның тиражлары көннән-көн кими бара, китап кибетләре берәм-берәм ябылып, китап тарату системасы әкренләп үзе дә таралып бетте, мәктәп китапханәләренә матур әдәбият бөтенләй диярлек сатып алынмый. Компьютер заманы килде дисәк тә, компьютер һәм Интернет системасында безнең урыныбыз әле бик-бик кечкенә. Бауман урамындагы тарихи Матбугат йорты ябылып, андагы нәшриятларның һәм редакцияләрнең шәһәр читендәге тыкрыкларга күчерелүе дә халкыбызның рухи тормышына, әдәбиятка һәм мәдәниятка карата булган дәүләти мөнәсәбәткә дәрәҗә өстәмәде. «Аптыраган үрдәк арты белән суга чума» дигәндәй, Татарстан китап нәшрияты үзенең кибетен Бауман урамындагы гипермаркетның подвалында ачарга мәҗбүр булды. Гасырлар буена халкыбызга рух биреп, аны яклап һәм саклап килгән татар китабының шулай әкренләп җир астына юл тотуы бик тә шөбһәле һәм символик мәгънәгә ия. Хәерлегә генә булсын инде...

Россия Президенты В. В. Путин үзенең быелгы юлламасында китап һәм китапханәләр хакында аерым басым ясап, тәфсилләп сөйләде. Үзебезнең илбашыбыз М. Ш. Шәймиевнең әдәбият-сәнгатькә һәрчак хәерхаһ булуын барыбыз да күреп һәм сизеп торабыз. Шуларны истә тотып, икенче укылышка әзерләгәндә татар китабына һәм республика матбугатына ярдәм йөзеннән бюджетка тиешле үзгәрешләр кертелсә, халкыбыз рәхмәтле булыр иде.

Депутатлар тәкъдиме һәм президентыбыз хуплавы белән без быелның гыйнвар аенда мәгариф өлкәсендәге оптимальләштерү мәсьәләсе хакында парламент тыңлаулары уздырган идек. Бу беренче чиратта мәгарифне җан башына исәпләп финанслау белән бәйләнгән иде. Парламент тыңлауларында чыгыш ясаган депутатлар һәм белгечләр милли мәгарифнең киләчәк язмышы хакында бигрәк тә борчылып сөйләделәр. Нормативлар буенча бер сыйныфта авыл мәктәпләрендә – 14, шәһәр мәктәпләрендә 25 бала укыту каралган. Әмма, барыгыз да белгән тарихи сәбәпләр аркасында, бигрәк тә милли мәктәпләрдә сыйныфларга бүгенге көндә бу кадәр бала җыю мөмкин түгел. Беренчедән, моңа демографик үзгәрешләр сәбәп булса, икенчедән, милли мәктәпләрнең юктан бар булып, әле яңа гына тернәкләнеп килүе дә зур роль уйный. Аннары шәһәрләрдә үткән гасырның 90 нчы елларында ачылган күпчелек милли мәктәпләрнең балалар бакчаларында һәм яраклаштырылган төрле биналарда урнашуы да ата-аналарның һәм балаларның ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Шуларны истә тотып, депутатлар милли мәктәпләр өчен махсус нормативлар кабул итүне сорап, хөкүмәткә мөрәҗәгать юллаганнар иде. Ләкин шушы көнгә кадәр әлеге мәсьәләнең хәл ителгәне юк. Чөнки ул әлеге дә баягы бюджет акчасы белән бәйләнгән.

Татарстанның «Телләр турында»гы Законында ике дәүләт телен яхшы белгән һәм үз эшендә кулланган өчен хезмәткәрләргә 15 процентка кадәр өстәмә түләү каралган. Өстәмә түләүне билгеләү тәртибе хөкүмәт әзерләгән положение белән хәл ителергә тиеш. Әмма яңартылган Законны кабул итүебезгә өч ел вакыт узса да бу положениенең әле һаман да эшләнеп беткәне һәм кабул ителгәне юк. Димәк, шул сәбәпле Законның әлеге статьясы эшләми, «Телләр турында» Законның нәтиҗәлелеге кими дигән сүз. «Телләр турында»гы Законыбыз телдә генә калмасын, ә тиешле финанс белән ныгытылып, дәүләт күләмендә чын-чынлап гамәлгә ашырылсын иде.

Соңгы еллардагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә урыннардагы мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре биналарын төзек һәм тиешле хәлдә тоту бурычы җирле хакимиятләргә йөкләнгән. Әмма, белгәнебезчә, җирле хакимиятләрнең финанс мөмкинлекләре бик чикләнгән. Шуның аркасында бүгенге көндә район һәм авыл мәктәпләренең, мәдәният йортларының байтагы авария хәлендә яки төрле дәрәҗәдә төзекләндерүне таләп итә. Әнә шул максатлар өчен җирле хакимият органнарына киләсе елгы республика бюджетыннан тиешле күләмдә субвенсияләр бүлеп бирүне тормышка ашырырга кирәк.

Россиядә, шул исәптән бездә дә, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр һәм корылмаларны төзекләндереп саклау эше әле һаман тиешенчә хәл ителмәгән. Аларны дәүләтнеке булмаган оешмаларга биреп, шулар исәбенә төзекләндерү эше дә бер урыннан кузгалып китә алмый. Шуның өчен бу биналарны һәм корылмаларны, бигрәк тә аларның тарихи һәм мәдәни әһәмиятләре зур булганнарын, нигездә, дәүләт бюджеты исәбенә төзекләндерергә кирәк. «Мирас» программасына тәгаенләнгән 100 млн. сум акча белән генә бу проблеманы хәл итү һич тә мөмкин түгел. Киләсе ел бюджетында бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирелсен иде.

Безнең комитетка караган өлкәләр һәм оешмалар, нигездә, берсе дә бүген-иртәгә үк акча эшләүгә корылган даирәгә кермиләр. Әмма, шуны сәбәп итеп, без аларга тиешле игътибар бирмәсәк, бүген табыш китерә торган өлкәләрнең дә киләчәктә авыр хәлдә калулары көн кебек ачык. Әгәр без үзебезнең, республикабызның һәм халкыбызның киләчәге турында уйлыйбыз икән, димәк, беренче чиратта икътисадка этәргеч булган фәнгә һәм халыкны – халык, кешене кеше иткән мәгарифкә, мәдәниятькә һәм сәнгатькә игътибар арттырырга тиешбез. Ә киләсе ел бюджеты проектында кайбер структураларга 60–80 процент үсеш билгеләп тә, фундаменталь фәнни эзләнүләр өлкәсендә мондый үсешнең нибары 0,03 процент кына каралуы һич кенә дә аңлашылмый. Мәгариф һәм мәдәният учреждениеләрен компьютерлар, ксерокслар һәм башка заманча җиһазлар белән тәэмин итү, янгынга каршы чаралар өчен дә бюджеттан һичшиксез өлеш чыгарылырга тиеш дип саныйбыз.

Бу чыгышымда мин, бик теләсәм дә, мәдәният, фән, мәгариф өлкәсендәге бөтен ихтыяҗларны сөйләп бетерә алмам. Без аларның иң мөһимнәрен бюджет проектын икенче укылышка әзерләгәндә Комитет исеменнән тәкъдим итәрбез әле.

Мәктәптә безне, Дарвин теориясе буенча, «Кешене кеше иткән нәрсә – хезмәт» дип укыттылар. Әйе, эш-хезмәт бик тә мөһим нәрсә, эшләмичә бернинди байлык та, без бүген бүлеп утыручы бюджет акчалары да барлыкка килми. Әмма эшне шулай ук ат та, ишәк тә эшли бит. Теләсә кайсы хайванны ниндидер эшкә өйрәтергә була. Әмма дөньядагы бер генә хайванны да, кешедән кала бер генә җан иясен дә укырга-язарга, фәнни ачышлар ясарга, әдәбият һәм сәнгать әсәрләре иҗат итәргә өйрәтеп булмый. Димәк, иң беренче чиратта кешене кеше иткән нәрсә ул – мәгариф, мәдәният, әдәбият, фән һәм сәнгать. Без башка җан ияләреннән шуның белән аерылып торабыз да.

2008 ел бюджеты проектын икенче укылышка әзерләгәндә безнең шушы аһ-зарларыбыз һәм тәкъдимнәребез искә алынсын иде.

*2007*

# МӘДӘНИЯТ, ФӘН, МӘГАРИФ – МИЛЛӘТНЕҢ ӨЧ АЛТЫН БАГАНАСЫ

«Бисмилла диеп башладым бу бәетнең башларын» дигән шикелле, мин дә бүген үземнең бюджет хакындагы чыгышымны рәхмәт сүзләреннән башлыйм әле... Узган еллар белән чагыштырганда без быел карый торган бюджет документы шактый камилләшә төшкән, ул элеккеләреннән тәфсилләбрәк эшләнгән. Әгәр дә моннан дистә еллар элек хөкүмәт безгә башлангыч мәктәп укучысы дәфтәре калынлыгындагы бюджет проекты тәкъдим иткән булса, быел исә Карл Маркс «Капитал»ы калынлыгында фәнни-икътисади трактат эшләп тапшырган. Чыннан да, бюджет проекты бик тә уйланып, җеген җеккә китереп эшләнгән. Әмма, «без өйләнгәч, төн кыскарды», дигәндәй, инде хөкүмәт бюджет проекты эшләргә өйрәнеп беткәч кенә, бөтен Җир шарын хәвефкә салып, икътисад гарасаты – дөньякүләм кризис пәйда булды, һәм ул безнең илне дә читләтеп үтмәде. Шуңа күрә, бюджет проектыбыз никадәр генә камил эшләнгән булса да, дөньядагы һәм Россиядәге икътисад торышын искә алып, киләчәктә аңа үзгәрешләр, коррективлар кертергә кирәк булыр дип уйлыйм.

Бюджет ул бер утыруда экспромт белән языла торган илаһи әсәр түгел, хөкүмәт аны ел буе әзерли. Без депутатлар да ел буе аларны бимазалап, тәкъдим-теләкләребез белән һәрдаим борчып торабыз. Бюджет проектының мәгънәсенә төшенү, аның бар нечкәлекләрен аңлау өчен, соңгы берничә ай эчендә генә дә без, финанс, икътисад министрлары һәм хөкүмәт әһелләре белән кат-кат очрашып, киңәшмәләр уздырдык, шактый мәсьәләләр буенча килешеп, уртак фикергә килдек. Әмма әле без төгәл җавап ала алмаган, бик кирәк булып та, бюджет киртәсенә керә алмый калган мәсьәләләр дә шактый.

Бюджеттан чагыштырмача иң күп акча бүлеп бирелә торган өлкә мәгариф булса, финанс ягыннан хәл ителмәгән иң күп проблемалар да шул ук мәгариф өлкәсенә туры килә торгандыр. Менә бүген кайсы гына мәктәпкә барып керсәгез дә, укытучылар сүзне иң элек хезмәт хакыннан башлый. Дөрес, хезмәт хакының тиешле дәрәҗәдә булмавы бер мәгарифкә генә түгел, бөтен бюджет сферасына хас күренеш. Киләсе елның башыннан без бюджет хезмәткәрләренә тармак системасы буенча эш хакы түләүгә күчәргә җыенабыз. Хөкүмәт һәм министрлыклар әзерләгән документлар буенча фикер йөрткәндә, яңа системага күчкәч тә, әгәр дә бюджетта өстәмә акча каралмаса, хезмәт хакы түләүдә артык зур үзгәрешләр булуы көтелми кебек. Чөнки бүгенге көндә әле күпчелек мәгариф учреждениеләренең үзләре акча эшләү өчен матди нигезләре, мөмкинлекләре тиешле дәрәҗәдә түгел. Сыерны да, күбрәк сөт бирсен өчен, башта әйбәтләп ашаталар, аннан соң гына савалар бит. Ә без, укучы балаларыбыз көннән-көн кимегән чорда җан башыннан финанслауга күчеп, иң беренче чиратта болай да көчкә-көчкә җан асраган юлсыз-автобуссыз авыл мәктәпләрен, туксанынчы елларда шәһәрләрдә ашык-пошык ачылган рәтле бинасыз милли мәктәпләребезне бик тә авыр хәлгә куябыз түгелме соң? Узган август конференциясендә президентыбыз милли уку йортларына һәм авыллардагы аз комплектлы мәктәпләргә аерым игътибар кирәклеге хакында басым ясап әйткән иде, район һәм шәһәр җитәкчеләре бу сүзләрне үгет-нәсыйхәт итеп кенә түгел, ә илбашыбыз фәрманы һичшиксез үтәлергә тиешле күрсәтмә итеп кабул иткәннәрдер дип уйлыйм.

Мәктәпләрне компьютерлаштыру ягыннан без Россиядә шактый алда барсак та, ул компьютерларның инде күбесе һәм физик, һәм мораль яктан искергән булуын, мәктәп китапханәләренә инде ничә еллар буе матур әдәбиятның бөтенләй диярлек алынмавын, күпчелек мәктәпләрдә янгынга каршы һәм саклану системаларының бөтенләй булмавын, мәктәпләрне һәм балалар бакчаларын ремонтлау өчен муниципалитетларның акчасы җитмәвен һәм шуның кебек йөзләгән борчулы мәсьәләләрне искә алсак, хәлнең шактый хәвефле икәнлеген күзалларга мөмкиндер. Менә шуңа күрә дә инде җитәкчелек тә, ата-аналар да, мәгарифкә һәрчак үзләренең мөнәсәбәтен белдереп, яңадан-яңа таләпләр куя. Татарстан Икътисад министрлыгыннан алынган

мәгълүматлар буенча, ата-аналарның 27,5 проценты – мәктәпкәчә белем бирү системасыннан, 31 проценты тәрбиячеләрнең профессиональ әзерлегеннән канәгать түгел икән. Шулай ук ата-аналарның 21,8 проценты – республикабыздагы мәктәпләрдә белем бирү системасыннан, 38,4 проценты – укыту сыйфатыннан, 29,9 проценты – мәктәпләрдә җиһазлар һәм приборлар җитмәүдән, 28 проценты укытучыларның әзерлек дәрәҗәсеннән канәгать түгел. Бу кимчелекләрне бетерү өчен безнең һәммәбезгә дә әле бик күп маңгай тире түгәргә һәм, әлеге ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен, бюджеттан өстәмә өлеш чыгарырга кирәктер.

Быелга кадәр мәдәният өлкәсенә финанс бүлеп бирелү ел саен күзгә күренеп арта килде. Казанның 1000 еллыгына Опера һәм балет театрына менә дигән ремонт-реконструкция ясалды, Г. Камал, К. Тинчурин һәм В. Качалов театрларына, Минзәлә һәм Бөгелмәдәге төбәк театрларына, филармониянең концерт залына һәм тагын шундый дистәләгән мәдәният үзәкләренә ремонт ясау өчен бюджеттан шактый зур финанслар бүлеп бирелде, иҗади проектларны гамәлгә ашыру өчен грантлар системасы булдырылды. Боларны күрмәү һәм искә алмау һич тә дөрес булмас иде. Әмма без үткәндә эшләнгән эшләргә генә куанып утыра торган халык түгел. Безне бүген инде Чаллы һәм Түбән Камадагы дәүләт театрларының махсус проект белән төзелгән, сәнгать сарае дәрәҗәсендәге биналары булмавы, Казандагы Татар яшьләр театрында инде ничә еллар җылыту системасы эшләмәү сәбәпле, балаларның һәм яшүсмер тамашачыларның спектакльләрне пальто-бияләй киеп караулары, шулай ук Татарстан Милли китапханәсенең җылыту системасына тиз арада капиталь ремонт ясау кирәклеге, республикабыздагы йөзләгән клубларның, мәдәният йортларының һәм китапханәләрнең авария хәлендә булуы борчый. Җирле үзидарә системасына күчкәч, аларның хәле тагын да ныграк мөшкелләнде, авылларга килгән инвесторлар да аларга ярдәм итәргә атлыгып тормый. Шуңа күрә, Хисап палатасы бәяләмәсендә әйтелгәнчә, 2009 елда мәдәният өлкәсенә 2008 ел белән чагыштырганда 20,7 процентка кимрәк акча каралуын без берничек тә аңлый алмадык.

Мәдәниятнең әле тагын бер бик тә четерекле өлкәсе – иҗат берлекләре бар. Мулласыз, мәзинсез мәчет булмаган кебек, язучысыз, композиторсыз, рәссамсыз милләт тулы канлы, цивилизацияле милләт була алмый. Дөрес, без һәр ел саен бюджеттан иҗат берлекләренә җан асрарлык кына булса да өлеш чыгарып торабыз. Әмма инфляция һәм бәяләр арту сәбәпле, бу хәер акчасы аларның иң кирәкле ихтыяҗларының чиреген капларга да җитми. Ә инде гонорар мәсьәләсенә килсәк, анда эшләр тагын да катлаулырак. Инде дистә елдан артык республикабызда гонорар системасы игътибардан читтә калып килә. Бүгенге көндә бездә гонорар хисабына гына профессиональ язучы, профессиональ композитор булып яшәү, гаилә асрау мөмкин нәрсә түгел, ел саен бюджет хезмәткәрләренең эш хакы күпмедер арта барса да, гонорарлар нишләптер арттырылмый, индексацияләнми, киресенчә, аның күләме елдан-ел кими генә бара, җитмәсә, авторлар шушы барлы-юклы акчаны да еллар буе ала алмыйча тилмерә. Белгәнегезчә, гонорар ул күктән иңгән әсәр өчен бирелгән сәдака да, хәер дә, бүләк тә түгел. Гонорар ул – иҗат кешесенең төн йокыларын, ялларын, отпускларын исраф итеп, йөрәк каны белән язылган, иҗат ителгән әсәрләре өчен түләү, димәк, аның хезмәт хакы. Әгәр дә инде моны белмәүчеләр яисә аңламаучылар булса, үзләре эштән соң төн утырып роман яисә поэма, симфония яисә картина язып-ясап карасыннар иде. Әгәр дә тиз арада тиешле чаралар күреп, гонорар системасын тәртипкә салмасак, безнең профессиональ сәнгатебезнең тагын да авыррак хәлгә калуы, мәдәниятебезнең һәвәскәрлек, үзешчәнлек дәрәҗәсенә тәгәрәве мөмкин.

«Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыру өчен каралган акча да нишләптер инде дүрт ел буена индексацияләнми, аның бүгенге күләме һич кенә дә Программага кергән чараларны үтәргә җитәрлек түгел. «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законда ике дәүләт телендә эшләүчеләргә 15 процент өстәмә түләү каралган булса да, шушы көнгә кадәр бу мәсьәләнең хәл ителгәне юк. Хезмәткә түләүнең яңа «тармак системасы»на күчкәндә, безгә бу «сакаллы проблема»ны һичшиксез хәл итәргә кирәк! Узган елны кабул ителгән Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәдә Татарстаннан читтә яшәүче ватандашларыбызга,

милләттәшләребезгә ярдәм итү хакында маддә дә бар. Бу вәгъдәбез коры сүз генә булып калмасын дисәк, аны гамәлгә ашыру өчен дә бюджетта урын табылырга тиеш.

Безнең комитет утырышында Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров Татарстан фәненең 2015 елга кадәрле стратегик үсеш Программасын тәфсилләп бәян итте. Бер карашка мәгариф тә, мәдәният тә, фән дә бюджетка табыш китерә торган өлкәләр түгел кебек. Ләкин бу – гаҗәеп тә беркатлы караш. Чөнки мәгарифсез, мәдәниятсез, фәнсез бюджетның табыш өлеше генә түгел, җәмгыять үзе дә куркыныч астында калырга мөмкин, дөресрәге, теләсә кайсы дәүләтнең, теләсә кайсы халыкның киләчәге менә шушы өч алтын баганага таянып тора, алардан башка алга киткән икътисад та, матди байлыклар да барлыкка килми. Без, депутатлар, Фәннәр академиясе президентының: «Бүген фәнгә бирелгән 1 сум берничә елдан 10 сум булып кире кайтачак», – дигән сүзләре белән тулысынча килешәбез, һәм бу залда утыручылар да әлеге фикерне якларлар һәм Татарстан фәненең стратегик үсешен тәэмин итүне яклап тавыш бирерләр дип уйлыйм.

Безнең күпләребез өчен бүген карала торган бюджет проекты, кызганычка каршы, соңгысы булырга мөмкин. Әйдәгез, бүгенге мөмкинлектән файдаланып, җәмгыятьнең киләчәгенә нигез салучы, халыкны – халык, милләтне милләт итүче фәнгә, мәдәнияткә һәм мәгарифкә кулдан килгән кадәр ярдәм кулы сузып, шушы Дәүләт Советыбыз тарихына игелекле затлар, халык мәнфәгатен кайгыртучы депутатлар сыйфатында кереп калыйк әле.

*2008*

# ПРОКУРОР ДӘГЪВАЛАРЫ БЕЛӘН КИЛЕШМИБЕЗ!

*(Татарстан Югары мәхкәмәсендә ясаган чыгыш)*

Татарстан прокуроры «Телләр турында»гы республика Законының өч билгеләмәсенә протест белдерә. Протестның беренче өлешендә прокурор Татарстанның телләр турындагы законының референдумнарда тавыш бирү бюллетененең Татарстан территориясендә ике дәүләт телендә әзерләнә дигән билгеләмәсенә каршы килә. Ул моңа нигез итеп Россия Федерациясенең телләр турындагы законында бюллетеньнәрнең рус телендә әзерләнә дигән билгеләмәсен китерә. Ә инде бюллетеньнәрне милли республикалар дәүләт телләрендә дә әзерләүне, Федераль закон күрсәткәнчә, Россия субъектларының закон чыгаручы органнары түгел, ә шул субъектның сайлау комиссиясе хәл итә, дип яза прокурор.

Россия Конституциясендә Россиядәге милли республикаларның рус теле белән бергә үзләренең титул телләре дә дәүләт теле итеп раслана ала дигән 68 нче маддә бар. Анда субъектларның дәүләт телләре Россиянең дәүләт теле белән бергә гамәлдә була дип язылган. Шуңа күрә Россия субъектлары булган милли республикаларның, шул исәптән Татарстанның да референдумнар үткәргәндә бюллетеньнәрне ике дәүләт телендә әзерләүгә конституцион хокуклары һәм Россия Конституциясенә нигезләнеп кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Законы бар, һәм моның өчен сайлау комиссиясе карары чыгаруның кирәге дә юк.

Протестның икенче өлешендә прокурор безнең «Телләр турында»гы Законның 14 нче маддәсендәге икенче бүлектәге «Татарстан дәүләт телләрен белмәүче халык күпләп яшәгән урыннарда рәсми эш башкару әлеге урында яшәүче күпчелек халык телендә алып барылырга мөмкин» дигән билгеләмәгә каршы килә. Монда ул тагын «Телләр турында»гы Федераль законның «Дәүләтчелеге булмаган халыклар яшәгән урыннарда рәсми эш башкару ике дәүләт телендә, ягъни, рус һәм республика дәүләт телендә алып барылудан тыш, әлеге халык телендә дә алып барылырга мөмкин» дигән билгеләмәсен нигез итеп ала. Безнең «Телләр турында»гы Законга ап-ачык итеп «дәүләт телләрен белмәүче халык» дип язылган. Рус телен дә, татар телен дә җитәрлек дәрәҗәдә белмәгән милләт вәкилләре яшәгән кечкенә генә бер авыл үзенең гомуми җыелышын яки аның протоколын әлеге телләрдә ничек алып барсын икән?! Әйтик, авыл уртасындагы коены төзәтү турындагы мәсьәләне ул ничек өч телдә протоколга яза ала, һәм бу кемгә кирәк? Бу авыл җыелышында республика яки Россия күләмендә хәл ителергә тиешле мәсьәләләр күтәрелсә, әлбәттә, соңыннан протоколны ике дәүләт теленә тәрҗемә иттереп, югарыдагы оешмага җибәрергә мөмкин. Нindидер бер татар, чуваш яисә мари авылында түгел, хәтта югары дәүләт органнарында, шул исәптән Югары мәхкәмә-судта да ике дәүләт телендә эш алып бару мәсьәләсе әлегә хәл ителмәгән. Шуңа күрә без протестның бу өлеше белән дә килешә алмыйбыз.

Протестның өченче өлеше белдерүләр, афишалар, башка күргәзмә мәгълүматлар, ярлыклар, этикеткаларның кайсы телләрдә булырга тиешлегенә багышланган. Татарстанның «Телләр турында»гы Законында, мондый төр мәгълүматлар кулланучылар теләген искә алып, «татарча да әзерләнергә мөмкин» дигән билгеләмә бар. Прокурор исә «Телләр турында»гы Федераль законның «рекламада рус теле куллану мәҗбүри» дигән төшенчәсенә нигезләнеп, безнең Законлагы әлеге билгеләмәгә протест белдерә. Әгәр дә без Законның бу маддәсен прокурор протесты буенча үзгәртсәк, татар җырчысы Илһам Шакировның татар авылында татар кешеләре өчен куячак концерт афишасын рус телендә дә бастырырга тиеш булачакбыз. Кемгә кирәк бу мәгънәсез эш?

Татарстан прокурорының әлеге протесты Дәүләт Советы Комитетында һәм сессиядә каралды. Дәүләт Советының эш планы буенча шушы елның маенда «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы

Законының ничек гамәлгә ашырылуы хакында хөкүмәтнең хисабы тыңланачак. Хөкүмәт әһелләренең һәм депутатларның тәкъдимнәрен искә алып, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертеләчәк. Бер үк мәсьәләгә кат-кат әйләнеп кайтмас өчен, без, прокурор протестындагы таләпләрне дә шулар белән бергә карап, мәсьәләне берьюлы хәл итәргә җыенган идек. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы Законы моңа кадәр 16 ел уңышлы гына эшләп килде, аңа дәгъва белдергән кеше булмады, халык аннан зыян күрмәде, хәзер дә артык куаламыйча, ашыктырмыйча, салкын акыл белән эшләсәк, яхшырак нәтиҗәгә ирешә алыр идек.
Әлегә без прокурор протестындагы дәгъвалар белән килешә алмыйбыз. Чөнки Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Законының прокурор тәңгәлләштерүне таләп иткән маддәләре Россия Конституциясенең 68 нче маддәсенә каршы килә. Ә безнең өчен Конституция иң югары, иң төп закон булып тора. Аннары, узган елның июнь аенда кабул ителгән Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләр бүлешү хакындагы Шартнамәдә Татарстан Конституциясенең танылуы хакында әйтелә. Ә~ безнең бөтен законнарыбыз да Татарстан Конституциясенә тәңгәл килә. Димәк, Федераль закон белән ныгытылган Шартнамә нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Законына дәгъва белдерергә хокукый нигез дә, әхлакый нигез дә юк дип саныйбыз.

*2008*

# ЯЗМЫШЫБЫЗ ЕЛЪЯЗМАЧЫСЫ

«Ватаным Татарстан» – республикабызның Дәүләт Советы һәм хөкүмәте тарафыннан гамәлгә куелган татар телендәге бердәнбер рәсми газета. Бер караганда, рәсми газета булу аңа мәртәбә һәм дәрәҗә өсти, ә икенче караганда, рәсмилек бу басмада эшләүчеләрнең җаваплылыгын арттыра, аларны дәүләти һәм рәсми кысаларга керергә мәҗбүр итә. Ул журналистларга үз сүзләрен генә түгел, ә хөкүмәт фикерен җиткерү бурычын да йөкли. Бу исә күпмедер дәрәҗәдә сүз һәм фикер ирегеп йөгәнләп яисә тышаулап куя. Чөнки рәсми газетаның төп максаты һәм бурычы, бер яктан, дәүләт идеологиясен халыкка аңлату булса, икенче яктан, халыкның уй-фикерләрен рәсми җитәкчелеккә һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү. Менә шуннан чыгып караганда, үз көнен үзе күрүче яисә рәсмилек статусы беркетелмәгән башка басмаларның хәле җиңелрәк, иҗат мөмкинлекләре зуррак кебек. Газетада яисә журналда басылган язма өчен алар бары тик үз укучылары һәм закон каршында гына җавап тота. Ә «Ватаным Татарстан»ның һәр җөмләсе дәүләт – республика идеологиясенә дә аваздаш булырга, Татарстанның гавамга әйтергә теләгән фикере булып яңгырарга тиеш. Бу гаҗәп тә катлаулы һәм җаваплы бурычны, шөкер, «Ватаным Татарстан» газетасы һәм аның элгәрләре инде менә бер гасырга якын уңышлы рәвештә башкарып килә.

«Ватаным Татарстан»ны юкка гына халык белән дәүләт һәм җитәкчелек арасындагы күпер дип атамый торганнардыр. Ә күпернең язмышы беркайчан да җиңел булмаган. «Күпер бик тә кирәкле нәрсә, әмма, гадәттә, күпер өстендә яшәмиләр, аның аркылы үтеп-сүтеп кенә йөриләр», – дигән иде кемдер. «Ватаным Татарстан» хезмәткәрләре – шушы күперне үз иңнәрендә тотып торучылар, ике ярны тоташтыручы рухи күпернең алтын субайлары!

«Ватаным Татарстан», татар телендә кануннар һәм рәсми карарлар бастыручы бердәнбер газета буларак, уникаль басма саналырга хаклы. Ләкин шунысы кызганыч: әлеге рәсми документлар барча халык тарафыннан да егылып укыла торган язмалар түгел. Бу нәрсә иң беренче чиратта газетаның тиражына тискәре йогынты ясый торгандыр. Чөнки ул тираж арттыру өчен, үзенең битләренә урам кызларын һәм замана башкисәрләрен чыгарып, «матбугати оргияләр» оештыра алмый. Шуны истә тотып, дәүләт органнары газетага ярдәмгә килсә һәм республикадагы ике мең китапханә, ике мең ярым клубка һәм мәдәният йортына, ике мең ярым мәктәпкә, бер мең муниципаль берәмлеккә, барча дәүләти оешмаларга берәр генә данә «Ватаным Татарстан»га язылуны оештырса, газетаның тиражы шунда ук бермә-бер артыр иде. Ә бу үз чиратында хокукый дәүләттә яшәргә җыенган халыкның законнар һәм карарлар белән танышу мөмкинлеген киңәйтәчәк. Без бит халыкка: «Законнарны белмәү беркемне дә җаваплылыктан азат итми», – дибез, ә үзебез аларга законлы хокукларын һәм бурычларын тиешле дәрәҗәдә аңлату өчен шартлар тудырмыйбыз. Билгеле, моның өчен газетада, законнарны һәм карарларны бастыру белән бергә, аларга тәфсилле аңлатмалар бирү һәм ул законнарның үтәлеше хакында даими язмалар урнаштыру да кирәктер. Юбилей алдыннан редакция кол-лективы белән очрашу вакытында президентыбыз да бу хакта үзенең фикерен әйтте.

Заманында бөек Тукай: «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер...» – дип әйткән. Ул бүгенге болгавыр һәм азгынлыкка чумган заманда, бәлки, Тукай заманына караганда да кирәгрәктер. Әмма соңгы елларда тәнкыйтьнең тәэсир көче кимедеме, әллә инде безнең тиреләребез калынайдымы, җан ачысы белән борчылып язылган мәкаләләр дә ни җәмәгатьчелек, ни җитәкчелек тарафыннан бөтенләй диярлек игътибарга алынмый башлады. «Эт өрер, бүре йөрер» дигәндәй, газета яза тора, азгынлыкка, бозыклыкка, ришвәтчелеккә баткан адәми затлар, берни булмагандай, үз гамәлләрен кыла тора. Бу хәлдән чыгу өчен безгә, бәлки, хөкүмәт яисә парламент дәрәҗәсендә сүз кузгатып, җитәкчеләргә һәм контрольлек итүче органнарга тәнкыйть мәкаләсенә игътибар итү, нәтиҗә ясау һәм чара күрү бурычын йөкләргә кирәктер? Киләчәктә үзебезнең комитет утырышларының берсен матбугат проблемаларына багышларга җыенабыз һәм анда бу мәсьәләне дә игътибар үзәгенә алырбыз дип уйлыйм.

«Ватаным Татарстан» Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Дәүләт Советы органы булса да, рус телендә чыгучы шундый ук рәсми газета саналган «Республика Татарстан»нан аермалы буларак, аның әле тагын бер бик югары миссиясе бар. Ул – бөтен дөнья буйлап сибелгән һәр татар кешесенең үз газетасы; бу матбага бүгенге көндә бөтентатар газетасы вазифасын да башкара. Менә шул газетага, аның коллективына өстәмә бурычлар һәм җаваплылык йөкли. Әгәр сиңа шундый җаваплы вазифа йөкләтелгән икән, димәк, син бөтен татар дөньясын мөмкин булган кадәр үз битләреңдә яктыртып барырга, читтәге татарларның да рухи һәм мәгълүмати ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешсең. Ә моның өчен техник һәм матди мөмкинлекләр тудыру, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә корреспондент пунктлары булдыру, алар белән ике яклы элемтә урнаштыру, газетаның кәгазь һәм электрон вариантларын дөньяның төрле төбәкләренә җиткерү чараларын күрү кирәк. Моннан алты ел элек без Татарстан Конституциясенә читтә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә Татарстанның ярдәме хакында аерым маддә өстәдек. Узган ел әлеге бурычны Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләр бүлешү хакындагы Шартнамәдә Федераль закон белән беркетеп куйдык. Димәк, «Ватаным Татарстан»ны дөньяга тарату өчен Татарстан Конституциясе дә, Россия законы да мөмкинлек бирә, безгә хәзер бергәләп шуны тормышка ашыру механизмын эшләргә һәм аны башкарып чыгарга кирәк.

Соңгы арада газета-журналлардан теләсә нинди юллар белән акча эшләүне таләп итә башладылар. Бер караганда, бу дөрестер дә. Әгәр бөтен илебез белән базар икътисадына кереп барабыз икән, без генә бер читтә коммунизм төзеп ята алмый торганбыздыр. Әмма «пәри башка, җен башка» дигәндәй, таләпне куйганда, иң әүвәл кемнән нәрсә сораганыңны акча янчыгы аша гына түгел, ә күңел аша да үткәреп карарга кирәктер. Мәсәлән, безнең илдә балага ундүрт яшькә кадәр эшкә урнашу, димәк, акча эшләү тыелган икән, шул яшьтәге балалар өчен чыгарылучы газета яисә журналдан көчләп акча эшләтү, акча таптыру дөрес гамәл булыр микән? Шулай ук бу очракта әдәби басмалардан да, матди байлыктан битәр, иң әүвәл рухи байлык таләп итү дөресрәктер, минемчә. Ә инде реклама бастырып акча эшләүгә килгәндә, бу өлкәдә татар басмалары рус басмалары белән берничек тә ярыша алмый. Гомумән, татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелмичә, аннан акча эшләтергә тырышу зур нәтиҗәләр бирмәс. Җитмәсә, үзебезнең хөкүмәтебез дә тендер-конкурслар турындагы реклама белдерүләрен рус телендә генә бастыруны хуплап, татар басмаларын бу юл белән акча эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм итте. Рекламаны рус телендә генә бастыру, татар телле газета-журналларның бюджетын ныгытуны гына чикләп калмыйча, татар теленең дәрәҗәсен һәм рәсми статусын түбән төшерә. Дөрес, мондый очракта газета-журнал укучыларның күңелләрен күрерлек язмалар өчен урын күбрәк кала, реклама бастырыласы урында алар үзләре теләгән кызыклы язмаларны күрә ала. «Татмедиа» җитәкчелеге киләчәктә газета-журналларның исәп-хисап нормативларын әзерләгәндә, һәр аерым басманың үзенчәлегенә игътибар итеп һәм милли басмаларның мөмкинлекләрен истә тотып эшләсә, дөресрәк булыр. Ә инде рәсми статустагы «Ватаным Татарстан»га аерым игътибар, дәүләти басмага, базар мөнәсәбәтеннән битәр, дәүләти мөнәсәбәт булырга тиешлеген беркем дә инкяр итә алмый.

Соңгы елларда республикабызда чыгучы милли басмаларның теле бик тә чүпләнде. Бу яктан караганда да башка басмаларга үрнәк күрсәтү – «Ватаным Татарстан»ның бурычы. Рус теленнән алынган калькалар, әдәби тел нормаларына сыймаган гыйбарәләрне хәзер һәр язмада диярлек очратырга мөмкин. Ялгышмасам, баш редактор булып Шәмси Хамматов эшләгән заманда, шушы чирдән арыну өчен, редакциядә тел чисталыгын тикшереп торучы әдәби мөхәррир штаты булдырылган иде. Ул вазифага Шәмси ага күренекле язучы, тел остасы Хәсән Сарьянны чакырды. Бу тәҗрибә бүген яңадан тормышка кайтса, бик дөрес булыр.

Үзең кылган гамәлләргә, басылган язмаларга читтән күз ташлау өчен, редколлегия эшен җанландырып, чыккан саннар хакында кимендә айга бер мәртәбә тәфсилле фикер алышу, парламент һәм хөкүмәт әһелләре белән газета хакында «түгәрәк өстәл»ләр, эшлекле әңгәмәләр үткәрү дә зыян итмәс.

«Ватаным Татарстан» гомер-гомергә әдәби хәрәкәтебезнең үзәгендә булды. Язучыларның иң асыл әсәрләре аның битләрендә дөнья күрде, әдәби тәнкыйть мәкаләләренең дә иң саллылары шунда басылды. «Ватаным Татарстан»да әсәр бастыру теләсә кайсы язучы өчен мәртәбә санала иде. Дөрес, хәзер махсус әдәби-мәдәни басмалар дөньяга килде. Әмма халкыбызның төп газетасы буларак, «Ватаным Татарстан» үзенең туксан еллык бу күркәм традициясенә хилафлык китермичә, әдипләребезнең иң төпле әсәрләрен киләчәктә дә халыкка җиткерә торсын иде.

Гадәттә, юбилей көннәрендә мактау сүзләре генә сөйлиләр. Ә мин һаман хәл ителәсе проблемалар, чишеләсе мәсьәләләр хакында сөйлим. Әйе, «Ватаным Татарстан» – күккә чөеп мактарлык, теләсә кайда горурланып сөйләрлек затлы басма, уйлы-фикерле, хисле-моңлы, иманлы һәм туры кыйблалы газета. Ә безнең аны тагын да матуррак һәм үтемлерәк, дәрәҗәлерәк һәм затлырак итеп күрәсебез килә. Чөнки ул – халкыбызның рухи көзгесе, язмышыбыз елъязмачысы. Ә без халкыбызга да, аның олуг газетасына да, үзебезгә дә бары тик матур киләчәк һәм бәхетле язмыш кына телибез.

*2008*

# ДИН ҺӘМ МИЛЛӘТ

Безнең республикада бүген олы вакыйга – Россия Мөфтиләре шурасы үзенең күчмә утырышына һәм «Россия мөселманнары берлегенең көнкүреш-мәдәни үсешендә мөселман дини оешмаларының роле: тарих һәм бүгенге заман» дигән фәнни-гамәли конференция үткәрергә Казанга җыелды. Бу ике зур чараның Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте тарафыннан уздырылган беренче берләштерү корылтаеның унъеллыгына туры килүе аеруча әһәмиятле.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!

Сезнең барыгызны да Республикабыз Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев, шулай ук Татарстан Дәүләт Советы һәм хөкүмәтебез исеменнән Россия мөселманнары тормышындагы әлеге әһәмиятле вакыйгалар белән чын күңелдән котларга һәм безнең башкалабызда үткәреләчәк игелекле эшләрегезгә уңыш теләргә рөхсәт итегез.

Беренче берләштерү корылтаеннан соң үткән ун ел эчендә республикабызның Диния нәзарәте тарафыннан бик күп җитди эшләр башкарылды. Шуларның иң әһәмиятлесе – Татарстан мөселманнары җәмгыятьтәге һәм көндәлек тормыштагы каршылыкларны җиңү өчен берләшеп, кулга-кул тотышып эшләүнең бик күпкә кулайрак икәнен күрсәттеләр.

Без бүген Татарстандагы мөселман дини оешмалары Россия мөселманнары өчен дә рухи тәҗрибә үзәгенә әверелә бара дип ышанып әйтә алабыз. Республикабызда мөселман оешмаларының саны меңнән артып китүе, мәчетләрнең күплеге, дини уку-укыту үзәкләренең, мәдрәсәләрнең һаман ишәя баруы шуны күрсәтә. Бүгенге көндә Казанда Россия ислам университеты, «Мөхәммәдия», «Исламның 1000 еллыгы исемендәге» мәдрәсәләр, Казан ислам колледжы, Чаллыда – «Ак мәчет», Әлмәттә – Риза Фәхретдин исемендәге, Түбән Камада – «Рисалия», шулай ук Буада һәм Нурлатта мәдрәсәләр эшләп тора.

Әлбәттә, мондый уңышларга республикабыздагы җитәкчелек, бөтен җәмәгатьчелек тырышлыгыннан башка гына ирешеп булмас иде. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең дини мәсьәләләрдә ярдәмчел зирәк гамәлләре, Татарстан Дәүләт Советының республикадагы гына түгел, ә бөтен Россиядәге дини конфессияләр хакындагы кануннарны камилләштерүдәге тырышлыклары, шулай ук хөкүмәтебезнең дини оешмалар хәлен яхшыртуга юнәлтелгән карарлары Татарстандагы мөселман өммәтен һәм башка дини конфессияләрнең бүгенге көн казанышлары дәрәҗәсендә эшчәнлек алып баруларын тәэмин итә.

Узган ун ел эчендә хаҗ кылган мөселманнарның саны бик нык артты. Әйтик, 2003 елда хаҗга баручылар 179 кеше булса, 2006 елда бу сан 1200 гә җитте. Хаҗга барып кайтуны оештыруда Татарстан Диния нәзарәтенең «Идел-хаҗ» департаменты белән берлектә дәүләт оешмалары да катнаштылар.

Дөрес, Татарстан Республикасы да, Россиянең мөселманнар тупланып яши торган башка төбәкләре дә уртак Ватаныбыз Россия шартларында көн күрәбез. Без үз тормышыбызны, үз эшчәнлегебезне Федераль Конституция, Федераль законнар нигезендә корабыз. Шул ук вакытта безнең Россия Конституциясе һәм Федераль законнарны камилләштерү эшендә катнашырга да хакыбыз бар. Әйтик, 1997 елда Россия Федерациясе «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр» дигән Закон кабул итте. Татарстан җәмәгатьчелеге, дини оешмалары, халык депутатлары бу Законны өйрәнеп, аңа төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертергә кирәк дип таптылар. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, бу тәкъдимнәрне туплап, 2001 елның 27 июнендәге карары белән Россия Дәүләт Думасына һәм Россия субъектларының закон чыгару органнарына җибәрде. Безнең төзәтмәләр, нигездә, Россиядәге аерым бер диннәргә генә өстенлек бирүнең дөрес түгеллеге, экстремистлыкка һәм җәмгыять тормышында сыналган гореф-гадәтләргә каршы килүгә корылган өр-яңа диннәр үз эшчәнлекләрен закон нигезендә генә алып барырга тиешлеге, Россия субъектларына дини оешмалар белән эшләүче органнар булдырырга хокук бирүнең кирәклеге, шулай ук һәр субъектта бер дингә караган бер генә үзәк дини оешма төзелә алуы, дини төркемне теркәгәндә дәүләт нотариаль оешмасы таныклыгы булырга тиешлеге хакында иде. Шул

ук вакытта без ислам оешмаларында вакыф мәсьәләсенең Россия күләмендә хәл ителергә тиешлеген дә күтәрдек.
Татарстан Дәүләт Советының бу тәкъдимнәренә Россиянең 17 субъекты үзенең мөнәсәбәтен белдерде. Шуларның унөче безне яклавын, дүртесе якламавын хәбәр иттеләр. Үз мөнәсәбәтен белдергән Россия субъектларының күбесе Татарстан Дәүләт Советы тәкъдимнәрен яклап чыкса да, Россия Дәүләт Думасы үзенең 2004 елның 7 июлендә кабул иткән карары белән Татарстан Дәүләт Советы тәкъдимнәрен кире какты.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!
Әлеге Федераль законга ныклабрак тукталуымның сәбәбе шунда: диннәр турында Федераль законнарны әзерләгәндә, инде кабул ителгән законнарга төзәтмәләр керткәндә, федераль дәрәҗәдәге дин оешмалары да, Россия субъектларындагы дин оешмалары да, аларның һәрбер җитәкчесе, һәр дин әһеле мөмкин кадәр актив катнашсыннар иде. Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган ислам әһелләре катнашында үтүче бүгенге очрашуда моны әйтеп китмичә булмый.
Гасырлар белән гасырлар алмашкан чорда ун ел гомер бик зур түгел. Шулай да узган унъеллыкта ирешкән уңышларны күрми калу ярамас. Ә инде эшләнәсе эшләр уңышлардан да күбрәк сыман. Әйтик, бүген без Татарстан мөселманнары берләште дип әйтсәк тә, мөселман дөньясына кагылышлы бөтен дин әһелләре, мөселман кешеләре рухи яктан берләшеп бетте дип әйтә алмыйбыз. Әле бүген дә мәхәллә белән мәхәллә, мәчет белән мәчет, мулла белән мулла арасындагы эреле-ваклы каршылыклар, үзара низаглар, бер-берең… юл бирмәскә тырышуларның беткәне юк. Мондый тискәре күренешләр халыкка, бигрәк тә яшьләргә дини тәрбия, әхлак тәрбиясе бирүгә зур зыян китерә.
Бүгенге көндә дини кадрлар мәсьәләсе дә хәл ителеп беткән дип әйтеп булмый. Муллаларыбызның, бигрәк тә күпмилләтле шәһәрләрдәге, шулай ук үзәкләрдән ерактагы аулак мәхәлләләр җитәкчеләренең кайберләренә дини яктан да, мәдәни яктан да ныклы белем, югары әхлак җитенкерәмәү барыбызны да борчый. Бу мәсьәләдә мәгариф системасының камил булуы бик әһәмиятле. Билгеле булганча, дини өлкәдә мәгариф системасы ике юнәлештә бара. Берсе дәүләт мәгариф учреждениеләрендә динне укыту мәсьәләсе булса, икенчесе – дини оешмаларның үз уку йортларындагы уку-укыту эшләре. Моннан берничә ел элек Россиядә дәүләт мәктәпләрендә православие динен укыту идеясен күтәреп чыктылар. Бу мәсьәләдә Татарстан үзенең катгый фикерен әйтте – дәүләт мәктәпләрендә аерым бер дин дәресләре түгел, ә дөньядагы иң зур, традицион диннәр тарихы укытылырга тиеш. Без бу мәсьәләне Россия җитәкчелегенә җиткерү өчен күп тырыштык, һәм, ниһаять, Владимир Владимирович Путин да, Дмитрий Анатольевич Медведев та дәүләт мәктәпләрендә диннәр тарихын укытуның дөрес булачагын яклап чыктылар.
Ә инде дини кадрлар, мәчетләрдә, мәхәлләләрдә эшләүче дин әһелләрен әзерләү, аларны укытып чыгару эшен дин оешмалары үзләре хәл итәргә тиеш. Бу мәсьәлә дәүләт югары уку йортлары белән тиңләштерелгән дини югары мәктәпләрдә, мәдрәсәләрдә уку-укыту һәм тәрбия эшләренең торышы белән бәйле. Әмма бүгенге көндә әле тирән белемле, әхлак һәм оештыру мәсьәләләрендә үрнәк булырлык дин әһелләре укытып чыгару эше тулысынча хәл ителгән дип әйтеп булмый.
Дини мәгариф системасы эшчәнлеге дин һәм милләт мөнәсәбәтләренә дә турыдан-туры кагыла. Әйтик Татарстан җирлегендәге ислам дине тарихына күз салсаң, ислам диненең һәрвакыт татар халкының иң матур, иң игелекле гореф-гадәтләрен, әхлакый нормаларын, Татарстан җиренә генә хас табигый көнкүреш традицияләрен югалтмаска, киресенчә, аларны алга таба да үстерергә омтылуын күрәсең. Татар халкының гаилә, ата-ана, нәсел-нәсәп, бала-чага, кияү-килен, кода-кодачалык, күрше-күләнлек мөнәсәбәтләрен изгеләштерүен һәм аларның үзара туганнарча яшәвен, туган халкыбызның аш-суга, көнкүрештә чисталыкка маһир булуын, белем алуга, төрле һөнәрләр өйрәнүгә омтылышын, башка милләт кешеләренә хөрмәт белән каравын ислам дине һәрвакыт яклап килде. Үз чиратында татар милләтенең иң асыл сыйфатлары ислам динен күтәрүгә ярдәм итте. Бу татар халкы белән генә түгел, ә ислам динен кабул иткән бөтен милләтләр, бөтен халыклар белән дә шулай булды. Милли үзенчәлекләрне йота барган бүгенге глобальлек чорында ислам әһелләре милләтебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу

мәсьәләсендә дә активрак эшләсеннәр иде. Барыбызга да билгеле булганча, хәзер Көнчыгыштагы бай мөселман илләрендә бик күп дини уку йортлары, зур мәдрәсәләр эшли. Аларда төрле мөселман илләреннән, мөселман төбәкләреннән килгән бик күп шәкертләр белем ала. Ул уку йортларында Россиянең мөселман төбәкләреннән килгән шәкертләр дә күп. Бүген безгә уйларга кирәк – алар нindirәк белем алып кайтырлар? Алар анда татар халкының һәм Россиянең мөселман төбәкләрендә яшәгән башка халыкларның тарихы, гореф-гадәтләре, җирле үзенчәлекләре нигезендә тәрбия алганнармы һәм туган халыкларының иң асыл сыйфатларын дини тәрбия эшендә файдаланырга әзерләрме? Россиядәге диния нәзарәтләренә, мөфтиләребезгә, тәҗрибәле муллаларыбызга бу турыда уйлану һәм туган җирләренә укып кайткан шәкертләрнең киләчәк эшчәнлегендә ярдәм кулы сузарга әзер булуларын телисе килә.

Дин һәм милләт мәсьәләсе турында сөйләгәндә, туган телебезне саклауның никадәр зур әһәмияткә ия икәнен дә әйтеп китмичә булмый. «Дин әһелләребез вәгазьләрен нинди телдә сөйләсәләр дә барыбер», – диючеләр бик нык ялгышалар, һәр мәхәлләдә, һәр мәчеттә, дин әһелләренең халык белән һәр очрашуында югары сыйфатлы туган тел, саф, чиста сөйләм теле хөкем сөрергә тиеш. Әйтик, чип-чиста татар җирлегендәге мәчеттә мулланың рус телендә яисә корама, ватык-җимерек татар телендә вәгазь сөйләве ким дигәндә мәхәллә әһелләрен мәчеттән биздерүгә генә хезмәт итәр иде. Ә мондый күренешләр әле бездә юк түгел.

Диннең җәмгыятьтәге урыны турында сөйләгәндә, исламның яшь буынны тәрбияләүдәге әһәмиятенә аеруча игътибар итәргә туры килә. Дин әһелләре тарафыннан яшь буынны тәрбияләү эшләре мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә генә түгел, ә җәмгыятебезнең, яшәешнең һәр өлкәсендә алып барылырга тиеш. Бүген безнең җәмгыятебездәге яшьләр тормышындагы гаять аяныч күренешләргә, әйтик, наркоманиягә, алкоголизмга, җәмәгать урыннарындагы әхлаксызлыкка, җинаять эшләренә каршы көрәшүдә ислам дине үзенең югары әхлак нормаларына нигезләнеп кыюрак эш итә алыр иде.

Соңгы елларда республикабызда дини тормышның яңаруы нәтиҗәсендә бала туу, аңа исем кушу, өйләнешү, туй кебек аеруча игътибар сорый торган ритуалларны матур итеп үткәрүдә шактый алга китеш сизелә. Әлбәттә, моны тәртипкә салуда дини оешмаларның тырышлыгы зур. Шулай да, өйләнешеп туй ясаганнан соң, гаиләнең ныклыгы, тотрыклылыгы, балаларга, әти-әнигә, өлкән буынга аеруча хөрмәт күрсәтү кебек игелекле яшәү рәвешен яшьләргә ныграк аңлатырга, аларны шушы рухта тәрбияләү эшен көчәйтергә иде. Бу мәсьәләдә соңгы елларда оешкан һәм инде матур гына эшли башлаган мөселман хатын-кыз оешмаларының мөмкинлекләре аеруча зур дип уйлыйм. Шул ук вакытта күптән түгел генә оешкан Татарстан Мөселман яшьләре ассоциациясенә тәҗрибәле дин әһелләренең һәрьяклап ярдәм итүләре бик кирәк.

Яшьләрне тәрбияләүдә, ислам диненең иң матур, игелекле эшләрен пропагандалауда исламның үз матбугат чаралары да күп эшли алыр иде. Әмма әлегә ислам басмаларының, газета-журналларының полиграфик яктан бик төссез, эчтәлек ягыннан һәр мөселман кешесенең күңеленә кереп җитәрлек язмаларга ярлы булуын әйтеп китми булмый. Дөрес, Коръәнне нәшер итү бөтен дөнья күләмендә югары сыйфатлы итеп башкарыла. Башка басмалар да шуңа омтылсыннар иде дип телисе генә кала.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр!

Тормышыбызның бөтен өлкәләрендәге кебек, ислам җәмгыятенең бүгенге эшчәнлегендә, аның дәүләт органнары, төрле җәмәгать оешмалары, мәхәллә әһелләре, һәр ватандаш белән мөнәсәбәтләрендә ирешкән уңышлар белән бергә киләчәктә үтәлергә тиешле олы бурычлар да байтак. Шуны кистереп әйтергә мөмкин: без бергә-бергә, үзара аңлашып, кулга-кул тотынып эшләгәндә генә бу бурычларны уңышлы башкара алачакбыз. Россия Мөфтиләр шурасы утырышы да, фәнни-гамәли конференция эше дә шушы юнәлештә барыр дип ышанып калам.

*2008*

# ИҢ ЗУР КРИЗИС – РУХИ КРИЗИС

Минем бүген һич кенә дә бу мөнбәргә чыгып бюджет проекты хакында сүз куертасым килмәгән иде. Беренчедән, илгә килгән икътисади афәттән башлары каткан җитәкчеләребезнең болай да яралы күңелләренә тоз саласым килмәсә, икенчедән, монда чыгып сөйләү түгел, кычкырып еласаң да файда булмасын, күктән акча яумасын, бюджет проекты үзгәрмәсен бик яхшы беләм. Әмма бүген дәшми калу сайлаучыларымның гозерләрен һәм мөрәҗәгатьләрен аяк астына салу булыр иде.

Шулай да чыгышымны иң элек рәхмәт сүзләреннән башлыйм әле... Соңгы елларда Дәүләт Советы утырышларында, матбугат битләрендә зур борчылу тудырган, бәхәсләр кузгаткан мәсьәләләр – туган телебезне саклау, борынгы архитектура һәйкәлләренә сакчыл карау, балаларыбызга тиешле белем-тәрбия бирү мәсьәләләре булгандыр. Безгә тәкъдим ителгән бюджет проектындагы 20 максатчан проект арасыннан бары тик берничә программа гына кыскартудан сакланып калган. Шулар рәтендә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында»гы Законны гамәлгә ашыру Программасы, балаларның ялын оештыру, «Татарстан балалары» һәм «Мирас» программалары булу, аларга элек каралган күләмдә акча тәгаенләнү өчен президентыбызга һәм башка җитәкчеләребезгә рәхмәттән башка сүз әйтеп булмый. Сәләтле балаларга ярдәм итүгә, телевидение һәм радиога каралган чыгымнарның үзгәрешсез калуы да күңелебезгә хуш килде.

Чыгышымның рәхмәт өлешен тәмамлап, көндәлек хәлләргә килсәк, шактый гына эшләребез бик шәптән түгел икән бит, җәмәгать. Әйе, мин кемнәрнеңдер «нишлисең бит, кризис», «юрганыңа карап аягыңны сузасың инде» дип әйтәчәген дә сизеп торам. Әмма ләкин илгә килгән бәлане тигезләп бүлеп, бергә күтәргәндә генә ул авырлыкларны җиңү җиңелрәк була. Югыйсә берәүләр шул кризистан аяк сузарга җыенганда, икенчеләрнең мәйдан тутырып «браво!», «бис!» кычкыруларын аңлау да, аңлату да бик авыр булачак. Инде моңа кадәр әйткәнебезчә, шушы елның биш аенда Татарстан китап нәшрияты тартып-сузып, көч-хәл белән нибары бер китап бастырып чыгара алды. «Мәгариф» нәшриятының хәлләре шулай ук яшәү белән үлем арасында. Сәбәбе гади – китап бастыру өчен акча бирелмәүдә. Бүген безгә тәкъдим ителгән бюджет проектында вакытлы матбугатка каралган 517 миллион сум акчаның егерме җиде миллионы кыскартылган булса, нишләптер шуның 20 миллионын нәшриятлар хисабына кискәннәр. Гомер-гомергә безнең илдә байларны талыйлар иде, бу юлы нишләптер көч-хәлгә очын очка ялгап яшәүче фәкыйрь нәшриятларга тотынырга уйлаганнар. «Без Интернет заманында яшибез, китап уку чоры узды», – диючеләргә мин Европа илләренең китапханәләренә, китап кибетләренә кереп карарга киңәш итәр идем. Китап заманы узса, Интернет чәчәк аткан Америкада, Япониядә, Франциядә, Германиядә, Англиядә елдан-ел арттырып миллионлаган-миллиардлаган китаплар бастырып чыгармаслар, мәһабәт китапханәләр төземәсләр иде. Беләм, бюджет проектын эшләүчеләрнең китап укырга вакытлары да юктыр, бәлки, арада китап укуны кирәксенмәүчеләр дә очрыйдыр. Әмма бюджет алар өчен генә түгел, ә республика халкы өчен кабул ителә, китаплар да шулай ук халык өчен бастырыла бит.

Китап дигәннән, республикабыздагы китапханәләрнең хәлләре дә көннән-көн мөшкелләнә. Китапханәләргә китап сатып алыр өчен муниципаль бюджеттан бер тиен дә акча бирмәүче районнарның саны арта бара. Газета-журналларга язылу өчен быел күпчелек районнарда финанслауны бермә-бер киметтеләр. Китапханәләрне җиһазлау, фондларын тулыландыру ягыннан без халыкара стандартлардан гына түгел, хәтта якын күршеләребез чувашлардан да бик нык артта калдык. Ә үзебез һаман: «Безнең халык – китаплы халык, мәгърифәтле халык», – дип, атлаган саен лаф орып, горурланып йөрибез. Республикабызның карап торган бердәнбер 145 яшьлек Милли китапханәсе язмышы бер Алла кулында. XIV гасырдан башлап бүгенге көннәргә кадәр тупланган бәһа биргесез рухи хәзинәләребез юеш подвалларда, чардакларда җан асрый, 300 мең китап сыйдырырлык бинада бүген 3 миллион 200 мең данә китап гомер сөрә. Китапханәнең

җылылык системасы инде күптән авария хәлендә. Узган елны черегән торбалар тишелеп, кыш уртасында бер афәт булган иде инде, әле аңа һаман ремонт ясалмаган. 3 ел рәттән хөкүмәттән акча теләнеп тә, бүгенге көнгә кадәр безнең аһ-зарга колак салган кеше юк. Әгәр быел да ремонт өчен 5 миллион сум чамасы акча бирелмәсә, кышын тагын авария булып, халкыбызның гасырлар буе тупланган бик күп акыл хәзинәләре юкка чыгарга мөмкин.

Китапханәләр, китаплар хакында болай озаклап сөйләвемә, аларга аерым игътибар итүемә гаҗәпләнмәгез, чөнки аларның кичә һөнәри бәйрәмнәре – Китапханәләр көне иде бит!

«Әйтсәң – сүз, төртсәң – күз» дигәндәй, сөйли китсәң, бу бюджет проектының очы-очка ялганмаган, мантыйкка сыймаган байтак урыннарын атап булыр иде. Мәсәлән, тагын берничә елдан без Казаныбызда дөньякүләм спорт ярышы – Универсиада үткәрергә җыенабыз. Моның өчен миллиардлаган сумнар сарыф итеп спорт корылмалары төзибез, шәһәребезне төзекләндерәбез. Болары бик яхшы. Әмма шул ук вакытта бюджеттан халык һөнәре сәнгатен үстерүне күздә тоткан 47 миллионлык программаны сызып ташлыйбыз. Универсиадага киләчәк дистәләгән мең туристка тагын шул түбәтәй белән чәкчәктән башка сувенир тәкъдим итә алмасак, алар безнең хакта нәрсә уйлар, Казаннан нәрсә тотып китәрләр икән?

Кризисның ачы җилләре мәгариф өлкәсен дә читләп үтмәгән. Мәсәлән, гамәлдәге бюджетта республика карамагындагы мәгариф объектларын капиталь ремонтлау өчен 47 миллион 846 мең сум акча каралган булса, бүген инде ул урында түм-түгәрәк ноль саны тора. Мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итү өчен бүленгән акча да 48 миллион 490 меңгә кимегән. Димәк, безнең укучыларның шактыена киләчәктә дәреслексез генә белем алырга яисә ике-өч кешегә бер китап тотып укырга туры киләчәк.

Фәнни эзләнүләргә, иҗат берлекләренә, фән, мәдәният, сәнгать һәм матбугат өлкәсендәге грантларга каралган болай да сәдака күләмендәге акчаның да шактый кимetelүен күргәч, мин кризисның чыннан да бик тирәнгә үтеп кергәнен аңлый башладым. Чөнки иң зур кризис – икътисади кризис түгел, ә рухи кризис, мәдәният, мәгариф, фән өлкәсендәге кризис. Чөнки күңеле төшкән, рухы сынган, өмете сүнгән кешенең кулыннан эш китә, ул яшәү өчен, матди байлыкларны ишәйтү өчен сәләтсез затка әверелә һәм матди кризистан чыга алмыйча тилмерә. Шуңа күрә дә безнең президентыбыз күңелләребезгә дәрт өстәү, өмет кабызу нияте белән һәрчак: «Без булдырабыз!» – дип оран сала. Чыннан да, без булдырабыз, булдыра алмаган кешене хәтта ир-егеткә дә санамыйбыз. Әнә бит, җиң сызганып тотынгач, бөтен авылларыбызны, шәһәрләребезне газлы иттек, тузган торaклардан котылу җаен таптык, Кама аша күпер дә салып куйдык, Кремль уртасында бөтен дөньяны шаккатырып, күз явын алырдай Кол Шәриф мәчетен торгыздык. Чыннан да, без булдырабыз! Бүгенге көндә Россиянең иң яхшы футбол командасы, иң яхшы хоккей командасы, иң яхшы волейбол командасы бездә – Татарстанда булуы һич кенә дә очраклы хәл түгел. Без бөтен Татарстан халкы белән бергә бу җиңүләр өчен куанабыз һәм киләчәктә шундый ук уңышлар һәм җиңүләр мәдәният, мәгариф һәм фән өлкәсендә дә булыр дигән өметтә калабыз, һәм бу хакта бер без генә түгел, ә бюджет проектын әзерләүчеләр дә уйлый торгандыр дип ышанам.

*2009*

# «КЕРЕМ»ЕҢНӘН АЛДА «ЧЫГЫМ»ЫҢНЫ УЙЛА

Яңа ел бюджетын кабул итү көннәрен без, Яңа елны көткән сабый балалар кебек, һәммәбез дә түземсезлек белән көтеп алабыз. Әйтерсең шушы көнне нинди дер могҗиза булыр, каяндыр бер тылсымчы килеп, Кыш бабай сыман, безгә бюджет капчыгыннан учлап-учлап бүләк өләшер шикелле. Быел да, әлеге могҗизага өметләнеп, инде ай буе комитет утырышлары үткәрдек, финанс һәм икътисад министрларын үзебезнең сорау-гозерләребез белән тинтерәтеп бетердек. Нишлисең бит, адәм баласы шулай яратылган: ул гомер буе яхшылыкка өметләнеп, иртәгесе көнем бүгенгесеннән матуррак булыр дип хыялланып яши. «Өметсез – шайтан» диләр бит безнең халыкта. Дөнья гел без теләгәнчә генә бармаса да, вакыт-вакыт өметләребез дә акланып куя. Әнә бит, ничә еллар хыялланганнан соң, ниһаять, әкият сарайларын хәтерләткән «Әкият» Курчак театры бинасы да төзелеп килә. К. Тинчурин театрының тарихи бинасына менә дигән итеп ремонт ясалды. Һәр кичне тамаша карарга килгән театр сөючеләрнең алкышлары сәнгать әһелләренә генә түгел, ә халыкка шушындый гүзәл залны бүләк иткән төзүчеләргә, җитәкчеләребезгә, депутатларга һәм «Татнефть» башлыкларына да рәхмәт булып яңгырый торгандыр. Русиянең бик күп төбәкләреннән аермалы буларак, бездә һәр ел саен яңа мәктәпләр, балалар бакчалары төзелеп тора, искеләренә авырлык белән булса да әкренләп ремонт ясала. Саный китсәң, эшләнгән эшләр шактый, күрә һәм саный белергә генә кирәк.
Әмма күңел һаман тынычланмый, һаман саен күбрәккә, яхшыракка өметләнә. Икътисади кризистан башыбыз чыкса, аягыбыз чыкмаган чорда, чүп өстенә чүмәлә булып, корылык кесәләрне корыткан заманда кемнәндер нәрсәдер таләп итү, бугаздан буып акча сорау бигүк дөрес тә түгелдер. Шуңа күрә безнең тәкъдимнәр һичшиксез киләсе елда башкарылырга тиешле таләпләр дип түгел, алда торган бурычлар итеп кабул кылынса иде.
Нинди генә зур эшләргә тотынсаң да, иң беренче чиратта акча кирәк, диләр. Әйе, акчасыз берни дә эшләп булмыйдыр. Әмма акчадан да элегрәк шушы эшне башкарып чыгу өчен зур теләк кирәк, омтылыш кирәк. Юкка гына «Иң әүвәл Сүз булган» дип әйтелмәгән бит Изге китапта. Теләк булса, катгый сүз – катгый карар булса, акчасы да, башкасы да табыла. Әнә бит, заманалар авыр дип тормаганнар, хәтта Бөек Ватан сугышы барган афәтле елларда Казанның иң мәһабәт бинасын – Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрын төзеп куйганнар. Бүген дә башкалабызда һәм башка шәһәрләребездә берсеннән-берсе затлырак биналар калкып чыга, метро төзелә, спорт сарайлары, кунакханәләр, банклар, рестораннар корыла. Барысы да әйбәт кебек, бары тик мәдәнияткә булган мөнәсәбәт кенә үзгәрми, элеккеге яманаты чыккан «остаточный принцип» бүген дә дәвам итә. Мәсәлән, бик күп милли республикаларның башкалаларыннан зуррак булган Чаллы шәһәренең дәүләт театры хәзергәчә бай кешенең мунчасы кадәрле бинада җан асрый, республикабызның иң хәлле шәһәре Түбән Кама дәүләт театры элеккеге кафе бинасында көн күреп ята, В. Качалов театрындагы ремонтның да очы-кырые күренми. Ә Милли китапханәгә яңа бина төзү мәсьәләсе инде бөтенләй тормышка ашмас хыялга әверелде бугай. Яңа бина төзү турында беренче хөкүмәт карары чыкканга озакламый 50 ел – ярты гасыр була. Аннан соң дүрт хөкүмәт карары, бер Югары Совет карары чыкты, иң югары дәрәҗәдә вәгъдәләр бирелде, конкурслар үткәрелде. Әмма берсенең дә нәтиҗәсе булмады. Шулай ук хөкүмәт карарлары кабул итеп тә, инде дистә елдан артык Түбән Камада – Муса Җәлилгә, Казанда Һади Такташка, Сара Садыйковага һәйкәл куя алмыйбыз. Дөрес, быел беренче президентыбызның дәрт һәм дәрманы белән борынгы тарихи һәйкәлләрне торгызу буенча моңа кадәр күрелмәгән күләмдә олы эшләр башланды. Киләчәктә шушы кодрәтне югалтмыйча, республикабыздагы башка тарихи һәйкәлләргә дә җан өрә алсак, Татарстаныбыз тагын да матураеп, үзебез өчен дә, кунакларыбыз өчен дә чын мәгънәсендә сокланып сөйләрлек дәрәҗәгә җитәр иде.
Киләсе елның апрелендә республикабызның һәм бөтен татар халкының горурлыгы булган бөек Тукаебыз тууга 125 ел тула. Тукай бәйрәменә Русия төбәкләреннән, бөтен төрки дөньядан, ерак чит илләрдән күпләп кунаклар килер. Ә Тукайның төп йорты булган Арча төбәге һәм Казан

шәһәре моңа әзерме соң? Габдулла Тукай үзенең иң мәшһүр әсәрләрен иҗат иткән «Болгар» номерлары кунакларны ни хәлдә каршы алыр? Казандагы, Арча, Кушлавычтагы шактый нык таушалган Тукай музейлары кунак каршыларлык хәлдә булырмы? Күптән түгел Тукай юбилеен үткәрү хакында хөкүмәт карары чыкты. Анда каралган 21, 9 миллион сум акча белән Тукай юбилеен тиешле дәрәҗәдә үткәрү мөмкин булырмы, әллә соң тагын итәк кисеп, җиң генә ялгарбызмы? Кияү егете туйда сынала, диләр бит. Безгә дә олуг юбилейны бөек Тукай дәрәҗәсендә үткәрергә, кунаклар алдында, халкыбыз алдында оятка калмаска иде.

Депутат буларак, кая гына очрашуга барсаң да, сүзне, гадәттә, хезмәт хакы турында сөйләүдән башлыйлар. Шуңа күрә бюджет проекты белән танышканда, мин иң элек әлеге мәсьәләгә кагылган маддәләрне, халыкның хезмәт хакын, тормыш дәрәҗәсен күтәрә торган урыннарны эзләдем. Киләсе елны мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру өчен бюджет проектына 2 миллиард сум чамасы акча тәгаенләнгәнен күргәч, сөенеп куйдым. Дөрес, хезмәт хакының уртача 16 процентка артуы гына укытучыларны балда-майда йөздерә алмаячак. Әмма, юрганыңа карап аягыңны суз, диләр бит. Монысы да алга китеш, фәкыйрь кешегә монысы да юаныч. Ходай кушып, киләчәктә мондый игелекле гамәлләр тагын да булыр дип өметләнергә генә кала. Шундый ук өстәмәләр мәдәният һәм матбугат хезмәткәрләренә, фән әһелләренә дә билгеләнсә, алар да үзләрен җәмгыятькә һәм дәүләткә кирәкле һәм кадерле кешеләр итеп тоя башлар иде. Хезмәт хакы дигәннән, иҗат әһелләренең хезмәт хакы бераз башкачарак, ятрак сүз белән – «гонорар» дип атала. Шулай ят сүз белән аталгангамы, соңгы елларда аңа булган мөнәсәбәт күзгә күренеп начарайды. Совет чорында роман-повестьлар язган атаклы әдипләребез, симфония-җырлар иҗат иткән мәшһүр композиторларыбыз гонорар хисабына гаиләләрен туендырган, тормыш алып барган булса, бүгенге көндә бу мөмкин түгел. Газета-журналларыбызның кайберләре хәзер бөтенләй гонорар түләми, түләгәннәренең әҗере исә «Бәхетле» кибетенә бер мәртәбә кереп чыгарга да җитми. Иҗат эше искиткеч катлаулы хезмәт, һәм иҗат әһелләрен бушка эшләтеп, яшәү белән үлем арасында тоту, беренчедән, гөнаһлы гамәл булса, икенчедән, ул безнең профессиональ сәнгатебезнең, әдәбиятыбызның киләчәген куркыныч астына куя. Татар халкы гомер-гомергә мәгърифәтле, китаплы халык булган. 1917 елгы революциягә кадәр генә дә татар телендә 15 меңнән артык исемдә 50 миллионнан артык данә китап бастырып чыгарылган. Димәк, без – ул чорда бөтен Русиядә урыслардан кала иң күп китап язган һәм китап бастырган халык. Тагын 2 елдан – 2012 елда – беренче татар китабы нәшер ителүгә 400 ел була. Ә мондый халыклар дөньяда бармак белән генә санарлык. Шуңа күрә дә соңгы елларда татар һәм урыс телләрендә китап бастыру өчен республика бюджетыннан бүленә торган акчаның бермә-бер киметелүен без берничек тә аңлый да, кешеләргә аңлата да алмыйбыз. Моны безгә электрон китаплар барлыкка килү белән исбатларга, акларга тырышалар. Ләкин инде дистә еллар элек электрон китапханәләр ачкан Көнбатыш илләрендә басма китап чыгару кимү түгел, киресенчә, арта гына бара. Алар фикеренчә, кампитр гадәти кәгазь китапны алыштыра алмый, фәкать аңа ярдәмгә килә, аны тулыландыра гына. «Пәри башка, җен башка» диләр бит халыкта.

Татарстан турында дөньяга хәбәрләр таратучы «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе үзенең географиясен отыры киңәйтә бара. Русия төбәкләрендә һәм төрле кыйтгаларда сибелеп яшәүче татар халкы өчен бүгенге көндә ул иң кирәкле һәм нәтиҗәле мәгълүмат чарасына әверелде дисәм, һич тә арттыру булмастыр. Әмма милләттәшләребез «ТЯГ» каналы аша Казан хәбәрләре белән бергә үз төбәкләрендәге яңалыкларны, үз тормышларын да күрәселәре килү турында безгә кат-кат мөрәҗәгать итә. Узган елларда Мәскәүдә, Екатеринбургта һәм Төмәндә «ТЯГ»ның корреспондент пунктлары ачылган иде. Әгәр без киләсе ел бюджетыннан тиешле күләмдә акча бүлеп биреп, миллионнан артык милләттәшебез яшәгән Башкортстанда һәм Оренбург өлкәсендә шундый ук корреспондент пунктлары ача алсак, Конституциябезнең читтәге татарларга ярдәм итү хакындагы 14 нче маддәсен гамәлгә ашыру юлында тагын бер адым алга атлар идек.

Безнең комитетның көндәлек эше мәгариф, фән, мәдәният, матбугат оешмалары – бюджеттан акча сораучы оешмалар белән бәйләнгән. Шуңа күрә дә мин бюджетның керем өлешенә тукталмыйча, нигездә, чыгым өлеше хакында гына сүз алып бардым. Әмма бу чыгымнар

киләчәктә республикабызның икътисади нигезен ныгытачак, рухи дөньясын баетачак, керемнәрен арттырачак чыгымнар. Мәдәнияткә, фәнгә, мәгарифкә бүген никадәр күбрәк игътибар итсәк, никадәр күбрәк акча бүлеп бирсәк, иртәгесе көнебезнең матуррак, мәгънәлерәк, мулрак булуына иманым камил. Бер мин генә түгел, халкыбызның, республикабызның киләчәк язмышын кайгырткан һәммә кеше, һәммә җитәкче, һәммә депутат шундый ук фикердәдер дип уйлыйм.

*2010*

# БИРСЕН ХОДАЙ!

Татар җәмәгатьчелеге элек-электән үзенең милли югары уку йортын булдыру хакында хыялланып яшәде. Әмма Россия монархиясе шартларында, әлбәттә, бу хыял тормышка аша алмады. Татар милли югары уку йортын оештыру юлында узган гасырның утызынчы елларында тагын бер омтылыш булып алды. Тик барча халыкларны бер «өлкән туган» тирәсенә укмаштыруга юл тоткан совет җәмгыяте шулай ук бу мәсьәләне хәл итәргә теләмәде.

Инде безнең чорда Татарстан Югары Советы «Телләр турында»гы Закон һәм аны тормышка ашыру буенча Дәүләт программасы кабул итте. Ул Программада Татар милли университеты ачу да каралган иде. Моннан берничә ел элек дөньяга килгән Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетын без әлеге карарны тормышка ашыру юлында хәлиткеч адым дип кабул иттек.

2005 елда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының концепция проекты, ике мәртәбә Татарстан Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан каралып, шактый ук кайнар бәхәсләрдән соң, үзгәрешләр кертелгәч, хуплау тапкан иде.

Хәзер инде бөтен татар җәмәгатьчелеге «Татар» исеме белән башланган бу бердәнбер университетның чын мәгънәсендә татар милли югары уку йорты вазифаларын үз өстенә алуын көтә. Безнең уебызча, бу университетта беренче чиратта чын татар тарихы, милли мәгариф, милли сәнгать һәм әдәбият, иҗтимагый фикер, әхлак, дин, хокук һәм дәүләт корылышы буенча фәнни эзләнүләр һәм шулар нигезендә уку-укыту эшләре башкарылырга тиеш. Бу университетта белем алып чыккан белгечләр татарлар тупланып яшәгән теләсә кайсы төбәктә татарча, русча һәм кимендә бер чит телдә эш алып бара алырга тиешләр. Бу университетта Татарстанның ике дәүләт телен һәм бер чит телне белгән яисә өйрәнергә теләгән теләсә кайсы милләт вәкиленә белем алырга мөмкинлек тудырылырга тиеш.

Бу хакта университетның 2015 елга кадәрге үсеш стратегиясе хакындагы саллы документта шактый тәфсилле язылган. Вертикаль көчәрнең шөрепләре көннән-көн тыгызлана барган чорда бу изге максатны, матур хыялны тормышка ашыру өчен университетның үз куәте генә җитмәячәге, монда республика җитәкчелегенең дә зур ярдәме кирәк булачагы көн кебек ачык.

Уважаемые участники заседания учёного совета!

Если сделать короткий экскурс в историю вопроса о национальном учебном заведении, то надо вспомнить, что в татарском обществе идея организации национального высшего учебного заведения возникла ещё в середине XIX века. Был проект у Хусаина Фаизханова об открытии высшего религиозно-светского учебного заведения в Казани в 1862 году. В 1881 году было обращение в правительство Исмаила Гаспринского об открытии 10 национальных высших учебных заведений в российских городах, в том числе в Казани. Не раз такие проекты и предложения составлялись и в начале XX века и в последующие годы. Но все эти инициативы так и не получили поддержку властей.

К реальному воплощению этой идеи мы подошли лишь сейчас, в начале XXI века. В связи с принятием Закона о языках и Государственной программы по его реализации у нас появилась возможность создания такого учебного заведения.

В Татарстане и в некоторых регионах России сохраняется необходимость в подготовке для сфер обслуживания специалистов, владеющих двумя государственными языками. Учитывая то, что до сих пор ни один проект закона в Татарстане не был написан на татарском языке за неимением квалифицированных татароязычных юристов, актуальным является языковая подготовка государственных служащих. Сегодня большая редкость, чтобы министр или иной крупный руководитель делали свои доклады или выступления на заседании правительства или сессии Госсовета на татарском языке, особенно по экономическим или финансовым вопросам. Государственный служащий без знания государственных языков, по-моему, нонсенс! По республиканскому и федеральному законам Президент Татарстана должен владеть двумя

государственными языками, а перед госслужащими почему-то такое требование не ставится... «Вертикальләр илендә» яшибез икән, монда да вертикаль булсын иде инде!

Подготовка как минимум двуязычных специалистов будет являться актуальной и в будущем. А как её реализовывать, когда университет в прямом федеральном подчинении? Эта проблема обсуждалась на заседании Совета безопасности Татарстана 31 марта 2008 года «О состоянии и первоочередных задачах высшего профессионального образования в РТ». В свою очередь в Комитете по культуре, науке, образованию и национальным вопросам Госсовета РТ совместно со специалистами Министерства образования и науки был подготовлен проект Федерального закона «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации в части наделения органов государственной власти субъекта Российской Федерации полномочиями в отношении высших учебных заведений, находящихся на территории этого субъекта». Смысл нашей законодательной инициативы, внесённой на днях в Государственную Думу Российской Федерации, сводится к расширению участия органов государственной власти субъектов не только в контроле и надзоре по соблюдению высшими учебными заведениями, расположенными на их территориях, лицензионных и аккредитационных требований, но и при определении контрольных цифр приёма граждан, обучающихся за счёт средств федерального бюджета, а также квот по целевому приёму в высшие учебные заведения.

Почему мы так настойчиво продвигаем идею изучения двух-трёх языков в нашей республике? Во-первых, знание государственных и других языков является для выпускников вашего университета и для других вузов, остающихся в своём большинстве в республике, конкурентным преимуществом. А впредь владение этими языками, несомненно, окажется полезным для желающих работать в соседних развивающихся тюркских государствах.

Во-вторых, знание языка, истории, обычаев, традиций народа, рядом с которым ты живёшь, способствует взаимопониманию и взаимоуважению между людьми разных национальностей. Всевышним человек создан таким: он может уважать только того человека, который с таким же уважением относится к нему. А знание языка, как я уже сказал, является ключом к взаимопониманию между людьми разных национальностей, стабильности в обществе.

Сезнең университетта Европа телләре белән бергә шәрык телләрен өйрәнүгә дә зур игътибар бирелергә тиеш. Әгәр Татарстан соңгы арада яңадан Россиянең шәрык илләре белән арадашчысы буларак активрак эшли башлаган икән, димәк, бу өлкәдәге белгечләр кытлыгын бетерү иң беренче чиратта Казан дәүләт университетына һәм сезнең университет җилкәсенә төшәргә тиештер.

Дөрес, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының төп максаты һич кенә дә телләр өйрәтү белән генә чикләнергә тиеш түгел. «Олы өйгә ни кирәк, кече өйгә шул кирәк» дигән шикелле, сезнең университет җәмгыятебезнең, республикабызның һәм халкыбызның рухи һәм матди, икътисади һәм сәяси, кыскасы, һәммә ихтыяҗларын канәгатьләндererлек белгечләр әзерләп чыгарырга тиеш.

Я думаю, «Стратегию развития ТГГПУ» необходимо утвердить. Но нельзя забывать, что это только первый шаг на трудном и тернистом пути. Бу әле зур эш башлар алдыннан укыла торган «юл догасы» гына.

Президентыбыз, хөкүмәтебез, Дәүләт Советыбыз ярдәм кулы сузып торганда, ә иң мөһиме, халкыбызда шундый университетка ихтыяҗ булганда, Сез үз алдыгызга куйган олы максатыгызга ирешерсез дип ышанам.

Моңа кадәр мин «Татар мәктәбен тәмамлап кем булып була?» дигән сорауга: «Татарстан президенты булып була!» – дип кистереп җавап бирә торган идем. Ә инде хәзер: «Татар гуманитар-педагогика университетын тәмамлап, киләчәктә кем булып була?» – дип сорасалар, «Россия президенты булып була», – дип җавап бирергә исәпләп торам.

Бирсен Ходай!

*2011*

# ЯҢА ПРОГРАММА КИРӘК

Телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү мөмкинлеге Татарстанда дәүләт дәрәҗәсендә, бөтен халык сайлаган парламент законы рәвешендә моннан 19 ел элек, 1992 елның 8 июлендә барлыкка килде. Бу законны тормышка ашыру юлларын күрсәткән Дәүләт программасы исә Татарстан Республикасы Югары Советы карары белән 1994 елның 20 июлендә кабул ителде. Татарстан Дәүләт Советы 2004 елның 24 июлендә әлеге Законга, шул елның 11 октябрендә Программага үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертте.

Современный Татарстан – это многонациональный и многоязычный регион Российской Федерации. В такой среде языковая ситуация характеризуется специфичностью положения языков народов Татарстана. Русский язык – это язык демографического большинства России. Его статус определён как государственный на всей территории России и в этом качестве он поддерживается федеральным центром. Что касается татарского языка, при практически одинаковой демографической мощности основных языков в республике, по своей коммуникативной роли он значительно уступает русскому.

«Телләр турында»гы Закон һәм Программа кабул ителгәннән соң үткән елларда республикабызда, өлешчә генә булса да аннан читтә дә, туган телебезне тормышыбызның төрле өлкәләрендә куллану, аңа көч-куәт бирү юлында байтак эшләр эшләнде. Әмма шунысын да әйтеп үтми булмый: без әле бүген ике дәүләт телен дә тормышыбызның бөтен өлкәләрендә дә тигез куллану, файдалану, өйрәнү һәм үстерү дәрәҗәсеннән бик ерак торабыз. Татар теле әле һаман гаилә, кухня, туган-тумача, дус-ишләр арасында аралашу чарасы гына булып калуын дәвам итә. Инде байтак гаиләләрдә, хәтта кайбер татар авылларында, татар мәктәпләрендә татар теле, бигрәк тә яшьләр арасында, үзара аралашу теле булудан да туктый бара.

Болары сүз уңаеннан гына әйтелгән, әмма әйтмичә калырга мөмкин булмаган мәсьәләләр генә.

Республиканское языковое законодательство было основано на принципах федерального законодательства о праве на сохранение и развитие родных языков, свободу выбора языка образования и закреплении на территории Российской Федерации государственного русского языка. Фактически в республике был создан основательный фундамент для укрепления и дальнейшего гармоничного развития государственных языков, который, к сожалению, так и не был скреплён подзаконными актами, направленными на наполнение языковых законов конкретным содержанием.

Следует признать, что этноязыковая стабильность может быть обеспечена лишь в том случае, если юридическое равноправие языков подкреплено их фактическим равенством. Именно в этой части у нас и сосредоточено наибольшее количество узловых вопросов.

Без әле һаман да Россия һәм Татарстан Конституцияләрендә, Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәдә һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башка телләр турында»гы Законда күрсәтелгән, Программада максат итеп куелган мөмкинлекләрне тормышка ашырырга, аларны көндәлек тормышыбызда, эшебездә һәрдаим файдаланырга өйрәнеп җитә алмыйбыз. Безнең күп кенә акыллы, үз эшенең остасы булган мөхтәрәм җитәкчеләребез, гуманитар булмаган төрле оешма, предприятие, учреждение башлыклары телләр язмышын кайгыртуны, «Телләр турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыруны мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре эше генә дип карыйлар. Әмма Закон һәм Программа белән якыннанрак танышкан һәр кеше анда телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү эшенең тормышыбыз, хезмәтебезнең бөтен өлкәләрендә һәр ватандашның төп бурычларыннан берсе икәнен күрер иде. Дөрес, телләр мәсьәләсе гуманитар өлкәдә эшләүче галимнәр, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләренә башкаларга караганда якынрактыр. Ләкин бу Закон промышленность, авыл хуҗалыгы, бигрәк тә турыдан-туры халыкка хезмәт күрсәтү өлкәләрендә эшләүче һәр кече һәм зур җитәкчегә дә турыдан-туры карый, канунны үтәүдә алардан да җаваплылык таләп итә. Татарстанның Административ җаваплылык турындагы кодексының 2 нче маддәсендә «Телләр турында»гы

Законны бозган өчен җитәкчеләргә төрле күләмдә штраф салу күздә тотылган. Кызганыч ки, бездә адым саен «Телләр турында»гы Законны бозу күренешләре булып тора, әмма мин әлегә кадәр республикабызда берәр җитәкчене җавапка тартканнарын хәтерләмим. Димәк, закон гына түгел, аны бозган өчен җавапка тарту чарасы булган Кодекс үзе дә тиешле дәрәҗәдә эшләми. Димәк, әле безнең ватандашларыбыз үзләренең тел өлкәсендәге хокукларын белми яисә, белеп тә, битарафлык күрсәтә.

Татарстан белән Россия арасындагы Шартнамәдә Татарстанның, Россия хөкүмәте белән бергәләп, Татарстаннан читтә яшәүче татар халкына үзенең милли мәдәниятен һәм туган телен саклауда һәм үстерүдә ярдәм итәргә тиешлеге әйтелә. Бу статьяны тормышка ашыру өчен читтәге милләттәшләребезгә ярдәм итү буенча федераль программа төзергә кирәк. Кызганыч, Федераль закон белән расланган Шартнамә гамәлгә керүгә шактый вакыт узса да, безнең әле һаман бу эшкә тотынганыбыз да юк. Ә Программасыз әлеге статья үзеннән-үзе беркайчан да эшләп китмәячәк.

Татарстанда ике дәүләт теленең тигез булырга тиешлеге үзебезнең президентыбыз эшчәнлегендә шактый ачык күренә. Россия белән Татарстан арасындагы әлеге Шартнамәдә Татарстан президентының ике дәүләт телен дә белүе бурыч итеп куелган. Президент эшчәнлеге безнең барыбызга да, бигрәк тә дәүләт органнарында эшләүче һәр җитәкчегә үрнәк булып тора. Шулай булгач, Татарстанның дәүләт органнарында эшләүче һәр җитәкче – югары урын биләп торамы ул, кечерәкнеме – Татарстан халкы белән ике дәүләт телендә дә аралаша алырга тиеш. Дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт телләрен белмәвен бүгенге көндә берничек тә аңлап та, аңлатып та, аклап та булмый. Татарча белмәгән килеш татар язучысы булып булмаган кебек, дәүләт телләрен белмичә дәүләт хезмәтенә алыну гайре табигый хәл саналырга тиеш. Дөрес, тел өйрәнү бер көнлек эш түгел, әмма без телләр турындагы Дәүләт программасының һәр пунктын мөмкин кадәр төгәлрәк һәм сыйфатлырак итеп тормышка ашыра барсак, акрынлап әлеге максатка якынаячакбыз.

Шәһәр һәм авылларыбыз урамнарын ике телдә бизәп, җыелыш-киңәшмәләрне ике дәүләт телендә алып барсак, кибетләр, рестораннар, акционерлык җәмгыятьләренең, шәхси оешмаларның исемнәрен ике телдә язып куйсак, шәһәрләрдә, авылларда, вокзалларда һәм транспорт чараларында игъланнарны ике телдә әйтсәк, халыкны кабул итә торган сырхауханә һәм хастаханәләрдә, даруханәләрдә, прокуратура һәм мәхкәмә оешмаларында, көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләрендә эшне ике дәүләт телендә тигез күләмдә оештырсак, без «Телләр турында»гы Законны тормышка ашыруда чын мәгънәсендә зур адым ясар идек.

Әлбәттә, теләсә нинди эшне башкару, тормышка ашыру өчен матди нигез кирәк. Шуны искә алып, дәүләтебез бюджетыннан «Телләр турында»гы Законны һәм Программаны тормышка ашыру өчен ел саен шактый күләмдә акча бүлеп бирелә. Дөрес, республикадагы һәр оешмага бүлә башлагач, әллә ни зур сумма килеп тә чыкмый торгандыр. Без һәр җирле үзидарә бюджеты да, республика бюджетыннан үрнәк алып, «Телләр турында»гы Законны һәм Программаны тормышка ашыру өчен үзеннән өлеш чыгарырга тиеш дип саныйбыз. Заманында бу мәсьәлә Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә хәл ителә башлаган иде. Ләкин соңгы елларда ул әкренләп юкка чыкты. Телләрне саклау һәм үстерү өлкәсендә аеруча зур эш күрсәткән активистлар хезмәтен бәяләп бару да бик әһәмиятле. «Телләр турында»гы Законда ике дәүләт телен дә үз эшендә куллана торган хезмәткәрләргә хезмәт хакының 15 проценты күләмендә өстәмә түләү каралган. Әмма бу түләүнең кемнәргә тиеш икәнлеге турында хөкүмәт әзерләгән һөнәр ияләре исемлеге һәм кагыйдәсе кирәк. Яңартылган Закон кабул ителүдән соң җиде ел вакыт узса да, алар әле һаман хөкүмәт коридорларыннан дөньяга чыга алмый тилмерә. Законда каралган әлеге күрсәтмәләр гамәлгә керсә, ике дәүләт телен дә тигез файдалану эше шактый яхшырыр иде. Беләм, бу – шактый четерекле мәсьәлә. Әмма хөкүмәт белән бергәләп без барыбер аның чишелешен табарбыз дип уйлыйм.

Единственной и безусловно важной областью, где плохо иль хорошо работает наш Закон и Программа, была и осталась лишь система общего образования. Но и в общеобразовательной школе мы не получили того эффекта на выходе, который ожидался, а ведь за эти 19 лет финансовые и трудовые средства потрачены немалые. Ситуация с татарским языком в нашей

школе очень схожа с ситуацией, которая у нас была всегда в рядовой советской школе с изучением иностранных языков. Вроде язык учили, начиная с пятого класса и до окончания школы, а результат был плачевный, единственно, что мы могли на этих языках – это лишь поздороваться и попрощаться.

Конечно, у нас есть серьёзные достижения, и главное – мы сформировали иное, чем было прежде отношение общества к необходимости изучения детьми в школе татарского языка как государственного наряду с русским языком. Да, мы многое сделали, но вопрос в другом, за эти почти 20 лет мы могли сделать многократно больше в деле достижения реального многоязычия.

Почему я говорю об этом особо? За последние 5 лет произошли кардинальные изменения в системе образования. В области общего образования введено ЕГЭ и его можно сдавать только на русском языке как итог среднего образования. В стране, в том числе и в Татарстане, идёт активный процесс оптимизации общеобразовательных учреждений. Этот процесс, ни для кого не секрет, ударил в первую очередь по нашим национальным школам в республике.

После принятия 309-го Федерального закона система национального образования лишилась учебно-методической базы: в учреждениях образования не могут применяться учебники, не утверждённые Министерством образования и науки Российской Федерации. Также методические пособия не могут использоваться в учебном процессе, если они не изданы в издательствах, допущенных Правительством РФ к изданию методических пособий. Пока ни одно издательство РТ не имеет такого права. Если учесть, что вся Россия пользовалась учебно-методическими пособиями РТ на татарском языке, то получается, что в России сегодня нет лигитимных учебников и методических пособий по татарскому языку и на татарском языке.

Кроме того, даже для вновь созданных учебников на татарском языке нет механизма получения грифа Министерства образования и науки РФ, так как рецензировать учебники могут только учреждения, допущенные Правительством РФ. К таковым относятся РАН и РАО, в которых нет специалистов, владеющих татарским языком.

Нам необходимо срочно на уровне Правительства Республики решить вопрос легитимности учебников по татарскому языку и на татарском языке, а также организовать систему рецензирования и издания учебной литературы на татарском языке на федеральном уровне.

Для повышения эффективности знаний по татарскому языку необходимо создать Центр тестирования по государственным языкам РТ, подобно Центру тестирования РФ по русскому языку, который будет заниматься разработкой тестов по различным уровням знаний татарского языка, проведением итоговой государственной аттестации в учреждениях образования и выдачей государственного сертификата о владении татарским языком на том или ином уровне всем желающим гражданам.

Республикадагы һәм Россиядәге телләр сәясәте көннән-көн катлауланып, хәл итәсе мәсьәләләребез бермә-бер арта барса да, нишләптер хөкүмәттәге телләр проблемасы белән шөгыльләнүче бүлек бетерелеп, шушы гаҗәеп зур проблема бер-ике хезмәткәр җилкәсенә генә өелеп калды. Бу эшнең никадәр җаваплы һәм катлаулы булуын искә алып, хөрмәтле премьер-министр, хөкүмәтебез әлеге бүлекне яңадан гамәлгә куярга тиеш дип саныйбыз. Россиянең күпчелек милли республикаларында мондый бүлекләр генә түгел, ә милли мәсьәлә белән шөгыльләнүче махсус министрлыклар да эшләп килүен без күпмилләтле илдә максатка ярашлы сәясәт дип уйлыйбыз.

Телләр язмышы хакында бер без генә түгел, туган халкы, туган теле турында кайгырткан һәммә иманлы кеше, һәммә җитәкче борчыла һәм уйлана торгандыр. Әмма борчылу гына җитми, безгә бүген конкрет гамәлләр кылырга вакыт. Мәсәлән, «Телләр турында» Законны тормышка ашыру буенча төзелергә тиешле Республика Дәүләт Советының закон кабул иткәннән соң дүрт ел узгач кына гамәлгә керүенә без Мәскәүне гаепли алмыйбыз. Ә эшләргә мөмкин булып та, үзебезнең битарафлыгыбыз һәм милли маңкортлыгыбыз аркасында кулыбыз җитмәгән, күңелебез ятмаган мондый мәсьәләләрнең бездә иге-чиге юк. Мәсәлән, Россия Югары мәхкәмәсе татарларга латин язуын файдалануны тыйганнан соң, безнең галимнәребез әлеге имляны фәнни максатларда һәм Интернетта файдалану мәсьәләсен күтәреп чыкканнар иде. Чөнки бүгенге көндә кириллицага

нигезләнгән татар әлифбасын Интернет системасы тулаем кабул итми яисә ул артык мәшәкатьләр тудыра, димәк, дөньяда сибелеп яшәгән татарлар үз туган телләрендә Интернет аша җиңел генә аралаша алмыйлар. Безнең галимнәребез фәнни максатлар өчен латин имлясындагы махсус татар әлифбасы тәкъдим итәләр. Безнеңчә, бу – мөмкин нәрсә, сүз монда телне дәүләт статусында файдалану хакында бармый, димәк, ул Россия Законына да каршы килми. Дәүләт Советында без ул Законның проектын да эшләдек, әмма бу мәсьәләдә әлегә прокуратура белән уртак тел таба алмыйбыз.
Ә Татарстан һәм татар халкы башкаласы булган Казандагы берәр ресторанда ялгышып кына булса да аш һәм ризык исемнәре татарча язылган меню күргәнегез бармы сезнең? Шәһәрләребездәге супермаркетларның, рестораннарның күбесенә импортный исемнәр кушылуны ничек аңлатырга? Республикабызда эшләнә торган товарларда да татарча язулар көннән-көн кими бара. Монысына кем гаепле? Мәскәүме? Әллә үзебезме?
Оят булса да әйтим инде, бүгенге көнгә кадәр безнең республикада бер генә закон да дәүләт теле саналган татар телендә язылмады. Юристлар һәм белгечләр моны татарча сәяси терминнарның камил булмавы белән аңлаталар. Шуңа күрә без Телләр Советында терминология комиссиясе дә оештырылырга тиеш дип саныйбыз.
Чыгышымда мин күбрәк Законны һәм Дәүләт программасын гамәлгә ашырганда килеп чыккан проблемалар, эшләнеп бетмәгән эшләр турында сөйләдем. Ирешкән уңышларыбыз шактый булса да, алар белән мактанып, горурланып утырырга иртәрәк, чөнки эшләнәсе эшләребез эшләнгәннәренә караганда күп мәртәбә артыграк. «Телләр турында»гы Законда Дәүләт программасын хөкүмәт эшләп, Дәүләт Советында кабул итү каралган. Гамәлдәге Программабызның унъеллык вакыты ахырына якынлашып килә, димәк, яңасын эшләргә вакыт җитте дигән сүз. Хөкүмәт, эшче төркем оештырып, озакламый бу мөһим эшкә тотыныр дип өметләнәбез. Яңа Программаның нигезенә республикабызда яшәүче һәр халыкның туган телгә булган конституцион хокукларын һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерү салынырга тиеш. «Телләр турында»гы Законны гамәлгә ашыруның һәрдаим эшләүче механизмын һәм аны контрольдә тоту чараларын, җитәрлек дәрәҗәдә финанслау мөмкинлекләрен булдырмый торып, бу максатка ирешү дә мөмкин булмаячак.
Ә без, үз чиратыбызда элекке кимчелекләребезне һәм бүгенге таләпләрне искә алып, галимнәр, тел белгечләре, хөкүмәт әһелләре һәм депутатлар белән бергәләп, заманыбызга яраклы Программа төзү эшенә үз өлешебезне кертербез дип ышанам.

*2011*

# АЛТЫН ТӘХЕТ МИНЕМ БӘХЕТ ТҮГЕЛ...

**– Быел сезнең китапханәгә 125 яшь тулды. Ләкин сүзебезне бәйрәм фанфаралары, котлаулардан түгел, ә китапханәнең бүгенге хәленнән башлыйк әле. Бу турыда газеталар, радио-телевидение аша еш ишетергә туры килә. Эшләр бүген ничек тора соң?**

– Унҗиденче, унсигезенче, унтугызынчы гасырларда һәм егерменче гасырның алтмышынчы елларына кадәр басылган миллионнан артык китап һаман элеккечә идәннән түшәмгә кадәр эскертләп өелгән килеш ята бирә. Республикабызда бердәнбер нөсхәдә генә булган иң кадерле китапларыбыз чери, бозыла, һәммәбезнең күз алдында юкка чыга. Март аенда безнең коллектив бер айлык экономик забастовка үткәрде. Ләкин аның бары тик караучысыз калган карт-корыларга һәм инвалидларга гына файдасы тиде бугай... Чөнки без ай буе эшләп тә протест йөзеннән алудан баш тарткан 2000 сумнан артык хезмәт хакыбызны Зеленодольскидагы караучысыз калган картлар һәм инвалидлар йортына күчердек. Ә китапханәчеләр югыйсә һич тә бай түгел, аларның уртача эш хакы нибарысы... 96 сум тәшкил итә. Забастовканы без Татарстан Министрлар Советының ВЛКСМ өлкә комитеты бинасын китапханәгә бирү турындагы карары чыккач туктаттык. Ә ул чираттагы алдау, кәгазьдәге буш вәгъдә генә булган икән. Гомумән, андый «югары карарлар»ның сиксән процентка якыны кәгазьдә генә кала, диләр... Хөкүмәт вәгъдә бирә – без ышанабыз, вакытлыча тынычланабыз, тагын вәгъдә бирә – тагын тынычланабыз. Менә инде 73 ел буе шулай өметләнеп һәм тынычланып яшибез. Мин хөкүмәтнең хәлен дә аңлыйм: күпме генә зурдан кубып сөйләсәк тә, аның әле һаман реаль властька ирешә алганы юк. Бөтен нәрсә белән әле дә партия (кайсы партия икәнен беләсез) җитәкчелек итә. Дөрес, ул элеккечә турыдан-туры әмер бирми, ә астан, башкарма комитетлар, хуҗалык җитәкчеләре, советлар аша үз политикасын алып бара. Чөнки әле һаман төп җитәкче урыннарын партия үз кулыннан ычкындырырга җыенмый. Димәк, безнең китапханә проблемасының ничә еллар буена хәл ителмәвен партия органнарының аңа битараф булуы белән генә аңлатырга мөмкин. Карл Маркс урамындагы яртылаш бушаган йортка без инде 800 мең китап күчердек. Ә бинаның өченче катын биләгән төрле оешмаларның аннан китәргә һич тә исәбе юк. Әгәр саксызлык белән янгын чыгып, бәла-каза була калса? Мисал өчен ерак йөрисе юк, республикабызның Дәүләт музее нәкъ менә шундый күршеләр аркасында харап булды бит...

**– Моннан ике ел элек Ленин китапханәсенә яңа бина салу турында ниндидер карар чыккан иде. Хәзер бу карарны китапханәчеләрдән башка берәү дә искә алмый сыман. Кабул иттеләр дә... тагын оныттылармы?**

– Бу инде китапханә төзү турында республикабызның югары органы кабул иткән өченче карар, алдагы икесе 60 нчы елларда дөнья күргән иде. Теге икесен техник проект эшләнгәч туктаткан булсалар, монысы әле һаман төрле кабинетларда адашып йөри. Проектчылар кайчан да булса Казанда китапханә төзелүенә ышанмый да башладылар инде. Алар да хаклы, чөнки 1552 елда Иван Грозный Казанны алганнан бирле, безнең шәһәрдә китапханә өчен махсус бина төзелмәгән. 438 ел элек Сөембикә ханбикә китапханәсе юкка чыгарылганнан бирле, безнең үз милли китапханәбез юк. Күрше Башкортстан, Мари республикалары менә дигән китап сарайлары салып куйды... Ә без һаман, туган җиребезне мазутка чумдырып, нефть чыгарабыз, бабаларыбыз күмелгән каберләрне күчереп, КамАЗлар, ТатАЭСлар корабыз. Нигә болай соң бу? Моның сәбәбен мин җитәкчеләребезнең интеллектуаль, мәдәни дәрәҗәсе түбән булуы, чын милли аңлы лидерларыбыз җитешмәве белән генә аңлата алам. Уйлап карагыз әле: сан ягыннан илдә җиденче урында торучы җиде миллионлы татар халкыннан Политбюро, ил хөкүмәтендә, һич югында, Россия хөкүмәтендә берәр вәкил бармы? Җитәкчеләребезнең күбесе халкыбызның чын тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен белми, ә китапка, бигрәк тә халык хәтерен саклаучы борынгы китапларга, аларның бөтенләй исләре китми...

**– Сез бит хәзер үзегез дә ил агасы – депутат, шуның өстенә «Туган як» җәмгыяте җитәкчеләренең берсе...**

– Спортта «һәвәскәр» һәм «профессиональ» дигән төшенчәләр бар. Безнең ил, белгәнегезчә, һәрчак һәвәскәрләрне алга сөреп, яклап килде. Баксаң, спортта гына түгел, башка бик күп өлкәләрдә, шул рәттән мәдәнияттә дә без бөтен эшне һәвәскәрлеккә корганбыз икән. Әле бүген дә мәдәният буенча Дәүләт программабыз, мәдәният турында Законыбыз юк, әле һаман халыкның рухи ихтыяҗлары өчен акчаны тиенләп кенә бирәләр... Ни чарадан бичара дигәндәй, халкыбызның рухи һәм мәдәни байлыкларын саклап калу нияте белән, соңгы арада төрле җәмгыятьләр оеша башлады. Сез әйткән «Туган як» җәмгыяте шуларның берсе. Җәмгыять оешкан көннән башлап без Киров урамындагы Печән базары мәчетен торгызу эшенә алындык. Анда кереп оялаган квартирантларны, контораларны чыгару өчен шактый иза чигәргә туры килде. Бу игелекле эштә Мәдәният министрлыгы, спонсор-предприятиеләр, аерым кешеләр дә катнашты. Илгиз Ханов җитәкчелегендәге «Яңару» кооперативы егетләре дә бик маһир реставраторлар булып чыкты. Бергәләп тотынсаң, күңел биреп эшләсәң, бүгенге шартларда да шактый нәрсәләрне җимереп кенә түгел, ә торгызып та була икән. Казанның баш мәчете 60 ел буе манарасы киселгән килеш торды. Ә менә бүген... Тукай шигырьләренә кергән, заманында татар халкының рухи үзәге ролен үтәгән Печән базары мәчете күккә ашкан манарасы, алтын айлары белән шәһәребезгә ямь биреп тора.

**– Ремонтка тотыну өчен сезгә мәчет бинасыннан төрле төзелеш конторaларын чыгарып, аны китапханә бинасына алырга туры килде. Ә төзәтеп бетергәч, анда нәрсә эшләргә җыенасыз?**

– Гомер-гомергә кешеләр мәчеткә, гыйбадәт кылу белән бергә, аң-белем алырга, бер-берсе белән очрашырга, аралашырга, дөнья хәлләрен уртаклашырга йөргәннәр, Печән базары хозурларында хәтта сәүдә эшләре белән дә шөгыльләнгәннәр, һәр мәчеттә уку йорты – мәдрәсә, китапханә булган. Соңгы елларда ачылган мәчетләрнең күбесе бу вазифаларның һәммәсен дә башкара алмыйлар. Шуны истә тотып, без Печән базары мәчетендә татар мәдәнияте, милли гореф-гадәтләр үзәге оештырырга ниятлибез. Иң беренче эш итеп без үзебезнең китапханәдәге дини китапларны, гарәп һәм латин хәрефләре белән нәшер ителгән басмаларыбызны монда күчерергә уйлыйбыз. Бинаның беренче катында гарәп, фарсы, төрек теле өйрәнү курслары, иске татар язуын өйрәнү түгәрәге ачарга җыенабыз. Моның өчен бездә җитәрлек дәрәҗәдә дәреслекләр һәм әзерлекле белгечләр дә бар. Ә икенче каттагы зур залда дин әһелләре һәм читтә яшәүче милләттәшләребез белән очрашулар, мөнәҗәт, бәет кичәләре уздырылачак, җомга вәгазьләре укылачак. Шунда ук, япон видеомагнитофоны куеп, халкыбызның онытылып барган гореф-гадәтләре, йолалары турында документаль видеофильмнар күрсәтәчәкбез, аңа комментарийлар бирәчәкбез. Дин әһелләре, аксакаллар һәм галимнәребез безгә бу эштә ярдәм кулын сузарлар дип ышанабыз. Югыйсә хәзерге яшьләрнең күбесе исем кушу, сөннәткә утырту, кыз ярәшү, килен төшерү, кешене соңгы юлга озату, өчесен, җидесен, кырыгын уздыру турында да рәтләп белмиләр. (Әле шушы арада гына бер йортта мәетне башы беләнме, әллә аягы беләнме озату турында бәхәс чыкканын сөйләделәр.) Мәчет булгач, теләгән кешегә анда намаз укып, дога кылып китәргә дә, һичшиксез, урын табылыр.

**– Сез – икеләтә депутат – Татарстанның Югары Советына һәм Казан шәһәр Советына сайланган кеше. Ике ел элек тә, быел да сайлаучылар алдында бер үк программа белән чыгыш ясаган идегез. Ул планнар тормышка ашар микән?**

– Моннан ике ел элек мин ил кереп чумган сәяси һәм икътисади кризистан чыгу, кешегә кеше булып калу өчен иң беренче чиратта рухи байлыкларны саклау һәм ишәйтү, иман яңарту һәм күңел хөрлеген кайтару кирәклеге турында чаң суга башлаган идем. Ләкин кайберәүләргә минем бу программам артык хыялый булып тоелды, ахрысы... Сайлаучыларга иң элек ит, колбаса, фатир вәгъдә итми торып, синең гомердә дә депутат буласың юк, диделәр. Нәкъ шул ук программа белән рәттән ике советка сайландым. Сайлау марафоны бик җиңел булды дип әйтмим, әмма, иң мөһиме, сайлаучылар белән без уртак тел таптык, уртак максатлар ачыкладык. Хәзер инде минем төп бурычым – шул максатларны тормышка ашыру...

**– Әңгәмә башында Сез КПСС хакында шактый усал сүзләр әйттегез. Моны конкрет бер мәсьәлә аркасында килеп чыккан үпкә дип кенә карарга-мы, әллә бу Сезнең партиягә**

**принципиаль бәягезме? Бәяне төрлечә биреп була: әле күптән түгел Сезнең бер төркем каләмдәшләрегез – татар язучылары – КПСС сафларыннан чыкты...**

– Заманында мин партия программасын шигырь укыган сыман рухланып укыган, аның идеалларына мөкиббән киткән идем... Сәяси дәресләрне миңа бик иртә, балачак елларыннан ук ала башларга туры килде. Әнкәй бөтен күңеле белән Аллага ышана, бисмилласыз бер эш тә башламый, ә әткәй исә коммунистларның да иң «кызылы», колхоз рәисе иде... Яшәвен бик тату яшәсәләр дә, һәр кичне икесе арасында бәхәс чыкмыйча калмый иде. Сүзләре Алла, дин, иман, коммунизм турында... Мин, Такташ китабыннан башны күтәреп, боларны тыңлыйм. Әткәй үзенең һәр сүзенә инанып, Ленин, Маркс сүзләрен кыстырып, өстәнрәк торып сөйли. Аның сүзләрен иртә-кич радио, газеталар да куәтләп тора. Ә әнкәй тыныч, сабыр, басынкы гына үзенекен кабатлый. Мисалларны ул күбрәк тарихтан, үткән тормыштан, риваятьләрдән, Коръән сүзләреннән, хәдисләрдән китерә. Күпме сөйләшсәләр дә, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнен ачыклау, бу бәхәскә нокта кую мөмкин түгел иде. Менә көннәрдән бер көнне «Коммунизм төзүченең мораль кодексы» басылып чыкты. Безгә аны дәрескә ятлап килергә кушканнар иде. Мин кычкыра-кычкыра ятлыйм, әнкәй эшеннән бүленеп тыңлый. Әткәйне ул, әлеге кодексны кулына тотып, елмаеп каршы алды. «Минем белән бәхәсләшкән буласың, менә, кара, коммунистлар китабына Хрущёв бабаң Коръәнне күчереп баскан», – дигәч, әткәй аптырап карап калды. Шул көннән башлап әткәй бу мәсьәләдә бәхәскә керүне бик үк өнәми торган булды. Такташ әйтмешли, безнең һәммәбездә әле хәзер дә «ике мин» яши. Мәсәлән, моннан дистә ел элек шул «мин»нең берсе – коммунист әткәй яклысы – мине КПСС сафларына алып килде. Ә диндар әнкәйнең догалары, изге теләкле бисмилласы, нинди эшкә тотынсам да, колагымда яңгырап торды. Туган авылым Ташлыктагы (Түбән Кама төбәге) җимерек мәчет манарасын торгызырга Казаннан реставратор егетләр ияртеп кайткач, әнкәйнең күзләреннән яшьләр чыкты. Ул күз яшьләренең ачысын соңрак миңа татырга туры килде. Райкомга да, обкомга да чакырып, «мәчет төзүче коммунистның КПСС сафларында торырга лаекмы-юкмы икәнлеге хакында» торгынлык елы комиссарлары каттый гаепләр яктылар, хәтта эштән азат итү белән дә янадылар... Ул елларда минем бердәнбер таянычым авыл халкының рәхмәтле сүзләре һәм изге теләкләре булды. Илне бөлгенлеккә төшергән КПССка ышанучылар, аның линиясен яклаучылар саны көннән-көн кими бара. Ләкин безгә, «дошманнарны юкка чыгарып, сарайларны җимереп» революция ясарга өйрәнгән халыкка, бу кризистан корбансыз чыгу юлын эзләргә кирәк. Моның өчен беренче чиратта «партия сарайларын» халык файдасына – хастаханәләргә, мәгариф һәм мәдәният оешмаларына, балаларга бирергә кирәк. Башка республикалар һәм өлкәләрдә бу юнәлештә эш башланса да, безнең партия җитәкчеләребез әле ашыгырга уйламый. Минемчә, партиядән чыккан һәр кеше аннан үзенең өлешен (түләгән взносларын да кертеп) таләп итәргә хаклы. Ә инде КПСС берничә партиягә таркалса, аның мөлкәте дә җан башына тигез итеп бүленергә тиеш.

**– Сез һәрвакыт дәүләт, җәмәгать һәм башка оештыру эшләре белән мәшгуль. Иҗат белән шөгыльләнергә кайчан вакыт табасыз? Инде дистәдән артык шигырь һәм проза китапларыгыз басылып чыккан, театрда пьесагыз гөрләп бара, җырларыгыз җырлана... Язган кадәрегез дә бер әдип гомере өчен җитәрлек түгелме?**

– Минем гомер әле яңа башлана гына бит... Нигә, дисезме? Күптән түгел миңа бик каты авыру кичерергә, ике мәртәбә пычак астына ятарга, үлем белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Табибларның шифалы кулымы, әнкәйнең догаларымы ярдәм итте, – исән калдым. Хәзер менә үземне яңадан туган кебек хис итәм. Инде киләчәктә элеккеге хаталарны кабатламаска, дусны дошманнан аера белергә, иманга хилафлык китермичә иҗат итәргә, көчне кызганмыйча эшләргә, көрәшеп яшәргә иде! Ә булганга канәгатьләнеп яисә урынга менгән һәрбер башлык алдында койрык болгап, президиумда яисә эш башында утыруны иң зур бәхет санап яшәүчеләрдән көнләшмим. Мин, абына-сөртенә, ялгыша-ялгыша булса да, үз юлым белән барырга тырышырмын. Кем әйтмешли, алтын тәхет минем бәхет түгел, алтын тәхет – шагыйрь ләхете...

*Әңгәмәдәш Әхәт Мушинский*
*1990*

# ЗАКОННАР ИКЕ ТЕЛДӘ
# КАБУЛ ИТЕЛЕРГӘ ТИЕШ...

**– Разил әфәнде, гадәттә, сессияләрдә законнар яки карарлар кабул иткәндә кыенлыклар килеп чыкса, проектны Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенә җибәрергә тәкъдим итәләр. Аны ничектер килештерү комиссиясе буларак күз алдында тоталар, күрәсең. Әллә комиссия, чыннан да, шундый максатны үтәргә тиешме?**

– Безнең комиссиянең беренче чиратта нинди юнәлештә эшләргә тиешлеге аның исеменнән үк күренеп тора. Әлбәттә, сез биргән сорауда да хаклык бар. Комиссия күпмедер дәрәҗәдә килештерү вазифасын үти, ләкин йөз процентка түгел. Әйтик, парламент авыл хуҗалыгы, промышленность, сәүдәгә кагылышлы законнар әзерли ди. Алар, нигездә, шушы юнәлештәге комиссияләр тарафыннан эшләнә. Әмма бу очракта гражданлык, дәүләт статусы, демографик сәясәт, мәгариф, милли мәсьәләләрне читләтеп үтеп булмый бит. Алар авылга да, шәһәргә дә кагыла. Димәк, безнең комиссия читтә кала алмый. Без бәхәсле мәсьәләләрне вакытында карап, тикшереп, уртак фикергә килә алабыз. Шунлыктан күпчелек очракларда килештерү комиссиясен төзүнең кирәге юк. 19 кешедән торган безнең комиссия составында халык хуҗалыгының төрле тармагында эшләүчеләр бар: завод директоры, авыл бригадиры, шофёр, район администрациясе башлыклары, югары уку йортлары укытучылары... Алар – төрле милләт вәкилләре.

Милли мәсьәлә – зур мәсьәлә. Теләсә кайсы проблемада бар ул. Менә сәүдәне генә алып карагыз. Әйтик, сатучы төрле яшьтәге, төрле милләт кешеләренә хезмәт күрсәтә. Аның шушы төбәктә күпчелекне тәшкил иткән халыкларның телендә сөйләшүе зарур. Димәк, дәүләтнең ике телен дә белергә кирәк. Этикеткаларның моңарчы бары урыс телендә генә язылуы белән дә килешеп булмый. Кибетләрнең бизәлешендә халыкның гореф-гадәтләре, традицияләре, бу төбәкнең үзенчәлекләре чагылыш табарга, шул ук вакытта кечкенә генә плакат та, рәсем дә зур зәвык белән эшләнергә тиеш. Миңа шушы көннәрдә ислам динен тотучы мөселманнарны кабул итәргә туры килде. Алар: «Нигә безнең ашханәләрдә барлык азыклар диярлек дуңгыз итеннән әзерләнә? Безгә шәригать буенча аны ашарга ярамый бит», – диделәр. Бүген тормышыбыз авыр. Җәмәгать туклануы өлкәсендә эшләүчеләргә ашамлыклар табу, аш-суны төрләндерү җиңел түгел, билгеле. Шулай да дин тотучылар теләгәнчә, һәр районга берәрне генә булса да, татар ашханәләре ачарга мөмкин бит.

**– Татар теле дәүләт теле дип игълан ителде. Ә шулай да Югары Совет законнарны һаман урыс телендә генә кабул итә...**

– Чыннан да, әлегә Югары Советта законнар урыс телендә кабул ителә. Законның татарчага тәрҗемәсе закон буларак кулланыла алмый. Чөнки аны Югары Совет расламаган бит. Киләчәктә законнар бер үк вакытта ике телдә дә кабул ителергә тиеш. Тик шул чагында гына татарча закон законлы була. Мөгаен, мондый тәртип «Телләр турында»гы Законны кабул итүдән башланыр. Әлбәттә, моның өчен алдан ныклы әзерлек кирәк. Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссия каршында татар теле буенча экспертлар булырга тиеш. Алар тарафыннан законнарның һәр сүзе ныклап уйланылыр, проект алдан ук ике телдә әзерләнер. Татарча белгән депутатлар татарча вариантка өстәмә кертерләр. Әгәр законнар ике телдә кабул ителсә генә, татар теле урыс теле белән тигез хокук алыр.

**– Сез телләр турындагы закон проектын искә алдыгыз. Белүемчә, хәзер ул Югары Советның даими комиссияләрендә тикшерелә, Сезнең комиссия аны карадымы? Шәхсән үзегез аны ничек бәялисез?**

– Без бу проектны комиссиядә тикшердек. Ул уйланып, әйбәт эшләнгән. Шулай да без аны шактый конкретлаштырдык. Мәсәлән, проектның 15 нче статьясында «Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт органнарында, оешмаларда, предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә эш кәгазьләре хезмәт коллективы карары белән татар яки урыс телләрендә алып барыла» диелә.

Ни өчен бу мәсьәләне коллектив хәл итәргә тиеш? Ә нигә ул Югары Совет карарын юкка чыгара? Республикабызда татар һәм урыс телләре 1990 елгы Декларациядә үк дәүләт телләре дип игълан ителде. Декларациягә ревизия ясарга берәүнең дә хакы юк. Һәркем үзе өчен уңайлы телдә гариза язсын, чыгыш ясасын.

**– Рәис итеп сайлаганда Сез бу комиссиянең эшен тулысынча күз алдына китерә идегезме?**

– Юк, билгеле. Мин мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясендә эшнең катлаулы икәнен белә идем. Әмма башкарасы эшнең бик күп булуына бары тик шушы урындыкка килеп утыргач кына төшендем. Закон проектлары эшләү процессында көн дә катнашырга туры килә. Чөнки законнар чыгару – Югары Советның төп эше.

Ләкин хәзергә халык белән эшләү бик күп вакытны ала. Районнардан кеше күп килә, чит төбәкләрдә яшәүче татарлар үз мәнфәгатьләрен кайгыртуны сорыйлар, таләп итәләр. Шулай да кешеләр беренче чиратта бирегә килергә тиеш түгел дип саныйм. Әйтик, мәктәпкә кагылышлы мәсьәләләрне район мәгариф бүлекләре, район башлыклары, министрлык хәл итәргә тиеш. Клуб икән – авыл Советлары, район мәдәният бүлеге, Мәдәният министрлыгы бар. Мин аңлыйм: кайберәүләр урындагы җитәкчеләрдән өмет өзгәннәр, күп очракта аларның бүлмәләренә керә дә алмыйлар. Ә безгә моннан торып әмер бирергә кала. Район җитәкчеләре исә: «Ул безгә кермәде, хәл итә идек», – диләр.

**– Комиссиянең эше, әлбәттә, аз түгел. Шулай да Сез беренче чиратта нинди мәсьәләләрне хәл итәргә җыенасыз?**

– Бүгенге көндә иң кирәклесе, иң катлаулысы – «Телләр турында» Закон. Ул киләчәктә милли киеренкелекне тудырмаслык итеп эшләнергә тиеш. Аның һәр өтеренә кадәр ныклап уйларга кирәк. Аннары – «Гражданлык турында» Закон, «Мәдәният турында» Закон. Алары да эшләнеп ята.

Киләчәктә архитектура, демографик сәясәт турындагы законнар кирәк. Аларны кабул итүне сузарга безнең хакыбыз юк.

**– Ә практик чараларга килгәндә...**

– Җәй көне Бөтендөнья татарларының конгрессын үткәрәчәкбез. Билгеле, аны әзерләүдә Министрлар Кабинеты, Президент Аппараты, күп кенә башка оешмалар да катнаша. Ә безнең комиссия координатор ролен үтәргә тиеш.

23 апрельдә милли хәрәкәт вәкилләренең киңәшмәсен уздырабыз. Аларның барысы да суверенлыкны ныгыту юнәлешендә эшләргә бурычлылар. Башкача аларны халык якламаячак. Чөнки референдумда халык үз сүзен әйтте. Хәзер аңа ревизия ясарга омтылу акылсызлык.

Башка төбәкләрдә яшәүче татарларның ихтыяҗларын урынга барып өйрәнеп, аларда эшләп килүче иҗтимагый оешмалар белән танышып, милләттәшләребезнең мәнфәгатьләрен кайгырту буенча элеккеге союздаш республикалар, шулай ук Башкортстан белән килешүләр төзергә кирәк булачак. Хәзер Декларация белән генә яшәп булмый, конкрет эш кирәк.

Татар теле – дәүләт теле, дибез. Ә күп кенә депутатларыбыз татарча белми. Аларга татар теле укыту да көн тәртибендә тора. Теләк белдерүчеләр бүген аз түгел.

Комиссия алдында торган тагын бер зур мәсьәлә бар. Ул – әдәбият, сәнгать, мәдәният хезмәткәрләренең тормыш-көнкүреше турында кайгырту. Аларның бүгенге хәле мөшкел. Музыка мәктәпләрен, китап кибетләрен, китапханәләрне югалтмаска иде. Талантлы яшьләрне сакларга, аларга ярдәм итәргә, киләчәктә милли мәдәният-сәнгать өзеклеген булдырмаска иде. Бүген талантлы композиторларыбыз, рәссамнарыбыз эшсез ята. Аларның әсәрләрен сатып алучы юк.

**– Разил әфәнде, иртәгә эш көнегезне ничек үткәрергә җыенасыз?**

– Иртәгә мин Украинага китәм. Анда Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә керүче илләр Югары Советларының милли мәсьәләләр буенча даими комиссияләре рәисләре җыела. Очрашуда милләтара мөнәсәбәтләр, тел мәсьәләләренә кагылышлы зур сөйләшү булачак.

**– Сезгә уңышлар телибез.**

– Рәхмәт.

*Әңгәмәдәш Әгъзам Фәйзрахманов*
*1992*

# МӨҺАҖИРЛӘР

**– Разил әфәнде, узган елның ноябрендә Сез җитәкләгән В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсе Милли китапханә статусын алды. Бу татар җәмәгатьчелеге тарафыннан республикабыз тормышында мәдәни генә түгел, сәяси әһәмияткә дә ия олуг вакыйга буларак кабул ителде. Минем иң беренче нәүбәттә менә шундый сорауга җавап ишетәсем килә: нәрсә ул милли китапханә, ул кемгә, нинди укучыга хезмәт итә?**

– Милли китапханә бөтен кешелек дөньясы тудырган интеллектуаль байлыкны туплаучы һәм теләсә кайсы милләттән булган теләсә нинди һөнәр иясен – тел белгечен, тарихчыны, кибернетикны, агрономны булсын – мөһим мәгълүматлар белән тәэмин итә ала торган милли хәзинәгә әверелергә тиеш. Дәүләтнең байлыгы алтын-көмешләр, казылма байлыклар белән генә исәпләнми. Хәзерге вакытта безнең республикабызда 4 меңнән артык китапханә эшли. Ә элекке союздаш республикалардагысы күпме! Димәк, горурланырга хакыбыз бар. Милли китапханәбез дә булгач, икеләтә горурланырга кирәк. Китапханәбез бик бай. Хәер, ул инде инкыйлабка кадәр үк Рәсәйдәге иң бай китапханәләрдән саналган. Мондый китапханәләр бары тик ике шәһәрдә – Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта гына булган. Хәзер милли китапханә фондында 3 миллионнан артык китап исәпләнә. Алар арасында безнең чал тарихыбызга караган борынгы китаплар да шактый. Мин боларны ни өчен әйтәм? Урыс шовинистлары инде 440 ел буена татар халкын надан халык итеп күрсәтергә тырыштылар. Хәзер дә тырышалар. Әмма 270 ел китап бастырган халык надан була алмый. Рәсәйдәге төрки халыклар инкыйлабка кадәр барысы бергә 500–600 исемдәге китап нәшер иткәннәр, ә татар 15 меңнән артык исемдәге китап бастырган. Дөрес, без бу өлкәдә урыслардан соң икенче урында торганбыз. Ләкин бусы да тарихи сәбәпләр аркасында. Урыс патшалары һәм аларның ялчылары безгә бу эштә һәрвакыт аяк чалып килгәннәр. Татарның зыялы булуы, һаман саен белемгә омтылуы аларны һәрвакыт шөбһәгә салган. Мисал эзләп еракка китәсе юк. Рәсәйдә татар китапханәләре дә беренче урыс инкыйлабыннан соң гына барлыкка килә башлый. Дөрес, Болгар, Казан ханлыклары чорында безнең гаҗәеп бай китапханәләребез булган. Әмма аларны яулап алучылар туздырганнар. Халыкның язма мирасы янган, таланган, кулдан-кулга күчеп йөргән, илләр буйлап гизә-гизә бөтен дөньяга таралган. Шул рәвешле ярым яраксыз хәлгә килгәннәренең һәм төпсез тарих чоңгылында гаип булганнарының да исәбе-хисабы юк. Милли китапханә менә шул китапларны туплау-барлау, аларны тәртипкә салу, төзекләндерү белән шөгыльләнә. Алты ел элек безнең фондта гарәп язуындагы 1 меңнән артык атамадагы китап исәпләнә иде. Хәзер алар 4 меңнән артып китте. Болары китапларның исемнәре генә, аларның бит әле берничә нөсхәдә булганнары да шактый.

Әйткәнемчә, татар халкының язма мирасы бөтен дөньяга таралган. Мөһаҗир китапларыбыз акрынлап илгә кайтарыла. Мәсәлән, биш ел элек Ашхабад милли китапханәсеннән XIX гасырда чыккан – 554, Якутск шәһәреннән 100 гә якын китап алып кайттык. Төркиянең Әнкарә университеты профессоры Субудай әфәнде исә безгә этисе – күренекле башкорт сәяси эшлеклесе Зәки Вәлиди язган китапларны һәм татар тарихына караган 200 китап бүләк итте. Казан компрессорлар заводы директоры Әхмәт Галиев Венгриядән XVIII гасырда Алманиядә нәшер ителгән татар китапларын алып кайтты. Язма мирасыбызны туплауда АКШта яшәүче кан кардәшләребез дә ярдәм итә. Мисал өчен, алар җәлилчеләрнең әле беркайда да басылмаган шигырьләрен җибәрделәр. Япониядән, Финляндиядән дә бик күп китаплар килде. Берничә ай элек мәрхүм Альберт Фәтхинең шәхси китапханәсен туганнарыннан сатып алдык. Моның өчен аңа китапханә акчасына кабер ташы һәм чардуган ясатылды.

Язма мирасны туплау бер хәл, аларны тәртипкә салырга кирәк бит әле. Хәзер бер төркем галимнәр революциягә кадәр нәшер ителгән татар китапларының төп нөсхәләре һәм күчермәләренең тулы басма каталогын булдыру белән шөгыльләнәләр. Бу группаны китапханәнең борынгы кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Раиф Мәрданов җитәкли, фәнни җитәкчесе – академик Әбрар ага Кәримуллин.

XVII гасырдан алып безнең көнгә кадәр чит ил матбугатында Татарстан, татар халкы, күренекле милләттәшләребез хакында басылган мәгълүматларны, фәнни телдә әйтсәк, татариканы туплый башладык. Шул максаттан чыгып, Мәскәүдәге чит илләр әдәбияты, Япониядәге көнчыгыш әдәбияты китапханәләре, Төркия милли китапханәсе, Англиянең Кембридж университетындагы һәм АКШның Төньяк Каролина штатындагы Үзәк библиография институтлары белән элемтәләр урнаштырдык. АКШ Конгресс китапханәсенә дә хезмәттәшлек итү турында килешү проекты җибәрелде. Ирешелгәннәр уңышның башы гына. Алга таба китапханәбезнең дөньякүләм мәдәни элемтәләре тагын да артыр дип ышанам.

– **Вакыт дигәнең кешеләрне генә түгел, китапларны да кызганмый. Алар да безнең кебек туза-картая. Милли китапханәдә хәтта XIV гасырда басылган китаплар да саклана. Андыйлары инде аеруча игътибар сорый торгандыр.**

– Моңа кадәр без, урын җитмәү сәбәпле, сирәк китапларны подвалларда сакларга мәҗбүр идек. Бина сорап күп тапкырлар Татарстан Мәдәният министрлыгына һәм Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать иттек. Хәлебезгә керүче булмагач, коллектив забастовка игълан итте. Бик үзенчәлекле каршы тору булды бу. Элеккегә караганда да яхшырак эшләдек. Әмма 208 кеше айлык хезмәт хакын алудан баш тартып, аны Яшел Үзән шәһәрендәге ятимнәр йортына күчерде. Мәсьәлә хәл ителмәгән очракта, хөкүмәт белән мөнәсәбәтләрне өзеп, китап укучылар биргән хәер акчасына яшәргә иде исәп. Бу турыда кисәтеп тә куйдык. Шулай тартыша торгач, комсомол өлкә комитеты бинасын бирделәр. Алай да бөтен китапларны да киштәләргә тезеп куярга урыныбыз юк. Ярты миллионнан артык XVII–XVIII гасыр китабы укучыга бирелмичә ята. Аны без «пассив фонд» дип атыйбыз. Гомумән, фондта булган китапларны киштәләргә тезеп куяр өчен тагын шундый алты бина кирәк.

– **Китапларга реставрация ясау мәсьәләсе ничек тора? Бу өлкәдә хәл бераз яхшырактыр инде, шәт. Подвалларда череп яткан китапларны «дәвалый» торгач, осталык бермә-бер арта төшкәндер?**

– Бусы белән дә бик мактанып булмый. Китаплар термоэшкәртү аша узарга тиешләр. Ә моны фәкать элекке союздаш республикаларда гына эшләп була. Әлеге эшне җайга салыр өчен махсус җиһазландырылган бина кирәк. Күрдегезме, мәсьәлә һаман да шул бинага килеп терәлә. Бик күңелсез хәл. Бу эшне озакка сузарга ярамый. Борынгы китаплар турында сүз бара бит. Шулай да сер бирмәскә тырышабыз. Узган ел без 2400 китапка реставрация ясаттык. Аларын да кооперативлар ярдәме белән генә. Ни генә димә, бу өлкәдә без Көнбатыш Европа илләреннән бик нык артка калганбыз. Тагын шунысы гаҗәп: моннан өч-дүрт гасыр элек басылган китаплар хәзерге заман китапларына караганда күп тапкырга чыдамрак. Чөнки алар сыйфатлы кәгазьдән эшләнгәннәр.

– **Китапханәдә төрле милләт вәкилләре эшли. Милли язма мирас белән эш иткәч, алар татар телен дә белергә тиешләрдер инде.**

– 1990 елның августында урыс һәм татар телләре дәүләт теле дип игълан ителгәннән соң, без китапханәдә җыелыш уздырдык. Коллектив урыс һәм татар телләрен яхшы белгән, аларны гамәлдә кулланган хезмәткәрләрнең хезмәт хакына унбиш процент өстәмә акча түләү турында карар кабул итте. Элек мондый акча чит телләрне белгән кешеләргә генә түләнә иде. Шулай итеп, хәзер бездә татар теле дөнья телләре кебек үк дәрәҗәле урында тора. Китапханәдә 40 кешелек татар теле курслары эшли. Аны Казан дәүләт университеты доценты Флёра Сафиуллина алып бара.

– **Разил әфәнде, Сез берьюлы Татарстан Югары Советының Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе һәм Республика Милли китапханәсе директоры вазифаларын башкарасыз. Бу бер кеше өчен күп түгелме? Шуның өстенә шагыйрь дә...**

– Өч елдан минем депутатлык срогым тәмамлана, аннары яңадан тулысынча китапханә эшенә чумачакмын. Миңа әлегә икесендә дә эшләргә кирәк дип уйлыйм. Коллектив та шул фикердә. Чөнки китапханәбез Милли китапханә статусын алгач, миңа аның эшчәнлеген дөнья югарылыгында оештыру өчен АКШның Конгресс, Канаданың Торонто, Монреаль милли китапханәләрендә һәм башка бик күп җирләрдә булырга, алдынгы тәҗрибә белән танышырга

туры килде. Өйрәнгәннәремне тормышка ашырмыйча китү ярамас. Аннары мин китапханәгә кечкенәдән гашыйк. Мәктәптә укыган елларда миңа авыл китапханәчесе дөньядагы иң акыллы, иң зур кеше булып тоела иде.
Иҗат мәсьәләсенә килгәндә, мин һич тә зарлана алмыйм. Вакыт кысылган саен фикер дә кысыла. Шуңа күрә әйтәсе килгән фикеремне шигырьгә салырга тырышам. Вакыт күп булса, мин аны прозада әйтер идем. Әмма шигырь күңелгә якынрак. Тагын шунысы бар: яраткан эш иҗатка берничек тә комачау итә алмый. Киресенчә, канатландыра гына. Яраткан эш, дидем. Кая гына куйсалар да, дөньямны онытып эшлим мин. Әйтик, урам себерүче булсам, мин үз урамымны башкаларныкына караганда чистарак итеп тотарга тырышыр идем. Ул чакта, алдынгы тәҗрибә белән танышыр өчен, Америка урам себерүчеләре конгрессында катнашырга җай табар идем.
**– Безнең ил кешесенә Америкада урам себерүче булып эшләү зур дәрәҗә инде ул. Бусы, әлбәттә, шаяртып кына әйтелде. 3 миллион китап арасында үзегезнең әсәрләрегезне күрү Сездә горурлык тудырамы?**
– Киресенчә, үземнең нинди кечкенә кеше икәнлегемне аңладым. Ә нинди китаплар бар монда! Иң аянычы – аларны мин беркайчан да укып чыга алмамын. Чөнки моның өчен 600 кеше гомере кирәк булыр иде.
**– Разил әфәнде, мисал өчен Нью-Йорк җәмәгать китапханәсе безнең Республика Милли китапханәсеннән кайсы ягы белән аерыла?**
– Аерма – җир белән күк арасы. Беренчедән, анда китап укучыга килмешәк итеп түгел, ә кунак итеп карыйлар. Анда бездәге кебек паспорт, прописка, укучы билеты кирәкми. Анкета да тутырып азапланмыйсың. Кирәк китапның исемен язып бирәсең дә, иң күбесе бер сәгатьтән ул инде синең кулыңда. Дөрес, анда китапны өйгә бирмиләр. Киләчәктә бездә дә шулай булыр дип уйлыйм. Аннары чит илдә күпчелек китапханәләр компьютерлаштырылган. Кирәкле китапны көннәр буе эзләп иза чикмисең. Безгә әле моңа бик ерак. Шулай да тырышабыз. Күптән түгел Милли китапханәдә өч компьютер куелды.
**– Китапханәдән китап урлаган очраклар да була дип ишеткәнем бар. Бу дөресме? Дөрес булса, андый кешеләргә карата нинди чаралар күрелә?**
– Әйе, кызганычка каршы, мондый хәлләр булгалап тора. Студентлар гына түгел, доцентлар да китап урлый белә икән. Мондый кешеләргә карата иң кискен чаралар күрелә. Мәсәлән, штраф түләтү. Кайбер очракларда аларны китапханәгә йөрү хокукыннан мәхрүм итәбез. Җинаять эше кузгату да каралган. Әмма әлегә андый чараны кулланганыбыз юк.
**– Язучылар үзләренең китапларының укылышы белән кызыксыналармы?**
– Бик сирәкләре генә. Язучы кеше өчен мондый битарафлык килешеп бетми, әлбәттә. Юкса үз укучыңның зәвыгы, уй-фикерләре белән кызыксынып тору иҗатка файда гына китерә бит.
– **Быел республика халкы татар китабы нәшер ителә башлауның 270 еллыгын билгеләп үтәчәк. Әлеге юбилей уңаеннан Милли китапханә нинди мәдәни чаралар үткәрергә җыена?**
– Аларның барысын да санап бетерү мөмкин түгел, һәрхәлдә, ышандырып әйтә алам: бу бәйрәм элеккесенә караганда да эчтәлеклерәк, күңеллерәк һәм матуррак узачак.

*Әңгәмәдәш Заһид Мәхмүди*
*1992*

# МӘДӘНИЯТ ЯКЛАУГА МОХТАҖ

**– Югары Советның бу елның февраль башында булачак сессиясе март башына кадәр кичектерелде. Бик сирәк була торган хәл бу. Шунлыктан әлеге үзгәреш төрле уй-фикерләр уятты. Ишетеп белүебезчә, сессиянең кичектерелүе быелга билгеләнгән бюджетның әле тиешенчә эшләнеп бетмәве белән дә бәйле. Чөнки анда күп кенә тармаклар, шул исәптән мәдәният өлкәсе дә, акча ягыннан бик нык кыерсытылган. Бу хакта сез җитәкләгән даими комиссия утырышында да борчулы сөйләшү булган. Югары Советның милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе һәм «Шәһри Казан» газетасының эксперты буларак, шушы мәсьәләгә ачыклык кертсәгез иде.**

– Дөрестән дә, мәдәният өлкәсендә эшләгән кешенең тормышы башка тармактагыларныкыннан яхшы дип булмый. Башка һөнәр ияләре зуррак, күбрәк мөмкинлекләрдән файдаланалар. Шунлыктан быелгы бюджетны кабул иткәндә дә, хәзер без эшли торган «Мәдәният турында»гы Закон проектында да мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклау мәсьәләсе бик нык истә тотылырга тиеш. Чөнки мәдәнияте булмаган милләтнең икътисади яктан да файдасы аз.

– **Ишетеп белүебезчә, Россия Федерациясендәге башка автономияле республикаларда мәдәният тармагына бюджеттан акча бездәгегә караганда күбрәк бүлеп бирелә. Ни өчен шулай?**

– Бу инде безнең иң авырткан җиребез. Мәдәнияткә кагылышлы мәсьәләләр күп: иҗат оешмаларының матди хәле дә безне борчый. Мәдәният хезмәткәрләренә, иҗат интеллигенциясенә: язучыларга, рәссамнарга, композиторларга – аларның барысын да санап тормыйча – ярдәм итәргә кирәк. Ләкин боларның бөтенесенең нигезендә финанслау ята. Тиешле дәрәҗәдә финанслау, акча булмаса, боларның берсен дә эшләргә мөмкин түгел. Бу елга билгеләнгән бюджет проектында Язучылар һәм Композиторлар берлекләренә генә акча бүлеп бирү каралган. Анда да әле шул Берлекләрнең идарә аппаратын тоту гына искә алынган. Ә иҗатчыларның үзләренә матди ярдәм күрсәтү каралмаган.

Калган иҗат берлекләре, берләшмәләре нинди акча исәбенә эшләргә тиеш соң? Иҗат оешмаларының хәле мөшкел. Ә анда әгъза булып торган, гомер буена иҗаты белән халыкка хезмәт иткән җырчыларыбыз Илһам Шакиров, Әлфия Авзаловалар, күренекле язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттахлар, композиторлар Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтовлар бүгенге көндә уртача дәрәҗәдән дә начаррак тормыш-көнкүреш шартларында яшиләр, очын очка көчкә-көчкә генә ялгыйлар. Иҗат оешмалары аларга берничек тә ярдәм итә алмый. Дөрес, Президент фондыннан ара-тирә аз-маз ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бар, диләр. Ләкин бюджетта даими биреп барырга акча каралмаган.

Россияне яманларга яратсак та, анда да кайвакыт яхшы яклар бар. Аеруча зур хезмәт күрсәткән мәдәният әһелләренә Россия президенты указы белән гомерлек дотация бирелә. Ягъни, ул кеше минималь дәрәҗәдәге ун хезмәт хакы күләмендә даими рәвештә акчалата дотация ала. Чөнки ул бу акча бәясен гомер буена халыкка хезмәт итеп аклаган инде.

**– Ә бездә бу мәсьәлә күтәрелмиме?**

– Без дә Югары Совет утырышында шундый карар кабул иткән идек. Әдәбиятта, сәнгатьтә, мәдәнияттә аеруча зур хезмәт күрсәткән, пенсия яшендәге кешеләргә ун хезмәт хакы күләмендә исемләнгән, шәхси дотация биреп бару турында тәкъдим ясадык. Моны Президент Аппаратында да хупладылар. Әмма, кызганычка каршы, Министрлар Кабинетының бу турыда карары, президентның да указы юк әле. Әгәр дә без, һич югында, 10–15 иҗат әһеленә шундый ярдәм күрсәтә алсак, һичшиксез, аларның күңеле күтәрелер, бигрәк тә яшь иҗатчыларда киләчәккә өмет-ышаныч уяныр иде. Гомер буена мәдәният өлкәсендә халыкка хезмәт итсәң, картлык көнеңдә дә кадереңне беләләр, дигән уй туар иде аларда.

**– Иҗат кешеләре хәзер җиң сызганып, тир түгеп иҗат белән шөгыльләнәсе урында да үзләренең һөнәренә хас булмаган «кара эш» башкаралар.**

– Дөрес, җырлыйсы, рәсем ясыйсы, роман-шигырь язасы урында алар көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән шөгыльләнәләр. Чөнки ачтан үләсе, югалып та каласы килми. Аларны да аңларга мөмкин.

**– Россия Федерациясендә бюджеттан мәдәният тармагына алты процент күләмендә акча бирелә...**

– Әйткәнемчә, Россиядә бик әйбәт законнар чыккалап тора. Гомумән, Россия Югары Советы законнар кабул итү буенча актив эшли. Мәдәният өлкәсендә дә шулай. Узган ел октябрь аенда Россия Югары Советы «Мәдәният турында» Закон кабул итте. Һәм шунда бик әйбәт маддә бар. Шуның нигезендә бөтен бюджеттан мәдәнияткә акча алты проценттан да ким бирелмәскә тиеш.

**– Ә бездә?**

– Үткән елда ул бөтен бюджетның ике проценты чамасын тәшкил итте. Быелгы бюджет проекты юлламасы да безне куандырмый. Алты процент турында хыяллана да алмыйбыз. Мәдәнияткә каралган акча ике белән өч процент уртасында. Хәзер ни өчен кистереп кенә әйтмәүнең дә сәбәбе бар: элек телевидение-радио, массакүләм мәгълүмат һәм матбугат, китап чыгару һәм сату, нәшрият мәдәнияткә карамый иде. Аларга бюджеттан акча үзләренә аерым бирелеп килде. Ә быел барысын да мәдәният өлкәсенә керткәннәр һәм бүлеп бирелгән акча бик аз гына арттырылган – барысына нибары 7 миллиард сум чамасы. Ә безнең бөтен бюджетыбыз 300 миллиард сумга якын. Шуннан алты процент бирсәләр, моны теләсә кем дә исәпләп чыгара ала, 18 миллиард сум булыр иде.

Без даими комиссиядә шулкадәр акча бирүне таләп иттек. Дөресен генә әйткәндә, телевидение-радио, нәшрият, матбугат оешмаларын мәдәнияттән аерып карыйсы килми. Киресенчә, безнең комиссия аларны мәдәнияткә кертеп карарга тырыша. Алай булмаганда, ул өлкәләрдә эшләүчеләр мәдәният эшчәннәре файдалана торган өстенлекләрдән мәхрүм калачаклар. Моңа аренда түләүдән, салымнардан азат итү һәм башка өстенлекләр кирә. Бу нәрсә бигрәк тә китап нәшриятына һәм китап кибетләренә кагыла... Үзегез күреп-белеп торасыз: шушы арада гына Казанда, гомумән Татарстанда 20 гә якын китап кибете ябылды. Китап урынына аракы, тәмәке сата башласаң, милләтебез, халкыбыз кая барып чыгар?

Менә шушы мәсьәләләрне, гомумән мәдәниятне финанслау мәсьәләсен без мәгариф даими комиссиясе белән бергә тикшердек. Утырышка бик күп югары оешмалар җитәкчеләрен чакырдык.

Без даими комиссия утырышында бюджетка кагылышлы мәсьәлә турында төпле генә сөйләшеп алдык. Тәкъдимнәребезне Югары Совет Президиумына җиткердек. Ләкин, үзегез беләсез, Югары Советның 14 нче сессиясенең дәвамы кичектерелде. Президиумда шундый карар кабул иттек. Моның төп сәбәбе – президент кул куеп җибәргән бюджет проекты турындагы юлламада Татарстанның тышкы икътисад эшчәнлеге, валюта фонды чагылыш тапмаган. Ә ул бюджетның төп состав өлеше булып тора. Нефть, газ һәм башкаларны сатудан килгән валюта табышы бюджет проектында күрсәтелмәгәч, аны тулаем тикшереп тә булмый. Бюджетта валюта фонды булырга тиешлеге Конституциядә дә, «Бюджет төзелеше турында»гы Законда да язылган. Без, Югары Совет Президиумы әгъзалары, үзебез чыгарган законны үзебез бозып утыра алмыйбыз. Шуңа бюджет проекты юлламасын кире кайтардык. Сессия дә кичектерелде. Бу, билгеле, күңелле хәл түгел. Беренчедән, республика халкы, барлык оешмалар, завод-фабрикалар эшләсен өчен финанслау таләп ителә. Ә тулы финанслау өчен бюджетны кабул итәргә кирәк. Ул булмагач, Финанс министрлыгына да, республиканың барлык дәүләт структураларына кыенлык туа. Ләкин монда Югары Советның бернинди дә гаебе юк. Моның төп сәбәбе, бәлки, Россия Федерациясе белән килешү булмауга барып тоташадыр. Бүгенге көндә күп өлкәдә Россия белән аңлашылмаучанлык аркасында валюта безнең кесәгә Россия банклары аша керә. Тулы мөстәкыйльлек алсак, бюджет проектын да Югары Совет үз вакытында тикшереп кабул итәр иде. Ә без үткән елда да бюджетны бик соңлап кабул иттек.

**– Бюджет проектында мәдәнияткә караган өлешне арттыру юнәлешендә даими комиссия нинди чаралар күрә?**

– Сессиягә кадәр даими комиссия ике мәсьәлә белән шөгыльләнәчәк. Беренчедән, комиссиянең барлык әгъзалары катнашында үтәчәк утырышка республикада мәдәниятне финанслау өчен җавап бирә торган кешеләрне, мәдәният өлкәсендә эшләүче барлык җитәкчеләрне, иҗат берлекләре, җәмгыятьләр башлыкларын чакырып, борчыган мәсьәләне уртага салып сөйләшәчәкбез, мәдәниятне финанслауга акчаны арттыруны сораячакбыз. Чөнки моны халык таләп итә. Мәсәлән, еш кына телерадиокомпаниягә татарча тапшыруларның аз булуы турында хатлар килә. Әмма моңа телерадиокомпания җитәкчеләре гаепле түгел. Алар берни эшли алмыйлар, чөнки бюджеттан акча җитәрлек бүлеп бирелми. Ә моны депутатлар хәл итә. Шуңа күрә мондый хатларны язучылар үзләренең депутатлары аша мәдәнияткә акчаны күбрәк бирүне таләп итсеннәр иде.
Без шөгыльләнә торган икенче мәсьәлә – мәдәният турында закон проектын эшләү. Татар мәдәнияте тарихында беренче булган бу канун бик тә кирәк безгә. Ул законнан башка бер мәсьәләне дә үзебез теләгәнчә хәл итә алмыйбыз, дип әйтсәк, бераз арттыру да булыр. Әмма шунсыз бездә эшләү бик авыр. Без ул законда мәдәният хезмәткәрләренең, иҗат әһелләренең, мәдәният оешмаларының хокукларын һәм бурычларын билгелибез, халыкның мәдәнияткә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерүен гарантияләп куябыз. Проектны матбугатта бастырып чыгарырбыз. Шул проектны киләсе утырышларның берсендә тикшерербез. Моннан тыш тагын берничә закон эшләнә. Аларны Югары Совет Президиумы хуплады. Дин оешмалары һәм дин турында закон кабул итәргә уйлыйбыз. Аларның хокукларын да, бурычларын да гарантияләү шулай ук мөһим.
Аннан соң матбугат оешмаларының да әлегәчә законы юк. Үзебезнеке булмагач, Россия законнары белән эшләргә туры килә. Матбугат турындагы закон проектын эшләүне быелгы планга керттек. Шул уңайдан матбугатка карата фикеремне җиткерәсем килә. Татар матбугатына артык зур дәгъвам булмаса да, кайбер газета-журналларның халык референдумда раслаган төп юнәлешкә каршы чыгуларына тыныч кына карый алмыйм. Татарстанда урнашып, аның полиграфия базасыннан, барлык башка мөмкинлекләрдән файдаланып та, Татарстан халкы фикеренә каршы булган газеталар бездә чыгарга тиеш түгел. Чөнки алар безнең хөкүмәткә дә, Конституциягә дә, Декларациягә дә каршы эш алып баралар. Бер генә илдә дә Конституциягә каршы эшләгән оешманы тотмыйлар. Шуңа күрә бу фикер дә матбугат турындагы законда чагылыш табарга тиеш.
Кат-кат сорый-үтенә торгач, планга өстәмә рәвештә тагын бер закон проектын кертүгә ирештек. Ул тәкъдимне сессия расласа, тарихи һәм мәдәни байлыкларыбызны саклау һәм куллану турында үз законыбыз булыр дип ышанам.
Бүген без ниндидер яңа җәмгыять төзү турында хыялланабыз. Ләкин моңа чаклы халкыбыз гасырлар буена туплап килгән мәдәни хәзинәләребезне саклап кала алмасак, безнең киләчәгебез булмас.
Милли мәсьәләләр буенча эш чиктән ашкан. Барысын да берьюлы эшләп бетереп тә булмас. Әмма качаклар мәсьәләсе кичектергесез. Безгә милләттәшләребез бертуктаусыз кайта торалар. Аларны эшкә урнаштырып кына мәсьәлә хәл ителми. Башка ихтыяҗларын да кайгыртырга кирәк. Бу турыда да закон эшлибез. Нишләптер аны планга кертергә ашыгып торган кеше юк. Югыйсә без исә аны күптәннән әйтеп киләбез.
Без милли мәсьәлә буенча законнар, карарлар кабул итәбез. Аларны кем тормышка ашыра? Дөрес, мәдәният буенча министрлык бар. Ә милли мәсьәлә буенча бернинди башкарма оешма юк. Татарстанда 80 ләп милләт вәкиле яши. Әмма аларны координацияләүче үзәк кайда? Бу максатка бүлеп бирелгән акчага кем хуҗа? Безгә кайткан милләттәшләребез белән кем шөгыльләнергә тиеш? Дөрес, алар белән безнең комиссия һәм Хезмәткә урнаштыру буенча дәүләт комитеты, Татар иҗтимагый үзәге эш алып бара. Ә бит аларны борчыган мәсьәләләр эшкә урнаштыру белән генә төгәлләнми. Бирегә алар буш кул белән кайталар, бернәрсәләре дә юк: торагы да, ваучеры да, чеклары да... Балаларын бакчага, мәктәпкә урнаштырасы, медицина хезмәте күрсәтүне җайга саласы бар. Йомгаклап кына әйткәндә, бу да милли мәсьәлә. Яки икенче зур мәсьәлә: «Телләр турында» Закон кабул иттек, аны тормышка ашыру өчен күп эшләргә кирәк. Аның белән кем

шөгыльләнә? Без даими комиссиядә Министрлар Кабинетында Милләтләр эше буенча дәүләт комитеты оештырырга тәкъдим ясадык. Карар да кабул иттек. Аны Югары Совет Президиумына, Министрлар Кабинетына, президентка җибәрдек. Ә җавап юк. Дөрес, Президиум карар чыгарды. Ә башкалар дәшми.

Кыскасы, проблемалар күп. Аларны күтәреп кенә калмыйча, хәл итү буенча да бергәләп эшләү сорала. Бер камытка җигелеп, бер тәртә арасына кереп... Шулай бердәм тотынсак кына, ил күзенә күренерлек зур эшләр эшләнер дип өметләнәбез.

*Әңгәмәдәш Шәех Зәбиров*
*1993*

# ТАТАРЛАР, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

**– Разил әфәнде, халкыбыз Сезне талантлы язучы, шагыйрь буларак белә. Язган күпсанлы җырларыгызны сәхнәләрдән мөхтәрәм артистларыбыз башкара. Пьесаларыгыз буенча куелган спектакльләргә тамашачылар теләп йөри, роман-повестьларыгыз кулдан-кулга күчеп укыла. Күзәткәнем бар: кайда гына эшләсәгез дә – балалар журналы «Ялкын»дамы, Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы эшләрдәме – Сез һәрчак үз вазифаларыгызга иҗади якын килә идегез. Гомумән, мәсьәләләргә катып калган фикер белән якын килү, җиңел кулдан гына хәл итәргә алыну Сезгә ят нәрсә.**
**Соңгы елларда җөмһүриятебезнең бәһаләп бетерә алмаслык байлыгы булган Милли китапханәгә җитәкчелек итәсез. Барыбыз да беләбез: моңа кадәр бик кысан бинага шыплап тутырылган иде ул байлык. Уникаль, кайберсе берәр генә данә сакланып калган ул хәзинәләргә игътибар җитәрлек тә түгел иде. Бүгенге көндә Сезнең турыдан-туры тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә китапханәбез яңа, иркен бинага күчте. Милләтебезгә, аның байлыкларына игътибарлы караш, мәхәббәт Сезгә яңа эшегездә дә ярдәм итәдер дип беләм. Чөнки Сез коеп куйган әдип кенә түгел, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче дә. Татарстанның халык депутаты, Татарстан Югары Советы Президиумы әгъзасы, Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссия рәисе. Сезнең җитәкчелектәге даими комиссия нинди эшләр башкара, тоткан кыйбласы нинди?**
– Билгеле булганча, язмыш татар халкын бөтен Җир шары буйлап сипкән, тараткан. Иң әүвәл шунысын әйтү кирәк: безнең Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссия төрле тарафларга сибелгән милләттәшләребезне, кан кардәшләребезне туплауны төп максаты итеп куя. Бу өлкәдә без җөмһүриятебез җитәкчеләре белән һәрдаим киңәшләшеп, фикерләшеп эшлибез. Нәтиҗәдә тарихта беренче мәртәбә милләтебезне берләштерү, аларга ярдәм итү өчен Татарстан хөкүмәте бюджеттан 270 миллион сум акча бүлеп бирде.
Безнең комиссия, нигездә, ике юнәлештә эш алып бара. Беренче төп юнәлешебез – чит өлкәләрдә яшәүче туганнарыбызга мәдәни ярдәм күрсәтү. Биредә сүз, әлбәттә, кайсыдыр өлкәдә яшәүче татарлар янына барып җырлап-биеп, күңел ачып кайту турында бармый. Гәрчә монысы да бик кирәкле эш. Безнең максат – теге яки бу өлкә, край, республикалар белән килешүләр төзегән вакытта милләттәшләребезгә шул төбәкләрнең үзләрендә матди ярдәм күрсәтелүенә ирешү. Ә безнең милләттәшләребез моңа бик тә хокуклы, чөнки алар шул төбәк икътисадын үстерүгә көч куялар: йортлар төзиләр, иген игәләр, терлек карыйлар. Читтә яшәүче милләттәшләребезгә Татарстан хөкүмәте генә ярдәм итәргә тиеш дигән сүз бу очракта мәзәк яңгырар иде. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә безнең уңышларыбыз да бар. Рәсәй, Башкортстан, Украина һәм башка дәүләтләр, өлкәләр белән төзелгән договор-килешүләр вакытында бу мәсьәләләр үзәккә куелды. Кыскасы, милләттәшләребезгә ярдәм итүне бары дәүләтләр арасындагы договор-килешүләр төзү нәтиҗәсендә генә хәл итеп булачак.
Әлегә җиде миллионлы татарны берләштерү, аларга хезмәт күрсәтүнең төп авырлыгы Татарстан җилкәсенә төшә. Бу очракта аерым министрлыкларның эшчәнлеген дә мактап телгә алырга кирәк. Читтә яшәүче милләттәшләребезне китап-дәреслекләр белән тәэмин итү, милли кадрлар әзерләү, аларга һәртөрле культура хезмәте күрсәтү өлкәсендә Татарстан Мәгариф министрлыгы, Татарстан Мәдәният министрлыгы зур, мактаулы эшләр башкара.
**– Разил әфәнде, Сезнең эш өстәлегездә өем-өем хатлар ята. Аларның барысын да диярлек чит өлкәләрдә яшәүче милләттәшләребез язган. Сер булмаса, әйтегез әле,ниләр борчый аларны?**
– Әйе, безнең Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиягә бик күп хатлар килә. Аларның берсен дә тыныч күңел белән укырга мөмкин түгел. Кан кардәшләребез күз яшьләре аша безгә мөрәҗәгать итәләр, үзләренең моң-зарларын бәян итәләр, ярдәм сорыйлар. «Без биредә татар буларак кирәк түгел, бары эш аты буларак кына кирәк», – диләр. Татарстан

җитәкчеләре, без никадәр генә тырышсак та, чит өлкәләрдәге милләттәшләребезгә мәктәпләр төзеп, мәчетләр корып бирә алмыйбыз, дип җавап кайтаралар. Әйткәнемчә, хәзер төзелгән договорларны эшкә җигәргә, аларны кәгазьгә язылган купшы сүзләр итеп кенә калдырмаска кирәк. Шунысы да бар: читтәге милләттәшләребез ул якларга килмешәк буларак төпләнгән халык түгел. Әйтик, күрше Башкортстан, Ырынбур, Себер якларында аларның бабалары гомер кичергән, ул аларның тарихи җире, Ватаны. Урындагы җитәкчеләр моның шулай икәнен онытмаска тиешләр. Ә җирле татар иҗтимагый үзәге активистлары моны аларга һәрчак искә төшереп торсыннар, уртак фикергә килү ягын карасыннар иде.

Киләчәктә милләтебезне берләштерү, туплау өчен без уртак мәгариф системасын булдырырга да тиешбез. Татар баласы кайда гына яшәвенә, укуына карамастан бер үк уку программасын өйрәнергә, үзләштерергә тиеш. Киләчәктә дәүләтара килешү-договорлар төзегәндә моңа аеруча әһәмият бирергә кирәк.

Татар халкының күпчелеге Рәсәйдә яши. Игътибар иткәнегез бардыр: Татарстанда яшәүче урыс милләтенең бөтен нәрсәсе бар. Театрлары да, мәктәпләре дә, балалар бакчалары да... Ә Рәсәйдә яшәүче татарларның нәрсәсе бар? Бармак белән генә санарлык алар. Әгәр дә инде без тигез хокуклы милләтләр, дәүләтләр төзү турында сүз куертабыз икән, иң элек шушы тигезсезлекне бетерергә, төзәтергә бурычлыбыз.

**– Әйе, нәкъ менә шушы тигезлек булмау сәбәпле, соңгы елларда качаклар мәсьәләсе көнүзәк, җан өзгеч мәсьәләгә әйләнде. Милләттәшләребезнең Татарстанга кайтып егылуы көннән-көн арта бара...**

– Безнең Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиянең икенче төп юнәлештәге эше нәкъ менә шушы качаклар мәсьәләсе белән бәйләнгән дә инде.

Халкыбызның ачы язмышка дучар булуы, фаҗигасе качаклар мәсьәләсендә аеруча ачык чагыла. Арада утызынчы елларда кулак дип туган җирләреннән сөрелгән милләттәшләребез дә байтак. Заманында аларны талаганнар, бөтен байлыкларын тартып алып, язмыш иркенә ташлаганнар, чит җирләргә сөргәннәр. Яшьлек, сәламәтлекләрен бетереп алар, анда яңа оя корганнар. Хәзер исә алар, янә шул байлыкларын калдырып, хәерче кыяфәтендә туган якларына кайтырга мәҗбүрләр. Дөрес, биредә дә Татарстан хөкүмәте аларның хәленә керергә тырыша. Качаклар мәсьәләсе Татарстан Югары Советында каралды. Кайтучыларга Биектау районында 80 гектар җир, йорт төзү өчен кредитлар бүлеп бирелде. Бүгенге көндә Татарстанга рәсми төстә 21 меңнән артык качак кайтты. Аларның барысы да диярлек эш, торак йортлар белән тәэмин ителде. Киләчәктә безгә качаклар турында махсус закон кабул итәргә кирәк, бары шул чакта гына без әлеге бәхетсезләрне яклый, төпле ярдәм күрсәтә алачакбыз.

**– Разил әфәнде, сезнең даими комиссиянең эше, әлбәттә, болар белән генә чикләнмидер.**

– Йөз еллар дәвамында рәнҗетелгән, бүлгәләнгән милләттәшләребезне бер йодрыкка туплау бүген-иртәгә генә хәл ителәчәк эш түгел. Моңа вакытлар кирәк булачак. Заман, бүгенге чынбарлык безгә бик җитди бурычлар куйды. Милли үзаңыбызны уяту, телебезне, мәдәниятебезне үстерү өчен барыбыз да көчтән килгәнчә эшләргә тиешбез.

Билгеле булганча, Татарстанда ике теллелек буенча закон кабул ителде, ул Конституциябездә дә беркетелде. Әмма бу өлкәдә дә әле җиң сызганып эшлисебез бар. Иң әүвәл, урыс теле кебек үк, татар телен дә югарыга күтәрергә кирәк. Әлегә татар теле үги хәлендә, мәктәпләрдә әле дә булса урыс теле хакимлек итә. Татар мәктәпләре, балалар бакчалары санаулы гына.

Киләчәк буыннарга тарихи истәлекләребезне, рухи байлыкларыбызны түкми-чәчми илтеп тапшыру турында да уйланырга вакыт җитте. Әлегә алар татарларның үзләре кебек үк төрле җирләрдә сибелеп, таралып, чәчелеп яталар. Тарихи китапларыбызны, йөзек-беләзекләребезне, сәнгати байлыкларыбызны бер тирәгә тупларга, барларга кирәк. Тик бу эшне теләсә кем кулына тапшырырга ярамый, ул дәүләт күләмендә башкарылырга тиешле.

Инде менә ничә еллар без кайсы әлифбага кайтыйк икән дип бәхәсләшәбез. Бу эш үзебезнең күптән түгел төзелгән Фәннәр академиясендә дә карала. Безнең комиссиягә килгән хатларда да милләттәшләребез бу уңайдан үз фикерләрен әйтәләр. Латинга күчү безне кан кардәшләребез төрекләргә, азәрбайҗаннарга тагын да якынайтачак дип саныйлар. Язучы буларак, мин үзем дә

шул фикердә торам. Дөрес, мәктәпләрдә бабаларыбыз укыган, язган гарәп әлифбасы да укытылырга тиеш. Чөнки безнең бик күп китапларыбыз гарәп графикасында басылган, аларда безнең күңел җәүһәрләребез саклана. Янәшәдә урыслар яши. Без алар белән аралашабыз икән, кириллица безнең тормышка үзеннән-үзе үтеп керәчәк. Шунысын да онытмыйк: бу әлифба белән дә безнең күпме китапларыбыз басылды бит.

*Әңгәмәдәш Рафис Гыйззәтуллин*
*1994*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРҮ – ДӘҮЛӘТ ЭШЕ

**– «Татарстан халыкларының телләре турында» Закон кабул ителүгә нәкъ ике ел вакыт үтеп китте. Законны тулы көченә хәрәкәткә китерү өчен вакыт җитәрлек иде. Ләкин ул бүгенге көнгәчә, билгеле бер сәбәпләр аркасында, канаты каерылган коштай, күтәрелеп китә алмый тора. Бер сүз белән әйткәндә, Закон эшләми. Сәбәбе нидә, Разил Исмәгыйлевич?**

– Шәхсән мин үзем аны бөтенләй эшләми димәс идем. Соңгы ике ел эчендә бер мәркәзебездә генә дә ничәмә-ничә татар гимназиясе, лицейлары ачылды. Аңарчы, үзегез беләсез инде, Казанда карап торган бер татар мәктәбе бар иде! Бу законның йогынтысы чит өлкәләргә дә барып җитте. Күрше Башкортстанда, Оренбург, Чиләбе шәһәрләрендә татар теле укытуга игътибар артты. Татар балалар бакчалары йә булмаса бакчаларда татар группалары оештырыла башлады. Әкренлек белән генә булса да алга китеш сизелә сизелүен. Тик мин шунысын да әйтергә тиешмен: бу эшләр күбесенчә милли хәрәкәт инициативасы, аерым министрлыкларның тырышлыгы белән генә башкарылды. Ә бит ул дәүләт эшенә, бөтен халык эшенә әверелергә тиеш. «Телләр турында»гы Законның 4 нче һәм 7 нче маддәләренә без, бу Законны тормышка ашыру өчен дәүләт Программасы кабул ителергә тиеш, дип язып куйган идек. Законның асылын тәшкил итә торган бик мәгънәле юллар бу. Чөнки Программадан башка бер адым алга, ике адым артка килеп чыгуы мөмкин. Ни кызганыч, шуны аңлый торып та, түземсезлек белән көткән ул документны без «Телләр турында» Закон кабул ителүгә ике ел вакыт узганнан соң гына әзерли алдык.

**– Ни өчен шулай бик озакка сузылды соң ул?**

– Ни өчен вакытында кабул ителмәде, дисезме? Министрлар Кабинетында безгә, акча юк, диделәр. Бу – объектив сәбәпләрнең берсе, әлбәттә. Әмма барын да акчага гына кайтарып калдырырга да ярамый. Бер карасаң, аның психологик ягы тагын да шөбһәлерәк. Үзләре татарча белмәгән кешеләрнең һич кенә дә татар телен дәүләт теле итеп кабул итәселәре килми.

Хәтерлисездер, «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законны кабул итү нинди зур авырлыклар белән барды, кызу бәхәсләр китереп чыгарды. Залда утыручы депутатларның күбесе, хәтта татар милләтеннән булганнарының да байтагы, татар телен рус теле белән янәшә куюга, дәүләт теле итеп тануга теш-тырнаклары белән каршы чыктылар. Гомумән, милли мәсьәләгә барып кагылган һәр закон, һәр карар сессия көн тәртибенә кертелгән минуттан алып зур каршылыкларга очрый башлый. Татарстанның Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул иткәндә дә шулай булды. Ике телнең дә дәүләт теле булуы беренче мәртәбә шушы документта чагылыш тапты. Аннан соң бу хакта без Татарстанның яңа Конституциясендә да әйттек. Һәм боларның берсе дә безгә җиңел бирелмәде. Үз телебезне торгызуның ни дәрәҗәдә әһәмиятле, татар халкының киләчәк язмышы өчен ни дәрәҗәдә кирәкле булуын озын-озак дәлилләргә, депутатларны шуңа ышандырырга туры килде. Карап торуга болай да ап-ачык бит инде. Әйе, бәхәсләр юкка булмаган икән. Әмма аның иң кайнары алда әле...

**– «Татарстан халыкларының телләре турында» Законны гамәлгә ашыру буенча Дәүләт программасы әзер, дидегез. Аның үтәлешенә гарантия бармы соң?**

– Иң элек аны Татарстан Югары Советының 18 июльдә булачак чираттагы сессиясендә расларга кирәк әле. Моның аеруча җитди мәсьәлә булуын исегезгә төшерәм. Программа кабул ителмәгән очракта ни буласын күз алдына китерәсездер. Бу документ ике ел дәвамында эшләнде. Министрлар Кабинеты төзеп биргәннән соң, без аны үзебезнең комиссиядә дүрт мәртәбә карадык. Дүрт мәртәбә кире кайтардык. Бары әнә шулай җентекләп тикшерелгәннән соң гына аны максатка ярашлы дип таптык. Ул күз буяу өчен генә эшләнмәде. Программаның аерым маддәләрен үтәү өчен җаваплы кешеләр билгеләнде, вакыты күрсәтелде, кем контрольлек итә –

шунысы ачыкланды. Һәрхәлдә, Программаның үтәлешен кемнән сорарга икәнлеген беләбез хәзер. Комиссия телләр турында Программаны гамәлгә ашыру өчен Дәүләт комитеты оештыру тәкъдиме белән чыкты. Бусы да кирәкле гамәл. Комитетны премьер-министр М. Г. Сабиров үзе җитәкләргә тиеш дип саныйм. Ни өчен нәкъ менә ул диярсез.

1921 елны да татар телен дәүләт теле итү өчен шундый комитет төзелгән булган. Һәм аны хөкүмәт башлыгы җитәкләгән. Аннары район, шәһәр хакимиятләре каршында да комиссияләр төзеләчәк. Шунсыз булмый. Чөнки әлеге Программаны тормышка ашыру барлык механизмнарны хәрәкәткә китерүне таләп итә. Ул тормышыбызның барлык өлкәләренә дә үтеп керәчәк. Ул һәркемгә – гигант КамАЗ белән җитәкчелек итүче шул ук Н. Бехка да, колхоз рәисенә дә бертигез кагылачак. Программаны тормышка ашыру, шулай итеп, дәүләт эшенә әвереләчәк. Ә инде гарантиягә килгәндә, Программаны үтәү өчен алдагы өч елга 30 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк.

**– Ничек кенә булмасын, куйган максатны тормышка ашыру өчен этәргеч дип әйтимме, башлангыч нигеземе – бар инде. Шулай да «Телләр турында»гы Законны гамәлгә ашыру Программасы тел мәсьәләләрен ахырынача хәл итеп бетерә алыр дип уйлыйсызмы?**

– Программа ун елга исәпләнгән. Шушы дәвердә татар телен урыс теле дәрәҗәсенә (кимсетә бу сүзләр, әйеме?) күтәрә алсак, үз алдыбызга куйган беренче максатка ирештек, дип фаразларга була. Бу ни дигән сүз соң? Бу иң элек барлык эшләр ике телдә алып барылырга тиеш дигән сүз. Югары Совет сессияләрен генә карагыз. Утырышларны татар телендә дә алып барыйк, дип тәкъдим кертеп карадылар бит инде депутатлар. Барып чыкмады. Ни өчен икәнлеге аңлашыла. Телне белмиләр. Ә инде Программа эшли башлагач, сессияне ике телдә алып бару мәҗбүри булачак. Хәзерге барлык рәсми документлар – законнар, карарлар бер генә телдә языла. Алга таба бусы да искә алыначак. Шуңа күрә без татар телен өйрәнү системасын эшләдек тә. Ул балалар бакчасыннан башлап югары уку йортларына кадәр баскычлап алып барылачак. Үз телеңне бишектән, балалар бакчасыннан ук өйрәнү күздә тотыла. Һәрбер югары уку йортында татар теле кафедралары булдырылыр дип уйлыйм. Аннан соң, ни өчен урыс баласы татарча белмәскә тиеш?.. Татар баласы урыс телен белә бит. Израильдә, мәсәлән, иврит телен белмәгән кешене эшкә дә алмыйлар. Башка илләрдә дә шулай ул. Балтыйк буе илләрендә, әйтик, өчәр-дүртәр тел беләләр. Кыскасы, Татарстанда татар телен белү мәҗбүри булырга тиеш. Балалар телне өйрәнер дә анысы, тик менә өлкәннәр белән нишләргә? Аларны ирексезләп укытып булмый бит. Программа бу мәсьәләне дә хәл итү юлларын тапты шикелле. Татар телен барысы да белеп бетермәсә дә, ике телне кайсы һөнәр ияләре белергә тиеш – шунысы ачыкланды. Мисалга, кибетче, табибка бу аеруча кирәк. Шуның өчен минимумнар, нормативлар, сүзлекләр эшләргә кирәк булачак. Һәр министрлыкта имтихан алу комиссияләре оештырылачак. Инде килеп, телне өйрәнүдә кызыксындыру чарасы да булсын. Әйтик, кем дә кем ике телне дә яхшы белә, шуңа унбиш процентка кадәр өстәмә хезмәт хакы билгеләргә... Мин җитәкләгән республика Милли китапханәсендә, мәсәлән, бу кызыксындыру чарасын без инде күптән – Татарстанның суверенитеты турында Декларация кабул иткән елны ук керттек. Башта татар телен 17 кеше өйрәнде, хәзер инде менә 40 тан артык кеше өстәмә түләү ала. Программада массакүләм информация чаралары өчен дә аерым пункт эшләнде. Без биредә читтә яшәүче 5 миллион татарны да онытмадык. Югыйсә аларның күңеле китек булыр иде. Соңгы вакытта чит өлкәләр белән төрле килешүләр төзи башладык. Шунда милләттәшләребезнең мәнфәгатен дә чагылдырырга тырышачакбыз. Татарстанда яшәүче урысларның мәнфәгате ничек киң яктыртылган булса, Россиядә яшәүче татарларныкы да шулай булырга тиеш. Шул чагында гына без гражданнарның тулы хокуклары хакында, чын демократия хакында сөйли алачакбыз.

*Әңгәмәдәш Мәдинә Авзалова*
*1994*

# ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

*Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе директоры, шагыйрь, язучы, драматург һәм публицист Разил Исмәгыйль улы Вәлиев Яшел Үзән районында мөстәкыйль татар газетасы булдыруда күп көч куйган кеше. Без «Яшел Үзән» газетасының беренче саны чыгу уңаеннан аның белән әңгәмә оештырдык.*

**– Разил әфәнде, хәзер депутатларны төрле-төрле наказлар белән күмү бетте дияргә мөмкин. Элеккеге шикелле күпер төзүне, юл салуны, мәктәп коруны депутатлар җилкәсенә өймиләр кебек. Сезнең төп бурыч – яхшы кануннар эшләп кабул итү. Республикабыз мөстәкыйльлеген тормышка ашыру максатыннан чыгып кабул ителгән «Телләр турында»гы Канун шундыйларның берсе иде. Әмма ул төрле киртәләргә очрады, хәзер дә очрап тора. Яшел Үзән шәһәрендә һәм районында ул, мәсәлән, мөстәкыйль татар газетасы булдыруда ачык чагылды. Шуңа күрә Сезгә, 119 нчы Васильево территориаль сайлау округыннан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат буларак, сайлаучылар әлеге мәгълүм Канунны шушы төбәктә тормышка ашыруны күздә тотып, мөстәкыйль татар газетасы булдыруда ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәннәр иде. Сез узган чакырылышта үзегез эшләгән һәм кабул иткән Канунны тормышка ашыру ниятеннән аны иң зур наказ буларак үз өстегезгә алдыгыз. Дәүләт Советына сайлаулардан соң ярты ел вакыт узып китте. Минем белүемчә, Сез республика, Яшел Үзән шәһәре һәм районы җитәкчеләре белән бу мәсьәләне уңай хәл итү юнәлешендә сөйләшүләр алып бардыгыз. Нәтиҗәдә «Яшел Үзән» мөстәкыйль татар газетасы туды. Бу уңайдан Сездә нинди фикерләр уянды? Дөньяга аваз салуында үзегезнең турыдан-туры катнашыгыз булган яңа басмага нинди теләкләрегез бар?**

– Дөрес әйтәсез: Дәүләт Советы депутаты дәүләт дәрәҗәсендәге проблемаларны хәл итәргә, бүгенгесе көндә Татарстан халкы өчен иң кирәкле булган кануннар һәм карарлар кабул итеп, шуларның төгәл үтәлешен тикшереп, күзәтеп торырга тиеш. Әмма ләкин мине конкрет кешеләр сайлады, мине яклап тавыш биргәндә аларның һәммәсе дә үзләренең көндәлек мәшәкатьләрен хәл итүдә депутат ярдәменә өмет иткәндер. Дәүләт күләмендәге мәсьәләләр белән генә шөгыльләнәм дип, ничек инде бәлагә тарыган, авыр хәлдә калган кешегә ярдәм кулы сузмыйсың ди?! Һәр көнне иртән эшкә килгәндә, мине инде Яшел Үзән районыннан берничә кеше көтеп тора. Берәүнең газиз улын Чечня сугышына җибәрәләр, икенчесе өенә газ кертә алмыйча тилмерә, өченчесе чирек гасыр буена фатир ала алмыйча иза чигә, дүртенчесенә пенсия бирмиләр, бишенчесенә... Саный китсәң, очына чыгарлык түгел. Һәммәсенә дә кулдан килгән кадәр ярдәм итәсе, кайгы-хәсрәтен уртаклашасы килә. Тырыша торгач, инде авылда мәчет салу артыннан йөргән иманлы затларга булыштым, хаксызга рәнҗетелгән сайлаучыларга кулдан килгән кадәр гаделлек табарга ярдәм иттем кебек. Татарстанның Чечняга җибәрелгән егетләрен туган якларына һәм Идел буе хәрби округына кире кайтару өчен шактый иза чигәргә, хәтта сугыш уты кабынган Грозныйга да барып чыгарга туры килде.

Моннан өч ел элек Татарстан Югары Советында «Телләр турында» Канун кабул ителгән иде. Бу законны мин үлем дәрәҗәсенә китереп җиткерелгән татар телен тергезү өчен кабул ителгән тарихи документ, милләтебез язмышын хәл итүче иң мөһим законнарыбызның берсе дип саныйм. Дөрес, бары тик бер телне – татар телен генә дәүләт теле дип игълан итүне даулаучылар да булды. Ләкин бу таләп ул вакыттагы реаль шартларга нигезләнмәгән, андый карарны кабул итү өчен депутатлар да, сайлаучылар да әзер түгел иде. Килер бер вакыт, бу мәсьәлә өлгереп җитеп, яңадан көн тәртибенә килеп басар дип уйлыйм. Ә бүген без бик зур кыенлыклар белән кабул ителгән шушы законыбызны гамәлгә ашырырга тиешбез.

Быел март аенда сайлаучылар белән очрашу вакытында миңа бу турыда кат-кат сораулар бирделәр, үзләренең теләк-фикерләрен әйттеләр, кырык меңнән артык татар яшәгән Яшел Үзән

районында мөстәкыйль татар газетасы чыкмаудан зарландылар, шушы мәсьәләне уңай хәл итүдә ярдәм кулы сузуымны үтенделәр.

Депутат булып сайланганнан соң, иң беренче эшем итеп мин хөкүмәт җитәкчеләренә, Яшел Үзән район һәм шәһәр хакимияте башлыгына мөрәҗәгать иттем, «Телләр турында»гы Законда татар теленең дубляж теле түгел, ә Дәүләт теле дип игълан ителүен әйтеп, мөстәкыйль татар газетасы чыгару мәсьәләсен хәл итүне сорадым. Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, хакимият башлыгы С. Когогин белән кат-кат очрашырга, мөстәкыйль татар газетасының кирәклеге хакында әңгәмәләр алып барырга туры килде. Президентыбыз М. Шәймиевкә бу турыда депутат гозере белән мөрәҗәгать иттем.

«Яшел Үзән» дигән шигъри исем белән аталган мөстәкыйль татар газетасы чыга башлавын шуңа күрә мин үзем өчен дә зур бәйрәм дип саныйм. Халкыбызга искиткеч күп талантлы язучылар, җырчылар, галимнәр, рәссамнар, композиторлар биргән Яшел Үзән районында дөньяга килгән милли газета тиз арада республикадагы иң популяр газеталарның берсенә әверелер дип ышанам. Ул халкыбызның чын дөрес тарихын өйрәнүдә, гореф-гадәтләребезне торгызуда, көннән-көн хәлсезләнә барган туган телебезне тергезүдә армый-талмый эшләр дип уйлыйм. Бу газета һәр татар гаиләсенең үз газетасы булырга, аның битләрендә ничә тонна тирес чыгару, ничә килограмм сөт саву турында гына түгел, ә кешеләрне борчыган бөтен проблемалар хакында да язылыр дип ышанам.

**– Разил әфәнде, депутат буларак, яңа газета аша үзегезнең сайлаучыларыгызга нинди әйтер сүзләрегез бар? Иҗат кешесе буларак Сезне җәмәгать эшләре кысрыкламыйммы?**

– Җәмәгать эшен мин һич кенә дә иҗат эшеннән аерып карый алмыйм. Әгәр дә көн саен кешеләр белән аралашмасам, аларның хәсрәт-кайгыларын, уй-борчуларын белмәсәм, аларны үземнекедәй итеп кабул итмәсәм, мин нәрсә турында һәм кем өчен әсәрләр яза алыр идем соң?! Язучы булуым миңа депутатлык эшчәнлегемдә ярдәм итсә, киресенчә, халык вәкиле булуым иҗатыма һәрчак азык биреп тора. Дөрес, барысын да эшләп бетерү өчен вакыт җитми. Өстәлемдә языла башлаган романым, пьесам, җырларым, шигырьләрем ята. Вакыт чыккан саен, кулга каләм алам. Аннары... мин гомер буе депутат булмам, бер вакыт, бөтен эшемне ташлап, бары тик иҗат белән генә шөгыльләнермен дип хыялланам. Ә бүгенге шау-шулы, ыгы-зыгылы, мәшәкатьле һәм гаҗәеп кызыклы көннәрем кайчан булса да кәгазьгә төшәр, романнарга, повестьларга, пьесаларга, җыр-шигырьләргә әверелер дип өметләнәм. Кыскасы, бүгенге көндә мин депутат һәм Милли китапханә директоры булып чын тормыш эчендә кайныйм, шул ук вакытта бүгенге һәм киләчәк иҗатым өчен мая да туплыйм.

Иң беренче, миңа ышаныч күрсәткәннәре өчен, әле яңа дөньяга килгән газета аша сайлаучыларыма чын күңелдән рәхмәт әйтәсем килә. Бу газетаны аларга бирәү дә күктән иңдермәде, алар аны үзләре сорап, таләп итеп алдылар. Шуңа күрә «Яшел Үзән» газетасы аларның һәммәсенең дә көтеп алган үз газеталары, якын киңәшчеләре, сердәшчеләре, булышчылары һәм дуслары булыр дип ышанам. Хәерле сәгатьтә, милләттәшләрем!

**– Татар теленең өлкән туган теле белән чып-чынлап тигез хокуклы булып әверелүе өчен һәр районда мөстәкыйль татар газетасы чыгару гына җитми бит әле. Сезнеңчә ничек, «Телләр турында»гы Канунны тормышка ашыру өчен тарткалаш тагын күпме дәвам итәр икән?**

– Моңа кадәр үзләрен «иң гадел демократ һәм интернационалист» дип атаган бик күп бәндәләрнең чыннан да кем икәнлекләрен «Телләр турында»гы Законны кабул иткәндә һәм бигрәк тә аны гамәлгә ашыра башлагач күрдек тә инде. Мәсәлән, депутат И. Грачёв, бу закон кабул ителә калса, Татарстанда олы гауга чыгачагы, хәтта Өченче бөтендөнья сугышы башлану мөмкинлеге булу белән куркытты. Үзебезнең милләттәшләребез арасында да татар теленең «кирәксезлеген» исбатлаучылар табылды. Билгеле, тора-бара аларның күбесе үз фикерләрен үзгәртергә мәҗбүр булдылар. Бу законның берничә милләтче яисә берничә дистә депутат теләге буенча гына түгел, ә тулы бер милләт таләбе белән аның киләчәк язмышы турында кайгыртып кабул ителүен төшенделәр.

«Телләр турында»гы Канун кабул ителгәннән соң эшләнгән эшләрне күрмәмешкә салышу дөрес булмас иде. Соңгы өч елда татар теле бераз тернәкләнеп аякка баса башлады: татар гимназияләре, лицейлары, колледжлары, мәктәпләре ачылды, яңа татар газеталары, журналлары дөньяга чыкты, көндәлек тормышта һәм дәүләт-хөкүмәт оешмаларында «татар» сүзе ешрак ишетелә башлады. Әмма ләкин эшләнгән эшләр белән чагыштырганда, эшләнәсе эшләребез бик күпкә артык. Без әле бүгенге көнгә кадәр татар телен югары уку йортларына кертә алмадык, парламентта, дәүләт оешмаларында татар теле һаман дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алмады. Иң мөһиме, татар теле хәтта үзебезнең туган республикабызда да яшәү һәм дөньяга танылу, «кеше булу» өчен кирәкле телгә әверелмәде. Бездә әле һаман да рус телен белмичә яшәү кыенрак, ә татар телен белмичә дә рәхәтләнеп яшәп һәм эшләп була. Шушы тигезсезлек бетерелмичә, Татарстанда ике тел чын мәгънәсендә дәүләт теленә әверелеп, бездә яшәүче һәр кеше рус һәм татар телләрен бертигез үзләштермичә торып, бу закон үз актуальлеген югалтмаска, бу проблема көн тәртибеннән алынмаска тиеш. Моның өчен иң беренче чиратта җитәкчеләребезнең бу мәсьәләгә йөз белән борылулары, аннан барыбер качып котылып булмасын бәгырьләре аша үткәрүләре кирәк. Тиешле финанс бүлеп бирелмичә, «Телләр турында»гы Канунны гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт комитеты оешмыйча торып, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәреп булмаячак.

**– Әле күптән түгел генә җөмһүриятебез халкы Татарстанның мөстәкыйльлек Декларациясе кабул ителүенә 5 ел тулу көнен зурлап билгеләп үтте. Татарстан суверенлыгын озак вакытлар танырга теләмәгән Рәсәй җитәкчеләре дә бу көнне үзләренең ышаныч сүзләрен җылы тойгылар белән төреп әйттеләр. Бу чыннан да безне танумы? Икейөзлеләнеп маташумы? Куркудан бераз артка чигенеп торумы? Гомумән, без чыннан да мөстәкыйльме соң? Бәйрәм көнне һава тутырып, күз явын алырдай итеп сибелгән фейерверк кебек кенә матур манзара түгелме бу?**

– Бәйсезлекне безгә бирәү дә бирмәс, бүләк тә итмәс, без аны үзебез яулап алырга тиеш. Бүгенге көндә мин Татарстанны, Конституциябездә язылганча, мөстәкыйль дәүләт дип әйтә алмас идем. Чын мөстәкыйльлек яулау өчен әле безгә бик күп көрәшергә, үзебезнең дүрт гасыр элек югалткан хокукларыбызны таләп итеп бик күп тарткалашырга туры килер. Моның өчен, бәлки, әле бер буынның гына мөмкинлекләре һәм вакыты җитеп бетмәс... Россия җитәкчеләренең котлау сүзләрендә мин үзем «Татарстан – мөстәкыйль дәүләт» дигән сүзләр күрмәдем. Ә инде теш арасыннан сытылып чыккан җөмләләрдә 12 декабрьдә булачак Думага сайлауларның һәм Чечня кайтавазының шәүләләрен генә төсмерләдем. Россия беркайчан да үз теләге белән империячел сәясәттән баш тартмаячак. Һәм шуңа күрә аннан бәйсезлек бирүне көтеп утыру бик зур беркатлылык булыр иде. Ә инде суверен республикабызны 5 еллыгы белән тәбрикләргә мәҗбүр булганнар икән, димәк, Татарстан белән исәпләшмичә булмый, камчы тоткан кулны вакытлыча артка яшереп торып, прәннеклесен алга сузарга ниятләгәннәрдер. Ләкин без бу прәннеккә, баштан сыйпауларга алданып, тоткан юлыбыздан тайпылмаска, моннан биш ел элек кабул иткән, «Дәүләт суверенлыгы турында»гы Декларациябезгә, Конституциябезгә, «Телләр турында»гы Кануныбызга тугрылыклы калырга тиешбез. Мөстәкыйльлек юлында әле без беренче адымыбызны гына атладык, алда безне зуррак эшләр, кыюрак адымнар көтә...

**– Шундый тәгъбир бар: һәр халыкның бөеклеген аның әдәбиятта һәм мәдәнияттә, фәндә һәм сәнгатьтә якты эз калдырган шәхесләре аша билгелиләр. Татар халкы андый шәхесләргә һәрвакыт бай булган. Сезгә, шагыйрь, драматург, мәдәният хезмәткәре һәм, ниһаять, депутат буларак, шундый сорау бирәсем килә: бүгенге парламент бу тармакта эшләүчеләргә, гомумән, зыялы ватандашларның тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга нинди өлеш кертә? Безнең мәдәниятебез ни хәлдә? Аңа караш нинди? Зур талантлар ачылу өчен, бәлки, ясалма киртәләрнең күбрәк булуы мәгъкульдер? Ни әйтсәң дә, үлемсез әсәрләрнең күбесе драматик вазгыять эчендә кайнаганда туа бит...**

– Дөньяның кайсы гына иленә барып чыксаң да, үзеңнең кайсы халыктан икәнлегеңне аңлата алмыйча тилмерәсең. Бигрәк тә татарның кем икәнен аңлату авыр. Әле күп җирдә безне татар-монголлар белән бутыйлар, бүген дә ат өстендә дала буйлап ихахайлап чабып йөрүче халык дип уйлыйлар. Бары тик балет остасы Рудольф Нуриев, галим Роальд Сәгъдиев, композитор Софья

Гобәйдуллина исемнәрен атагач кына, безнең кем икәнне аңлый башлыйлар. Дөрес, соңгы елларда Татарстанга игътибар артты, килеп-китеп йөрүчеләр дә ешайды, икътисади элемтәләребез дә киңәя төште. Ләкин безне әле барыбер бик аз беләләр һәм татарның без зурлаган бик күп атаклы уллары Татарстанның үзе өчен генә атаклы булып кала бирә, аларны олы дөнья йөзенә чыгару өчен тиешле чаралар күрелми.

Әдәбият-сәнгать әһелләренең яшәү һәм иҗат итү шартларына килсәк, алар торгынлык елларына караганда күпкә начарайды. Татар газета-журналлары ачылса да, гомумән алганда, аларның тиражлары кимеде, татарча китап чыгару буй җитмәслек проблемага әйләнде; иҗат хезмәте, язучы-рәссам-композитор һөнәре белән тамак туйдыру мөмкин булмаган эшкә әверелде. Дөрес, гонорарларны арттыру, әдәбият-сәнгать-мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклау турында бик яхшы хөкүмәт карарлары, президент указлары да чыкты. Шунысы кызганыч: бу карарларның күбесе һаман да кәгазьдә генә кала бирә. Әлеге дә баягы иң беренче чиратта «культурага, мәгарифкә акча җитми». Торгынлык елларында республика бюджетының өч проценты мәдәният ихтыяҗларына бүленеп бирелгән булса, «мөстәкыйль Татарстанда» ул бер процент дәрәҗәсенә төште. Бу хакта сөйли-сөйли минем инде телләрем талды, каннарына тоз сала торгач, инде шактый җитәкченең дошманына әйләнеп беттем бугай. Әмма әлегә артык үзгәреш күренми. Президент М. Шәймиев киләсе ел бюджетында культурага акчаны бермә-бер арттырырга вәгъдә бирде бирүен. Аның бу сүзләре фәрештәнең «амин» дигән вакытына туры килә генә күрсен инде.

Язучы кеше, сәнгать, иҗат кешесе – гадәттә катлаулы язмышлы кеше. Иҗат кешесе булу ул – бөтен дөнья белән, җәмгыять, яшәеш кануннары белән бәхәскә керү, аларны яхшы якка үзгәртергә омтылу. Шулай булгач, аңа ясалма киртәләр корып маташу иҗатына аяк чалу, аның болай да катлаулы тормышын чын-чынлап трагедиягә әйләндерү генә була. Иҗат кешесенә эшләү һәм яшәү өчен никадәр күбрәк шартлар тудырсаң, ул үз халкын дөньяга таныту өчен шулкадәр зуррак эшләр эшләячәк, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәчәк.

*Әңгәмәдәш Александр Филиппов*
*1995*

# ӨМЕТЛӘР АКЛАНСЫН ИДЕ

**– Татарстанның мөстәкыйльлек Декларациясе кабул ителүгә 6 ел тула. Декларация безгә нәрсә бирде соң?**

– 1990 елның 30 августы бүгенгедәй хәтердә әле. Ул көнне мине Югары Советның секретариатына сайлаганнар иде. Безгә төрле районнардан телеграммалар ява. Урамнан петицияләр керә. Ирек мәйданында меңнәрчә халык. Халыкның теләге, омтылышы зур иде, шунлыктан мин бу көнне искиткеч вакыйга буларак кабул иттем. Мөгаен, гомеремдә иң нык тәэсир иткән вакыйгаларның берсе шулдыр. Ул чагында шулкадәр беркатлы булганбыз инде, хискә бирелгәнбез, дөньялар үзгәреп китәр, җиңдек дип уйладык. Әткәйләрнең Берлинны алуы кебек. Әмма Декларация кабул итү безнең алдагы эшләрнең кечкенә генә адымы булган икән. Декларация кабул иткәндәге өметләрне акладыкмы икән дигән шик тә туа миндә. Өметләр зурдан иде. Ләкин чынбарлык башкачарак икән. Тулы мөстәкыйльлекне яулап алу бүгенге көндә мөмкин булмаган нәрсә кебек. Чөнки безнең кан тамырларыбыз Россиягә, БДБ илләренә бәйләнгән. Кайвакыт күңел сыкранса да, моның белән ризалашмый булмый.

**– Шулай да Декларация безгә берни дә бирмәде дип булмый бит.**

– Декларация безгә дәүләтчелегебезне торгыза башларга мөмкинлек бирде. Әлеге тормышыбыз яхшырмады. Рухи яктан да, башка яктан да артка киттек. Шулай да Татарстанны азмы-күпме дәүләт дип таный башладылар. Без үзебезне дә күпмедер дәрәҗәдә милләт дип таный башладык. Дөрес, мин үземне элек тә кеше дип саный идем. Әмма хәзер башкачарак инде. Мин үземне күпмедер бәйсезлек яулап алган дәүләтнең гражданы итеп хис итә башладым.

**– Хәзер чит илләрдә Татарстанны азмы-күпме беләләр.**

– Мин әле генә Төркиядән кайттым. Төркия – кардәш ил. Ләкин безне анда бик аз кеше белә. Бигрәк тә гади халык белми. Дөрес, Шәймиевне беләләр.

Суверенлык безгә үзебезне азмы-күпме ирекле кеше итеп сизәргә мөмкинлек бирде. Чит илләр белән турыдан-туры элемтәләр урнаштыруда да беренче адымнар ясалды.

Татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү буенча бераз алга китеш бар. Ләкин мин «Телләр турында»гы Законның үтәлешеннән тулысынча канәгать түгел әле. Программа 10 елга каралган иде. Вакыт үтә. Акча бирелми. Узган ел 4 миллиард каралган иде. Аның яртысын гына бирделәр. Быел бюджеттан 5 миллиард билгеләнде. Хәзергә бер сум да бирмәделәр.

**– Аннары, бу акчаның кая киткәнлеген дә депутатлар төгәл ачыклый алмыйлар бит.**

– Әйе. Без сессияләрдә бәхәсләшеп күпмедер акча алабыз. Аның нинди максатка тотылуын белмибез. Югыйсә бит безнең парламент – иң югары закон чыгару һәм контроль органы. Без кулдан килгән кадәр законнар чыгарабыз, әмма аларның үтәлешен контрольдә тотмыйбыз. Шул ук «Телләр турында»гы Законны гына алыйк. Урамнарда, трамвайларда, вагоннарда азмы-күпме татарча сөйләшә башладылар. Ләкин әле бу бик аз. Самолётта очканда, поездларда йөргәндә, телне вата-сындыра белдерүләр укыйлар. Алар өчен оялам. Беткәнмени Татарстанда татарча белгән кеше. Һич югында, магнитофонга яздырт та шуны тыңлат. Айрат Арсланов кебек сүз осталары сөйләсен. Рәхәтләнеп тыңларлык, телнең матурлыгына сокланырлык булсын.

Мәктәпләр буенча да күп нәрсә эшлисе бар. Татар мәктәпләреннән балалар китә башлады. Әти-әниләр балаларын татарча укытудан баш тарталар. Чөнки татар теленең чын мәгънәсендә дәүләт теле булуына ышанмый башладылар. Дәүләт Советының Милли университет турында карар чыгаруына ике елдан артык вакыт үтте. Ә ул һаман юк.

**– Декларация СССР таркалганчы кабул ителгән иде. СССР таркалгач, кайберәүләр югалып калдылар кебек.**

– 70 ел буе мөстәкыйль яшәргә, уйларга өйрәнмәдек. Өстән кушканны үтәп килдек. Җитәкчеләребезнең дә күбесе мөстәкыйль уйларга өйрәнмәде әле. Әгәр кем дә булса мөстәкыйль фикер йөртә башлый икән, аның башына сугарга тырышабыз. Бөек акыл иясенең әйткән сүзе бар: «Әгәр дә кешеләрнең барысы да бертөсле уйлый икән, бер кеше дә бернәрсә дә уйламый».

Җитәкче мең төрле фикерне туплап, шуннан сөземтә чыгарып, акыллы нәтиҗә ясарга тиеш. Шунсыз җәмгыятьтә фикер үсеше, алга китеш була алмый. Бүгенге көндә җитәкчеләребез үз тирәләренә кем башын иеп сабыр гына тыңлап тора, анекдот сөйләгәндә эчен тота-тота көлә – шундыйларны җыя. Бу җитәкченең көчсезлегеннән, булдыксызлыгыннан килә. Аңа каршы сүз әйтмәсеннәр, аныңча гына эшләсеннәр, аныңча уйласыннар.

**– Декларация һәм Конституция буенча без Россия белән ассоциацияләшкән дәүләт, ягъни, тигез хокуклы дәүләт. Ләкин хәзергә ул тигезлек һич тә сизелми.**

– Әгәр дә безнең Конституциядә язылган әйберләр каршы як Конституциясендә юк икән, ул үтәлми. Россия Татарстанны мөстәкыйль дәүләт дип танымый, мөгаен, тиз генә танымас та.

Әгәр Мәскәүдән уртакул гына министр килсә дә, бөтен Татарстан куба, урамнарда транспорт хәрәкәте туктатыла. Халык эшкә бара алмый җәфа чигә. Тигезлек турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

**– Россия белән мөнәсәбәтләрне билгеләгәндә, куркаклык та бар кебек. Югыйсә Шартнамәдә, Россия һәм Татарстан бер-берсенең Конституцияләрен таный, диелгән.**

– Без Шартнамәне бер юрист белән укып утырган идек, анда логик яктан 100 дән артык җитешсезлек таптык. Шартнамәдә Россия һәм Татарстан хөкүмәтләре арасындагы 13 килешүдә безнең Конституция 103 мәртәбә бозыла. Хөкүмәт Шартнамә буенча эшли. Конституция икенче урынга төште. «Россия Татарстан Конституциясен таный» дигән җөмләне мин гомумән аңламыйм. Алар бер-берсенә каршы килә. Тану түгел бу, бары бер-береңә түзеп тору.

**– Татарстан Конституциясе буенча без Россия субъекты түгел, ә Россия Конституциясендә без субъектлар рәтендә.**

– Иң зур җитәкчеләребез дә Татарстан Россия субъекты дип ычкындыргаладылар. Мин игътибар белән күзәтәм: мондый сүзләрне президентыбыз гына әйтми. Башкалар кат-кат кабатлады. Мин җитәкчеләрнең хәлен дә яхшы аңлыйм. Әгәр дә артык кыю булсалар, аларның краннарын ябып куялар. Акча Мәскәүдә басыла. Тимер юллар, хокук органнары – барысы аныкы. Әмма ләкин бераз кыюрак булырга иде. Акыллы кыю. Мин җүләрләрчә күкрәк киереп йөрү ягында түгел. Дудаев кебек булу да бүгенге көндә шактый башсызлык. Шулай да аның егетлегенә сокланам. Аннары Дудаев артында бер миллион чечен халкы тора. Бер сызгырсаң, аның яртысы урамга йөгереп чыга. Ә бездә 10 кеше чыгар микән?!

**– Кайберәүләр 30 августны Татарстанның туган көне, республикага 6 яшь дип сөйли башладылар...**

– Бу уңайдан минем кешеләр белән бәхәсләшкәнем булды инде. Мәсәлән, язучы Әмирхан Еникигә 80 яшь, дибез. Ул бит тугач та яза башламаган. 30 яшьләрендә башлаган. Алайса, мин язучы Ә. Еникигә 50 яшь дип әйтергә тиеш булам. Татарстан «татар иле» дигән сүз. Ул 1990 елның 30 августында дөньяга килмәде. Татарстанның тарихы бик зур.

**– Суверен Татарстан депутатларының – Россия Федерациясе Дәүләт Думасында, ә җитәкчеләребезнең Федерация Советында утыруына ничек карыйсыз?**

– Әлбәттә, бу безнең Конституциягә туры килми. Әгәр биш ел элек кыюрак куйсак, Россия парламентына күзәтүчеләр җибәрергә мөмкин иде. Без ул вакытта Россия президентын сайламадык. Хәзер инде, урыс әйтмешли, «поезд ушёл».

Алты ел элек хыялланган хыялларыбыз тормышка ашмады шул. Промышленность җимерелде, рухи яктан төшенкелек, бөлгенлек, атыш-үтереш. Халыкның күңеле сүрелде. Андый халык эшкә бик атлыгып тормый, прогресска омтылмый. Аңа мөстәкыйльлегең дә, мәдәниятең дә кирәк түгел. Төп уе – ничек итеп тамак туйдыру.

**– Шартнамәнең, хөкүмәтара килешүләрнең, Конституциянең үтәлешенә Дәүләт Советы җавап бирергә тиеш. «Гражданлык турында»гы Закон кебек мөһим документларны һаман кабул итә алмыйбыз.**

– Парламентның роле нык кимеде. Ул – тыңлаучан, «олы агайлар» сүзеннән чыкмый торган парламент. Һәр кеше мөстәкыйль уйласа гына, мөстәкыйльлек була ала. Депутат булып утырган район җитәкчеләре мөстәкыйль уйлый алмыйлар. Чөнки алар турыдан-туры олы җитәкчеләргә

бәйле. Шунлыктан мин бу парламент Татарстан язмышын хәл итәрлек, дәүләтчелеген ныгытырлык законнар кабул итәр дип ышанмыйм.

Кабул ителә торган законнарыбызны Россиянеке белән тәңгәлләштерергә омтылабыз. Мин парламентның юридик идарәсе белән бәхәсләшеп арыдым инде. Алар тегесе – Россия законына, монысы Шартнамәгә каршы килә дип җәфалыйлар. Монда бер генә принцип булырга тиеш – безнең законнар Конституциябезгә туры килсен. 130 депутатны җыеп, Россиянең барлык законнары бездә гамәлдә дип карар чыгарыйк алайса. Россия законнарын аз-маз үзгәртеп күчереп утыра торган парламентның нигә кирәге бар?

Декларация кабул иткәндә өметләр зурдан иде шул. Читтә яшәүче татарлар бер милләт булып яшәрбез, бердәм мәгариф системасы, мәдәният учаклары, газета-журналларыбыз булыр дип өметләнгәннәр иде. Ләкин бу нәрсә әлегә барып чыкмый.

Чит илләрдә татарлардан бик бай эшкуарлар бар. Алар, Татарстан гражданлыгы бирелсә, йортлар, җир сатып алып, завод-фабрикалар салу, икътисадны алга җибәрү турында хыялланалар. Ләкин Казан безгә теше-тырнагы белән каршы тора, диләр. Шунлыктан гражданлык турындагы закон безнең иң төп законнарыбызның берсе булырга тиеш. Ничек инде ул – үзебез мөстәкыйль дәүләт, үзебезнең гражданлыгыбыз юк?! Димәк, безнең Конституциябез дә Декларация генә.

**– Законнар һаман рус телендә генә кабул ителә.**

– Законнарны ике телдә кабул итүнең бернинди катлаулылыгы юк. Закон бер телдә языла, аннары тәрҗемә ителә һәм, нигездә, кабул ителә. Хәзер синхрон тәрҗемә бар. Төзәтмәләрне ике телдә кертергә була. Кабул ителгән законны парламент аппараты ике-өч көндә тиешенчә тәрҗемә итә ала. Даими эшләүче парламент теләсә кайсы көнне җыелып аны кабул итә. Хәзергә татар телендәге законнар законсыз алар. Чөнки аларны парламентның кабул иткәне юк.

**– Разил әфәнде, Республика көне алдыннан укучыларыбызга нинди теләкләрегез бар?**

– Халык авыр яшәгән чорда бәйрәмне бик шау-шу белән үткәрмәскә дә булыр иде. Ләкин бәйрәм итмәскә дә ярамый. 1990 елгы 30 август искә төшә дә, күңелләр кузгалып китә, урамга чыгасы килә. Ул – безнең тарихи көнебез, Татарстан халкының язмышын борып җибәргән көн.

Без – иске системада тәрбияләнгән кешеләр. Шуңа күрә өметем яшьләрдә. Әгәр без мөстәкыйльлек юлын сайлаганбыз икән, ул халыкның бер өлешенең генә хыялы булмасын. Ә хәзергә күпчелек халык битараф. Без әкренләп-әкренләп мөстәкыйльлеккә барырга тиеш. Безнең башка юлыбыз юк.

*Әңгәмәдәш Әгъзам Фәйзрахманов*
*1996*

# ҮЗЕМ БУЛЫП КАЛА АЛСАМ, МИҢА ШУЛ ҖИТКӘН

**Нияз АКМАЛОВ.** Разил әфәнде! Сезне туган көнегез белән тәбрик итәм. Сез – Яңа ел башында, әмма гасыр уртасында туган кеше. Без Сезне чын милләтпәрвәр шагыйрь, язучы буларак беләбез. Бу милләтпәрвәрлекнең асылы-нигезе кайдан? Кемнән?

**Разил ВӘЛИЕВ.** Зурлавыгыз өчен рәхмәт. Юбилей көннәрендә матур ялган катыш мактау сүзләре һәркемгә дә әйтелә инде ул. Әмма бу каты бәгырьле заманда әллә нигә бер җылы сүз ишетү барыбер рәхәт. Кышкы зәмһәрир суыкта учак җылысына юлыккан кебек буласың...

Милләтпәрвәрлеккә килгәндә, ул һөнәр түгел, аңа өйрәнеп тә, өйрәтеп тә булмый. Милләтпәрвәр булу өчен хәтта кешелекнең бар акыл байлыгын үзләштерү дә җитми. Милләтпәрвәр ул – үзенең язмышын үз халкының язмышы белән бер итеп күргән, милләтенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгыртып, бар кылган гамәлләрен милләт файдасына багышлаган кеше.

Минем үземне авыз тутырып милләтпәрвәр дип атаганым юк, бу турыда үзең түгел, кешеләр әйтсә күңеллерәк булыр дим. Чынлап уйлаганда, минем шушы яшемә җитеп әле үземнең кем икәнлегемне төгәл белгәнем, кемлегемә төгәл атама таба алганым булмады. Дөнья шулай корылган инде, кеше турында чын бәяне ул фани дөньядан киткәч кенә әйтеп буладыр. Чөнки кеше исән чакта аның янәшәсендәге замандашлары, мең төрле сәбәпләр аркасында субъективлыктан арына, көндәшлек хиссиятеннән өскәрәк күтәрелә алмыйлар.

Әгәр дә инде сорауга төгәлрәк җавап бирсәк, мине шушындый итеп яраткан өчен мин иң әүвәл әти-әниемә, укытучыларыма, әби-бабайга, дусларыма һәм авылдашларыма бурычлы.

**Н. А.** Татарстанның баш китапханәсенә Милли китапханә исеме бирелү – исеме генә түгел җисеме дә шул – һичшиксез, Сезнең исем белән бәйләнгән. Тик, китап-китапханә дип сүз башласам, иң элек балачак искә төшә. Беренче кат укыган китаплар, беренче язылган шигырьләр... Китапның сезнең җандагы урыны, мәгънәсе, дәрәҗәсе кайдан? Кемнән? Кемнәрдән?

**Р. В.** Мин сигез балалы, әтиле-әниле, әбиле-бабайлы тулы-түгәрәк гаиләдә үстем. Һәм әле бүген дә чын татар гаиләсендә өч буын – әби-бабай, әти-әни һәм оныклар – бергә яшәргә тиеш дип саныйм. Чөнки бары тик шундый гаиләдә генә буыннар арасындагы җеп өзелми, гореф-гадәт һәм йолалар бозылмыйча, бер буыннан икенчесенә тапшырыла, туган телнең бөтен нечкәлекләре түгелми-чәчелми әби-бабайдан, әти-әнидән балаларга һәм оныкларга күчә. Апаларым дәрес әзерләгәндә яннарында утыра торгач, дүрт яшем тулганда укырга һәм язарга өйрәнгәнемне сизми дә калдым. Өйдә, түрдәге шкаф башында, ак сөлгегә төрелгән Коръән саклана иде. Әби белән бабай да, әнкәй дә еш кына аны кулларына алалар, вакытлар узып, битләренә чорлар сарысы иңгән Коръән белән авыз эченнән пышылдаша-пышылдаша эч серләрен бүлешәләр иде. Мин сабый. Коръәнне аңламыйм, анда ни язылганын белмим, әмма аның иң изге, иң кадерле китап икәнен эчтән генә төшенә идем. Мин ул чакта инде әкиятне кешеләр уйлап чыгарганны, китапны язучылар язганны да аңлый башлаган идем. Һәм мин үземнең сабый акылым белән бу Коръән китабын – Аллаһы Тәгалә үзе язган китап, ә Аллаһы Тәгаләне дөньядагы иң зур язучы дип уйлый идем. Менә шул заманнардан, дүрт яшьлек малай чагымнан бирле, мин Китапка изге нәрсә итеп карарга өйрәндем, китап иҗат итүчеләргә илаһи затлар дип табындым.

Ә авыл китапханәсе минем өчен оҗмахның бер бүлмәсе кебек иде! Мәктәп тәмамлаганчы, мин андагы берничә мең китапны «сөзеп чыктым», матур әдәбиятны укып бетергәч, хәтта техникага багышланган әдәбиятка, В. Ленин, К. Маркс томнарына ябыштым. Ул чактагы иң зур хыялым – үскәч китапханәче булу, һич югында, өйдә бик тә зур шәхси китапханә туплау иде. Дөрес, балачак хыяллары гел үзгәреп торды: соңрак гармунчы йә баянчы булырга, очучы һөнәрен үзләштерергә, дөнья буйлап сәяхәт итәргә дә ниятләдем. Әмма гомерем буена китап мине һәрчак озата йөрде, мин һәрвакыт китап белән янәшә булдым, бервакытта да китапка хыянәт итмәскә тырыштым.

Милләтебез язмышы турында уйлаганда һич кенә дә китап язмышы хакында фикер йөртми булдырып булмый. Әгәр дә татар халкы гасырлар зилзиләсендә бөтенләй адашып, югалып, юкка чыгып бетмәгән икән, аны милләт булып саклап калуда иң беренче чиратта ислам диненең, татар җыры, татар моңының, татар китабының әһәмияте әйтеп бетергесез зур.

**Н. А.** Соңгы елларда (соңгы елларда гына микән?) күп кенә әдипләребезгә – әйтер сүзен каләм аша әйтергә теләгән әдипләребезгә – турыдан-туры сәясәт белән шөгыльләнергә туры килде. Бу берьяктан аңлашыла да: сүз бит татар халкының гасырлардан килгән өмете – мөстәкыйль дәүләтчелеге турында бара. Әмма кулында каләм булган, йөрәгендә-җанында шигъри аһәң булган кешенең вакытын-көчен сәяси бәхәсләргә, алыш-бирешләргә сарыф итүе кызганыч та кебек. Ә бәлки, шушы вакыйгаларның үзәгендә булу иҗат өчен бер-бер җирлек тә бирәдер? Бу ыгы-зыгылы заманны кәгазьгә теркәп-төшереп барырга өлгерәсезме?

**Р. В.** Бу сорауны мин үз-үземә шулай ук бик еш кабатлыйм. Кайчакларда, сәясәтнең мәкерле һәм буталчык уеннарына кул селтәп, ак кәгазь белән бергә-бер каласы килгән вакытлар да була. Аннары уйлыйсың-уйлыйсың да, җанда кайнаган уй-хисләрне башкаларга да җиткерер өчен, милләт файдасына ниндидер гамәл кылу нияте белән уттай кызган трибунага тагын чыгып басасың...

Безгә кадәр дә татар язучысы һәрчак сәяси көрәшнең үзәгендә булган. Шул ук Тукайларны, Исхакыйларны, Ибраһимовларны, Такташларны, Җәлилләрне генә искә төшерик. Аларның берсе дә «коеп куйган шагыйрь» яисә язучы гына түгел. Эш монда әлеге дә баягы дәүләтчелеккә барып тоташа. Үз дәүләте булмаган милләтнең профессиональ сәясәтчеләре, милләт һәм дәүләтчелек мәнфәгатьләрен яклаучы махсус әзерлекле һөнәр ияләре була алмый. Шуңа күрә дәүләтсез милләттә үтә катлаулы бу йөкне тартып бару иң беренче чиратта язучылар, шагыйрьләр, мәгърифәтчеләр, галимнәр, сәнгать осталары җилкәсенә төшә. Бүгенге көндә милләтебезнең төп хыялы-идеясе булган дәүләтчелекне торгызу, нигездә, шулар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Татарстанның мөстәкыйльлеге, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү фикере дә иң беренче чиратта татар зыялылары тарафыннан күтәрелде.

Билгеле, кем әйтмешли, «сыер – абзарда, сатучы базарда булырга», ә язучы өстәл янына утырып язарга тиеш. Ләкин милләт язмышы хәл ителгәндә, тарих безгә дәүләтчелегебезне торгызырга соңгы мөмкинлекне биргәндә, ак кәгазь белән генә серләшеп калып булмый шул. Дөрес, язучы кеше шушы ук идеяне тормышка ашыру өчен үзенең әсәрләре белән көрәшергә, милләткә ярдәм итәргә тиеш. Ә вакыт көтми, әсәр язылып халыкка барып җиткәнче еллар уза, ә ул арада санаулы вакыт үтеп, мөмкинлек кулдан ычкынырга мөмкин. Ил, дәүләт, халык язмышы хәл ителгәндә каләмнәрен вакытлыча куеп торып, кулларына башка төрле корал алган әдипләр тарихыбызда шактый күп булган. Монда иң мөһиме ничек һәм нинди корал белән көрәшү түгел, ә нинди максат өчен көрәшү, шул максатка ничек итеп тизрәк ирешү. Минем үзем өчен өстәл янында утырып, бөтен гомеремне бары тик иҗатка гына багышлау җиңелрәк тә булыр иде. Иҗат кешесе ул үзенең вөҗданы, намусы белән ярашып яшәгән саф күңелле кеше булып кала ала, һич югында, моның өчен аның мөмкинлекләре бик зур. Ә инде сәясәттә үзең булып калу, үз намусыңа, халык өметенә, кешеләр ышанычына, милләт идеясенә хыянәт итмичә, төрле алдавыч «мәмиләргә» кызыгып башың әйләнмичә яисә өстәгеләрнең һәр төчкерүенә дер калтырап, ләббәйкә тотып утырмыйча, теләсә кайсы урында үз сүзеңне әйтә алу ай-һай авыр һәм шактый куркыныч нәрсә. Соңгы елларда сәясәткә башаяк кереп чумып, күпмедер дәрәҗәдә иҗат эшенә хилафлык килүенә үкенгән чакларым да, үз-үземне аклаган чакларым да булды. Әмма, нәрсә генә эшләсәм дә, минем бар кылган гамәлләрем бер нәрсәгә – милләт мәнфәгатен кайгыртуга барып тоташса, максатыма ирештем дип санар идем. Аннары, иҗат кешесе ул һәр эшкә дә иҗади карый. Мин инде шактый еллар буе сәясәт казанында күргәннәремне ак кәгазьгә төшерә барам. Казан бераз суынгач, мин бу шулпадан башкаларга да авыз иттерермен дип ниятлим.

Кыскасы, сәясәттә дә, иҗатта да намусыма, вөҗданыма хыянәт итмичә, үзем булып, Разил Вәлиев булып кала алсам, миңа шул җиткән. Мин берчакта да буй җитмәслек зур урыннарга, бал-майда йөзәрлек артык зур байлыкларга кызыкмадым, әмма үзем эшләгән теләсә кайсы эшне дөньядагы иң мөһим һәм кирәкле эш дип санадым.

**Н. А.** Соңгы елларда татар китабы эзеннән бик күп илләрдә булдыгыз, бу изге-олы хезмәтегез җәмәгатьчелек тарафыннан да югары бәяләнде. Төрки әдәбият галимнәре белән аралашу дәвамында шул илләрнең китап мәгарәләрендә безнең борынгы язмаларыбызның саклануы-сакланмавы хакында нинди мәгълүматлар табылды?

**Р. В.** Үзенең кулъязма һәм басма әдәбиятының байлыгы ягыннан татар халкы патша Русиясендә иң алдынгы урыннарның берсендә торган. Язма мирасыбызның язмышы белән кызыксына башлагач, Сез әйтмешли, шактый илләрдә дә йөреп кайткач, мин татар халкының, бу җәһәттән караганда, дөньядагы «олы милләтләр» белән янәшә тора алуына инандым. Әмма безнең бәһа биреп бетергесез байлыгыбыз, халкыбыз кебек үк, бөтен дөньяга чәчелеп, таралып беткән. Татарстанның баш китапханәсе Милли китапханә статусы алгач, язма мирасыбызны туплау һәм барлау өлкәсендә шактый эшләр эшләнде. Әмма бу эш гаҗәеп четерекле һәм катлаулы, бүгенге мөмкинлекләрдән генә чыгып гамәл кылганда, язма мирасыбызны барлап чыгу өчен безгә дистәләгән еллар кирәк булачак.

Моңарчы билгеле булмаган яисә билгеле булып та юкка чыккан, югалган дип саналган борынгы кулъязма яисә басма китапны табуны мин якут тундрасында алмаз яисә алтын табудан мөһимрәк эш дип санар идем. Төрле илләрнең китапханәләрендә булу, китапханәчеләр һәм китап галимнәре белән очрашулар нәтиҗәсендә мин Төркия, Финляндия, Украина, АКШ, Кытай һәм башка җөмһүриятләрнең китап «мәгарәләрендә» үзебезнең басма һәм язма мирасыбыз үрнәкләре саклануын белдем. Иран, Гыйрак, Әфганстан, Согуд Гарәбстаны кебек илләрдә, Урта Азия республикаларында да борынгы татар китабының шактый күп булуы хакында мәгълүматларыбыз бар.

Язма мирасыбызны барлауда олуг галимебез Әбрар ага Кәримуллин бәя биреп бетергесез зур эш башкарды. Әле күптән түгел генә академик Миркасыйм Госмановның Иран парламент китапханәсеннән Болгар чорына караган XIII гасыр кулъязмасының күчермәсен табып алып кайтуы да безнең өчен яңа бер табыш булды. Әмма язма байлыгыбызны эзләп табу һәм халыкка кайтару өлкәсендә дәүләт дәрәҗәсендә борчылу һәм кайгырту булмаса, очраклы табылган хәзинәләргә һәм галимнәребез фидакарьлегенә генә куанып яшәсәк, безнең рухи байлыгыбызның шактый өлеше әле тиз генә үз халкыбызга хезмәт итә алмаячак.

Галимнәребезнең күбесе әле һаман татар тарихын Болгар, Биләр һәм Казан Кремле тирәсеннән генә эзлиләр. Анысы да бик кирәкле эш, без әле шушы көнгә кадәр аяк астыбызда нәрсә ятканын да белеп бетермибез. Әмма безнең географиябез киңрәк, безнең тарихыбыз олырак. Әгәр дә инде без халкыбызны чыннан да зур халык, бай тарихлы, киләчәкле халык дип саныйбыз икән, аның бөтен җир йөзенә чәчелгән-сибелгән рухи хәзинәсен тупларга, өйрәнергә һәм исән-имин килеш алдагы буыннарга тапшырырга тиешбез.

**Н. А**. Мин алдарак милләтпәрвәрлек хакында сүз кузгаткан идем. Ләкин бит халыкка, милләткә, Сез әйткәнчә, төрлечә, төрле юллар белән хезмәт итеп була. Җир кешесе булып хезмәт итә кемдер, мөгаллим булып, гыйльми эш башкарып, халык аңының уяулыгы сагында торып... Кайчандыр татарның атаклы байлары да милләткә хезмәт иткән. Әгәр дә шундый бер мөмкинлек бирелсә (булса), Сез халыкка хезмәт итүнең кайсы юлын сайлар идегез?

**Р. В.** Инде әйткәнемчә, монда кем булып хезмәт итү түгел, ә нинди максатка хезмәт итү мөһимрәк. Мин язмышка ышанам. Язмыш миңа әдәбият-сәнгать, мәдәният, сәясәт тирәсендә булуны хуп күргән, мин шул өлкәдә кулдан килгәнчә эшләргә тырышам. Әгәр бүтән өлкәдә, бүтән урында эшләргә туры килсә дә, мин барыбер милләт кайгысын, милләт борчуын күз уңында тотып, үземнең эшемне иң кирәкле эш санап яшәр һәм хезмәт итәр идем. Әгәр язмыш кушып, урам себерүче булырга язса, мин үземнең урамны ялт иттереп себереп, Парижга яисә Лондонга Бөтендөнья урам себерүчеләр конгрессына барырга тырышыр идем. Ә инде чынлап та бара калсам, татарның чисталыгы, йорт-җирен дә, урамын да, авыл-каласын да, күңелен дә, намусын да чиста сакларга тырышуы хакында доклад сөйләр идем... Ярый, бу турыда бүген безнең урамнарны себерүчеләр уйласа яхшырак булыр, ә мин, күргәнегезчә, башка эшләр белән мәшгуль...

**Н. А.** Безнең сораулар барысы да иҗат, китап, тарих хакында булды кебек. Ә Сез соңгы утыз елда – иҗат юлыгызда – дистәләгән-йөзләгән олуг әдәбият-сәнгать әһелләре белән аралашып яшәдегез һәм яшисез. Әнә шул еллар дәвамында иң татлы һәм иң ачы мизгелләр дә булгандыр. Булдымы?

**Р. В.** Төнлә юлга чыкканда яисә урманга барганда, әнкәй миңа гел бер сүзләрне кабатлый иде: «Улым, курыкмыйм дисәң, күңеленә шом кермәсен дисәң, барган чакта артыңа борылып карама. Артыңда нәрсә булуын уйламаска тырыш, гел алга гына кара». Мин бу сүзләрнең тирән мәгънәсен үсә төшкән саен ныграк аңлый бардым. Әниемнең киңәшен истә тотып, мин хәзер дә үткән гомер турында мөмкин кадәр азрак уйларга тырышам. Дөрес, үткәннәрдән гыйбрәт алып яшәргә кирәк, әмма көне-төне үткән турында гына уйлап, газапланып яисә куанып яшәү миңа башын артка борып, алга таба барган кешене хәтерләтә сыман. Гомере буе кемгәдер үч тотып, мөмкинлек чыккан саен көндәшенә яисә каләмдәшенә аяк чалырга җай эзләп йөргән кешеләрне кызганам, аларның яхшылык эшлисе урында этлек кылырга сарыф ителгән гомерләрен җәллим. Урысның атаклы шагыйре, Мәскәүдә Әдәбият институтында укыганда минем остазым булган профессор Лев Ошанинның аталарча кайгыртып әйткән гыйбрәтле сүзләре әле хәзер дә истән чыкмый. «Разил, дошман миңа этлек эшли дип, зинһар өчен, үз күңеленә этлек кертә күрмә. Чөнки тора-бара ул этлек иң беренче чиратта үз күңелеңне, бәгыреңне кимереп, ашап бетерәчәк», – дигән иде ул.

Билгеле, бәгырьгә кагылган, җанны өзгәләгән сүзләр ишетергә дә, нахак бәла ягуларга түзәргә дә, шулар нәтиҗәсендә җиде ай буе хастаханәдә ятып, «әҗәл хәзрәтләре» белән кат-кат очрашырга да туры килде... Әмма мин бүген беркемгә дә үч сакламыйм. Мин боларның һәммәсен дә язмыш сынавы дип кабул итәм. Шул сынауларны исән-имин килеш җиңеп чыгып, шул көрәшләрдә чыныгып бүгенге көнгә килеп җитә алуым өчен язмышыма рәхмәт укыйм.

**Н. А.** Безнең халык бик күп фаҗигаләр кичергән! Әйтергә кирәк, бәхетсез халык, әмма аның бәхеткә лаек халык икәнен Сез үз иҗатыгыз аша да, парламент дәрәҗәсендә дә әйтә киләсез. Димәк, Сез халыкның киләчәгенә ышанасыз? Шул ышанычны ныгыту өчен бездән тагын нинди гамәлләр сорала дип уйлыйсыз?

**Р. В.** Нинди генә авыр хәлдә калганда да киләчәккә өмет сакламаган кеше яисә халык озын гомерле була алмый. Үз язмышына үзе хуҗа булган, үз туган телендә белем бирә, аралаша, эш йөртә, дәүләт белән идарә итә торган, дөньядагы башка мөстәкыйль дәүләтләр һәм милләтләр белән бер хокуктагы халык булу өчен безгә әле бик күп эшләргә һәм көрәшергә туры киләчәк. Бүгенге көндә кылган гамәлләребез никадәр генә мөһим булсалар да, алар әле безнең шушы юлда атлаган тәүге адымнарыбыз гына.

Әйе, мин халкымның хөр тормышка, бәхетле язмышка лаек икәненә җаным-тәнем белән ышанам. Әмма бу бәхеткә барып җитү өчен бер минем яисә берничә мең милләттәшемнең шулай уйлавы гына җитми, бу олы максатка бары тик халыкның күпчелек өлеше бер уй, бер хыял, бер максат белән яшәгәндә генә ирешергә мөмкин.

*Әңгәмәдәш Нияз Акмал*
*1997*

# КЕШЕ КАДЕРЕ БУЛМАГАН ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ЮК

**– Разил Исмәгыйлевич, Сез гәрчә Казанда яшәсәгез дә һәм күптөрле җәмәгать эшләре башкарсагыз да, ай саен үз сайлаучыларыгыз белән очрашырга Түбән Камага кайтырга да вакыт табасыз. Сайлаучыларына мондый игътибарлы депутат алар өчен күп нәрсә эшләргә өлгергәндер?**

– Сайланганыма озакламый ике ел тула. Сайлау алдыннан очрашулар вакытында үз сайлаучыларыма ай саен ким дигәндә бер мәртәбә кайтып кабул итәргә вәгъдә биргән идем. Кулдан килгән кадәр вәгъдәмне үтәргә тырышам! Бер урында кабул итәрмен дигән булсам да, аларга уңайлырак булсын өчен, ике урында кабул итәм. Һәр кайтуымда 70–80 кеше була. Беренче килүемдә хәтта 170 кеше булган иде. Бу, беренчедән, Түбән Кама төбәгендә проблемаларның күплеге турында сөйли. Икенчедән, халыкның депутатлар корпусына ышанычы зур булуын күрсәтә. Өченчедән, халык җирле хакимнәргә керә алмаганга депутатка килергә мәҗбүр. Җирле үзидарә, берләштерелгән Совет, предприятиеләр, завод җитәкчеләре хәл итәргә тиешле мәсьәләләр, гомумән, дөньяда нинди проблема бар – барысы белән дә депутатка киләләр, чөнки ул бердәнбер кереп була торган урын. Ә депутат мәсьәләләрне үзе генә хәл итә алмый, аның бернәрсәсе дә юк, шул ук предприятиеләргә һәм оешмаларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.

Килүчеләрнең күбесе пенсионерлар, чөнки иң яклаучысыз, иң ярдәмгә мохтаҗ катлам – алар. Мин шуңа да беренче чиратта яклаучысыз калган кешеләргә ярдәм итәргә тырышам. Йөз кешедән һәр унысы, хәл иттегез дип, рәхмәт әйтергә керә. Мәсәлән, бер апа, пенсиям 600 сум гына иде, хәзер 1000 сум ала башладым, дип, рәхмәт әйтергә килгән...

**– Сез Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә танылган шәхес. Республикабызның мөстәкыйльлеге өчен тырышучы, милләтпәрвәр шәхес татарны читтә таныту буенча да нindидер гамәлләр кыладыр?**

– Чит илләргә күп йөрим, дөнья күрергә түгел, иң беренче максатым бөтен Җир шарына сибелгән татарны бер милләт итеп берләштерү, татарның зур милләт булуын дөньяга таныту. ПЕН-клубны да шул максат белән оештырдык. Татар китапларын инглиз теленә тәрҗемә итеп, дөньяга таратуыбыз да шул максат белән эшләнә.

Халыкара конференцияләргә баргач, һәрвакыт татар халкы тарихы, мәдәнияте, без алып барган сәясәт турында сөйлим. Татарстанны белсеннәр, аның турында объектив бәя бирә алсыннар дип тырышам. Мин генә түгел, чит илләргә чыккан башка язучылар, галимнәр, сәясәтчеләр дә татар халкы һәм Татарстан турында сөйли. Татарстан дөнья базарына чыга алсын өчен дә аны белүләре, аңа ышанулары кирәк бит. Менә шул армый-талмый аңлатулар нәтиҗәсе буларак, чит илләрнең безгә карата фикерләре шактый үзгәрде, Татарстанга ышанычы артты, товарларыбызны алалар, инвестиция кертәләр.

**– Законнарыбызны Россиянекенә тәңгәлләштерү бара. Мәскәүнең басым ясавы аңлашыла. Ә без, аларга яраша-яраша, мөстәкыйльлек юлында яулангannarны югалтып бетермәбезме? Тагын ничәдер гасырга сузылачак коллык көтмәсме?**

– Андый куркыныч бар. Россия бүгенге көндә халыкларга басым ясауны бик нык көчәйтте. Ләкин аның бу юл белән баруы империяне саклап калу өчен соңгы көчәнүләре булыр дип уйлыйм. Чөнки бер генә империянең дә таркалмый калганы юк әле. Милләтләрне кысу ахыр чиктә шуңа илтә. Яшәргә, үсәргә шартлар тудырмый икән, кайсы халыкның анда изелеп яшисе килсен – ул шушы дәүләттән чыгу ягын караячак. Хокуклары кысыла икән, аннан ничек булса да котылырга теләячәк.

Бу күпкә бара торган сәясәт түгел: Россия милләтләргә йә ирек бирәчәк (конфедерациягә берләшәме яисә башкачамы), йә таркалачак – бүтән юлы юк.

**– Россия таркалырга җыенмый, ә татарларны таркату планы эшләнә бугай.**

– Минем кулга киләсе елда халык санын алуга кагылышлы бер документ килеп эләкте. Россия Фәннәр академиясенең этнология һәм антропология институты директоры В. Тишков әзерләгән аны. Бу документта халык санын алганда языласак халыклар һәм телләр исемлеге бирелгән. Анда милләтләр санын 34 кә арттыру каралган. Русларны түгел, нигездә, төрки һәм башка халыкларны бүлгәләү исәбенә. Татарларны биш милләткә һәм этносларга бүлгәләмәкчеләр: типтәр, керәшен, себер татары, ногайбәк, әстерхан татары, мишәр, болгар һ. б. Әгәр бу принцип белән барсак, урыстан кырык-илле милләт ясап булыр иде. Юк, урысларны бүлмиләр, киресенчә, урыс халкы турында аерым закон проекты эшләнде. Аны Россия Дәүләт Думасында тикшерүдә мин дә катнаштым. Проектта урысны бүлгәләмәү мәсьәләсе катгый куела.

Халык санын алганда, төрки халыкларны бүлгәләү турындагы әлеге документ буенча В. Тишковның үзенә хат яздым. Бу мәсьәләне Дәүләт Советында да уртага салып сөйләштек. Хәзер Россия хөкүмәте белән сөйләшүләр алып барабыз.

Татарның хәле Башкортстанда да бик авыр. Аны башкорт итү буенча шактый эшләр алып барыла. Татарның санын ничек итеп булса да киметү, аны таркату буенча Россиядә күп нәрсә эшләнә. Шуңа күрә бердәмлекне сакларга кирәклеге турында халыкка аңлату эше алып барабыз.

**– Сугыш барган урыннарга – Әфганстанга, Ичкериягә, Ингушетиягә баруларыгыз рухи һәм матди кыйммәтләргә, дөньяга яратылуыбызга карата уй-фикерләрегезне үзгәртмәдеме?**

– Бу илләрдә йөргәндә, кеше язмышы турында бөтенләй башкача уйлый башладым. Сугышның мәгънәсен аңларга тырышып карасам да, аңлый алмадым. Кешене изгелек, гаделлек алга әйдәргә тиеш. Әмма безнең тарихка күз салсаң, һәммә җирдә көч куллану. Дөньяга күзеңне ачып карасаң, гел үтереш, гел сугыш, гел яманлык... Әгәр җәмгыять, изгелекне, гаделлекне байрак итеп алып, милләтләргә, милли республикаларга йөз белән борылмаса, бу илдә берниндн алга китеш булмас.

Күп илләрдә булырга туры килде. Кая барсам да, бер нәрсәгә көнләшеп кайтам – аларда кеше кадере бар. Бездә кеше кадерсез. Кеше кадере булмаган җәмгыятьнең киләчәге юк.

Дәүләт идеологиясе концепциясен төзисе булса, төп критерий итеп кеше кадерен куяр идем. Бездә кешене аңлау түгел, хәтта тыңламыйлар да. Күкәйдән яңа чыккан җитәкчеләр сине кабул да итмиләр...

Америкада мин сенаторларга да, президент ярдәмчеләренә дә барып керәм. Барысы да тоткарлыксыз, ачык йөз белән каршы ала, игътибар белән тыңлый. Мин анда үземне кеше итеп хис итәм. Шулай да чит илләрдә яши алмас идем, чөнки үз илемдә үз халкым белән бергә бай рухлы булып, бер язмыш белән яшисем килә.

**– Америка дигәннән, «террорчыларга каршы көрәш» исеме астында Америка белән Россиянең якынаюына ничек карыйсыз?**

– 11 сентябрь фаҗигасе беркемне дә битараф калдырмагандыр. Шуннан бер атна гына элек үзем Америкада шул ике бина янында йөргәнгә, Рифат Табилар белән сәүдә үзәге янында фотога төшкәнгә, алар күз алдында тора...

Бу фаҗигагә репетиция күптән башланган инде. Егерме-утыз ел буена исламга каршы салкын сугыш алып барыла. (Башта ике система арасында барган иде салкын сугыш.) Дөньяда нинди генә начарлык эшләнсә дә, ислам дине, мөселман кешеләре белән китереп бәйлиләр. Исламның дөньяда беренче урынга күтәрелүеннән курку «террорчыларга каршы» көрәшне китереп чыгарды. Бэн Ладенның Америка кадәр Америкада шундый террор оештыра алганына ышанмыйм. Исламны көчсезләндерү, иң күпсанлы дин булуыннан мәхрүм итү өчен эшләнде кебек бу. Җинаятьче ачыкланмаган килеш, хәзер бөтен бер илне җимерү бара.

**– Сез – закон чыгаручы да, сәясәтче дә, милләтебез кайгысын кайгыртып йөрүче ялкынлы көрәшче дә, илче дисәк тә ярый. Барыннан да элек Сез – язучы, шагыйрь. Берьюлы поэзия, проза, драматургия жанрларында иҗат итүче киңкырлы талант. Бүгенге бу күпкырлы эшчәнлегегез бай материал бирәдер, аны иҗатыгызда файдаланырга вакыт таба аласызмы?**

– Дөресен әйткәндә, иҗатка вакыт бик аз кала. Әмма ләкин үкенмим, бүген кылган бөтен гамәлләрем бер тегермәнгә коя. Эшчәнлегем дә, иҗатым да татар халкына ярдәм итүгә

багышланган. Рухи капитал, язылачак әсәрләремә мая туплыйм. Һаман дәүләт эшендә эшләмәм. Алар киләчәк иҗатымда урын алачак.
Минем сәясәткә кереп китүем дә милләткә ярдәм итү, аңа мөмкин кадәр файдалы буласы килү теләгеннән иде. Татарстанда җитлеккән сәясәтчеләр булмаганлыктан, кереп китәргә туры килде. Әгәр бөтен яктан белемле, милләтпәрвәр кешеләр булса, депутатлыктан мин бүген китәргә әзер. Татарстанда андый сәясәтчеләр итеп Фәндәс Сафиуллинны, Рафаэль Хәкимовны һәм Индус Таһировны гына күрәм. Калганнары – сәясәткә очраклы рәвештә килгән кешеләр. Шулай да өметем зур: һәрьяктан әзерлекле, лаеклы яшьләр сәясәткә килми калмас.
Мин – өч чакырылыш Татарстан халык депутаты. Көндәлек алып барам. Киләчәктә роман-хроника язармын, Алла боерса. Иҗатка килгәндә, махсус язып утырырга вакыт юк. Мин юлда – машинада, поездда, хәтта сессиядә дә язам, фикер килүгә, теркәп куям.

*Әңгәмәдәш Зөлхия Дәүләтшина*
*2001*

# АЗАТЛЫК АЛУЫБЫЗГА
# ИХЛАСТАН ЫШАНГАН ИДЕМ

***(Тәфсилле әңгәмә)***

*19 апрель календарьда берничек тә тамгаланмастыр. Әмма ул көнне һәр татар кешесе хәтерләп калырга тиеш. 2002 елның 19 апрелендә Татарстан Дәүләт Советы Татарстан Конституциясенең яңа редакциясен кабул итте. 438 еллык коллыктан соң килгән 12 еллык беркадәр хөр чорга шул рәвешле нокта куелды.*
*Иң якты тарихи хатирәләребезнең берсе булып калачак әлеге 12 елны һәм тулаем татар язмышын мин бер кеше язмышы аша күрсәтергә булдым. Бу кеше — Татарстан Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары, язучы Разил Исмәгыйль улы Вәлиев.*

## Кызыл Позиция урамы, 6а...

**– Әлеге әңгәмәне мин... ошбу эшнең остасы, ата әңгәмәче белән үткәрәм икән. Син бит инде, Разил, ничә ел рәттән Татарстан телевидениесендә «Бер алманы бишкә бүләек» дигән әңгәмәләр шәлкемен алып барасың. Һәм әле, җитмәсә, үзең дә интервью арты интервью биреп торасың. Бер тапкыр шулай, яныңнан үтеп барган президент: «Разил тагын интервью бирә!» – дигәч, нәрсә дип әйткән идең әле син?**
– Әйе, сессиядә, тәнәфес вакытында Минтимер Шәрипович: «Тагын интервью бирәсеңмени, Разил?» – дигән иде шул. Мин әйтәм, башка бирер нәрсәм булмагач, интервью бирәм инде!
**– Биреп бетермәдеңме соң әле? Миңа да калдымы?**
– Бар әле, бар. Сиңа дип иң шәбен саклап тоттым.
**– Уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, Разил, менә бу өстәл янында кара-каршы утырып гәп коруыбыз минем өчен гаҗәп бер эш. 1965 елны, университетта бер группада укып, бер бүлмәдә яшәп ятканда, Разил берзаман түрә булыр да, син аның кабинетына интервью алырга барырсың, дисәләр, бу миңа бик кызык тоелыр иде.**
– Рәфикъ, синең бу фикерең белән тулысынча килешәм мин. Түрә булырмын дип үзем дә уйламаган идем. Һәм әле... шушы яшемә җитеп, нинди генә урыннарда утырсам да, үземне түрә, начальник итеп хис иткән дә булмады анысы.
**– Чабатаңны түргә элмәгәнне беләм, Разил! Чөнки моның үземә кагылышлы, беркайчан да онытылмаячак дәлилләре бар.**
– Кызыл Позиция урамындагы 2 нче тулай торакның 27 нче бүлмәсендә яшәгәндә нинди булсам, мин хәзер дә шул Разил әле. Күпмедер җүләрлек, күпмедер романтиклык – болар бөтенесе дә минем холыкта калды... Син дә үзгәрмәдең. Шулхәтле дә принципиаль кеше идең син. Бәхәстә беркайчан да үз сүзеңне бирмәдең, чөнки сүзеңнең хаклыгына инана идең... Зөлфәт тә шул ук Зөлфәт, бары шагыйрь буларак үсә-камилләшә генә барды... Димәк, инде шул вакытта ук күңелләребезгә оеткы шәп салынган, без ул чакта ук инде үз юлыбызны тапкан кешеләр булганбыз.
**– Ул 27 нче бүлмәне син «Эт кояшы» дигән повестеңда әдәбиятка да теркәп калдырдың бит. Егерме бер яшеңдә үк язган, ул заманда беркайда да басыла алмаган «кара» әсәреңдә.**
– Әйе, әйе.
**– Син анда яшьли дөнья куйган җете талант Фәрит Гыйльмине дә бик матур тасвирлагансың... Хәер, ул 27 нче бүлмәбез... үзе дә «мәрхүм» бит инде.**
– Ни булган аңа? Шул тирәдән узганда, мин гел аның тәрәзәсенә карап китәм. Беренче кат бит инде, сулдан беренче тәрәзә.
**– Тәрәзә шул ук анысы. Тик... Кырый дүрт бүлмәне – 25 тән 28 гә кадәр – кушканнар да...**
– Безгә музей ясамаганнардыр ич? *(Көлә.)*

**– Юк шул, зур бер ял бүлмәсе ясаганнар. Югыйсә музей ачканда да ярыйсы икән. Соңгы өч елны мин 26 нчы бүлмәдә Илдус Гыйләҗев белән тордым. Орденлы колхоз рәисе һәм ару гына шагыйрь чыкты бит үзеннән. 27 нчедә, почмак бүлмә, Мөдәррис Әгъләметдинов яшәде дип хәтердә калган... Ә син безне ул 27 нче бүлмәдән нигә сөргәннәрен беләсеңме? Беренче курстан соң?**

– Бер фикер бар миндә үзе, ялгыш түгел микән? Йә, башта син әйт әле.

**– Комендант Малофеев, тәртип булмаган өчен, дигән иде.**

– Үрнәк тәртип булмады инде анда, әйе.

**– Әмма шаккатарлык тәртипсезлекләр дә булмады. Йөзләгән бүлмә арасыннан бер безне генә куып тараттылар бит! Икенче елны тулай торактан бөтенләй урын да бирмәделәр.**

– Чынлап та, артык каты кыландылар шул. Нигә икән?

**– Минем үземнең дә башка әле яңарак кына барып җитте бу. Хәтерлисеңме, без бит бүлмәдә стена гәҗите чыгара идек.**

– Әйе, әйе, «Фанатик» дигән.

**– Ә стена гәҗитләре ул заманда зур нәрсә санала иде. Аларның һәркайсының өске ягында девиз тора иде: «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» Ныклы контрольдә иде алар. Факультет гәҗитен, әнә, элгәнче, берәр партбюро әгъзасы соңгы ноктасына хәтле укып чыга торган иде. Ә монда... тулай торакның ниндидер бер бүлмәсендә гәҗит чыгып ятсын әле! «Фанатик» атлы!**

– Әйе шул, минем бу кадәресен уйлаган юк иде әле.

**– Ә син, нигә кудылар, дигән идең?**

– Җәй көне булды бу эш. Син ул чакта каникулда идең микән?

**– Ул җәйне мин төзелеш отрядында эшләгән идем.**

– Без Зөлфәтләр белән чиләккә салып шигырь китаплары яндырдык. Мәхмүт Хөсәен, Нур Гайсин, Галимҗан Латыйп, тагын кемнәрнеңдер китапларын. 10–15 китап. Шигърият мондый булырга тиеш түгел, дип.

**– Кыз-зык! Беренче ишетүем. Ут-күз чыгу куркынычы булмагандыр бит?**

– Төтен исе килә, дип кереп әйттеләр анысы. Ачуландылар. Тик бер куркынычы да юк иде. Чиләктә бит ул. Китаплары да бәләкәй әле аның.

**– Әмма мәгънәсе зур булган. Манифест инде бу! Татар әдәбияты тарихына кереп калырлык гамәл!.. Ләкин искене яндыру гына түгел, яңаны булдыру да барды бит безнең 27 нче, 28 нче бүлмәләрдә... Минем иске калыпта шигырьләр әтмәлләвемнән көлеп, Зөлфәт «Фанатик»та «шап та шоп кирпеч суга» дип язган иде. Бу чакта «Казан утлары»нда аның бөтенләй башка рухтагы шигырьләре басылып өлгергән иде инде. Мөдәрриснең дә ай үсәсен көн үскән чагы... Син исә баш-аягың белән экспериментларга чумдың. «Фанатик»ның 2 нче санында бугай:**

**Минем эти**
**Тарих тәгәрмәченә**
**Тимер кыршау кидергәндә**
**Тапталып үлде, –**

**дип башланган шигырең басылган иде. «Җир шарына утырып тәмәке төрдем, Җир шарына басып сүндердем» дигән «гади генә» нәмәрсәң дә никтер һаман онытылмый әнә... Тагын шул искә төште, Разил. Биш җан, биш холык – бәп-бәләкәй бүлмәгә сыеп яшәргә дә кирәк бит әле. Син аю гәүдәле, әтиең Зур Исмәгыйль кебектер инде, җитмәсә, дуамал-усал да күренәсең... Бер кичне шулай караватка капланып үксеп-калтыранып елаганыңны күрдек тә шаккаттык. Бөтенләй бүтән Разил ачылды безгә... 37 ел үткәч булса да әйт әле: нигә елаган идең син ул чакны? Теге «Эт кояшы»ндагы мәхәббәт линиясе шаукымы булмагандыр бит бу?**

– Елаганны хәтерләмим дә инде... Юк, «Эт кояшы»нда сурәтләнгән хәлләргә бәйле түгел, тик барыбер дә «мәхәббәт линиясе»дер инде. Бер мәхәббәт трагедиясе булып алган иде минем.

**– Сине түрә, кемнәрдер әйтмешли, «дәүләт эшлеклесе» булырсың дип уйламасам да, студент Разилдә депутат Разил чалымнары бар иде анысы. Минем белән чагыштырсаң, бу бигрәк тә ачык күренә. Син ничектер хөррәк, бәйсезрәк идең. Иң гаҗәбе шул тагын: син реаль тормышны, чынбарлыкны миңа караганда шәбрәк белә, дөресрәк аңлый идең. Әйтерсең лә синең – «мәктәп чебеше»нең – тормыш тәҗрибәсе минем ике ел эшләп, армияләрдән урап кайткан егетнекенә караганда зуррак иде! Нидән бу, Разил?**

– Чыннан да, Рәфикъ, сиңа караганда яшьрәк булсам да, минем шактый гына күңел тәҗрибәсе бар иде шул. Үз-үземне аңлый башлаганнан бирле хәтерлим, әткәй белән әнкәй туктаусыз бәхәсләшә торганнар иде. Әнкәй бик диндар кеше, әнисе ягыннан нәселе – муллалар. Ул Коръәнгә таянып, дингә таянып сөйли. Әткәй – коммунист. Сугыштан яраланып кайткач, аны колхоз рәисе итеп куялар. Артыгы белән дөрес кеше иде әткәй. Ачуны китерерлек дәрәҗәдә. Тарантаста ялгышып кына бер кочак печән кайткан булса, аны инде колхоз абзарына илтеп калдырыр. Мин тыңлыйм – әнкәй сөйләгән дә дөрес кебек, әткәй сөйләгән дә дөрес кебек. Ләкин икесе ике төрле дөрес. Тагын бабай да бар бит әле – әнкәйнең әтисе. Бәхәскә әнкәй ягыннан ул да кушыла. Бабайның заманында тегермәне булган. Су тегермәне. Биш бертуган бергәләп салганнар аны. Раскулачивание башлангач, бар булган милекләрен алалар, ике катлы йортларын күрше авылга күчереп, авыл Советы ясыйлар. Әмма ләкин үзләрен сөрмиләр. Авыл халкы җыен җыеп алып кала. Чөнки, беренчедән, яллы хезмәт кулланмаганнар, икенчедән, аларны җибәрсәң, тегермәндә эшли белүче кеше юк.

Бабай гомере буена шушы тегермәндә эшләде. Колхозга кермәде үзе. Шул колхозга кермәгән аркасында бәрәңге дә утырттырмыйлар, малларын да көтүгә чыгарттырмыйлар, пенсиясез дә кала... Ә әткәйне туктаусыз райкомга чакыртып сүгәләр: «Менә синең авылда колхозга кермәгән бер кеше бар!» Ул «бер кеше»нең аңа кем тигәнлеген белеп алгач, коры сүздән инде выговорларга күчәләр...

Гомере буе безнең идеологиягә каршы сөйләде бабай. Шулай дип тә әйтә торган иде: «Юк, тормыш болай бара алмый. Дин бетте, кешенең кадере бетте, җирнең кадере бетте. Барыбер комга терәләчәк, элеккегә әйләнеп кайтачак әле ул».

Мин менә шуларны ишетеп-күреп үстем инде.

**– Көнләшәм мин синнән, Разил! Мин исә тырыш укучы, тәртипле малай идем. Кайбер нәрсәләрне аңласам, ә кайберләрен аңларга якын торсам да, мин барыбер дә ике үлчәмле, «кызыл», советча дөньяда үстем... Синең бабаң ничәнче елгы иде ул?**

– 1886 елгы.

**– Ә минем әти 1877 елгы. Ул миңа бик күп нәрсәләр сөйли ала иде. Ләкин берни дә сөйләмәде. Минем өчен курыккандыр инде. Үләр алдыннан гына нәрсәдер әйтәсе килде – әйтеп өлгермәде... Әгәр дә мин шулай нәселебез рухиятеннән киселеп калмаган булсам, безнең 27 нче бүлмәдәге аралашуларыбыз бөтенләй бүтән кимәлдә, күпкә мәгънәлерәк үткән булыр иде.**

– Нишләмәк кирәк, бик күпләргә хас югалту инде бу.

**– Безнең бөтен буынга хас фаҗига. Минем язмыш закончалык чагылышы булып, синеке аннан бер чыгарма гына шул...**

**Әүвәлге сәясәт дәресләрен гаиләдә алгансың, димәк. Милли аң дигәне дә шунда борнамадымы?**

– Гаиләдә дә, мәктәптә дә. Минем укытучылар да гел шәп булды. Туган авылым Ташлыкта – башлангыч мәктәптә дә. Андагы укытучыларымның берсе – Алмаз Хәмзинның әнисе Разия апа. Күрше Шәңгәлчедә дә. 9–11 классларны Түбән Камада укыдым. Ул чакта өр-яңа шәһәр бит инде. Безнең мәктәптә бик тә романтик рухлы укытучылар җыелган иде. Кызык шәхесләр. Гыйлем кешеләр – һәркайсы профессор шикелле. Бер Зыятдин Билалович Җәләлиевне генә алыйк. Физика укытты ул. Менә дигән спортчы үзе. Искиткеч шәп җырлый, искиткеч шәп итеп баянда уйный. Хор оештырып, Салих Сәйдәшевнең булган бөтен җырларын өйрәтеп бетерде безгә. Башка мәктәпләргә барып концертлар да куеп йөрдек хәтта. Алмаз Хәмзин хорда җырлый, ә мин – солист! 8 метрлы стена гәҗите чыгарабыз. Радиоузелга кадәр бар – һәр тәнәфестә шунда кереп

тапшырулар алып барабыз. Кайвакытта радиоузелда кунып та калам. Язам шунда, радио тыңлыйм инде. «Азатлык» радиосын да тыңлыйм инде. Бер тапкыр шулай, кунып калгач, иртәнге якта, кнопкаларны ялгышып, «Азатлык» радиосы тапшыруын урамга җибәргәнмен.

**– Шәп!**

– Шәһәрдә бердәнбер радиоузел булганга, парад-демонстрацияләр вакытында урамга музыка җибәрерлек итеп көйләнгән иде ул. Берзаман, мыш-мыш килеп, директор Николай Максимович Максимов атылып килеп керде. Керәшен ул, бик тә тәртип ярата торган, акыллы, төпле кеше. Килеп тә керде, әйләндереп тә җибәрде. «Син мине төрмәдә черетергә телисеңмени?!» – ди. Ә мин нигә икәнен аңламыйм. Радио сөйләгәчтен, аны кеше тыңларга тиеш дип уйлыйм. Үпкәләп, аздан гына бүтән мәктәпкә күчмичә калдым.

Дөресен генә әйткәндә, авылда чакта мин милләткә бүленүне аңламый идем. Түбән Камада инде татар белән урыс арасындагы кайбер кытыршылыкларны да күрдем. Без, авылдан килгәннәр, бер класста 12 бала: 7 малай, 5 кыз. Шәһәрнекеләр башта, «деревня», «татарва» дип бик каты кыерсытырга маташтылар. Аерым-аерым очратып кыйныйлар да иде. Ләкин без берләшеп алдык та беркемгә баш бирмәдек...

Бусы элегрәк әле: әнкәйләргә ияреп Алабугага әйбер алырга барганда, бик гарьләнә торган идем – урысча белмәгән аркасында каты бәрелүләрен тоеп. «Чего там калякаете?!» – дип кенә кычкыралар иде. Урамда авыз ачып сөйләшергә дә куркып йөргәннәрем хәтердә. Пышылдап кына сөйләшә торган идем. Әнкәйләр дә, Алабугага килеп кергәч, кысылып-бөрешеп кала торганнар иде. Ничек инде ул үз телеңдә сөйләшеп яшәп булмый икән дип бик аптырый торган идем.

**– Түбән Камада татар мәктәбендә укыгансыңдыр инде?**

– Юк шул, катнаш мәктәптә, классы гына татар классы. Анда да әле физика, математика кебек фәннәрне урысча укыттылар. Без Шәңгәлчедән бик яхшы укып килдек. Мин «дүртле» алуның ни икәнен белми идем. Һәм кинәт безнең нәтиҗәләр нык түбәнәйде – тел белмәгән аркасында гына. Мин моңа бик рәнҗедем. Менә шушы ике нәрсә инде – урамда кыерсытылу, мәктәптә кыерсытылу. Әле протест та, ни дә юк, бары күңелдә ниндидер дискомфорт, уңайсызлык. «Азатлык» радиосын тыңлый башлагач, күз ачылды аннан. Казанда исә милли ризасызлык хисе гел көчәя генә барды. Татар мәркәзендә бөтен нәрсә урысча гына язылган! Монда да бөтенесе чат урыс телендә генә сөйләшә! Татар журналисты булырга да урысча укырга мәҗбүрмен менә. Кыскасы, урыс белән татарның мөмкинлекләре бер түгеллеген ап-ачык аңладым.

**– Безнең 455 нче группага шактый көчле егетләр-кызлар җыелган иде. Бөтен СССРдан диярлек. Сөйләп җибәрсәләр, шаккатып тыңлап торасың. Менә шул егермеләп кешедән иң югары күтәрелгәне, иң зур эшләр майтарганы син булдың. Ә ул чакта дәресләрдә син, ләм-мим бер авыз сүз әйтмичә, уйга чумып утырыр идең – тәрәзә янында...**

– Укуга күңелем ятмады минем монда. Чөнки бөтен хыялым Мәскәүдәге Әдәбият институтына керү иде. Ләкин анда барырга кыюлык җитмәде. Беренче курста укыганда, Илдар Юзеев чакырып алып, минем бу хыялны тагын дөрләтеп җибәрде. Икенче курсны тәмамлагач киттем бит инде.

**– Үзеңә генә күңелсез булыр дипме, мине дә димләп йөрдең әле. Йә, мин бармыйча ни югалттым да, син барып ни оттың?**

– Син ни югалтканны белмим, мин үзем ирекне беренче тапкыр менә шунда – Әдәбият институтында татыдым. Хөр рухның, бәйсезлекнең ни-нәрсә икәнен аңладым. Без бит шулхәтле дә куркытылган. Тege ярамый, бу ярамый дип, авылда безнең гел кашык белән башка сугып тордылар. Казанга килдек – монда да чикләү өстенә чикләү. Сине кешегә санау юк, фикереңне тыңлау юк. Монда бит беркем беркемне тыңламый, начальник булмасаң. Әдәбият институтында исә гел башкача. Күренекле профессорларына кадәр синең белән исәнләшә, исәпләшә. Тулай торакта берүземә бер бүлмә бирделәр. Йә, иҗат дәрте тулы яшь егеткә тагын ни кирәк?

**– Дөньясында бердәнбер Әдәбият институтында хөрлек мәктәбе үтү депутат Вәлиевкә бик ярап куйгандыр анысы, ләкин ул хөрлек тә чамасыз булмагандыр, күрәсең. Югыйсә сыеша алмыйча нидер даулап йөрмәс идең.**

– Ә, әйе, шундый бер хәл булды шул. Беренче курста укыганда бу. Водолагин атлы профессор партия тарихын укыта. Сугыш вакытында Сталинград өлкә комитетында идеология секретаре булган кеше. Бер лекциясендә: «Крымские татары они все предатели», – диде бу. Шуннан соң: «Я с вами не согласен, не хочу вас слушать», – дидем дә торып чыгып киттем. Мине, һичшиксез, институттан куачаклар иде, шул коткарды: минем арттан – бурят шагыйре, аның артыннан – калмык язучысы, ә аларга ияреп монголлар, поляклар чыкты. Англиядән килгән бер негр бар иде – ул да чыкты. Халыкара ЧПга әйләнде бу, димәк. Мине ректорга чакырып бик каты сүктеләр сүгүен, әмма ләкин институтта калдырдылар.

**– Моңа янә бер ЧП, тагын да җиллерәге ялгана бит. Шул ук беренче курста укыганда, 1968 елның 25 мартында сез, Зөлфәт, Мирза Мансуров һәм син, Татарстан язучыларының VII съезды барган Камал театры балконыннан листовкалар ыргыттыгыз. Аларда төп таләп – татар телендә яшьләр журналы чыгару. Күчереп язып листовкаларны ишәйткәндә, аларның кайбер нөсхәләренә Татарстанга союздаш республика статусы бирү, мөстәкыйльлек бирү кебек сәяси таләпләр дә өстәлгән булган. Әлеге акция – яңа чор татар милли хәрәкәте тарихыннан иң тәвәккәл гамәлләрнең берсе. Эзсез калмады ул. Хәзер менә синең белән «Идел» атлы яшьләр журналы өчен гәп корып утыра алабыз икән, күпмедер дәрәҗәдә бу әнә шул акция нәтиҗәсе дә. Ә аны оештыручы син идең.**

– Бу хакта тәфсилләп язылды инде, син үзең үк яздың. Шуңа күрә сүз озайтып тормыйк. Шунысын гына әйтим: шул ук милли тигезсезлек, татар язучыларына басылыр урын аз булу этәрде бу эшкә. Әдәбият институтында укыганда, бу гаделсезлек миңа аермачык күренде.

**– Ә бу «операция»гә әзерлек шул ук Кызыл Позиция урамындагы тулай торакта барды бит инде.**

– Әйе, Зөлфәтләрнең 28 нче бүлмәсе аның штабы кебек булды.

**– 27 дән куылган Зөлфәт бер елдан шул почмак бүлмәгә урнашты, әйе...**

**Шуннан соң күп айлар, күп еллар үтте. 1999 елның көзендә без шул ук М. Горький урамындагы театр бинасында «Идел» журналының 10 еллыгын бәйрәм иттек... Бәйрәмнең сценариен әзерләгәндә, минем башка үземчә бер бик шәп идея «китереп сукты». Зөлфәт белән синнән шул ук балконнардан янә листовкалар ыргыттырырга! Бу юлы инде – котлау листовкалары. Зөлфәт ризалашты, әмма авырып китте, ә сине күндереп булмады. Хәтерлисең микән, шунда мин, сине оялтмакчы булып, болай дигән идем: «Әгәр дә теге студент Разилгә: «Сез даулаган журнал ачылып, аның унъеллыгында сиңа котлау листовкалары да ыргытырга туры киләчәк әле», – дисәләр, ул бит моңа дүрт куллап ризалашкан булыр иде!» Син моңсу гына елмайдың. «Моны эшләсәмме? Әллә нинди ямьсез якларын китереп чыгарачаклар». Ышанмадым. Бу матур эшнең нинди ямьсез ягын табып булсын икән? Әмма син хаклы булып чыктың. Котлау сүзендә шул листовкалар вакыйгасын телгә алып китүеңдә генә дә (безнең үтенеч буенча бит әле!) шаккаткыч тыйнаксызлык күрүчеләр табылды. Исләрем-акылларым китте. Заманында әлеге вакыйга бөтен иҗат интеллигенциясен тетрәндереп тә, бу каһарманлыкны эшләүчеләрнең онытылуы, матбугатта исемнәре генә дә аталмау искә төште. Шул уңайдан 5 ел элек үзем үк язган сүзләрне кабатлыйсы килеп китте: «Бу да татарның милли үзенчәлегенә бәйле бер нәрсә инде. Безгә каһарманлык һәм аның нәтиҗәләре кирәк, каһарманнар үзләре кирәкми. Кемнеңдер данга манылуы безнең өчен күрше гаражга яңа машина керү белән бер».**

## «Эчеңдә ачу туплама, Разил!»

**– Бер тапкыр син, хәл белергә баргачтын, җитәкче буларак үсеш линиясендә торган язучыдан «Кайсы аягың сынды соң?» дип сорагансың да, «сул аяк» дигәч, «Ай, бигрәкләр дә яза торган аягың икән шул!» дип, «хәленә кергәнсең». Юкса ахыры юньле булмасын да белеп торасың инде. Әмма шаярту шундый да җилле ки, ул инде синең авыздан үзе сикереп чыга! Әдәби иҗат та шундый нәрсә түгелме, Разил? Тыелып калып булмаганга язу түгелме?**

– Мин дә нәкъ шулай уйлыйм. Әгәр дә язмыйча калып булганны язасың икән, бу инде чын иҗат түгел. Кәсеп, һөнәр... Тормышта да еш кына шулай була: трибунаданмы, башкачамы – чәчрәп чыгып әйтмичә кала алмыйсың. Бусы инде чын хис, җан авазы. Кайбер кеше әйтмичә дә кала ала. Андыйлар инде...
**– ...ихлас яшәмиме?**
– Ихлас яшәми!
**– Дөнья артык каршылыклы. Һәр яхшының пылт итеп начар ягы килеп чыга. Таяныч дигәнең үзе какшап тора. Әйтик, гаделсезлеккә каршы беренче булып күтәрелгән милли хәрәкәт әйдәрләре миңа чын фидаиләр, изге затлар булып күренгән иде. Алай ук түгеллеге ачыкланды. Чеченнар дип җан аттык – аларның бөтенесе дә чиста булып кала алмады. Иң көчле (ә элек – бердәнбер) төрки мәмләкәт дип Төркиягә күз терәсәң, анда көрд дигән халык белән тарткалашып яталар. Дин кардәшләр дип гарәп дөньясына баксаң, аларда да шул бездәге таркаулык, берләшә алмау... Ә син нинди күңел кайтулар кичердең, Разил?**
– Университетта укыганда, бердәнбер ошаган дәрес диалектик материализм булды. Аны профессор Мансур Габдрахманов алып барды, беләсең инде.
**– Фәлсәфә буенча татар телендә дәреслек чыгарган кеше.**
– Әйе. Диаматны мин шигырь укыган кебек укыдым. Шуңа күрә дөньяның каршылыклы булуына исем китми. Яхшылык белән бергә начарлык та булырга тиешлекне аңлый идем мин. Әмма ләкин мин начарлыкның яхшылыктан күбрәк, көчлерәк булуын беркайчан да аңлый алмадым. Һәм тагын әле начарлыкның аңлы рәвештә эшләнүен аңлый алмадым. Ялгыш начарлык эшләргә дә мөмкин кайвакытта... Тик кешеләрнең шулхәтле дә кара эчле, явыз ниятле булуына һич ышанасы килми иде.
Тормышта бик рәнҗегән вакытым – минем өстән анонимка арты анонимка язылган чак... Мин әле Әфганстанда, иҗади командировкада. Ике ай булдым бит анда. Исән кайтаммы, юкмы – кем белә әле.
**– Син утырган бронетранспортёр каплангач, икенче туган көнең белән котлаганнар бит үзеңне.**
– Әйе, төрле хәлләр булды. Ә монда мине Язучылар берлегендә партия җыелышы җыеп тикшерәләр! Мин бик каты рәнҗедем. Авыруым көчәеп китүгә, бәлки, шул да сәбәп булгандыр. Җиде ай больницада яттым: 4 ай Казанда, 3 ай Мәскәүдә. Операция ясадылар да ябып куйдылар. Икенче тапкыр ясарга кеше таба алмадылар – юк андый врач. Хатыным соңыннан Медицина энциклопедиясеннән табып күрсәтте – минем авырудан дүрт ярым процент кеше генә исән кала икән. Мин бу дөнья белән хушлашкан идем инде.
**– Яшәү мәгънәсе турында яңача уйлау булмадымы?**
– Дөресен генә әйткәндә, яшәүнең мәгънәсе бөтенләй югалган иде. Ятасың көннәр буе. 18 килога ябыктым. Дөньяның бер кызыгы юк. Тәрәзәдән самолет очканын күрәсең. Нигә оча инде ул, нигә кирәге бар аның? Урамда трамвай дөберди – нигә дип йөри инде ул? Менә бу бимазалаучы чебеннәр ни пычагыма кирәк инде – шуларны уйлап ятам... Икенче операцияне миңа Япониядә укып кайткан бер табиб ясады. Әйбәт килеп чыкты. Югыйсә 7 ай эчендә Казанда һәм Мәскәүдә минем белән бер палатада 13 кеше ятты – 13 е дә үлде... Ә мин яңадан туган кебек булдым. Дөньяны бөтенләй бүтәнчә аңлый башладым.
Авырып ятканда, институттагы семинар җитәкчем Лев Иванович Ошанин миңа бик акыллы киңәш бирде. «Разиль, не копи в себе зло, зло тебя будет разъедать», – диде. Ул вакытта күңел нечкә, мин моны бик шәп хәтерләп калдым... Ачуым бөтенләй үк бетте дип әйтә алмыйм анысы, кайчакта хәзер дә усалланып алам. Ләкин теге кешеләрнең миңа карата кылган явызлыклары барьерның теге ягында калды инде. Аннары, сәясәткә кереп киткәч, мин башка төрле яманлык, явызлыкларны да күрә башладым. Болары инде кеше белән кеше арасында вак мөнәсәбәтләр генә түгел – милләт кадәр милләтләргә юнәлтелгән иде. Тегеләре кечерәеп калды шуннан соң.
Әмма, шөкер, яхшылыкны да татыдым. Мәскәүдә укыганда, өйләндем бит инде, беләсең. Кызыбыз туды.

**– Аны Сөембикә дип яздырыр өчен Мәскәү загслары белән даулашып йөргәнеңне дә беләм әле.**

– Әйе, булды. Теркәттек без ул исемне... Акча юк, яшәргә урын юк. Бер өч айлап эзли торгач, Перловка дигән станциядә иске дача таптым. Шунда юлда Л. И. Ошанин очрады. Килде дә: «Разиль, как дела?» – ди. «Нормально, Лев Иванович!» – «У тебя ведь дочка, оказывается, родилась. Как может быть нормально, тебе же стипендию не дали», – ди. Мин әйтәм, вакытлыча гына бит бу, бирерләр әле, дим. «Ладно», – диде дә кесәсеннән 200 сум акча чыгарып кулга тоттырды. «Купи подарки жене, дочери, поздравь от моего имени», – ди. Минем ул вакытта стипендия 28 сум!

**– 7 стипендия!**

– Минем өчен миллион инде бу. Киттем кибеткә, күчтәнәчләр, бүләкләр алдым.

**– Хатын алдында авторитет та артып китте бит инде.**

– Китмичә! Әле кем биргән бит!.. Акчаны алганда сорыйм инде: «Лев Иванович, а когда вернуть?!» – дим. «Когда разбогатеешь, тогда отдашь», – диде. Укыган килеш, макарон фабрикасына эшкә кердем, 65 сум түлиләр. Аның белән генә баеп булмады. АЗЛКда – теге «Москвич»лар чыгарган заводта – бер еллап эшләдем, эш хакы 95 сум. Кая ул, ашарга да җитми. Берзаман Казанда минем «Зәңгәр кабырчыклар» дигән китап чыкты. 800 тәңкә гонорар бирделәр – икегә бүлеп. Шунда 200 сум акчаны тоттым да йөгердем Лев Иванович янына: «Лев Иванович, вот долг отдаю». Карап-карап торды да: «Разиль, я у тебя эти деньги не возьму», – ди. «Нигә, – мин әйтәм, – баегач түләрсең дигән идегез, менә баедым мин!» «Ты, наверное, ослышался, я, наверное, сказал, когда станешь богаче меня», – диде дә тәки алмады.

**– Синең Әдәбият институтына китүеңә әллә ни кызыкмаган идем, Разил. Ә менә Ошанин шәкерте булуыңны белгәч, «Их!» дип куйдым. Аның җыр текстларын ярата идем мин. Гап-гади генә сүзләрне янәшә куя да, алардан шундый ятышлы вә мәгънәле, үзе җырлап торган нәрсә килеп чыга!**

**Эх, дороги!**
**Пыль да туман.**
**Холода, тревоги**
**Да степной бурьян...**

## Сыерлар гәҗит укыса, татар матбугаты да исән калыр иде ул

**– Син Чаллы Язучылар оешмасына җитәкчелек иткәндә, мәрхүм Рәис Беляев анда шәһәр комитетының беренче секретаре иде. Сине бик тә ихтирам итә иде бит. Татарстан өлкә комитетының идеология секретаре булып алгач, сине китапханәгә махсус куйгандыр әле ул. Шунда тынычта яраларын ялаштырып ятсын, көч тупласын дип.**

– Тагын ике урын тәкъдим иткәннәр иде: республика гәҗитенең баш редакторы урынбасары, китап нәшрияты директоры урынбасары... Китапханә мине чыннан да рухи яктан да, физик яктан да савыктырды. Чөнки, беренчедән, мин үзем яраткан урынга – китаплар арасына барып эләктем, икенчедән, эштән дә шәп дәва юк ул. Китапханә мине башланырга торган тагын бер чирдән дәвалады әле.

**– Анысы ни тагын?**

– Мәскәүләрдә укып кайттым бит инде.

**– Элитар институтта!**

– Әйе. Кемнәр белән генә аралашылмады анда... Бер-бер артлы китаплар да чыгып тора. Үз-үземә бик тә белдекле, укымышлы кеше булып тоела башладым берзаман. Китапханәдәге китапларны күздән кичердем. 3 миллион китап арасында йөреп, мин үземнең шыр надан икәнне аңладым! Мине лып итеп җиргә утыртты бу. Беркадәр сабырлык, басынкылык та өстәде...

Бик әйбәт коллективка килеп эләктем мин анда. Муеннан эшкә чумдым.

**– Моның нәтиҗәләре шундый да саллы ки, хәтта... язмышыңны бүтәнчә борып җибәргән теге анонимщикларга рәхмәт әйтергә кирәк түгел микән әле? Тфү, тфү, ялгыш сүз булды бу, чир газапларың истән чыккан...**
**Синең китапханә фасылыңа кагылышы бер сер бар, Разил.**
– Нинди сер икән ул?
**– Китапханәчеләреңне ничек итеп эш хакыннан баш тартулы акциягә күндерә алдың икән син? Өч айга сузылган акциягә! Хатын-кыз лабаса алар – һәрбер тиенне санап яшәргә күнеккән. Аларның да әле җан асрарлык кына – 60–80 тәңкә алып эшли торганнары.**
– Әйе, без забастовка игълан иттек. Җир шарында шуңарчы беркайда беркайчан булмаган забастовка: китапханәчеләребез эшне дә эшлиләр, акчасын да алмыйлар. 40–50 яшьлек, гомергә сәясәтнең ни икәнен белмәгән бу хатыннар, урамнарга чыгып, плакатлар күтәреп тә йөрделәр әле. Комсомол өлкә комитеты бинасын китапханәгә бирүне сорап. Хәзер үзләре дә шаккаталар, ничек шулай йөри алдык икән, диләр. Соңыннан, җаен табып, бу акчаны түләдем мин үзе. Сере гади инде моның: китапка ихтирам, үз эшеңә фанатикларча карау. Урын җитмәгәнлектән китаплар череп ята бит.
**– Китап череп ята... Татар борын заманнардан бирле түрдә, иң ару урында тоткан китап... Мәскәүгә алып кителгән Сөембикә китапханәсенең эзе табылмадымы әле, Разил?**
– Төрле экстрасенс ише затлар вакыт-вакыт килеп әйтәләр үзе. Мин аның кайдалыгын беләм, диләр.
**– Төрле җирдә итеп тә күрсәтәләрдер әле.**
– Әйе, төрле җирдә итеп... Минем үземнең бер шигем бар барын. Загорскида түгел микән ул?
**– Троицк-Сергеев лаврасындамы?**
– Әйе. Мин инде Патриарх всея Русига хат та яздырган идем – Лихачевтан. Василий Николаевич Федерация Советы рәисе урынбасары чакта. Җавап килмәде. Бу хәл шикне арттыра гына төште.
**– Ничегрәк язылган иде ул хат?**
– Сөембикә китапханәсе дип әйтмәдек без үзе. Анда Казан ханлыгы чорына караган китаплар була ала, безнең галимнәргә шуларны өйрәнергә мөмкинлек бирсәгез иде, дидек.
**– Чынлап та сәер хәл. Дин әһелләренә мондый илтифатсызлык хас түгел бугай бит. Теге Карл Маркс урамындагы бинада яңа бүлегегез ачылгач, укучы буларак миңа да рәхәт булып китте. Шунда күчкән гәҗит-журналларыгыз да иркенрәк тын алып җибәргәндер әле.**
– Китаплар да иркенрәк тын алсын өчен, искесеннән җиде мәртәбә зуррак бина кирәк шул.
**– Китапларны җәлләп мәйданга чыккан, тыйнак кына киенгән хатын-кызларыгызны да күз алдына китерәм, Разил. Сессияләрдә оеп утырган тук чырайлы чиновникларны да телевизордан күреп торабыз. Шуларның бәгыренә үткәзергә тырышып сөйләгән әрнүле сүзләреңдә истә. 12 ел рәттән сөйләгән сүзләрең! «Китап байлыклары безнекенә караганда 2–3 мәртәбә кимрәк булган Башкортстан, Мари Иле, Чувашстан республикаларында милли китапханәләр өчен безнекеннән 2–3 мәртәбә зуррак биналар салып куйдылар». «Россиянең «Мәдәният турында»гы Законында мәдәнияткә бюджетның 6 процентыннан да ким бирелмәскә тиеш, дип язылган... Торгынлык елларында да... мәдәнияткә 3 процент чамасы бүлеп бирелә торган булган... 1995 елгы бюджет проектында исә мәдәнияткә республика бюджетының 0,95 проценты тәгаенләнгән». «2000 елгы бюджетның гомуми күләме үткән елгыдан 54 процентка арткан, ә мәдәнияткә дигән өлеше 20 процентка кимегән». «Телебезне тергезер өчен 7,2 миллион сум акча каралган, Татарстанда яшәүче һәр кешегә уртача 1 сум 70 тиен туры килә бу. Әлеге акчага нәрсәдер тергезү түгел, хәтта бер дәфтәр генә дә сатып алып булмый». Боларга, Разил, мәшһүр Фасил Әхмәтов 1993 елда язган сүзләр дә бик матур ялгана: «Мин балаларыма, оныкларыма васыять итеп калдырачакмын: мин үлгәч теләсә нәрсә эшләгез, әмма ләкин берүк татар композиторы булмагыз... Мин, татар композиторы, бәхетсез һәм хәерче кеше».**
**Разил! «Камыр аяклы» булса да, син әйтмешли, суверенитет алган идек бит. Нигә кирәк булды безгә суверенитет? Иң әүвәл татар халкы башка халыклар кебек үсә алсын өчен. Ә**

**моның өчен иң кирәкле нәрсә – мәдәниятне үстерү. Һәм нәкъ менә шуңа акча табылмый. Ягъни, тиеш булганның капма-каршысы эшләнә. Нигә алай ул?**
– Нигәме? Җитәкчеләребезнең, бигрәк тә урта буын җитәкчеләрнең, интеллектуаль дәрәҗәсе түбән булганга. Министрларга кагыла бу. Хакимият башлыкларына кагыла, чөнки районнарда барысын да алар хәл итә. Элек, үзәкләштерелгән системада яшәгәндә, акча Мәдәният министрлыгында бүлеп бирелә иде. Анда беләләр инде – клубларга урындыклар кирәк, баяны, сәхнә киемнәре... Китапханәләргә дә шулай ук. Татарстан китап нәшриятында, башка нәшриятларда чыккан нинди китап кирәк – барысын да туплап, бибколлектор аша китапханәләргә җибәрә идек. Децентрализация дигән нәрсә башланып җирле үзидарә системасы кергәч, бу хокукларның барысын да җирле бюджетларга – районнарга, шәһәрләргә бирдек. Бер яктан караганда, бик әйбәт бу, демократиянең бер казанышы инде. Ләкин бит әле андагы җитәкчеләрнең әзерлеге тиешле дәрәҗәдә булу да кирәк. Хакимият башлыгы гомерендә бер китап та укымаган икән, ул инде акчага бүтән төрле урын да таба... Америка президенты әнә ел саен ил алдында хисап тота. Анда ул ничә тапкыр театрда, музейда булуын да, ничә китап укуын да әйтә... Безнең президентны һич гаепләп булмый. Ул театрга да йөри, музейларга да, китап та укый...
**– Шулай. Әмма үрнәк алмыйлар бит үзеннән. Син әйтмешли, мех кепкасын гына өлге иттеләр.**
– Шул гына, әйе. Хакимият башлыкларының күбесенең аң-белем дәрәҗәсе дә, әзерлек дәрәҗәсе дә бик түбән.
**– Өстән килә бит бу, Разил. Шундый кешеләрне эзлиләр! Берәү дә алардан, клубың, китапханәң ни хәлдә, милли культура ничек үсә, дип сорамый.**
– Мин күптән түгел бер хакимият башлыгы белән сөйләшеп утырдым. Мин әйтәм, хәлләр ничек сездә, халык саны артамы, кимиме? Кими шул менә, кими, ди. Нишләп, мин әйтәм, моңа ныгытып тотынмыйсыз? Моның өчен әйбәт туклану кирәктер инде, экология әйбәт булу, больницалар... Бөтенесе дөрес, барысын да беләбез, тик миннән моны сорамыйлар бит, ди. Халык саны кими дип, мине беркемнең дә сүккәне юк әле, ди. Менә берәр төрле чир чыгып 20–30 сыер йә дуңгыз үлсә, миңа выговор бирәләр яисә эштән үк куалар, ди.
Милли китапханәнең директоры чагында, авылга кайткач, бер классташ очрады. «Нихәл, Разил, китапханә төзедеңме әле?» – дип сорады. «Юк, төзеп булмады шул әлегә», – мин әйтәм. «Син аны төзи дә алмаячаксың», – ди сабакташ. «Нигә алай дип әйтәсең, менә бит монда сыерларга шәп кенә абзар төзеп куйгансыз, мөмкинлек бар, димәк», – дим. Җавапны һич онытасым юк. «Сыерларга була ул, сыерлар алар сөт бирә, ит бирә. Ә синең китапханәгә йөргән кешеләр сөт тә бирмиләр, ит тә бирмиләр, шуңа күрә аларга беркайчан да китапханә төземәячәкләр. Ә менә сыерлар китап укый белсә, аларга китапханә төзерләр иде». Шулай булып чыкты да. Китапханәгә яңа бина салырга җыенган кеше юк әле. Бу хакта хөкүмәтнең һәм парламентның инде 6 карары чыгуга да карамастан!
**– Милли университет ачу турында ничә карар кабул ителде әнә... Кая ул яңаны булдыру, татар матбугатын җимермәкчеләр бугай әле. Гәҗит-журналларга ярдәм күрсәтүдән туктау шул җимерү бит инде ул. Еллыгы 2–3 мең сум торган гәҗит яки журналга ничә генә кеше язылыр? Базар заманы, үтемле тауар чыгарырга кирәк, янәмәсе. Халыкны акчасыз калдырмаска кирәк иде, алайса. Татар телендә гәҗит укый алырлык татарларның санаулы гына, гомумтатар массасының делегатлары рәвешендә генә калуына кем гаепле, без гәҗит-журналчылармы? «Юлдаш» гәҗите үтемле тауар да әнә, ләкин татарның киләчәге өчен моның ише басма гына җитәрме? Халык тәҗрибәсен дәлил итмәкчеләр: сигез сыер асраганчы, симез сыер асра, янәсе. Симез матбугат сыерлары заманын күрдек инде, аларны кем савасын да беләбез... Кая илтә бу юл? Рәсәйдә бердәнбер «симез» тел, бердәнбер «симез» халык калдыру сәясәтенә ялгана ул.**
**Шулай менә, Разил, журнал даулап янә листовкаларга тотынырга туры килмәгәе монда...**
– Нык алга киткән дөнья илләрендә, чыннан да, гәҗит-журналлар үз иркенә куелган. Әмма ул илләрдә халыкның 100 проценты туган телләрендә укый-яза белә. Ә татарда мондыйлар 10

процент чамасы гына булса кирәк. Укый-яза белгәннәрнең 10 проценты гәҗит-журнал укыса, бу бик шәп күрсәткеч дип исәпләнә. Безнең теге 10 процентны да 10 га бүләргә кирәк, димәк. Бик аз сан чыга бит. Җитмәсә, боларның да шактые читтә киселеп калган, татар матбугатына языла алмый. Теге илләрдә чыгымнарның яртысын реклама капласа, татар телендәге гәҗит-журналларның бу җәһәттән мөмкинлекләре бик чикләнгән – реклама кулланучыларның күбесе урысча гына укый...
Бүгенге көндә халыкның рухы сүнеп бара – суверенитет барып чыкмады чөнки. Мәдәниятебез авыр хәлдә... Татар матбугатына үз көнен үзе күрергә кушу – урын өстендә яткан кешегә «Бар, акча эшлә дә үзеңә дару ал!» дип әйтү белән бер ул!

## «Ник дулкын китте ары?»

**– Илһам Шакиров синең сүзләргә җырлаган «Дулкын» дигән халык җырын белмәгән кеше бар микән? Ә менә ул сүзләргә салынган мәгънәне, яшерен мәгънәне белүчеләр күп түгелдер. Син әйткәнне дөрес хәтерләп калган булсам, революцияләр чорына килеп кергән, таркалган-сибелгән татар халкының фаҗигасе тасвирланган анда.**
– Шулайрак, әйе.
**– Шуны белгәч, болай да мәгънәле текст тагын да көчәеп китә:**

**Чем-кара карлыгачлары,**
**Гөнаһсыз иде яры.**
**Ник шунда гына калмады,**
**Ник дулкын китте ары?..**
**...Елга ярын сагынып елый**
**Диңгезнең дулкыннары...**

**Үткән гасыр азакларына таба вәзгыять янә үзгәрде. Балтыйк буе халыклары – латышлар, эстоннар, литвалылар – хөрлек җиленең беренче тын кагылышларын ук тоеп алдылар.**
**Сиксән ничәнчедер елда миңа Яңа елны Латвиядә, язучыларның «Дубулты» иҗат йортында каршыларга туры килде. Ашханәдә мәҗлес бара. Латыш музыкантлары безгә кәеф-сафа корырга булышалар. Кемнәр алар, нindирәк кешеләр, ни уйлыйлар – империянең каләм аристократиясен һич кызыксындырмый бу. Хезмәтчеләргә игътибар итеп торалар димени? Унике тулырга ничәдер минут кала, һич көтмәгәндә, «хезмәтчеләребез» уен коралларын идәнгә куйдылар, каяндыр бокаллар тартып чыгарып, аларга шәраб салдылар. Берсе тост әйтте: «За свободную Латвию!»**
**Татарга азатлык алай ук тансык түгел иде. Уянуның беренче билгесе яшь галим Рафаэль Мөхәммәтдиновның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар язмышы турында фикер алышулар үткәрә башлавы булды шикелле. Аннары шул ук институтта Татар иҗтимагый үзәге оешты. 1989 елда Югары Советның яңа составы сайлангач, дәүләт кимәлендә дә актив эш башланды. Шуннан соң инде азатлыкның онытылган татлы тәмен искә төшерүчеләр бик тиз ишәя барды.**
– Ул чакта мине дә, башка күпләрне дә эйфория биләп алды. Азатлыкка ирешәчәгебезгә ихластан ышанган идем мин. Мондый ышанычны ни бирде соң? Халык дәрәҗәсендә нәрсәгәдер ирешер өчен шул халыкның күпчелеге шундый фикердә булырга тиеш. 90 нчы еллар башында, минемчә, халыкның күпчелеге, аңлы күпчелеге – аның бит әле бөтенләй уйламый торганы да бар...
**– Иярүчеләр.**
– Әйе. Менә шул аңлы күпчелек Татарстанның дәүләтчелеген ныгыту ягына, мөстәкыйльлек ягына борылган иде. Бу ышанычка тагын СССРның таркалып баруы да куәт өстәде. Әмма булган мөмкинлекләрдән файдаланып җиткерә алмадык без. Мәңге шулай дәвам итәр дә, әкрен-әкрен генә, ашыкмыйча гына файдаланырбыз шунда дип уйладык бугай. «Йомшак керү»нең сәясәттәге варианты инде бу. «Гел болай бара алмый!» дип кисәтүчеләр булды булуын, әмма ләкин без

аларны ишетмәмешкә салыштык. Әгәр дә шушы ун елны акыллырак файдаланган булсак, без берничә баскыч югарырак күтәрелгән булыр идек.

**– Биектән егылып төшү...**

– Анысы да бар, биектән егылу – хәтәррәк, әмма ләкин ул чакта, бәлкем, егылмый да калган булыр идек әле.

**– Халыкның яклавы да гел бүтәнчә булыр иде, дисеңме?**

– Әйе, ул чакта халыкның милли аңы да ныклап уянган булыр иде, тормыш хәле ару булса, суверенитетны ул инде үз өен, үз милкен яклаган кебек яклар иде. Әмма ләкин... Кайбер даирәләргә ошамый торган сүз инде бу. Халыкның күпчелек өлеше бик нык хәерчеләнде шул. Бер бездә генә түгел, бөтен Рәсәйдә шулай шулаен. Тик барыбер дә халыкны ул дәрәҗәгә төшермәскә иде. Әллә каян гына күпме бай, миллионер-фәлән пәйда булды әнә. Шулар хисабыннан льготалар, ташламалар биреп булса да, халыкның менә шул өлешенең тормышын яхшыртырга кирәк иде... Җәмгыятьнең байларга-ярлыларга бүленүе үзе дә ничектер ипсезрәк, кыргыйрак формада барды. Районнарда йөрим бит, беләм: тракторчылар, комбайнчылар, башка һөнәр ияләренә әле премия-фәлән тамарга мөмкин – югары уңыш алу җәһәтеннән. Сыер савучылар, төзүчеләр, тагын кемнәрдер еллар буе хезмәт хакы күрми. Түләгәндә дә фуражлата, икмәкләтә түлиләр. «Яңа елга – 200 сум, Сабан туенда – 200 сум – ел буена алган акчабыз шул» – мондый сүзне күп җирдә әйтә алалардыр. Ә хуҗалык җитәкчеләре менә дигән машиналарда йөри, коттеджлар сала. Хакимият башлыклары «Мерседес»ларда җилдерә. Аның бәясе – 70 мең доллар. Ул 70 мең долларга бөтен районның укытучыларына, культура һәм медицина хезмәткәрләренә бер айлык хезмәт хакы биреп була. Кечерәк районнарда алай гына да түгел әле.

**– Ә бит халыкның тормышын, хәлен яхшырту суверенитет игълан итүнең төп максатларыннан берсе дип тәгаенләнгән иде.**

– Депутат буларак беләм мин: җитәкчеләр янына керә алмыйлар хәзер. Халык әйтә, торгынлык заманында атнага бер кабул итү көне бар иде, кереп гозерләребезне сөйли ала идек. Монда хәл итмәсәләр – Казанга, Казанда эшләмәсәләр, Мәскәүгә язып җибәрә идек, барыбер очына чыга торган идек, диләр.

**– Бу әңгәмә басылачак санда Зәки Зәйнуллинның документаль повесте бирелә, Разил. Клуб җыештыручы хатынның Брежневка приемга керүе дә тасвирлана анда. Кайтыр билетларына хәтле алып бирәләр үзенә – купейный вагонга.**

– Шул шул. Ә хәзер, хакимият башлыкларын әйтеп тә тормыйм, алардан түбәнрәкләр янына да еллар буена керә алмыйлар. Җәмгыятьтә тәртип бар иде, контроль бар иде, хәзер юк, ди халык.

**– Син кайчандыр шундый сүз әйткән идең: «Милли хәрәкәтнең фаҗигасе – хакимияткә килә алмау». Килеп ни майтарырлар иде дип уйлыйсың?**

– Теләсә кайсы партиянең, хәрәкәтнең максаты – хакимияткә килү. Ул бит үзенең ниятләрен башкача тормышка ашыра алмый. Милли идеяне урамда йөреп, Иҗтимагый үзәктә 12–15 кеше җыелып кына гамәлгә ашырып булмый ул. Рафаэль Хәким хакимияткә милли хәрәкәттән килде әнә. Күп кенә эшләр майтарды. Әгәр дә тагын шундый 10–15 кеше килгән булсамы, министр урынбасарлары, министрлар булып?! Милли җанлы, татар халкы һәм Татарстан язмышына битараф булмаган кешеләр. Битарафларга алмашка.

**– Битарафларга, бармагы үзенә кәкреләргә, ялагайларга алмашка... Ләкин андый 10–15 кешене каян тапмак кирәк? Булдыра алмасалар? Хәер, булдыра алмаганын башкасы алыштырыр иде, сайланырлар, чарланырлар иде әле.**

– Мәсьәләгә менә бу яктан килик әле. Безнең бүгенге хәлгә таруыбызның төп сәбәбе – дәүләт тоту тәҗрибәбез булмау. Гасырлар буена империянең аяк астында тапталып яшәгән халык вәкилләре буларак, без ил белән, халык белән идарә итүне онытканбыз. Үз артыбыздан халыкны ияртә алуны, халык белән бергә булуны онытканбыз. Һәм бу тәҗрибәне берничә елда гына туплый алмыйсың, билгеле. Әмма кайбер нәрсәләрне эшләп була иде. 1990 елда, суверенитет игълан итү белән, 2 меңме, 3 меңме яшь белгечебезне, студентыбызны чит илләргә укырга җибәргән булсак, алар инде әллә кайчан, дөнья тәҗрибәсен туплап кайтып, җигелеп эшли башлаган булырлар иде. Мин моны тәкъдим дә иткән идем, күнмәделәр. Андагы тормышны

күргәч, күбесе шунда торып калачак, диделәр. Милләт өчен янып йөргәннәре барыбер кайта иде аның. Киткәннәрнең чиреге генә булса да. Әмма алар инде бик тә эшлекле җитәкчеләр булачаклар иде. Завод директорлары, министр урынбасарлары... 2 мең кешене Венгриядә йөртеп кайтардылар әнә – укытабыз, дип. Әмма бу уку булмады, кунак булып, экскурсияләрдә йөреп кайту гына булды. Акча туздыру, ягъни...

**– Иске номенклатура сез «килмешәкләрне» үз итәме?**

– Мин бу номенклатур дөньяга очраклы рәвештә генә килеп эләктем. Китапханәнең авыр хәлен күреп, аңа, бер уңайдан тулаем татар мәдәниятенә дә ярдәм итә алмаммы дип. Номенклатура – йомык бер төркем ул. Теге вакытта комсомол эшендә, партия эшендә булганнар төркеме. Алар үз араларына бүтәннәрне кертмиләр, теге, кәҗәләр арасына сарыклар кермәгән кебек. Үзләре белгән, 100 процент ышанган кешеләр белән генә эшләргә тырышалар. Әмма 90 нчы еллар башында бу схемага әзрәк кенә үзгәреш керде. Бөтенләй башка даирә кешеләре булган Рафаэль Хәким, Индус Таһиров, Фәндәс Сафиуллин кебекләр өстәлде. Номенклатура безне бик якын да китерми. Еракка да җибәрмәскә тырыша. Еракка җибәрсәң, бәйдән ычкынырга мөмкинбез чөнки... Әмма аларга без дә кирәк.

**– Витрина буларакмы?**

– Әйе, менә безнең арада шундый кешеләр дә бар бит әле, дип әйтергә. Туфан Миңнуллин белән мин, мәсәлән, әдәбият-сәнгать кешеләре буларак кирәк. Аннары, безнең аша алар үзләре белмәгән әйберләрне дә белә алалар... Әмма барыбер дә кабул итеп үк җиткермәүләре сизелеп тора инде. Бөтенесе дә димим, алар арасында демократик карашлылары да бар үзе.

**– Ә президент, Сезгә ул ничегрәк карый?**

– Президентның безнең типтагы кешеләр белән уртак тел таба алуы, белеп-аңлап сөйләшүе мине кайчакта гаҗәпкә дә калдыра. Ул да безне тулысынча кабул итә, безнең белән 100 процент килешә дип әйтмим, әмма ләкин ул безнең фикер белән гел кызыксына, кайбер вакытларда безнеке белән беренче чиратта кызыксына.

**– Миллилек дигән нәрсәдән курку – иң өстәге җитәкчеләрдән башлап бөтен номенклатурага хас бугай бу. Әнә, Башкортстанның сәяси хокуклары, мөстәкыйльлеге дә азрак инде. Ә менә башкорт халкының хокуклары татар халкының хокукларына караганда шәбрәк яклана, милли үсеш өчен мөмкинлекләр күбрәк тудырыла шикелле. Моның башка халыклар, иң әүвәл татарлар исәбенә дә эшләнүе белән мин килешмим, әлбәттә.**

– Аларда элекке менталитет сакланып калган. Башкортлар безнең кебек үк куркытылган, имгәтелгән халык түгел. Үткән 450 елда күргәннәрдән соң без әле яңарак кына тернәкләнә башладык.

**– Хикмәт менталитетта гына түгелдер ул, Разил. Башкорт мәдәниятенең үсүе өчен анда министрлары да, хакимият башлыклары да җавап тота. Ә бездә әнә районга елына бер китап кайтармаган хакимият башлыгы да түш киереп йөри ала икән...**

– Башкортларның хөррәк яшәве – Мәскәүнең яшерен сәясәте нәтиҗәсе дә ул. Рәсәйгә үзләре теләп кушылдылар дип карау да бар монда, башкасы да. Җентекләп өйрәнеп бетерә алганыбыз юк әле моны. Дугинның «Геополитика России» дигән китабында беркадәр ачыла бу үзе... Башкортларга тимиләр. Ә татарга мөнәсәбәт бөтенләй башка инде. Безнең җитәкчеләр дә сизеп тора моны. Сиздереп торалар чөнки.

**– Безнең икебезнең бер уртак герой да бар бит әле, Разил.**

– Ә, әйе, Рифкать Миргазизов.

**– Шартлый торган гранатаны күкрәге белән каплап, иптәшләрен сау калдырган Түбән Кама егете турында син – «Яшисе килә» дигән повесть, мин исә гәҗит очеркы яздым. Шулай башын салган кешеләр күпме безнең халыкта! «Сугышта юлбарыстан көчле» татар белән горурлана алабыз. Дөрес, кайчакта, кемнәрнеңдер өйрәтелгән «юлбарыслары» булып, милләттәшләребез ни хакына батырлык кылганнарын да белмичә дөнья куйганнар. Хәзер менә татар өчен авыр чор. Теге батырлыклар кирәкми юкса. Син язгансың бит әле:**

**Үлем белән якалашканда да,**
**Акны кара диеп сөйләмәм, –**

**дип. Менә шул гына кирәк. Булдыра алмыйсың икән, дәшми генә тор. Юк, чәчрәп чыгып каршы сөйлиләр, Мәскәү оештырган хатларга кул куялар. Соңыннан «Туры килде инде», дип гафу үтенәләр. Атмыйлар да, төрмәгә дә утыртмыйлар юкса. Кемнәрдер кырын карамасын дип кенә бит бу... Акны кара диеп сөйләмәү үлем күзенә карап һөҗүмгә барудан да куркынычрак микәнни ул, Разил? Мин түрәләрдән бер-ике авыр сүз ишетеп инфаркт алган сугыш батырларын беләм.**

– Коллык психологиясеннән килә инде бу. 400–500 ел буена хезмәтче булып яшәү нәтиҗәсе. «Слушаюсь!» дип, «Есть!» дип безнең эчтән шулай «служивый татар» аваз сала. Армиядә нәрсә хакына икәнен дә белмичә кан коюдан ни мәгънә? Үзеңнекен генә булса бер хәер иде әле. Ишәк кебек эшләүдән алда кемне баетасыңны уйларга кирәк... Халык моны аңлый башлады кебек инде үзе.

**– Халык, дибез. Чын халык, Тукай «зур ул, көчле ул» дип язган халык бармы хәзер? «Тарихта хәлиткеч роль уйный» дип мактый-мактый коммунистлар аның үзен үк хәл итеп ташламадылар микән? Халык булып, табигый яшәү белән яши алмагач, үзе, түрәләрдән башка ни шәһәрдә, ни авылда берни дә хәл кыла алмагач – кешеләр суммасына гына әйләнеп калмадымы ул хәзер? Яки сыйфаты җуелган, бозылган халык түгелме? Син менә туган авылың Ташлыкта мәчеткә манара куйдыргансың. 1979 елда. Шунда авылның бөтен кешесе, хәтта күрше авыллар да җыелып килүен күреп, халык бар икән әле, исән икән әле дип сөенгәнсең. Ләкин хәзер шул ук халык һәр авыл саен төзеп куелган мәчетләргә йөрми бит.**

– Халык бик нык үзгәрде, әйе. Ләкин бөтенләй үк юкка чыкты дип әйтмәс идем. Менә Сабан туена кайтып килдем авылга. Көрәшәбезме, җырлыйбызмы, мәзәк сөйлибезме – шулхәтле укмашып яшәдек ул көнне! Бер йөрәк кебек. Түбән Камада да шулай булды. Бер бәйрәмме, бер шатлыкмы, бер ниятме тирәсенә шулай җыела ала икән, димәк, ул халык бар әле. Безнең бит дәүләтчелегебез юк иде. Менә шул дәүләтчелекне дә Сабантуйлары, җыеннар алыштырган. Дәүләт бит халыкны туплау дигән сүз ул. 450 ел дәвамында халык нигә югалмаган? Ул җыела алган – шуңа. Җыела алмый икән – халык юк инде, аерым кешеләр генә бар.

Менә тиздән Конгрессыбыз була. Ул – татар халкының тагын бер, зуррак колачлы җыены, берләшергә омтылуыбызның бер билгесе.

**– Янә бер хатирә сөйләп алыйм әле, Разил. Тагын Иҗат йортында чак бу, әмма бу юлы инде – Пицундада. Шәһәр буйлап йөрим беркөнне шулай. Эссе! Диңгез буендагы нәни генә курорт шәһәре бит инде, тугарылып китеп башта – күлмәкне, аннары майканы да салып аттым. Шунда мине 24–25 яшьләрдәге егет туктатты. «Сез нигә болай йөрисез, безнең халык моны яратмый!» – ди. Пицунданың абхаз шәһәре икәнен белә идем үзе, әмма бу ничектер экзотика кебегрәк кенә иде минем өчен. Менә шунда мин абхаз җирендә икәнемне чынлап торып аңладым. Гафу үтенеп, җәһәт кенә киенәсе булды.**

**Безнең Татарстанда толерантлык дигән бик әйбәт бер нәрсә бар. Башкаларга карата түземлелек, киң күңеллелек. Ләкин ул кайчакта нигәдер үзебезне кимсетүчеләргә, Казанны бозыклык оясына әйләндереп ятучыларга карата киң күңеллелек булып чыга.**

– Син дөрес әйтәсең, Рәфикъ. Толерантлык шул рәвештә тормышка ашса, татар үзенең үзенчәлеген җуячак. Хәер, югалтып бетерә яздык инде без аны. Моның төп сәбәбе халкыбызның үз тамырларыннан аерылуы булды. Без бит Шәрекъ традицияләрендә, ислам динендә тәрбияләнгән халык. Шуны онытып, без Көнбатышка йөз белән борылдык. Болай без үз-үзебезне саклап кала алмыйбыз. Шәрык традицияләрен яңартыр өчен безгә Шәрыктән өстәмә куәт алырга кирәк. Культура багланышларын да иң әүвәл Көнчыгыш илләре белән көйләргә тиешбез.

## Калганын яңа буын эшләп бетерер

– 80 нче еллар азагында, 90 нчы еллар башында шулкадәр дә куанып, хыялларга чумып законнар, Конституция кабул иткән идек. Берәм-берәм аларны юкка чыгару, үтерү шулкадәр дә авыр булды ки, кайчакларны төнлә куркып уянып китәм. Соңгы ике ел тормышымның иң авыр еллары булды.

Трибунага чыгып, депутат таныклыгымны тапшырам да чыгып китәм – шундый теләк тә бар иде. Йә, киттем ди, шуннан ни үзгәрә? Калсам, бәлки, нәрсәдер эшләп булыр дидем.

Бердәнбер юаныч – җитәкчеләрнең беркадәр эволюция кичерүе. Мин инде күбрәк Фәрит Мөхәммәтшин белән эш итәм. Ул күп нәрсәне үзе теләгәнчә генә эшли алмый, чөнки шундый шартларга куелган. Әмма ләкин без эшләгәннәргә, кайвакытта яхшук четерекле нәрсәләрне эшләгәндә дә хәерхаһ була...

Татар халкының бүгенге хәле минем бабайның язмышына охшаган. Бүген бит безнең дә булган бөтен нәрсәне тартып алалар. Социалистик система, колхозга кертеп, аның «мин»ен юкка чыгартырга теләгәндә, ул, тегермәндә бушка диярлек эшләп булса да, үзен саклап калган.

**– Безне дә көчләп Рәсәй колхозына керттеләр менә.**

– Безгә дә үзебезне, үзенчәлегебезне ничек тә булса сакларга, йоттырмаска кирәк. Килер бер көн, без дә... Өметсез, шайтан, – ди. Әгәр дә мин татарның киләчәгенә ышанмасам, болай итеп җан тартышып йөрмәс тә идем...

Бик күп кешеләр безне Дон-Кихотлар дип саныйлар. Җитәкче урындагыларның да кайберләре, нәрсәгә инде син, тел дип, мәдәният дип, мәгърифәт дип, һаман нидер даулыйсың, үз эшеңне белсәң, тыныч кына утырсаң җитмәгәнмени, диләр. Янәсе, берәүләр шулай итеп тегесенә дә ирешә, монысына да ирешә. Китаплары да бер-бер артлы чыгып тора, коттеджлар да салалар, бик әйбәт машиналарда да йөриләр... Мин дә хәерче түгел, димен, минем дә торыр урыным бар. Әмма ләкин...

Бу – җан авазы, кан авазы инде. Бер миндә генә түгел, синдә дә бар ул, башкаларда да. Безнең халыкның үткәне безнең канда уйный торгандыр инде. Бөтен нәрсәне дә акыл белән уйлап эшлим димим, кан авазы бардыр ул, шул чакыра торгандыр.

Моны мин Америкага баргач та күрдем. Соңгы баруымда Вашингтонда Сәгыйть Сәлах дигән кешеләрдә яшәдем мин. Кореяда туып үскән ул. Сеул шәһәрендә. Анда 26 татар гаиләсе булган. Шушы 26 гаилә, акча җыеп, татар мәктәбе ачканнар, татар гәҗите, татар журналлары чыгарганнар – кулдан язып булса да. Үзләренең зиратларын булдырганнар. Кореяда бит ул! 26 гаилә! Ни өчен кирәк бу аларга? Менә ул милләтнең көче! Үз-үзен саклау көче!

Сәгыйть абый шуннан соң япон әсирлегендә булган, аннары киткән Америкага, анда өч югары уку йорты бетергән. АКШтагы иң атаклы атомчы галимнәрнең берсе ул бүгенге көндә. Америка энциклопедияләрен карап чыктым, бөтенесендә дә аның биографиясе бирелгән... Хәзер аңа 69 яшь. Иртән торуга беренче эше – кампитрны кабызып куя, аннан «Азатлык» радиосын тыңлый, бүтән татар радиоларын – Интернеттан. Югыйсә нәрсәгә ул аңа: ул бит инде Сеулда туып үскән, калган гомерен Америкада үткәргән, анда аның теленең дә, татарлыгының да беркемгә хаҗәте юк. Алардан тузан бөртеге хәтле дә файда чыгара алмый юкса... Менә ул җан авазы!

Милләттәшләребезнең диңгездәге бер йомычка килеш кенә дә үзләрен саклап калулары мине шаккатырды. Ул Нью-Йоркта татар җәмгыяте оештырулар, анда татарча спектакльләр, «Зәңгәр шәл»ләрне куюлар. Япониядә мәчетләр ачу. Мәктәпләр, техникум ачып, гәҗит-журналлар чыгарып, бер миллиардлы Кытайда җуелмыйча, татар булып гөрләтеп яшәп ятулар. Менә ул милләтнең яшәү көче! Шуның берәр чаткысы бездә дә бардыр ул. Борынгы бабаларның, дәүләтчелегебезнең чаткылары уйный торгандыр, тернәкләнергә тырыша торгандыр...

**– Кемнәрдер татарлыктан качарга омтыла бит. Карт, авылча гади әнисеннән оялган күк оялып. Шулай нәрсәгәдер ирешмәкчеләр.**

– Нью-Йоркта әле яңарак кына бер егетне күреп кайттым. Рөстәм Нуретдинов дигән егет, Алабуганың Туйма авылында туып үскән, Лениногорскида сәнгать училищесын бетергән. Мәскәүдә 1–2 ел укыган да, Америкага киткән. Бүгенге көндә 15 миллионлы Нью-Йоркта атаклы рәссамнарның берсе. Дөньяның меңнәрчә рәссамы җыелган шәһәрдә бит бу! 9 ел эчендә ирешкән! «Син, авыл малае, ничек булдыра алдың моны?!» – дип сорагач, «Миңа шул татар малае, авыл малае булу ярдәм итте дә инде, – диде. – Минем күңелем чиста, күзләрем саф, Нью-Йоркны мин үземнең хисне кушып ясадым, шул бик ошады», – ди. Гап-гади бер малай инде. Чыкылдап торган татар телендә сөйләшә, исемен Рөстәм Нур дип йөртә. Аның остаханәләре бар, йортлары бар, иң шәп машиналары бар – бөтен нәрсәсе бар. Хәзер галереясын ачып ята. 30

менеджеры гына бар – аның рәсемнәрен сатып йөрүчеләр... Менә ул татар рухының ныклыгы! Шушыларны күргәч, минем киләчәккә өметем арта, оптимистик рухым ныгый.
**– Безнең бу җиңелү, фаҗигале чигенүнең башы, аның беренче билгеләре нинди булды?**
– Эшнең хөртиләнә башлавын иң әүвәл җитәкчеләребез авызыннан «субъект» дигән сүз чыккач сиздем. Татарстанны «Россия субъекты» дип әйтә башлагач. 95 нче еллар тирәсендә булдымы икән ул? Бәлки, алданрактыр да.
**– 1994 елда Шартнамәгә кул куйганнан соң башланды дип хәтердә калган.**
– Мин сессиядә әйтеп тә карадым. Татарстан Россиянең субъекты түгел, бу сүзне нинди документка таянып кулланасыз, дип... 3 ел чамасы элек Рәсәйнең Конституция суды республикаларның суверенитетка ия булмавы турында карар чыгарды. Рәсәйгә күпләп налог та түләтә башладылар. Хакимияткә В. Путин килгәч, бөтен бу эшләр системага салынып, Рәсәйнең эчке сәясәтенең төп юлына әйләнде. Без моңа башта бик нык каршы тордык. Прокуратура, законнарыгызны тәңгәлләштерегез, дип карарлар җибәрә – без аларны тикшереп тә тормыйбыз. Шуннан соң безне судка бирә башладылар. Татарстан суды безнең кайбер законнарны аклый, шуннан соң Мәскәүгә җибәрәләр. Аннан инде ул акланганнарны да гамәлдән чыгарган карар килеп төшә.
Ике ел элек Рәсәй тагын бер карар кабул итте. Субъект законнарны тәңгәлләштермәгән, бу хактагы суд карарларын үтәмәгән очракта әлеге субъектның парламентын тарату процедурасы каралган иде анда. Без әнә шул юлдан да китә ала идек. Әмма ләкин республика җитәкчеләре дә, депутатлар да моны кулай дип санамадылар. Чөнки, чыннан да, безнең кайбер законнарны Рәсәйчә үзгәртәсе, аларга демократик чалымнар өстисе бар иде... Шунысы беркадәр юаныч халыкның рухи дөньясына кагылышлы законнарга әллә ни үзгәреш кермәде. Әйтик, «Телләр турында»гы Законга прокуратурадан бер генә протест та алынмады.
**– Ә Конституция ничек үзгәртелде?**
– 30 кешедән торган комиссия төзелде. Анда мин дә кердем. Туфан абый да, Индус Таһиров та. Рәис итеп Минтимер Шәриповичны сайладык. Әмма тагын эшче төркем дә бар иде әле, алар бер ел дәвамында Мәскәү белән килешеп эшләделәр, һәрбер маддәсен күздән кичерделәр. Проектны безгә сессиядә тикшерүгә 1,5 ай кала гына күрсәттеләр. Конституциябездәге мөһим нәрсәләрне саклап калып булганча сакларга тырышканнар үзе. Өлешчә генә булса да, суверенитет та калды.
**– Туфан Миңнуллин белән икәүләшеп бер бик шәп өстәмә дә керттегез бит әле.**
– Әйе, 14 нче маддәне. Татарстан Республикасы Татарстаннан читтә яшәгән татарларның милли мәдәниятен, телен үстерүдә, үзенчәлеген саклауда ярдәм итә, дигән.
**– Ничек үткәрә алдыгыз аны?**
– Бик нык дәлиллисе булды инде. Соңрак президент та хуплады.
**– Әмма Рәсәй составында булуыбыз кырт кисеп әйтелгән инде. Бу юлы Казанны үзебез бирдек. Халык бирмәде, 1992 елгы референдумда халыкның фикере бүтәнчә иде... Номенклатура бирде. Сөембикәне морзалар биреп җибәргән кебек. Син дә бирмәдең, Туфан абый да бирмәде. Сез ахыргача көрәштегез.**
– Сессиядә ясаган чыгышымда, референдум карарын бозган Конституциягә тавыш бирә алмыйм, дидем... Инде камалган Казанны бирдек без, әмма биреп үк бетермәгәнбез, күрәсең. Прокуратурадан янә протест килде, Конституциянең яңа редакциясен дә судка бирәләр... Теләсә нишләсеннәр, соңгы өметләребезне дә алырга җыеналар икән, безгә андый Дәүләт Советы кирәкми.
**– Казанны алу белән бергә Мәскәү Россия Федерациясенең «федерация» дигән өлешеннән дә арына. Рәхәтләнеп арына – тәненнән шырпы чыккандагы күк... Разил, хәтерлисең микән, Милләтләр эше министрлыгы бетерелгәч, аның функцияләренең бер өлеше Эчке эшләр министрлыгына йөкләнгән иде. Шунда нигә Армия белән КГБны оныттылар икән дип уйлап куйган идем. Милләтләр эше министры булган чакта Шахрайның Кавказда десантчы формасында йөргәннәре исеңдәдер әле.**
– Әйе.
**– Шушы авыр чорда нишләргә соң, Разил?**

– Һәркем үз урынында кулыннан килгәнне эшләргә тиеш.
Иң әүвәл милли мохит булдырырга кирәк. Милли элита да шул туфракта үсәчәк, башкасы да. Әмма ләкин моңа бөтен җәмгыятьтә берьюлы ирешеп булмастыр. Башта менә шуның институтларын, утрауларын булдырырга кирәк: милли гимназияләр, милли лицейлар, милли мәктәпләр... Ни дисәң дә, шәһәрләр әле татарныкы түгел. Аларда милли культура, милли мохит бөтенләй юк диярлек. Милләт яшәсен өчен тулы мохит кирәк – бөтен нәрсә шул телдә, шул рухта булсын. Ә моны бары авылда яки район үзәгендә генә эшләп була.
Моның өчен, минемчә, Америка индеецларының резервацияләрен барып өйрәнергә кирәк. Безнең татар авылы моңа кадәр милләтне саклап калган резервация ролен үтәде. Хәзер ул бездән китә башлады – җибәрмәскә кирәк! Аны җибәрмәү механизмнары, минемчә, әнә шул резервацияләрдә булырга тиеш. Бәлкем, берничә авылдан шундый төбәк оештыру мөмкиндер – мәдәният йорты, урта мәктәбе, китапханәсе, дәвалау урыны, чәчтарашлары, эш урыннары һ. б. булган. Татар резервацияләре, ягъни. Бу сүз куркыта икән, бүтәнен табыйк. Әмма халыкны саклыйк. Тыюлыклар ясап, аерым төр агачларны, җәнлекләрне дә саклыйлар лабаса. Татар шул пошилардан, төлкеләрдән кайтышрак түгелдер ич инде.
Бусы турында күптән хыялланам инде, тәкъдим иткәнем дә бар: татар халкын өйрәнү үзәге булдырырга кирәк. Тарихын, телен һ. б. гына түгел, берсе аягын, берсе кулын өйрәнә дигәндәй – тулаем өйрәнсеннәр. Киемнәрен дә, гореф-гадәтләрен дә, холкын-фигылен дә, моңын-җырын да – комплекслы төстә. Татар халкының бүгенге яшәешен дә өйрәнсен ул, киләчәккә юнәлеш тә бирсен... Милли университет ачылса, бу эшне күпмедер дәрәҗәдә ул башкара ала.
Саратовта, Төмәндә бик бай татарлар бар. Менә шуларны төбәкләрдәге милли хәрәкәтнең таянычы итәсе иде. Ләкин аларның күбесенең милли аңы чамалы гына. Татар конгрессы тирәсендә малтабарлар ассоциациясе оештырырга кирәктер. Татарстан белән сәүдә иткәндә, аларга льготалар бирелсен, ә алар табышларының ничәдер процентын милли оешмаларга биреп барсыннар.
**– «Нәрсә эшләргә?» дигән сорауга җавап булды. «Ничек эшләргә?» дигәненә җавапны үзем бирәм. Разил Вәлиевчә эшләргә кирәк.**
– Ничек ул?
**– Беренче мисал. Листовкалар ыргыту турында Зөлфәт миңа болай сөйләде: «Селтәп җибәргәч, сибелеп киттеләр. Разил ике бармак арасыннан гына төшереп җибәрде, аның листовкалары төшә-төшә таралдылар». Өлге бу: бөтен эшне дә гайрәт күрсәтеп эшләү кирәкмидер. Боксчылар да селтәнми генә суга әнә. Икенче мисал. Син мәчеткә манара куйдырасың. 1979 елны бит бу! Авылда, районда күпме түрәнең күзе синдә булгандыр. Җайлый, көйли белгәнсең! Өченче мисал. Без җомга көнне ял итәргә тиеш, дип сөйләүчеләр күп булды. Эшләүче – бер син генә. Милли китапханә җомга көнне ял итә. Монысын үзең аңлатып бир: ничек ирешә алдың?**
– Китапханәгә йөрүчеләргә шундый анкета тараттык: китапханә хәзер якшәмбе көнне ял итә. Якшәмбе көнне эшләп, җомга көнне ял итсә, сезнең өчен җайлырак булмыймы? «Якшәмбе көнне мин рәхәтләнеп китапханәгә килеп утырыр идем. Җомга көн – атнаның соңгы көне, китапханәгә килергә минем вакытым да булмый әле». Шундыйрак җавап теркәлгән йөзләрчә анкета тупладык без. Аларны теләсә кайсы җирдә күрсәтә алам.
**– Менә бит! Җип-җиңел генә. Ә кемнәрдер, без мөселман республикасында яшибез, Милли китапханә җомга көнне ял итәргә тиеш, дип тотыныр да җәнҗалдан гайре берни дә чыгара алмас иде. Дүртенче мисал. Син Дәүләт Советына депутат булып Яшел Үзән районыннан сайлангансың. Күпчелек урыслар яшәгән, татар булганнарының да шактые, асылда, урыслашкан төбәк бу. Милләтпәрвәрләрдән тагын кем генә үтә алыр иде икән аннан? Сайлаучылар белән 107 тапкыр очрашкансың! Ташны тишкән тамчы түземлеге бу!**
– Безнең буын һәм бездән әзрәк алданрак килгән буын коммунистик режимда үсте. Без шул килеш тә, милли аңны югалтмыйча, нәрсәгәдер ирештек, шуннан артыгына хәзер мөмкинлек бар дип санамыйм. Яңа буын бүтән сәяси җәмгыятьтә, бөтенләй башка шартларда яши. Алар бер ун елдан ныгып аякка басарлар. Без аларны инде күреп торабыз. Аяз Гыйләҗев малайлары кебекләр

килә әнә... Кыюлык та бар аларда, акыл да бар. Иң мөһиме – рухи хөрлек бар. Хәзер минем бөтен өметем шул яңа килгән буында. Алар безгә караганда 2–3 мәртәбә күбрәк эшләргә тиешләр.

**– Амин!**

*Әңгәмәдәш Рәфикъ Юныс*
*2002*

# БЕЗНЕҢ БАСКЫЧ КИРЕГӘ ӘЙЛӘНДЕРЕЛГӘН

**– Әңгәмәбезне сәнгать турында сөйләшүдән башлыйк әле...**
– Сәнгать белән кызыксынам димим, чөнки мин шуның белән яшим. Мөмкин кадәр спектакль премьераларына, концертларга йөрергә тырышам. «Татар тотып карамыйча ышанмый» диләр бит. Миңа да, үз күзләрем белән күрмәгәч, кеше сүзе, кеше фикере генә җитми. Иң борчыганы – үзешчәнлекнең артык активлашып китүе. Мин үзешчәнлеккә каршы түгел. Бөтен профессиональ сәнгать үзешчәнлектән килеп чыга, ул – сәнгатьнең тамыры. Әмма ләкин үзешчәнлекне бервакыт та беренче урынга куярга ярамый. Үзешчәнлек – сәнгатьнең беренче баскычы. Ә безнең ул баскыч кирегә әйләндереп куелган. Күп җитәкчеләребезнең аң-белем, зәвык дәрәҗәсе үзешчәнлек хәлендә булу аркасында шулай килеп чыга. Мәсәлән, хакимият башлыкларының шактые сәнгатьнең иң үтемле төре табын артында җырлап утыру дип уйлый. Болар һәммәсе дә кирәк. Әмма ул культура хезмәте күрсәтү дип атала. Ә сәнгать... анысы бөтенләй башка. Югары сәнгать булырга тиеш. Ул бездә юк дип әйтмим. Опера театрыбыз, зәвыклы, әзерлекле, үзләренә югары таләпләр куеп иҗат итүче сәнгатькәрләребез бар. Аларга бүген игътибар аз.
**– Күптән түгел бик зурлап «Татар җыры» фестивале үткәрелде. Сезнең, күп җырлар авторының, фикере нинди, чыннан да «Татар җыры» булдымы ул?**
– Фестивальләр шик тә тудыра, көлемсерәп тә куям. Без купшы сүзләрне яратабыз. Әле генә сәхнәгә чыгып ике-өч җыр җырлаган кешегә «йолдыз» дибез. Андый сүзләр белән халыкның башын бутарга ярамый. Халык матбугатка ышанырга тиеш. Ә купшы сүзләрдән соң ышандырмый башлый. Нинди йолдыз булсын ди ул?! Күңелгә сукыр лампа яктысы да бирә алмый. Тыйнаграк буласы иде. Халык Илһам Шакировны «халык артисты» исеме алганчы ук үзенеке дип кабул итте. Рәшит Ваһаповны да, Фәридә Кудашеваны да, Зифа Басыйрованы да. Аларның исемнәре бармы-юкмы – мин аларның йолдыз икәнен беләм. Әмма Илһамны «йолдыз» дигәннәрен ишеткәнем юк әле. Ә ул инде, бәлки, йолдызлардан да югарыдыр.
«Татар җыры» фестивалено килгәндә... Мин аларны татарча җырлый торган фестивальләр дияр идем. Соңгы елларда «татар җыры» дигән илаһи сүз очсызланды. Яңа җырларыбыз татар җыры булудан ерак тора. Кайчакта күземне йомам да уйлап куям: әгәр дә, мин әйтәм, сүзләре татарча булмаса, бу татар җыры булыр идеме икән, дим. Чувашча җырласаң – чуваш җыры, марича җырласаң, мари җыры дип уйланыр иде. Бу бездә генә түгел, башкаларда да шул ук проблема. Дөньялар буталып бетте. Бәлки, бу табигыйдер, халыклар бер-берсенә якынаерга, тәэсир итешергә тиештер. Әмма ләкин үзәге калсын. Иң беренче чиратта халык үз иҗатына, үз моңына таянсын. Җырчы татар халык җырыннан аерыла икән, ул инде җырчы түгел.
**– Газеталарда үткән ел бәхәс кузгалган иде: җырга кем хуҗа? Шагыйрь бу хакта нәрсә уйлый?**
– Дәүләтнеке булмаган радиокомпанияләрдә автор исемен әйтүне бөтенләй кирәксенмиләр. Габделфәт җыры, диләр, Салават җыры, диләр, әйтерсең шагыйре булмаган. Без хокукый дәүләттә яшәргә телибез. Иҗат әһелләренә хөрмәт йөзеннән булса да, исемнәрен әйтергә кирәк. Кешенең исем-фамилиясе, әтисенең исеме булган кебек, җырның да исеменнән тыш әти-әнисе дә бар. Һәрхәлдә, бу игътибарсызлык культура дәрәҗәсенең югарылыгы турында сөйләми. Җыр чын сәнгать әсәре булып рухи мирасыбызга кереп кала икән, аңа халык хуҗа. Иң югары дәрәҗә шушы. Ул вакытта мин авторларның исемнәре онытылуга да риза. «Сарман»ны кемдер язган... «Фазыл чишмәсе»н дә халыкныкы диләр, ул Сибгат Хәкимнеке. «Бер алманы бишкә бүләек» җырының минеке икәнен онargalar икән, мин сөенәчәкмен генә. Әмма исән чагымда исемемне әйтсеннәр. Мин ниндидер матди файда көтмим, түләгәннәре дә булмады, хезмәт хакым бар, мохтаҗлыгым юк.
**– Сез – «Татарстан» телеканалындагы «Бер алманы бишкә бүләек» тапшыруының авторы. Аның дәвамы булырмы?**

– Бу тапшыруга җаным әрнегәнгә, аптыраганнан тотындым. Минем һәр секундым кадерле, миллион эшем бар. Татар теле аягына торып басарга тиеш, дибез, телсез халык була алмый, дибез. Иманым камил, моңсыз халык та була алмый. Сәнгатьсез, җырсыз, театрсыз, әдәбиятсыз халык булмый. Әмма дә ләкин музыка язмышы турында ныклап кайгырткан кеше дә, андый закон да, программа да юк. Билгеле, Мәдәният министрлыгыбыз бар, ул тырыша, тик аларның гына куәте җитми. Бөек шәхесләребезнең эт типкесендә йөрүен күреп йөрәк әрни. Бер елны мәдәният хезмәткәрләре корылтаена Фасил Әхмәтов килә алмады. Фикерен сорагач: «Мин балаларыма, оныкларыма, композитор була күрмәгез, дип васыять язып калдырачакмын, аларга үземнең аяныч язмышны теләмим», – дигән иде. Без бик дус идек, бергәләп җырлар яздык. Бервакыт мәдәният хезмәткәрләренең корылтае булырга тиеш иде. Килеп алыйм, дип шылтыратам. «Бармыйм», – ди. «Ничек инде?» – дим. «Кил әле», – ди. Кухняда сөйләшеп утырдык. Ул елап җибәрде. «Минем анда киеп барырга юньле костюмым да юк», – ди. Ул – Россиянең халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты. Бөек шәхесләребезнең аянычлы хәле бу. Илһам Шакировның ничек яшәгәнен күреп торам. Башка илдә туса, миллиардер булыр иде. Андыйларга хөкүмәтнең игътибары җитми. Халыкның бәгыренә үтеп кергән, милли хәзинәбезгә әйләнгән иң атаклы сәнгатькәрләребезне видеотасмаларга язып калдырасы килә. Мәрхүм Хәйдәр Бигичевны, Фасил Әхмәтовларны язып кала алдык. Инде 50–60 лап язма җыелгандыр. Ә бит әле шәхесне эзләп табарга кирәк, аның авырган вакыты була, кәефсез чагы туры килә. Мин Азат Аббасов артыннан ике атна йөрдем. Башта риза булды, инде бар да әзер булгач, шылтырата: «Җыенып беткән идем, көзгегә карадым да кабат киемнәремне салып ташладым, мине тамашачыларым элекке чибәр чагымдагыча хәтерләп калсыннар», – ди.

Тора-бара тапшыруларым, бәлки, атаклы шәхесләр турында сериягә әйләнер. Мин аларны кәгазьгә дә күчерәм, китап итеп чыгарырга да уйлыйм.

**– Сәясәттә Разил Вәлиевнең барлыкка килүе аның шигърияттәге өлешенә кермәдеме?**

– Мин гомер буе шигырь генә язып торган кешеләрне беләм, яшьлегендә язып, башка эшкә күчкәннәрне дә беләм. Җан нәрсәгә тарта, күңел нәрсә тели, шуны эшләргә кирәк. Мин бөтен нәрсәгә: утын яраммы, йорт саламмы, закон язаммы – барысына да иҗат дип карыйм. Шулай итмәсәң, яшәүнең мәгънәсе югала. Мин сессиядә сөйлисе чыгышымны да хикәя язгандай язам, анда канатлы сүз дә, кытыклап ала торган урын да булырга тиеш, елмайтсын да ул, үртәп тә алсын. Кайчакта шуның белән мөмкин булмастайны да үзгәртеп була. Дәүләт Советында җиде комиссия эшли. Бюджет караганда безнең комиссия кебек уңышка ирешкәне булмады. Быел бер тиен дә артык бирмибез дигәндә дә мәдәният, фән-мәгариф өчен 150 миллион сум өстәмә акча алуга ирештек.

Шигырь язуга килгәндә... 70–80 яшькә кадәр шигырь язучыларны кайчакта карт кешенең бала-чагадай уйнавы кебек күз алдына китерәм. Хәсән Туфан гына уникум шәхес иде. Шигырь язылырга тиеш, әмма аны профессиягә әйләндерергә ярамый. Андый шагыйрьләр бар, алар башка эш белмиләр, булдыра алсалар, бәлки, бүтән эш белән шөгыльләнгән булырлар иде. Мин шигырьне көндәлек эшкә әйләндерүгә каршы. Шигырьнең синнән сорап тормыйча, ишек шакымыйча кергәне әйбәт. Кайчакта сессиядә утырганда да, машинада да языла. Алар – мин эзләгән түгел, мине эзләгән шигырьләр. Мин менә 10 ел көндәлек алып барам. Безнең язучыларның 99 % ында бертөсле биография: авылда туган, Казанда югары уку йорты тәмамлаган, редакциядә яки нәшриятта эшләгән. Язучының биографиясе нинди, иҗаты шундый. Минеке башкачарак. Авылда тудым, әмма Мәскәүдә дә яшәдем, укыдым, КамАЗда да булдым, Әфганстан сугышын да, Чечнясын да күрдем. Хәзер инде өч чакырылыш депутат булып сайландым. Бу даирәдә нәрсә барганын беләм. Биредәге тормышны сурәтләгән әдәби әсәр юк әле. Күргән-белгәнемне язып чыга алсам, зур әсәр булыр иде. Туплаган маямны кәгазьгә күчерә алсам, максатыма ирешкән булам.

*Әңгәмәдәш Рузилә Мөхәммәтова*
*2002*

# БЕЗНЕҢ АЛДА ЗУР СЫНАУЛАР ТОРА

**– Билгеле булганча, парламент «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Закон кабул итте. Дөресрәге, Конституциянең өр-яңа варианты эшләнде. Рәсми телдә аны Конституциянең яңа редакциясе дип тә йөртәләр. Разил әфәнде, Сез аннан ни дәрәҗәдә канәгать? Ул гамәлдәге Конституциядән уңышлыракмы?**
– Әлбәттә, һәркем киләчәккә өмет белән яшәргә тиеш. Беттек инде дип яшәүдән берәүгә дә файда юк. Миңа иң ошаганы, күңелемә иң якыны 14 нче маддә булды. Ул да булса «Татарстан Республикасы читтә яшәүче татарларның милли мәдәниятен, телләрен үстерүгә, үзенчәлекләрен саклауга ярдәм итә» диелгән маддә. Без аны, Конституция комиссиясе әгъзалары буларак, Туфан Миңнуллин белән икәү керткән идек. Конституция комиссиясендә бу хакта бик күп бәхәсләр булды. Мәскәү тарафдарлары да безгә ташландылар. Бу Татарстан вәкаләтләренә керми, читтә яшәүче татарларга Татарстан ярдәм итә алмый, моны Русия кайгыртырга тиеш, ул аның вәкаләте, диделәр. Әмма без Русиянең төрле төбәкләрдә яшәүче татарларга мөнәсәбәтен, ярдәм күрсәтмәвен бик яхшы беләбез. Аларда мәктәпләр дә ачылмый, хәтта булганнары да ябыла, мәдәни һәм башка мәнфәгатьләр дә кайгыртылмый. Әгәр дә моны Татарстан үз өстенә ала икән, минемчә, һич тә начар булмаячак. Бу гамәлне хупларга гына кирәк. Шунысы да бар: моңа кадәр кабул ителгән конституцияләрнең берсендә дә читтә яшәүче татарларга ярдәм турындагы маддә юк иде.
Күреп торабыз, татарларның күпчелеге Татарстаннан читтә яши. Алар безгә карап торалар. Чөнки Татарстан – татарның дәүләтчелеге булган бердәнбер урын, дәүләтчелеге булган республика, һәм безнең татар мәктәпләре өчен барлык дәреслекләр, гомумән, татар телендә матур әдәбият та Казанда басыла, милли кадрларыбыз да, нигездә, биредә әзерләнә. Кайсы яктан гына карасаң да, татарның рухи тормышы Татарстанда формалаша.
**– Югары уку йортларында чит төбәкләрдәге татарлар өчен квота булса иде...**
– Моңарчы да без тырыша идек. Ләкин югары уку йортлары ректорлары өчен законлы нигезебез юк иде. Хәзер бу мәсьәлә Төп Законга беркетелә.
**– Аннары бит Конституциягә нигезләнеп махсус закон да эшләргә була**.
– Һичшиксез, андый законны эшләргә кирәк. Аннан соң тагын бер мәсьәлә. Гамәлдәге Конституциядә, һәр кешегә нинди телдә уку мөмкинлеген сайлау хокукы бирелә, диелгән. Шулай да ул дәүләт тарафыннан гарантияләнмәгән иде.
Без Конституциягә «ике дәүләт телендә дә укыту дәүләт тарафыннан гарантияләнә» дигән төзәтмә керттек. Моңа кадәр гарантия булмагач, Хапугин дигән кеше, урысларны көчләп татарча укыталар дип, безне судка биреп тә интектерде. Безгә сәламәтлек саклау, медицина хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгатьләр күп булды. Сер түгел, бүген хастаханәләребездә бик күп төрдәге хезмәт күрсәтү түләүле төстә алып барыла. Даруларны, хәтта тастымал-сөлгеләрне дә авырулар өйләреннән алып киләләр. Ләкин бит әле бездә күпчелек халыкның хезмәт хакы түбән. Хәтта бай илләрдә дә, мәсәлән, Канадада медицина хезмәте бушлай. Дөрес, әгәр инде акчаң бик күп икән, түләүле хастаханәгә кереп ята аласың. Өч-дүрт бүлмәле палатада ятарга мөмкин. Без, озак уйлаганнан соң, Конституциягә «Татарстанда медицина хезмәте, нигездә, бушлай күрсәтелә» дип язып куйдык.
Гамәлдәге Конституциядә кешенең бурычлары күбрәк язылган иде. Болай эшләргә тиеш, тегеләй тиеш. Аның дәүләт алдында да, хөкүмәт алдында да бурычлары күп.
**– Өченче укылышта Конституциянең яңа редакциясеннән «тиешләренең бер өлеше төшеп калды. Булган хокуклар да гарантияләнмәде. Ә гарантияләнмәгән хокук ул – буш сүз генә...**
– Тулаем алганда, Конституция элеккегесеннән шактый аерыла. 1 нче маддә бөтенләй башка. Референдум нәтиҗәләренә нигезләнгән 61 нче маддә төшеп калды. «Татарстан – суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты» дип язып куйган идек. Референдум нәтиҗәләренә ревизия ясарга берәүнең дә хакы юк. Бу халыкара хокук нормалары буенча да шулай.

– **Русиянең Конституция суды карар чыгарды чыгаруын.**
– Ул да законлы карар түгел.
**– 61 нче маддәне тулысынча ук гамәлгә ашыра да алмадык кебек.**
– Әйе, без чын мәгънәсендәге суверен дәүләткә әверелмәдек. Бу маддәне тулысынча гамәлгә ашыру мөмкин дә түгел иде. Чөнки, Русиядән аерылып чыгып, мөстәкыйль дәүләт булып яшәү ул Декларация белән генә хәл ителә торган эш түгел, Конституциянең яңа редакциясендә без инде реаль җирлеккә төштек. Без вәкаләтләребез кысаларында гына суверен. Ул Шартнамә белән дә, Татарстан һәм Русия Конституцияләре белән дә чикләнгән. Шулай да элеккеге Конституциядәге нигезләмә минем үземә ныграк ошый иде. Ул, реаль булмаса да, безгә алга бару өчен мөмкинлек бирә иде. Алга таба хәрәкәт итү өчен офыклар һәрвакыт ачык булырга тиеш.
Милек турындагы маддә минем күңелдә ризасызлык калдырды. Гамәлдәге Конституциядә «Татарстанның җир астындагы һәм җир өстендәге мөлкәте республика халкы байлыгы» дип язылган иде. Хәзер ул «бөтенхалык байлыгы»на әверелде. Мин әле һаман да бөтен халыкның кем икәнен аңламыйм. Аңа махсус аңлатма бирергә кирәктер. Ул бөтен Җир шары халкы да, бөтен Аурупа яки бөтен Русия халкы да булырга мөмкин. Хәзер менә Беларусь та Русия белән кушылырга җыена. Без үзебезнең байлыкларыбызның кемнеке икәнен ачык кына язып куя алмадык. Ә менә президентның ике дәүләт телен белү зарурлыгы сакланды.
Тагын бер маддә бераз куандырды да, шул ук вакытта хафага да салды. Билгеле, без аны авырлык белән булса да саклап кала алдык. Бу – гражданлык турындагы маддә. Мәскәүдән безгә кисәтүләр ясадылар, әлеге маддәне алып ташларга тәкъдим иттеләр, сезнең гражданлыгыгыз булырга тиеш түгел, диделәр. Субъектларның гражданлыгы турындагы маддә Русия Конституциясендә юк. Дәүләт Думасы «Русия гражданлыгы турында» Закон кабул итте, анда «субъектларның үз гражданлыгы булмый» дип язылган. Әмма Русия Конституция судының Татарстан гражданлыгын тыюына да карамастан, без Төп Законыбызга үз гражданлыгыбыз турындагы маддәне кертеп калдырдык.
**– Бәлки, тагын судка бирерләр.**
– Бирерләр. Русия Конституция суды карары нигезендә безнең Конституциядә «суверенлык» дигән сүз дә булырга тиеш түгел иде. Әмма ләкин без, суд карары белән килешмичә, суверенлыкны чикләнгән күләмдә булса да калдырдык, гражданлыкны да калдыруга ирештек. Дөрес, гражданлык турындагы бүлектә шактый кыскартулар булды. Әмма төп фикер калды – Татарстанның үз гражданлыгы бар.
**– Вакытында гражданлык турында үз законыбыз ике укылышта кабул да ителгән иде.**
– Әйе, без ул законны эшләгән идек. Бәхәсләшә-бәхәсләшә, аны ике укылышта кабул иттек. Аннан соң ул чактагы спикер В. Лихачёв аны Русия һәм чит ил юристларына күрсәтәбез дип ышандырды. Закон өченче укылышта кабул ителмичә калды. Әгәр без аны кабул итсәк, бәлки, күпмедер алга китеш булыр иде.
**– Аны барыбер Русиянең суд органнары гамәлдән чыгарырлар иде.**
– Анысы да бик мөмкин. Әмма ул безнең күңелебезгә кереп калыр иде. Татарстанның гражданлык турында законы булган, димәк, бу мөмкин нәрсә дип уйлар идек. Бу нәрсәне эшләргә ярый, ярамый дип утырмаска, алга карап эш итәргә кирәк. Әгәр без акрын-акрын алга барсак, чигенүләрне дә халык аңлар, безне гаепләмәс.
Гомумән, бүген Татарстанның дәүләтчелеген ныгыту өчен мөмкинчелекләр элеккегә караганда күбрәк. Чөнки без 1990 елда – Декларация, аннары Конституция кабул иткәндә коммунистик режимнан кучеп кенә бара идек. Аңнарыбыз да яңа гына уянып килә иде. Без – коммунистик идеяләрдә тәрбияләнгән буын. Соңгы 10 елда яңа буын формалашты. Алар бөтенләй башка аң, идея, менталитет белән тәрбияләнделәр. Яшьләрнең мөмкинлекләре безнекенә караганда бик күпкә артык булачак. Тагын 10 елдан бу буын тиешенчә өлгереп җитәр, дәүләтчелегебезне яңа баскычка алып менә алыр дип ышанам.
**– Ләкин бит шунысы да бар: Ельцин Путинны үзенең варисы, эшен дәвам итүче дип атаган иде, ә ул читкә борыла...**

– Билгеле, Ельцин заманында милләтләр өчен күпмедер дәрәҗәдә ирек бирелде. Ә Путин, Русия дәүләтенең таркала башлавын күреп, үзенең каты кулы белән аны җыярга тырышты. Әмма дәүләтне көч белән генә җыеп булмый. Чөнки ирекне бер татыган кеше ул дөньяда нәрсә булганны күреп тора. Дөньяда бөтенләй башка төрле процесслар бара. Әгәр Русиядә милләтләргә, халыкларга ирек бирелмәсә, аның киләчәге дә шик-шөбһә астында калачак.
Татарстанның Русиядән чыгу турында бер генә закон да кабул иткәне юк. Мин моны мөмкин нәрсә дип тә санамыйм. Русия ул урыс дәүләте генә түгел, ул безнең дәүләт тә. Русияне урыслар гына кормаган. Русия – Алтын Урданың варисы, Татарстан да Алтын Урда варисы. Бәлки, без күбрәк аның варисыдыр да. Русияне урыс халкы белән бергә татарлар да төзегән, шуңа күрә ул безнең дә ватаныбыз. Русиядә бүген 5 миллионнан артык татар яши, бу әле рәсми исәп буенча гына. Бәлки, ул 10 миллиондыр, катнаш гаиләләрдә туган балаларны исәпләгәндә, 20 миллиондыр да. Безнең Русиядә үз өлешебез зур. Без аны кемгәдер бүләк итеп китә алмыйбыз.
**– Әмма Русияне таркалмас дип әйтеп булмый...**
– Мин 90 нчы еллар башында ук «Русиянең киләчәге конфедерациядә» дип язып чыккан идем. Бүген дә ул фикеремнән кире кайтканым юк. Русия унитар дәүләт булып яши алмый. Империянең, көч-куркытуга таянып корылган дәүләтнең киләчәге юк. Русия демократик юлдан барырга, субъектларга ирек бирергә тиеш. Республикалар үзләре теләп тупланырга тиеш. Безнең кендекләребез береккән. Минем Башкортстан татарларыннан да, Чиләбе татарларыннан да аерыласым килми. Әгәр без аерылып китәбез икән, бу милләтебез тамырына балта чабу булыр иде. Татарстан бүген Русияне федераль дәүләт итү юнәлешендә зур эш башкара. Безнең Конституцияне якларга, Татарстан суверенлыгын сакларга тырышуыбыз – Русияне федераль дәүләт итәргә омтылышыбыз да ул. Президент М. Шәймиев тә бу хакта һәрдаим әйтеп килә. Татарстан Конституциясен Русиянекенә тәңгәлләштерүгә өндәүчеләрнең кайберләре, күрәсең, Русия Конституциясен укып та карамаганнар. Анда да «Русия составындагы республикалар «дәүләт» дип язылган.
Безнең Конституция белән килешмәүчеләр шактый булыр, судка да мөрәҗәгать итәрләр. Ләкин түзәрбез. Русиянең үз законнары да Конституциягә тәңгәл түгел. Без законнарыбызны шулар белән тәңгәлләштердек. Шартнамәнең кайбер маддәләре Конституция белән каршылыкка керә. Путин, шартнамәләр легитим, әмма алар киләчәктә Дәүләт Думасында закон буларак расланырга тиеш, диде. Аны закон дәрәҗәсенә җиткерү, бигрәк тә Федераль җыен аша уздыру авыр булачак. Безнең алда зур сынау тора. Йөздән артык законыбыз үзебезнең Конституциябезгә каршы килә. Аларны да яраклаштырасыбыз бар. Без бүгенге көндә Татарстанның икътисади базасын, сәяси нигезен ныгыту, халыкның тормыш хәлен яхшырту турында кайгырту урынына шулар белән шөгыльләнергә мәҗбүр булачакбыз.
Мин – гамәлдәге Конституцияне кабул итүдә катнашкан кеше, аны үзгәртү миңа бик авыр булды. Ләкин башка юл юк иде.

*Әңгәмәдәш Әгъзам Фәйзрахманов*
*2002*

# КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНАМ...

**– Әйдә, сүзне бала чактан башлыйк әле. Синең «Ялкын» журналында эшләгән чакларыңны хәтерлибез. Бала чагыңны сагынасыңмы? Сагынсаң, ничек итеп?**

– Ни әйтсәң дә, балачак бүгенге тормышымнан күпкә матуррак, кызыклырак тоела. Без бит күпләребез бала чакта «зур кеше» булырга хыялланып яшибез. Ләкин дөнья үзенекен итә, һәркемнең тормыштагы урынын билгеләп куя. Бала чакны сагыну табигый хәл. Кешенең гомере гел нәрсәнедер сагынудан тора. Мин, мәсәлән, төшләремдә бала чагымны еш күрәм. Болар – инеш, елга, чаңгы-чана шуулар яисә балык тотулар. Минемчә, балачак хисен югалтмаган кеше генә язучы була аладыр.

**– Язучы булу Ходай Тәгалә бүләк иткән бер тәкъдирме, әллә һәркем үзенчә тырышкан үҗәтлекме?**

– Менә хикмәти нәрсә: олыгайган саен, Ходай Тәгаләгә ныграк ышана барасың. Мин үзем бар нәрсә дә Ходайдан дип уйлыйм... Язучы шундый кеше ул – аның халыкка әйтер сүзе бар. Әйтер сүзе булган кеше, һичшиксез, каләмгә тотына, әйтер сүзен әйтеп калырга ашыга.

**– Трибунадан, телевизор аша, үзебезнең хөрмәтле язучыларыбызны шактый еш күреп торабыз. Сез һәммәгез дә дөрес һәм акыллы фикерләр әйтәсез. Депутат әдипләрнең мөһим сүзләрен, кыйммәтле фикерләрен аңлаучы түрәләребез бармы?**

– Безнең алдагы парламент усалрак, мөстәкыйльрәк иде. Шул чакларда үзебезнең гербны, флагны һ. б. булдырдык. Бу инде тарихка кереп калды. Хәзер исә шундыйрак хәл: милли хәрәкәт сүлпәнәйде.

Депутатларны, әйе, халык сайлый. Халык исеменнән эш йөртеп, халык мәнфәгатен кайгыртып, әдәбият, сәнгать, мәдәният, әхлак хакына бик мөһим эшләрне эшләргә була. Төрле караштa булуга карамастан, депутатларның күбесе моны яхшы аңлый. Кайчагында мин микрофонга «ялгыз бүре» буларак та чыккалыйм.

Җөмләдән, мисал. Туфан Миңнуллин белән бергә киңәшеп, Татарстан гражданлыгы һәм республикабыз паспортын булдыру хакында тәкъдим белән чыктык. Чынлап торып аңлатсаң, килешәләр икән. Хәтта урыс милләтле депутатлар да безне хупладылар.

**– Разил әфәнде, хакимият башлыкларын «автоматически» рәвештә депутат ясау дөрес эшме? Юкса алар, үз төбәгендә үз эшләре белән шөгыльләнеп, Татарстанга күбрәк файда китермәсләр иде микән?**

– Безгә демократия җитми. Парламент ул, нигездә, законнар чыгара һәм аларның үтәлешен контрольдә тота торган орган. Миңа калса, алга таба безнең парламент ике өлештән торырга тиеш. Беренчесе – законнар чыгара торган даими эшләүче, профессиональ әзерлекле депутатлардан торган палата. Икенчесе – вәкилләр палатасы, ягъни, болар – киңәшчеләр. Район хакимият башлыклары менә шушы статуска тәңгәл килә дә инде. Уенын-чынын кушып әйткәндә, алар шактый гына алышынып та торалар. Һаман саен депутат сайлау исә бюджет кесәсенә кыйммәткә төшә.

**– Бу тормышта сине иң нык борчыганы нәрсә?**

– Кызыклы сорау бу. Миңа калса, безнең илдә кеше кадере булмау – иң зур бәла. Балаларга кадер юк, өлкәннәргә, ягъни пенсионерларга кадер юк. Минем АКШ, Төркия һәм башка чит илләрдә булганым бар. Анда кешегә кадер-хөрмәт зур. Шаккаттым: инвалид кешене самолёт трабыннан төшерү өчен Нью-Йорк аэропортында махсус автобус килеп туктады!..

Икенчесе. Бездә түрә кешегә – чиновникка барып керү бик кыен мәсьәлә. Нью-Йоркта яшәп яткан милләттәшем профессор Рифат әфәнде Таби белән без АКШ конгрессы китапханәсе директорына шылтыраттык. 30–40 минуттан соң безне шәхсән каршы алды ул, озак кына сөйләшеп утырдык. Бездә булса, ул дәрәҗәдәге кеше янына керер өчен атналар-айлар буе чират көтәргә туры килер иде әле.

**– Элегрәк «СССР таркала» дисәк, моңа берәү дә ышанмас иде. Хәзер инде күпмилләтле Рәсәйдә яшәп ятабыз. Фаразың ничек: 10–15 ел эчендә Рәсәй шулай ук таркалып төшмәс микән**?

– Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: көннәрнең-елларның берсендә империяләр барыбер таркала. Акылына килми һәм милли сәясәттә гадел чишелешләр тапмый икән, Рәсәйгә дә әнә шундый куркыныч янап тора. АКШ һәм Кытайның да көннәрнең берендә «сүтелеп» китүе бар.

Дөньяда таркалмый, бүленми торган нәрсә юк. Хәтта кечкенә генә молекула да таркала. Шулай булгач, империяләрнең таркалуы бер дә гаҗәп түгел.

**– Синең өчен шагыйрь булу кызыклыракмы, әллә сәясәтче булумы?**

– Икесе дә кызыклы. Иҗатымда да, сәясәттә дә мин милләтем, туган тел өчен борчылам.

**– Әйтик, йөз елдан соң татар кая таба барып җитәр икән? Туган телебез исән калырмы?**

– Әгәр дә татар исән калмый дип уйласам, мин милләтем өчен янып та тормас идем. Татар калачак. Вакыт агышы безне тарихтан берничек тә сызып ташлый алмаячак. Киләчәккә ышанам...

**– Бүгенге яшьләрне кайсы яктан сүгеп була, кайсы сыйфатларын мактап була?**

– Яшьләрне сүгү – картлар, өлкәннәр эше. Мин бит әле андый яшькә җитмәгән...

**– Илле яшьне узып киткән арада нинди ачышлар ясап өлгердегез?**

– Алар байтак инде. Ә шулай да иң зурысы – гомер бик кыска икән! Бу ачышка, мөгаен, бик күпләр барып төртеләдер.

*Әңгәмәдәш Рашат Низами*
*2003*

# ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР

**– Разил әфәнде, «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Закон кабул ителүгә 10 ел тулды, беренче сорауны кабыргасы белән куям: ни өчен без бу законны кабул иттек? Аның хаҗәте бар идеме?**

– Һичшиксез. Бу закон 10 ел элек түгел, безгә күптән кирәк иде инде. Чөнки газиз ана телебез 50–80 нче елларда әкренләп сүнүгә, югалуга йөз тотты. Аңлагыз, мин мәсьәләгә бик үк өметсез карый торган кеше түгел, телебез тулысынча бетәр иде дип әйтә алмыйм. 450 ел буена патшасыз, хөкүмәтсез, дәүләтсез яшәп тә бетмәде, югалмады ул. Әмма телебез, бик нык хәлсезләнеп, бары тик әби-сәби белән генә сөйләшә торган телгә әйләнеп калырга мөмкин иде.

Әгәр тел чын мәгънәсендә дәүләт теле икән, аның киләчәге булырга тиеш. Балалар бакчасыннан алып югары уку йортларына хәтле мәгариф системасында, мәдәният тармагында, урамда, трамвай-троллейбуста – һәркайда аны кулланырга кирәк. Җәмгыятьнең барлык даирәләрендә кулланылмый торган телне тулы канлы тормыш белән яши дип булмый, һәм аның киләчәге дә бик үк өметле түгел.

80 нче еллар азагына кайтыйк әле. Ул чакта Казан шәһәрендә татарча белем бирүче бары тик 10 нчы интернат-мәктәп кенә эшләде. 35 нче һәм 80 нче мәктәпләрдә исә ана телебез өлешчә укытылды. Башкала тулысынча диярлек татар теленнән ваз кичү юлына басты. Татар телендә чыгучы газета-журналларыбыз бармак белән генә санарлык иде. Башка тармакларда да мактанырлык эшләребез булмады. Транспортта мәгълүматлар урысча гына бирелде. Хәтта чын татар авылларында да бөтен шигарьләр, лозунглар урысча язылды. Товар исемнәре, аларга аңлатма язулары шулай ук фәкать урысча гына эшләнде.

Телебезне мондый авыр хәлдән чыгару өчен бердәнбер дөрес юл «Татарстан халыкларының телләре турында» Закон кабул итү иде, һәм ул гамәлгә керде. Ә ни өчен Татарстан халыкларының телләре? Сәбәбе гади. Татарстан – күпмилләтле республика. Әгәр татар телен үстерү турында гына закон кабул ителсә, ул дөрес аңлашылмас иде. Бәлки әле, андый законны парламент аша да үткәрә алмас идек. Чөнки Югары Советтагы 250 депутатның яртысыннан артыгы татар түгел, шактый өлеше урыслашкан татарлар булды. Ә закон кабул ителсен өчен, депутатларның яртысыннан артыгының тавыш бирүе кирәк.

**– Башка халыкларның телләре үсүдән татарга зыян килми бит.**

– Зыян юк, билгеле. Әгәр без Татарстанда бер-беребез белән килешеп яшәргә телибез икән, без барлык халыкларның да ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, аларга тигез карарга тиешбез. Шунлыктан бу бер татар теле турында гына түгел, бөтен Татарстан халыкларының телләре турындагы закон булды.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар: әгәр без республикада яшәүче мари, мордва, чуваш, удмурт һәм башка халыкларның телләре турында кайгыртабыз икән, димәк, ул республикаларда да татарларга мөнәсәбәт яхшыра. Без шуңа өметләнәбез.

Закон кабул ителгәндә, бер маддәдә «аны гамәлгә ашыручы дәүләт программасы булырга тиеш» дип язылган иде. Программа әзерләү, аның буенча фикер алышу өчен ике ел вакыт кирәк булды. Программа кабул ителгәннән соң, закон конкрет рәвештә тормышка ашырыла башлады. Барыбыз да күреп торабыз, программа нигезендә бик күп эшләр башкарылды. Телебез тернәкләнеп китте. Мәктәпләребез, гимназияләребез, лицейларыбыз ачылды, яңа газета-журналлар барлыкка килде. Яңа нәшриятлар оешты. Телевидениедә һәм радиода яңа каналлар эшкә керește.

Татар теле дәүләт структураларына да үтеп керә башлады. Әмма ләкин без тулаем бу законның үтәлешеннән канәгать түгел әле. Беренче кимчелек шул: программада «Телләр турында»гы Законны гамәлгә ашыру механизмы күрсәтелмәгән иде. Мәсәлән, канунның беренче маддәсендә аны бозучыларны җавапка тарту хакында әйтелә. Ләкин ничек җавапка тартыла, бу эшне нинди оешма башкара? Әлеге сорауларга җавап юк иде. Һәм менә, ниһаять, Татарстанда административ җаваплылыкка тарту турындагы кодекс эшләнде. Дөрес, кодекс проектында «Телләр турында»гы

Закон кертелмәгән иде. Беренче укылыштан соң безнең комиссия андый маддәне кертте. Кодекс өченче укылышта кабул ителде инде, президент кул куйгач, ул гамәлгә керәчәк. Киләчәктә инде «Телләр турында»гы Законның бер җөмләсе генә бозылса да, судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Гаепле кешене биш минималь хезмәт хакыннан ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штрафка тартып була. Бусы – матди җаваплылык. Моның әле әхлакый ягы да бар бит. Суд карарлары матбугатта чыга, радио һәм телевидениедән хәбәр ителә.

**– Даими комиссия утырышында Сез «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законга төзәтмәләр кертү хакында да сүз алып бардыгыз. Бу законга нәрсә җитми? Нинди үзгәрешләр кертергә җыенасыз?**

– Законны конкретлаштырасы бар. Мин алдарак, законны гамәлгә ашыру механизмы кирәк, дип әйттем. Әгәр «Телләр турында»гы Закон бар һәм аны тормышка ашырырга кирәк икән, димәк, моның өчен җаваплы конкрет оешмалар, җаваплы кешеләр булырга тиеш.

Татарстан хөкүмәтендә халыкларның телләрен үстерү буенча махсус бүлек ачуга ирештек. Анда 3–4 кеше эшли. Әмма закон кадәр законны 3–4 кеше генә гамәлгә ашыра аламы соң? Моның өчен һәрбер районда, һәрбер шәһәрдә җаваплы кешеләр булырга тиеш. Билгеле, җаваплы кешеләр формаль төстә билгеләп тә куелыр. Кайбер урыннарда хакимият башлыгы урынбасарларына андый бурыч йөкләнә. Әмма бу эшнең җәмәгать башлангычы тәртибендә генә башкарылуы көтелгән нәтиҗәне бирми.

Әгәр гражданнар нинди дә булса чиновникка мөрәҗәгать итсәләр, ул исә телне белмәү аркасында җавап бирүдән баш тартса, бу кеше хокукын бозу дигән сүз. Мондый очракта кеше кая барып егылырга мөмкин? Тел мәсьәләләре буенча милициягә барып булмый бит инде.

– **Милициядә аны кабул итмәскә дә мөмкиннәр.**

– Әйе. Менә шундый җаваплы дәүләт кешеләре булырга, алар каршында комиссияләр төзелергә тиеш. Комиссия, шикаятьне тикшереп, закон бозган кешене җавапка тарту мәсьәләсен хәл итә, башка көндәлек эшләрне башкара. Урамнарны, кибетләрне, базарларны бизәгәндәге язуларның дөреслеген дә шул кешеләр күзәтеп-карап торырга тиешләр.

Законга өстәмәләрдә менә шушы мәсьәләләр күз алдында тотыла. Аны гамәлгә ашыруда иң эшләнмәгән өлкә – дәүләт структураларында ике дәүләт телен, бигрәк тә татар телен файдалану мәсьәләсе. Әгәр президенттан, хөкүмәттән, Дәүләт Советыннан башлап авылдагы җитәкчеләргә кадәр гамәлдә татар телен кулланмыйлар икән, монда гади халык турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Иң әүвәл җитәкчеләребез һәм алар кул астындагы чиновниклар үрнәк күрсәтергә тиеш. Дәүләт Советы ике телдә эшләмәсә, шәһәр Советлары да татар теленә хөрмәт күрсәтми. Президент Аппараты ике телдә сөйләшмәсә, ничек итеп район һәм шәһәр хакимиятләре алай эшләсен?!

Бу очракта мин президентны тәнкыйтьләргә җыенмыйм. Дәүләт Советына президентның һәр указы ике телдә килә. Башка эш кәгазьләре дә аңардан ике телдә керә. Ә менә хөкүмәт башкаларга үрнәк күрсәтә алмый әле. Бик күп оешмалар безнең татарча хатларга җавапны урысча сырлый. Без аларны кисәтәбез инде. Мәгълүм законга төзәтмә кертелгәч, андыйларны җавапка тартмый булмас.

КамАЗ, Түбән Камадагы «Нефтехим», Горбунов исемендәге авиация, вертолёт, «Органик синтез» кебек эре предприятиеләргә барсаң, аларда татарча сыңар сүз дә таба алмыйсың. Татар теле аларның бусагалары аша да үтеп керә алмады әле. Әйтерсең лә бу предприятиеләр бөтенләй башка илдә, башка республикада яшиләр. Законнарыбыз аларга кагылмый кебек. Билгеле, алар – Россия дәрәҗәсендәге предприятиеләр. Ләкин анда да бит безнең гражданнар эшли, яши. Ул предприятиеләр безнең законнарга буйсынырга, аларны хөрмәт итәргә тиешләр. Без шушы мәсьәләне дә аерым бүлек итеп законга кертмәкче булабыз.

Мәгълүм ки, югары уку йортларында татарча укыту һәм татар телен өйрәтү һәрвакыт актуаль. Бу уңайдан законга тагын бер бүлек өстәргә уйлыйбыз. Әгәр дә яслеләрдән, балалар бакчаларыннан башлап югары уку йортына кадәр өзлексез милли мәгариф системасы булмый икән, «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законыбыз тулысынча тормышка ашты дип әйтә

алмаячакбыз. Чөнки югары уку йорты анда укучы студентларны гына тәрбияләп калмый, ул безнең киләсе буыннарны да тәрбияли бит.
**– Әле шул ягы да бар, анда укый торган кешеләр иртәгә төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр булып эшләячәкләр...**
– Һичшиксез. Җитәкчеләр арасында ике телдә эшли алырлык кешеләр бик аз. Менә Татарстан парламенты 400 гә якын закон кабул итте. Шул законнарның берсе генә дә татарча язылмады. Ни кызганыч, татарча закон язарлык дәрәҗәдә ике телне камил белгән юристларыбыз да, икътисадчыларыбыз да юк. Ә бит, гадәттә, законнарны алар яза. Депутатлар исә шулар әзерләгән проектларны тикшерәләр, кабул итәләр.
Узган 10 елга күз ташлап, тагын шуны әйтә алам: «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законны кабул иткәч, без республикада ике телне дә белергә тиешле кешеләр исемлеген булдыра алмадык. Дөрес, бу мәсьәлә күп тапкырлар күтәрелде. Комиссия исеменнән мин дә хөкүмәткә 4–5 мәртәбә мөрәҗәгать иттем. Югыйсә андый исемлекне булдыру дәүләт программасында каралган. Хөкүмәткә 1994 елның ноябренә кадәр шул исемлекне парламентка тапшыру бурычын да куйган идек. Инде сигез елдан артык вакыт үтте, әмма без Министрлар Кабинетыннан ул исемлекне ала алмадык.
**– Ике телне белүче кайбер белгечләргә өстәмә түләү тәртибе кертелгән иде.**
– Әйе, кертелде. Ә исемлек һаман да юк. Дөрес, андый исемлекне төзү авыр нәрсә, һөнәр ияләре күптөрле. Аларның кайсыларына ике телне белергә кирәк? Бу хакта бәхәсләр күп. Без инде берничә вариант тәкъдим иттек.
Минем фикеремчә, иң беренче чиратта ике телне дәүләт хезмәткәрләре белергә тиеш. Ике дәүләт телен белмәгән кеше дәүләт хезмәтендә эшләмәскә тиеш. Дәүләт хезмәткәре шактый югары хезмәт хакы ала, киләчәктә пенсиясе дә югары булачак. Аңа башка күп кенә ташламалар каралган. Ничек инде дәүләт хезмәткәре дәүләт телләрен белмәскә тиеш? Бу – бәхәссез. Эшне шуннан башларга кирәк. Йөз җөмлә өйрәнү өчен аерым вуз тәмамларга кирәкми.
**– Сөйләм телен дип әйтергә телисезме...**
– Әйе, аралашу телен. Килгән кешенең нәрсә әйткәнен аңлау, аңа кимендә берничә җөмлә белән җавап бирү дәрәҗәсендә. Бер кереп киткәч, үзеннән-үзе шомара ул. Һәр чиновник алдында шундый бурыч куелырга тиеш. Әмма шушы нәрсә эшләнмәде.
Мин дөнья буйлап күп йөрдем. Шундый бер язылмаган закон бар: яшәү, эшләү өчен кирәк булмаган телне өйрәнү мәҗбүри түгел. Өстәмә хезмәт бит ул. Дөрес, сәләтле, аң ягы югары булган кешеләр аларын да өйрәнергә мөмкин. Ә менә кирәк булган очракларда өйрәнәсең инде. Ул яктан иң кулай мисал – Израиль. Анда хәзер бик күпләр күчеп килә. Израильдә дәүләт теле булган иврит телен белмәсәң, бер эшкә дә, хәтта чүп түгүче итеп тә алмыйлар.
Татарстанда андый система эшләнмәгән әле. Татарстанда урыс телен белмичә яшәп булмый, ә татар телен белмичә яшәргә була. Татар телен белмичә татар теле укытучылары һәм татар театры артистлары гына яши алмый. Хәтта муллаларыбызның да шактые татар телен җүнләп белмиләр.
Шулай бервакыт Канаданың Квебек парламентында телләр турында сөйләшеп утырабыз: «Без программада татар теленә күбрәк игътибар иттек, аңа күбрәк мөмкинлекләр бирергә тырыштык. Чөнки безнең татар телен урыс теле дәрәҗәсенә күтәрәсебез бар», – дидем мин. Алар аптыраштылар. «Ничек инде татар телен урыс теле дәрәҗәсенә җиткерергә? Сез аны төшерергә уйлыйсыз мәллә? Республика дәүләт бит инде ул», – диләр.
Үзебезнең телнең хәлен һич кенә дә аңлатып булмый боларга. Татарстан дәүләт булгач, татар теленең дәрәҗәсе дә бик югары, рус теленә караганда артыграк булырга тиеш дип саныйлар алар.
**– СССРда союздаш республикаларның төп милләт халыклары телләре татар теленнән күпкә статуслырак, көчлерәк иде.**
– Көчлерәк иде. Безнең бит Россия составында булуыбызга да 450 ел узды. Дөрес, патша Россиясе вакытында татар теле 90 нчы еллар башындагы дәрәҗәгә үк төшмәгән иде. Югыйсә Россияне «халыклар төрмәсе» дип йөрттеләр. Патша хөкүмәте дәүләт исәбеннән татарларга бер мәктәп тә, мәдәният йорты да, мәчет тә ачмаган ачуын. Бөтенесен татар үз акчасына, хәер-сәдака

җыеп төзегән. Ләкин татар халкы телен дә, мәдәниятен дә саклап калган. Татар үз кабыгына йомылып яшәгән, аралашмаган, шулай итеп үз-үзен саклап калган.
Хәзер йомылып яшәп булмый, татар урыслаша яки башка милләткә күчә. Шуңа күрә бүгенге көндә хәлсез булу бик куркыныч. Хәлсез булсаң, бетәсең. Исән калу өчен көч тупларга кирәк. Шуңа күрә бүген безнең һичсүзсез үз дәүләтебез булырга тиеш. Дәүләтчелеге булмаган милләтнең теле саклану мәсьәләсе һәм киләчәге бик шикле. Дәүләт яклавыннан башка бүгенге көндә бер нәрсәне дә хәл итеп булмый. Җәмгыятьләр, мәдәни автономияләр дәрәҗәсендә генә яшәргә ярамый бүген. Дөрес, халыкның аңын үстерү өчен алары да кирәк. Әмма зур проблемалар дәүләт ярдәмендә генә хәл ителә ала. Шуңа күрә милли оешмаларыбыз дәүләт белән бергә эшләргә тиешләр.
Шушы көннәрдә генә Дәүләт Советы Татарстанда «Милли-мәдәни берләшмәләр турында» Закон кабул итте. Без аны ни өчен кабул итәбез соң? Бу закон татар халкы өчен генә түгел. Республикада марилар, мордвалар, удмуртлар, чувашлар һәм башка халыкларның оешмалары бар. Аларны да тупларга, тәртипкә салырга кирәк. Алар да үзләренең хокукларын, бурычларын белсеннәр. Алар да бит Татарстан гражданнары!
**– Сезнең комиссия «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законның үтәлешен тикшерү буенча Балык Бистәсендә, Минзәләдә һәм кайбер башка районнарда күчмә утырышлар үткәрде. Уртак кимчелекләр нидән гыйбарәт? Бүген нәрсә җитми?**
– Иң җитешмәгән нәрсә – хакимият башлыкларының, аларның ярдәмчеләренең мәсьәләгә бик формаль караулары. Күрәсең, бераз шауларлар да тынарлар дип уйлыйлар.
Бездә бит бик күп законнар, программалар үтәлмәде. 2000 елда СССРда бөтен кешеләргә фатир бирергә вәгъдә иттек. Бүгенге чиновниклар шушы мәктәпне узган кешеләр. Монысы да үтеп китәр, вакытлы гына нәрсәдер ул дип уйлыйлар алар. Әмма ләкин татар халкының тел проблемасы ул фатир проблемасы гына түгел. Ул – күңелгә, бәгырьгә кагыла торган проблема! Ул халыкның яшәве, яшәмәве белән бәйле. Бәлки, кайвакыт начар фатирда да торырга мөмкиндер. Ә теле бетсә, милләт яши алмый, үлә. Андый милләтнең киләчәге юк. Шуңа күрә моңа ниндидер кампания дип кенә карарга һич ярамый. Татар халкы яшәгәндә бу закон яшәргә тиеш. Бу закон яшәгәндә татар халкы да яшәр. Конституциядән кала, халыкны яшәтә торган төп законнарның берсе ул.
Мин тагын берничә дәүләт программасы кабул итәргә тәкъдим ясар идем. Беренчесе – татарның милли музыкасын үстерү программасы. Тел кебек үк милләтнең рухын, бәгырен, үзәген саклап кала торган нәрсә – ул музыка. Татар музыкасы дип кенә әйтергә ярамас аны. Татарстан халыкларының музыкаль сәнгатен үстерү, саклау һәм өйрәнү дәүләт программасы кирәк.
Театр сәнгатен үстерү буенча шулай ук дәүләт программасын эшлисебез бар. Әгәр дә безнең театр, музыка сәнгатьләребез булса, хәтерне яңарту өчен музейларыбыз турында документлар кабул итсәк, минемчә, халкыбызның гомере тагын да озаер.
Татарстан музейларында татар халкының тарихына кагылышлы бүлекләрне карагыз. Анда чабата, киез эшләпә кигән абзыйлар сурәтләнгән. Әйтерсең лә безнең ханнарыбыз, патшаларыбыз, баһадирларыбыз, полководецларыбыз, бөек шагыйрьләребез булмаган. Кайда соң алар? Ә менә урыс тарихын кара: анда патша да дворян! Дәреслекләрдә дә шулай сурәтләнгән. Татар – башкисәр, хәерче. Безгә музейларның концепциясен төзергә кирәк.
– **Хәтта татар халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев музеена да чабата элеп куйганнар. Ул Казан дәүләт университетында студентларга лекцияләр укып йөргән зур галим дә бит әле. Әйтерсең лә Мәһдиев гомере буе чабата киеп йөргән.**
– Татарга чабата «бөек» күршеләребездән XIX гасырда кергән. Ул хакта галимнәр яздылар инде.
Соңгы вакытларда «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законны гамәлгә ашыру шактый йомшарган иде. Киләчәктә аңа өстәмә көч бирү өчен без хөкүмәтнең хисабын тыңлыйбыз. Ун ел дәвамында ул нәрсә эшләгән? Хөкүмәт алдына бурычлар куярбыз. Законга өстәмәләр кертергә, программаны яңартырга исәп. Күпме акча каралуы да, кем җаваплы булуы да анда күрсәтелергә тиеш.

**– Казан шәһәре үрнәгендә, бәлки, бюджет керемнәренең бер процентын һәр шәһәрдә һәм районда «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законны гамәлгә ашыруга бирергә дигән җөмләне программага кертергәдер.**

– Андый өстәмәне законга кертергә ярый. Әмма «Телләр турында»гы Законга кагылышлы тагын бер законыбызның гамәлгә ашмавы күңелне борчый. Ул – латин графикасына күчү турындагы закон. Моның сәбәпләре берничә. Беренчесе – үзебезнең галимнәребезнең бер фикергә килә алмавы. Бәхәсләшеп төп максатны оныту, төп максат тирәсендә бер-берсен җиңәргә омтылу татарның традицион халәте инде. Икенчесе – без ун ел бәхәсләшеп ята торгач, Мәскәү, безнең башыбызга сугып, үзенең яна законын кабул итеп куйды.

Билгеле, мин бу мәсьәләдә Мәскәү эшчәнлеген хуплый алмыйм. Мәскәүнең мондый эшләргә тыкшынырга һич кенә дә хакы юк. Үз Конституциясен дә, халыкара хокук нормаларын да бозды ул. Мәсьәлә болай гына тукталып калмас, киләчәктә татар теле барыбер латин язуына күчәр дип уйлыйм. Ул безнең таләп кенә түгел, заман таләбе! Мин, китаплар чыгарган язучы буларак, моңа каршы булырга тиеш идем. Китапларымны укый алмыйлар дип. Әмма мин үзем турында гына уйлый алмыйм. Латинга күчү киләчәк буын өчен кирәк. Моны тыю, кайсы яктан карасак та, хокукый, цивилизацияле дәүләттә эшләнергә тиешле гамәл түгел. Беренчедән, Россия Федерациясе депутатларының бу эш белән шөгыльләнергә хаклары юк. Икенчедән, ул безнең телебезнең алга китешенә тормоз ясый. Шуңа күрә без моның белән генә туктап калмаячакбыз.

АКШта бик әйбәт традиция бар. Президент ел саен халык алдында хисап тота. Нәрсәләр эшләгән, икътисад, башка тармаклар күпмегә үскән, халыкның тормыш дәрәҗәсе яхшырганмы – шулар хакында ул тәфсилләп сөйли. Америка президенты узган ел ничә тапкыр музейда булган, ничә тапкыр театрда булган, концерт караган, күпме китап укыган – шул хакта да халык алдында хисап тота.

Бу җәһәттән безнең президентыбыз да театрларга, күргәзмәләргә актив йөри. Ә менә республика дәрәҗәсендәге башка җитәкчеләр, район һәм шәһәр хакимияте башлыклары мондый гамәлләре белән бик үк мактана алмыйлар.

Болар хакында мин нигә сөйлим? Әгәр чиновникларыбыз, зур түрәләребез мәдәниятле булса, милли гореф-гадәтләребезне, газиз ана телебезне үстерүгә зуррак өлеш кертерләр, чеп-чи татар авылларында күргәзмә материалларны, белдерү-лозунгларны урысча язып куймаслар иде.

**– Аннары мәдәниятне, сәнгатьне үстерү турында сүз барганда, гадәттә, без бюджетта акча юк, дип акланабыз. Булганын да дөрес файдаланмыйбыз.**

– Минем хисап буенча, спортка елына ике миллиард сумнан артык акча тотыла. Дөрес, аның барысы да бюджеттан түгел. 90 миллион сум чамасы бюджеттан. Калганы – башка урыннардан. Әмма алары да күктән төшми бит. Юллар салырга, сәламәтлекне ныгытырга, ишегалларын тәртипкә китерергә, йортлар ремонтларга дигән акча ул. Кыскасы, халык акчасы! Менә шушы 2 миллиард сум 4–5 команданы тотарга китә.

Нигә безгә ул кадәр профессиональ команда? Бер команда тот та, акчаның калганын массакүләм спортка җибәр. Спорт мәйданчыклары төзе, зуррак авылларда спорт мәктәпләре ач. Мәктәпләрнең һәрберсендә спорт мәйданчыклары булырга тиеш. Менә шул чагында халык сәламәт яшәр.

– **Казан шәһәр Советы сессиясендә дә бу хакта әйтелде. Берничә мең кеше өчен ике миллиард сум акча тоту дөрес нәрсә түгел.**

– Әле ул командаларда республикада туып үскән кешеләр дә юк. «Ак Барс»та, мәсәлән, бер татар.

**– «Рубин»га футболчыларны Бразилиядән чакыралар.**

– Мәскәү газеталары ««Ак Барс»ның еллык бюджеты 22 миллион доллар» дип яздылар. Ул 650 миллион сум дигән сүз. Анда 50–60 кешедер инде. Ә бөтен Татарстан мәдәниятенә – китапханәләргә, музейларга, театрларга, музыка, сәнгать мәктәпләренә, халыкның бөтен рухи тормышына 450 миллион сум акча бирелә. Бер хоккей командасына бөтен халык мәдәниятенә караганда акча 1,5 тапкыр артыграк тотыла. Бәйрәмнәрне дә чамадан тыш зурлап үткәрергә кирәкми, минемчә.

*Әңгәмәдәш Әгъзам Фәйзрахманов*
*2003*

# ГЛОБАЛЬЛӘШҮ: КЕМГӘ ФАЙДА, КЕМГӘ ЗЫЯН?

**– Глобальләшү темасын миңа Сез тәкъдим иткән идегез. «Бүген Җир шарында бөтен халыкны борчый торган бер проблема бар, ул да булса – глобальләшү. Ни гаҗәп, бу хакта бездә язмыйлар да, сөйләмиләр дә. Чит илләргә барып галимнәр, эшмәкәрләр, сәясәтчеләр белән очрашасың икән, әлеге тема беркайчан да читләтеп үтелми», – дигән идегез.**

– Мин күп кенә тарихчыларның, сәясәтчеләрнең язмалары белән танышып чыктым. Мәсәлән, И. Медведева һәм Т. Шишова дигән авторлар, глобальләшүнең иң соңгы максаты – дөньяда бер хөкүмәт идарә итә торган бердәнбер дәүләт төзү, диләр. Димәк, әлеге дәүләттә бер генә акча берәмлеге, бер генә халык, бер генә мәдәният, бер генә тел һ. б. булырга тиеш. Әле заманында Чыңгызхан да, бөтен Европаны, Азияне берләштереп, бердәм дәүләт системасын эшләгән: бер үк салымнар, акча берәмлеге, бер үк мәгълүмат алмашу чаралары һ. б. керткән. Аерма шунда гына – ул чорда дәүләтләрне юкка чыгармаганнар, ә ныгытканнар. Чыңгызхан булмаса, бүгенге Русия дәүләте барлыкка килер иде микән әле, монысы бәхәсле мәсьәлә».

**– Димәк, глобальләшүдән куркырга ярамый, аның файдалы яклары да шактый.**

– Әлбәттә, мәсәлән, экологик һәлакәт куркынычын алыйк. Климат җылына, җирдә энергия запаслары бетә бара, атмосферада озон катламы кими. Шуның өстенә кеше үзе дә Җир шарын әллә ничә мәртәбә юк итәрлек корал туплады. Әлеге глобаль афәтләрдән уртак көч белән генә котылырга мөмкин. Изге эшләр өчен берләшергә кирәк, мәсәлән, галәмгә очу, чит цивилизацияне өйрәнү өчен. Бу юнәлештә күпмедер дәрәҗәдә кулга-кул тотынып эшләү бара да.

**– Разил әфәнде, телеэкраннар аша еш кына глобальләшүгә каршы оештырылган пикетларны, демонстрацияләрне күрсәтәләр. Русиядә исә шылт иткән тавыш та юк. Әллә безнең илгә бернинди куркыныч та янамыйммы?**

– Безнең халык, беренчедән, глобальләшүнең ни икәнен аңлап бетерми. Икенчедән, Русия хәзергә шактый гына көчле дәүләт исәпләнә.

Соңрак аңа да чират җитәчәк. Чит илләрдә исә халык икътисади сәбәпләр аркасында урамнарга чыга. Бай илләр үзләренең төрле корпорацияләре аркылы көчсезрәк илләрнең ресурсларын үзләренә алалар, мәсәлән, ярлы илләрнең хезмәт ресурсларын, ягъни, эшче кулларны. Япония, мәсәлән, машина уйлап таба да, аны Азия, Африка илләрендә арзанга эшләтеп, дөнья базарында кыйбатка сата. Югары технологиягә ия булмаган илләрнең язмышы билгеле инде. Русия дә чимал базасына гына әйләнеп калды.

**– Сез Русияне кайсы илләр рәтенә кертер идегез? Аңа да чират җитәчәк, дип кисәтеп, куркытып та куйдыгыз.**

– Бөтендөнья дәүләте төзү өчен башка илләрне көчсезләндерергә, аларның бәйсезлеген бетерергә кирәк. Бу процесс бөтен дөньяда, шул исәптән Русиядә дә бара. Чит ил корпорацияләре, төрле оешмаларның йогынтысы көчәя. Хәтта Русия Конституциясендә халыкара законнарның федераль законнардан өстен икәнлеген язып куйдылар. Димәк, без инде үз законнарыбыз буенча гына яши дә алмаячакбыз.

Үзебезнең акчага килик. Хәзер ул доллар, евро белән тышауланган. Әле киләчәктә бердәм электрон акчаларга күчү турында да сүз бара. Бөтен дөньяда кешене номерлап, аларга электрон досье тутыру башланды. Русиядә бу эш идентификацияле салым номеры – ИНН аша эшләнә. Шулай ук «Русия территориясендә гражданнарны теркәү тәртибе турында», «Шәхси характердагы мәгълүмат җыю һәм саклау турында» Закон проектлары эшләнү дә тикмәгә генә түгел, һәр кеше өстеннән тоташ контроль урнаштыру һәм, кирәк икән, бөтен мәгълүматларны чит илгә җибәрү өчен бөтен шартлар тудырыла дигән сүз.

**– Бер мәкаләдә «Тиздән Русия килмешәкләр иленә әйләнәчәк, якындагы 50 ел эчендә Русия үзенең бушап калган җирләренә 253 миллион эмигрант кабул итәргә тиеш» дигән юлларны укыган идем. Разил әфәнде, шулай «бөек күченүләр» башланачагына, Русиянең юкка чыгасына ышанасызмы?**

– Җирле халыкны кысрыклау – бөтендөнья дәүләте төзүнең иң зур максатларыннан берсе.

Русиядә җирләрне теләсә кемгә сатуга рөхсәт итү демографик хәлне тагын да начарайтачак. Инде Русиянең көнчыгыш өлкәләрендә кытайлылар шул төбәк халкының ун процентын тәшкил итә. Дөньяның кайсы шәһәренә генә барып кермә, анда кытай урамнары, кытай рестораннары, хәтта кытай университетлары бар. Русиягә дә бу куркыныч яный.

Ил үзенең җирләрен сата башлый икән, бу инде җүнлегә түгел. Тарихтан бер мисал китерим әле. 1947 елга хәтле Израиль юк иде. Бай яһүдләр Фәләстыйндагы җирләрне сатып ала башладылар һәм шунда барып урнашып, дәүләтнең үзәген оештырдылар.

Аннан соң инде аерым дәүләт таләп итә башладылар. Әгәр Фәләстыйн җирендә яһүдләр яшәмәсә, Берләшкән Милләтләр Оешмасы дәүләт оешуга каршы килгән булыр иде, ә бу очракта ризалашмый кая барсын? Халыклар күченүе башланса, дөньяда яшәү рәвеше, тәртип бозылачак. Кайбер сәясәтчеләрнең Русия килмешәкләр иленә әйләнәчәк диюләрендә хаклык юк түгел. Минем тормышка ашмастай бер хыялым бар: әгәр дә бик бай бер татар табылып, Татарстан җирен сатып алса, Татарстанга кем хуҗа булыр иде? Әлбәттә, җир хуҗасы. Соңгы вакытта кабул ителгән законнар әлегә моңа киртә, тик тора-бара шул юлга басарга мөмкинбез.

**– Разил әфәнде, Русия таркалачак дигән фаразлар инде күптән әйтелеп килә. Русияне һәрьяклап көчсезләндерү сәясәте махсус программа буенча алып барыла дип тә ишеткәнем бар.**

– Мин моңа ышанам. Әле 60 нчы еллар азагында, 70 нче еллар башында ук АКШның иң күренекле сәясәтчесе, АКШ президенты Картерның милли куркынычсызлык буенча ярдәмчесе Збигнев Бжезинский бер программа язган иде. Ул иң элек СССРның ничек таркалачагын тәфсилләп аңлатып, бу процессның нигезендә икътисади һәм милли проблемалар ятуын дә әйткән иде. СССР нәкъ ул әйткән вакытта таркалды. З. Бжезинский программасының икенче өлешендә Русиянең таркалачагы да язылган. Моның беренче чаткылары күренә сыман. СССР ни өчен таркалды? Чөнки аның икътисады какшады, милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә каршылыклар килеп чыкты.

СССР җимерелүдә Ельцинны гаепләү генә дөрес түгел, чөнки шартлар өлгергән иде инде, Борис Николаевич таркалуны тизләтте генә. Русия икътисады да бүген тезләнгән хәлдә, милли сәясәтнең дөрес юлдан бармавын әйткән дә юк.

**– Разил әфәнде, бервакыт шушы ук темаларга сөйләшеп утырганда, Сез: «Чит илләрдә 25 миллион чамасы урыс, 7 миллион тирәсе татар яши, аларга монда кайтырга шартлар тудырырга кирәк, – дидегез дә шунда ук: Әлбәттә, бу гына проблеманы хәл итмәячәк», – дип, үз-үзегезгә каршы килгән идегез.**

– Мин иң элек Русиядә кешечә яшәр өчен шартлар тудырырга кирәк дигән фикер әйтмәкче булганмындыр. Халыкны көчләп күчерүнең файдасы юк. Җүнле илгә халык үзе күчеп килә ул.

**– Русиянең үз эчендә дә глобальләшү бара дияргә мөмкинме? Әгәр шулай икән, моның нинди сыйфатларын әйтеп китә аласыз?**

– Беренчесе – урыслашу. Әмма бу башка төрле урыслашу, урыс милләтенә әйләнү түгел. Чөнки урыс кардәшләребез үзләре дә бетеп баралар. Русиядә урыс милләте битлеге кигән, урысча сөйләшүче иссез-төссез нindидер бер милләт оештырырга омтылыш бара.

Икътисад өлкәсенә килсәк, бездә бөтен байлык – дәүләтнеке, ә дәүләт халыкныкы дип канга сеңдерелгән үзе. Конституциядә дә «бар байлык халыкныкы» диелгән. Ә асылда, бөтен байлык олигархлар кулына күчеп бара. Бүгенге көндә Русиядә 10 лап миллиардер исәпләнә, тик алар байлыгында минем өлешем дә бар дип әйтә дә, закон нигезендә таләп тә итә алмыйсың. Шулай итеп, халык байлыгы хисабына эреләнү бара.

**– Разил әфәнде, Сез «глобальләшүдән качарга мөмкин түгел, ул котылгысыз» дигән фикердә торасыз. Ә нишләргә?**

– Глобальләшүнең тискәре якларына каршы тору өчен аерым кешеләрнең көрәшүе генә җитми, ә бөтен халык, милләт мәнфәгатьләрен яклый торган дәүләт кирәк. Ә ул юк. Татарстан мөстәкыйльлек алса, үзен эреп югалудан күпмедер дәрәҗәдә саклап калыр иде, мөстәкыйльлеге шулай ук юк. Инде нинди юл кала? Безгә үзебезне яклардай ишләребезне табарга, уртак сыйфатлар, уртак мәнфәгатьләр булган дәүләтләр, халыклар белән берләшергә кирәк. Мин

киләчәктә казах, кыргыз, үзбәк һ. б. бу хакта уйлый башларлар дип өметләнәм. Хәер, башладылар да инде: мәсәлән, Олжас Сөләйманов, Чыңгыз Айтматов берләшү мәсьәләсен кат-кат күтәреп язып чыктылар. Глобальләшүгә багышланган халыкара конференцияләр үткәрүнең ешаюы да төрки дәүләтләрнең бу хакта шактый ук баш ватулары турында сөйли.

**– Былтыр Төркиядә узган шундый конференцияләрнең берсендә Сез дә катнаштыгыз бит, Разил әфәнде. Евразия берлеге төзү турында сүз кузгатмый калмаганнардыр?!**

– Мондый дәүләт безгә кулайрак. Без бит, мәсәлән, Латин Америкасына барып, үзебезгә иш эзләп йөри алмыйбыз. Үз янәшәңдәгеләр турында күбрәк уйларга кирәк. Бер фикер әйтсәм, Разил тагын үз-үзенә каршы килә дип уйларсыз инде. Менә без урыслашудан куркабыз. Ә бит, төптән уйлап караганда, безгә урыстан да якын милләт юк, төрки, мөселман халкыннан кала, диюем. Чөнки без урыс белән мең еллар янәшә яшибез, барыбыз да Алтын Урда балалары, менталитетыбыз бер үк, бер-беребезгә ияләшкәнбез. Мине урыс халкының йоклап ятуы борчый. Безне урыслар урыслаштырмый, чөнки үзләре авыр хәлдә. Менә театрларына гына барып кара: бөтен Русиясендә бер генә саф урыс театры юк, урыс телле театрлар гына бар. Аларның мондый хәлгә калуы – бер милләтнең дөньяны үз кулына алырга маташуында. Әлеге милләт инглиз телле дә, испан телле дә, күпмедер вакыт урыс телле дә булырга мөмкин... Әмма дөньяда бер генә милләт кала алмый. Ходай Тәгалә безне шулай төрле итеп яраткан. Табигать законнарына каршы килгәнгә, тормышыбызның бер дә рәте юк, төрле афәтләрдән баш чыкмый.

**– Ә Гыйрак сугышын глобальләшүнең бер чалымы дияргә мөмкинме?**

– Һәр сугыш глобальләшүгә бер адым ул: кемнеңдер өстенлек итәсе, үз яшәү рәвешен башкаларга сеңдерәсе килә. Гыйрак сугышы, бер караганда, диннәр, культуралар сугышы да.

Хәтерләсәгез, әле сугыш башлануның беренче көнендә үк мин сезгә, АКШ Гыйрак белән генә тукталып калмас, дигән идем, эш шуңа таба бара да.

**– Разил әфәнде, АКШка каршы башка мөселман илләре дә берләшә башласа, сугыш зурга китеп, ике системаның бәрелешенә китермәсме?**

– Юк. Үлчәүнең ике тәлинкәсе дә тигез булса, сугыш чыкмаячак. Элек СССР вакытында баланс саклана иде. Хәзер кайбер илләр, шул исәптән Русия дә, көчсезләнеп таркала башлагач, нindидер берлек төзү кирәклегенә калкып чыкты. Евразия берлеге төзү идеясе минеке түгел бит, күп сәясәтчеләр Җир шарында тигезлек саклануны шунда күрәләр.

*Әңгәмәдәш Риман Гыйлемханов*
*2003*

# МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘ – МӘҢГЕЛЕК МӘСЬӘЛӘ

**Шамил Хамматов.** Разил әфәнде, бүген татар җәмәгатьчелеген аеруча нык борчыган вакыйгаларны ачыклап үтсәгез иде.

**Разил Вәлиев.** Соңгы елларда, аеруча 2002 елда, төп игътибар Россиядә яшәүче татарлар белән бәйле булган ике мәсьәләгә юнәлдерелде. Әйтергә кирәк, болар татарларга гына түгел, ә, гомумән, илебезнең барлык халыклары яшәешенә дә кагыла. Беренчесе Бөтенроссия халык санын исәпкә алу булса, икенчесе – халыкларга үз язуларында кириллицадан башка алфавитларны куллануны тыючы федераль закон. Безнең халыкка бу латин графикасына күчүне рөхсәт итмәүгә кайтып калды. Чынлыкта федераль көчләрнең бу законны кабул итү максатлары да, нигездә, шул иде.

Әле халык санын исәпкә алу башланганчы ук Мәскәүдә татар халкын берничә өлешкә бүлгәләү сәясәте алып барылды. Башта Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты эшләгән схема буенча татарларны 5–6 этник төркемгә бүлсәләр (бу очракта федераль үзәк этник төркемне аерым халык итеп күрсәтергә омтыла иде), соңрак безне хәтта 40–45 вак төркемгә бүлүгә үк барып җиттеләр. Әлбәттә, мондый төр тәкъдимнәр татар җәмәгатьчелеген берничек тә битараф калдыра алмады. Бу мәсьәләдә Татарстан Республикасының дәүләт мәнфәгатьләре белән киң катлам халык мәнфәгатьләре туры килде. Әйтергә кирәк, Россиядә мондый тәңгәллек еш күзәтелми. Татарстан Республикасы президенты үз дәрәҗәсендә, ә республиканың Дәүләт Советы Россия президентына юллаган мөрәҗәгатендә безнең халыкны таркатуга, аның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен вак-вак кисәкләргә бүлгәләп, юкка чыгаруга илткән омтылышларга чын-чынлап каршылык күрсәттеләр. Безгә бербөтен халык буларак бетү куркынычы янады. Ә инде федераль үзәк тарафыннан тагылган схемалар татар халкын, гомумән, аның дәүләтчелеген торгызуга бернинди дә өмет калдырмый иде. Ләкин бу маташулар тиешле нәтиҗәсен бирмәде, чөнки, кабатлап әйтәм, республиканың югары даирәсе һәм татар җәмәгатьчелеге бер фикердә булды – халыкның бөтенлеген саклап калу стратегик линия дәрәҗәсенә күтәрелеп үз көчендә кала алды. Халык санын алу вакытында федераль хакимият күзгә бәрелеп торган гаделсезлекләргә барырга җөрьәт итмәсә дә, үз максатын тормышка ашырырга әйләнгеч юллар тапты. Россия Дәүләт Думасында Татарстан мәнфәгатьләрен яклаучы депутат Фәндәс Сафиуллин бу күрәләтә ялганны хокукый дәлилләр белән фаш итте. Ул Россиянең Статистика буенча Дәүләт комитетының халык санын алуда кулланган документларының ялган булуын раслады һәм бу эшнең нәтиҗәләрен дөрес түгел дип игълан итеп, аларны юкка чыгаруны көн тәртибенә куйды.

**Ш. Х.** Россия Президенты Владимир Путиннан кала безнең беребезгә дә туган телебез нинди булуы турында сорау бирмәделәр. Аңа исә Россия законы таләп иткән чын, махсус документ әзерләнгән булган...

**Р. В.** Әйе, сәяси итагатьлелек аңа карата гына сакланды. Күренгәнчә, миллионлаган кешеләрнең теләге, бигрәк тә милли азчылыкны тәшкил итүчеләр ихтыяры читләтеп үтелде. Кайсы халык кына үз-үзен саклап калырга теләми икән соң? Ә татар халкы Россиядә сан буенча икенче урынны саклап калырмы, юкмы дигән сорау, татарларның үзләреннән бигрәк, федераль һәм губерна хакимиятләренең күп кенә шовинистик рухлы вәкилләрен борчый. Әгәр дә татар халкын исәпкә алу буенча эшләнгән принцип белән барсак, урыс халкын да бихисап төрдәге этник төркемнәргә бүлеп булыр иде. Бу турыда сүз күп булды, ләкин ул «көн тәртибеннән» тиз алынды. Россия халыкларының милләт буларак үзбилгеләнү мәсьәләсендә эш ике төрле йөртелә. Бу – дәүләтнең цивилизацияле милли сәясәте юклыгын күрсәтүче ачык фактор.

**Ш. Х.** Әмма көчле административ ресурс та бар бит әле. Дәүләт органнары хәрәкәткә килгәндә, Россиядә яшәүче халыкларның алыштыргысыз хокуклары турында әйтелгән матур сүзләр шунда ук онытыла, юкка чыга. Россия Дәүләт Думасының бер депутаты белән рәсми булмаган әңгәмә вакытында минем «Сез «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Законга шул

дәрәҗәдә мәгънәсез төзәтмәләр кертүне яклап ничек шулай бердәм тавыш бирә алдыгыз?» дигән соравыма ул: «Безгә Татарстанны бар яклап та кысрыкларга дигән фәрман килде...» – дип җавап бирде. Димәк, федераль хакимияттәгеләр, безнең халыкны бүлгәләү кампаниясе барып чыкмагач, төп игътибарны латин графикасы мәсьәләсенә юнәлттеләрмени?

**Р. В.** Россиядә милләтара дуслыкка ирешү юнәлешендә эшләү турындагы купшы сүзләр үзәк хакимиятнең шовинистик карашларда торучы төркеме тарафыннан алып барыла торган сәясәткә бер дә туры килми. Бу очракта аек фикер йөртүче кеше, әлбәттә, Россия төбәкләрендәге, урыннардагы чын сәясәтчеләр, җәмәгатьчелек сүзенә колак салачак. Милли хәрәкәт вәкилләре исәпләвенчә, Мәскәүнең бүгенге сәяси элитасы Россиядәге федерализм үсешенә каршы киртә кора. Ул федерация субъектларына һәм, гомумән, анда яшәүчеләргә мөһим булган чын демократик үзгәрешләрнең дошманы буларак чыгыш ясый.

Бу яктан Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиевнең Дәүләт Советына юлламасы игътибарга лаек. Ул бирелә сүзне милли сәясәткә, Россиядәге федерализмга кагылышлы мәсьәләләрдән башлый. Соңгысын президент демократиянең территориаль төп өлгесе (каркасы) дип атый һәм аның бүген дә яклауга мохтаҗ икәнлеген белдерә. Татар теленең латин графикасына күчүе мәсьәләсенә килгәндә, президентыбызның сүзләрен цитата рәвешендә китерәсем килә: «Бу карар Бөтендөнья татар конгрессының өченче корылтае резолюциясенә, шулай ук Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре фикерләренә нигезләнде, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 68 нче статьясына туры килә. Ә бит әлеге Төп Законда дәүләт «үзенең барлык халыкларына туган телләрен саклауны, аларны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыруны гарантияли», республикаларга исә «үз дәүләт телләрен урнаштыру хокукын бирә» дип акка кара белән язылган. «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» РФ Законына өстәмәләр кабул итеп, үзәк чынлыкта үз Конституциясен, шулай ук кайбер халыкара нормаларны, аерым алганда, азчылык милләтләр хакындагы Европа кысаларындагы конвенцияне бозды. Мондый адымны телләрнең иректә үсешенә бәйле рәвештә халыкларның хокукларына һөҗүм дип карарга мөмкин. Ул гына да түгел, бу төзәтүләрне кабул итеп, Федераль җыен федераль субъектларның фәкать үзләренә генә караган вәкаләтләренә тыкшынды. Бу гамәлләрнең һәммәсе дә анык булмаган милли сәясәт җирлегендә эшләнә, кайбер намуссыз сәясәтчеләр һәм чиновниклар аларны үзләренең мәкерле максатларында файдаланалар».

**Ш. Х.** Федераль министрлык катнашы белән дөньяви мәктәпләрдә православие дәресләрен укыту мәсьәләсе үзәк тарафыннан җитди дәрәҗәдә куелганда, Россиядә яшәүче халыкларга сәяси итагатьлелек, ихтирам турында нинди сүз булырга мөмкин?

**Р. В.** Күптән түгел газетагызда Самарадагы бер мәктәпнең ишегалдында рәсми рәвештә чиркәү ачылу турында язылган иде. Анда хәтта шәһәр хакимияте башлыгы да катнашкан. Шушындый башбаштаклыкны урындагы җитәкчеләр «әдәп-әхлаклылыкны ныгыту акциясе» дип бәялиләр. Бу бер дә Россия җитәкчеләренең җәмгыятьтәге милләтара һәм конфессияара тигезлек турындагы белдерүләре белән туры килми. Бер яктан, кайбер тәкәббер дин вәкилләренең сүзләренә ышанып, Татарстанны бернинди нигезсез Россиядәге «ваһһабичылар оясы» дип күрсәтергә тырышалар (ә бит республикабызда ирешелгән милләтара һәм конфессияара килешеп яшәүне күптән инде бөтен дөнья таный). Икенче яктан, күпмилләтле өлкәләрнең берсенең әләмендә дәүләт символикасы буларак дини атрибутика кулланылу хупланыла. Мондый әләм төрле диндәге халыкларны берләштерә аламы икән соң? Сүз уңаеннан, Россия Федерациясе Дәүләт гербындагы сурәт тә бу максаттан ерак тора.

Латин графикасы мәсьәләсенә кайтып шуны әйтәсем килә: федераль үзәк үзенә үзе ерып чыга алмаслык мәшәкатьләр, тоталитар хакимияткә хас тискәре караш тудыра. Россиядә кеше хокукларын бозу гадәти күренеш санала. Ә бәлки, бу гамәл махсус эшләнә торгандыр әле.

Патша заманында төрки халыклар гарәп имлясында язганнар һәм аңа карап Россиянең бер генә җире дә «кимемәгән». Ә бүгенге сәясәтчеләр латин графикасына күчүне илнең куркынычсызлыгына яный дип лаф оралар. Үз җирендә яшәүче халыкларның табигый рухи ихтыяҗларын да канәгатьләндерә алмагач, бу нинди дәүләт була инде? Бүген төрле милләт халыклары иҗтимагый тормышның һәр өлкәсендә дә нәтиҗәле эш алып бару кирәклеген яхшы

аңлыйлар. Мондый тыюларның «җимешләре» озак көттермәс дип уйлыйм. Соң, кешенең сулавын да тыеп булмый бит инде. Ә биредә сүз бер кеше турында гына түгел, тулы бер милләт турында бара.

Бу яктан Карелия җәмәгатьчелегенең дә кискен ризасызлык белдерүен аңлап була. Карелларның милли язулары күптән инде латин графикасына нигезләнгән. Әмма республикага бу графиканы куллануны тыя алмыйлар, чөнки карел теле дәүләт теле булып саналмый. Бу республикада карел телен дәүләт теле дип игълан итү көн тәртибенә куелган иде инде. Нәкъ шушы вакытта федераль үзәк тарафыннан законга төзәтмәләр кертү исә аны бу мөмкинлектән мәхрүм итте. Бүгенге көндә үзбилгеләнү мәсьәләсен хәл итү алдында торган халык өчен бу, әлбәттә, көтелмәгән адым. Ләкин үзәк моның белән тамчы да исәпләшми.

Монда эш бер латин графикасы мәсьәләсе белән генә дә бәйләнмәгән. Аны куллануны тыю теләсә нинди мөстәкыйльлек һәм бәйсезлеккә омтылу күренешләрен бастыру буларак кабул ителә (болар белән татарстанлылар соңгы вакытка кадәр нигезле рәвештә горурландылар). «Субъектларны бар яклап та кысрыкларга» дигән әмер бирелүе дә шушы фактор белән бәйле.

Россиянең бу мәсьәләдә «ике яклы пычак» булуына тагын бер мисал: дөньякүләм дәрәҗәдә ул актив рәвештә үз милли мәнфәгатьләрен кайгыртучы ил буларак чыгыш ясый. Үз чиратында алар безнең җәмгыятьнең теләкләре белән дә тәңгәл килә. Ә үз дәүләте эчендәге халыкларның ихтыяҗларын күпсенә. Әлеге хәлдән чыгу өчен халыкларның иҗтимагый мәнфәгатьләрен кайгыртучы дәүләт институтлары булдыру зарур. Бу очракта мин, мәсәлән, Россиянең законнар чыгару органында милләтләр палатасы булдыруны күз алдында тотам.

Россиядә әнә шундый милли сәясәт алып барылганга, кешеләрдә туган илләре белән горурлану, ватандарлык хисләре әкренләп сүнә бара. Дәүләтебездә күпчелек халык социаль яктан якланмаган килеш, бездә гражданлык җәмгыяте төзелә дип белдерәләр. Бүгенге көндә Россия үз гражданнарын тышкы шартлардан – коррупция, талау, эшсезлек куркынычыннан яклый алмаган, хәерчелектән арына алмаган яшьлек, тиешенчә тәэмин ителә алмаган картлык кына бирә алырлык дәүләт сыйфатында калды. Шул ук вакытта дәүләт чиновниклары җәмгыятьнең җинаятьчел юл белән олигархка әверелгән катламын гына туендырып торучы инфляция, девальвация һ. б. кыргый базар мөнәсәбәтләре белән килешеп яшиләр. Нәтиҗәдә болар барысы бергә гади халык өчен яшәп булмаслык шартлар тудыра. Без нинди җәмгыять төзибез соң, бүгенге вазгыять нинди нәтиҗәгә китерәчәк – моны аңлаучы да, аңларга теләүче дә юк. Бүген аларга, империя амбицияләрен канәгатьләндерү урынына, халыкларны «Россия» дип аталучы уртак йортның түбәсе астына җыярга кирәк. Ә бу исә халыкларның тигез хокуклы, рухи һәм социаль-икътисади потенциаллары ягыннан бертигез дәрәҗәдә булуларын таләп итә. Ә республика һәм өлкәләргә сепаратизм ярлыгы тагып, сәламәт тамырларына балта чабуны мин гомумән аңламыйм.

**Ш. Х.** Федераль үзәк Татарстанның үз вәкаләте кысаларында куйган таләпләрен дә сепаратизм дип атады. Республиканың табигый байлыкларын, матди һәм рухи мөмкинлекләрен, фәнни-техник потенциалын кулланып, эчке социаль-икътисади үсеш мәсьәләләрен үзенчә хәл итү мөмкинлеген дә калдырмады. Хәзер төбәкләрне үз керемнәрен арттыру мәсьәләсе дә кызыксындырмый, чөнки табышның күп өлеше үзәктә калачак. Бу сәясәт шундый итеп төзелгән ки, дәүләтнең мөстәкыйльлеге, аның икътисади яктан тотрыклылыгы өчен көрәш алып бару бар яктан да мәгънәсен югалта. Инде тормышыбызның рухи, мәдәни ягына да кул суза башладылар. Бәлки, без, 90 нчы еллар башында яулап алган вәкаләтләребездән вакытында файдаланмыйча, бер урында озаграк таптанып торганбыздыр һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, икътисади һәм сәяси өлкәләрдәге үсеш тенденцияләрен ныгытырга өлгермәгәнбездер?.. Безнең бүгенге халәтебез җәмгыятьнең 80 нче еллар ахырындагы вазгыятен хәтерләтмиме? Татар халкына хәзер кайсы тарафка карап эш йөртергә соң?

**Р. В.** Без барыбыз да – коммунистик режим буын вәкилләре (мин урта һәм өлкән яшьтәгеләрне күз алдында тотам). Ул чорда бары тик халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм турында гына сөйләшергә ярады. Милли проблемалар, милли мәдәниятне торгызу һәм аны дәүләти яклау мәсьәләләре хәл ителмәде. 90 нчы еллар башында яуланган бәйсезлекне ничек файдаланырга икәнен без, гади генә әйткәндә, белмәдек тә. Озак вакытлар ябылуда булган кеше,

ireккә чыккач, авыр сынау – ирек сынавы үтә, диләр. Ул югалып кала, хаталар ясый, аны дөрес юлга юнәлтмәсәң, ялгышуы да бик мөмкин.
Безнең белән дә шуңа охшаш хәлләр булды. Җитәкләп йөртүчебез булмады һәм була да алмас иде. Халыкның тарихи хәтере уяну, җәмгыятьтә үз урынын һәм ролен аңлауга бәйле хис-кичерешләр, өметләр күп булды. Җимерелгән нигездә кабаттан яңарып килгән икътисад турында мин инде әйтмим дә. Көнбатыштагы сыман йөзләрчә еллар дәвамында оештырылып килгән демократик дәүләтне бездә нибары ун ел эчендә, әлбәттә, төзеп булмый иде. Безнең крепостнойлык хокукыннан котылуыбызга да 30 ел чамасы гына – әле крестьяннарга паспортлар күптән түгел генә бирелә башлады – аңа кадәр алар батрак хәлендә дип әйтерлек иде. Шуңа да карамастан Татарстанда, Россиянең башка төбәкләреннән аермалы буларак, соңгы елларда авыл хуҗалыгы күзгә күренеп үсте, республиканың җитештерү, икътисади яктан куәте сакланып калды. Әмма Россия икътисады (ә без аңа бәйле) хәрабәләрендә югары нәтиҗәлелеккә ирешү мөмкин түгел.
Үзәк, бүгенге көндә төбәкләрнең соңгы елларда үз-үзләренә җитәрлек тормыш итү өчен әзерләнгән таянычларын юкка чыгара барып, Россия федераль төзелешенең икътисади нигезен дә какшата. Вәкаләтләре артып киткән хөкүмәт элеккеге коммунистик режимның начар варианты хәлендә калырга мөмкин. Татарстан, Башкортстан, Свердловск өлкәсе һәм башка донор төбәкләр өчен бу бигрәк тә аяныч. Алар соңгы елларда артка тәгәрәдеме яки тезгенсез Россия базары стихиясендә эчке һәм тышкы хуҗалык элемтәләрен таба алмадымы әллә? Әгәр бүгенге кебек салымнарның төп һәм җиңел җыела торган өлеше федераль үзәккә җибәрелсә, ә төбәкнең табигый хокукы, икътисади иреге булмаса, димәк, аның югары нәтиҗәгә ирешергә җаваплылыгы һәм этәргече дә булмаячак дигән сүз. Демократик үзгәрешләр ихтималы биредә бөтенләй күренми. «Көчле төбәкләр – көчле үзәк» формуласы онытылды. Үзәкнең көчлегә әверелүе дә шикле, әмма аның хәрәкәтләренең тоталитар характеры ачыграк күренә бара. Барыннан да бигрәк төбәкләргә, димәк, аларда яшәүче халыкларга юнәлтелгән тоталитар характердагы эш-гамәлләр генә активлаша бара. Олигархлар Көнбатышка күчерелүче байлыкны арттырып кына бераз «җәфа» чигә.
Безгә, татарларга, нәрсә эшләргә соң? Милләтне саклап калу буенча рецептлар тәкъдим итәргә җыенмыйм, ләкин килеп туган хәл үзе үк ничек эш итәргә икәнен күрсәтә. Бу иң беренче чиратта Татарстанда – авырлык белән шытып чыккан бәйсезлек үсентеләрен саклап калу, шул исәптән дәүләт бәйсезлеген дә. Россия татарларына үзләренең тарихи Ватаннары Татарстан тирәсендә ныграк берләшү кирәк. Мин-минлекләрен канәгатьләндерү өчен генә ярсынган аерым шәхесләр артыннан иярү үлемгә тиң. Акыл һәм интеллект бездә Аллага шөкер, әмма болар гына җитми һәм тарихта татар халкы үсешен алар гына билгеләми, халыкның язмышын әби-бабаларыбыздан мирас булып калган көчле, какшамас һәм эшлекле халәтне саклау хәл итә. Халык санын алганда безне бүлгәләргә тырышу һәм үзебезнең язуны сайлап алуны тыюның милләтне көчсезләндермәве, ә киресенчә, аның гомуми куркыныч алдында берләшүе бик куанычлы хәл. Безнең оппонентларга уңай нәтиҗә китермәде ул.
Үзәк тырышлыгы белән сәясиләштерелгән татар мәсьәләсе башлыча культурологик, рухи, интеллектуаль һәм этник мәсьәләдән (ә бит татарлар, Татарстан беркайчан да Россиядән чыгып китәргә омтылмады) милләтнең исән калу проблемасына әйләнде. Татарларның күп кенә иҗтимагый оешмалары – милли-мәдәни мохтәриятләр, мәдәни үзәкләр, хәтта дини җәмгыятьләр бүген хокук яклау функцияләрен башкарырга мәҗбүр. Аларны моңа милли түбәнсетүгә юл куючы Россия дәүләте үзе этәрә.
Һәм алар хокукый, сәяси һәм икътисади яктан кысуга, чикләүләргә каршы торуда ялгыз түгел. Мәсәлән, танылган халыкара оешма, Бөтендөнья язучылар конгрессы – ПЕН-клуб, Татарстанга теләктәшлек белдерде һәм Дәүләт Думасының Россия халыклары язуын бердәйләштерү эшчәнлеген гаепләгән резолюция кабул итте. Безнең тарафтан үз чиратыбызда Россия Конституцион судына һәм халыкара судларга мөрәҗәгатьләр дә булырга тиеш. Тик шулай да безнең каршылыкларны административ ресурс түгел, ә вакыт һәм аек фикер хәл итәчәк.

Куелган сорауга кайтып, җавап бирәм: юк, без, агымсуга ике тапкыр кермәгән кебек, 80 нче еллар ахыры һәм 90 нчы еллар башындагы халәткә кире кайтмадык. Үзебездән коллык психологиясен һәм үзгәртеп коруга кадәр булган унъеллыклардагы зомбилаштыруны кысып чыгарып, XXI гасырга кердек. Безнең өчен бу «кече туган» комплексларыннан котылуга да тиң, аеруча Россия төбәкләрендә.

Каршылыклы тышкы шартларга карамастан, татар халкы фикерләү ирегенә, үзенең бөек үткәне белән горурлану ирегенә ия булды, милли үзенчәлекләрне саклап һәм үстереп, рухи һәм икътисади күтәрелешнең өметле булуына ышанды. Үзәк белән мөнәсәбәтләр катлаулы булса да, халыкның тарихи хәтерендә уянган дәүләтчелек фикере безнең аңга сеңде һәм ул бүген безнең өчен, икътисади булудан бигрәк, әхлакый-этик категория булып тора. Ә килер шундый вакыт, әлеге фикер матди көчкә әверелер. Россиянең күп кенә халыклары үзаңнарында шундый үзгәрешләр кичерә. Шул исәптән, соңарып булса да, рус халкы да. Башка халыклардан аермалы буларак, аларга үз мәдәниятләрен, тарихи фәнен, милли үзаңнарын үстерергә кем һәм нәрсә комачаулык итә соң?

**Ш. Х.** Әлбәттә инде, «аз санлы халыклар» түгел, чөнки аларның үз тарихларын торгызу яки мәдәниятләрен үстерү омтылышына «милләтчелек, бердәм һәм бүленмәс дәүләткә каршы гамәлләр» ярлыгы тагылды...

**Р. В.** Халыкларның милли рухиятен яклау Россия дәүләтчелегенең хәленнән килмәде. Киресенчә, агымдагы сәяси система рус мәдәниятенең хәлсезләнүенә китерде. 90 нчы елларга чаклы ул конкуренциядән читтә калды, һәм хакимият диктаты, «өлкән агай» өстенлеге белән алыштырылды. Бүген исә барысы да ап-ачык күренә. Үз-үзеңнән канәгать булу, үз-үзеңә соклану һәрбер милләтне рухи яктан чикли, сизгерлекне киметә. Әллә ни искитәрлек булмаган Көнбатыш мәдәнияте үрнәкләрен үзләштерү белән мавыгу россиялеләрнең рухи тормышын ярлыландырды. Хәзер үзәктән ерактагы төбәкләрдә мәдәният тизрәк үсеш ала. Россия мәдәният министры Михаил Швыдкой сүзләренә караганда, мәскәүлеләр җан башына мәдәни тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча илдә 52 нче урында тора, ә Ханты-Манси төбәгендә яшәүчеләр, халыкларның үзенчәлекле мәдәнияте үсеше ярдәмендә, 1 нче урында.

Русларга башка милләтләрнең милли үзаңы уянуы аңлашылмады, хәтта аларны куркытты да. Рус халкы исә үзе көнбатышның әхлакый колонизациясенә дучар булды – ягъни элеккеге идеологиядән калган бушлыкны тутырды. «Вак халыклар» моннан азрак зыян күрде, чөнки милли мәдәниятләрне торгызу вакыты килде, алар хәзер, нигездә, шуның белән мәшгульләр.

«Кече туган»ның рухи үсеш куәте буенча «өлкән агай»дан сизелерлек алга киткәнлеге ачыклангач, Россия галимнәре һәм культурологлары реформалар үткәрергә керește. Ә бу, мәгърифәтле зыялылардан ераклашкан хакимият әмере буенча эшләнгәндә, мәгънәсезлекләр китереп чыгара. Аларның рус телен чистартырга дип бөтенләй ялгыш юлларга кереп китүләрендә бу бик ачык күренде.

РФнең «Дәүләт теле турында»гы Законы кискен тәнкыйтьләнде. Шул исәптән ул М. Ш. Шәймиевнең «Интерфакс»тагы дәлилле әңгәмәсендә дә чагылыш тапты. Россия галимнәре, булмаган дошманны эзләп, урысларның үзләре дә көтмәгән нәтиҗәгә килделәр: имеш, сүгенү сүзләре урыс теленә татарлардан кергән икән! Киресенчә, татарлар ешрак урысча сүгенә, югыйсә.

**Ш. Х.** Укучыларыбыз хатларыннан күренгәнчә, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә губернаторлар сайлау алды яки башка җаваплы кампанияләр вакытында сайлаучыларның милли составын исәпкә алырга мәҗбүрләр, алар, вәгъдәләр биргәндә, алай саранланып тормыйлар, ләкин соңыннан барын да җиңел генә оныталар. Мәсәлән, Санкт-Петербургта шундый хәл булды: татар милли-мәдәни мохтәриятенә иң югары дәрәҗәдә Россиядә йөз ел чамасы элек чыга башлаган беренче «Нур» татар газетасы редакциясенә бина да, финанслау да вәгъдә ителде (аны нәшер итүгә заманында император галиҗәнаплары рөхсәт биргән һәм ул хакимияттән яклау тапкан, бүген исә газета җирле җәмәгать эшлеклесе фатирының идән астында нәшер ителә дип әйтергә була). Сайлаулар узгач, әлеге вәгъдәләр «онытылды».

Хат авторлары хакимиятнең закон чыгару органнарына сайлаулар җиткәч, татар вәкилләренең, гадәттә, читтә калуына аяныч белдерәләр. Татарга, җитәкче посты алу өчен, үзенең эшлеклелек

һәм акыл сәләте буенча башка дәгъвачылардан өч башка биегрәк булырга кирәк. Бу милли проблемалар милләтара мөнәсәбәтләрдә хакыйкатьнең бозылуы нигезендә барлыкка килә дигән сүз түгелме соң? Яисә билгеле бер этник төркем кешеләрен (татарларны гына түгел) социаль кысрыклауданмы?

Димәк, законга буйсынучы, әмма урыс милләтеннән булмаган гражданнар икеләтә салым түләүчеләр булып чыга. Аларның салымы хисабына урыс телле мәктәпләр, театрлар, башка дәүләти мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре эшли. Төбәкләрдәге милли азчылыкның үз рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен мондый матди нигезләре юк. Мәсәлән, Ульяновск татарлары күп еллар дәвамында хакимияттән милли китапханә өчен бина сорый, үз көчләре белән меңнән артык китап та җыелган. Нәтиҗәдә аларга яки башка төбәк татарларына үз балаларына туган телне өйрәтү өчен укытучылар эзләргә, концерт һәм спектакльләр кую өчен костюмнар тегәргә теләнеп акча җыеп йөрергә туры килә. Бәлки, безнең ил Россия гражданнары һәм аның гражданнары булмаганнарга, үз балалары һәм үги балаларга, тантана итүчеләр һәм гаепleләргә, җиңүчеләргә һәм түбәнсетелгәннәргә бүленгәндер?

**Р. В.** Менә инде без кеше хокуклары турындагы мәсьәләгә килеп җиттек. Кеше хокукларыннан, һәрбер аерым шәхескә ихтирамлы мөнәсәбәттән башка бөтен бер халыкның хокуклары да – белем алу, туган телне өйрәнү, үз тарихыңны белү, бабаларның гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклау хокукы була алмый. Миңа Квебекта (Канада) булырга туры килде. Анда берничә милләт балалары укыган мәктәпләр эшли. Аларның һәрберсе өчен үз туган телләрен өйрәтүче укытучылар бар.

Бездә исә эш башкачарак тора. Россиядә, Татарстаннан тыш, дәүләти татар мәктәпләре бармак белән генә санарлык. Татар эшкуар-меценатларыннан башка алары да юкка чыгар иде. Мәгарифкә билгеле бер вакыт узгач шартлый торган мина куелган кебек. РФ Мәгариф министрлыгы раслаган дәреслекләрдә элеккегечә «поганый татарин» һәм тагын бик күп ямьсез сүзләр язылган. Ә балалар барысына да ышана, нәтиҗәдә мәктәптә укучы иптәшләрен «үзләренеке»нә һәм «чит»ләргә бүлә. Татар укучылары Татарстанда нәшер ителгән дәреслекләрдән үз халкының гадел тарихын өйрәнә, чит өлкәләрдә исә татарның тарихы башкача тасвирлана. Әгәр бу каршылыкларны җайга салмасак, балаларны үзара ызгыш-талашка дучар итәчәкбез. Ә битараф калсак, Россия шәһәрләре урамнарында юлында очраган һәрнәрсәне җимерүчеләр төркемнәрен арттырачакбыз.

Шәхси мөнәсәбәтләр арасында әлегәчә уянмаган милләтара низаг та яшерен урын алган бит, урыс кешесе әле аңа тиешле игътибар гына бирми. Теләсә кайсы татар кешесеннән Пушкин, Лермонтов, Есенин турында сорагыз – ул аларны яттан сөйләп бирергә мөмкин. Без «чит» Толстой, Достоевский, Чехов, Тургенев, Чайковскийларга соклана алабыз. Башка халыклардан да Тукай, Такташ, Сәйдәш, Исхакый һәм Мәрҗанигә шундый игътибар булуына өметләнәбез. Рус укучысы яисә студенты ялгышмыйча бер-ике татар язучысы, мәдәният һәм сәнгать эшлеклесе исемен әйтеп бирә алса, бик яхшы булыр иде әле. Бу да бит йөзләрчә еллар иңгә-иң яшәүче халыкларның тигез хокуклылыгы һәм әхлакый дәрәҗәсе турында сөйли.

Бәхәсләшмим – социаль-икътисади кыенлыклар нигезендә милләтара мөнәсәбәтләр дә кискенләшә: җәберләнгән кеше үз хокуклары өчен тагы да ныграк көрәшә башлый. Әмма социаль җитешсезлекләрне бетереп кенә милли мәсьәләнең юкка чыгуы белән ризалаша алмыйм. Шул ук Квебекны алыйк. Халыкның мул тормышта яшәве буенча ул Канаданың башка провинцияләре арасында гына түгел, дөньяда да алдынгы урыннарда тора. Бирелә нинди кыенлыклар булырга мөмкин дия аласыз? Шуңа да карамастан әлеге провинция халкы белән Канада хөкүмәте арасында каршылыклар күптән килә: ул инглизләр тарафыннан басып алынганчыга кадәр булган XVII гасырдагы үткәнен кире кайтарып, мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыгарга тели. Бу ярлылар ризасызлыгы түгел, димәк, милләт холкы чагылышы яки халыкларга үз үткәннәрен оныттырырга теләмәгән һәм аларга бердәнбер дөрес һәм үз-үзен тәэмин итә алырлык үсеш юлын күрсәткән ата-бабалар чакыруы, җан авазы. Тәрбияле угыл үз этисеннән яисә энисеннән баш тарта аламы соң?

Әлбәттә, татар халкы да үз үткәненнән, 1552 елда юкка чыгарылган дәүләтчелегеннән баш тартмаячак.

**Ш. Х.** Соңгы сорау, Разил әфәнде, сезнең карашка, милли мәсьәлә кайчан да булса хәл ителеп бетәрме?

**Р. В.** Минем фикеремчә, бу – мәңгелек мәсьәлә. Аерым төр сыйныфлар югала, иҗтимагый-икътисади формацияләр алышына, ә милләтләр кала. Димәк, милләтләрнең үзара аралашып яшәү мәсьәләсе дә мәңгелек. Дәүләт милли мәсьәләне дөрес хәл итеп, дин ирегеп таныса, ул уңай эчтәлеккә ия була. Ә милли мәсьәләне дөрес хәл итү сәяси яки икътисади комбинацияләр белән алыштырылса (безнең әңгәмә башлыча шул хакта барды да инде), низаглы хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Иң мөһиме, дәүләт бер халыкның икенчесе хисабына өстенлекләр белән тәэмин ителешенә сәбәпләр тудырмасын иде. Күп милләтле Россия өчен бу беренчел шарт: андагы бер генә халык та башка халыклардан яхшырак яисә начаррак түгел.

*Әңгәмәдәш Шамил Хамматов*

*2003*

# САГЫНДЫРА МОҢЛЫ ҖЫР...

**– Разил абый, Сез Дәүләт Советында бик җаваплы комиссия рәисе, дәүләт эшлеклесе, дөресен генә әйтегез әле, җыр тыңларга вакытыгыз бармы?**
– Минем җырсыз яшәгәнем дә юк. Әгәр җыр тыңлый алмасам, үзем эчтән генә җырлап, күңелемнән генә моңланып йөрим, юлда, машинада булсам да, җәяү йөргәндә дә, комиссия рәисе кәнәфиендә утырганда да... Җыр-моң күңелне тәртипкә сала, күңелне көйли. Татарда «көй» дигән сүзнең мәгънәсе тирән, ул музыканы гына түгел, «көйле, җайлы» дигәнне дә аңлата. Көй ул – рухи дөньяндагы гармония.
**– Димәк, Сез – көйле кеше...**
– Мин бәләкәйдән үк җырлый идем. Безнең гаиләдә гармун уйнамаган, җырламаган кеше юк. Әнкәй дә гомер буена, бүлмә якта дибез инде без, аш пешерә торган җирдә ипи саламы, камыр басамы, ашарга пешерәме – һәрвакыт эчтән көйләп йөри иде. Гомумән, мин җыр-моң арасында үстем. Без Алмаз Хәмзин белән бәләкәй вакытта да сәхнәдә җырлап йөрдек. Түбән Каманың 1 нче мәктәбендә укыганда, безнең бик яхшы хорыбыз бар иде. Аның җитәкчесе Зыятдин Билалович дигән укытучыбыз, үзе физика укытса да, баянда искиткеч яхшы уйный, җырлый иде. Безгә ул Сәйдәшнең бөтен җырларын өйрәтте. Безнең күңелгә моң менә шул Сәйдәш аһәңнәре аша кереп урнашкандыр, күрәсең. Тагын бер кызык нәрсә: мәктәптә укыганда, мин җырчы идем, Алмаз шагыйрь иде. Әкрен-әкрен без Алмаз белән урыннарны алыштык. Дөрес эшләгәнбез, минемчә.
**– Бәлки, чынлап та атаклы җырчы булып китәр идегез...**
– Мин үз тавышымның мөмкинлекләре чикле булуын чамаладым. Тавыш мөмкинлекләре булмаса да, җырчы булып йөргән кешеләрне кызганам мин. Барыбер җырдан аерылмадым. Башлангыч мәктәптә укыган вакытта, безнең авылга татарның бөек җырчысы Рәшит Ваһапов килде. Аның белән Мөхтәр Әхмәдиев, Оркыя Ибраһимова да бар иде. Шулхәтле шәп концерт куйдылар! Мөхтәр Әхмәдиев белән Оркыя Ибраһимова шулкадәр матур итеп баянда уйнадылар. Ак баянлы Оркыя Ибраһимова белән Мөхтәр абый әле һаман күз алдымда тора. Рәшит Ваһапов концертыннан мин шаккатып, сокланып, әсәрләнеп чыктым. Шул көнне үз-үземә баянчы булырга сүз бирдем. Шуннан соң әткәйдән елый-елый яшел хромка гармун алдырттым. Аның төймәләренә ноталарны кулдан язып ябыштырдым. Түбән Камага барып нота китаплары сатып алдым һәм үзлегемнән гармунда уйнарга өйрәнә башладым. Һәм ярыйсы гына уйнарга өйрәндем. Клубларда кызларны, егетләрне дә биеттем, концертларда да уйнап йөрдем.
**– Ләкин нигәдер баянчы түгелсез...**
Моның да хикмәте бар. Безнең күрше авылда бер очучы бар иде. Ул чакта Түбән Кама әле төзелеп кенә килә. Бездән ерак түгел кечкенә генә аэропорт бар иде. Очучы абый Казаннан шул аэропортка «кукурузник»та очып үткәндә, күрше Шәңгәлчедә яшәгән әнисенә төенчекләп күчтәнәч ташлап китә иде. Бу минем өчен башка сыймаган могҗиза иде. Шушы минем күңелемә кереп калды. Үсәм, очучы булам, самолёт белән кайтып әнкәйгә күчтәнәч ташлап китәм дип хыяллана башладым, һәм шушы хыял минем гармунчылыгымны икенче планга күчерде. Күккә менү турында хыяллангач, шигырьләр яза башладым. Мәктәпкә язучылар, шагыйрьләр килде дә шигырьләремне Казанга алып китеп бастырып та чыгардылар. Шуннан соң – Казан, университет, Мәскәү, Әдәбият институты. Ул хыялга инде кире кайтып булмады. Ләкин язмышым җыр белән гел янәшә йөрде.
**– Һәм Сез җырчы шагыйрьгә әйләндегез?**
– Мине җыр дөньясына җитәкләп алып кергән кеше Илһам Шакиров үзе булды. Әдәбият институтында беренче курста укый идем. Мәскәүдә әле беркемне дә белмим, утырам шулай тулай торак бүлмәсендә ялгызым моңланып. Берзаман ишекне шакыдылар, ачып карасам – шаккаттым: Илһам Шакиров басып тора. Ул инде минем өчен Аллаһы Тәгалә белән янәшә торырлык кеше. Мине күргәне юк инде аның. «Разил дигән егет син буласыңмы?» – ди. «Әйе, – дим, – керегез, узыгыз, Илһам абый». – «Кереп тормыйм, вакытым юк, – ди. – Мин Мәскәүгә «Мелодия»

ширкәтенә пластинка яздырырга килгән идем, анда сигез җыр булачак, җидесенең сүзе дә, көе дә бар, ә менә сигезенчесе – халык көе, әмма сүзләренең рәте юк. Мин андый сүзләргә җырлый алмыйм. Син шул көйгә сүзләр язып бирмәссеңме икән?» «Минем бит беркайчан да җырга сүзләр язганым юк», – дим. Ул: «Күптән түгел генә «Казан утлары»нда шигырьләреңне укыган идем, миңа бик ошады. Сине юкка гына эзләп килмәдем, Мәскәүдә бүтән бер татар шагыйрен дә белмим, язып бирсәң иде», – ди. «Күпме вакыт бирәсез, бер аймы, өч аймы?» – дим. «Энекәш, нинди бер ай, өч ай, мине аста такси көтеп тора, хәзер бер җиргә барып киләм дә сәгать ярымнан монда булам. Алтынчы катка кабат менеп йөрмәм, беренче катка төшеп тор, сүзләрең машинкада басылган булсын», – ди бу. Ничек язганны хәтерләмим, әмма сәгать ярымнан мин шигырьне язып, машинкада басып, шул кәгазьне кулыма тотып, Илһам абыйның килгәнен көтеп тора идем инде. «Дулкын» дигән җыр иде ул. Илһам абый белән язган беренче җыр шушы булды. Аннан соң ул миңа, заказ биреп, «Бер алманы бишкә бүләек»не яздырды. Аннан инде «Таң җыры»н һәм башка җырлар яздык. Илһам абыйның җыр сүзенә, җыр шигыренә таләбе зур иде, бу миңа иң беренче зур мәктәп булды. Мин, мәсәлән, «Бер алманы бишкә бүләек»тә «кар аклыгы гөлгә күчкән, алмагачлар кояш эчкән» дип язган идем. Илһам абый әйтте: «Алай булмый, шигырь өчен матур ул – «кар аклыгы», ә җырлаганда бит «караклыгы» булып ишетеләчәк. Җырда сүзләрнең мондый тезмәсе булырга тиеш түгел», – ди. Бу минем күңелемә мәңгегә кереп калды. Мин аны «кыш аклыгы гөлгә күчкән» дип үзгәрттем. Мәгънәсез сүз тезмәләре бүген татарда гына түгел, урыс җырларында да искиткеч күп. Санап китсәң, адәм көләрлек, адәм ышанмаслык, чәчләр үрә торырлык җыр сүзләре бар бүгенге көндә.

**– Шуңа күрә тыңлыйсы да килми аларны...**

– Бүген татарча иң мәгънәсез сүзне ишетәсең килсә, эстрада җырларының сүзләрен тыңла. Көйләрен әйтмим, көенең дә төрлесе бардыр. Сүзләрнең туксан тугыз проценты бернәрсәгә дә ярамый, анда поэзиянең бөтенләй катнашы юк. Хәзер кайбер җырчыларыбыз юньле җыр юк дип зарланалар, җырларның бүген генә табадан төшүен көтеп яталар. Нишләп бездә җыр булмасын ди? Мәсәлән, бүген 50–60–70 нче еллар композиторлары онытылып бара. Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Хөснулла Вәлиуллин, Мансур Мозаффаров, Аллаһияр Вәлиуллин, Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтов язган искиткеч җырлар бар лабаса. Алар – безнең җыр сәнгатенең алтын фонды. Ник аларны җырламыйлар? Әйтик, Җәүдәт Фәйзинең Һади Такташ сүзләренә язган «Урман кызы» – ул бит классика. Аны мин көн саен иртәдән кичкә кадәр тыңларга әзер. Менә ул безнең чын татар җыры. Сәйдәштән, Габәшиләрдән башланган җыр мәктәбе ул. Аның соңгы вәкиле Фасил Әхмәтов иде. Фасил Әхмәтовтан соң инде татар моңы сүнә, җырыбызда миллилек көннән-көн кими башлады. Алардан соң Резеда Ахиярова, Луиза Батыр-Болгари, Рәшит Абдуллиннар матур-матур җырлар иҗат иттеләр. Ә бүгенге көндә миллилек инде бөтенләй юк диярлек. Рухи дөньябызда, җыр-моң, музыка өлкәсендә иң зур бәлабез дә шушы – дәвамчылык, эзлеклелек бетү. Шәхсән безнең буында һәрвакыт төп принцип бар иде: безгә кадәр иҗат иткән кешеләрнең традицияләрен дәвам итү. Бу яктан караганда, безнең консерваториябез әле бик зәгыйфь. Казан консерваториясе Татарстанда булса да, татарныкы түгел. Мин анда еш булам, алар кулдан килгән кадәр тырышалар, милли музыка факультеты да ачтылар. Әмма ул факультет зур бер чиркәүнең эченә кереп, бер почмагына намазлык җәеп, намаз укып утырган мөселман агае шикеллерәк хәзергә.

**– Разил абый, иң яхшы җырларны билгели торган тамашалар үткәрүгә Сез ничек карыйсыз?**

– Хәзер шундый «шагыйрьләр», шигырь язучылар барлыкка килде: арба артындагы дегет чиләге шикелле, көйгә, музыкага тагылып поэзиягә керергә тырышучылар. Шигырьләрен көеннән аерып карасаң, шигырь дигәннең «ш» хәрефе дә күренми югыйсә. Рифмасы да, җөмләсе дә юк, төзек тә, татарча да түгел, мәгънәсез сүзләр тезмәсе. Мин композиторларның, музыкантларның шундый шагыйрьләргә мөрәҗәгать итүләренә аптырыйм. Татарда бер чын шагыйрь дә калмаган диярсең. Хәсән Туфанның җырлап тора торган матур шигырьләре бар. Дәрдемәнднең бер генә шигыренә дә көй язылмаган. «Кораб» кына бар, анысы да халык көе. Һади Такташ, Сибгат Хәкимнең моңлы шигырьләре бик күп. Урта буын шагыйрьләре: Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Рәдиф

Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Марсель Галиевнең күпме әйбәт шигырьләре бар. Инде язылган шигырьләр арасыннан таба алмыйсың икән, алар бит әллә кайда түгел, Казанда яшиләр. Яннарына бар, сөйләш, киңәш, көйләреңне тыңлат. Нишләптер беркем аңламый торган, беркемгә керәге булмаган шырдый-бырдый шигырьләр табалар да шуларга көй әрәм итәләр.

**– «Мин җырлыймын шырдыйны...» дигән такмак искә төшеп китте. Тыңлаучысы булгач, нигә җырламаска ди?**

– Чөнки без хәзер үзебезнең тамашачыларны шул җырлар белән тәрбиялибез. Әгәр болай барса, тагын ун елдан соң татар җыры шундый булырга тиеш дип уйлый башлаячаклар. Чөнки без җырның зәвыклы үрнәкләрен күрсәтмибез. Мин дә үземне бик үк югары зәвыклы кеше дип санамыйм, мин дә авыл баласы, тиешле дәрәҗәдә музыка тәрбиясе алган кеше түгел. Ходайга рәхмәт, язмышыма рәхмәт, укытучыларыма рәхмәт дигәндәй, мәктәптә безнең күңелебезгә Сәйдәшне тирән салып калдырдылар. Казанга килгәч, мин операларга, балетларга шактый йөрдем. Мәскәүдә исә укытучыларыбыз безне кыстый-кыстый, ачулана-ачулана операларга, балетларга, симфоник концертларга алып бардылар. Атна саен Мәскәүнең Чайковский исемендәге консерваториясенә классик музыка тыңларга мәҗбүри рәвештә бара идек. Миңа алар башта шулкадәр ят иде, концерт вакытында йокыга киткән чаклар да булды. Безнең өчен кызык түгел, ят музыка, безгә бит «Карурман» булсын да «Тәфтиләү» булсын. Ә биредә Бах, Чайковский, Шостакович... Әмма шул концертларга йөри-йөри, әкрен-әкрен мин аларны аңлый һәм ярата башладым. Чөнки алар, бая әйткәнемчә, күңелемне көйлиләр иде. Менә шунда күпмедер классик музыка тәрбиясе алдым. Бәлки, шуңа күрә дә минем җырга карата таләпләрем катгыйрактыр. Һәм бүгенге көндә без татар җыры чын мәгънәсендә татар җыры булып калсын, дөньяга чыксын, саклансын дибез икән, җырга зәвыкны балалар бакчасыннан, хәтта бишектән башлап тәрбияләргә тиешбез. Бүгенге әниләр балаларына бишек җыры җырлыймы? Бармы бездә бишек җырлары? Балалар мәктәптә дәресләрдә, кичәләрдә татар җыры тыңлап үсәргә тиешләр. Хәзерге вакытта үзешчән сәнгатькә авылда да, шәһәрдә дә игътибар юк. Шуңа күрә безнең бүгенге көндә опера сәхнәсендә Муса Җәлил партиясен, «Алтынчәч»тә Җик Мәргәнне җырларга кешебез юк, читтән чакырабыз. Шушы булдымы җиде миллионлы бөек халык?! Ә без мактанабыз да мактанабыз. Бар уртакул җырчылар, әмма, Хәйдәр Бигичев вафат булганнан соң, халыкара дәрәҗәгә чыга алырдайлар күренми. Аларны тәрбияләргә кирәк, әмма моның белән шөгыльләнүче юк. Япон балаларына, мәсәлән, мәктәптә беренче сыйныфтан башлап соңгысына хәтле һәр көнне сәнгать дәресе керә. Җырларга да, рәсем ясарга да, сәнгать фәннәрен дә өйрәтәләр. Шуңа алар бүген бөтен дөньяда иң алдынгы, иң акыллы милләт.

**– Минемчә, замана җырчыларының, музыкантларының дәрәҗәсе дә шул чама гына. Алар инде Мәскәү буйлап татар шагыйре эзләп йөргән Илһам Шакиров түгел...**

– Мин инде бу турыда Дәүләт Советы сессиясе трибунасыннан да сөйләгәнем бар: укыган соңгы китабы мәктәптәге «Ботаника» булган җырчыларыбыз, композиторларыбыз, музыкантларыбыз бик күп безнең, андыйлар җитәкчеләр арасында да җитәрлек. Кешегә поэзия тәрбиясе бирү дә бик мөһим, монда да без үзебез: депутатлар да, бигрәк тә югары җитәкчеләр, үрнәк күрсәтергә тиешбез. Аллага шөкер, безнең президентыбыз әдәбиятны, сәнгатьне бик яхшы тоя, аңлый һәм белә торган шәхес. Ул театрга йөри, мәдәният яңалыкларыннан һәрчак хәбәрдар, аңа карап башкалар да әкренләп сәнгатькә тартыла. Минем фикеремчә, җитәкчеләрне эшкә куйганда, аларның интеллектуаль дәрәҗәсен дә күз алдында тотарга кирәк.

**– Разил абый, Сез – йөзләгән җыр авторы. Әйтегез әле, җыр ничек туа ул?**

– Җыр язылу тарихы бик кызык. Менә берзаман, мин җырлар яза башлаган гына вакыт, «Бер алманы бишкә бүләек» язылган инде, Илһам Шакиров концертларында яңгырый – композитор Фәтхерахман Әхмәдиев килде дә: «Мин кичә Ленин турында көй яздым, шуңа шигырь язып бир әле», – ди. «Көй ул ничек Ленин турында булырга мөмкин соң?» – дим. «Мин аны Ленинны уйлап яздым», – ди ул. Кызганыч ки, мин Фәтхерахман абыйның Ленин турындагы көенә сүзләр яза алмадым инде. Менә шундый мәзәк хәлләр дә була.

Без Рәшит Абдуллин белән бик күп җырлар иҗат иттек. Безне Камал театры директоры Шамил Закиров таныштырды. Мин ул вакытта «Ялкын» журналында эшли идем. Рәшит Абдуллин

Казанда армиядә хезмәт итә иде. Рәшит редакциягә килеп көен уйнап күрсәтте. Мин аптырадым, көе традицион калыпта түгел иде, сүз язуы кыен булды. Нәтиҗәдә «Төсле җыр» туды, заманында шактый уңыш та казанды. Рәшит – бик талантлы композитор, ул татар музыкасына яңа аһәңнәр алып килгән кеше. Шәһәрдә туып үскән музыкантның безнең милли моңга тартылуы ул инде начар нәрсә түгел. Андый композиторларыбыз бик сирәк.

**– Шулай да башта көй языламы, әллә сүзләрме?**

– Төрлечә була ул. Мәсәлән, җиде ай хастаханәдә ятып, бик күп җәфалар күргәннән соң, Мәскәү янындагы бер карурманда – иҗат йортында, бик моңсу вакытымда «Зинһар өчен, кермә төшләремә» дигән шигырь язган идем. Бер иҗат кичәсендә мин бу шигырьне укыдым. Аны Венера Ганиева тотып алды, бу бит җыр, үзеннән-үзе көй сорап тора, ди. Ул аны шул көнне үк Резеда Ахияровага күрсәткән, һәм алар төнге сәгать икедә икәүләшеп миңа шылтыратып яталар. «Җыр яздык!» – дип кычкыралар трубкага.

Кайчак композиторлар әзер көйләрен тәкъдим итә, Ленин турында түгел инде, әлбәттә. Мин көйне өйгә алып кайтам да егерме-алтмыш-йөз мәртәбә, күңелгә үтеп беткәнче тыңлыйм. Шул көйне үзем җырлый башламыйча яза алмыйм. Әгәр дә мин аны җырларга өйрәнә алмыйм икән, димәк, ул минем күңелемә ятмый, һәм мин аңа сүз яза алмыйм. «Сөембикә» дигән җырны бик озак яздым. Шуңа күрә ул миңа бик кадерле. Минем кызым да Сөембикә исемле. Кызымны да, халык язмышын да уйлап яздым. Композиторның күңел көе белән шагыйрьнең күңел көе тәңгәл килү – җыр өчен иң зур бәхет.

**– Димәк, Сез дә бәхетле, чөнки үзегез кебек «көйле» композиторлар тапкансыз. Өмет Сездә, төсле җырлар язучыларда инде бүген...**

– Эстрададагы мәгънәсезлек белән көрәшүнең иң нәтиҗәле юлы – яхшы җыр язу дип уйлыйм. Җыр ул – минем язмышым да, бурычым да. Әле менә шушы арада гына ике җыр дөньяга килде. Берсен Рәшит Абдуллин белән, икенчесен Алмаз Хәмзин белән яздык. Нинди җырлар дип сорамагыз, алдан әйтсәң, кызыгы бетә. Шунысын гына әйтәм: беренчесен Рафаэль Сәхәбиев, икенчесен Алмаз үзе җырлаячак. Вакыты җиткәч, Алла боерса, ишетерсез дә, күрерсез дә әле.

*Әңгәмәдәш Нурсөя Шәйдуллина*

*2004*

# ҮЗЕ ТЕЛӘП КЕМ КИТӘ?

**– Разил әфәнде, Диалог-Авразия платформасы ничек оешты, аның «беренче кирпечләрен» кем салды?**

– Башлап йөрүчеләр иң беренче чиратта Русия һәм Төркия галимнәре, язучылары, журналистлары, гомумән, зыялылары иде. «ДА»ның үзәгендә атаклы әдипләр: казакъ шагыйре Олжас Сөләйманов, кыргызның бөек язучысы Чыңгыз Айтматов торды. Алар бүген дә бик актив эшлиләр.

«ДА»ның оешуы гайре табигый хәл түгел. Билгеле бер идея, максат тирәсендә дәүләтләрнең, илләрнең берләшүенә мисаллар бар бит. Мәсәлән, Евросоюз. Ул беренче чиратта – икътисади, икенче чиратта сәяси мәсьәләләрне бергәләп хәл итүне максат итеп куя.

**– «ДА»ны оештыруда Русия дә башлап йөргәч, димәк, урыс милләтенә дә куркыныч яный булып чыга?**

– Әлбәттә. Соңгы елларда урыс зыялылары милли мәдәният, сәнгать, тел мәсьәләләрен күтәреп чыга башлаганнар икән, бу тикмәгә түгел. Милләт бетү куркынычы Төркиягә дә яный: ул европалаша, үзенең милли үзенчәлеген югалта. Әлбәттә, дөньякүләм масштабта үз урынын алган АКШ, Англия, Германия, Франция кебек дәүләтләрнең хәсрәте юк. Глобальләшү беренче чиратта дәүләтчелеге ныгып җитмәгән халыкларның язмышы өчен куркыныч, чөнки дәүләтсез халык ятим, караучысыз, яклаучысыз халык бит инде ул.

**– Разил әфәнде, «ДА» платформасында элекке СССРдан чыгып мөстәкыйльлек алган, инде шактый ныгыган Балтыйк буе, Кавказ арты, Урта Азия дәүләтләре дә бар һәм Татарстан белән чагыштырганда аларда уртага салып сөйләшерлек зур милли проблемалар юк та кебек.**

– Әйе, ул төбәкләрдә яшәүче халыкларның үз дәүләтләре бар, әмма, Җир шары масштабында караганда, алар да зур, көчле милләт түгел шул әле. Мәсәлән, украин теле югалу алдында, Кыргызстанда исә дәүләт эшләре ике телдә алып барыла, хәтта урамнардагы, кибетләрдәге язуларга хәтле урысча. Казакъстанда да шул ук хәл. Бу – электән килгән урыслаштыру сәясәте җимешләре. Дөрес, казакълар дәүләт эшләрендә, мәгарифтә әкрен-әкрен үз телләренә күчәләр. Әмма бер кызыклы хәл: шул ук вакытта анда инглиз теле урыс телен кысрыклый, чөнки үзенең киләчәген уйлаган, мөмкинлеге булган яшьләр инглиз телен өйрәнә.

**– Бу начармыни?**

– Юк үзе, әмма инглиз теле урыс телен генә түгел, казакъ телен дә кысрыклый бит. Шулай итеп, кайсы яктан карасаң да, проблема үз милләтеңне саклауга барып тоташа. Шуңа күрә фикердәшләр, бигрәк тә кардәш халыклар белән берләшеп, мәсьәләне уртага салып сөйләшмәсәк, дөнья аренасыннан безнең дә китүебез бар.

**– Инде әкрен-әкрен чигенә, позицияләрне бирә башладык. Әлеге дә баягы латин язуына күчү. Бу проблема «ДА»ның Бишкәктә үткән конференциясендә дә күтәрелде, дигән идегез. Анда сез рәислек тә иткәнсез.**

– Әйе, булды андый хәл. Менә син, җиңелә барабыз, дидең. Әмма Бишкәктә үткән шул олы форумда Татарстанның латинга күчүен хуплап чыгучылар шактый иде. Димәк, без ялгыз түгел. Мәсәлән, азәрбайҗаннар, үзбәкләр, кырым татарлары, Коми күптән латинча яза, хәзер казакълар күчәргә җыена. Ә без берни белмәгән килеш үзара бәхәсләшеп яттык.

**– Кызык кына әйтеп куйдыгыз, берни белмәгән килеш бәхәсләшеп буламыни?**

– Менә шунысы кызык та, кызганыч та инде аның: берни белмичә, төрле фаразлар корып, теге килеп чыкмасмы, бу килеп чыкмасмы дип талашып яттык. Шунда бит берничә галимне, хөкүмәтнең берничә җаваплы кешесен, мәсәлән, Азәрбайҗанга җибәреп була иде. Ятсыннар иде айлар буе тәҗрибә өйрәнеп. Без әле тагын милли мәгариф системасы кертү мәсьәләсендә дә ике каен арасында буталып йөрибез. Казакълар моңа кереште инде, ягъни, балалар бакчасыннан башлап югары уку йортына хәтле ана телендә тәрбияләү-укыту кертелә. «ДА»ның әһәмияте дә

коры бәхәс куптару түгел, әнә шул проблемаларны уртага салып сөйләшү һәм бер-береңнән тәҗрибә алу.

– **Диалог-Авразия дәүләти оешма түгел, дигән идегез. Аның идарәсе ниндирәк?**

– Рәисе, генераль секретаре бар. Аннан соң Бишкәктә узган конференциядә һәр илдән милли комитет төзергә дигән тәкъдим ясалган иде. Элек һәр илдән ике вәкил иде. Шунда мин Русиядән бер генә комитет булырга тиеш дигәнгә каршы чыктым: «Әгәр бу юл белән китсәк, оешмабыз дәүләти структура буенча эшли башлаячак. «ДА» – иҗтимагый оешма, һәм без аның эшендә дәүләт исеменнән түгел, халык, милләт исеменнән катнашырга тиеш», – дидем. Әлбәттә, Русия вәкиле каршы чыкты. Әмма узган ел «ДА»ның Төркиядә үткән конференциясендә минем тәкъдим кабул ителде. Хәзер Русиядән ике, ягъни, Мәскәүдән һәм Татарстаннан берәр милли комитет эшли. Бу – үзебезнең мөстәкыйль тавышыбыз бар дигән сүз.

**– Татарстан җитәкчелеге Диалог-Авразия платформасына нинди караштa?**

– Платформага түгел, проблемага дияр идем мин. Әле «ДА» оешканчы ук Президентыбыз М. Шәймиев Авразия хәрәкәтенә уңай мөнәсәбәтен белдергән иде. Президентның сәясәт буенча дәүләт киңәшчесе Рафаэль Хәкимов иң мәртәбәле халыкара форумнарда бу хакта чыгышлар да ясады. Алар Диалог-Авразия күтәргән проблемаларның Татарстан өчен дә бик әһәмиятле икәнен кат-кат ассызыклап әйттеләр. Хөкүмәтебез белән килешеп, «ДА» Татарстанда берничә чара да үткәрде, үзенең матбугат органы – «ДА» журналын тәкъдир итү дә узды. Инде менә июнь аенда Казанда Ислам конференциясе узачак. Анда ислам дәүләтләренең иң югары дәрәҗәдәге җитәкчеләре катнашыр дип көтелә. Ә май аенда дин мәсьәләләре буенча Мәскәүдә зур конференция узачак. Әлеге форумнарда Диалог-Авразия дә үз сүзен әйтер. Сүз уңаеннан, «ДА» журналының бер саны Казанның меңьеллыгына багышлана. Әлеге журнал берничә илдә таратыла, димәк, ул безгә дөньяга чыгу өчен «тәрәзә» дә.

**– Разил әфәнде, чагыштырмача күптән түгел «ДА» тирәсенә журналистларны да тупларга дигән ният белән зур сөйләшү узды. Ләкин глобальләшү котылгысыз процесстыр инде ул, һәм моңа каршы көрәшү бушка чәбәләнү түгелме?**

– Иң элек журналистлар хакында әйтим әле. Хәзер дөнья объектив мәгълүматка мохтаҗ. Илләр төрле рангларга бүленгән: АКШны иң бай, куәтле дәүләт дип кенә беләбез. Кытайга килсәк, ул АКШның куркыныч көндәше, һәм бу ил турында тискәре мәгълүмат күбрәк. Төркиядә кеше хокуклары бозыла, анда ислам террорчылары, чечен бандитлары... Татарстанны исә сепаратизмда гаепләргә ашкынып торалар, ваһһабичылык дип тавыш куптаралар. Русия матбугатына гына күз салыгыз – сиксән-туксан проценты тискәре материал. Менә шуңа күрә без, бер яктан, «ДА» журналы, икенче яктан, халыкара мәгълүмат үзәкләре, өченче яктан, «ДА» платформасының Интернет сайты аркылы хак мәгълүмат таратырга тиеш. Ә инде глобальләшүнең котылгысызлыгына килгәндә, мин Чыңгыз Айтматовның бер фикерен искә төшереп үтим: «Үз акылында булган кешенең беркайчан да үз теләге белән бу дөньядан китәсе килми», – дигән иде ул. Дөрес, кеше дә, халыклар да, мәмләкәтләр дә мәңгелек түгел. Әмма хикмәт шунда: ничә яшькә хәтле яшисең бит. Шуңа күрә халкыңның гомерен озайту өчен эшләп калырга, халкыңның бөтен рухи байлыгын, иң күркәм сыйфатларын бөтендөнья халыклары рухи байлыгының бер өлеше итеп калдыру өчен тырышырга кирәк.

*Әңгәмәдәш Риман Гыйлемханов*

*2005*

# МИЛЛИ ХӘРӘКӘТ ЯҢА СЫЙФАТКА КҮЧТЕ

*28 октябрьдә Татарстан Дәүләт Советы Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләрне бүлешү турындагы Шартнамә проектын кабул итте. Россия Дәүләт Думасы раслаганнан соң, әлеге документка Татарстан һәм Россия президентлары кул куярга тиеш. Татарстан Республикасы – Россия субъектлары арасында үзәк белән мөнәсәбәтләрен ике яклы килешү нигезендә төзүче бердәнбер субъект. 1994 елда кабул ителгән Шартнамә гамәлдән чыкканнан соң, республика статусы ачыкланмаган килеш калды. Яңа Шартнамә исә федераль закон нигезендә ныгытылачак.*

**– Разил Исмәгыйлевич, Сез Татарстан ягыннан эшче төркем составында Шартнамәне әзерләүдә катнаштыгыз. Яңа Шартнамәнең үзенчәлекләре нидә?**

– Документны әзерләү эше моннан ел ярым элек, 2004 елның маенда Путинның карары чыкканнан соң башланды. Ике яктан да сигезәр кешедән торган эшче төркем төзелде, Россия ягыннан аның җитәкчесе итеп РФ Президентының Идел буе округында вәкаләтле вәкиле Сергей Кириенко, ә Татарстан ягыннан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин билгеләнде. Мин мәдәният, мәгариф, милли мәсьәләләргә кагылышлы өлешкә җаваплы идем. Әйтергә кирәк, документны әзерләү эше бик авыр барды. Техник яктан катлаулылыклар килеп чыкты. Татарстан ягыннан без башыннан ахырына кадәр М. Ш. Шәймиев раслаган сигез кеше эшләдек, ә Россия ягыннан эшче төркем составы берничә мәртәбә алышынды. Шулай итеп, аңлату, исбатлау, ышандыру эшен безгә берничә мәртәбә яңадан башларга туры килде, бу күп эмоциональ көч, вакыт таләп итте.

**– Татар язуын латинга күчерүне Шартнамәгә кертү мөмкин булдымы?**

– Кертергә омтылыш булды, ләкин ул турыдан-туры керә алмады. Шулай да Шартнамәдә бер бик яхшы әйбер бар: «Татарстан Президенты ике дәүләт телен дә белергә тиеш» дигән пункт. Югыйсә Татарстан Конституциясендә ул язылган иде, ләкин Россия Югары суды карары белән гамәлдән чыгарылды. Хәзер без ул шартны яңадан кертә алдык. Телгә кагылышлы тагын бер нәрсә: Шартнамәдә «Татар теленең дәүләт теле буларак статусын һәм аның куллану даирәсен, куллану тәртибен Россия һәм Татарстан законнары билгели» дигән пункт кертелде. Моның нигезендә киләчәктә татар теленең графикасын да үзгәртергә мөмкинлек кала.

Мин Россия белән Татарстан арасында Шартнамә кабул итү фактын гына да югары бәялим, чөнки ул бүтән субъектлар арасында Татарстанның статусын бер башка күтәрә. Бүтән субъектлар федератив килешүгә кул куйдылар. Икенче яктан, без Шартнамәгә кул куймасак, бик кызык хәлдә калабыз. Без федератив договорга кул куймадык, иске Шартнамә гамәлдән чыкты, димәк, безнең статусыбыз һавада асылынып кала. Россия 1552 елда Казан ханлыгын үзенә көчләп кушканнан соң, безнең Россия составына керүебез турында бернинди дә документыбыз, карарыбыз юк. Без капитуляция турында пактка кул куймадык. Удмуртия, Башкортстан һ. б. республикалар кебек, Россиягә үз теләге белән кушылу турында Грамотабыз да юк. Юридик яктан безнең мөнәсәбәтләр ачыкланмаган килеш кала. Чынлыкта бу Шартнамәне кабул итү Россия өчен безгә караганда да әһәмиятлерәк – ул үз субъектлары белән мөнәсәбәтләрен ачык билгеләргә тиеш. Югыйсә Балтыйк буе илләре мисалындагыча да булуы мөмкин – 1991 елда СССР составыннан чыгу өчен нигез итеп алар 1940 елда оккупация булганын дәлилли алдылар, һәм моны бөтен илләр таныды. Безнең әле бүгенге көндә дәүләтебез ныгып җитмәгән, аның турында без Россия шикелле кайгырта алмыйбыз, ә үзен куәтле дәүләт итеп саклап каласы килсә, Россия беренче чиратта субъектларның статусы турында уйларга тиеш.

**– Без, Россиядә милли сәясәт юк, дибез. Чынлыкта Россиянең милли сәясәте бар, һәм ул бер генә милләт – рус милләте мәнфәгатьләрен яклый кебек...**

– Бу чынлап та шулай. Бүгенге көндә Россиянең илдә яшәүче рус булмаган халыклар өчен берни дә эшләгәне юк. Татар халкы мисалында алсак та, бүген Россия төбәкләрендә татар мәктәпләре, театрлар ачу түгел, булганнары да ябылып бетеп килә. Илдә руслаштыру сәясәте бара. Әгәр дә

Татарстан хөкүмәте Россия хөкүмәте белән сөйләшеп, бөтен Россиядә татар халкын үстерү буенча дәүләт программасы кабул итмәсә, хәлебез бик мөшкел булачак. Башкортлар Башкортстанда башкорт халкын үстерү буенча бик әйбәт программа кабул иттеләр, аның буенча бик күп эшләр эшләделәр. Алар соңгы елларда татарларга караганда үз милләтләре турында күбрәк кайгырттылар. Башкортлар – яшь милләт, безнең кебек күпсанлы милләт тә түгел, йоклап ятсак, юкка чыгабыз дип тырыштылар. Ләкин алар программасы Башкортстан территориясенә генә кагыла. Алар өчен бу ярыйдыр да, чөнки башкортның дүрттән өч өлеше республика территориясендә яши.Безгә татарлар турында Татарстан территориясендә кайгырту гына җитми, ә безнең законнарыбыз Татарстаннан читтә гамәлдә була алмый. Дөрес, Конституциябездә 14 нче маддә бар, анда «Татарстан Республикасы Татарстаннан читтә яшәүче татарларның милли мәдәниятен, мәгарифен үстерүдә, милли үзенчәлекләрен саклауда ярдәм итә» диелгән. Тик бүгенге көндә бу декларация генә, чөнки ул Татарстан хөкүмәте карарлары белән ныгытылмаган.

**– Ә Татарстанда татар халкының үсеше турында программа бармы соң?**

– Кызганычка каршы, андый программа юк. Без 14 нче маддәне гамәлгә ашыру буенча хөкүмәттән программа төзүен сораган идек, президент үзе дә аның кирәклеге белән килеште. Әмма бүгенге көнгә кадәр ул эшләнмәгән. Россиядә рус телен үстерү буенча программа бар, Россиядә рус халкының мәнфәгатьләрен яклау буенча махсус законнар чыкты. Рус теленең статусы турында гына да берничә закон кабул ителде. «Россия Федерациясе халыкларының телләре турында»гы Законда сүз, нигездә, рус теле турында бара. Хәзер исә «Закон о русском языке как о государственном языке РФ» дигән махсус закон чыкты. Бүгенге көндә РФнең дәүләт милли сәясәте дигән концепциясенә үзгәрешләр-өстәмәләр кертелә. Рус булмаган халыклар өчен бик тә начар үзгәрешләр кертмәкчеләр анда, ул да булса, Россиядә элекке «өлкән туган» сәясәтен кире кайтармакчы булалар. Ягъни рус халкы Россия халыкларын берләштерергә тиеш. Аның 1 нче маддәсендә «бөтен халыклар да тигез» дип язылган, ә аннары «рус халкы безне җыярга, тупларга тиеш» диелгән. Элеккечә халыкларны сортларга аеру килеп чыга. Чынлыкта бер халык икенчесен берләштерергә тиеш түгел, берләштерә дә алмый, мин моның практик ягын күз алдына да китерә алмыйм. Халыкларны хөкүмәт, дәүләт берләштерергә тиеш, бөтен халыкларны тигез итеп.

Концепция төзегәндә бездән дә тәкъдимнәр сорадылар, без аларны җибәрдек, тик берсе дә искә алынмады. Бу бик куркыныч концепция, без аңа каршы киләчәкбез. Заманында безнең Дәүләт Советы православие культурасын мәгариф системасына кертүгә каршы чыккан иде, безнең Россия хөкүмәтенә, президентына, Дәүләт Думасына җибәргән мөрәҗәгатебезгә башка субъектлар да кушылды. Ул вакытта 89 субъекттан 56 сы, хәтта кайбер рус субъектлары да безне яклады. Бу сәясәт биш-алты елга туктап торды да тагын күтәрелә башлады. Әлеге концепцияне киң җәмәгатьчелеккә чыгармыйлар да – матбугатта да ул күренеп кенә алды. 7 октябрьдә Краснодарда бу турыда фикер алышырга тиешләр иде, анда Россия субъектларының җитәкчеләре, милли сәясәт белән шөгыльләнә торган дәүләт структуралары җитәкчеләре җыелырга тиеш иде, ни өчендер аны чигерделәр. Минемчә, әлеге концепцияне хәтта күпчелек белән дә кабул итәргә ярамый, монда барысы да риза булырга тиеш.

**– Россия Конституциясендә «бөтен халыклар да тигез» диелгән. Милли концепция илнең Төп Законына каршы килмәсме соң?**

– Алар каршы килүгә карап тормый. Мисал өчен, Россиянең «Вөҗдан иреге һәм дини оешмалар турында»гы Законы («Закон о свободе совести и религиозных объединениях»). Аның преамбуласында ук христиан диненә өстенлек бирелә! Югыйсә Конституциядә «бөтен диннәр тигез» диелгән. Безнең Дәүләт Советы бу законга төзәтмәләр кертергә тырышып мөрәҗәгать иткән иде, үткән елның 7 июлендә мин Россия Дәүләт Думасына барып чыгыш та ясадым, безне яклап ун процент депутат кына тавыш бирде. Телләр тигезлеге буенча Конституциядә «бөтен телләр дә тигез» диелгән, ә «Закон о русском языке, как о государственном языке Российской Федерации» дигән законда рус теле бөтенләй алга чыгарыла, дәүләт теле буларак кына түгел, һәр өлкәдә дә аңа өстенлек бирелә. Аның һәр статьясы диярлек Конституциягә каршы килә. «Россия

халыклары телләре турында»гы Законның 3 нче статьясы исә – бөтенләй дөньяда булмаган хәл, – кешегә үзе теләгән графикада язуны тыя, андый закон бер илдә дә юк.

**– Латин графикасын яклау өчен халыкара хокукый чаралар бармы?**

– Халыкара рычаглар бар, ләкин безнең әлегә аның белән шөгыльләнеп йөрердәй өлгергән шәхесләребез юк. Бөтенесен дә дәүләт җилкәсенә өеп булмый. Страсбургта Кеше хокуклары буенча суд бар. Ләкин анда аерым кеше хокуклары яклана, анда конкрет бер кеше мөрәҗәгать итү кулайрак. Моның өчен аның хокукы бозылу турында документ кирәк. Безнең очракта, мәсәлән, кеше латин графикасында китап яза ди, ә нәшрият аңа җавап бирә: закон нигезендә сезнең латин язуында язарга хакыгыз юк, ди. Шушы рәсми җавап нигезендә ул халыкара судка мөрәҗәгать итә ала. Ләкин әлегә андый документ язып бирерлек Кеше табылганы юк. «Латиницада язганны бастырмады» дигән яман атны күтәргәнче, алар басуны артык күрә.

**– 15 октябрьдә, традиция буенча, Казанда Хәтер көне үтте. Митингта катнашканнар арасында күбрәк өлкәннәр булуы, халык санының да елдан-ел кими баруы күренеп тора. Сезнеңчә ничек: татарларда милли хәрәкәт сүндеме, сүлпәнәйдеме, әллә башка сыйфатка күчтеме?**

– Милли хәрәкәт башка формага күчте. Сыйфат ягыннан ул хәзер югарырак дәрәҗәдә дип саныйм. Элек милли хәрәкәт, нигездә, урамда иде, бүген ул дәүләт структураларына үтеп керде, дәүләт структураларында эшләгән кешеләр арасында да шактый ук милли җанлы кешеләр. Шул ук театрларда, Дәүләт Советында, министрлыкларда да бар алар. Милли хәрәкәт цивилизацияле юллар белән эшли хәзер. Дөрес, урамнарга чыгу да кирәк, милли хәрәкәт төрле формаларда булырга тиеш. Әгәр дә һәммә җирдә милли җанлы кешеләребез эшләмәсә, милли хис урамнарда гына булса, ерак китә алмас идек. Тагын бер сәбәп – халыкта ниндидер күңел кайту хисе бар. 90 нчы елларда урамнарга чыккан кешеләрнең күңелләре кайтты, чөнки алар теләгән максатларына ирешә алмадылар. Милли хәрәкәт көчәюдән куркып федераль үзәк субъектларга күпмедер ирек бирде, Татарстан нефтенең дә бер өлешен үзебезгә бирә башладылар, әмма ул байлык, нигездә, халыкка да, урамнарга чыгучыларга да эләкмәде. Ниндидер бер өлеш баеды, калганнар урамда кычкырып калды. Алар арасыннан берничә кеше генә дәүләт структураларына кереп, үзләренә урын таба алды.

Мин урам сәясәтенә каршы түгел, ләкин ул акыллы булырга тиеш. Без унбиш елдан артык Хәтер көне үткәрәбез, тик быел гына ул азрак цивилизацияле төскә керә башлады. 15 октябрьдә ел саен җыелабыз да Иван Грозныйны сүгәбез, аның карачкысын яндырабыз. Ә бит Иван Грозныйны сүгеп кенә бернәрсәгә дә ирешеп булмый. Үзебезне дә сүгәргә кирәк: ни өчен без милләт файдасына эшләмибез? Безнең бүген законнарыбыз җитәрлек – «Телләр турында» Законыбыз бар, мәгариф турында, мәдәният турында. Нигә без аларны үтәмибез? Безгә үзебезне үзгәртергә кирәк. Бер генә мисал: бездә «Телләр турында» Законны бозган өчен административ җаваплылыкка тарту турында кодекс бар. Татарстанда 2 миллион татар яши, әле бүгенге көнгә кадәр бер генә татарның, «минем белән татарча сөйләшмәделәр, татарча язган гаризамны алмадылар, судта татарча сөйләргә ирек бирмәделәр һ. б. дип, судка мөрәҗәгать иткәне юк. Бөтенесе дә минем өчен кемдер эшләргә тиеш дип уйлый. Син гражданин икәнсең – үзеңне үзең яклый бел. Әлбәттә, моның өчен гражданнар җәмгыяте төзү кирәк.

**– Яшьләрдә өмет бармы?**

– Минем бөтен өметем яшьләрдә, һәр буын яшьләргә шулай өмет белән карыйдыр инде. Без бит үзебез коммунистик чор продукциясе. Минем әтием кып-кызыл коммунист иде, әле шул чорда үсеп тә, без нидер эшли алдык. Инде без үзебез булдыра алганны эшләдек бугай. Яшьләр яңа чорда тәрбияләнә. Алар, Татарстандагы яшьләрне әйтәм, безнең кебек, татарны бетереп ташлаган дәреслекләр буенча укымыйлар, алар татар гимназияләрендә белем алалар, теләкләре булса, үз милләтенә караган теләсә кайсы мәгълүмат белән таныша алалар. Чынлап уйласаң, соңгы 15 елда без милли аң үсеше буенча бик алга киттек. Халыкның милли аңы уянуы – безнең соңгы 15 елда ирешкән иң зур уңышыбыздыр.

Яңа шартларда үскән яшьләр безгә караганда бик күп артык эшләргә тиешләр. Хәзер алар мәктәпләрне тәмамлап килә, вузларда укый, югары уку йортларын тәмамлый, бер биш-ун елдан

мин милли үсештә бик зур алга китеш булыр дип уйлыйм. Ул вакытта алар урамнарга да бик артык чыгып йөрмәс, башка төрле юллар табар. Ул егетләр-кызлар министрлыкларга эшкә килер, депутатлар булыр, ул вакытта безнең бүгенге проблемаларыбыз бөтенләй башка төрле юллар, ысуллар белән хәл ителер.

**– Татар яшьләрен милли мәдәнияткә тарту өчен татарның шәһәр мәдәниятен булдыру кирәк. Сез моның белән килешәсезме?**

– Әлбәттә. Татарны саклап калган нәрсә, беренчедән, дин булса, икенчедән – гаилә. Авыл – татарның нәни дәүләте. Татар дәүләтен югалткан, ләкин дәүләтчелеген югалтмаган. Татарның һәрбер авылы – кечкенә генә дәүләт сыман. Аның президенты бар, ул, гадәттә, авылның хөрмәткә иң лаек кешесе була, янында премьер-министры – булдыклы егете йөрер. Авылның парламенты – киңәш органы, җыены бар, аның консерваториясе бар: музыкантлары, җырчылары, бер шамакае, бер җүләре бар – дәүләттә нинди компонент булырга тиеш, һәммәсе дә бар. Татарның дәүләтчелеге бер авыл кысасына сыйган. Авылдагы гаилә культы безне саклап калган.

Хәзер авылларыбыз бик авыр хәлдә. Безнең хәзер иң төп максатыбыз – татарның шәһәр культурасын булдыру. Бүгенге көндә ул бик зәгыйфь хәлдә әле. Әгәр дә без киләчәктә татарның шәһәр культурасын булдырмасак, бу безнең өчен катастрофага әвереләчәк. Татар авылы бетә, ә татар шәһәребез юк безнең. Без югалып калачакбыз. Җанны иң нык борчыган нәрсә – Казанның милли йөзе бөтенләй булмавы. Яшьләр шушы мохиттә үсә, Казанда милли рухның юклыгын тоеп үсә. Бүген безнең яшьләр күңеленә ята торган мәдәниятебез бик аз. «Зәңгәр шәл»ләребез әйбәт, әмма аны яшьләребез карый алмый. Аларны карау өчен яшьләр әзер түгел. Ә заманча яшьләр сәнгате бик тә примитив хәлдә, үзешчәнлек дәрәҗәсендә генә. Һәвәскәр җырчылар да кирәк. Ләкин без аларны үзебезнең иң зур казанышыбыз дип саныйбыз икән, димәк, без рухи яктан ярлы халык. Бүген опера сәнгатенә дә, башка югары сәнгатькә дә игътибар җитми. Иң начары – җитәкчеләребез дә үзешчәннәргә йөри, алардан кумир ясый. Җитәкче, дөнья классикасына йөрмичә яисә татарның зур сәнгате вәкилләре булган Сәйдәшләр, Яхиннар кебек композиторларны тыңламыйча, үзешчәннәргә генә йөри икән, бу инде бик тә начар үрнәк.

Мәдәният оешмаларына да яшьләрне мәдәнияткә-сәнгатькә җәлеп итү өчен бик күп эшлисе бар. Аның иң беренче нигезе сәнгать уку йортларында салынырга тиеш. Безнең консерваториядә татар музыкасы факультеты – зур бинаның җимерелеп беткән ике бүлмәсе генә. Консерваториядә татар музыкасы өчен нибары шул ике бүлмә генә булуы бик зур чиркәүгә кереп, аның бер почмагына намазлык җәеп, намаз укыган кебек: анда синең динеңне дә белмиләр, музыкаңны да санга сукмыйлар. Татар музыка факультеты килеп кергәндә үк бөтен бизәлеше, бар мохите белән татарлыкны күрсәтеп торырга тиеш. Анда бөтен халәт милли рухта булырга тиеш, шунсыз анда татар музыканты тәрбияләп булмый. Бүгенге көндә безнең театр, музыка өлкәсендә татарча белүче бер-ике генә сәнгать белгечебез бар. Шул булдымы эш? Театрыбызны, музыкабызны үз телебездә аңлатып язарлык-сөйләрлек белгечләребез дә юк. Театрларыбызның күбесендә артистларыбыз, татарча спектакль уйнап сәхнә артына кергәннән соң, шундук русча сөйләшә башлыйлар. Безнең югары уку йортларында да татар теле үги бала шикелле генә, татар тарихын да белмиләр анда, сәнгатен дә. Яшьләр өчен сәнгатьне кем тудыра? Менә бүген генә мәдәният һәм сәнгать университетында укып чыккан яшь сәнгать әһелләре – режиссёрлар, хореографлар һ. б. Ә бу уку йортларында татарча мохит юк, шуңа да алар яшьләргә лаеклы, кызык, җәлеп итәрлек музыка язарлык, спектакль куярлык сәнгатькәрләр әзерләп чыгара алмыйлар. Без, яшьләр татарча музыка язмыйлар, дибез, ә үзебез татарча музыка язарлык белгечләр тәрбияләмибез.

Бу уңайдан безнең комитетның бер нияте бар. Татар теле үлем хәленә килеп җиткәч, республикада «Татарстан халыклары телләре турында» Закон кабул ителгән иде. Соңгы елларда ул законны тиешле дәрәҗәдә эшләми дип әйтсәк тә, аның нигезендә бик күп алга китеш булды: мәктәп-гимназияләр ачылды, яңа газета-журналлар чыкты һ. б. Дөрес, башкарасы эшләр әле бик күп...

Милләтне саклап калу өчен тел генә җитми. Милли музыкасыз милләтне күз алдына да китереп булмый, чөнки ансыз милләтнең рухы югала. Шуңа да без киләсе елга музыка белгечләрен, музыка сәнгатенә катнашы булган җитәкчеләрне чакырып, парламент тыңлаулары уздырырга

уйлыйбыз, һәм «Татарстанда музыка культурасын өйрәнү, саклау, үстерү турында Дәүләт программасы»н кабул итәргә телибез. Ул, «Телләр турында»гы Закон кебек, 10 елга исәпләнгән булырга тиеш. Бары дәүләт күләмендәге шундый чаралар гына милли музыкабызны, димәк, милли мәдәниятебезне дә саклап калырга мөмкинлек бирәчәк.

*Әңгәмәдәш Алия Сабирова*
*2005*

# БЕР-БЕРЕБЕЗДӘН НИГӘ ШИКЛӘНӘБЕЗ?

**Гыйнвар аенда узган ТР Дәүләт Советы сессиясе утырышында Россия җитәкчелегенә мөрәҗәгать кабул ителде. Мөрәҗәгатьнең асылы мондый: илдә динара, милләтара мөнәсәбәтләр кискенләште. Төрле халыклар арасында бер-берсен күралмау, шикләнү хисләре көчәя бара. Бу хисләр инде күңелләрдән ташып чыгып конкрет гамәлләргә әверелә башлады. Ил җитәкчелеге кичекмәстән чаралар күрергә тиеш. Нишләдек соң без? Кая барабыз? Шушы сораулар белән сессиядә кабул ителгән мөрәҗәгатьнең авторы, Дәүләт Советының даими комитеты рәисе Разил Вәлиевкә мөрәҗәгать итүем табигый иде.**

**«Иртәгә сессия утырышы дигән төнне куркып уяндым. Төн болай да шомлы инде ул», – дип сүз башлады Разил әфәнде.**

**– Әлбәттә, илдә милли, дини тотрыклылык урнаштыру кирәклеге турында уй бер кичтә, бер төндә генә тумагандыр. «Ксенофобия» дигән зәхмәт барлыкка килүнең сәбәпләре турында элегрәк тә күп уйлагансыздыр.**

– «Ксенофобия» дигән сүзнең мәгънәсен беләсездер. Ул – грек сүзе, «таныш түгел йөзләрдән курку», «шикләнү» дигән мәгънәне аңлата. Яңа җәмгыять төзибез дисәк тә, без айдан төшкән, төрле планеталардан килгән затлар түгел бит. Гасырлар буе шушы җирдә гомер иткән кешеләр. СССР вакытында «Тугандаш халыкларның тату гаиләсе», бер оя балалары идек. Инде СССР таркалып, суверен Россия дәүләте, демократик җәмгыять төзелә башлагач, күңелдә тагын да якты өметләр уянган иде. Чөнки Россия Конституциясе бөтен халыкларга тигез хокук, дин иреге вәгъдә итте.

**– Ләкин, Разил әфәнде, ничек кенә хурласак та, элекке СССРда «таныш түгел йөзләрдән курку, шикләнү», башка милләтләргә бүре итеп карау сизелми иде шикелле.**

– Әйе, «халыклар дуслыгы» байрагы астында яшәдек. Әмма күз буяу кебек кенә иде ул. Формаль булса да, Милләтләр палатасы бар иде. Яхшымы-яманмы, телевидениедән айга бер, кайда бер дигәндәй, төрле милләтләрнең әдәбиятына, мәдәниятенә кагылышлы тапшырулар күрсәтәләр иде. «Маяк» радиосыннан сәгать буе татар музыкасын бирәләр иде. Әмма шул ук вакытта СССРда халык берничә сортка бүленгән иде: мәсәлән, беренче сорт – илне берләштерүче рус халкы, икенче сорт – союздаш республикаларда яшәүче халык, өченче сорт – автономияле республикаларда, дүртенче сорт – автоном округларда яшәүчеләр һ. б. СССРда милләтләрне ачыктан-ачык талаштыру, маңгайга-маңгай чәкештерү юк иде. Әмма уйлап карагыз, чын дуслык булса, СССР таркалган булыр идемени?

**– Разил әфәнде, суверен Россия дәүләте оештырылгач мантып киттекмени?**

– Россия Конституциясе бөтен халыкларның тигез хокуклыгын игълан итте һәм 90 нчы елларда бу юнәлештә бераз алга китеш тә булды. Ә менә соңгы елларны тагын чигенә башладык: Конституция менә дигән, аңа каршы бер сүзем дә юк, ә тормыш икенче юлдан китте.

**– Разил әфәнде, төрле милләт халыкларының бер-берсенә кырын карый башлавына Чечня сугышы да сәбәп булмадымы? Бездә бит «кавказ йөзле» дигән яңа, дошман милләт барлыкка килде.**

– Бөтен бер халыктан дошман ясау милләтара мөнәсәбәтләрдә тискәре роль уйнады, әлбәттә. Тик рус-чечен сугышын гына беренче планга куярга ярамый. Бу сугыш өлкән туганның башка милләтләргә мөнәсәбәтен раслады гына. «Кавказ йөзле», «Кавказ чырайлы» дигән тамга аларга соңрак ябышты. Ә бит тамганың «татарская морда» дигәне дә бар иде. Бервакыт Кавказ кешесенә шаяртып әйтеп тә куйган идем: «Меняю татарскую морду на лицо кавказской национальности, – дип. – Потому что «лицо» бывает у людей, а «морда» у «животных», – мәйтәм.

**– Нәрсә диде инде кавказлы?**

– Дәшмәде. Моңсу гына елмаеп куйды.

**– Разил әфәнде, хәзер безгә «татарская морда» дип кычкырып әйтүче юк бит.**

– Шикләнәләр. Чөнки Татарстан үз көчен, үз куәтен күрсәтә, үзе белән исәпләшергә мәҗбүр итә башлады. Мин бит ил-җир буйлап күп йөрим һәм сизәм: куркалар, шикләнәләр, әмма исәпләшәләр.

**– Разил әфәнде, Сез бу сүзләрне күпмедер дәрәҗәдә күңелне тынычландыру өчен генә әйтәсез кебек.**

– Ә мин күкрәк кагып йөри башладык дияргә җыенмыйм да, һәм моңа рөхсәт тә итмәячәкләр. Халыкта «бармакның кайсын тешләсәң дә авырта» дигән гыйбарә бар бит. Мин, мәсәлән, бөтен милләтләргә дә бертигез карыйм, бер генә халыкка да үчем юк, рәнҗемим дә. Әлбәттә, үз халкың беренче урында торырга тиеш инде ул, әмма бу башка халыкларны, башка диннәрне кысу, җәберләү хисабына аерым бер милләтне генә чәчәк аттырырга кирәк дигән сүз түгел.

Соңгы еллардагы дини, милли каршылык, исламнан дошман эзләү әлеге дә баягы бар халыкларга да бертигез мөнәсәбәт булмаудан. Юкса, алдарак әйткәнемчә, Россия Конституциясе бөтен милләтләргә тигез хокук бирә. Әмма шул ук вакытта «бармакны тешләгәч, авыртуын сизмибез», дөресрәге, сизмәскә тырышабыз. «Вөҗдан һәм дин иреге турында»гы Законны гына алып карыйк. Аның бисмилласында ук, ягъни преамбуласында ук инде Конституциягә каршы килү бар: православие диненең аерым әһәмияткә ия булуы турында язылган, аннан соң башка диннәр булса ярый, булмаса ярый дигәндәй, санап кына кителә. Татарстан парламенты әлеге законда конституцион хокуклар бозылуны дәлилләп Россия Думасына үз закон проектын тәкъдим иткән иде. Әмма тәкъдим үтмәде.

Узган елның 7 июлендә мин Думада закон инициативасы белән чыгыш ясадым. Россия законының преамбуласына ук үзгәрешләр кертергә тәкъдим иттем, диннәрнең тигезлегенә ирешергә, секталарга, чит илдән килгән миссионерларга таләпне көчәйтергә, дини оешмаларны теркәгәндә игътибарлы булырга кирәклеге турында сөйләдем. Тәкъдимнәрем үтмәде.

**– Кемнәр хупламады, законга үзгәрешләр кирәк түгеллеген ничек дәлилләделәр?**

– Кая дәлилләү! Иң кызыгы – миңа каршы сөйләүче булмады, әмма 450 депутаттан нибары 45 е хуплап тавыш бирде.

**– Ә калганнары?**

– Тавыш бирүдә катнашмадылар, гәрчә, кем әйтмешли, өелешеп шунда утырсалар да. Спикер дә дәшмәде. Дини оешмалар эшенә, вөҗдан ирегенә кагылышлы проблемалар белән шөгыльләнүче комитет әгъзалары белән дә сөйләштем. Иң кызыгы: «Сез тәкъдим иткән закон проекты бик актуаль, ә бүген без аны кабул итә алмыйбыз», – диделәр. Хәтта сүзсез калмый торган Жириновский да авызына су капкандай утырды.

**– Разил әфәнде, регламент буенча депутатларның тавыш бирүдә катнашмаска хокуклары бар бит.**

– Бар, әмма дәшми калу үзе үк җинаять түгелме соң? Депутатлар безнең хаклы икәнне беләләр иде, диннәрнең тигезлегенә каршы тавыш биреп, Россиянең күпмилләтле халкы алдында җавап тотудан курыктылар алар. Менә хәзер үзебез чәчкәнне үзебез урабыз: синагогага кереп 40 кешене суеп чыгалар, муллаларны кыйныйлар. Безнең дин әһелләре Волгоградка, салыначак мәчет урынына таш куярга барганнар иде, тегендә мәчет салуга каршы митинг оештырдылар.

Зиратларда, бөтен ил буйлап, кабер ташларын җимереп йөриләр. «Русия – руслар өчен» дигән шигарь астында фашистик оешмалар барлыкка килде. Бу – нинди дә булса милләтне, динне башкалардан өстен куярга омтылу нәтиҗәсе.

Фашизм, Гитлер каян килеп чыкты? Немецлар – аерым бер раса, башкалар аңа хезмәт итәргә тиеш дип ишанудан. Мин гади халыкны гаепләмим, өстән нәрсә кычкыралар – астагылар шуны эшли. Мәсәлән, Жириновский: «Многонациональность – это беда для России», – дигәч, әлбәттә инде, башкаларны себерең түгәргә дигән фикер туа башлый, халык моны дәүләт сәясәте буларак кабул итә.

Аннан соң дәреслекләрне генә укып кара. «Татарская морда», «злой татарин», «кровожадный татарин» кебек сүзтезмәләр әледән-әле очрап тора.

– **Разил әфәнде, бу хакта сүз күптән бара түгелме соң? Галимнәребез, тарихчыларыбыз, депутатларыбыз фикере Мәскәүгә барып җитә алмыймы? Әллә барып җитеп тә санга сугу юкмы?**

– Без Россия җитәкчелегенә мөрәҗәгать итеп карадык инде, безнең фикергә башка төбәкләр дә кушылды. Узган ел федерация Советында да махсус сөйләшү булган иде, әмма нәтиҗә юк. Нәтиҗәне үзебезгә ясарга калды: димәк, Россиядә дәүләт күләмендә милли сәясәт юк, һәм ул җитәкчелеккә кирәк тә түгел.

**– Ялгышмасам, Россиянең милли дәүләт сәясәте турында закон эшләнгән иде бит.**

Закон проекты эшләнгән иде, моннан 5–6 ел элек, ләкин бүгенгә хәтле кабул ителгәне юк. Аның каравы рус теле турында ничәмә-ничә закон кабул ителде. Тагын Конституцияне искә алырга туры килә инде: Төп Закон барлык телләргә дә тигез хокук бирсә, рус теле турындагы законда аерым телләргә өстенлек бирелә.

**– Россия дәүләтендә рус теленә өстенлек бирелергә тиештер бит инде?**

– Дәүләт теле буларак тиештер. Мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Милли дәүләт сәясәте концепциясе турындагы законда Россия рус милләте тирәсенә оешкан дәүләт диелгән фикер бар. Ә бит ул Алтын Урда чорында оешты, димәк, дәүләт барлыкка китерүче милләтләр икәү – рус һәм татар милләте була. Президентыбызның дәүләт киңәшчесе Рафаэль Хәкимов та: «Ул ике аякта басып торырга тиеш», – дигән иде. Казанның 1000 еллыгына килгәч В. Путин да татарның Россия дәүләтен төзүче халыкларның берсе икәнен әйтте. Шулай булгач, ни өчен рус милләте генә дәүләтне оештыручы да, башкалар аның тирәсендә чабышып йөрүче генә булырга тиеш ди.

**– Разил әфәнде, менә Сез сөйлисез, әмма минем баштан бер уй китми: боларның барысына да кем гаепле соң?**

– Әйткәнемчә, Конституциягә тел-теш тидерәсе килми. Бүгенге көндә Россия җитәкчелеге, президенттан башлап хөкүмәт, федерация Советы, Думага кадәр бер үк сәясәт алып баралар. Әлеге сәясәтнең максаты – унитар дәүләт төзү. Ә унитар дәүләт милләтләрнең тигезлеген дә, үсешен дә тәэмин итә алмый.

Без СССРда совет халкы идек, хәзер «Россия халкы» дигән милләтле, дөресрәге, милләтсез дәүләт төзүгә омтылыш бара.

**– Безнең халык та АКШтагы «америкалы» кебек «россияле» генә булып яши алмыймыни?**

– Беренчедән, АКШта милли, дини нигездә ачыктан-ачык маңгайга-маңгай чәкештерү, түбәнсетү, рәнҗетү юк, әмма барлык милләтләр турында кайгырту да югары дәрәҗәдә дип әйтәсе килми.

АКШта бит төрле җирдән җыелган халык яши. Баштарак җирле халык белән килмешәкләр арасында бәрелешләр булгалаган. Хәзер индеецлар исә резервациядә. Бу илдә тормыш дәрәҗәсе югары, әмма баштарак яңа җирне үзләштерү, төзү, тормышны югары дәрәҗәгә җиткерү өчен дөньясын онытып эшләгән халык хәзер үзенең килеп чыгышына игътибар итә, тамагы туйгач, «икмәк турында түгел, хикмәт турында» уйлый башлады. Мәсәлән, кайчандыр Мексикадан күчеп килгән испан телле халык үз таләпләрен куя. Дөрес, хакимият аларның сүзенә колак сала һәм, мәсәлән, испан телендә мәктәпләр ачыла башлады. Канада французлары исә, без яшәгән җирдәге мәктәпләрдә бары тик француз теле генә укытылырга тиеш, диләр. Әгәр анда барып француз кибетенә кереп инглизчә сөйләшә башласаң, буш кул белән чыгып китүең дә бар. Әйткәнемчә, Америка яшь әле ул, 200 елдан аз гына артык тарих. Бу нибары 7–8 буын дигән сүз. Утырып, урнашып кына килә әле ул.

Менә шул утырып урнашкач, тормышын тәэмин иткәч, үз тамырларына кайта башлады Америка халкы, һәм бу киләчәктә милли каршылыклар китереп чыгарырга мөмкин. Америкада яшәүче төрле халыкларның бер юанычы бар, аларны АКШ дәүләте генә түгел, үз дәүләтләре дә яклый. Ә безнең ярдәм сорап барыр җиребез юк, без Россиядән чыгып та китә алмыйбыз.

**– Разил әфәнде, яңадан Дәүләт Советында кабул ителгән мөрәҗәгатькә кайтыйк әле. Аның язмышы ничек булыр?**

Анык кына әйтә алмыйм, дәшми калсак, телсез, диячәкләр. Мөрәҗәгатьтә бит татар, Татарстан язмышы турында гына сүз бармый. Безне кечкенәдән үк «татулыкка ни җитә» дип тәрбияләделәр. Өйдә талаш чыга икән, байлык та, мал да, гомумән, бернәрсә дә күзгә-башка күренми бит ул.

Илдә тавыш чыкса да, бәрәкәт бетәчәк. Президентыбыз М. Шәймиевнең атлаган саен «бездә тотрыклылык, бездә аңлашып яшәү...» дигәннәренә артык күнегеп беттек кебек. Ә бит Минтимер Шәриповичның милли, дини татулыкны беренче урынга куюы бик тә, бик тә әһәмиятле. Безгә хәзер ничек булса да Татарстанда шушы дуслык хисләрен саклап калырга, алай гына да түгел, бөтен Россиягә җәелдерергә кирәк.
Милләтара ызгыш русларга да кулай түгел, башка халыкларны үзенә каршы кую – зур фаҗиганең башы ул. Кыскасы, дини, милли сәясәттә бер-бер чара күрелмәсә, ил таркалачак. Гауга «син», «мин» димәктән чыгар, ди бит.

**– Әле тагын «Җил чәчсәң, давыл урырсың» дигәне дә бар.**

– Ә бу кемгә кирәк?

*Әңгәмәдәш Риман Гыйлемханов*
*2005*

# ЧИГЕНҮ ТҮГЕЛ – КӨРӘШҮ

*Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиев белән турыдан-туры әңгәмә.*

**– Разил абый, авыл җирләрендә аз комплектлы мәктәпләрне кушу турында сүзләр йөри. Бу дөресме? (Фирүзә Исмәгыйлева, Чаллы)**
– Узган ел Татарстан хөкүмәте мәктәпләрне үзгәртеп кору (модернизацияләү) турында программа кабул итте. Аның буенча аз комплектлы мәктәпләрнең кайберләрен башлангыч итеп калдырып, аларда укучы балаларны башка мәктәпләргә йөртеп укыту каралган. Моның өчен хөкүмәт тарафыннан автобуслар бүлеп бирү, шулай ук юллар төзү планга кертелгән. Бу эш, акрын гына булса да, башланды инде.
Бер мәктәптән икенчесенә йөртеп укыту, бәлки, кирәктер дә. 20–30 бала өчен урта мәктәп тотып булмый. Әмма моның өчен гадәти шартлар булу, ягъни, юл, автобус һәм башкалары кирәк. Шуңа күрә бу мәсьәлә әле 1–2 елда гына хәл ителмәс дип уйлыйм. Ләкин дөньяда, әйтик, шул ук Америкада, Европа илләрендә бу мәсьәлә инде хәл ителгән. Бездә әле алардагы шикелле шартлар юк шул. Бу программаны кабул иткәндә, хөкүмәт: «Без балаларга яхшы тәрбия, яхшы белем бирергә телибез икән, алар бөтен уңайлыклары, бөтен мөмкинлекләре булган мәктәпләрдә укырга тиешләр», – диде. 20–30 бала укыган мәктәптә, билгеле, андый мөмкинлекләр юк. Димәк, иң беренче чиратта безгә бу шартларны тудырырга кирәк.
**– Алайса, бу әле киләчәк эше...**
– Әйе, бүгенгә әле бу тулысынча хәл ителгән мәсьәлә түгел. Аның башка проблемалары да бар. Әйтик, үз мәктәпләрендә балалар моңа кадәр татарча укыганнар, ә күрше авылда – рус мәктәбе. Димәк, балалар рус мәктәбенә йөрергә тиеш булалар. Моның белән килешү мөмкин түгел. Без балаларыбызны милли рухта, милли белем биреп тәрбияләргә телибез. Икенче кыенлык, мәсәлән, бала күрше авылга йөреп укый. Анда бит 9, 10, 11 нче сыйныф укучылары белән бергә 5, 6, 7 нче сыйныф балалары да бар. Өлкән классларның дәресләре икедә, өчтә тәмамланырга мөмкин, ә кечкенәләрнеке иртәрәк бетә. Аларга көтеп торырга туры килә. Автобус берәү генә, шоферы да бер генә. Ул авырып китсә, балаларны кем илтә?
**– Фәнни хезмәткәр Фәрит Минхәеров борчый әле Сезне. Мин Милли китапханәгә 35 ел йөрим. Аның татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегенең бүгенге халәте һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Китапханәнең йөзе булырга тиешле бу бүлекнең киләчәге нинди?**
– Татарстан Милли китапханәсе – республикабызның баш китапханәсе. Борынгы китаплары, фондлары буенча ул Россиядә иң бай китапханәләрнең берсе санала. Анда бөтен бүлекләрдә дә шартлар авыр. Бүген китапханәдә 3 миллион ярымга якын китап саклана, ә безгә бирелгән биналарда норматив буенча 500 мең китап кына сакланырга тиеш. Укучыларга да, китапларга да, килгән кешеләргә һәм анда эшләүчеләргә дә уңай шартлар тудыру өчен безгә 7 тапкыр зуррак бина кирәк. Бу мәсьәләне дистә еллар буе күтәреп киләбез инде, тик әлегә кадәр уңышка ирешкәнебез юк. Яңа бина төзү буенча хөкүмәтнең 5 карары чыкты. Дәүләт Советының да 1990 елда чыккан карары бар. Проект та эшләнгән, урын да билгеләнгән, акча гына табасы калды. «Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү буенча дәүләт программасы» нигезендә Милли китапханә бинасы 2010 елга кадәр төзелергә тиеш, насыйп булса.
**– 1990 елда Сез Татарстан бәйсезлеген яклап тавыш биргән идегез. Суверенитетка һөҗүм башлангач, Татарстан Конституциясен җиңел генә үзгәртеп куйдыгыз. Моны ничек аңларга? (Сәгъдулла Шәйхуллин, Казан)**
– Бу мәсьәләдә мин Сезнең белән килешмим. Дәүләт Советы сессиясе материаллары белән танышып барган кеше болай дип әйтмәс иде. Чөнки без анда пәрмә-пәр килеп, бик күп бәхәсләр алып бардык. Прокурор кисәтүләре дә булды, дистәләгән судларга да бардык, аларның кайберләрендә хәтта җиңеп тә чыктык. Әмма Россиянең куәтле дәүләт машинасына берничә

депутат кына каршы тора алмый. Конституциянең яңартылган вариантын эшләгән вакытта мин комиссия әгъзасы идем. Бик күп нәрсәләр белән килешмәдек, үзебез кирәк дип санаганнарын якладык. Мәсәлән, без Туфан Миңнуллин белән Конституциягә өр-яңа 14 нче статьяны керттек. Анда «Татарстан читтә яшәгән татарларның милли мәгарифен, мәдәниятен үстерүдә, милли үзенчәлекләрен саклауда ярдәм итә» диелгән. Аны үткәрү дә безгә җиңел булмады.

1992 елда кабул иткән Конституциядә «Татарстан суверен республика» дип язылган иде. Бу чыннан да шулай булырга тиеш. Әмма прокурор протест белдергәннән соң, без бераз гына артка чигендек һәм «Татарстан Республикасы үзенә бирелгән вәкаләтләр кысасында суверен» дип үзгәрттек. Чыннан да шулай бит. Булмаган вәкаләтләреңдә суверен була алмыйсың. Ләкин көрәш киләчәктә дә дәвам итәр. Бүген без Дәүләт Думасында Татарстан белән Россия арасында вәкаләтләр бүлешү турындагы Шартнамәнең расланuyн көтәбез. Ул кабул ителсә, безнең эшләр бераз җиңеләячәк. Чөнки анда бүген бәхәсле булган кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертеләчәк. Без Шартнамә проектына «Татарстан Президенты ике дәүләт телен дә белергә тиеш» дип язып куйдык. Димәк, көрәш дәвам итә дигән сүз.

**– «Бердәм Россия» партиясе Россиянең бердәмлеге һәм бүленмәслеге позициясендә тора. Сезнең бу партиягә керүегезнең сәбәбе нәрсәдә? (Әгерҗедән газета укучыбыз)**

– Мин «Бердәм Россия» партиясе исемлеге белән сайланган депутат түгел. Үземнең туган ягымнан, бер мандатлы округтан халык тарафыннан турыдан-туры сайландым. Партия исемлегеннән кергән депутатларны да хурларга җыенмыйм. Алар арасында Туфан Миңнуллин, Индус Таһиров кебек милләтебез өчен җан атып торган депутатларыбыз бар. Нинди дә булса партиягә керүчеләр булса, аларны да гаепли алмыйм. Дөньяда бер генә партиянең дә начар программасы булганы юк. Эш ул программаларның ничек үтәлүендә.

**– Ни өчен Татарстанда Милләтләр эшләре министрлыгы юк, ә Башкортстанда бар? (Рәшит Гобәйдуллин, Азнакай)**

– Без дә хөкүмәткә нәкъ шундый ук сорау бирәбез. Әмма республика җитәкчеләре: «Әгәр без мондый министрлык оештырсак, башка министрлыклар бу эштән читләшәләр. Милли мәсьәлә белән бер министрлык кына түгел, бөтенесе дә шөгыльләнергә тиеш», – диләр.

Бер караганда, бу дөрес тә. Шулай да аерым министрлык булып, бу юнәлештәге эшләрне координацияләп, оештырып торса, тагын да дөресрәк булыр иде. Бүген бездә милли мәсьәләләр белән күбрәк Мәгариф һәм Мәдәният министрлыклары шөгыльләнә. Безнең комитет шулай ук бу эшнең үзәгендә кайный.

**– Разил Исмәгыйлевич, Мәдәният йортларын хәзер җирле үзидарәләр карамагына бирделәр. Болай эшләү аларның бетүенә китермәсме? (Мәдинә, Чирмешән районы)**

– Күпмедер дәрәҗәдә андый куркыныч бар. Без бу хакта хөкүмәткә дә әйттек. Үткән сессияләрнең берсендә Мәдәният йортларының гына түгел, гомумән, мәдәният учреждениеләренең язмышы турында бик борчылып сөйләдек. Әле шушы көннәрдә генә күңелгә бераз җылы кертә торган хәбәр – «хөкүмәтнең бүгенгә кадәр эшләгән Мәдәният йортлары эшләргә тиеш» дигән карарын алдык. Әмма карар бер нәрсә, ә аны гамәлгә кертү башка эш. Шулай да өметләнәбез инде.

**– Ремонт эшләре дә шул суммага керәме?**

– Ул үзегезнең район бюджеты хисабына үткәрелергә тиеш. Әгәр район җитәкчелеге авыл мәдәният йортын ремонтларга акча сорап хөкүмәткә мөрәҗәгать итә икән, өлешчә андый ярдәм дә күрсәтелергә мөмкин. Шуңа күрә сезгә башта район муниципаль берәмлеге җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк, ә алар – республика җитәкчелегенә. Без исә кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышырбыз.

**– Башкортстанда татарларга карата булган карашны ничек бәялисез? (Егоров, Теләче районы)**

– Татарларга карата андый мөнәсәбәт булырга тиеш түгел дип саныйм. Сан ягыннан икенче урында торган халыкның телен дәүләт теле итеп игълан итмәү – ул бернинди кысаларга да сыймый торган хәл. Без бер-беребез белән тыныч, дустанә мөнәсәбәттә булып, аңлашып яшәргә телибез икән – бер-беребезнең телен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә тиешбез.

Мортаза Рәхимовны президент итеп сайлаган вакытта ул сайлаудан соң бу мәсьәләгә кире кайтырга, аны хәл итәргә вәгъдә биргән иде. Кызганыч, мәсьәлә әле дә хәл ителмәде, һәм ул хәл ителмичә торып, минемчә, андагы киеренкелек бетәчәк түгел.

**– Биектау районының Биектау авылыннан татар теле укытучысы Илзирә Мөхәмmәтҗанова борчый Сезне. Разил Исмәгыйлевич, татар телен дәүләт теле итә алырсыз дип зур өметләр баглаган идек. Татар авылларында татар теленең бетеп барганын беләсезме соң? Депутатлар бу хәлне ник президентка җиткермиләр?**

– Күп вакыт без, үзебезнең проблемаларны чишә алмаганда, Мәскәүне гаепләргә яратабыз. Югыйсә татар авылларында, татар мәктәпләрендә үз ана телебездә укытырга кем комачаулый соң? Йә булмаса үзебезнең Дәүләт Советы сессияләрендә, гомумән, республика, хәтта район күләмендәге җыелышларда туган телебездә сөйләүне кем тыя? Юк бит андый тыюлар.

**– Шул ук вакытта сессияләрдә гел русча гына сөйләшәсез. Моңа Дәүләт Советы нинди чара күрергә тиеш тер бит...**

– Кешенең үзендә юк икән, аны мәҗбүр итеп кенә эшләтеп булмый. Туфан абый белән мине беркем дә мәҗбүр итми, тыймый да, рәхәтләнеп сөйлибез бит татарча. Безнең Дәүләт Советында 100 депутат бар. Шуларның 80 гә якыны үзебезнең милләттәшләребез. Араларында татарча шартлатып сөйли ала торган, татар авылында туып үскән җитәкчеләр дә бар – сөйләшмиләр бит татарча. Аларны ничек мәҗбүр итәсең?!

**– Дәүләт Советы закон нигезендә моңа чик куя алмыймы?**

– Кешене закон нигезендә син болай сөйләш, тегеләй сөйләш дип тыеп булмый. Моннан ике ел элек Дәүләт Советында «Телләр турында»гы Законның яңа вариантын һәм яңа программа кабул иттек. Без анда 2005 елны «Дәүләт Советы Татарстанда ике дәүләт телен дә белергә тиешле һөнәр ияләренең исемлеген расларга тиеш» дип яздык. Ә исемлекне 2004 елда Татарстан Фәннәр академиясе төзеп, хөкүмәткә тапшырырга тиеш иде. Шушы исемлек расланган булса, Сез әйткән мәсьәлә бик җиңел хәл ителер иде. Безнеңчә, дәүләт хезмәтендә эшләгән кешеләр иң беренче чиратта ике телне дә белергә тиеш.

**– Безгә Мәгариф министрлыгыннан да, районнан да бөтен документлар рус телендә килә. Моны кем карарга тиеш соң?**

– Урындагы депутатлар да, хөкүмәт тә карарга тиеш. Без закон нигезендә эшләргә тиеш. Шул уңайдан, хәзер «Телләр турында»гы Законны бозган өчен административ җаваплылыкка тартырга мөмкин. Шундый кодекс кабул иттек. Сезнең соң законны бозулары турында берәр җирдә шикаять белдергәнегез бармы? Әйтик, мәктәбегездә Татарстан халыклары телләре турындагы законны бозган өчен судка йә булмаса район җитәкчеләренә, прокуратурага, хөкүмәткә язып биргәнегез бармы?

**– Алай эшләгәнебез юк, минем уйлавымча, моны депутатлар контрольдә тотарга тиешләр...**

– Бу барыбызның да эше. Әгәр бөтен кеше дә кемдер эшләргә тиеш, дип кул кушырып утырса, бездә бернәрсә дә барып чыкмаячак.

**– Татарстанда татар теле генә дәүләт теле булырга тиеш. Мәктәпләрне татар һәм рус мәктәпләренә аерырга кирәк. (Йосыпов, Казан)**

– 1990 елның 29–30 август көннәрендә, Татарстанның Дәүләт суверенлыгы турындагы декларация кабул ителгән вакытта, бу хакта бик күп бәхәсләр булды. Декларациянең берничә варианты бар иде. Берсендә «татар теле генә дәүләт теле булырга тиеш» диелсә, Штаниннар язганында рус теле генә дәүләт теле булырга тиешлекне күздә тота иде. Өченче варианты – ул вакытта әле Татарстан Югары Советы Рәисе Минтимер Шәрипович Шәймиев тарафыннан тәкъдим ителгәне – «татар һәм рус телләре икесе дә дәүләт теле булырга тиеш» дигән вариант иде.

Билгеле, әгәр татар теле генә дәүләт теле булса, бәлки, бүген тел буенча булган күп проблемаларыбыз хәл ителгән булыр иде. Әгәр рус телен генә дәүләт теле итсәк, татар теле бөтенләй юкка чыга иде. Без моңа бара алмадык. Ул вакытта безнең Конституциябез дә, Декларациябез дә кабул ителми иде. Без телебезне саклап калу өчен мөмкин булганның һәм кулдан килгәннең барысын да эшләдек. Әйтә алмыйм, бәлки, кайчандыр татар теле генә чыннан

да дәүләт теле булып калыр. Әмма цивилизацияле җәмгыятьтә берничә тел дәүләт теле булган очраклар да шактый бит... Швейцариядә дүрт дәүләт теле бар. Финляндиядә исә ике тел – фин һәм швед телләре дәүләт теле.

Бүген тел мәсьәләсе искиткеч катлаулы. 10–15 ел эчендә башкарылган эшләр күп булды. Тик анда без күбрәк санга игътибар бирдек. Ә сыйфат ягы аксады. Иң мөһиме: бүген татар телен эш өчен, дәүләт өчен, яшәү өчен кирәкле телгә әйләндерергә, аңа ихтыяҗ тудырырга кирәк.

**– Кукмара районыннан Анурбек Гобәйдуллин мин. «Татарстан» радиосы фондында 5500 сәгатьлек җыр әрәм булып ята. Аларны татар радиоларына бирергә иде.**

– Моннан өч-дүрт атна чамасы элек «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышын үткәрдек. Премьер-министрга хат язып, подвалларда череп ята торган рухи байлыгыбызны DVD дискларга күчерү өчен акча сорадык. Шулай эшләгәндә, аларны киләчәк өчен саклап калып булачак. Телевидение җитәкчелеге шушы фондларда яткан җырлардан атна саен бер концерт тапшырырга вәгъдә итте. Димәк, атна саен дүшәмбе көнне «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесендә үз фондларында сакланган халык җырларыннан тапшыру булачак. Тагын бер яңалык – һәр атнаның шимбә, якшәмбе көннәрендә «Татарстан – Яңа гасыр» радиосы фондлардагы элек язып алынган спектакльләрне тыңлаучылар игътибарына тәкъдим итәчәк. Гомумән, озакламый «Татарстан – Яңа гасыр» радиосы гел татарча гына сөйли башлаячак. Элек алар чиратлап – бер сәгать татарча, бер сәгать русча сөйли иделәр. Хәзер бары тик соңгы хәбәрләр, ягъни яңалыклар гына ике телдә булачак.

**– Разил әфәнде, Волгоград урамы чатында уен автоматлары, бер караганда, юкка чыга, икенче караганда, тагын пәйда була. Кайчан бөтенләй алалар соң инде аларны? Үзәккә үттеләр бит. (Сафиуллиннар, Казан)**

– Татарстан Дәүләт Советында уен автоматлары буенча кабул ителгән законда аларның хуҗаларына ярты ел эчендә бу «баганалар»ны билгеләнгән махсус урыннарга күчерергә кушылды. Моның өчен аларга ике урын: берсе – Кама Аланы, икенчесе – яңа ипподром территориясе тәкъдим ителде. Бу вакытның инде ике ае үтте, димәк, калган дүрт ай эчендә алар алыначак.

**– Россиядә рус халкы турында канун кабул ителде, ә Татарстанда нишләп татарлар турында шундый закон юк?**

– Дөрес, Россиядә андый закон проекты эшләнгән иде. Без Дәүләт Думасы аны тикшергән парламент тыңлауларында булдык. Анда Индус Таһиров белән чыгыш та ясадык һәм бик кызык бер алым кулландык – Мәскәүдән безгә җибәрелгән әлеге проектның «рус» дип язылган җирен «татар» дип алыштырдык та, «татар халкы турында Россия законы» дип Дәүләт Думасына юлладык. Рус халкы турында закон кабул ителә икән, Россиядә татар халкы икенче урында тора, шуңа күрә икенче закон татар халкы турында булырга тиеш дидек.

Гомумән, Россиядә йөздән артык милләт яши икән, шул күләмдә закон да булырга тиеш дип куйдык мәсьәләне. Чөнки Конституциядә «бөтен халыклар да тигез» диелгән. Шуннан соң бу мәсьәлә үзеннән-үзе тынды, закон кабул ителмәде. Аның урынына рус теленең дәүләт теле булуы турындагы закон кабул ителде. Мин үзем аны кирәкле закон дип санамыйм. Чөнки Россия халыклары телләре турындагы закон бар. Анда рус теленә бер бүлек багышланган.

Безнең исә татар теленә мөмкинлекләр тудыра алырдай «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законыбыз бар. Әгәр без аны үтәп бара алсак, бик күп мәсьәләләребез хәл ителер иде. Кызганыч, бүгенге көндә мин аны илле-алтмыш процентка гына үтәлә дип саныйм. Тагын бер проблема бар – «Телләр турында»гы Закон бер Татарстанда гына эшли. Ә милләттәшләребезнең күпчелеге Татарстаннан читтә яши. Шуңа күрә киләчәктә татар халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аның милли мәдәниятен, мәгарифен үстерү турында Россия күләмендә дәүләт программасы кабул итүгә ирешергә кирәк. Хөкүмәтебез Россия хөкүмәте белән шул хакта сүз алып барырга тиеш. Әмма бу бик катлаулы мәсьәлә.

**– Республикада китапханәләр, клублар, мәктәпләр бер-бер артлы ябыла барганда, спорт клубларына миллионнарча долларлар бүлеп бирү дөрес эшме? (Мөдәррис Вәлиев, Арча)**

– Китапханәләр, клублар бер-бер артлы ябыла дип әйтә алмыйм. Мин Татарстан Югары Советында депутат булып эшли башлаганда республикада ничә китапханә булса, ул бүген дә шул чамада. Дөрес, 20–30 лап китапханә ябылып алды, ләкин ачылганнары да байтак. Бүген Татарстан Мәдәният министрлыгы системасында – 1639, ә Мәгариф министрлыгы системасында ике меңгә якын – барлыгы дүрт мең чамасы китапханә бар. Биредә сүз сан турында түгел, сыйфат турында барырга тиеш. Аларның фондлары, биналары нинди хәлдә, белгечләр таләпләргә җавап бирерлекме?
Китап алу өчен ел буена бер тиен дә акча бирелмәгән районнар бар әле бездә. Менә проблема нәрсәдә. Газеталарга язылу өчен дә акча бик аз тама. Минем хөкүмәт белән әлегә уртак тел таба алмаган бер хыялым бар – ни өчен 1639 китапханәгә Татарстанда чыккан бөтен газета-журналларны, берәрне генә булса да, яздыра алмыйбыз? Әгәр халкыбызның рухи тормышы турында уйлыйбыз икән, моны киләчәктә, һичшиксез, эшләргә тиешбез.
Ә инде клубларның хәлен мин дә әйбәт дип әйтә алмыйм. Йөзләгән клубларыбыз бүген ярым җимерек хәлдә. Җирле үзидарә карамагына калгач, үзләрен тотарга акчалары да җитмәячәк. Шуңа күрә без аларга республика бюджетыннан ярдәм фонды булдырырга һәм, шушы күчеш чорында булса да, аларга ярдәм итәргә тиешбез.
Спорт мәсьәләсенә килгәндә, мин аңа һич тә каршы түгел. Әмма кемнәндер сатып алынган спорт шулай ук спорт түгел. Мондый спортны мин спортчы отты дип түгел, акча отты дип саныйм. Бездә акча ота. Әйтик, безгә Бразилиядән яисә башка илдән килеп уйныйлар икән, анда безнең акчабыз уйный һәм акча ота. Үзебезнең Әтнә, Арча, Саба, Сарман яки Чаллы, Түбән Камадан чыккан егетләр уйнап, алар отса, менә бу республика отуы булыр иде. Мин шул хакта хыялланам. Әгәр киләчәктә һәр мәктәптә хоккей тартмалары, волейбол, футбол командалары булса, тренерлар билгеләнсә, аларга яшьләр белән эшләргә шартлар тудырылса, мондый спортны мин ике куллап хуплыйм.
**– «Ватаным Татарстан» газетасының 7 май санында басылган «Алда –Мәскәү, артта – упкын» (Зиннур Хөснияр) дигән язмага мөнәсәбәтегез нинди? Ни өчен татар балаларына чит җирләрдә бастырылган дәреслекләр бирәләр һәм шуның буенча укыталар? (Расих Җәләл, Казан)**
– Зиннур Хөснияр белән тулысынча килешәм. Бик ачынып язган ул. Әле күптән түгел генә без Дәүләт Советында Россиянең мәгариф законына үзгәрешләр кертү турындагы яңа закон проектын карадык. Анда стабиль дәреслекләр турында сүз бара. Бер фән буенча бер дәреслек сайлап алына. Бер яктан караганда, әйбәт тә шикелле бу. Әмма аның буенча, мәсәлән, Оренбург өлкәсендәге мәктәпләрдә укучы татар балаларының милли ихтыяҗлары канәгатьләндереләме икән? Стабиль булгач, бөтенесенә бер шаблон була бит инде ул. Бертөрле дәреслек кенә бөтен халыкларның мәгариф өлкәсендәге мәнфәгатьләрен һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Бездә укучыларга да, укытучыларга да төрлечә фикер йөртү мөмкинлеге бирелергә тиеш. Әмма ул әхлак кысаларында, безнең милли дәүләт кысаларында булырга тиеш.
**– Татар һәм рус телләре дәүләт теле булгач, һәр ике телдә дә рус һәм татар баласын бер үк сәгать санынча укыту кирәк. Мәгариф министрлыгы нигә бу мәсьәлә белән шөгыльләнми? (Нәбиулла Хәкимҗанов, Арча)**
– «Татар һәм рус телләре – ике дәүләт теле бертигез күләмдә укытылырга тиеш» дип, безнең телләр һәм мәгариф турындагы законның икесендә дә язылган. Дөрес, монда Мәгариф министрлыгының бераз гына иркенәеп киткән урыннары бар. Без аңа кайвакыт бик каршы да килмибез. Әйтик, татар гимназиясе икән – анда татар телен күбрәк укытуга без каршы түгел. Рус гимназиясе икән, анда шулай ук бер-ике сәгать рус телен артык укытсыннар. Ә инде гомуми урта мәктәпләрдә бу дәресләр тигез укытылырга тиеш.
Бездә соңгы вакытларда дәүләт телләрен тигез укыту һәм сыйфатлы итеп өйрәтү буенча шактый чатаклыклар була башлады. Балалар бакчаларында татар теле группалары кими, мәктәпләрдә татар класслары азая. Акрынлап кирегә китү бара. Мәгариф министрлыгының әле бу өлкәдә эшне җанландырасы бар.

**– Клубта эшләүчеләргә стаж буенча өстәмә түләү турында сүз булган иде. Тик әлегә нигәдер түләү күренми, ул булачакмы? (Айметов, мәдәният хезмәткәре, Чүпрәле. Радик Әминов, Балтач)**

– Клуб хезмәткәрләренә генә түгел, без Татарстандагы мәдәният хезмәткәрләренә озак еллар эшләгән өчен өстәмә түләү кертү мәсьәләсен инде ничә ел рәттән күтәреп киләбез. Тырыша торгач, без аны 1998 елны китапханәләр турындагы законга кертә алдык. Республикадагы дүрт меңгә якын китапханәче 2000 елдан башлап өстәмә түләү ала. Ә инде клуб һәм архив, музей, кино, театр хезмәткәрләренә бүгенгә әле мондый түләү юк. Ул закон проекты күптән эшләнде һәм беренче укылышта кабул да ителде. Хәзер хөкүмәт белән бу хакта аңлашу чоры бара. Без 2006 елгы бюджетка төзәтмә керттек, анда мәдәният хезмәткәрләренә грантлар бирү каралган. Ә моның өчен 50 миллион сум акча бүлеп бирелү күздә тотыла. Өстәмә түләү дә булса, грант та бирелсә, эшләр шактый уңайланачак.

**– «Евроислам» нәрсә ул? Һәм ул нәрсәне пропагандалый? (Вазыйх әфәнде, Чирмешән районы)**

– Соңгы елларда «Евроислам» дигән агым турында шактый күп сөйлиләр. Аны XX гасыр башындагы җәдитчелек белән янәшә куеп карыйлар. Чөнки җәдитчелектә бүгенге «Евроислам»да күтәрелә торган мәсьәләләр – исламны җирле шартларга җайлаштыру күтәрелгән булган. Бу бик катлаулы мәсьәлә. Мин моны якларга да, аннан баш тартырга да җөрьәт итә алмыйм. Чөнки Татарстандагы ислам Үзбәкстан, Әфганстан, Төркиядәгедән аерыла. Кеше, телиме, юкмы, барыбер үзе булып кала, һәм дин барыбер аның күңеле аша үткәч, күпмедер дәрәҗәдә үзгәрмичә булдыра алмый. Чөнки ислам ул күңелдә булырга тиеш.

**– Латин графикасына күчү турында сөйләүдән тындыгыз. Күчмибезмени инде? (Гарифҗан абыегыз, Казан)**

– Тынганыбыз юк. Бу мәсьәлә Россиянең Конституция суды тарафыннан каралды. Алар латинга күчүне туктатырга тиешле закон кабул иттеләр. Әмма бүгенгә кадәр прокурорның протесты булса да, латин язуына кире кайту турындагы законны гамәлдән чыгарганыбыз юк. Чөнки Россия Конституциясенең 68, 71, 72, 73 нче статьялары нигезендә бу мәсьәлә безнең вәкаләттә. 68 нче статьяда «милли республикаларның үз дәүләт телләре бар, алар дәүләт телләрен үзләре кабул итә алалар» дип язылган. Хәрефсез тел була алмый бит. Телне дә хәрефтән аерып булмый. Хәрефеңне дә алыштыра алмагач, нинди тел үстерү инде?! Димәк, безне латинга күчүне тыя торган Конституция судының карары турыдан-туры Россия Конституциясенә дә һәм халыкара хокук нормаларына да каршы килә. Без моның белән беркайчан да килешмәячәкбез, киләчәктә, һичшиксез, бу мәсьәләгә кире әйләнеп кайтырбыз дип уйлыйм.

**– Оныгымны урнаштырырга татар балалар бакчасы юк. Шул да булдымы дәүләт теле? (Лениза Гәрәева, Казан)**

– Балалар бакчасында хәлләр чыннан да әйбәт түгел. Ни өчен, һәр кварталда ук булмаса да, һәр районда берничә татар балалар бакчасы булмаска тиеш? Нишләп әле алар иң әйбәтләре түгел, ә иң начарлары булырга тиеш? Без байтак балалар бакчаларында булдык. Аларда хәтта татарча хәрефле шакмаклар да юк. Нибары таушалып беткән ике-өч китаплары гына бар. Гаеп мәгариф системасында һәм ата-аналарда. Еш кына бала тәрбиячесе белән татарча сөйләшә, ә әти-әниләр аны русча каршы ала. Шулай булгач, кемгә үпкәләргә?

**– Кайчан татар милләтеннән булган түрәләр татарча сөйләшә башларлар икән? Берәр тапшыруга чакыра башласаң, матбугат үзәге хезмәткәрләре: «Ул бит татарча белми, рус телле тапшырулар оештырыгыз», – диләр. (Телевидение журналисты)**

– Без быелгы бюджеттан һәр министрлыкка хезмәткәрләрен татарча өйрәтү өчен акча бүлеп бирдек. Аларның кайберләрендә татар телен өйрәнү курслары бар. Ә кайберләре оештырырга тиешләр һәм әлеге дә баягы «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законны гамәлгә ашыру программасында әйтелгән һөнәр исемлеге булырга тиеш. Ике дәүләт телен дә белергә тиешле һөнәр исемлеген раслагач, дәүләт хезмәткәрләре мәҗбүри рәвештә ике дәүләт телен дә белергә тиеш булгач кына, бу мәсьәлә хәл ителергә мөмкин дип саныйм. Президентыбыз

кирәк вакытта ике телдә дә сөйли бит. Дәүләт Советы Рәисе дә татарча сөйли. Ә ни өчен башкалар өйрәнмәскә тиеш?

**– Улым быел мәктәпне тәмамлый, Бердәм Дәүләт Имтиханы тапшырырга тиеш. Анда милли компонент күздә тотылмаган, шуңа күрә баламның белеме дөрес бәяләнмәс дип куркам. Аннан баш тартып булмыймы соң? (Венера Сыраева, Казан)**

– Бу имтихан турында бәхәсләр күп булды. Компьютер каршына утыртып кына тестлар буенча, минемчә, баланың белеме тулысынча ачыкланмый. Балаларны төрле яктан сорау биреп сынап карарга кирәк. Мин тере укучының тере укытучыга күзгә-күз карап имтихан тапшыруын иң гадел алым дип саныйм. Бүген татар телендә Бердәм Дәүләт Имтиханы тапшырырга да була. Әмма мондый укучы бары тик Татарстан югары уку йортларына гына керә ала. Бу инде кеше хокукларын чикләү була.

Гомумән, мин бу имтиханга шикләнеп карыйм. Киләчәктә, бәлки, аңа үзгәрешләр кертелер.

**– Мәктәпләргә православие дине дәресләрен кертү турында сүз бара. Әмма моңа Россиянең генераль прокуроры урынбасары дәрәҗәсендәге кешеләр дә каршы. Бу хакта Сез нәрсә уйлыйсыз? (Рәсимә Сабирова, Казан)**

– Мин дә моңа каршы. Дәүләт Советында бу хактагы фикеребезне Россия җитәкчелегенә җибәрдек. Әгәр без дөньяви дәүләт икән – мәктәпләребез дә дөньяви булырга тиеш. Монда, танышу өчен, дин тарихын кертергә мөмкин, әхлак дәресләре дә кертергә була (ул, нигездә, дин кануннарына корылган). Ә инде дини дәресләр факультатив рәвештә, дәрестән соң мәктәптәме яисә мәчетләрдәме укытылырга мөмкин. Мәктәпләрдә поплар, муллалар укытырга тиеш түгел дип саныйм. Әхлак дәресләре укытылган очракта да аны дөньяви укытучылар укытырга тиеш. Әгәр Россия ислам университетында шундый укытучылар әзерләнсә, әхлак дәресләрен укытучыларга кытлык булмаячак.

*Әңгәмәдәш Роза Рәхмәтуллина*
*2006*

# ДӨНЬЯ ҮЗГӘРӘ – ИМАН ҮЗГӘРМИ

**Марсель Галиев.** Разил әфәнде, синең яшьлектә язган бер шигыреңдәге юллар минем генә түгел, бик күпләрнең хәтерендә калгандыр дип уйлыйм:

Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм, –

дип тәмамлана иде ул шигырь. 60 яшь тулган елында гомер үреңнән артка карап уйлангач, тәэсирләр ничегрәк: дөньяны үзгәртә алдыңмы, әллә гел үзең генә үзгәреп беттеңме?

**Разил Вәлиев.** Син әйткән шигырь ул, Марсель туган, инде күптән язылды. Миңа ул вакытта 20 яшь чамасы иде. Минем һич кенә дә үземнең үзгәрәсем килми иде, билгеле. Бүген язсам, мин аны, ихтимал, башкачарак язар идем. Ләкин яшьлектә шулай яңакка суккан кебек әйтелүе дә табигыйдер.

Ә дөнья, минемчә, чынлап та үзгәрде. Күреп торабыз: 1967 елдагы дөнья түгел хәзер. Безнең уйларыбыз да, хисләребез дә, мөмкинлекләребез дә бөтенләй бүтән. Минемчә, дөньяның шулай үзгәрүендә синең дә, минем дә, башкаларның да аз гына булса да өлеше бар. Димәк, минем ул чакта әйткән сүзләрем күпмедер дәрәҗәдә чынга ашкан.

Билгеле, үзем дә үзгәрдем. Дөнья үзгәрү бит ул ниндидер абстракт дөньяның үзгәрүе генә түгел, кешеләрнең дә үзгәрүе. Мин үзгәргәнмен, башкалар үзгәргән икән, димәк, дөнья үзгәрә.

**М. Г.** Без 1969 елны Казан университетына укырга кергән идек. Шунда ишетәбез: Разил Вәлиев дигән яшь шагыйрь Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый икән. Ә Әдәбият институты башка бер илдә дә юк, Мәскәүдә генә иде бит. Без чын мәгънәсендә көнләшү һәм кызыгу белән: «Кайчан күрербез икән аны?» – дип уйлап та куйган идек. Чөнки ул чорда Мәскәү шаулый иде, кайный иде бит. Мәскәү дигәч, без инде Евтушенко, Вознесенский, Белла Әхмәдуллина, Булат Окуджаваларны күз алдына китерә идек, һәм син менә шулар янәшәсендә тоела идең. Хәтерлим әле, шул вакытта безнең бик талантлы шагыйребез Эдуард Мостафин Мәскәүдән кайтып төште. «Разил Вәлиев шундый шәп цикл язган», – дип, «Авылда туй» дигән шигыреңнең истә калдырган юлларын кат-кат укып-кабатлап йөрде. Минем хәтердә шулай калган:

Урамнарны иңләп шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны –
Бәйрәм керсен татар өенә! –

дип тәмамлана ул шигырь. Мәскәүдәге Әдәбият институты сиңа ниләр бирде?

**Р. В.** Мин Түбән Камада урта мәктәптә укыган вакытта ук Мәскәүгә барырга атлыгып тора идем, минем күңел Мәскәүдә иде. Чөнки ул вакытта шигъриятнең шулкадәр дә бәһале чагы. Әдәбият институтында Белла Әхмәдуллина, Евгений Евтушенколар укый, мин алар турында ишетеп торам. Гомумән, Мәскәү ул вакытта шаулап-гөрләп тора, Казан исә шактый ук тыныч иде. Ләкин мин Түбән Камадан, авылдан чыгып, туры Мәскәүгә барып керергә җөрьәт итмәдем. Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый башладым. 1 нче курсны тәмамлагач, Илдар Юзеев тәкъдиме белән, үземнең шигырьләремне, урысчага юлга-юл тәрҗемә итеп, Мәскәүгә җибәрдем. Иҗади конкурстан үттем. Бу конкурс шактый зур була икән – бер урынга 200 кеше. Аны үткәч, мин инде үземне укырга кергән дип санадым. Әмма имтихан бирәсе бар, анысын мин, ахрысы, уйлап бетермәгәнмендер, һәм, университетны ташлап диярлек, Мәскәүгә китеп бардым. Чыннан да, ялгышмаганмын, Мәскәү бөтенләй бүтән дөнья икән. Бер үк социалистик ил булса да, бер үк законнар-кагыйдәләр булса да, анда инде демократия җилләре исә, Көнбатыштан килгән ирекле мохит сизелә башлаган иде.

Без Әдәбият институтында нибары 125 кеше укыдык. 5 курска, көндезге укуга бары тик 125 студент. Болар һәммәсе дә йә шагыйрь, йә драматург, йә прозаик, йә тәнкыйтьче, йә әдәбият белгече, йә тәрҗемәче. Һәм шунысы кызык: безнең профессорларыбыз да ни җитте профессорлар, ни җитте укытучылар гына түгел иде. Мин анда бөтен җаным-тәнем белән бирелеп укыдым. Билгеле, барысы да җиңел генә бармады. Ул заманда безнең белән шагыйрь Николай Рубцов укыды, аның белән күрше бүлмәләрдә яшәдек. Юрий Кузнецов белән дә без бик дуслар идек, көне-төне бергә булдык. Юрий Кузнецов үзе урысның азау ярган милләтчесе, мин үзем – күпмедер дәрәҗәдә милләтпәрвәр, татар дип җан атып йөрим, һәм шушы ике кеше – берсе урыс милләтчесе, берсе татар милләтчесе – шулкадәр дус яшибез. Тирә-юньдәгеләр шакката: сез, ике халыкның милләтчеләре, бер-берегезне күралмаска тиеш, диләр. Ә без көннәр, төннәр буе бергә. Моның хикмәте шунда: ул да үз халкын ярата, мин дә үз халкымны яратам. Башка халыкка карата бездә нәфрәт юк. Шушы нәрсә безне берләштергәндер.
1 нче курста СССР тарихыннан лекция тыңлап утырабыз. Лекцияне Сталинград шәһәре партия комитетының элекке идеология секретаре Водолагин дигән профессор укый. Ватан сугышы чорына килеп җитте дә бу, кырым татарлары турында сөйли башлады: «Сатлык җаннар, тегеләй иткәннәр, болай иткәннәр», – ди. Минем җаным түзмәде: «Мин моннан ары сезнең лекцияне тыңлый алмыйм. Сез татарлар турында бик начар сүзләр сөйлисез», – дидем дә урынымнан торып чыгып киттем. Чыктым да коридорда басып торам. «Дөрес эшләдем микән, юк микән?» – дим. Күңелгә шик тә керә. Әле бит Советлар илендә яшибез. Моның өчен институттан да куарга мөмкиннәр. Әмма минем арттан дустым, бурят егете Нимбуев килеп чыкты. Без аның белән бергә утыра идек. Аның артыннан калмык егете Манджиев күренде. Алар артыннан монгол егетләре чыкты, аннары – поляклар, берничә негр... Группадагы 25 кешенең 10 нан артыгы минем арттан иярде. Бу хәл ректорга да барып иреште, мине аның янына чакырдылар. Әмма ул-бу булмады, милләтара гауга чыгудан курыкканнардыр инде, бәлки. Водолагин да бераз «юашланды».
Хәзер күз алдына китерәм, әгәр дә шушы ук сүзләрне Казан дәүләт университетында, туган шәһәребездә әйткән булсам, мине нишләтерләр иде икән? Минем арттан ияреп чыгарлар идеме? Әлеге сораулар мине элегрәк тә бимазалады, хәзер дә бимазалый. Әмма ләкин дөньялар шактый үзгәрде, хәзер безнең халык та башын азмы-күпме югары күтәреп яши башлады, һәм моңа, һичшиксез, безнең башка халыклардан, башка илләрдән өйрәнүебез тәэсир итә торгандыр.
Мин Мәскәүдә укыган елларымда үземне, халкымны, әдәбиятыбызны, сәнгатебезне ихтирам итәргә өйрәндем. Мәскәү минем өчен бик зур мәктәп булды.
**М. Г.** Гадәттә, кеше җитди проза әсәрен 30 яшьтән соң гына яза ала, диләр. Син, беркем көтмәгәндә, бөтенебез дә шигырь язып йөргәндә, «Эт кояшы» дигән повесть язып кайттың Мәскәүдән. Без шаккатып калдык, кульязмаң кулдан-кулга йөрде. Ул чор өчен шактый кыю әсәр иде, чөнки цензура бик көчле заман иде бит. Аны Аяз Гыйләҗев күтәреп, мактап чыкты. Ләкин аны берәү дә үз вакытында бастырып чыгара алмады. Кыймадылар. Аның исеме үк куркыныч булган бит. Шул сәер исеме куркытмады микән әле редакторларны? Ул әсәрнең үз вакытында басылмавын ничегрәк аңлатыр идең?
**Р. В.** Мин, үпкәләдем дип әйтмим, рәнҗедем ул вакытта. Чөнки ул чакта ук азмы-күпме әдәби тәҗрибәбез бар бит инде. Бигрәк тә Аяз Гыйләҗев шулкадәр матур сүзләр әйткәннән соң. Ул вакыттагы беркатлылыгым белән, һичшиксез, бу әсәрне бастырып чыгарырга тиешләр дип уйлаган идем.
Мин Казанга канатланып кайттым. Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең киңәйтелгән утырышында шул повестем турында сүз алып бардылар. Шунда мин үземне ниндидер мәхкәмәдә утырган шикелле хис иттем. Мине ниндидер гаепле эш эшләгән шикелле бәялиләр: «Кара әсәр язган, совет чынбарлыгын дөрес тасвирламаган», – диләр.
Шуннан соң мин, бәлки, бөтенләй проза язмаскадыр дип тә уйлый башладым. Чөнки шигырьдәге фикер эчкә яшеренгән була, аны кайбер тәнкыйтьчеләребез кайвакыт аңлап та бетерми. Аннары: «Мин алай әйтергә теләмәдем, башка нәрсә әйтергә теләдем», – дип тә котылырга мөмкин. Шигырь ул эзоп теле белән языла. Хәзерге көндә мин, ни өчен ул әсәрне яздым, дигән сорауга җавап бирә алмыйм. Бәлки, дөнья әдәбияты тәэсире дә булгандыр. Мәскәүдә мин бик күп

укыдым. Достоевский белән дә «женләндем», дөнья әдәбияты классикларын да өлешчә «сөреп чыктым». Әмма иң беренче тәэсир Мәскәүдәге мохит үзе иде. Безнең тулай торак, безнең институт аерым бер дәүләт шикелле иде. Ирекле фикерләр «аза» башлагач, бу институтны бит заманында ябып та торганнар. Без килер алдыннан гына ул яңадан ачылган иде. Евтушенко, Белла Әхмәдуллиналар анда беренче студентлар булды.

**М. Г.** Син: «Бүтән проза язмаска дип уйлап куйдым», – дип әйттең дә, ләкин аннан соң бит берничә әсәр язып ташладың. «Яшисе килә» повестең Муса Җәлил бүләгенә дә лаек булды. Күптән түгел генә Язучылар берлеге идарәсе «Иске сәгать дөрес йөри» дигән китабыңны Тукай премиясенә тәкъдим итте. Китапка кергән «Мирас» романында синең бабаңнар чоры, автобиографик чалымнар күренеп китә шикелле. Син бу романда үзеңнең бик таза, булдыклы нәселең турында барысын да әйтеп бетерә алдыңмы?

**Р. В.** Мине бала чактан шулай тәрбияләделәр – бөтен нәрсәне дә белергә тиешсең, дип. Бабай мине балта тотарга, пыяла кисәргә, тимерчелек һөнәренә, мотоцикл, велосипед төзәтергә, тәгәрмәч бөгәргә, чаңгы ясарга, кулга чалгы тотып печән чабарга өйрәтте. Әткәйдән, ул колхоз рәисе иде, кешеләр белән аралашырга, әйткән сүздә торырга өйрәндем. Әнкәй минем бик җор телле, шигъри җанлы кеше иде. Ул мине әдәбият-сәнгатькә якынайткандыр дип уйлыйм.

Казанга укырга килгәч, безгә тулай торактан урын бирмәделәр. Мин Федосеев урамындагы Вәли бабайның өй артындагы иске бер сараена тәрәзә куеп, идән түшәп, түшәм тезеп, мич чыгарып яши башладым. Без, авыл балалары, күбебез шулай. Дөрес, кайбер шагыйрьләр лампочка да бора белми, андыйлар да бар.

Кыскасы, мин тик торырга яратмыйм. Шигырьне бит гел язып утырып булмый. Шигырь артыннан йөреп, куып тотып була торган әйбер түгел. Ул күңелгә үзе очып килеп керергә тиештер дип аңлыйм мин. Ә прозаны утырып язарга кирәк. Әгәр минем күңелгә шигырь килми икән, мин бит аны көтеп утырырга тиеш түгел. Минем фикерем бар, уем бар, дөньядагы хәлләрне кәгазьгә төшерәсем килә. Аннан соң драматургия белән дә бераз гына мавыгып алдым. Дүрт-биш пьеса яздым, икесе куелды инде, калганнары да, бәлки, сәхнәгә менәр дип өметләнәм.

**М. Г.** Әйе, күп һөнәрлелек синең әдәби эшчәнлегеңдә дә чагыла. Әле җыр жанры турында әйтми калдырдың. Безнең яшьтәшләр арасыннан син беренче булып җыр өчен махсус шигырьләр яза башладың. Ул вакытта Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрнең менә дигән җырлары бар иде. Бөек композиторлар плеядасы яшәгән чорда алар инде Олимп тавында иде. Син Мәскәүдә укыган чагында, ничек йөрәгең җитеп, халык көенә шигырь язып ташладың икән?

**Р. В.** Аның тамырлары тирәндәрәктер, Марсель. Авылдан ук килә торгандыр. Әйткәнемчә, минем әнкәй шигырь ярата, бәетләр чыгара иде. Ул һәрвакыт авыз эченнән генә көйләп йөрде, кычкырып җырлаганы булмады. Минем апалар да җырга-моңга хирыс иде. Разилә апа гармунда менә дигән итеп уйный иде, ул хәзер мәрхүмә инде. Энекәшем Рәмзил баянда бер дигән уйный, бер дигән җырлый. Авылда вакытта ук мин классташым, партадашым Алмаз Хәмзин белән концертлар, спектакльләр куеп йөри идем. Түбән Камада урта мәктәптә укый башлагач, менә дигән хор оешты, һәм мин шул хор солистларының берсе идем. Димәк, ул вакытта ук инде җырга тартылу булган.

Мине иң беренче кулыма каләм тоттырып диярлек җыр яздыручы кеше Илһам Шакиров булды. Ул хакта минем язганым да, сөйләгәнем дә бар.

Җыр – халык күңеленә иң тиз барып җитә торган, иң үтемле жанр. Ул элек тә шулай булган, бүген дә шулай. Ләкин җыр халыкның зәвыгын да бозарга мөмкин. Хәзерге көндә безнең бик күп җырларыбыз халыкка тискәре йогынты ясый. Мин болар өчен бик борчылам. Әмма моны туктатып та булмый. Туктату кирәк тә түгелдер, бәлки. Ул хакта анык фикер әйтергә кирәктер. Хәзер без нишләптер мондый җырларга тиешле бәя биреп, үз сүзебезне әйтә алмыйбыз. Мин монда үзебезне дә гаепле саныйм. Чөнки аларга цензура куеп булмый. Ләкин матбугат, радио-телевидение аша без аларга тиешле бәяне бирергә тиешбез. Әгәр дә 5–10 ел буена бернинди мәгънәсе, көе-моңы, рифмасы булмаган җырлар җырлыйлар икән, халкыбызның зәвыгы бөтенләй бозылып бетәргә һәм ул җыр шушындый булырга тиеш дип уйлый башларга мөмкин.

**М. Г.** 1970–1980 елларда әдәбиятта Җир шары, зурлык белән мавыгу чире бар иде. Берәү әйткән дә бит: «Җир шарын кайгырту бик җиңел, ә менә янәшәндәге кешенең хәленә керү, аның мәнфәгатьләрен кайгырту авыррак», – дигән. Шул чорда син, ярсып, сәхнәдән: «Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген», – дип шигырь укыганда, кайберәүләр елмаеп та куя иде.
Синең үз тормыш юлыңны күздән кичереп, «дөньяны үзгәртәм мин» дигән сүзләреңне мин болайрак аңлыйм. Син, Мәскәүдән кайтып, «Ялкын» журналына эшкә кердең. «Ялкын»да яңа рубрикалар ачу, аның төсен, кыяфәтен үзгәртү синнән торды бит. Бу инде үзеңнең буең җиткән дөньяны үзгәртү дигән сүз. Аннан соң Чаллыга китеп, андагы Язучылар оешмасының җитәкчесе булганнан соң, бу шәһәр кайнап торды – Мәскәүдән язучылар чакырылып, зур җыелышлар, семинарлар үткәрелде. Аннары Казанга кайтып Ленин китапханәсенә директор булып килгәч, аның исемен һәм җисемен үзгәртү зур вакыйга булды.
Ә инде парламенттагы эшчәнлегең турында барыбыз да яхшы беләбез. Парламент эшчәнлеге синең иҗатка шактый зур комачаулык та ясыйдыр шикелле. Шул ук вакытта, миңа калса, син идарә итү үзәгендә кайнап, язасы әсәреңә ниндидер түл дә җыеп киләсең кебек.
**Р. В.** Марсель, соравыңның башыннан ук җавап бирә башлыйм әле. Әйттең бит әле: «Заманында без барыбыз да авырып алдык, Җир шарының язмышын кайгырттык», – дип. Мин дә, билгеле, бу авырудан читтә кала калмадым.

Җир шарына утырып тәмәке төрдем,
Җир шарына басып сүндердем, –

дип яздым мин дә. Бөек алман шагыйре Һетеның бер сүзе бар бит: «Һәр кеше иң беренче чиратта үз кишәрлеген эшкәртергә тиеш», – дигән ул. Дөньяны үзгәртү дә үз кишәрлегеңне эшкәртүдән башланырга тиештер. Үзең эшләгән, үзең яшәгән мохиттә син нәрсә майтара аласың? Әнә шунда әкрен-әкрен эшең бара икән, ул үзеннән-үзе зур масштабка әйләнә.
Хәзерге көндә парламентта эшләүгә килгәндә, кайберәүләр аңа, бәлки, тискәре бәя бирәдер. Бездә бит бер-береңнең хезмәтен, уңышын күрү артык популяр түгел. Әгәр язучы кеше парламентка кергән икән, аңа шикләнеп карау да бардыр инде, аңа таләпләр дә башкача куела торгандыр. Язучы, иҗат кешесе сәясәттән читтә булырга тиеш дип әйтәбез бит. Мин болар белән килешәм. Бер караганда, мин китапханәдә эшләп яисә редакциядә утырып, шигырьләр язып кына да яши алыр идем. Ә парламентта эшләү минем теләктән генә торган нәрсә булмагандыр. Алга таба сөйләнәчәк вакыйгалар китапханәдә эшләгәндә булды.
Мин китапханәгә килеп кергәндә, аның юеш подвалларында йөзәр меңләгән китап череп, күгәреп ята, зур уку залының түбәсе җимерелеп төшкән, җылыту батареяларыннан су ага иде. Ул подвалларда яткан китаплар – татар халкының иң изге, иң кадерле мирасы. Ничек инде җаның түзеп шуларны суда яткырырга мөмкин?! Мин теге кабинетка кереп карыйм, бу җитәкченең ишеген шакыйм, хатлар язып җибәрәм. Хәтта урамга чыгып, демонстрация да үткәрдек, экономик забастовка да игълан иттек. Ул забастовка бик кызык булды. «Әгәр дә безнең китапханәгә яңа бина бирмисез икән, без барыбер эшләячәкбез, әмма хезмәт хакын алудан баш тартачакбыз», – дидек. Мондый забастовканың Җир шарында булганы юк икән. Ничек инде кеше эшли, әмма хезмәт хакы алмый? Һәм кем алмый бит әле – китапханәче, аена 60, 70, 80, 90 сум акча эшләүче кеше алмый. Бездән башта көлделәр. «Алмагыз, бик яхшы булыр, акча янга калыр», – диделәр. Алай түгел икән шул, без аны башта ук уйлаган идек. Чит илләрдән корреспондентлар килә башлады. Нинди халык бу – эшли, әмма хезмәт хакы алмый? Ни өчен? Чөнки китаплар череп ята. Бу хәл күңеле туң җитәкчеләргә дә тәэсир итмичә калмады. Гариф Ахунов әйтмешли, черәшә торгач, Карл Маркс урамындагы комсомол өлкә комитеты бинасын алдык. Ләкин моның белән генә чикләнеп калып булмый иде. Чөнки мәдәниятнең проблемалары хәттин ашкан иде шул. Мин шул вакытта аңлый башладым: мондый юллар белән генә – урамга чыгып, хатлар язып, таләп итеп кенә – мәсьәләне хәл итеп булмый, монда башка юл кирәк. Уйлый торгач, мин парламентка сайлану зарурлыгын аңладым.
Билгеле, парламентта да бөтен теләкләрне дә тормышка ашырып булмагандыр. Әмма без анда шактый мәсьәләләрне хәл итүгә ирештек. Әгәр дә парламентта әдәбият-сәнгать әһелләре,

галимнәр эшләмәсә, безнең «Телләр турында»гы Законыбыз булмый иде. Бу законның хәзерге көндә эшләве-эшләмәве башка мәсьәлә. Әмма безнең республикада бүген меңнән артык татар мәктәбе бар икән, яңа газета-журналларыбыз чыга башлаган икән, яңа телевидение ачылган икән, гимназияләр, мәдрәсәләр бар икән – монда шушы законның һәм парламенттагы әдәбият-сәнгать әһелләренең күпмедер дәрәҗәдә өлеше бар. Әлбәттә, беренче чиратта президентның, хөкүмәт җитәкчеләренең өлеше зур. Әгәр дә халык 90 нчы елларда дәррәү кубып урамнарга чыкмаса, безгә дә бу эшләрне эшләү мөмкин булмас иде. Ул вакытта без халык белән бергә бардык, халык безнең белән бергә барды.
Ә инде әсәр язу дигәннән, бу, чыннан да, кызык сорау. Безнең язучыларыбыз бөтенесе дә диярлек авылдан чыккан. Барыбызның да биографияләре бертөрлерәк. Авылда тудык, каз көтеп, ат көтеп, чирәмнәрдә тәгәрәп үстек, мәктәптә укыдык, аннары Казанга килдек, югары уку йортында укыдык, күбебез редакцияләрдә эшләде. Безнең язган әсәрләребез дә шушы кысадан артык читкә чыга алмый. Күпмедер чыгулар була торгандыр, әмма, әйткәнемчә, кеше үзе белгәнне генә яза ала бит.
Соңгы вакытта вазгыять бераз үзгәрде – биографияләребез дә төрлеләнә, байый башлады. Безнең бизнес системасына кереп киткән язучыларыбыз да, спорт өлкәсендә эшләүче язучыларыбыз да, дәүләт структурасында эшләүче әдипләребез дә бар. Соңгы елларда мин парламентта эшләвемне иҗат өчен шактый зыянлы дип саныйм. Күләм ягыннан караганда. Әгәр дә мин парламентта эшләмәгән булсам, күбрәк язар идем. Чөнки парламент вакытны шулкадәр күп ала, миннән бүген: «Нәрсә җитми?» – дип сорасалар, мин: «Вакыт җитми», – дип әйтер идем. Әмма 80 нче еллар азагыннан бүгенгә кадәр дәүләт даирәләрендә барган ыгы-зыгыларны, зур вакыйгаларны, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, дәүләт учреждениесендәге мәсьәләләрнең ничек хәл ителүен, андагы кухняны, андагы казанның ничек кайнавын безнең шикелле берәү дә белми. Мин инде дистә елдан артык боларны теркәп барам, ул минем хәтеремдә. Әгәр дә киләчәктә Ходай Тәгалә сәламәтлек, ихтыяр көче бирсә, нинди дә булса бер әсәр язармын дип уйлыйм. Ул әсәр инде яртылаш язылган дип әйтергә дә мөмкин. Ул роман-хроника булырмы – жанрын әлегә төгәл генә әйтә алмыйм. Әмма мин үземнең гомеремне һич кенә дә бушка үтә дип әйтмәс идем. Иҗат кешесе буларак та, парламент депутаты буларак әйтәм мин моны.

*Әңгәмәдәш Марсель Галиев*

*2007*

# ГОМЕРЕ БУЕ ШАГЫЙРЬ ҖАВАПЛЫ

**– Разил әфәнде, Сезнең белән очрашуга җыенып, онытылмаска тиешле сорауларымны барлаганда, тел очында һаман-һаман Наҗар Нәҗминең шигырь юллары әйләнде:**

**Нигә? Нигә? Бала-чага кебек,**
**Сорау бирәм...**
**Соравыма кем соң җавап бирер?..**

**Аннан соң шагыйрьнең шигырь юлларын үземчә борып куям да:**

**Гомер буе шагыйрь кыл өстендә,**
**Гомер буе шагыйрь җаваплы, –**

**дигән аксиома җөмлә китереп чыгарам. Ә бит сорауларым тел язмышы, мәдәният язмышы, мәгариф язмышы, ахыр килеп, халык язмышы тирәсендә – чыннан да, шагыйрьнең иҗаты мәгънә таба, гамәлгә аша торган рухи мәйдан да шушы!**
**Бер ай элек Түбән Камада Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышы булды. Юкка гына түгел инде бу. Димәк, баш өстендә татар халкының рухи хәзинәсен – күңел кошын тибеп алмакчы булып карчыга әйләнә башлаган. Әллә борчылу урынсызмы соң?**
– Сәбәпләр бар. РФ Дәүләт Думасында «Кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Канун проекты беренче укылышта кабул ителгәч, барыбыз да өнсез калдык. Хәтта ул ТР Дәүләт Советы сессиясендә аерым бер мәсьәлә буларак тикшерелде. Югыйсә, илкүләм проектлар кабул ителгәч, беркадәр өмет уянган иде. Мәгарифкә игътибар, ягъни приоритетлы мөнәсәбәт уңай үзгәрешләр вәгъдә итте ул. Вәгъдәләр акча белән дә ныгытылды. Без бит хәзер һәр ниятне, һәр башкарылган эшне акчага күчереп бәялибез. Акча күзлегеннән караганда да күренеш матур иде. Россия бюджетыннан приоритетлы проектны тормышка ашыру өчен өстәмә рәвештә Татарстан мәгарифенә 700 миллион чамасы акча бүлеп бирелде. Татарстан бюджетыннан 600 миллион өстәлде. Бу инде игътибарның суммар чагылышы. Гомумән, республика бюджетының өчтән бер өлеше диярлек мәгарифкә тотыла.
Приоритет билгеләп, конкрет эш башладык. Әйтик, сыйныф җитәкчесенә өстәмә түләү. Сыйныф җитәкчесе – мәктәп тәрбиясендә төп кеше. Тәрбия – мөһим нәрсә! Без сыйныф җитәкчесенә өстәмә түләүне илкүләм проект кабул ителгәнче үк керткән идек инде. Ел саен 300 миллион сум акчаны чыгымнарның шул өлеше өчен тәгаенләп куя идек.
87 мәктәпкә берәр миллион сумлык грант билгеләдек. Аннары укытучыларга махсус грантлар булдырдык. Күтәренке күңел белән эшләү өчен канат кую ул грант. Мәктәп автобуслары йөри башлады. Әмма анда уйланылмаган нәрсәләр дә күп. Узган ел 423 укытучы эшсез каласы иде. Гомер буе шунда яшәгән, төпләнгән авыл укытучысы кая барсын?!
Грантлар бирү әйбәт хәл анысы. Хәтта татар теле һәм әдәбияты укытучыларының да Россия президенты кулыннан грант алуы сөенечле фал сыман иде. Ләкин бит матур гына йомарланган йомгак сүтелергә тора.
Әйе шул, эшләр алга киткән иде кебек. Әмма сүз башында телгә алган канун проекты баллы тәпәнгә дегет булып таммакчы. Мәгарифнең иң нечкә җире – милли мәгариф бар бит әле. Дәүләтле халык иң элек милли мәгарифен кайгырта. Ә без һаман алга китә алмый йөдибез.
Мәскәүнең милли мәгарифкә хәерхаһлыгы берьяклы кебек. Кайдадыр, Балтыйк буендамы анда, әллә Үзбәкстандамы, үз бармагын (телен дип аңлыйк) Былтыр кысканда гына кеше хокуклары хакында дөньяга чаң кагыла. Ә Россиядә яшәүче ниндидер «вак халыклар»ның теле ни дәрәҗәдә хокуклы булу кадәресе чыннан да «вак» мәсьәлә булып кала. Сүземне шул темага ялгамакчы идем. «Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең

еллар буена үстереп килгән, өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирерлек дәрәҗәгә китергән». Бу – халык язучысы Гомәр Бәширов сүзләре. «Телне кысуларга» килгәндә исә, үзебез дә гаепле. Татарстанның «Телләр турында»гы Законын күпләр әле дә белеп бетермиләр. Әйтик, Латвиядә рус фамилияләрен латышча боруга руслар кискен каршы чыкты. Татар фамилияләрен инде күптәннән «русчага бордылар». Югыйсә законда моны дөресләү мөмкинлеге каралган. Законның 15 нче маддәсенең 4 нче пунктында «документлар милли традицияләрне истә тотып рәсмиләштерелә» диелгән. Тел җәһәтеннән кешеләрнең хокуклары шактый әйбәт якланган ул законда. Ул законның теге яки бу маддәсендә каралган хокукы бозылганда судка бирергә дә, гаеплене 30 минималь хезмәт хакына кадәр штрафка тарттырырга да мөмкин. Миңа ул законда 9 нчы маддәнең 1 нче пунктында язылганнар бик ошады, «Балаларын ана теленә өйрәтү ата-ананың гражданлык бурычы булып тора» диелгән анда.

**– Мәктәп беттеме – авыл бетә бара. Авыл белән бергә тел дә бетә. Димәк, татарга шәһәрне яулап алырга кирәк. Бик вакыт! Бу эштә милли мәгариф куәтле фикердәш, кулдаш була ала.**

Гәрчә Россия Конституциясенең 68 нче маддәсендә «Россия Федерациясе үзенең барлык халыкларына туган телне саклап калуга, аны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыруга хокукларын гарантияли» диелсә дә, Россия Дәүләт Думасы әлеге канун проектын кабул итте. Бу безне бик нык сагайта. Сагаюның сәбәбе бар. Әйтик, безнең мәктәп программалары әлегәчә өч өлештән тора. Беренчесе – федераль компонент, ул бирелә торган дәресләрнең 75 процентын тәшкил итә. Милли-төбәк компоненты унбиш процент били. Тагын ун процент мәктәп компоненты өстәлә. Әнә шулай итеп, дәресләрнең егерме биш процентын үзебез теләгән фәннәрдән туплау хокукыбыз бар иде. Татар теле һәм әдәбияты, татар тарихы, төбәк тарихы, культурология әнә шундый юл белән укытылды. Ягъни канунга сыйган мөмкинлекләр бар иде. Хәзер Россия Думасы депутатлары мәктәпләрдә укытыла торган программада фәкать бер генә компонент калдырмакчылар. Канун проекты кабул ителеп, РФ президенты аңа имза салса, Россия төбәкләрендә генә түгел, хәтта үз республикабызда да бу фәннәрне укыту чикләнәчәк. Милли компонент федераль укыту стандартлары эшләгәндә искә алыначак дип, безнең уяулыкны йоклатмакчылар. Милли компонент законда беркетелми торып, сүзгә генә ышану кыен. Әгәр законда анык язылмый икән, хөкүмәт теләсә нинди карар кабул итәргә мөмкин.

Инде Дәүләт Думасына тәкъдим ителгән шушы закон проекты кабул ителсә, барлык халыкларның да милли мәгарифләрен үстерү мөмкинлеге чикләнәчәк.

**– Димәк, ул проект үтәрме, юкмы икән дип гөманлап, кул кушырып утыру ярый торган эш түгел.**

– Менә шуңа күрә дә инде Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, ихтимал туачак хәлгә борчылып, РФ Президенты В. Путинга, Россия хөкүмәте рәисе В. Зубковка, Федераль Совет Рәисе С. Мироновка, Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызловка Мөрәҗәгать кабул итте. «...мәгариф стандартының гамәлдәге төшенчәсен һәм өч компонентлы структураны калдыруны тәкъдим итәбез», диелә анда.

Россия субъектларының өчтән бер өлеше безнең Мөрәҗәгатьне хупласа, әлеге канун проекты үтми. Төньяк Осетия, Краснодар краe, Чувашстан, Алтай Республикасы, Карачай-Черкес, Башкортстан, Якут-Саха, Бурятия һ. б. төбәкләр Мөрәҗәгатьне яклап чыктылар инде.

**– Федераль үзәк белән Татарстан арасындагы Шартнамә шундый четерекле мәсьәләләрне дә күздә тотарга тиештер бит.**

– Шартнамә бик тә катлаулы шартларда кабул ителде. Мин аның эшче төркемендә идем. Соңгы төзелгән Шартнамә федераль закон көченә ия. Димәк, ул Россиянең барлык төбәкләрендә дә үтәлергә тиеш. Әмма Шартнамәне гамәлгә ашыра бару өчен дә дәүләт программасы кирәк.

**– Федераль законнар Мәскәүдә кабул ителә. Россия Дәүләт Думасында безнекеләр дә бар. Чананы тауга каршы алар да этешәдер.**

– Төрлечә була инде. Милли сәясәт министрлыгы юкка чыкканнан бирле, милләтләр чарасыз калды. Министрлык юк икән, димәк, милли проблема да юк кебек. «Россия Федерациясендә

телләр турындагы закон»ның 3 нче маддәсенә үзгәреш кертелү тарихын искә төшерик. «Россиядә яшәүче халыклар фәкать кириллица имлясында гына укый-яза ала» диелгән анда. Башка имляда язганы дәүләт телендә язган булып саналмый.
Инде менә милли мәгарифебезгә зыян салачак канун проектының яңасына нәүбәт җитте. Россиядәге милли парламентлар ялда чагында Думада аны җиңел генә кабул итеп куймакчы булганнар. Мин үзем хөкүмәт тарафыннан кабул ителгән бу проектны Интернетта күреп алдым. Шуннан соң РФ Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган депутатлар белән сөйләштем, мәсьәләнең чын хикмәтен төшендердем кебек. Әмма барысы да диярлек милли мәгариф өчен һәлакәтле шушы документны хуплап тавыш биргән. Каршылардан бары берәү – И. Гыйльметдинов кына бар.
**– «Телгә, Илгә, Дингә һәм Иделгә тугры калып, тарих кичкәндә...» дигән шигырь юллары искә төшә дә, сызланып куям. Тугры калдык, әмма саклый алдыкмы соң? Илне, Телне...**
– Әйдә, алайса, шигырь белән сөйләшәбез. «Туган телдән йөзен чөергәннең сукыр йолдыз янсын күгендә», – ди Зөлфәт.
«Туган телем әгәр бетә икән, мин үләргә әзер бүген үк», – ди Рәсүл Гамзатов.
**– Ә бит дус түгелләрнең соң максаты да шул: «Вы, прадеды наши, в неволе, мукою запудривши лик, на мельнице русской смололи заезжий татарский язык», – ди Ярослав Смоляков дигән шагыйрь. Тегермән ташы астыннан исән чыккан тел орлыкларын гомерле, бәрәкәтле итәсе иде бит.**
Аның өчен тел ихтыяҗ булырга тиеш. Яшәү өчен, эшләү өчен кирәге булмаган телне, билгеле, өйрәнүгә ихтыяҗ аз. Телебезне үзара аралашу теле итеп кенә калдырмыйча, һәр урында кирәкле тел дәрәҗәсенә җиткерү зарур. Аның өчен ике дәүләт телен дә белү тиешле һөнәр ияләренең исемлеген булдырып, аларны дәүләт хисабына укытырга, аннан соң эшкә урнаштырырга кирәк.
**– Гадәттә, ике телле белгечләр бюджет оешмаларына кирәк. Димәк, иң аз түләнә торган урыннарга.**
– Тел төбендә ни барын аңладым. Җиде ел үткәрә киләбез бит инде бер урында озак эшләгән һәм дәүләт телләрен белгән өчен өстәмә түләү мәсьәләсен. Ниһаять, 2007 елның 1 гыйнварыннан мәдәният хезмәткәрләренә өстәмә түләү гамәлгә керде. Моның өчен бюджетка өстәмә 120 миллион акча салынды. Башкортстанда андый өстәмә бар иде инде. Күп төбәкләрдә әле дә юк. Киләсе елның 1 июленнән һөнәр өлкәсенә карап хезмәткә түләү системасы кертеләчәк. Әйтик, Татарстанда мәгарифкә 22 миллиард бирелә икән, аны кая, ничек сарыф итәсен билгеләү мөмкинлекләре арта.
**– Грантлар бирү тәртибе акча бүлүдә беркадәр мөстәкыйльлек, иркенлек тудырган иде дип беләм.**
– Грант ул – бөтен дөньяда иң прогрессив система. Грантка дәгъва белдергәндә, аның ни өчен кирәклеге дәлилле итеп нигезләнә. Финанс министрлыгы грантлар өчен 64 миллион сум караган иде. Без тагын 50 миллион сорадык. Димәк, 114 миллионга исәп тотабыз.
**– Безнең халкыбыз борын-борыннан мәгърифәтле, китаплы халык булган. Гасырлар буена дәүләтсез, республикасыз яшәгән вакытларда да безне юкка чыгудан, югалудан дин белән мәгърифәт саклап калган.**
– Безнең бүген дә, шагыйрь Хәсән Туфан әйтмешли, Татарстанлы чакта да, югаласыбыз, юкка чыгасыбыз килми. Әмма бүген татар китабының, татар басмаларының нинди аяныч хәлдә икәнлеге күз алдында. Аларның тиражы кими бара, китап кибетләре берәм-берәм ябылып, китап сату системасы тәмам таркалды. Компьютер заманы килде дисәк тә, компьютер һәм Интернет системасында безнең урыныбыз әле бик бәләкәй. Бауман урамындагы тарихи Матбугат йорты ябылып, андагы нәшриятларның һәм редакцияләрнең шәһәр читендәге тыкрыкларга күчерелүе дә халкыбызның рухи тормышына, әдәбиятка һәм матбугатка карата булган дәүләти мөнәсәбәткә дәрәҗә өстәмәде. «Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чума» дигәндәй, Татарстан китап нәшрияты үзенең кибетен Бауман урамындагы гипермаркетның подвалында ачарга мәҗбүр булды. Гасырлар буена халкыбызга рух биреп, аны саклап килгән татар китабының шулай

әкренләп җир астына юл тотуы бик тә шөбһәле һәм символик мәгънәгә ия. Хәерлегә генә булсын инде.

**– Татар китабының фаҗигале язмыш сәхифәләрендә «Сөембикә китапханәсе»нең сере дә бар.**

– «Сөембикә китапханәсе» артыннан йөрдем мин. Ул Загорскидагы патриарх архивында түгел микән дигән шигем бар. Патриархка Василий Лихачёв исеменнән хат яздык. «Сезнең фондларда эшләргә рөхсәт итсәгез иде», – дип. Җавап килмәгәч, шик тагын да көчәйде. Патриарх, юк та, бар да, димәде. Дин әһеле ялганлый алмый лабаса.

**– Китап тарихы буенча фән кандидаты булган кеше беренче татар китабының туган көнен яхшы белә булыр. Ике төрле дата тирәсендә сүзләр куера.**

– Быел без Россиядә нәшер ителгән татар китабының 285 еллыгын билгеләр идек. 395 ел элек исә Германиядә татарлар өчен китап басылу факты да бар.

**– Шулай итеп, татар китабына лаеклы бүләк әзерләү өчен бөтен нигезләр бар икән.**

– Казан уртасында бик шәп китапханә салып кую өчен киләсе ел бюджетында 500 миллион сум каралды. Анда инде бик зур китап кибете дә булыр. Тагын бер хыялым бар әле. Казан гомер-гомергә китап үзәге булган. Һәр районда китап кибетләре ача алсак иде. Безнең китап басучылар елның-елында дөньяның китап ярминкәләренә йөри. Бүләкләр белән кайталар. Ә нигә Казанда китап ярминкәсе уздырмаска?!

**– Дөньядан җыярга остардык. Тәҗрибә бар димәкче булам. «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивале генә дә ни тора! Дөньяның 43 иленнән килделәр соңгысына. Йөзләгән фильм күрсәтелде.**

– Үз киносы юк, әмма кино фестивале уздырыла торган бердәнбер ил ул Татарстан. Ярый әле соңгысында «Дилемма» булды. Кино төшерә башлау өчен бюджеттан өстәмә 50 миллион сорадык.

Безнең театр һәм музыка сәнгате дә, рәсем һәм нәкыш сәнгате дә, әдәбиятыбыз да ил күләмендә алдынгы санала. Әмма, ни кызганыч, бөтен сәнгатьләр арасында иң үтемле саналган кино сәнгате бездә әле һаман балалык чорыннан чыга алмый тилмерә. Кино сәнгатен үстерү өчен бездә югары дәрәҗәдәге әдәбият та, артистлар һәм режиссёрлар, музыкантлар да бар. Әмма тиешле база һәм финанслаусыз гына, әкияти тылсым белән генә кино сәнгатен бар итүе кыен.

**– Дөнья сәнгатенә ераклашырга тырышкан булу бар инде ул бездә. Софья Гобәйдуллина хакын хаклап, заманча музыка бинасы салып куйдык. Ә берәр татар композиторының үзәге бармы бездә?**

– Татар композиторларын, татар дирижёрларын, җырчыларын, музыкантларын әзерләү – милли музыканы үстерү булырга тиеш бит безнең максат.

Телсез-тешсез булудан туктарга вакыт безгә. «Дәшми торсаң, бу дөньяда кояшсыз да калдырырлар!»

*Әңгәмәдәш Асия Юнысова*
*2007*

# ӘКИЯТ УКЫП ТУЯ АЛМЫЙМ...

**– Шушы арада гына «Мәгариф» нәшриятында «Дөнья классикасын татарча укыйбыз» сериясеннән матур рәсемнәр белән бизәлгән «Алтын алма» исемле китабыгыз дөнья күрде. Дөнья халыклары әкиятләренең тәрҗемәләре тупланган бу китап «Әкият ул – могҗиза!» дигән сүзләр белән башлана. Сез моңа чын-чынлап ышанасызмы?**

– Минем бала чактан алып бүгенге көнгәчә бер дә укып туймый торган китапларым – әкият китаплары. Башлангычта укыганда, бик матур итеп бизәлгән әкиятләр җыентыгы эләккән иде кулыма. Шуннан «Ак бүре» исемле әкият укып, мин шаккаткан идем. Бу әкиятне бүгенге көннең әллә нинди фантастик-детектив әсәрләреннән дә камилрәк дип саныйм... Әкияттә бөтен нәрсә бар! Һәр халык үз хыялын, өметен әкияткә салган. Әкиятләргә алдан күрүчәнлек тә хас: андагы тылсымнар бүгенге көндә акрынлап чынга аша бара... Хәзер дә моңсу вакытларымда, авыр чакларда кулыма әкият китабы алам да рәхәтләнеп, онытылып, шуңа «чумам»... Китап кибетләренә кергәч тә иң элек әкият китаплары карый башлыйм. Язучылар язган әкиятләрдән иң яратканым – Экзюпериның «Нәни принц»ы. Мин аны балалар өчен генә түгел, олылар өчен дә язылган бик фәлсәфи әсәр дип саныйм һәм һич кенә дә укып туя алмыйм.

**– Әлеге әкият энциклопедиясен карап-укып утырдым әле: күпчелеге таныш бит! Болар «Ялкын» журналының тышлыгында сан саен чыгып килүче әкиятләр түгелме соң?**

– Нәкъ үзләре. Мин «Ялкын»да 1972 елдан 1981 елга кадәр эшләдем, шул елларда, балалар яратмый калмас әле дип, дөнья халыклары әкиятләренең тәрҗемәләрен журналга тәкъдим иттем. Болай ук озын гомерле булыр дип тә уйламаган идем мин аларны, бер-ике ел барыр да туктар дигән идем. Әмма юк бит: һаман сорыйлар журнал укучылар шул әкиятләрне...

Әкиятләрне тәрҗемә иткәндә, үзем өчен тагын бер кызык нәрсә ачтым: дөнья халыклары әкиятләренең сюжетлары бер-берсенә шактый охшаш икән! Димәк, дөнья бик кечкенә, һәм төрле кыйтгаларда гомер сөргән халыклар кайчандыр якыннан аралашып яшәгәннәр! Барлыгы 30–40 сюжет бар, калганнары шуларның вариацияләре генә. Әкиятләр укып та әллә нинди ачышлар ясарга була икән.

**– Үзегезнең әкиятләр язганыгыз бармы соң?**

– Юк...

**– Ни өчен?**

– Мин – хыялый кеше. Үзем әкият язмасам да, әсәрләремнең барысында да әкият чалымнары бар, геройларым да рухи яктан байлар, хыялыйлар, әкият дөньясыннан килгән кешеләр кебек. Җырларым да шундыйрак...

**– Җыр димәктән, чын шигырьгә көй язып булмый дигән фикергә, бик күп җырлар авторы буларак, карашыгыз ничек?**

– Килешмим, әлбәттә. Чын җыр бары тик чын шигырьгә генә язылырга тиеш. Минем күп кенә җырларым нәкъ менә җыр булсын өчен язылмаган. Алар, мөстәкыйль шигырь булып шактый яшәгәч кенә, композиторлар тарафыннан табылып, көйгә салынган. Җыр иҗат итү шигырь язуга караганда катлаулырак: аңа аерым таләпләр куела, гади күзгә күренми торган нюанслары да бар, һәм җыр шигыре музыкасыз да «җырлап» торырга тиеш. Әмма соңгы вакытта бер нәрсә күңелне тырный: халыкның зәвыгын боза торган мәгънәсез җырлар чыга да тора, шуларга бер әтрафлы фикер әйтүче, бәя бирүче юк. Җырлаучылары колак салмаса да, бәлки, тыңлаучылар ишетер иде, дим...

**– Язучының дәрәҗәсе әсәрләре дәреслеккә кертелү-кертелмәүгә карап бәяләнә дигән фикер белән килешәсезме?**

– Бу бик катлаулы мәсьәлә. Әдәбият, уку, ана теле дәреслекләренә карата каршылыклы фикерләр күп. Тиздән бу хакта Татарстан Язучылар берлегендә дә зур киңәшмә, фикер алышу булырга тиеш... Шәхсән минем үземә Альберт Яхин дәреслекләре ошый: тапталып беткән эздән бармавы, оригинальлеге белән. Ә «Мәгариф» нәшриятында чыккан китапларның зәвыклы булуы сөендерә,

май чүлмәге тышыннан билгеле, дигән кебек, үзләрен кемгә күрсәтсәң дә оят түгел, инде аларның эчтәлеге дә тышына тәңгәл килер дип уйлыйм.

**– Сезнең гаиләдә бездә чыккан дәреслекләр белән укучылар бармы соң?**

– Бар. Оныгым Җәмилә инглиз мәктәбенең татар сыйныфында укый. Ул ана телен яхшы белә, өйдә татарча гына сөйләшәбез. Үземнең чит телләр белмәвем үзәгемә үтте, шул сәбәпле, балаларым-оныкларым булса, аларга һичшиксез чит телне өйрәтермен, дигән идем. Шул сүземне, шөкер, үтәдем: кызым да, оныкларым да ана телен, рус телен һәм инглиз телен яхшы беләләр.

**– Сезнең хезмәт урыннарыгыз бик күп, койрыкта сөйрәлгән колхозларны «кеше итәргә» җибәрелгән рәис сыман, гел генә дә артта калган оешмаларны алга чыгарып яшәгәнсез. Мәсәлән, Милли китапханә үзе генә дә ни тора! Татарстан Республикасының халык депутаты буларак, 2000 елдан башлап Сез – Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе. Эшегезне яратып башкарасызмы?**

– Мин яратмаган эшемдә гомумән дә эшләмим, бармыйм андый хезмәткә. Милли китапханәгә эшкә килгәндә, ул ярым җимерек хәлдә иде, әле генә сугыш үткән кебек: җылыткыч торбалары шартлап беткән, утлары янмый, түбәсеннән су үтеп ята, зур уку залының түшәме ишелеп төшкән... Әмма подвалларда череп яткан, XIV гасырдан башлап бүгенге көнгә кадәр җыелган өч миллионнан артык китапны күргәч, мин монда эшкә килергә тиеш дип уйладым. Авыр булды, әлбәттә, әмма мин бу эшемне дә яратып башкардым...

Хезмәтемнең бүгенгесендә дә яратып эшлим, чөнки күңелемә якын эш белән, үз эшем белән шөгыльләнәм дип саныйм. Мәдәният, фән, мәгариф, милли мәсьәләләр, шулар өстенә иҗтимагый оешмалар, иҗат оешмалары, нәшриятлар, телевидение, радио, дин – болар безнең рухи дөньябыз. Шуларга дәүләт дәрәҗәсендә кулдан килгән, мөмкин булган кадәр ярдәм итәргә тырышу – безнең төп эшебез. Билгеле, теләгәннең барысын да башкарып чыгып булмый, әмма эшләгән кадәресе дә шактый, алары һәммә кешегә мәгълүм.

**– Ә ял итәргә вакыт каламы соң?**

– Әгәр эшем барса, шул минем өчен иң шәп ял. Мин, дөресен генә әйткәндә, ялның нәрсә икәнен белмим, әле ял итәргә түгел, эшләргә дә вакыт җиткереп булмый. Аз гына җаен чыгара алсам инде, уйланып, урманда йөрергә яратам...

*Әңгәмәдәш Нурзидә Нотфуллина*
*2007*

# ЧИРЛЕ ГАДӘТ

**– Разил әфәнде, узган гасырның 80–90 нчы елларындагы милли хисләр әкренләп сүрелә. Татарстан үз дәүләтчелеге позицияләрен ташлый-ташлый чигенә башлады кебек. Кая барып терәлербез?**

– Россиядә гасырлардан гасырларга күчеп килүче йола-гадәт бар бит инде ул: ил бик авыр хәлдә калып, җимерелү куркынычы яный башласа, милләтләргә бераз ирек биреп, дилбегәне бушатып алалар.

1917 елгы революциядән соң да, узган гасырның 90 нчы еллар башында да шулай булды. Россия таркалу хәлендә иде, һәм Ельцин, бергә булсак яшәрбез, дип юмалап, йота алган хәтле суверенитет вәгъдә итте. Соңыннан исә хокукларны кире тартып алу башланды. Тарих кабатлана.

**– Әби патша заманында да шуңа охшаш сәясәт алып барылды түгелме?**

– Әлбәттә, Екатерина II татарларга мәчетләр төзергә рөхсәт бирде. Чөнки илдә чуалышлар вакытында татары, башкорты, чувашы, удмурты ирек таләп итә башлады. Пугачёв восстаниесен генә искә төшерегез. Әмма аннан соң төрле милләт халыкларын янә кысу башланды. Хәтерлисездер, заманында татарга тимерчелек белән шөгыльләнү дә тыелды, чөнки татар корал ясар дип куркалар иде. Ачуым килмәгәе, ат дагаларга да хокукыбыз юк иде. Әле бит Казан уртасындагы бакчада «Татарларга һәм этләргә керергә ярамый...» дигән язуның юкка чыгуына да 100 генә ел. Ни өчен тарихны искә төшерәм? Сез әйткәнчә, артка чигенеп килсә дә, дәүләтчелек дәгъва итүдән туктамый бит татар.

**– Менә Сез инде ничә еллар парламентта. Артка чигү кайчан башланды?**

– 2000 елдан, Россия прокуратурасы законнарыбызга дәгъва белдерә башлагач. Иң элек «суверенитет» дигән сүзгә бәйләнделәр. Конституциябездәге 40 тан артык маддәне үзгәртергә куштылар.

**– Һәм үзгәрттек.**

– Юк, яртысына да кагылмадык, һаман да тартышабыз, тарткалашабыз әле.

**– Әмма Россия Думасы үз Конституциясенә каршы килеп законнар кабул итә тора. Республикалар, аерым алганда, Татарстан өчен иң куркынычы кайсылары дип уйлыйсыз?**

– Мәсәлән, республикада президентны сайлап кую хокукын бетерү.

**– Димәк, Сезнең тартышу-тарткалашу юкка көч әрәм итү генә була түгелме?**

– Ә нигә әле федераль үзәк белән Татарстан арасында төзелгән Шартнамәне онытасыз? Аны «декларатив документ» дип кенә бәяләүчеләр дә булды. Бер генә мисал: Шартнамәдә президентның ике дәүләт телен дә белергә тиешлеге язылган. Бу зур җиңү дип исәплим мин, һәм аңа ирешү өчен шактый тарткалашырга туры килде. Безгә: «Сез президентлыкка кандидатның хокукларын бозасыз», – диделәр. Ә без: «Русча белмәгән кешене Россия президенты итеп сайларга мөмкинме?» – дидек. «Юк, – ди болар, – тик без моны законга язып куймыйбыз». Без әйтәбез: «Бездә ике дәүләт теле икәнен онытмагыз, Татарстандагы 2 миллион сайлаучының яртысыннан артыгы татар, аларның президент белән үз телләрендә сөйләшәсе килә. Сез аларның хокуклары турында уйлыйсызмы?» – дибез. Каршы як бирелергә мәҗбүр булды. Минем уемча, һәрнәрсәнең башы һәм ахыры булган кебек, әлеге җиңүнең дә дәвамы булырга тиеш. Ягъни, иң югары дәрәҗәдәге җитәкче татар телен белә икән, димәк, аның даирәсендәгеләр дә, гомумән, дәүләт хезмәтендәге барлык түрәләр дә татарча белергә тиеш дигән сүз. Без шуңа омтылабыз да.

**– Менә «дәүләт» дигән сүзгә дә килеп җиттек.**

**Күптән түгел Россия Думасына төбәк парламентларында, гомумән, хакимият органнарында «дәүләт» сүзен куллануны тыю турында закон проекты килеп кергән иде. Бу ни дигән сүз инде?**

– Иң элек яхшы хәбәр әйтим әле: әлеге закон проекты Думада яклау тапмады. 57 депутат хупласа, калганнары каршы тавыш биргән йә катнашмаган, йә аумакай булып чыга инде. Һәрхәлдә, хәзергә җиңел сулап куярга мөмкин, әмма хәзергә генә шул. Чөнки мондый закон проектының

Думага беренче генә керүе түгел. Хәтерлисездер, В. Жириновский: «Россиядә бер генә президент булырга тиеш», – дип, күптәннән шаулый.
Әгәр дә әлеге закон проекты Думада хупланса, дәүләт төзүгә омтылыш юкка чыгачак. Дәүләт юк икән, димәк, президент та кирәк түгел дигән сүз.
Хәзергә тавыш тынды, әмма бу шомлы тынлык. Чөнки безгә Россия прокуратурасы: «Сез – дәүләт түгел», – дип, инде ничә еллар протест белдереп килә, гәрчә Россия Конституциясенең 5 нче маддәсендә акка кара белән «республикалар – дәүләт» дип язылса да. Моңа гаҗәпләнәсе юк. Дума Россия Конституциясенә каршы килә торган күпме закон кабул итте бит инде. Бу ил законнар буенча түгел, аерым бер төшенчәләр буенча гына яши шул.
Менә «Россия халыклары телләре турында»гы Законга кертелгән үзгәрешләрне генә алыгыз. Янәсе, Россиядә бар халык бары тик кириллицада гына язарга тиеш. Бу шулай ук РФ Конституциясенең 68 нче маддәсенә каршы килә. Төп Законда бит барлык телләрнең иркле үсешенә тигез шартлар гарантияләнә. Үз алфавитыңны да раслый алмагач, иркле үсеш була аламы?
**– Разил әфәнде, без Россия мәгариф стандартларына үзгәрешләр кертелү уңаеннан «Ватаным Татарстан»да Сезнең белән әңгәмә чыгарган идек инде.**
– Әйе, элек мәгариф стандартларында җитмеш биш процент федераль компонент булса, калган егерме биш проценты безгә мәгарифтә милли үзенчәлекләрне сакларга ярдәм итә иде. Иң кызыгы, мәгариф стандартларына үзгәрешләр кертү турындагы закон проектында баштарак «милли үзенчәлекләрне искә алып» дигәнрәк сүзләр бар иде, һәм проект шушы хәлендә төбәк парламентларына җибәрелде. Әлбәттә инде, җирле парламентлар, милли үзенчәлек сакланачак икән дип, проектны хуплады.
Тик икенче һәм өченче укылышларда әлеге җөмлә сызып ташланды, һәм закон ашык-пошык кабул ителде. Гәрчә мәгариф мәсьәләләре федераль үзәк белән төбәкләрнең уртак вәкаләтләренә керсә дә, Дума җирле парламент фикерен сорап тормады. Думага сайлаулар алдыннан В. Путин әлеге законга кул куйды.
Шунысын да әйтим, Президентыбыз Минтимер Шәймиев «күпмилләтле илдә мондый закон кабул ителергә тиеш түгел» дип, Россия президентына ачыктан-ачык хат та язды. Сайлаулар алдыннан В. Путин белән күзгә-күз очрашкан да иде. Мәгълүм булганча, Путин президентыбызга сайлаулар узгач әлеге мәсьәләгә әйләнеп кайтырга вәгъдә дә бирде.
**– Аның хәзер әйләнеп кайтырга вакыты да калмады бит. 2 мартта яңа президент сайлыйбыз.**
– Хөкүмәттә калам, диде бит. Эш анда гына түгел, безгә күктән төшкәнне көтеп ятмаска кирәк. Үзем җитәкләгән комитет Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Думага җибәрер өчен закон проекты әзерләде. Эчтәлеген сөйләп тормыйм, чөнки комитетта расланмаган, сессиягә тәкъдим ителмәгән әле ул. Шуңа күрә үзгәрешләр булырга мөмкин. Ә асылы, максаты мондый: Россиядә милләтләр сакланып калырга, үсәргә, мәгарифтә милли компонентлар сакланып калырга тиеш.
**– Разил әфәнде, «дәүләт» сүзен куллануны тыю турындагы закон проектына яңадан әйләнеп кайтыйк әле. Дәүләт статусы бетсә, Татарстанга парламент кирәк булырмы соң?**
– Парламентны бетермәсләр анысы. Әмма әлеге сүзне тыю – дәүләткә хокукны тартып алуга бер адым. Ә бу – Россия җитәкчелегенең генераль линиясе. «Дәүләт» дигән сүзне бетерү статусны төшерү, кемнеңдер колы булу дигән сүз инде ул. Бу – мәкерле сәясәтнең, башта ук әйткәнемчә, Россия дигән империядә гасырлар буе яшәп килгән чирнең дәвамы.
**– Дөресен әйткәндә, соңгы елларда милли хисләр бераз тупасланды кебек. Суверенитет та сиңа, миңа, зыялыларга, аерым бер тар катлауга гына кирәк шикелле.**
– Минемчә, бүген татарның күпчелегендә милли горурлык, милли хис бар, тик ул эчкә яшерелгән. Инде татарның ничә гасыр дәүләтсез яшәп тә үз-үзен саклап кала алуы шуңа дәлил түгелмени?
Иң элек халык күңелендә киләчәккә өмет уятырга кирәк, нәкъ 80–90 нчы еллардагы кебек. Бүген әлеге өмет өлешчә югалды, әмма милли аң яши. Ул бары тик башка формаларга гына күчте. Мин

яшь буынга өметләнәм. Өлкән буын үз эшен эшләде, ә 80 нче еллардан соң туган яңа буын милләт өчен яңача һәм зуррак эшләр башкарыр дип уйлыйм.

*Әңгәмәдәш Риман Гыйлемханов*
*2008*

# ҮЗ ҖИРЕБЕЗДӘ ХУҖА БУЛЫЙК

*Халык өчен алар – килмешәкләр. Урамнан узып баручы кара тәнле студент та, базарда сату итүче үзбәк тә, киләчәкне юраган чегән дә безгә чит-ятлар. Әмма ни генә булмасын, Татарстан аларның барысын да сыендыра һәм республикабызның күпмилләтле, тыныч, имин яшәүче төбәк дигән даны бар. Килмешәкләрне колач җәеп каршы алу, аларга хәерхаһлы мөнәсәбәттә булу көннәрдән бер көнне үзебезгә үк зыян китермәсме, үкенергә туры килмәсме? ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев белән шул хакта әңгәмә кордык.*

**– Разил әфәнде, Татарстанда 115 милләт вәкиле яши, диләр. Бу санның шулай зур булуы нәрсә белән бәйле?**

– Русия, гомумән, күпмилләтле дәүләт бит инде. Бездә генә түгел, башка төбәкләрдә дә шул ук хәл. Әмма бездә күпләп яшәгән милләтләр бер дистә чамасы гына: татар, урыс, чуваш, мари, мордва, удмурт, украин, белорус, башкорт һәм үзбәкләр. Соңгы арада азәрбайҗаннар ишәя башлады. Ә калган милләтләр кайсы 100 кешелек, кайсының берничә дистә вәкиле бар, кайсы бөтенләй бер-ике кешедән генә тора.

Әгәр Башкортстан белән Татарстанны чагыштырып карыйбыз икән, ни өчен аларда сәяси хәлләр катлаулырак? Чөнки анда төп милләтләр өчәү. Ә бездә икәү генә. Ике милләтне килештерү өч милләтне килештерүгә караганда чагыштырмача җиңелрәктер. Сүз дә юк, соңгы елларда Татарстанда яшәргә теләүчеләр саны артты. Урта Азия һәм Кавказ якларыннан гына да берничә йөз мең кеше килде. Чөнки Татарстан кунакчыл, ашлы, бай республика санала. Бөтендөнья татар конгрессы корылтаенда Үзбәкстаннан килгән милләттәшләребез белән сөйләшеп утырдым. «Заманында безнең әби-бабайлар Ташкент якларына күчкән. Ул вакытта Ташкент ашлы шәһәр саналса, хәзер Казанны бай шәһәр дип атыйлар», – диде алар. Татарстанда яшәү шартларының чагыштырмача әйбәт булуы бер хәл, иң әһәмиятлесе – бездә сәяси яктан тотрыклылык бар. Халкыбыз күпмилләтле булса да, Аллага шөкер, ызгыш-талашлар юк. Ә кайтучыларны, аштан кала, тынычлык-иминлек тә кызыксындыра. Чөнки берәү дә үз иленнән рәхәткә чыдый алмаганга чыгып китмәгәндер.

**– Күптән түгел Татарстан халыклары корылтае уздырдык. Шул ук Башкортстан бу мәсьәләдә алай ук шапырынмый бит?**

– Без күпмилләтле булуыбыз белән шапырынмыйбыз, башка милләт вәкилләренең дә мәнфәгатьләрен кайгыртуыбызны гына сөйлибез. Әгәр башка яклардан күченеп киләләр икән, без бит аларны каршы ала белергә дә тиеш. Аннан соң, аларның килүе безгә дә файдалы бит. Бүген Татарстанга югары квалификацияле 100 меңләп белгеч кирәк. Яңа ачылган «Алабуга» икътисади зонасына гына да 30 мең белгеч таләп ителә. Түбән Камада зур ике завод төзелә. Анда да 15–20 мең кеше кирәк булачак. КамАЗ заводы якындагы авыллардан 1200 кешене автобусларда йөртеп эшләтә, чөнки эшче куллар җитми. Ә читтән кайтучы милләттәшләребезнең күбесе югары белемле. Алар безгә файдалы кешеләр.

Башка милләт вәкилләре исә күбесенчә сәүдәгә һәм кара эшкә килә. Боларын да хуплыйбыз. Республикада зур төзелешләр бара. Анда да дистәләгән мең кеше җитми, ташчысы да, штукатуры-маляры да – барысы да кирәк. Авыл хуҗалыгында да шул ук хәл. Урак өсте җиттеме, күрше республикалардан комбайнчылар, шофёрлар, тракторчылар эзли башлыйбыз. Гомумән, Татарстан бүген кайнап тора.

**– Шул ук вакытта үз халкыбыз эшсез ята. Бигрәк тә авылларда эшсезлек колач җәйде.**

– Эшсез яту эш булмау аркасында гына түгел ул... Соңгы елларда халык ялкауланды. 70–80 еллык колхоз системасы аларны эшләмәскә өйрәтте. Мин авылда җимерек йортта яшәп ятуны күз алдына да китерә алмыйм. Бер-ике дистә мең кирпеч табып, йорт тергезеп кую теләсә кайсы ир кешенең кулыннан килергә тиеш. Әле бит аның 5–6 гектар пай җире дә бар. Шунда суганмы,

бәрәңгеме үстереп сатарга мөмкин. Мал асрар мөмкинлек тә бар. Хәзер печән муеннан, чабылмый ята.
Әлбәттә, барысын да ялкаулыкка сылтау дөрес түгел. Бүтән сәбәпләр дә бар. Авылларга инвесторлар килде. Алар белән бергә яңа техника, технология керде. Моңа кадәр 20–30 кеше эшләгән эшне хәзер бер кеше башкара. Оптимальләштерү дә үз нәтиҗәләрен бирде, эшсезләр санын арттырды. Хәзер без шул кешеләрне яңа һөнәрләргә өйрәтергә, эш белән тәэмин итәргә тиеш.
**– Ә килүчеләр авылны сайлыймы, шәһәрнеме?**
– Күбесе шәһәрдә берегеп калырга омтыла. Бигрәк тә Казан белән Чаллыда. Авылга кайтучыларның күбесе олы яшьтә, алар зиратка, туган нигезгә якынрак булырга тырыша. Тик без үз чиратыбызда кайтучыларны кая кирәк, шунда җибәрергә тырышабыз.
90 нчы елларда миграция сәясәте белән республика үзе шөгыльләнә иде. Хәзер исә моны Русия үз кулына алды. Ул татарларны Татарстанга кайтару ягында түгел кебек. Татарлар бер җирдә артык күп җыелып, берләшерләр дип куркалардыр инде. Бу рәсми төстә эшләнми, әлбәттә, әмма Русиянең милли сәясәте шуңа корылган. Шулай да уңган-булган егет-кызларыбыз ничек тә кайту юлларын эзләп таба. Соңгы елларда безгә күченүчеләрнең җитмеш проценты – татарлар.
**– Татар исеме белән кайтучылар чын татарлармы?**
– Мондый проблема да бар. Аларның күбесе бүтән менталитет белән кайта. Мондагы шартларга, гореф-гадәтләргә бик авыр ияләшәләр. Минем хатыным Үзбәкстаннан. Ул инде биредә 30 еллап яши, әмма безнең халыкның яшәү рәвешенә һаман төшенеп бетә алмый. Безнең өчен бик гади нәрсәләр дә аңа гайре табигый тоела. Авылга ияләшү аеруча авыр. Шәһәрдә бу җиңелрәк, чөнки биредә гомер буе күршедә яшәп тә бер-берсен күрмәгән кешеләр бар, ә авыл бер гаилә кебек бит. Кайтучыларның күбесе авыл тормышы белән таныш түгел. Бездә бит авыл халкы мал асрарга, бакча тотарга тиеш дип санала. Ә күченүчеләр күбесенчә сәүдәгә тартыла. Шунлыктан авылда аларга еш кына: «Аркылыны буйга алып салмыйлар, әрәмтамаклар», – дип әйтәләр.
Әмма кайтучыларның әйбәт яклары да бар. Безнең халык соңгы арада шактый европалашты, тик Европаның күбрәк начар сыйфатларын үзләштерде. Ә кайтучылар күбрәк шәрык менталитетын алып кайталар, безне янәдән элеккечә кунакчыл, киң күңелле, ачык йөзле булырга өйрәтәләр дияргә дә була. Без бит бу сыйфатларны инде югалтып барабыз.
**– Разил әфәнде, базарларда хәзер килгән халык өчен безнекеләр эшли, Вьетнам базарында югары белемле укытучыларыбыз сату итә, аларга акча эшләп бирә...**
– Монда үзебезнең халыкның да гаебе бар. Без үзебезне һаман «служивый» татарлар итеп күрсәтәбез. Гасырлар буена дәүләте булмаган татар башка халыкка хезмәт итәргә шулкадәр өйрәнгән ки, әле һаман да шул гадәтеннән арына алмый. Армиядә дә иң әйбәт солдат татарлар, диләр бит. Әмма ул яхшы солдат булганчы яхшы генерал булсын иде!
Ә инде кемдер 3–4 мең чакрым ераклыктан гаиләсен ияртеп кайтып монда урнашкан икән, димәк, ул төшеп калган кеше түгел. Мин дөньядагы бик күп илләрдә булдым һәм бөтен җирдән татар эзләдем. Көньяк Кореяда гына тапмадым милләттәшләребезне. Мин очраткан татарлар барысы да көчле рухлы, кызыклы шәхесләр. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки каядыр барып җитеп тормыш кору өчен кыюлык, чаялык, ниндидер асыл сыйфатка ия булу кирәк. Мескеннәр анда барып җитә алмый. Китүчеләрнең үз максатлары булган, яхшырак тормышта яшиселәре, балаларын зуррак орбитага чыгарасылары килгән. Безгә килүчеләр дә шундыйлар. Алар монда да югалып калмыйлар.
**– Милләтара дуслык дия-дия, Татарстанда яшәүче 4 миллион халык кайткан кешеләрнең хезмәтчесенә әверелмәсме? Ул кайтучылар тора-бара җитәкче урыннарга ук үрмәләмәсме?**
– Без бөтенләй үк төшеп калган халык түгел бит инде. Президентыбыз, премьер-министр, Дәүләт Советы Рәисе, министрлар, район җитәкчеләребез – берсе дә килмешәк түгел, үзебездә туган, үскән, белем алган, аякка баскан кешеләр. Тик бик зур бер кимчелегебез бар: без сәүдә өлкәсендә биреште к. Гомер-гомергә татарны сәүдәгәр халык дигәннәр. Мин бүген шаккатып, аптырап карап торам: ничек инде базар мөнәсәбәтләре чорында базарны кулдан ычкындырырга мөмкин? Ул бит бик тиз, берничә атнадан табыш китерә торган өлкә. Без дилбегәне хәерчелек заманында кулдан

ычкындырдык бугай. Ә ул вакытта Үзбәкстанда тормыш җитешрәк иде. Хәерчелектә яшәгән ике-өч буын борынгыдан килгән сәүдәгәрлек сыйфатларын югалтты.

**– Гади халык: «Кайтучылар шәһәрне басып алды, без алар артыннан чүп җыярга тиеш», – дип зарлана.**

– Безгә катырак булырга, катгыйрәк таләпләр куярга кирәк. Алар шулай, алар тегеләй дип зарланып утырмаска, әгәр без шушы җирдә хуҗа икән, димәк, башыбызны күтәреп, хуҗа икәнлегебезне күрсәтергә, тәртип урнаштырырга тиеш. Килүчеләр Татарстандагы гореф-гадәт, йолаларны хөрмәт итәргә, безнең тәртипләр буенча, безгә яраклашып яшәргә тиеш. Без үзебез артык тыйнак. Әгәр үз җиребездә дә хуҗа була алмыйбыз икән, ничек зур дөньяга чыгыйк инде? Ә без бит Татарстанны бөтен дөньяга күрсәтергә телибез.

**– Бу тыйнаклык мәгариф өлкәсендә дә сизелә. Инде кайсы заманда ук Казанның яһүд мәктәбендә бассейн төзелде. Безнекеләрнең төшенә дә кермәгәндә, аларның балалары укырга махсус автобусларда йөрде.**

– Ул бит хәйриячеләр хисабына алга киткән, бөтәйгән мәктәп. Аны шул ук яһүдиләр яшәтә. Ә татарда исә, киресенчә, кара байлар күбәйде. Элек үз байлыгын үзенә генә тоткан, үзе генә ашап яткан байларны «кара бай» дигәннәр. Бүгенге көндә милләткә эшләгән Дәрдемәнд, Акчурин, Апанаевлар шикелле чын асыл байларыбыз юк дәрәҗәсендә. Менә без Хәйрия елы үткәрдек. Бик яхшы, бик хуп. Әмма миллиардлаган табыш алучы предприятие җитәкчесенең күпмедер сумманы кемгәдер бүлеп бирүен чын хәйриячелек дип санамыйм мин. Бу әйбәт эш, кирәкле ярдәм. Тик хәйрия бит ул – үз кесәңнән үз табышыңны чыгарып бирү, 3 мең сум пенсия алган бабайның берәр балалар йортына 100 сум акчасын китерүе – менә кайда ул чын хәйриячелек.

Бу мәсьәләдә Төркияне мисал итеп куярга була. Мин андагы хосусый мәктәпләрдә булып, ничек эшләүләрен сораштырдым. Анда хәйриячелек фондлары – вакыфлар бик күп. Тик анда мәктәпләр байлардан акча сорап йөрми, ә берәр байның мәктәп салырга тәкъдим иткән акчасының хәләлме, түгелме икәнлеген, кайдан табылганлыгын тикшерә. Акча хәләл түгел икән, аны алмыйлар. Әгәр инде берәр байның акчасына мәктәп төзелә икән, бу аның өчен бик зур мәртәбә санала. Без моңа кайчан килеп җитәрбез – билгесез. Әлегә без байлардан китап чыгарырга, гарип балаларга ярдәм итәргә, мәктәпкә ремонт ясарга ярдәм итегез әле дип теләнеп йөрибез. Бу безнең менталитетыбызга бәйле, каныбызга сеңгән. Совет чорында без бик бозылдык. Элек нинди генә хәерчелек булса да, һәрбер авыл акча җыеп мәчет, мәдрәсә салган. Хәзер авыллар чагыштырмача байрактыр да, әмма син мәктәп салырга кешедән акча сорап кара әле?! Үлсәң дә җыя алмаячаксың.

**– Бүгенге байлар шул Совет чорында тәрбияләнгән кешеләр. Ә менә яңарыш чорында туган, бүген инде үзләрен XXI гасыр яшьләре дип йөрткән яшьләрне күзәткәнегез бармы? Аларда татарлык һәм шул татарлык белән горурлану ни дәрәҗәдә? Аларның менталитеты нинди?**

– Минем бөтен өметем шуларда. Безнең буын нindидер могҗиза белән сакланып калган инде. Милләт турында, халык турында уйлау дигән хисләрне бөтенләй үк югалтып бетермәгәнбез. Без үзебез булдыра алганны мөмкин кадәр тормышка ашырырга тырыштык. Кайберәүләр: «Менә сезнең буын китәр дә, милләт турында уйлаучы калмас, яшь буынга акча гына кирәк», – диләр. Мин алай димәс идем. Мин аларны безгә караганда күбрәк эшләрләр дип уйлыйм Хәзер 80–85 нче елларда туган балалар вакыты җитә. Алар бөтенләй башка шартларда үстеләр, башка чорда яшәделәр. Казандагыларның да, барысы булмаса да, шактые татар гимназияләрендә укыды. Митингларны күреп үстеләр, фикер хөрлеге алдылар. Минемчә, тагын 5–10 елдан сәяси мәйданга милли үзаңы көчле булган тулы бер буын киләчәк. Милли аң ул яшьләрдә бүген дә бар, әмма аны башкаларга җиткерергә мөмкинлекләре юк. Алар тиешле урыннарга утырып, мөмкинлекләрен файдалана ала башлагач, милләт тагын бер башка үсеп китәр, яңа сикереш булыр.

**– Тик бу яшьләр кансызлык белән вәхшилекне дә күреп үсте бит. Башка милләтләрне кыерсыту, ягъни ксенофобиячелек күренеше дә заман яшьләре арасында колач җәйде.**

– Чыннан да, бу шактый куркыныч нәрсә. Ярты ел чамасы элек без ксенофобиячелеккә каршы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен дә кабул иткән идек. Бу мөрәҗәгатьне кабул итүгә төрле өлкәләрдәге

милләтара ызгышлар, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылында яшәүче милләттәшләребезгә каршы оештырылган чаралар этәргеч ясады. Аны без Русия президентына да, Дәүләт Думасына да, хөкүмәт җитәкчеләренә дә җиткердек. Тәэсире шактый көчле булды. Без бу уңайдан үз фикеребезне курыкмый җиткерә алабыз, чөнки милләтара мөнәсәбәтләр бездә шактый тотрыклы. Әмма каршылыклар бөтенләй юк дип тә әйтеп булмый. Милләт булган җирдә милли проблема булмыйча кала алмый. Моны барча милләтләрнең мәнфәгатьләрен бертигез кайгыртып кына хәл итеп була. Әгәр дә һәр милләтнең үз балалар бакчасы, мәктәбе, үзенчә яшәү өчен мөмкинлекләре бар икән, андый каршылыклар, ыгы-зыгылар килеп чыкмаячак.

**– Куеныңда елан асрау дигән нәрсә дә бар бит. Әнә Франциядә эмигрантлар ничек кан коешып ята. Башларыннан сөя-сөя килмешәкләр җыю бездә дә шул хәлгә китермәсме?**

– Алар берсе дә башларыннан сыйпаганга күтәрелмиләр. Киресенчә, начар мөнәсәбәткә түзә алмаганга ярсыйлар. Германиядә булсын, Франциядә булсын, баш күтәрүчеләр, нигездә, мөселман илләреннән килгән яшьләр. Соңгы 15–20 елда Европада ислам диненә һәм мөселман дөньясына карата тискәре күренешләр күбәеп китте. Европа һәм Америка бүген исламнан уттан курыккан шикелле курка һәм үзләренә аларны китертмәс өчен ниләр генә эшләми.

Без дә читтән килүчеләрнең башыннан сыйпап, кадерләп кенә тотабыз димәс идем. Әмма эшләр, укыр һәм яшәр өчен аларга шартлар тудырырга тырышабыз. Кан коешлар, ызгышлар булмасын өчен милләтләргә тигез карау кирәк.

*Әңгәмәдәш Гөлнара Сабирова*
*2008*

# КИЛЕШЕП ЭШЛӘҮГӘ ӨМЕТ БАР

*Май аенда Дмитрий Анатольевич Медведевның Россия президенты вазифасына рәсми рәвештә керешү тантанасыннан соң без ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиевкә «Сезнеңчә, РФнең яңа президенты үз вазифасына керешкәч, Татарстан Республикасы белән федераль үзәк арасындагы мөнәсәбәтләр ничек үсәчәк (яки ни рәвешле үсәргә тиеш), республикабызда төп игътибар нәрсәләргә юнәлтелергә тиеш?» дигән сораулар белән мөрәҗәгать иттек.*

– Россия Федерациясе президенты булып Дмитрий Анатольевич Медведев сайланганнан соң, Россия дәүләтенең сәяси һәм икътисади вазгыятендә тамырдан үзгәрешләр булыр дип уйламыйм. Президент алышынса да, нигездә, элекке команда кала бирә. Шуның өстенә премьер-министр вазифасына элекке президент, бүген илебездә әйдәп баручы партия саналган «Бердәм Россия»нең җитәкчесе Владимир Путин билгеләнүе дә моңа дәлилдер. Илдә тынычлык, иминлек, тотрыклылык саклап калуны төп максаты һәм мәсләге дип санаган партия җитәкчесе – премьер-министр белән яңа президент янәшәлеге уңышлы эшчәнлекне дәвам итү, ил алга китсен өчен барысын да эшләр, билгеләнгән курстан читләшмәс дип уйлыйм. Ә яңа президент Д. А. Медведевка килгәндә, ул яшь, сабыр, зыялы, киң колачлы сәясәтче, аның эшчәнлегендә кайбер либеральлек чалымнары күренер дигән уй да бар. Минемчә, ул бүгенге федераль хакимиятне, Россиянең вертикаль сәяси вазгыятен күпмедер дәрәҗәдә горизонтальләштерергә тиеш. Бу бигрәк тә РФ субъектларының вәкаләтләрен арттыруда, аларга күбрәк сәяси һәм икътисади мөмкинлекләр бирүдә чагылыш табар, мөгаен. Россия Федерациясе – күп субъектлы дәүләт, димәк, анда һәр төбәкнең, һәр халыкның мәнфәгатьләре Россия Конституциясе нигезендә якланырга тиеш, беркемне дә кимсетергә хакыбыз юк.

Ә инде РФ белән ТР арасында мөнәсәбәтләргә килгәндә, бу уңайдан бер нәрсәгә тукталасым килә. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе белән мөнәсәбәтләрен вәкаләтләрне бүлешү турындагы Шартнамә төзү аша беркеткән бердәнбер төбәк. Үзегез беләсез булыр, Шартнамә төзү шактый кыен һәм катлаулы булды. Мәскәү ягы аяк терәп диярлек әлеге документның барлыкка килүенә каршы торды, ул гына да түгел, Татарстанга мондый мөмкинлек бирмәү өчен тырышты. Бу Шартнамә кабул итү процессында нык сизелде. Әмма ахыр чиктә Мәскәү барыбер Шартнамәне кабул итәргә мәҗбүр булды. Ә бит Шартнамә ике якка да яңа бурычлар, таләпләр куя. Анда язылганнар җитәкчеләрнең кул тамгалары куелган кәгазьдә генә сакланып калырга тиеш түгел. Аны тормышка ашырыр өчен конкрет гамәлләр кирәк. Моның өчен федераль дәрәҗәдә программа эшләнергә, аны тормышка ашыру юллары билгеләнергә тиеш. ТР президентының әлеге мәсьәләне күздә тоткан махсус карары бар инде. Әмма бу эш, әйткәнемчә, ике яклы булырга тиеш, чөнки үзара килешеп эшләү ике як өчен дә уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

Мине бүген милли мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләр бик нык борчый. Инде мәгълүм булганча, 2007 елның 1 декабрендә «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Канун кабул ителде. Ул, нигездә, дәүләт белем бирү стандартларына үзгәрешләр кертүне, милли-төбәк компонентын юкка чыгаруны күздә тота. Әлеге законны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә дәүләт белем бирү стандартларындагы үзгәрешләр Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеш хокукларын чикләүгә китерәчәк, туган телдә уку-укытуны киметәчәк. Бу шулай ук Татарстан мәктәпләрендә дә татар телен, әдәбиятын, татар халкының тарихын өйрәнү дәресләре кыскартылачак дигән сүз. Ә бит бу мәсьәлә бер Татарстанга гына кагылмый. Башка милли субъектлар да шул хәлдә калачак дигән сүз. Шуны күздә тотып, узган елның сентябрь аенда ТР Дәүләт Советы депутатлары РФ Президенты В. В. Путинга, РФ хөкүмәте Рәисе В. А. Зубковка, Федерация Советы Рәисе С. М. Мироновка, Дәүләт Думасы Рәисе Б. В. Грызловка, шулай ук РФ субъектларындагы дәүләт хакимияте органнарына әлеге мәсьәләне уңай хәл итүне сорап мөрәҗәгать юллады. ТР Дәүләт Советының мөрәҗәгатен РФнең 21 субъекты яклап чыкты. Кызганыч ки, безнең мөрәҗәгать Дәүләт Думасы һәм ил җитәкчелеге

тарафыннан игътибарга алынмады. Ә бит Россиянең күпмилләтле булуы – дәүләт җитәкчелегенә барча халыкларның да телләрен саклау, үстерү бурычын йөкли дигән сүз. Бу хәтта Россия Конституциясенең 68 нче маддәсендә дә беркетелгән. Шуңа күрә киләчәктә ике якның Мәгариф һәм фән министрлыклары арасында үзара килешү төзелергә тиеш дип саныйм, һәм анда төп, көнүзәк мәсьәлә булып, милли телдә уку-укыту проблемаларын хәл итү ятарга тиеш. Чөнки Мәскәүдән торып белем стандартларына үзгәрешләр кертү, субъектларда яшәүче милләтләрнең үз ана телендә уку мөмкинлекләрен чикләргә тырышуны һич тә аңлап бетереп булмый. Шуның өстенә Татарстан Конституциясенең 14 нче маддәсе республикадан читтә яшәүче милләттәшләребезнең мәнфәгатьләрен яклауны, аларның туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауны күздә тота. Әмма бу проблемаларны Татарстан үзе генә чишеп бетерә алмый. Без Шартнамәне әзерләгәндә Төп Канунныбыздагы әлеге маддәне аның эчтәлегенә дә салып куйдык. Ә яңа Шартнамә РФ законы буларак кабул ителде. Шуңа күрә Россия җитәкчелеге безнең читтә яшәүче милләттәшләребез язмышына битараф була алмый. Милләтләр сакланып калырга, алга таба да үсеш кичерергә тиеш. Россиянең көчле, кодрәтле дәүләт булуы анда яшәүче халыкларның, милләтләрнең хөрлектә, иркенлектә, муллыкта яшәвенә бәйле булачак.

Мине бүген татар теленең куллану даирәсе тараю да борчый. Россиядә сан ягыннан икенче урында булган татарларның тел, мәдәният мәсьәләсе бүген бик тә актуаль. Хәер, бу хәл бер татарларга гына кагылмый. Башка милләтләр – марилар, чувашлар, удмуртлар, калмыкларның һ. б. да хәле мөшкел. Узган ел Россиядә Рус теле елы дип игълан ителде. Рус теле турында федераль закон да дөнья күрде. Рус теленең дәрәҗәсе калган телләрне кысу бәрабәренә үсәргә тиешме? Һич тә юк! Без һәммәбез бертигез сакланырга, хокукларыбыз тигез булырга тиеш. Әгәр һәрдаим рус теленә генә өстенлек бирәбез һәм башка халыкларның телләренә күз йомабыз икән, ул чакта нинди күпмилләтле бердәм Россия турында сүз булырга мөмкин?! Бүгенге Россия дәүләте цивилизацияле юлдан атлауны, дөнья җәмәгатьчелеге алдында абруен күтәрүне максат итеп куйган икән, ул ил эчендәге халыкларның язмышына, аларның киләчәк үсешенә игътибарны арттырырга тиеш. Шуңа да РФнең яңа президентына теләгем шушы: ул күпмилләтле Россия дәүләтендә һәр милләт үзен ирекле-иркен, тулы хокуклы итеп һәм уңайлы хис итсен өчен барысын да эшләсен иде.

Соңгы арада татар-төрек лицейлары тирәсендә сүз бик нык куерды. Бу мәсьәлә хәтта Татарстан Дәүләт Советы сессиясенең көн тәртибенә дә кертелде, шактый тавыш-гауга тудырды. Ә, минемчә, куелган проблеманың асылына төшенү өчен, иң элек реаль хәл-халәткә күз салу кирәктер. Төрекләр безгә килеп, уртак уку йортлары оештырып, милли мәгариф системабызга яңа сулыш өрделәр. Әлеге уку йортлары ачылып күп вакыт та үтмәде, аларның абруе бермә-бер күтәрелде. Ни өченме? Чөнки алар белем бирү-укыту системасына үзләрендә булган уңай тәҗрибә белән яңалык керттеләр. Иң беренче эш итеп укытуның сыйфатын үзгәрттеләр. Бүген әлеге лицейлардан дүрт тел белгән, заман таләпләренә җавап бирерлек укучылар чыга икән, моннан кемгә зыян?! Республикабызның зыялы вәкилләрен арттыручы бу лицейларга рәхмәт кенә укыйсы бар. Һәм тагын бер генә нәрсәгә тукталасым килә. Аларның бездә дистә еллап эшләү дәверендә әлеге лицейларда бер генә тәртип бозу да, җинаять эшләре дә, ниндидер ЧПлар да булмады.

Ә аларны кайтарып җибәрүнең «сәбәбе» нәрсәдә дип уйлыйсыз? Янәсе, белем бирүгә дөрес таләпләр куелмый, дәреслекләре стандарт таләпләргә туры килми. Ә шул ук вакытта әлеге лицейларны тәмамлаучылар йөз процент югары уку йортларына укырга керә. Аң-белем дәрәҗәләре дә күпләрне көнләштерерлек.

Лицейны ябу бик җиңел эш, моның өчен хәтта янгын саклау идарәсеннән бер тапкыр килеп тикшерү, карар чыгару да җитә. (Мондый максат куелса, Россиядәге күпчелек мәктәпләрне бүген үк ябып булыр иде.) Ә нәтиҗәсе? Без бит киләчәктә югары интеллектуаль көч булырдай кешеләрнең өметле юлына киртә куябыз. Бүгенгә кадәр татар-төрек лицейларын тәмамлаган 1600 баланың берсе дә җинаять кылмаган, ә һәр ел саен үтә торган фән олимпиадаларында һәрдаим җиңү яулаган укучылар бит алар.

Ә төрек укытучыларының эштән китүенә аларның укыту-белем бирүгә квота алмауларын сәбәп итеп куюны, гомумән, аңламыйм. Чөнки бу эш белән укытучылар үзләре түгел, ә муниципаль хакимият органнары, Мәгариф министрлыгы шөгыльләнергә тиеш иде. Безнең системада очсыз-кырыйсыз бюрократик киртәләр, ерып чыккысыз лабиринтлар булуда төрек укытучыларының гаебе бармы соң? Демократик илдә мондый мәсьәләләр алай ордым-бәрдем юлы белән генә хәл ителергә тиеш түгел. Тик, ни кызганыч, 22 төрек укытучысы бүген, әлеге формаль таләпләргә буйсынып, яраткан хезмәтләрен ташлап, Россиядән туган илләренә кире кайтып китәргә мәҗбүр. Югыйсә ниятләре изге иде аларның. Казандагы укучылары төрек мөгаллимнәрен күз яшьләре белән озатып калдылар.

*«Татарстан» журналыннан*
*2008*

# БЕЗНЕ ТУГАН ТЕЛ ЯШӘТӘ

*17–18 ноябрьдә Россиянең мәгариф стандартларында милли-төбәк компонентын саклап калу максатыннан башкалабызда милли мәгариф проблемаларына багышланган илкүләм киңәшмә узачак. Киңәшмәне зурдан кубып үткәрергә җыеналар. Мондый сөйләшү күптән кирәк иде инде. Узган ел ахырында РФ Дәүләт Думасының, «Мәгариф турында»гы Законына үзгәрешләр кертеп, милли-төбәк компонентын юкка чыгаруы җәмәгатьчелектә зур борчу уятты. Инде бер ел буе, әлеге закон белән килешмичә, проблема уңай якка хәл ителер дигән өмет белән яшибез бит. Шушы мәсьәлә турында Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил ВӘЛИЕВ белән әңгәмә кордык.*

**– Разил Исмәгыйлевич, ишеткәнебезчә, конференция милли компонент язмышын хәл итәргә тиешле шәхесләрне җыячак. Шулай да анда кемнәр катнашыр икән?**

– РФ Дәүләт Думасының мәгариф һәм милли сәясәт комитетлары җитәкчеләре, Федерация Советы вәкилләре, Россиядәге 20 (!) милли республиканың мәгариф министрлары һәм парламент җитәкчеләре, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Россиянең мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко катнашуы көтелә.

**– Киңәшмәдә катнашучыларның бердәм булып милли-төбәк компоненты мәсьәләсен яклап чыгарына ышанасызмы?**

– «Өметсез – шайтан» диләр. Иң беренче булып бу мәсьәләне Төньяк Осетия парламенты күтәреп чыкты, аннан соң әлеге көрәшкә безнең республика һәм Башкортстан кушылды. Аларның һәммәсе мөрәҗәгатьләрен Россия җитәкчелегенә җибәрделәр. Безнең бу мөрәҗәгатьләрне барлыгы 21 субъект яклап карарлар кабул итте. Нигездә, алар милли республикалар. Шулай ук милли булмаган өлкәләр дә бар. Чөнки бу мәсьәлә барлык милләтләргә дә кагыла. Рус мәктәпләре өчен дә уңай күренеш түгел бу. Чөнки нәкъ менә төбәк һәм диннәр тарихын өйрәнү милли-төбәк компоненты аша хәл ителергә тиеш иде. Әгәр милли компонент мәсьәләсе хәл ителмәсә, әлеге фәннәрне өйрәнү дә шик астында калачак.

**– Җыенда бу компонентны кире кайтаруны ничек хәл итеп була соң?**

– Үз тәкъдимнәребез белән чыгачакбыз, моның өчен киңәшмәнең резолюция проектын да әзерләдек. Аны кабул итеп, ил җитәкчелегенә җиткерәчәкбез. Без бу мәсьәләне бары тик Россиянең «Мәгариф турындагы» Законына үзгәрешләр кертеп кенә чишеп була дип уйлыйбыз. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы милли телләрне, әдәбиятларны укытуны мәгариф стандартлары аша хәл кылырга тәкъдим итә. Ләкин аларның тәкъдим иткән вариантларында хәл киресен сөйли. Алар безгә 4 төрле вариант җибәрде. Шуларның 2 сендә туган телне укыту бөтенләй каралмаган, калган икесе исә безне бөтенләй канәгатьләндерми.

**– Киңәшмәдә тагын нинди мәсьәләләр күтәрергә җыенасыз?**

– Россиянең «Мәгариф турында»гы Законында «Бердәм дәүләт имтиханнары бары тик рус телендә генә тапшырылырга тиеш» дигән маддә барлыкка килде. Бу маддәне гамәлгә ашыру буенча РФ мәгариф һәм фән министрының әмере чыкты. Димәк, укучылар киләсе елдан башлап БДИны Россиядә бары тик рус телендә генә бирергә тиеш булачак. Без моның белән дә килешә алмыйбыз, чөнки үз ана телендә укып та, сынауны туган телендә тапшыру мөмкинлеге булмау мантыйкка туры килми. Әлбәттә, әлегә безнең республикада теләгәннәр имтиханны татар телендә дә бирә ала. Әгәр шушы закон гамәлгә керсә, Бердәм республика имтиханнары да бетәчәк. Бу мәсьәләне укытучыларның август киңәшмәсендә Минтимер Шәймиев РФ мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко алдында күтәреп чыкты һәм уңай җавап та алды. Әмма Россия Мәгариф һәм фән министрлыгыннан әлегә бер уңай хәбәр дә килгәне юк. БДИ нәтиҗәләрен үзебезнең республика вузлары гына кабул итә. Бу инде мәгариф өлкәсендә кеше хокукларын турыдан-туры бозу дигән сүз. Конституциядә һәм законнарда туган телдә белем алу хокукы хакында маддә бар икән, укучы имтиханны да үз ана телендә бирә алырга тиеш.

**– Республикада 14 район үзәгендә татар мәктәбе юк. Татар мәктәпләре ачарга нәрсә комачаулый соң?**

– Районнардагы җитәкчелекнең битарафлыгы, ваемсызлыгы комачаулый. Татарстанның әле күптән түгел генә кабул ителгән Дәүләт милли сәясәте турындагы концепциясен үтәмәүне аңлата бу. Ә концепция Президентыбыз указы белән дөньяга килгән. Аны үтәмәскә беребезнең дә хакы юк, ә инде хакимият башлыкларының бигрәк тә. Президент аларны бу хакта кисәтте. Бу хөкүмәт карарларында да чагылыш тапты, без аны алга таба да күз уңыннан ычкындырырга уйламыйбыз. Алдагы айларда җыелышып, әлеге районнарда татар мәктәпләре ачу хакында фикер алышачакбыз. Комитетның 19 ноябрьдә Буада узачак утырышында да әлеге проблемалар хакында сөйләшәчәкбез.

**– Мәктәпләрне оптимальләштерү нәтиҗәсендә шактый милли класслар юкка чыкты. Моның сәбәпләрен нәрсә белән аңлатыр идегез?**

– Оптимальләштерүне дөрес аңламаган кешеләр күбәйде. Аны кыскарту дип кенә кабул итәләр. Соңгы вакытта оптимальләштерү нәтиҗәсендә кайбер милли мәктәпләр һәм класслар ябылды. Бер мәктәпне икенчесенә кушканда да хаталар киткәләде. 90 нчы еллар башында, милли хәрәкәт җанланганда, шактый күп мәктәпләр ачкан идек. Аларга, нигездә, иске биналар бирелде, чөнки башкалары юк иде. Әйтик, мәхәлләдә ике мәктәп бар икән, шуның берсе заманча җиһазландырылган рус мәктәбе ди. Ә икенчесе – балалар бакчасы бинасында урнашкан татар мәктәбе. Әлбәттә, бу очракта ата-аналар яхшы белем бирү өчен затлырак мәктәпне сайлаячак. Башкалабызның Яңа Савин районында сыйфатлы белем алу өчен барлык шартлар тудырылган мәктәп ачылган икән, аның янында шундый мөмкинлектәге татар мәктәбе дә төзелергә тиеш. Мәсәлән, Түбән Камада, Әлмәттә татар гимназия-мәктәпләренә ата-аналар балаларын бик теләп бирә. Әгәр һәрбер районда мәктәпләрдә шартлар Казандагы 177 нче мәктәптәге кебек, ә белем бирү татар-төрек лицейларындагы шикелле булса, ата-аналар балаларын шунда укытачак. Аннары тагын бер мөһим нәрсә бар: кеше бит үзенә яшәү өчен, эшләү өчен кирәкле гамәлләр генә кылырга тырыша. Әгәр дә аңа тормышында татар теле кирәк түгел икән, ул аны өйрәнергә атлыгып тормый. Безгә иң беренче чиратта татар телен яшәү өчен кирәкле телгә әйләндерергә кирәк. Бу – иң мөһим бурыч.

**– Соңгы вакытта татар классларында да русча белем бирелә башлады. Безнең редакциябезгә, баламны туган телдә укытыр өчен, мәйданга чыгып, ачлык игълан итимме әллә, дип шылтыратучылар да бар. Аларга һич кенә дә акылы җиңеләйгән кешеләр дип карарга ярамый. Мондый милли җанлы ата-аналарны ничек тынычландырырга соң?**

– Безнең «Телләр турында»гы Законыбыз бар бит. 6 ел элек Дәүләт Советы административ хокук бозулар турында Кодекс кабул итте. Һәм аның 2 нче маддәсендә «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр» Законын бозганнарны җаваплылыкка тарту карала, диелә. Әлеге Закон бозылган очракта, иң беренче чиратта хакимияткә мөрәҗәгать итәргә кирәк, әгәр хакимият колак салмый икән, прокуратура, суд органнары бар. Без ул район яки шәһәр җитәкчеләренә законда нәрсә каралганын, аның ничек үтәлергә тиешлеген аңлатыр идек. Дөрес, ул исенә төшерү белән йөгереп китеп барысын да эшләр дип әйтеп булмый. Әмма ләкин барыбер файдасы сизеләчәк. Әле үткән ел гына Татарстанда 17 район үзәгендә татар мәктәбе юк иде, быел бу сан 14 кә калды.

**– Димәк, кеше үз хокукларын белми булып чыга?**

– Исләренә төшерергә кирәк шул. Татарстанда ике миллион татар бар, ләкин шуларның берсенең дә тел өлкәсендәге үз хокукларын яклап судка мөрәҗәгать иткәне юк. Булды шундый бер хәл: «Корстон» күңел ачу үзәгендәгеләр үз белдерүләрен инглиз телендә язып элгәннәр. Бер ватандашыбыз прокуратурага язгач, алар аны татар һәм рус телләрендә язарга мәҗбүр булдылар. Кеше активлык күрсәтсә, аның нәтиҗәсе булачак. Киңәшмәдә әле телгә алган барлык проблемаларны күтәреп, аларның, бигрәк тә милли-төбәк компонентын кире кайтаруның чишелешен таба алырбыз дип ышанам.

*Әңгәмәдәш Сәрия Садрисламова*
*2008*

# ТАЛАНТ ХОДАЙ ТАРАФЫННАН ГЫНА БИРЕЛӘ

**– Сез тормышта ни өчен нәкъ менә язучы булып киттегез икән?**
– Кешеләргә әйтер сүзем, җиткерәсе фикерем булганнандыр дип уйлыйм.
Малай чакта күз төшкән кызларга хисләремне җиткерер өчен иң үтемле ысулның шигырь икәнен аңлагач, мин үземә яңа бер тылсымлы дөнья ачкан кебек булдым. Бәйрәм көннәрендә үзенә атап язылган котлау шигыре укыгач, әнкәйнең күз яшьләрен күрү дә мине аптырашта калдырган иде. Тора-бара мин үземнең соклануым һәм мәхәббәтемне дә, борчу-сагышларым һәм нәфрәтләремне дә шигырь калыбына салып дөньяга чыгарырга өйрәндем, һәм бүген дә мин шигъриятнең бер канаты мәхәббәт булса, икенчесе нәфрәттән гыйбарәттер дип саныйм. Дөньяда ак белән кара, яхшылык белән яманлык яшәгән чакта, ул һәрвакыт шулай булачак!
Шигырь яза башлавыма иң әүвәле әнкәй белән Такташ сәбәпче булгандыр дип уйлыйм. Әнкәй авылның оста бәет чыгаручысы иде, мин студент вакытта хатларын да бик еш кына шигырь белән яза иде. Ә Такташ шигырьләрен мин, апалар ятлаганда тыңлап торып, инде биш яшьтә чакта ук күңелгә сеңдергән идем. Яңа ел бәйрәмендә мәктәптә урындыкка бастырып «Мокамай»ны укытканнары әле дә күз алдымда тора. Ә Тукайга ул чакта теш үтмәгәндер инде, мин аңа соңрак килдем, юк, әле һаман бөтенләе белән килеп җитә алмадым бугай...
**– Язучылык таланты Ходайдан биреләме, әллә...**
– Талант бары тик Ходай тарафыннан гына бирелә дип исәплим мин. Күпмедер сәләтең булып, яши-яши, яза-яза нindидер осталыкка ирешсәң дә, Ходай биргән талантың булмаса, син барыбер илаһи биеклеккә күтәрелә алмыйсың. Андый чакта инде том-том китаплар чыгару да, өсте-өстенә премия алулар да синең рухыңа канәгатьлек китерми. Киресенчә, тора-бара илаһи иҗат синең өчен гадәти бер эшкә генә әверелә башлый. Чын шигырь, минемчә, гади каләм белән түгел, ә фәрештә каурые белән язылырга тиеш. Маңгай тире түгеп язылган, һәр сүзенә тир исе сеңгән әсәрләрне, күпме генә хис һәм фикер өелсә дә, күңел кабул итә алмый. Ә инде татарның телен-сүзләрен белеп тә, аның җан авазына-моңына төшенмәгән кешедән берчакта да чын шагыйрь чыкмый. Әмма, ни кызганыч, башкалар күреп-сизеп торса да, гадәттә, ул моны үзе аңлый алмый. Ә бу инде иҗат кешесе өчен чын мәгънәсендә фаҗига!
**– Әсәрнең герое авторның үзеннән дә акыллырак, өстенрәк булырга мөмкинме?**
– Кеше беркайчан да үзеннән акыллырак була алмый. Дөрес, тормышта үзеннән акыллырак кеше ролен уйнаучылар да шактый күп очрый. Әмма бу алдау-алдану озакка бармый, аның барыбер чын йөзе ачылып, ул барыбер кайчандыр үз бәясен ала. Әдәбиятның, иҗат әһеленең иң зур көче аның ихласлыгында, үзе булып кала алуындадыр. Әмма моның өчен иң элек зур, кызыклы, бай шәхес булу кирәк. Югыйсә хәерче күңелеңне, фәкыйрь җаныңны ихласлык белән дөньяга ачып күрсәтүдән ни мәгънә?! Менә шуңа күрә дә кайберәүләр гомере буена үзеннән акыллырак, үзеннән талантлырак кеше ролен уйнарга тырыша да инде. Бәгъзе затлар шактый уңышка да ирешә... Ә монысы инде башка талант.
**– Берәүләр – аз, икенчеләр күп яза. Моның сәбәпләре нәрсәдә?..**
– Аз яисә күп язу иҗат кешесе өчен талантны үлчәү берәмлеге, критерий була алмый. Мәсәлән, Дәрдемәнд нибарысы җиде йөз юл чамасы шигырь язган. Ә мин аның бер «Кораб» шигырен кайберәүләрнең әллә ничә том әсәренә алышмас идем. Эш санда түгел, сыйфатта! Дөрес, талантлы кеше күбрәк, ә талантсызлар азрак язса, бик шәп булыр иде дә бит. Кызганыч, күп очракта шуның киресе килеп чыга...
**– Киләчәктә язучылык эшенең дәрәҗәсе түбәнгә төшмәс микән?**
– Безнең җәмгыятьтә, элекке чорлар, хәтта совет чоры белән чагыштырганда, әдәбиятның дәрәҗәсе шактый түбән төште. Мин моны иң беренче чиратта дөньяның, тормышыбызның көннән-көн матдиләшә баруыннан күрер идем. Соңгы елларда җәмгыятебезнең рухи дөньясы

саегып, әхлак киртәләре җимерелеп, кешеләр рухи ориентирлардан битәр күбрәк матди байлыклардан ләззәт эзли башладылар. Илһамлы сүзнең көче-куәте кимемәсә дә, аны тыңларга, ишетергә сәләтле затлар, сафлар сирәгәйде. Моның сәбәбе нәрсәдә? Моның өчен кемне гаепләргә? Гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр. Әмма шунысына иманым камил: илаһи сүзне, илаһи фикерне санга сукмаган, рухи кыйбласын югалткан җәмгыятьнең киләчәге юк!
Киләчәктә язучылык эшенең дәрәҗәсе төшмәсен өчен безнең бер генә юлыбыз бар: ул да булса югары дәрәҗәдәге талантлы әсәрләр язу! Язучы, әдип заманга яраклашам дип үзе түбән төшмәсә, укучы барыбер аның биеклегенә күтәрелергә омтылачак! Бүген булмаса – иртәгә, иртәгә булмаса, берсекөнгә омтылачак. Ходай Тәгалә кешене җирдә яшәп, күккә, өстәгеләргә табыну өчен яраткан. Мин моның киләчәктә дә шулай буласына ышанам! Ә моңа ышанмасаң, җирдә яшәвеңнең дә, әсәрләр язуыңның да мәгънәсе шулкадәр генә.

*Әңгәмәдәш Рашат Низами*
*2008*

# БЕЗ ӘЛЕ КАЯ БАРАБЫЗ?

**– Габдулла Тукай, кая барырга, ни эшләргә белмичәрәк аптырап торган чагында: «Мин әле кая барам?» – дияргә яраткан. Дуслары да бөек шагыйрьне нәкъ менә әлеге сүзләрен кабатлап үртәгәннәр. Әмма бүген мондый сорауны биргәндә, һич кенә дә көләсе, шаярасы килми. Соңгы вакытларда татарның милли рухы өлкәсендә артка чигенүләр шактый булды һәм хәзер дә дәвам итә. Киләчәктә безне ни көтә? Без әле кая барабыз?**
**Май азагында IV чакырылыш ТР Дәүләт Советының III утырышы узды, һәм көн тәртибендәге иң мөһим мәсьәлә Татарстан бюджетына үзгәрешләр кертү турында иде. Сез үз чыгышыгызда, борчылып: «Иң зур кризис – рухи кризис», – дип белдердегез. Бүген татарның рухи халәтен ничек бәяләр идегез?**
– Бүгенге көндә финанс-икътисад кризисы дип күп сөйлибез. Бу, чыннан да, шулай. Бер бездә генә түгел, бөтен дөнья халкы аның авырлыкларын татый. Мондый чорда оптимистик сүзләр сөйләү һәм нидер таләп итү дә урынсыз сыман. Әмма әйтмичә дә булмый. Әйе, икътисад, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр, милли сәясәт, мәгариф, мәдәният – һәммәсе дә бердәй яклауга мохтаҗ. Ләкин нигәдер бездә аның матди ягын гына күрәләр. Иң зур кризис ул – рухи кризис. Шул хакта сүз әйткән кеше юк. Сессиядә ясаган чыгышымда да мин нәкъ менә шуны аңлатырга тырышкан идем. Әгәр дә кешенең рухы, күңеле сына икән, аның кулыннан эш төшә, һәм ул икътисади кризистан да тиз генә чыга алмаячак. Моннан ничек котылырга? Рухи якка игътибарны көчәйтмәсәк, белмим, алда безне ни көтәр икән?! Бу уңайдан Мәскәүгә дә тәкъдим белән чыгып карадык. Хәтерләсәгез, илкүләм өстенлекле биш проект кабул ителде. Без шунда мәдәниятне дә кертмәкче идек. Әмма моны кирәк санамадылар. Шулай да гел Мәскәүне генә сүгеп утыру дөрес үк булмас. Алар безнең мәшәкатьләрне кайгыртырга артык ашкынып тормый. Шуңа үз мәнфәгатьләребезне үзебез кайгыртырга тиешбез.
Моннан утыз еллар элек, ягъни торгынлык чорында да, матбугатыбызда милләт хакындагы проблемаларыбызны зурдан кубып күтәреп чыккан саллы мәкаләләр дөнья күрә иде. Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Мирсәй Әмир һәм башка язучыларыбыз һәрчак үз сүзләрен әйтә килде. Габдулла Шамуковның Сөембикә манарасы хакындагы язмасы төрмәгә утыртырлык иде. Әле ярамаган чакта! Россия матбугатында да кыю язмалар шактый күренде. Фатих Хөснинең «Литературная газета»да татар әдәбияты турында зур мәкаләләр белән чыкканын хәтерлим. Кайда алар бүген? Хәзер, бастырам дисәң дә, андый мәкаләләрне китерүче юк бит! Халык нишләптер соңгы вакытта бик пассив. Рухи ихтыяҗлар кимеде. «Рухсызлык заманы киләме икән әллә?» – дип куркып уйланган чаклар да бар. Рухсызлык идеологиясен алга сөрә торгач, үзебез дә шундыйга әйләнә башладык, ахры. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә зурдан кубып милли тәрбиягә тотынмасак, киләчәк тагын да начаррак булырга мөмкин. Моңа кадәр һәрчак: «Татар инде ул китаплы, мәгърифәтле, матбугатлы халык», – дип горурланып, шуның белән юанып яшәдек. «Шуңа исән калганбыз», – дип мактанышабыз. Әгәр инде шулар да бетсә, нәрсә булыр?! Дәүләте булмаган халыкны рух тота. Вакытында тиешле чараларны күрмәсәк, милләтебезнең язмышын аянычлы нәтиҗәләр көтә.
**– Татар әдәбиятының мең елдан артык тарихы бар дип күп сөйлибез. Татар китабының торышы ни хәлдә? Аның чыкмаганына борчылган кеше бармы?**
– Ел башыннан бүгенге көнгә кадәр Татарстан китап нәшриятында нибары бер генә китап басылып чыкты. Сессиядәге чыгышымнан соң мин язучыларга мөрәҗәгать иттем: «Әйдәгез, сез дә бераз кымшаныгыз, күтәреп чыгыгыз инде? Нигә сез битараф?» Әлегә аларның күзгә ташланырлык гамәл кылганнары юк. Быел бюджетта ике китап нәшрияты өчен 46 миллион сум акча каралган иде. Шуның 20 миллионы, ягъни 40 проценты кисеп ташланды. Бу бит беркайда да күрелмәгән хәл! Димәк, акча бары тик китапны әзерләүгә һәм коммуналь чыгымнар өчен түләүгә генә бирелә. Китап бастырырга исә акча бөтенләй юк. Бу хәлгә язучы гына түгел, китапны укучы һәм файдаланучы да борчылырга тиеш...

**– Безнең бит хәзер бар борчуларыбыз, шатлык-кайгыларыбыз Татарстанның спорт командалары белән бәйле. Түрәләребез авызыннан: «Менә китап укымыйча да кеше булдым әле», – дигән сүзләр яңгыраганда, китапка, әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт уяту һәм хөрмәт-ихтирамны арттыру мөмкинме икән? Югыйсә спорттан нинди культ ясый алдык бит?! Бүген хоккейчыларны, футболчыларны белмәгән әби-бабайлар республикада бармак белән генә санарлык калгандыр...**

– Татар мәдәниятен алга җибәрүнең шулхәтле җиңел юлы бар. Биш елда бөтен дөньяга күренергә була. Минем бу хакта җитәкчеләргә дә әйткәнем бар. «Ничек?» – диләр. Әйдәгез, бер миллион долларга француз язучысын сатып алабыз! Шуңа татарның Мөхәммәтҗаннары, Шакирлары, Зәйнәпләре турында яздырттырабыз. Испанлы, италияле музыкантларга акча түләп көй яздырыйк, Кытайдан булса, тагын да яхшырак. Менә шуларның әсәрләренә, җырларына татарча исемнәр куеп, дөньяга чыгарабыз. «Юк, әдәбият-сәнгать өлкәсендә алай ярамый», – диләр.

Әдәбият-сәнгать культы дигәннән, бер мисал китерим әле. Америка президенты ел саен парламент каршында хисап тота. Бу – берничә илгә хас күренеш. Ул анда быел ничә тапкыр музейда, китапханәдә булуы, нинди китаплар укуы – шулар хакында да сөйли. Мин район җитәкчеләренә: «Нишләп сез китап сәүдәсен оештырмыйсыз, китапханәләр торышы белән кызыксынмыйсыз, мәдәният йортлары, мәгарифкә игътибар бирмисез?» – дип еш әйтәм. «Разил туган, бездән бит аны сораган кеше юк. Күпме сөт савып алынуын, нихәтле ашлама кертелүен, ничә баш сыер, дуңгыз, сарык барлыгын гына сорыйлар», – диләр. Рухи дөньяга таләп Россия күләмендә гадәткә кермәгән әле. Җитәкчеләрне эшкә алганда, аларның профессиональ осталыкларыннан тыш рухи дөньясын да сынарга иде. Бер бөек кешенең әйткән сүзләре бар: «Теләсә кайсы җәмгыятьнең төп продукциясе, товары булып ул илдә җитештерелгән, әйтик, самолёт та, автомобиль дә, суднолар да түгел, ә кеше тора». Заманында Азнакай районы хакимият башлыгы булып татар теле бүлеген тәмамлаган Әнәс Исхаков эшләде. Ничек инде татар теле белгече моны башкара алсын, дип, бик аптыраган идем. Әмма ул чакларда район гөрләп торды. Ул, бәлки, агрономияне, терлекчелекне, төзелешне яхшы белмәгәндер дә. Ләкин Әнәс Исхаков кешенең җанын аңлый, килешеп эшли белә иде.

Алдагы буыннар турында кайгырту ул – мәгарифкә, фәнгә, мәдәнияткә мөрәҗәгать итү. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң җимерелеп беткән Германия, атом бомбасы ташланган Япония егерме елда иң алдынгы илләр рәтенә басты. Әгәр шул илләрдә алар трай тибеп, туп артыннан куып йөргән булсалар, белмим, кая барып чыгарлар иде икән?! Иң беренче чиратта алар мәгариф, фән һәм мәдәният турындагы программалар кабул иттеләр. Димәк, алар милләтнең киләчәге турында ныклап уйланганнар.

Әдәбият-сәнгать яхшылыкка, матурлыкка өнди. Аның тәэсире искиткеч зур. Минем бер өметем бар әле. Безнең президентыбыз тәкъдиме белән Татарстанда мәгарифне үстерү буенча дәүләт программасының проекты эшләнә башлады. Ул 2010–2015 елларга каралган. Көз көне Дәүләт Советына керер дип уйлыйбыз. Моңарчы президент программалары уңышлы үтәлеп килде.

Ул проектны киңәйтеп, матбугат, сәнгать, милли мәдәниятне үстерүгә дә игътибарны арттырасы иде. Матбугат өлкәсен генә алыйк. Совет чорында газета-журналларга көчләп яздырдылар. Бу аңлашыла да, чөнки дәүләт идеологиясе булырга тиеш. Ул гомер-гомергә барган. Карл Маркcның: «Дәүләт – басым ясау органы», – дигән сүзләре бар. Бүген Татарстанда дүрт меңгә якын китапханә, меңләгән дәүләт учреждениеләренең һәммәсе языла икән, дәүләт матбагаларының тиражы бермә-бер артыр иде. Безнең республика ярлы түгел, тик матбугатның хәленә керүне кирәк санамыйлар. Димәк, басым ясалырга тиеш. Яңа мәгариф стандартларының беренче вариантларында «туган телне һәм әдәбиятны укыту ирекле» диелгән иде. Ягъни факультатив укытылачак дигән сүз. Моның белән катгый килешмәдек. Безгә: «Димәк, сезнең балаларыгыз үз телләрен өйрәнергә теләми?» – диделәр. Тәрбия ул теләктән генә тормый. Юнәлеш тә булу мөһим. Ни өчен, геометрия, чит тел, рус теле мәҗбүри? Әйдәгез, аларны да ирекле итик. Шулай була калса, илле процент бала, мөгаен, бер дәрескә дә йөрмәс иде.

Бүген иң төп проблема – милли мәгариф өлкәсендә. Безнең Комитетның җитмеш биш процент эше дә шуларны хәл итүдән гыйбарәт...

**– Инде быел Бердәм дәүләт имтиханнарын да рус телендә тапшыра башладык...**
Ул – бүгенге көндәге милли сәясәт. Аның белән көрәшү җиңел түгел. Әмма кул кушырып утырырга да җыенмыйбыз. Ни өчен Россиянең Югары мәхкәмәсендә БДИны судка биргән Аида Камалова җиңеп чыга алмады? Моннан ике ел элек Россия мәгариф законына бер үзгәреш кертелгән иде. 2007 елга хәтле Россиядә мәҗбүри белем бирү тугыз сыйныф дәрәҗәсендә саналды. Ягъни тугызынчы сыйныфтан соң бала мәктәптән китә дә алды. Теләсә, техникумга керә яисә бөтенләй укымаска да мөмкин иде. Хәзер исә мәҗбүри белемне унбер сыйныфка кадәр күтәрделәр. Әмма Россиянең шул ук мәгариф законында 6 нчы маддә бар. Ул уку-укытуның теле турында. Анысы элек тә тугыз сыйныфка кадәр иде, хәзер дә шулай калды. Минем: «Ни өчен анысын да унберенче сыйныфка кадәр күтәрмәдегез?» – дигән соравыма җавап бик гади булды: «Истән чыгарганбыз». РФ Конституциясендә «Россиядәге бөтен телләр дә тигез» дип язылган. Әгәр дә шушы 6 нчы маддәдә милли белем бирү унберенче сыйныфка кадәр калса, судта җиңеп булачак иде. Бүгенге көндә шул 6 нчы маддәгә үзгәрешләр кертү белән шөгыльләнәбез. Минемчә, шуңа ирешә алсак, БДИ өлкәсендә җиңү яулавыбыз да ихтимал. Аңа без генә каршы түгел. БДИны Россия Федерациясе рәисе Сергей Миронов та, күп кенә депутатлар да хупламый. БДИны үз туган телебездә бирә алу хокукын азакка кадәр якларга тиешбез. Хәтта халыкара судларга барып җитәргә мөмкин...

**– Татарстанда, башкалабыз Казанда дөньякүләм әһәмиятле вакыйгалар бер-берсен алыштырып кына тора. Шулар шаукымында милли мәсьәләләрне хәл итүгә вакыт калмый кебек...**

– Нигездә, мин ул чараларга каршы түгел. Тик алар безнең халыкка файда китерәме? Милли сәнгатебез, милли үзенчәлекләребез чагыламы? Алар татар халкы үсешенә этәргеч бирәме? Без бит гел кешене генә карап утыра алмыйбыз, үзебезне дә күрсәтергә тиешбез. Сәхнәдә, стадионда татар юк икән, ул чараларның әһәмияте нидә? Инде суверенлыкка яңа һөҗүм башланды. 8–9 ел бу мәсьәләдә бераз тынычлык иде. Димәк, Россиядә ниндидер проблемалар, шөбһәләнү бар. Мин моны «шөрепләрне кысу», кулга җыю дип бәялим. Кризис, Кавказдагы хәлләр дә борчу өстәгәндер. Җитәкчеләр дә баш калкытып алды: Мортаза Рәхимовның чыгышы да хафага салгандыр. Безнең җитәкчеләр дә үзләренең принципиаль сүзләрен гел әйтеп киләләр. Суверенлык турындагы маддәне Конституциядән алып ташлау җиңел түгел, ул бары тик референдум юлы белән генә үзгәртелә ала. Бу РФ Конституциясенең 123 нче маддәсендә язылган. Татарстан Конституциясе бер дә бәйләнерлек түгел. Менә мин үземнең өемдә яшим. Телим – тәрәзә ачам, телим икән – ремонт ясыйм. Миңа каршы килергә беркемнең дә хакы юк. Менә бу – минем суверенлыгым. Әгәр дә подъездга, урамга чыгам икән, суверенлыгым кими. Без дә республикада үз өебездәге кебек суверен булырга тиеш. Кызганыч, бу мәсьәләдә башка милли республикалар белән бердәм эш итә алмадык. Ярый әле милли компонентлар буенча уртак фикергә килдек. Билгеле, бүгенге көндә мәсьәлә хәл ителеп бетмәгән. Әмма Мәскәү даирәләре шактый артка чигенде. Безне ишетә, тыңлый башладылар. Минемчә, барысы да милли мәгарифтән тора. Иң беренче чиратта милли мәктәпләрне сакларга иде...

**– Шундый авыр шартларда татарның яңа элитасын булдыру һәм саклау мөмкин эшме? Милли интеллигенция тәрбияли алсак, бәлки, әлеге проблемаларны хәл иткәндә таяныр шәхесләребез күбрәк булыр иде?**

– Без шәркый рухта тәрбияләнгән халык. Олыларга хөрмәт күрсәтү, аларга иярү һәр татар кешесенә диярлек хас. Заманында премьер-министр вазифасын башкарган Мөхәммәт Сабиров эшкә грузинныкына охшаган фуражка киеп килгән иде. Бер айдан соң сессия булды. Ни дип уйлыйсыз? Бөтен хакимият башлыклары да шундый фуражкадан килгән! Әгәр дә бүгенге көндә һәрбер хакимият башлыгының өстәлендә татар газеталары ятса, иң беренче чиратта шуларны укыса, бәясен бирсә, фикерен белдерсә, аңа калганнар да иярәчәк. Ләкин бик сирәгенең генә өстәлендә татар газетасын очратырга була. Җитәкчеләр үрнәк күрсәтергә тиеш. Бик күп нәрсә алардан башлана. Соңгы елларда халкыбызның милли аңы шактый сүлпәнәйде, интеллигенция катлавы бик юкарды. Юкса милли аң дәрәҗәсе ярдәмендә генә зур уңышлар хакында хыялланырга мөмкин икәнлеген һәркем белә. Җитәкчелек тә, гади халык та...

Габдулла Тукайның 1908 елда язылган «Өмид» шигырендә: «...Мин әле кая барам? – җуйган эзем таптырмасаң», – дигән юллар бар. Әгәр бүгенге рухи халәтебез торышы турында уйланмасак, дәүләт күләмендә аңа әһәмият бирелмәсә, бу сорауга җавап табу, ай-һай, көннән-көн кыенлаша гына барачак...

*Әңгәмәдәш Рөстәм Галиуллин*
*2009*

# СӨЙЛӘШӘБЕЗ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

*Шушы көннәрдә Мәскәүдә «Россия Федерациясендә күптеллелек: проблемалар һәм аларны хәл итү юллары» турында зурдан кубып сөйләшү булды. Әлеге чара безгә нинди үзгәрешләр китерәчәк, соңгы елларда катлаулана барган туган тел, милли мәктәп язмышын нәрсә көтә? Бу хакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев белән әңгәмә корырга уйладык.*

– **Разил Исмәгыйлевич, тел, мәгариф, фән проблемаларын үз эченә алган бу зур чарада сез дә катнашкансыз, алай гына да түгел, Татарстан исеменнән чыгыш та ясагансыз. Бу хакта безгә дә сөйләсәгез иде.**

– Россия Дәүләт Думасының «Россия Федерациясендә күптеллелек: проблемалар һәм аларны хәл итү юллары» дигән темага парламент тыңлаулары иде бу. Без моны күптән көттек. Чөнки бүген күпмилләтле Россиядә тел мәсьәләләре белән шөгыльләнү югары дәрәҗәдә куелмаган. Югыйсә 2002 елдагы халык саны алу нәтиҗәләре буенча дәүләттә барлыгы 182 милләт һәм актив кулланылышта булган 147 тел бар дип санала. Күптелле дәүләтләр арасында Россия Европада беренче урында тора. Хәзерге вакытта телләр проблемасы көннән-көн кискенләшә барса да, аның белән җиң сызганып шөгыльләнүче дәүләт структурасы бөтенләй юк. Бер караганда, барысы да әйбәт шикелле. «Россия телләре турында» Законда, «Мәгариф» Законында «туган телдә укырга мөмкин» дигән статьялар бар. Бары тик тормышка гына ашыр. Конституциянең 68 нче статьясында Россиядә телләрне үстерү гарантияләнә. Әмма шул ук вакытта 309 нчы законны кабул итеп, милли-төбәк компонентын алып ташладылар. Милли мәктәпләр кимеде, Бердәм дәүләт имтиханын туган телдә бирүне тыйдылар. Шундый шартларда ничек итеп телләрне үстереп була икән соң ул?

– **Аңлавымча, сез үзегезнең чыгышыгызда 309 нчы закон кабул ителгәннән бирле Татарстанда һәм башка милли республикаларда килеп туган ыгы-зыгы турында сөйләп киткәнсез...**

– Бу парламент тыңлауларында бөтен Россия төбәкләре катнашты. Шулай ук 21 милли республикадан да вәкилләр килгән иде. Мин дә ун минуттан артык чыгыш ясадым. Ни кызганыч, чыгыш ясаучыларның күбесе: «Бездә проблема юк, барысы да әйбәт», – дигәнрәк фикерне алга сөрделәр. Мин моның белән килешә алмадым, билгеле. 2011 елның 1 сентябреннән 309 нчы закон гамәлгә керергә торганда, ничек инде барысы да ал да гөл булырга мөмкин?! Дөрес, соңгы елларда президентыбыз, хөкүмәтебез, парламентыбыз Россия җитәкчелегенә кат-кат рәсми мөрәҗәгатьләрен юллады. Казанда, Россия Дәүләт Думасыннан, Мәгариф министрлыгыннан, милли республикалардан җитәкчеләрне, депутатларны чакырып, зур киңәшмә үткәрдек. Шуларның нәтиҗәсе буларак, 309 нчы законга бераз үзгәреш кертелде. Анда «Мәгариф стандартын төзегәндә, милли үзенчәлекләрне искә алырга» дигән бер статья барлыкка килде. Ләкин аны хәлиткеч статья дип әйтә алмыйм. Билгеле, милли мәгарифкә күпмедер мөмкинлекләр бирелә кебек. Әмма без бу статьяның аныграк булуын теләгән идек. Моңа кадәр бит Россия мәгариф стандартлары өч өлештән тора иде. Беренчесе – федераль компонент (75 %), икенчесе – милли-төбәк компоненты (15%), өченчесе исә мәктәп компоненты. Әлеге унбиш процентны тәшкил итүче стандартны Татарстан Мәгариф министрлыгы моңа кадәр үзе әзерләп, мәктәпләргә тапшыра иде. Менә шулай матур гына татар халкы тарихын, туган телебезне, әдәбиятыбызны укытып ятканда, бу мөмкинлегебезне дә тартып алдылар. Хәзер инде мәскәүләр, туган телеңне бер сәгать укытырга кирәк, дип әйтәләр икән, син инде монда беркая да бара алмаячаксың. 309 нчы законга үзгәрешләр кертү буенча үзебезнең таләпләребезне тәкъдим иткән идек. Менә шул мөрәҗәгатебездән соң безне Россиянең 20 дән артык субъекты яклап чыкты. Мәгариф стандартының бүген беренчедән алып дүртенче сыйныфка кадәрге өлеше расланды. Әйтергә кирәк, анда безнең теләкләрнең шактые искә алынды. Яңа стандарт буенча башлангыч мәктәптә рус теле белән татар телен тигез күләмдә укытырга хакыбыз бар. Әмма моны да бик хәйләкәр эшләделәр. Бүген яңа стандартлар нигезендә уку-укыту планы төзелә. Әлеге планда

мәктәпләргә укыту өчен өч төрле вариант бирелә. Беренчесендә, мәсәлән, татар телен атнага – бер, икенчесендә – өч, ә өченчесендә биш сәгать укытырга кирәк, диелә. Шушы вариантларның берсен мәктәп үзе сайлап алырга тиеш. Әгәр мәктәп директоры татар теленә бигүк мөкиббән китмәсә, район җитәкчеләре туган телебезгә битараф булса (кызганыч, андый кешеләр бик күп), иң начар вариантның гамәлгә керүе мөмкин.

– **Димәк, алар белән көрәшергә туры киләчәк...**

– Әлбәттә, без иң яхшы вариантны сайлап алу ягында һәм аны тормышка ашырырга тырышачакбыз да. Моның өчен безнең законлы нигезебез дә бар. Чөнки 2004 елда Хапугин дигән бер иптәш Россиянең Конституцион судына: «Балама татар телен укытырга теләмим. Ә Татарстан законнары рус һәм татар телләренең бертигез күләмдә укытуны таләп итә. Бу Россия Конституциясенә туры киләме?» – дип мөрәҗәгать иткән иде. Без әлеге судта катнашып, җиңеп чыктык. Татарстанда ике дәүләт телен бертигез күләмдә укыту турындагы закон Россия Конституциясенә каршы килми икәнлеген исбат иттек. Конституцион судның шушы карарына таянып, Татарстанда рус һәм татар телләрен бертигез күләмдә укытуны таләп итәчәкбез.

**– Бу закон фәкать Татарстан өчен генә каралган бит, ә чит төбәктәге милләттәшләребезне нәрсә көтә?**

– Әйе, бу Татарстанга, милли республикаларга гына хас булачак. Читтә исә мәсьәлә бик тә катлаулы булырга охшый. Аларда укыту стандартының иң начар вариантын сайлап алулары да мөмкин. Атнага бер сәгать ана телен укыту белән генә милли мәктәпләрне, милли мәгарифне саклап калу авыр булачак.

– **Чыгышыгызда Бердәм дәүләт имтиханнары хакында да сүз кузгаткансыз икән. Сүз дә юк, бүген мәктәп укучысының рус телендә генә имтихан тапшыруы милли мәктәпләрнең саны азаюга китерәчәк ләбаса.**

– Чыннан да, Бердәм дәүләт имтиханнарының рус телендә генә бирелүе бернинди кысаларга да сыймый. Россия Конституциясенең 26 нчы статьясы, Россиянең мәгариф, телләр турындагы законнары бар. Монда «һәрбер кеше үзенең туган телендә белем алырга хокуклы» диелгән. Әгәр кеше ана телендә укырга хокуклы икән, Бердәм дәүләт имтиханы туган телдә белем алуның соңгы баскычы бит инде. Без әлеге документны кешенең мәгариф өлкәсендәге хокукларын боза торган закон дип саныйбыз. Моңа һәрвакыт каршы килдек, моннан соң да каршы булачакбыз. Безнең бу «баш күтәрү»ебездән соң Россия Дәүләт Думасында «эшче төркем» оешты. Әлеге төркем бу хакта бүген дә бәхәс куерта. Ә Бердәм дәүләт имтиханының рус телендә бирелүе безнең республика таләпләренә, милли мәнфәгатьләргә туры килмәвен үз чыгышымда да әйтеп киттем.

**– Парламент киңәшмәсендә Европа Хартиясе турында да сөйләнелгән. Әйтегез әле, телне, мәгариф өлкәсен саклауда Хартиянең безгә файдасы бармы?**

– Дәүләт Думасының Халыкара мөнәсәбәтләр буенча комитет рәисе Константин Косачев Төбәк телләре һәм азчылык телләр Хартиясе хакында чыгыш ясады. Бу Европа Хартиясе 1992 елда ук Европа Советы тарафыннан әзерләнгән һәм аңа 2001 елда Россия Президенты кул куйган. Әмма әлеге Хартия бүгенге көнгә кадәр ратификацияләнмәгән, ягъни Россия Дәүләт Думасы тарафыннан расланмаган, һәм ул безгә аның ни өчен расланмавын дәлилләргә тырышты. Мин аның чыгышыннан шуны аңладым: Россия Дәүләт Думасы депутаты Хартияне ничек итеп ратификацияләү түгел, ә ничек ратификацияләмәү турында уйлый. «Бездә, башка илләр белән чагыштырганда, милләтләр саны бик күп. Шуңа күрә әлеге Хартияне гамәлгә ашыру бик катлаулы», – дип акланырга тырышты К. Косачев. «Россиядәге төрле милләт вәкилләренең мәнфәгатьләрен кайгыртмагач, аларны нәрсәгә бер түбә астына җыярга кирәк иде соң?» – дигән сорау белән мөрәҗәгать иттем мин. Россияне Европа Советына әлеге Хартияне ратификацияләү шарты белән генә кабул иткәннәр иде. Европа Советына керүенә инде менә тугыз ел узды, ләкин бернинди дә үзгәреш сизелми. Әмма безнең бу ратификациягә өметебез бик зур. Әгәр ул Хартия гамәлгә керсә, без телләрне халыкара таләпләр, Европа стандартлары буенча үстерергә тиеш булачакбыз. Аның аерым программалары төзеләчәк, һәм безнең мәгариф, тел өлкәләрендәге эшләребез шактый җиңеләячәк.

*Әңгәмәдәш Алсу Хәсәнова*
*2010*

# ҮЗГӘРЕШЛӘР АҢДА БАШЛАНЫРГА ТИЕШ

**– Үтеп киткән елның 25 мартында Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасы Президенты булды. Шәймиев дәвере төгәлләнде. Разил әфәнде, сез ул дәвергә нинди бәя бирерсез һәм яңа президентның беренче адымнары турынданиләр әйтерсез икән?**

– Шәймиев дәвере – безнең халык өчен һәм безнең республика өчен тарихи чор. Шул чор эчендә без үзебезне киләчәгебез өчен җаваплы гражданнар итеп тоя башладык.

Татарстанда яшәүчеләрнең тормыш шартларын яхшырту нисбәтеннән бихисап эшләр эшләнде. Без Россиядә беренче булып торак пунктларга газ үткәрүне башкарып чыктык. Моның нәрсә икәнен авылда яшәп, мич яккан кеше генә белә. Тузган торактан арыну программасы нигезендә әле 30 нчы елларда төзелгән бараклардан күпме кеше уңайлы фатирларга күченде. Саескан тавы турысында Кама-Чулман аша күпер салынды. Аның әһәмиятен Николай II заманында Идел аркылы суздырылган Романовлар күперенеке белән генә чагыштырып буладыр. Мин үзем дә тумышым белән Кама аръягы кешесе, Казан ягына чыгу өчен кичтән килеп чират алуларны онытасым юк. Беренчедән, «вакыт – акча» булса, икенчедән, паром кичүе – үзе чыгымлы эш. Тагын бер казанышыбыз – социаль ипотека. Шәймиев башлангычын, ышанам, Рөстәм Миңнеханов яңа куәт белән алга алып китәр.

Шәймиев дәверендә мәдәният һәм гаммәви мәгълүмат чаралары игътибар үзәгендә булды. Татарча, русча, башка телләрдә никадәр яңа газета-журнал чыга башлады! Тарихи темаларга, милли мәсьәләләргә кагылышлы йөзләгән-меңләгән китап дөнья күрде. «Яңа гасыр» телевидение каналы спутник аша тапшыруга күчте. Шәймиев исеме белән бәйле бу һәммә эш татарлар өчен әһәмиятледән әһәмиятле. 80 нче еллар ахырында татар теле югалу чигенә килеп җиткән иде. Миллион кеше яшәгән Казанда бердәнбер татар мәктәбе булып, анда да «башкала киләчәге» түгел, республика районнарыннан җыелган балалар укыды. РСФСР Конституциясе гражданнарга ана телендә белем алу хокукын гарантияләп торган хәлдә бу.

Шәймиев дәвере, Шәймиевнең фидакяр хезмәтләре турында алга таба да бәйнә-бәйнә сөйләп булыр иде. Хәлбуки мин ул дәвер тәмамланды дип уйламыйм. Республиканың яңа башлыгы – Шәймиев шәкерте, һәм президентлыктагы тәүге эшләре аның шәп шәкерт булуын күрсәтеп тора. Рөстәм Нургали улын ул әле Арча районы кулланучылар җәмгыяте рәисе булган вакыттан ук беләм. Аннары Биектау районы җитәкчесе, финанс министры, премьер-министр. Кайсы вазифасында да ул арадашлык өчен ачык, эшлекле, вәгъдәле булды. Сүздә тору, «вәгъдә – иман» сыйфатын мин аерып әйтер идем, чөнки безнең илдә, хәтта иң югары җитәкчелектә дә, сүзне гамәлгә ашырмау зур гаеп саналмый. Ә Рөстәм Миңнеханов әйттеме – үти. Депутатлар фикере дә шундый, аның белән бер командада эшләүчеләр дә шулай дип раслый.

**– Күптән түгел Дәүләт Думасы Россия Федерациясе республикалары президентларының вазыйфаи исемен үзгәртү турында закон проектын карап кабул итте. Чечня Республикасы башлыгы Рамзан Кадыйровның Россиядә бер генә президент булырга тиеш дип белдерүенә сез шәхсән ничек карыйсыз?**

– Безнең халыкта «юкны бушка авыштыру» дигән гыйбарә бар. Эш күрсәтү урынына эш тирәсендә шушы рәвешле чәбәләнүләр соңгы вакытта ешрак күзәтелә. Милицияне полиция дип үзгәртүне алыйк. Әлбәттә, полиция турындагы законга заман үзе «төртеп күрсәткән» өстәмәләр кертелде, ләкин әлеге дә баягы «тышкы үзгәреш» нәрсәгә?! Аек акыллы һәр граждан бу турыда уйланмый калмагандыр. Ә язучы буларак хафалануым шуңа: Россия халыклары әдәбиятларының һәммәсендә полицай фигурасына мөнәсәбәт гаять тискәре. Моны беркая куя алмыйсың, без шул әдәбият белән тәрбияләнгән. Нәрсә, бүген бу китапларны юк итәргә тиеш булабызмы?!

Республика башлыкларының вазыйфаи исемнәрен алыштыруга килсәк, хикмәт исемдә түгел, ә тирәндәрәк, ягъни вәкаләтләрдә. Хәзерге көндә республика җитәкчесе халык тарафыннан сайлап куелмый икән, аны президент дип атау, дөресе шул, хакыйкатькә хилафлык итү ул. Ләкин без

«Татарстан Республикасы президенты» атамасына күнектек бит инде. Бу атама безнең өчен республикабыз дәүләтчелеге чагылышы.
Әгәр Татарстан президенты алга таба да президент дип атап йөртелсә, моннан Россиягә бернинди дә зыян килмәячәк. Бу уңайдан да бер шәп гыйбарәбез бар безнең: «Кычытмаган җирне кашымыйлар».
**– 2010 ел Россиянең өр-яңа тарихында икенче мәртәбә халык исәбен алу елы булды. Җанисәп нәтиҗәләре белән танышырга әле иртәрәктер. Сезнеңчә ничек, бу вакыйгага әзерлек канәгатьләнерлек булдымы?**
– Җанисәп алу һәр заманда, һәр халык өчен зур вакыйга. Ә без татарлар өчен ул сыналу да. Безнең мөкәммәл дәүләтчелегебез юк, бу – беренчедән; икенчедән**,** без – Россия буйлап таралып яшәүче милләт. Шуның нәтиҗәсе буларак, җанисәп алуда төрле проблемалар калкып чыга. 2002 елгы җанисәп вакытында татар халкын кырык алты субэтноска бүлеп теркәсәләр, бу юлы субэтнослар саны йөздән артып китте.
Әйе, татар дигән халыкның этник тамырлары төрле: Казан татарлары, Әстерхан, Себер, Касыйм татарлары, мишәрләр, типтәрләр... Без моның белән горурланабыз, төрлелегебезне милли байлык саныйбыз. Җанисәп алу идеологлары мантыйгы буенча карасаң, – мин бу турыда Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты директоры В. Тишковка да хат язып әйттем, – рус халкын тагын да күбрәк сандагы субэтноска аеру мөмкин булыр иде. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» – бу бүгенге Россия шартларына абсолют ярашсыз, империячел сәясәт. Без бит гражданлык җәмгыяте турында хыялланабыз, шуңа омтылабыз. Татарлар Россиянең территориаль бөтенлеге яклы, Россиянең бүгенге чикләре Алтын Урда дәүләте чикләренә тәңгәл диярлек. Әлеге җөмләдән әйтелгәннән артык фикер эзләү кирәкмәс. Тарих шулай хәл иткән.
Безнең Татарстанда, Аллага шөкер, аерым проблемалар юк. Татарлар татар дип, яһүдләр яһүд дип языла. Керәшен үзидентификациясе мәсьәләсе бар, шуның белән шул... Ләкин проблемалар татарлар тупланып яшәгән башка төбәкләрдә – Свердловск, Чиләбе, Оренбург өлкәләрендә, Пермь краенда һәм бигрәк тә Башкортстанда бар. Халык исәбен алуның алдагысы моны ачык күрсәтте. Чагыштыру өчен 1970 елгы җанисәп нәтиҗәләрен алсак, 32 ел эчендә бу республикада башкортлар саны – 329 мең кешегә, ягъни утыз җиде процентка, ә татарлар кырык алты мең кешегә (биш процент) арткан булып чыга. Башкортларның сан ягыннан үсеше татарлар белән чагыштырганда җиде ярым тапкыр «тизрәк» барган. Мондый хәл, әлбәттә, була алмый.
Башкортстандагы татарларга әлеге вазгыять – татар санын ясалма кыскарту ошамый, алар ярдәм сорап Татарстанга мөрәҗәгать итә. Әле ярый безнең Конституциядә 14 нче маддә бар, шуңа ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы милли мәдәният, тел һәм башка милли үзенчәлекләрне саклауда республикадан читтә яшәүче татарларга булышлык итә ала. Татарстан һәм Россия Федерациясе арасында вәкаләтләр алмашу турындагы Шартнамәдә дә шуңа кагылышлы аерым маддә каралган. Ә монысы инде юридик көче илнең барлык территориясенә тарала торган федераль закон. Быелгы җанисәп алдыннан ТР Дәүләт Советы Россия Федерациясе җитәкчеләренә һәм республикадан читтә яшәүче татарларга атап аерым мөрәҗәгать кабул итте. Аның үз эшен эшләвенә шигебез юк. Гәрчә халык исәбен алуга йомгак ясалмаса да, без нәтиҗәләрнең 2002 елгы җанисәп нәтиҗәләренә караганда объективрак булуына өметләнәбез. Алай да борчылырга урын бар. Минем үземне кайберәүләрнең битарафлыгы шөбһәгә сала. Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, гражданнарның унга якын проценты җанисәп алуда бөтенләй катнашмаган. Чынлыкта бу сан тагын да зуррактыр әле ул. Мәгълүматларны телефоннан тапшыру мөмкинлеге тудырылу гаҗәп. Нинди объективлык турында сөйләп булсын инде шуннан соң?! Телефоннан Иванов сөйләштеме, Вәлиевме – кем белгән?
**– Татарстан Президенты вазифасын калдырудан беркадәр элегрәк Минтимер Шәймиев Болгар һәм Свияжск тарихи һәйкәлләрен торгызу инициативасы белән чыккан иде. Разил Исмәгыйлевич, республикадагы тарихи-мәдәни мирасны саклау җәһәтеннән әлеге проектка карата фикерегезне әйтсәгез иде.**
– М. Ш. Шәймиев хәл итәргә тотынган проблема бүгенге яки алдагы гасыр проблемасы гына түгел. Ул – чишелешен берничә гасырлар буе көткән проблема. Белгәнебезчә, әле Петр I

Болгардагы тарих һәйкәлләренең аяныч хәленә игътибар иткән. «Яңарыш» проектына каршы кешеләр дә бар. Милли хәрәкәттә Болгарны күтәрүгә ике куллап риза булып, Свияжскины, Казанны алу өчен Иван Грозный тарафыннан махсус төзетелгән форпост санап, кире кагучылар очрый. Кайберәүләр өчен Свияжск – изге урын, православие диненең Казан янындагы тагын бер үзәге. Минем уемча, архитектура һәйкәлләренең һәрбарчасы торгызылырга тиеш. Ташларның гаебе юк. Гаеп бездә – кешеләрдә. Кем белән кем сугышмаган? Тарих бит ул. Кешелек тарихы – башлыча сугышлар тарихы, бүгенгеләргә сабак.
Болгар да, Свияжск та торгызылыр, сезнең соравыгызда куелганча, бу әле юлның башы гына. Татарстанда 10 мең тарих һәйкәле исәпләнә. Аларның яртысы дәүләт карамагында һәм акрын гына үзләренә аерым игътибар көтеп ята.
Үзем җитәкли торган комитетның гыйнвар аена тәгаенләнгән киңәйтелгән утырышында республикадагы зиратларның хәл-әхвәле мәсьәләсе күтәреләчәк. Зиратлар бит адәм баласының соңгы йорты гына түгел, кабер ташлары, һәйкәлләр, төрбәләр дә. Арада тарихи- мәдәни әһәмияткә ия булганнары да бихисап. Утырышта галимнәр, министрлык җитәкчеләре, район башлыклары булачак.

**– Октябрь аенда булып узган муниципаль сайлауларга тукталмый ярамас...**

– Президент алмашыну зур сәясәт өлкәсенә караса, «түбәндә», әлбәттә, беренче урындагы сәяси вакыйга – Татарстанда һәм бөтен Россиядә булган муниципаль сайлаулар. Кем әйтмешли, бу вакыйга сайлаучыларның активлыгы белән узды, тик шунысын әйтми мөмкин түгел – авыл җирләрендә депутат мандатына кандидатлар җитенкерәмәү күзәтелде. Ни әйтерсең, депутат вазифасы җәмәгать эше тәртибендә үтәлә, кемнең үз җилкәсенә артык йөк саласы килсен? Яңа закон нигезендә муниципаль органнарга сайлану хокукы 18 яшькәчә төшерелде. Әлеге чара яшьләрнең сәяси активлыгын арттырыр дип уйлыйм, әмма ул «эшләп китсен» өчен, мөгаен, вакыт кирәктер. Яшь кеше үз мәнфәгатьләрен мәйданнарда гына түгел, цивилизацияле юл белән хакимиятнең вәкаләтле органнарында якларга тиеш.
Муниципаль сайлаулар алдыннан ТР Дәүләт Советы республика мәктәпләрендә «Гражданин һәм сайлаулар» темасына парламент дәресләре уздырды. Хәзерге укучылар моннан ун ел элгәреге яшьтәшләреннән нык үзгә. Алар прагматик акыл белән аерылып торалар. 16–17 яшьлек үсмерләрнең күбесе Татарстанның киләчәге турында җитди уй йөртә.

**– Президент Д. А. Медведев Укытучы елы дип игълан иткән ел да тәмамланды. Укытучының абруен күтәрү эчен федераль дәрәҗәдә һәм Татарстанда нәрсәләр эшләнде?**

– Бу елны «Мәгариф» өстенлекле гомумдәүләт проектының бер ягы итеп тә карарга кирәк. Аның кысаларында укытучыларга класс җитәкчелеге өчен өстәмә түләнә башлады, мәктәпләрне техник җиһазландыруга акчалар бүленә, укытучылар һәм мәктәпләргә грантлар бирелә. Күптән түгел безнең комитет Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумында күчмә утырыш үткәрде. Ул агымдагы елда федераль үзәктән 30 миллион сум грант алган иде, Татарстан да шулкадәр үк бирде. Хәзер техникумга карап гаҗәпләнерлек! Мондый уку йортына чит ил кунакларын чакырырга да оят түгел, «Һәр укытучыга – ноутбук» программасы тормышка ашырыла. 2011 елда ул йөз процентка үтәлергә тиеш.
Моннан тыш Укытучы елында Татарстанда алдагы биш елга исәпләнгән «Киләчәк – Будущее» стратегиясе эшләнде. Аның кысаларында нәтиҗә өчен эшләүче педагоглар грантлар һәм президенттан ике оклад күләмендә өстәмә түләү алачак. Шулай ук электрон уку-укыту системасын киңәйтү, «Гыйлем йорты» фән һәм техника интерактив музеен, ТР президенты лицееннн, сәләтле балалар өчен ел әйләнәсе шөгыльләнү мөмкинлеге бирүче үзәк булдыру күздә тотыла. Шушы һәм башка максатларга республика бюджетыннан елына уртача 2 миллиард сум акча бүленәчәк. Минемчә, Укытучы елы начар тәмамланмады.
Кызганычка каршы, Укытучы елында Дәүләт Думасы мәгариф турында яңа законны кабул итмәде. Быел Президент Д. А. Медведев аны бөтенхалык тикшерүенә чыгармакчы. Әгәр бүген Россиядә мәгариф, фән, югары мәктәп турында аерым-аерым законнар гамәлдә булса, киләчәктә бу өч бердәм юнәлеш уртак нигезле документка «утыртылачак». Күптән кирәк иде. XX гасыр тарихы шуны күрсәтте, яңарыш аңыбызда башланса гына уңышлы була. Германия белән

Японияне генә алып карагыз. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң бу илләрнең икътисады хәрабә хәлендә була, һәм алар беренче итеп мәгарифне үстерү программаларын булдыралар. 10–15 ел эчендә идарә итү һәм сәнәгать өлкәләрендә төп урыннарны алдынгы кадрлар биләп ала, һәм дөньяда Германия белән Японияның икътисади могҗизасы турында сөйли башлыйлар. СССР таркалганнан соң 20 ел вакыт үтте, ә без мәгариф турында яңа закон кабул итү турында яңа гына уйлана башладык.

**– Мәгариф системасындагы милли-төбәк компоненты ни хәлләрдә бүген?**

– Әйе, яхшысын сөйләгәндә, милли мәктәпләр үсешендәге негатив тенденцияләрне дә игътибардан читтә калдырып булмый. 2007 елның 1 декабрендә 309 нчы Федераль закон кабул ителгәнче, мәгариф стандартлары өч компоненттан тора иде: федераль, милли-төбәк һәм мәктәп. Аларга укыту өлешенең җитмеш биш, унбиш, ун проценты туры килә иде. Хәзер бердәм мәгариф стандарты буенча туган тел, әдәбиятны өйрәнү «үзагышка» куела, ягъни әкренләп мәҗбүри түгелгә әйләнә. Моның Россия Конституциясендә халыкларга туган телне саклау, аны өйрәнүгә һәм үстерүгә шартлар тудыруны гарантияли торган 68 нче маддәсенә каршы килүен сөйләп тору кирәкме икән? РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының БДИны бары тик рус телендә генә тапшыру турындагы карары мәкерле күренә. Безнең оппонентлар тел альтернативасы булу рус телен какшата дип белдерә. Бу көлке! Рус теленнән БДИ мәҗбүри һәм аны теләсә кайсы башка телдә бирү мөмкин түгел. Балалар рус телен белми калыр дигән сүзләр ышандырмый. Бу җәһәттән безнең ата-аналар РФ Югары судына мөрәҗәгать итте, ә Казанның 2 нче татар гимназиясеннән бер ана Страсбург судына кеше хокуклары буенча гариза язды.

Милли мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләрдә мин әгъза булып торган «Татарстан – Яңа гасыр» фракциясе үз сайлаучылары мәнфәгатьләрен ахырга кадәр якларга тырыша. Безнең башлангыч белән Дәүләт Думасында махсус эш төркеме булдырылды, бу төркемнең кайбер карарлары мәгариф турындагы яңа закон проектына да кертелде. Күптән түгел Казанда РФнең Федерация Советы рәисе Сергей Миронов булып китте. Ул проблеманың булуын, Дәүләт Думасы һәм Федераль Җыелышның мәгариф системасыннан милли-төбәк компонентын ашыгып алуларын таныды. Без, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутатлары, болар белән генә канәгатьләнергә җыенмыйбыз.

**– Узган ел юбилейларга бай булды. Алар арасында Сезнең игътибарны ТАССРның 90 еллыгына юнәлтәсем килә.**

– Парламентта бу мәсьәләне тикшергәндә, кайбер депутатлар шикләнү белдерде. Татар дәүләтчелегенең 1500 еллык тарихы бар бит. Ә тарихыбызның өр-яңа өлешен без 1990 елның 30 августында мөстәкыйльлек турында декларация кабул иткән көннән башлыйбыз. Ни өчен бу юбилей билгеләнми?! Шул ук вакытта ТАССРның 90 еллыгын билгеләү дә начар түгел. Ни дисәң дә, 1552 елда Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, татарлар 1920 елда беренче тапкыр дәүләтчелеккә ия була. Әйе, бик аз хокукларда, әмма шулай да. Минемчә, без бу юбилейны лаеклы үткәрдек. Тинчурин театрына – 1920 елда автономиянең оештыру җыелышы үткән бинага – мемориаль такта элдек, С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында республиканың элекке һәм хәзерге җитәкчеләре катнашында тантана үткәрдек, вакытлы матбугатта бу темага бик күп язмалар чыкты.

**– 23 декабрьдә ТР Дәүләт Советының киңәйтелгән утырышында депутатлар 2010 елга йомгак ясадылар. Иң мөһим эшләр дип кайсыларын саныйсыз?**

– Соңгы вакытта Дәүләт Советы Татарстан законнарын федераль законнарга яраклаштыру буенча күп эшләде. Монда да проблемалар бар. Егермедән артык федераль законның РФ Конституциясенә туры килмәве турында эксперт тикшерүе әзерләдек һәм күрсәттек. Мәсәлән, Россия Федерациясенең Төп Законы гражданнарга тугыз сыйныфлы төп белем алуны гарантияли. Бүгенге көнгә гамәлдә булган мәгариф турындагы законда гомуми урта белемне гарантияләү турында сүз бара. Һәм бу бердәнбер казус түгел. Прокурор кушуы буенча, без законнарны федераль законнарга тәңгәлләштерергә тиеш.

Безнең комитет, гомумән алганда, 18 фундаменталь закон эшләп кабул итте. Хәзер без аларның мониторингы белән шөгыльләнәбез. Чөнки заман алга бара, кичә бар көченә эшләгән законнар

бүген төзәтмәләр кертүне сорый. Бу эшкә Казан университеты галимнәре һәм төрле дәрәҗәдәге экспертлар җәлеп ителә. Шуны да искә алып китик, безнең парламент Россиядә беренче булып закон чыгару эшчәнлегенә мониторинг үткәрә башлады.

**– Соңгы вакыттагы зур вакыйгалардан 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын Россиядә үткәрәчәге турында FIFA карарын әйтми калып булмый. Чемпионат үтү ихтималы булган 13 шәһәр арасында Казан да бар...**

– Мәктәптә укыган елларда теләсә кайсы үсмер кебек футбол уйнасам да, мин спорттан ерак кеше. Әлбәттә, бу Россия өчен дә, Татарстан өчен дә зур вакыйга. Монда хикмәт спортта гына түгел, Казанга бөтен дөньядан җанатарлар да киләчәк дигән сүз. Алар безнең шәһәрне күрәчәк, татарларның һәм Татарстанда яшәүче башка халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән танышачак. Спорт – халыкларны якынайту чарасы ул. Менә дигән стадионнар төзү белән мавыгу гына түгел, үзебезнең спортчыларны да тәрбияләргә кирәк. Чит илләрдән уенчылар сатып алу өчен әллә ни зур акыл кирәкми. Хәзер менә Россиягә чит илләрдә танылу алган галимнәрне чакырырга уйлыйлар, шул исәптән үзебезнең ватандашларны да кире кайтармакчы булалар. Әгәр болай дәвам итсә, озакламый француз язучыларын чакыра башлаячакбыз: менә сезгә фәлән миллион евро, килегез дә бездә нинди кешеләр яшәве турында языгыз. Бу юл тупикка илтә. Киңрәк карау кирәк – икътисадны да, спортны да, мәдәниятне дә, фәнне дә, мәгарифне дә үстерү зарур. Шул вакытта гына без алга киткән илләр рәтенә басачакбыз.

**– Разил Исмәгыйлевич, үткән елның кайсы вакыйгасын аерып билгеләр идегез?**

– Аллага шөкер, безнең тормышны авырайткан вакыйгалар күп булмады. Сәясәттә беренче зур вакыйга – президент алышыну, икенче урында – муниципаль сайлаулар. Мәдәният өлкәсендә шулай ук һәрнәрсә үз чираты белән барды кебек. Тинчурин театрын, ниһаять, реставрацияләп ачтылар. Яхшы эчтәлекле «Бибинур» татар фильмы күрсәтелде. Шаляпин, Нуриев фестивальләренең уңышын билгелиләр, гәрчә мин үзем опера театрының эшчәнлегеннән канәгать түгел. Ул республика бюджетыннан яхшы гына акчалар үзләштерә, әмма аның сәхнәсендә Татарстанның милли мәдәнияте юк диярлек. Республиканың иҗат коллективлары беренче чиратта үзләренең милли кадрларын әзерләүгә игътибар бирергә тиеш. Әмма, кызганычка каршы, мәдәният өлкәсендә без футбол һәм хоккей юлыннан барабыз. Зур акчаларга «варяглар» чакырабыз, шул ук вакытта үзебезнең иҗади коллективларга акчаны экономиялибез.

Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның 75 яшенә багышланган театр фестивале бик ошады. Анда Россиядәге бөтен татар театрлары да катнашты. Татарстанда мондый чара үткәне юк иде әле. Ун көн дәвамында Казанның берьюлы берничә театр мәйданында бер үк драматургның әсәрләре куелсын әле! Үземә килгәндә, быел композитор Шамил Тимербулатов белән Бөек Җиңүгә багышланган «Утлы хәтер» симфония-ораториясен тәмамладык. Бу эшкә алынганда шикләнгән идем, – моңа кадәр ораторияләр белән кызыксынган булмады, – әмма бик кызыклы жанр булып чыкты ул. Шамил Харис улы дуэтның үз өлешен бик яхшы башкарды, ә калганын тыңлаучы хөкеменә калдырыйк.

*Әңгәмәдәш Алексей Егоров*

*2011*

Литературно-художественное издание

**Валеев** Разиль Исмагилович

**ЗАБОТЫ ЗЕМНЫЕ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Вәлиев** Разил Исмәгыйль улы

**ДӨНЬЯ ГАМЕ**

Мөхәррире *Р. Ә. Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т. В. Гредюшко*
Корректорлары *Г. Г. Зиннәтуллина, С. Н. Галимуллина, Г. Г. Гарифуллина,*
*Г. М. Хәбибуллина, Л. Р. Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.11.2011. Форматы 70×100 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 48,1. Тиражы 3000 д. Заказ Р-1845.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча**
**сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.